Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫНДА ХАТЫН-КЫЗ МӘГАРИФЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Документлар җыентыгы

Казан – 2020

УДК 396.4(376.72)
ББК 74.03(2)
Е 25

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

**Фәнни редактор**

*Гибатдинов М.М.*, педагогика фәннәре кандидаты

**Рецензентлар:**

*Мәрданов Р.Ф.*, филология фәннәре кандидаты

*Байбулатова Л.Ф.*, тарих фәннәре кандидаты

Е 25 **ХХ гасыр башы татар вакытлы матбугатында хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләре (документлар җыентыгы)** / төзүче-авторлар *Мортазина Л.Р., Зиннәтуллина А.Ә.* – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2020. – 380 б.

ISBN 978-5-94981-352-2

Китапта XX гасыр башында дөнья күргән татар газета һәм журналлары – «Әл-Ислах», «Сөембикә», «Вакыт», «Шура», «Тормыш», «Сибирия»дә басылган, татар хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр туплап бирелде. Җыентык галимнәргә, аспирантларга, студентларга һәм татар мәгарифе тарихы белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-352-2

УДК 396.4(376.72)
ББК 74.03(2)

© Мортазина Л.Р., Зиннәтуллина А.Ә., 2020
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2020

# ЭЧТӘЛЕК

**Кереш.**
«Татар дөньясының якты көнгә чыгуы хатын-кызларны тәрбия итүгә баглыдыр»...... 4

**I бүлек.**
«Мөслимә улдыгымыз сәбәпле, уку безгә дә фарыз» ...... 13

**II бүлек.**
«Дини рух, милли тойгы бирә торган тәрбия йортында укучы кызлар»...... 84

**III бүлек.**
«Шатлыклы вә тантаналы бәйрәм кичәләрен беренче мәртәбә күрүемезгә сәбәпче булуы өчен...»....... 182

**IV бүлек.**
«Галим вә мөгаллимнәр халыкка белем, фикер вә рух бирсәләр, матди куәтне бирүче – гади һөнәрчеләрдер» ...... 194

**V бүлек.**
«Ысул тәрбиягә вакыйф мөгаллимәләр йитешә башласа гына, кызлар арасына гыйлем вә фикер керә»...... 209

**VI бүлек.**
«Бала тәрбиясе кем кулында?»...... 261

**VII бүлек.**
«Милләткә файдалы хезмәт итсеннәр!» ...... 274

**VIII бүлек.**
«Иганә сахибләренең һәркаюсына самим калебтән тәшәккер кылып, рәхмәт укыйбыз»...... 289

**IX бүлек.**
«Мөселман кызларының хәленнән» ...... 327

Җыентыкта файдаланылган газета һәм журналлар турында кыскача мәгълүмат ...... 363

Авторлар һәм шәхесләр күрсәткече ...... 365

Географик атамалар күрсәткече ...... 377

# КЕРЕШ

## «ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ЯКТЫ КӨНГӘ ЧЫГУЫ ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫ ТӘРБИЯ ИТҮГӘ БАГЛЫДЫР»

### XX гасыр башы татар матбугатында хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләре

«Тәрбияле аналар, мәгълүматлы кызлар булса,
күп гасырлардан бирле мөселманнар арасында
олы галимнәр һәм шөһрәтле әдипләр җитешер иде»
*(Риза Фәхретдин)*

XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты шул чорда татар-мөселман дөньясы проблемаларын тикшерүдә иң кыйммәтле, бай, шул ук вакытта чагыштырмача аз өйрәнелгән чыганакларның берсе булып тора. Ул үзенең беренче көннәреннән үк татарларны һәм башка төрки халыкларны төрки-мөселман дөньясы, Россия халыклары һәм бөтен дөнья хәлләре белән таныштырып баруны үзенең төп максаты иткән. Газета-журнал битләрендә сәясәт, сәнәгать үсеше, икътисади мәсьәләләр, халыкара мөнәсәбәтләр һәм башка бик күп проблемалар чагылыш тапкан. Җәмгыятьтә барган яңарыш, мәдәният, мәгариф өлкәсендәге яңалыклар, хатын-кыз эмансипациясе мәсьәләләре шул заман төрки-татар җәмәгатьчелегендә зур кызыксыну уяткан. Хатын-кыз мәгарифе, хатын-кызның җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге урыны, хокуклары һәм вазыйфалары кебек проблемалар вакытлы матбугатта аеруча киң яктыртылган.

Совет чорында татар вакытлы матбугатының Октябрьгә кадәрге дәвере беркадәр өйрәнелсә дә, татар педагогик фикере үсеше тарихын, аеруча хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләрен, фәнни тикшерүдә төп чыганак буларак киң файдаланылмады, объектив бәя тапмады. 70нче еллар ахырында дөнья күргән хезмәтләрдә, аерым алганда, Я.Г.Абдуллин, Р.Г.Әмирханов тикшеренүләрендә[1], татар мәгърифәтчелек фикере, мәгариф мәсьәләләрен өйрәнүдә XX гасыр башы вакытлы матбугаты язмалары файдаланылды. Соңгы елларда Октябрьгә кадәрге чорда татар вакытлы матбугатында белем һәм тәрбия

[1] Абдуллин Я.Г. Татарская просветительская мысль. Казань: Татар. кн. изд-во, 1976. 319 с.; Амирханов Р.У. Татарская демократическая печать (1905–1907 гг.). М.: Наука, 1988. 191 с.

мәсьәләләре Н.Ә.Ваһапов хезмәтләрендә тикшерелде, аларда өлешчә хатын-кыз мәгарифе проблемалары да чагылыш тапты[2].

Татарларда хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләрен җентекләп өйрәнгән галимнәр арасында А.Х.Мәхмүтова, Т.Ә.Биктимироваларны аерым атап үтү кирәк. Әлеге авторлар хезмәтләрендә XIX–XX гасырлар чигендә хатын-кызлар өчен мәктәпләр барлыкка килү, аларның эше, аерым педагогларның тормыш юлы һәм эшчәнлеге яктыртыла, хатын-кыз мәгарифенең үсеш сәхифәләрен ачыклауда татар вакытлы матбугатында дөнья күргән мәкаләләр файдаланыла[3]. Моннан тыш, соңгы елларда XX гасыр башында дөнья күргән кайбер газета һәм журналларда татар хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләренең яктыртылышына багышланган фәнни мәкаләләр дә күренә башлады[4]. «Мәктәп», «Тәрбия», «Мөгаллим» кебек педагогик басмаларда басылган материалларның бер өлеше ике томлык «Татар педагогик фикере антологиясенә»[5] кертелгән.

Шул ук вакытта, хәзерге көнгәчә хатын-кыз мәгарифе һәм гомумән XX гасыр башында хатын-кыз мәсьәләләрен өйрәнүдә татар матбугаты мирасының тулысынча файдаланылмавын әйтеп китү урынлы булыр. «Вакыт», «Кояш», «Әл-Ислах», «Йолдыз», «Фикер», «Сибирия», «Тормыш», «Сөембикә», «Шура» кебек басмаларда дөнья күргән бик күп мәкаләләр мәгариф тарихын өйрәнүчеләрнең күз уңыннан һаман да читтә кала килә. Ә бит

---

[2] Вагапов Н.А. Проблемы образования и воспитания в татарской периодической печати (1907–1916 гг.). Автореф. дисс. ... к.и.н. Казань, 2006. 29 с.; Ваһапов Н.Ә. Татар вакытлы матбугатында мәгариф һәм тәрбия мәсьәләләренең чагылышы (1907–1916 еллар). Казан, 2010. 188 б.

[3] Махмутова А.Х. Становление светского образования у татар: борьба вокруг школьного вопроса (1861–1917). Казань, 1982. 96 с.; Мәхмүтова А.Х. Вакыт инде, без дә торыйк... (Җәдитчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. 366 б.; Биктимирова Т.Ә. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. Казан: 2001. 140 б.; Биктимирова Т.Ә. Ил язмышын салып иңнәренә. Казан: «Алма-Лит», 2006. 239 б. һ.б.

[4] Галихузина Д.С. Проблема женского образования в освещении журнала «Шура» (1908–1917 гг.) // Ученые записки Казанского университета. Серия Гуманитарные науки. 2010. Т. 152. Кн. 1. С. 58–65; Зиннатуллина А.А. Освещение деятельности мусульманских женских благотворительных обществ на страницах некоторых татарских периодических изданий (1908–1917 гг.) // Татар педагогик фикере үсеше мәсьәләләре. Казан, 2011. С.142–145; Брилева Д. О женщине и устами женщины: мусульманка в татарской периодической печати начала XX века // Государство, религия и церковь в России и за рубежом. 2018. № 2. С. 17–36; Муртазина Л.Р., Зиннатуллина А.А. Проведение экзаменов в татарских женских школах (по материалам татарской периодической печати начала XX века) // Научно-педагогичекое обозрение. 2019. №6 (28). С.178–184; Муртазина Л.Р. «Хорошее обучение одной девушки выгоднее, чем обучение десяти юношей» (проблемы женского образования на страницах газеты «Вакыт» в 1906–1918 гг.) // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2020. №10. Т. 1. С. 71–85 һ.б.

[5] Татар педагогик фикере антологиясе. Ике томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Т. 2. 2016. 407 б.

революциягә кадәр татар телендә 35 газета, 32 журнал чыккан[6]! Бу бай мирасны файдалану күп кенә фәнни мәсьәләләрне тулырак өйрәнүдә, күп аспектларга үзгәчә карарга ярдәм итәр иде. Шуның белән бергә, татар вакытлы матбугатында дөнья күргән милли, кыз балалар тәрбиясенә багышланган мәкаләләрнең бүгенге көндә дә әһәмиятләрен югалтмауларын әйтеп үтәргә кирәк.

XX гасыр башы татар матбугатында татар һәм башка төрки-мөселман халыкларының мәгарифенә бәйләнешле бик күп проблемалар чагылыш тапкан. Бигрәк тә яңача эшләүче җәдит мәктәпләре һәм аларның эчтәлеге, эшчәнлеге, мөгаллимнәре, дәреслекләр, әлеге мәктәпләргә матди һәм мәгънәви ярдәм күрсәтүчеләр һ.б. турындагы мәгълүматлар киң яктыртылган. Хатын-кызлар проблемаларына килгәндә, әлбәттә, беренче чиратта аларга белем һәм тәрбия бирү, дөньяга карашларын һәм күзаллауларын киңәйтү, гаиләдә һәм гомумән җәмгыятьтә тоткан урыннарын ачыклау һәм әһәмиятләрен арттыру һ.б. мәсьәләләр күтәрелгән. Кызлар тәрбиясе – «булачак милләт аналарын тәрбияләү»гә игътибар аеруча зур булган. Бу мәсьәлә гомумән милләт алдында торган иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе буларак каралган, чөнки аналар тәрбиясеннән милләтнең киләчәге бәйле булган. Риза Фәхретдин сүзләре белән әйткәндә, «Хатыннары тәрбияле булган милләт – тәрбияле; хатыннары тәрбиясез милләт – тәрбиясез; хатыннары тырыш вә идарә итүчән милләт – бай; хатыннары ялкау вә исраф итүчән милләт фәкыйрь буладыр»[7].

Хатын-кыз мәгарифе XX гасыр башында бик актуаль булган хатын-кыз мәсьәләсенең мөһим бер өлеше буларак каралган. Шул рәвешле хатын-кызның җәмгыятьтә һәм гаиләдә тоткан урынын билгеләү, әһәмиятләрен арттыру, гаиләдә ирләр белән бертигез хокуклылыгына ирешү кебек гомумән Россия күләмендә әһәмиятле мәсьәләләр белән беррәттән, мөселман хатын-кызларына тиешенчә белем-тәрбия бирү, мәктәпләр ачу, мөгаллимәләр җитештерү һ.б. проблемалар да күтәрелгән.

Хатын-кыз мәсьәләләре, педагогик журналлар белән беррәттән, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-публицистик басмаларда да киң чагылыш тапкан. Иң беренче чиратта, әлбәттә, «Сөембикә» журналын атап китү дөрес булыр. Шулай ук мөхәррирләренең берсе хатын-кыз (Фатыйма-Фәридә Нәүрүзова) булган «Сибирия» (Томск), аның дәвамы буларак чыккан «Тормыш» (Уфа) газеталарында да хатын-кыз мәсьәләсе иң күп яктыртылганнарның берсе була. Әлеге ике басмада туташ һәм ханымнарыбыз өчен махсус сәхифәләр – «Хатын-кыз дөньясы», «Хатын-кыз галәме» рубрикалары эшләп килгән. Аларда хатын-кыз мәктәпләренең һәм аерым педагогларның эшчәнлеген,

[6] Нуруллина Р.М. Татарча вакытлы матбугатка – 100 ел! // Татарская периодическая печать: Научно-энциклопедическое издание / Сост. и науч. ред. Р.А.Айнутдинов, З.З.Гилазев. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. С. 178.

[7] Фәхреддин Р. Тәрбияле ана. Тәрбияле хатын. Казан: Рухи Мәгърифәт Академиясе, 2006. Б. 23.

педагогик тәҗрибәсен, хокукый һәм гаиләдәге хәлләрен яктырткан мәкаләләр, җәмгыятьтә кысынкылык яки гаиләдә авырлык кичергән ханымнарның милләттәшләреннән рухи ярдәм сорап язган яки үз хәлен тасвирлаган хатлары, язмалары урын алган.

«Сөембикә» журналында шул заман татар җәмгыяте, татар тормышы өчен әһәмиятле булган темаларга, бигрәк тә хатын-кызлар яшәеше мәсьәләләренә караган фикер алышуларда, ирләр белән беррәттән, хатын-кыз авторлар, шул исәптән билгеле шәхесләр, мөгаллимәләр, кызлар мәктәпләре җитәкчеләре, мәсәлән, Багбостан Мөэминова, Маһруй Мозаффария, Фәхрелбәнат Сөләймания, Камилә Мозаффарияләр һ.б. катнашкан. Журналдагы «Тәрбия кыйсеме» дигән махсус сәхифәдә балалар тәрбиясенә караган язмалар урын алган. Мөселман хатын-кыз мәктәпләре һәм татар мөгаллимәләренең хәле, педагогик кадрлар әзерләү (дарелмөгаллимат ачу, курслар үткәрү) проблемалары белән беррәттән, башка илләрдә хатын-кызларның тормышы, мәктәпләре һәм тәрбия үзенчәлекләренә багышланган мәкаләләр укучыларда зур кызыксыну уяткан.

Хатын-кыз мәгарифен яктыртуда башка татар басмалары да калышмаган. Казан шәһәрендә ике елга якын (1907–1909) чыгып килгән «Әл-Ислах» газетасында хатын-кыз мәсьәләләренә багышланган «Хатын-кыз галәме» дигән махсус сәхифә булган. Анда Россиянең төрле төбәкләрендә кызлар мәктәпләре ачу һәм мөгаллимәләр әзерләү, хатын-кыз мәгарифенең торышы һәм проблемаларына багышланган язмаларга урын бирелгән. Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең матди ярдәме нигезендә Риза Фәхретдинов мөхәррирлегендә дөнья күргән, төрки-татар дөньясында киң популярлык яулаган «Шура» журналы (Оренбург, 1908–1917), мәктәп-мәдрәсә, тәгълим-тәрбия, мәгарифнең гомуми мәсьәләләре белән беррәттән, хатын-кыз мәгарифен яктыртуга да зур әһәмият биргән. Анда татар хатыннарының хокуклары, гаиләдәге хәле, тәрбиясе, хатын-кыз мәктәпләре, кыз балаларны укыту үзенчәлекләре һ.б. темаларга караган язмалар урын алган. 9 ел дәвамында чыгып килгән журналда хатын-кызлар мәгарифенә багышланган егерме биш мәкалә дөнья күргән[8]. Авторларны киләчәктә «милләт аналары» булып җитешәчәк кыз балаларны тәрбияләү мәсьәләсе борчыган, чөнки алар милләтнең алга баруын кызларга яхшы белем бирү белән бәйләп караганнар: «Бер милләтнең хатыннары никадәр хөр вә тәрәккыйгә малик булса, ул милләт шулкадәр үк мәсгуддер. Әгәр без, милләтемезнең тәрәккый итүен вә балаларымызның сәгадәттә яшәүләрен эстәсәк, кызларымызны вакытсыз укудан тыю урынына, бу юлда үземез тырышлык итеп, мөмкин кадәр аларның «белем» арттыру вә укуларына иҗтиһад итәргә кирәк»[9]. Басманы җентекләп өйрәнгән галим М.Госманов сүзләре белән әйткәндә, «гасыр

[8] Галихузина Д.С. Проблема женского образования в освещении журнала «Шура» (1908–1917 гг.) // Ученые записки Казанского университета. Серия Гуманитарные науки. 2010. Т. 152. Кн. 1. С. 60.

[9] Хәтимә-Нәзифә. Кыз балаларны яшьли укудан алу // Шура. 1915. № 12. Б. 373–374.

башындагы иҗтимагый, мәдәни, рухи хәятебезне яхшылап белергә, аңларга теләгән һәм теләүчеләр өчен «Шура» журналы бетмәс-төкәнмәс чыганаклар хәзинәлеге булып хезмәт итте һәм киләчәктә дә дәвам итәчәк»[10]. Хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләрен өйрәнүдә аеруча.

1906–1918 елларда Оренбург шәһәрендә бертуган Рәмиевләр акчасына чыгып килгән абруйлы «Вакыт» газетасын хатын-кыз мәгарифе һәм гомумән хатын-кызлар проблемаларына иң күп әһәмият биргән басма дисәк, һич тә ялгыш булмас. Газетада татарлар белән беррәттән, башка мөселман халыкларда белем һәм тәрбия мәсьәләләре, шулай ук Россиядә һәм чит илләрдәге хатын-кыз мәгарифенең торышы да яктыртыла. Хатын-кыз мәгарифенә караган мәкаләләр «Дахили хәбәрләр» («Дәүләт эчендәге хәбәрләр»), «Оренбург хәбәрләре», «Уфа хәбәрләре», «Казан хәбәрләре», «Әтраф хәбәрләре» сәхифәләрендә аеруча күп очрыйлар.

XX гасыр башы вакытлы матбугаты Россиянең төрле төбәкләрендә ачылган татар хатын-кыз мәктәпләре, аларда укучылар, педагогик коллективлары, мәктәп бинасын салуда һәм аны тотуда зур ярдәм күрсәткән иганәчеләрне билгеләүдә дә бик кыйммәтле чыганак булып тора. Аларда басылган язмалардан Казан, Оренбург, Уфа, Пенза, Самара кебек Россиянең үзәк шәһәр һәм губерналары гына түгел, Семипалатинск, Казалы, Тоз-Түбә, Алма-Ата кебек читтәрәк урнашкан өлкәләрдәге мәктәпләр турында да мәгълүмат тупларга мөмкин. Кайбер мәкаләләр хатын-кыз мәгарифендәге моңарчы билгеле булмаган яки аз билгеле булган факт һәм вакыйгаларны ачыклауда да ярдәмче була алалар.

XX гасыр башы – хатын-кыз мәгарифендә зур күтәрелеш чоры. Ул җәдиди мәктәпләр ачылу, аваз ысулына нигезләнеп укыту, дөньяви предметлар кертелү, мөгаллимәләр әзерләүгә нигез салыну кебек әһәмиятле яңалыклар белән билгеләнә. Яңа өлкә булу сәбәпле, кызлар мәктәпләрендә беренче елларда ирләр мәктәбе яки рус хатын-кызлар һәм рус-татар мәктәпләре тәҗрибәсенә таянып эшләнә. Башка чит илләрдәге милләтләр тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итү очраклары да еш булган. Бу турыдагы мәкаләләр газета-журнал битләрендә урын алган. Атаклы мөгаллимә, Оренбургта кызлар мәктәбе җитәкчесе Багбостан Мөэминова, мәсәлән, үзенең Төркия уку йортлары, анда хатын-кызларны укыту һәм тәрбия бирү эшенең торышы турындагы фикерләре белән «Сөембикә», «Вакыт» укучылары белән уртаклаша[11].

Хатын-кыз укытучылар әзерләү мәсьәләсе XX гасыр башы татар җәмгыятендә торган иң мөһим мәсьәләләрнең берсе санала. Дарелмөгаллимат, ягъни

[10] Госманов М. «Шура» журналы һәм аның библиографик күрсәткече // М.Г.Госманов, Р.Ф.Мәрданов. «Шура» журналының библиографик күрсәткече. Казан: «Милли китап» нәшр., 2000. Б. 8.

[11] Багбостан. Истанбул хатирәте // Сөембикә. 1914. №22. Б.4–8; Багбостан. Истанбул хатирәләре (Төркиядән мәктүб) // Вакыт. 1914. 25 июнь.

хатын-кыз мәктәпләре өчен мөгаллимәләр әзерләүче уку йортлары, ачу турындагы мәкаләләр татар вакытлы матбугатында еш дөнья күрә.

Вакытлы матбугатта чагылыш тапкан проблемалар үзләренең төрлелеге, киңкырлылыгы белән аерылып торалар. Мәсәлән, «Вакыт» газетасында 1910 елда Оренбургта кызлар мәктәбе каршында кызларга яшәү өчен махсус бина (интернат, тулай торак) булдыру вакыйгасы сурәтләнә. Шул рәвешле, заманы өчен иң мөһим мәсьәләләрнең берсе хәл ителә, ерак җирләрдән кызларын укытырга җибәргән ата-аналар бу хәлгә сөенүләрен белдереп хәбәр итәләр[12].

Матбугат чараларында дөнья күргән язмаларга караганда, татар җәмәгатьчелеге кызлар мәктәбе эшчәнлегенә битараф булмаган. Уку елы башында, һәм аеруча ахырында үткәрелгән ачык сынауларга, кыз балаларның ата-аналарыннан тыш, иганәчеләр, шул җирлектәге зыялылар һәм гомумән, хатын-кыз мәгарифе белән кызыксынган затлар килгән. Имтиханнардан соң үткәрелгән кул эшләре күргәзмәләре, әниләр һәм башка хатын-кызлар өчен махсус әзерләнгән лекцияләр турындагы мәгълүматлар матбугат битләрендә яктыртылып барылган. Мондый төр чаралар һәм алар белән җәмәгатьчелекне таныштырып бару татарлар арасында кул эшләренең яңа төрләре таралуга китергән, кызыксыну уяткан, кызларга һөнәр өйрәтүнең әһәмиятен ассызыклаган. Чөнки укучы кызлар – булачак аналар, гаилә учагын саклаучылар, аларны кул һөнәрләренә өйрәтү киләчәктә гаиләнең матди хәлен яхшыртуга, балаларны да шул рухта тәрбияләүгә зур өлеш кертәчәк. Моның белән беррәттән, татарлар арасында яхшы, яңа мода буенча хатын-кыз киемнәре тегүчеләрнең булмавы яки аз булуы, нәтиҗәдә татар хатыннарының башка милләт, аеруча яһүд, тегүчеләренә мөрәҗәгать итүләре, шул рәвешле татар кулында калырга тиешле акчаның башка милләт карамагына күчүе татар җәмәгатьчелегендә зур борчу тудырган[13]. Бу исә татар кызлары өчен һөнәр мәктәпләре ачу яки аларны рус һөнәр мәктәпләренә биреп укыту юлларын эзләргә этәргән.

Һөнәр үзләштерү, кызлар мәктәбендә алган белемне дәвам иттерү, яшь туташларга махсус һәм югары һөнәри белем бирү мәсьәләсенең актуаль булуы төрле язмаларда чагылыш таба. «Вакыт» газетасында басылып чыккан шундый мәкаләләрнең берсендә танылган иганәче Гәүһәр Рәмиева мәктәбендәге имтиханнардан соң мөгаллимә Әминә ханым тарафыннан укылган лекция турында мәгълүмат бирелә. Мөгаллимәнең чыгышында татар хатын-кызлары арасында һөнәри белем алуның мәҗбүрилеге мәсьәләсе күтәрелә, кызларны урта һәм югары мәктәпләргә керүгә әзерләүнең мөһимлеге, «хәзерге көндә иң бөек бер ихтыяҗ булган акушерлыкка, фельдшерица, табибәлек хезмәтләрен үтәрлек кешеләр чыгарырга тиешлеге» ассызыклана.

---

[12] Кызлар укыту // Вакыт. 1910. 30 сентябрь.

[13] Зиннатуллина А.А., Муртазина Л.Р. На пути к становлению и развитию женского профессионального образования: рукоделие в татарских женских школах в начале XX века // Вестник Оренбургского государственного педагогического университета. 2020. № 3 (35). С.206–215.

Әминә ханым хатын-кызларга үзләренә тырышырга, белем алырга, күтәрелергә вакыт җиткәнен, элеккеге кебек «гомер буе ирләргә генә таянып торырга ярамаганлыгын белдергән»[14].

Кызлар мәктәпләрендә дәрестән соң үткәрелгән чаралар, төрле юнәлештәге кичәләр, дини бәйрәмнәр, экскурсияләргә зур игътибар бирелгән. Газета һәм журналларда «Бәраәт кичәсе», «Мәүлид ән-Нәби» кебек дини бәйрәмнәр белән беррәттән, атаклы татар шагыйре Габдулла Тукайга багышланган шигырь бәйрәмнәре, искә алу кичәләре турында материаллар шактый.

Матбугатта киң күләмдә чагылыш тапкан тагын бер мөһим мәсьәлә – хатын-кызларның хәле, уку-тәрбиягә карашлары, кызларны укытуда туган проблемалар, җәмгыятьтә тоткан урыннары, гаиләдәге аянычлы хәлләре һәм аны үзгәртүгә омтылыш һ.б. Әлеге темаларны яктырткан аналитик мәкаләләрнең авторлары булып күп очракта хатын-кыз мәктәпләре мөгаллимәләре һәм укучы кызлар үзләре торган.

Россиянең төрле почмакларыннан килгән хатларда хатын-кыз мәктәпләренең эшен үзгәртү, яхшырту турындагылары да шактый. Мәсәлән, 1906 елда Казалыдан килгән бер хатта укучы кызлар мәктәпне үзгәртү, кыз балаларны язуга өйрәтү, тагын бер мөгаллимә билгеләү мәсьәләсен күтәрәләр, хәтта аңа түләүнең дә юлын күрсәтәләр[15].

Кайбер язмаларда җәмгыятьтә кызлар мәктәпләренә булган карашны үзгәртү кирәклеге мәсьәләсе күтәрелә. «Вакыт» газетасында басылып чыккан шундый мәкаләләрнең берсендә кайбер ата-аналарның дини предметлар белән беррәттән дөньяви, шул исәптән рус теле дә, укытылган мәктәпләргә балаларын бирергә теләмәүләре хәбәр ителә. Нәтиҗәдә мондый мәктәпләр, бала саны аз булу сәбәпле, ябылуга дучар булганнар. Казанның Яңа татар бистәсендәге кызлар мәктәбе әнә шул сәбәп аркасында 1910 елда эшчәнлеген туктата.

Хатларда татарлар арасында хатын-кыз мәгарифенең әһәмияте ассызыклана, хатын-кызлар тормышы башка милләтләр белән чагыштырыла, бу мәсьәләгә карата җәмәгатьчелекнең фикерен ишетү теләге сизелә. Шундый язмаларның берсендә: «Ватандашларыбыз булган руслар үзләренең кызларын монтазам шәһәр мәктәпләрендә, гимназияләрдә укыталар. Аның илә генә дә канәгатьләнмиләр, югары мәктәпләргә җибәреп, әдәбият вә голүм тәхсил иттерәләр, хәтта Яурупага җибәреп укыталар. Безнең этиләр исә безнең өчен адәм гакыллы бер ибтидаи мәктәп тә ачып бирмиләр; руслар кызларын укытыр өчен бөтен байлыкларын сарыф итәләр, безнең этиләр исә кызларын укытырга бөтенләй әһәмият бирмиләр», – дигән юлларны укырга мөмкин[16].

Әлбәттә мондый хатлар җәмәгатьчелектә фикер уяткан. «Хокукны саклау исә ялгыз гыйлем вә мәгърифәт аркасында гына мөмкин. Мәгърифәтсез кешеләр җиңелә вә аяк астында изелә. [...] Шушы дөньяда торып яхшы

---

[14] Каргалыда Гәүһәр ханым Рәмиева мәктәбе // Вакыт. 1914. 9 май.
[15] Казалыда укучы кызлардан аталарына ачык хат // Вакыт. 1906. 13 июнь.
[16] Хатын-кыз мәктүбләреннән // Вакыт. 1911. 20 гыйнвар.

мәгыйшәт итә алыр өчен Марияга кирәк булган гыйлемнәрнең шуның илә бер шәһәрдә, бер урамда, вә хәтта бер йортта торучы Фатыймага, Гайшәгә кирәк булмавы, әлбәттә, мөмкин түгелдер. Чөнки мәгыйшәтнең кануннары боларның икесе өчен дә бертигездер», – дигән юлларны редакция хезмәткәре тарафыннан бирелгән җавап хатында укырга мөмкин[17].

«Милләт аналары» тәрбияләү мәсьәләсе, әйтеп узылганча, XX гасыр башы татар матбугатында күтәрелгән иң мөһим проблемаларның берсе, шуңа күрә дә, «Бер кызны яхшы укыту ун ир бала укытудан да файдалырактыр. Чөнки кыз бала гаилә башлыгы, балалар анасы булгач, ул үзенең гыйлем вә мәгърифәте илә бөтен бер гаиләне яктырта, балаларын гүзәл тәрбия итеп, инсаният юлына кертә»[18].

Хатын-кызлар тарафыннан язылган мондый хатлар аларның үзаңы үсүе, җәмгыятьтә ныгып урнашкан шартлар белән риза булмауларын раслый. Мисал итеп, тарихта Гыйффәт туташ исеме белән билгеле булган шагыйрә Заһидә Бурнашеваның үзенең аянычлы язмышын сурәтләгән хатларын һәм аларга җавап йөзеннән язылган, «Вакыт», «Сөембикә», «Тормыш» кебек газета-журналларда басылып чыккан, татар җәмәгатьчелегендә зур кызыксыну һәм җанлану уяткан язмаларны атарга мөмкин.

Гомумән алганда, XX гасыр башы хатын-кыз мәгарифе үсешендә ике чорны аерып карарга мөмкин. 1906–1912 еллар хатын-кыз мәктәпләренең күпләп барлыкка килүе белән билгеләнсә, 1913–1917 елларда аларның эчтәлеге ягына игътибар арта. Бу үзенчәлек матбугат битләрендә дә чагылыш таба.

XX гасыр башы татар матбугатында дөнья күргән, хатын-кыз мәгарифенә багышланган мәкаләләрне, эчтәлекләреннән чыгып, түбәндәге юнәлешләргә бүлеп карарга мөмкин:

– кыз балаларга уку кирәклеге, белем алуның әһәмияте һ.б.;

– хатын-кыз мәктәпләре, китапханәләр, кыйраәтханәләр, аларның ачылу тарихы, эшчәнлеге, мөгаллимәләре һ.б.;

– кызлар мәктәпләрендә, хатын-кыз җәмгыятьләрендә кичәләр, бәйрәмнәр үткәрү тарихы;

– кызлар мәктәпләрендә кул һөнәрләре өйрәтү, хатын-кыз һөнәр мәктәпләре, курслар һ.б.;

– мөгаллимәләр әзерләү;

– татар мөгаллимәләренең бала тәрбиясе турындагы фикерләре;

– татар хатын-кыз мәгарифе үсешенә зур өлеш керткән педагоглар турындагы язмалар;

– хатын-кыз мәгарифенә матди ярдәм күрсәткән иганәчеләр, хәйрия җәмгыятьләре эшчәнлеге;

– мөгаллимәләрнең һәм гомумән мөслимәләрнең җәмгыятьтә һәм гаиләдәге урыннары, проблемалары.

---

[17] Хатын-кыз мәктүбләреннән // Вакыт. 1911. 20 гыйнвар.

[18] Хатын-кыз мәктүбләреннән // Вакыт. 1911. 20 гыйнвар.

Әлеге юнәлешләргә бәйле рәвештә, җыентыкка кертелгән мәкаләләр аерым бүлекләргә туплап бирелде. Китапка Россиянең татарлар күпләп яшәгән шәһәрләрендә чыгып килгән, татар-мөселман хатын-кызлары мәгарифе мәсьәләләренә аеруча зур игътибар биргән иҗтимагый-сәяси, әдәби-публицистик басмалардан – «Әл-Ислах», «Сөембикә» (Казан), «Вакыт», «Шура» (Оренбург), «Тормыш» (Уфа), «Сибирия» (Томск) газета һәм журналларында басылган, авторлар тарафыннан әһәмиятле табылган мәкаләләр сайлап кертелде. Аерым бүлекләр эчендә язмалар хронологик тәртиптә урнаштырылды.

Чыганакларны басмага әзерләгәндә текстларда күзәтелгән кайбер стиль кытыршылыклары, аерым сүзләрнең грамматик формалары, хәтта бер үк чыганактагы төрлелекләр үзгәртелмәде (үземез – үзебез, китапларымыз – китапларыбыз, йир һ.б.). Шул ук вакытта, XX гасыр башында әдәби тел нормалары урнашып бетмәү нәтиҗәсендә, сүзләр язылышында күзәтелгән кайбер төрлелекләр бердәйләштереп, хәзерге тел нормаларына туры китереп бирелделәр (исемнәрнең күплек һәм килеш кушымчалары, исем-фамилияләр, рус һәм Европа телләреннән кергән сүзләр һ.б.). Тыныш билгеләре хәзерге татар теленең пунктуацион кагыйдәләренә туры китереп куелды. Гарәп-фарсы алынмаларының һәм кайбер башка сирәк кулланыштагы сүзләрнең тәрҗемәләре һәрбер мәкаләнең астөшермәләрендә биреп барылды, географик атамаларга, шулай ук шәхесләрнең исем-фамилияләренә аңлатмалар текстта беренче тапкыр очраганда бирелде. Газета-журналларның искерүе, ертылуы сәбәпле, текст укылмаган очракта, мәкалә авторы үзе куйганда һәм чыганактагы хатын-кыз мәгарифенә турыдан-туры бәйләнеше булмаган өлешләр кыскартылып бирелгәндә […] билгесе куелды.

Җыентыкны әзерләүдә КФУның Н.И. Лобачевский исем. фәнни китапханәсендә саклanучы басмалар файдаланылды. Китапта тәкъдим ителгән фотосурәтләрнең күбесе «Сөембикә» журналыннан алынды.

# I БҮЛЕК

## «МӨСЛИМӘ УЛДЫГЫМЫЗ СӘБӘПЛЕ, УКУ БЕЗГӘ ДӘ ФАРЫЗ»

Кыз балаларга уку кирәклеге, белем алуның әһәмияте һ.б.

***«Вәкилә»***[1]

### Ирләргә протест

Мөселман хатыннары тарафыннан: без, мөслимәләр, кайчангача бу игътибарсызлыкта, бу кадерсезлектә калачакмыз? Мөселманнарның ирләре берлә хатыннары чагыштырылса, күрелер ки: ирләр хатыннарга караганда кат-кат бәхетледерләр.

Ирләр һәркөн иркендә вә ачык һавада сулап йөриләр, без мөслимәләр исә, читлектәге кош кеби, төне-көне һавасыз өйләрдә, тыгыз бүлмәләрдә ябылып ятамыз.

Ирләр балаларының авырганын, егълаганын вә борчыганын күрмәй, кәсеп сылтавы берлә чыгып китеп, киң бакчаларда, яхшы чәйханәләрдә вә гүзәл ресторааннарда ашап-эчеп йөриләр. Аннан башка безнең йөрәгемезне яндыра торган урыннарда йөргәннәре дә ишетеләдер.

Без мөслимәләр исә, гяһ[2] авырган баламызны карап, гяһ егълаган баламызны көйләп, гяһ борчыган баламызны шелтәләп, көне-төне җәфа тартамыз; бездә юк туйганчы аш ашау, бездә юк татлы йокы йоклау! Безгә юк дөнья яктысын күрү! Аның соңында, ирләр һәртөрле мәктәпләргә кереп укыйлар, белектән тәм вә зәвык табалар, вә һәртөрле гәзитә, җәридә[3], китап укып ләззәтләнәләр, вә белек нуры берлә күңелләрен нурландыралар, вә бер-берсе берлә татлы утырышлар кылалар. Без мөслимәләр исә, мәктәп күрмәй, белектән өлеш алмай, белексез, тәмизсез[4], надан, тәрбиясез калып, гомеремезне аһ-ваһ илә кайгы вә хөсран[5] илә [...][6], үзенә һичбер яктан юаныч тапмай, гомерене сагышта вә хәсрәттә кичерәдер.

Бу сүзләрне бәгырем көйгәнгә сөйлимен.

---

[1] М.Бөдәйлинең «Псевдонимнар» кулъязма сүзлегенә караганда, «Вәкилә» псевдонимы белән «Вакыт» газетасының мөхәррире Фатыйх Кәрими басылган (КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 2501 т.)

[2] Гәһ – әле, кайчак.

[3] Җәридә – журнал.

[4] Тәмизсез – пакъ түгел, пычрак.

[5] Хөсран – зыян, үкенеч, зарар.

[6] Газетада укылмый.

Хөрмәтле ирләр! Үз хәлеңезне төзегәндә вә төзәткәндә, без зәгыйфәләрне дә искә төшереңез, без мескеннәрне дә онытмаңыз, безне дә бераз тәрбия итү ниятендә булсаңыз ла; үзеңез безне тәрбия итмәгәч, без гүзәллекнең ничек икәнен белмәймез вә сезгә каршы нәзакәт[7] күрсәтә алмыймыз. Шулай итеп, хөрмәтле ирләремезнең тәрбиясендә без дә, косурлык кылып[8], аларның күзенә иләмсез, сөемсез, мәхәббәтсез күренәмез! Укыган марҗалар безнең ирләремезне кулымыздан алып баралар!

Ирләр безне бик көнләшәләр; күңел Мисыр хидьюинең[9] кардәше Пәнбә ханым бер немецка ияреп киткәч, бөтен мөселманнар кыямәт кубардылар. Мәшрикъдан[10] кычкырып, Мәгърибкә[11] ишеттерделәр. Хәлбуки[12] һәр елда берничә ирләр безнең кулымыздан китеп, марҗаларга иптәш булалар. Без бу эшкә тавышымызны чыгармай түзәмез. Сез, хөрмәтле ирләр, безне шулай хиссез, җансыз дип беләсезме?

Бән[13] инсаф[14] итеп, бу мәктүбемдә[15] марҗа кулында корбан булган ирләрне адреслары илә әйтеп фаш итмәймен. […]

Бонлардан башка, әгәр саныйм дисәм, бик күп табылачак. Хәзергә түзәмен. Соң үтенечем будыр ки: әй, хөрмәтле ирләр, безне игътибар итеңез, безне тәрбия кылыңыз, безгә дә рәхәт йөзе күрсәтергә тырышыңыз, юк исә арамыз ачылып китәр. Әгәр сезнең мәрхәмәтеңездән башка аяклансак вә күз ачсак, арамызга суыклык төшәр.

*«Вакыт», 1906, 11 март.*

***«Вәкил»***

## Контрпротест

Ирләр тарафыннан хатыннарга.

Вәкилә ханым әфәнде! Сез: «Ирләр иркенлектә йөриләр, безләр исә томаланып ятамыз», «ирләр безнең кулымыздан чыгып, укыган марҗаларга корбан булып баралар», – дия протест язгансыз! Язган сүзләреңез пәк тугъры, бу рәвешчә язар булсаңыз, язар сүзләр генә табарсыз һәм хакыңыз да бардыр. Ләкин, сез, ханым әфәнде, бу илә гәзитә сәхифәләре аркылы без ирләргә протест кылгач, безнең ягымыздан да бер контрпротест язарга лязем[16] күрелде. Сез, ханым әфәнделәр, һавасыз өйләрдә ябылып ятасыз, көне-төне рәхәт йөзе күрми балалар тәрбия кыласыз, сезнең араңызда фәрештә кеби

[7] Нәзакәт – әдәплелек, аһәң нәфислеге.
[8] Косурлык кылу – кимчелекле булу, җитешсезлектә булу.
[9] Хидью – патша, әмир.
[10] Мәшрикъ – Көнчыгыш.
[11] Мәгъриб – Көнбатыш.
[12] Хәлбуки – ләкин.
[13] Бән – мин.
[14] Инсаф – гаделлек.
[15] Мәктүб – хат, язылган әйбер.
[16] Лязем – тиеш, кирәк.

гөнаһсыз […][17] сөекле булганнарыңыз бардыр. Сез бөтен дөньядагы инсаннарның[18] аналарысыз, сез йортларның әләмнәресез[19], күңелләрнең арзулары[20], егетләрнең кояшысыз, сез ханымнарны канча[21] мактасак кына аздыр, сөйләп мактасак, бетермәй агызымыз арыр, телемез талыр, язсак, каләмемез кибәр, сезнең кашыңызда йөземез кара, телемез кыскадыр. Вәләкин сездә дә безне борчыган өчен бер-ике гаеп бардыр ки, үзеңез сүз башлагач, әйтмәй китәргә чарамыз юктыр.

Сез, ханым әфәнделәр, балаларны пәк начар тәрбия кыласыз; аларга түземлек, якты йөз, гыйлемгә мәхәббәт, татлы сохбәт[22], татлы тел кебиләрне һич үгрәтмәйсез вә бу эшләрне әфгалеңез[23] белә күрсәтмәйсез, аларга әхлак дәресе бирмәйсез. Бәлки алар алдында юкка-барга да кыяматләр кубарып кычкырынасыз, йөзеңезне бозасыз, укыган кешеләрне хурлайсыз, гайбәт берлә сохбәт итәсез, күп чагында әшәке сүзләр сөйләшәсез. Шулай итеп әшәке татар үрчетәсез.

Аның соңында янә бер-ике ярамаган эшләреңез бардыр ки, чүпрәккә вә күлмәккә һәвәскәрсез; кырык-илле күлмәк, йитмеш күлмәк, йөз күлмәк ясайсыз, һаман да күлмәктән туймайсыз, ашка барыр өчен, бәйрәм күрер өчен тагы күлмәк кисәсез, күлмәк бетертәсез!

Хәлбуки[24] сандык-сандык чүпрәк җыйганчы, санап бетермәслек күлмәк тектергәнче, акчаны кара көн өчен сакласаңыз, яхуд газиз балаларыңызны яхшы укытып тәрбия итсәңез, вә яхуд, һич булмаганда, асылташ алсаңыз, чүпрәк күбәйтүдән артык булыр иде, чөнки асылташ – тәрбияле бала кебидер. Һичбер вакыт бәһасен җуймас.

Аның соңында, Вәкилә ханым әфәнде! Сез, ягъни гомумән мөселман хатыннары, аш-суга күп акча туздырасыз вә күп вакыт исраф итеп[25], ашка-суга йөрешәсез, ирләреңез бер ишектән чыгып сәфәргә (юлга) китсәләр, икенче ишектән чыгарып кунак чакырырга бала йөгертәсез. Кунак чакыру өчен вә кунак-кунак уйнау өчен һичбер төрле көн вә сәгать интихаб итмәйсез[26], һәр көн вә һәр сәгать сезгә кунак чакыру өчен лаек вә мөсагыйдтер[27]. Хәлбуки һәр милләт ялгыз үзләренең бәйрәмнәрендә кунакка йөрешәләр, бәгъзе шәһәрләрдә шундай гадәт «12 сәгать тулганда килеп йитәсез» дип бардыр ки: записка язалар, ысул җәдидчә укытуларны да хәрам

[17] Газетада укылмый.
[18] Инсан – кеше, адәм.
[19] Әләм – байрак.
[20] Арзу – теләк, омтылыш.
[21] Канча – күпме.
[22] Сохбәт – иптәшлелек, юлдашлылык.
[23] Әфгаль – эш, гамәл.
[24] Хәлбуки – ләкин.
[25] Исраф итү – әрәм итү.
[26] Интихаб итү – сайлау.
[27] Мөсагыйд – мөмкинлек бирүче, рөхсәт итүче.

чыгаручы ханымнарның бәгъзеләре шул записка буенча килеп, акшамгача[28] утыралар...

Вәкилә ханым әфәнде! Сезгә үтенечемез шулдыр ки: бар һимметеңезне[29] балалар тәрбиясенә багышлаңыз, аларга түземлек, тырышлык, татлы сохбәт, татлы тел үгрәтеңез. Аның түбән ягында иркәкләреңезнең газиз акчаларына һәрничек булса да уку вә укыту юлына тотарга иҗтиһад[30] итеңез. Без һәм сез ки каршы булган косурлыкларымызны[31] төгәлләргә тырышырмыз. Хуш, Тәңре ярдәмче булсын.

*«Вакыт», 1906, 15 март.*

***«Вәкилә»***

## Вәкилә ханымның икенче мәктүбе[32]

Вәкил әфәнде! «Контрпротест» сәрләүхәле[33] бәндеңез[34] илә бәнем беренче мәктүбемә җавап язып, сез чук гүзәл сөйләмешсез, әйткән сүзләреңез тугрыдыр. Ягъни без, мөселман хатыннары, балаларымызга гүзәл тәрбия бирә белмәймез, морадымыз чүпрәк күбәйтүдер. Сөйләгәнемез гайбәт, кылганымыз ашка йөрешү вә бондан башкалар...

Ләкин безнең бу илә тәрбиясезлегемезгә кем гаепледер? Безләр ирексез хайван хөкемендәмез. Хайваннарны да гяһан[35] иркен кырларга чыгарып йибәрәләр. Тугрысыны әйткәндә, безгә хайван ирке дә юктыр. Безләр урамга чыксак, ислам шәригате буенча чыкмай, сарт[36] гадәте буенча чыгамыз. Урамга чыкканда, башымызга җиңнәре итәгеннән озын булган алама чапан ябынуга көчләнәмез. Ирләр безнең йөземезне өретүгә көчләү берлә генә канәгать булмайлар, бәлки өммәһат мөэминин[37] хәзрәте һич күрмәгән вә ислам шәригате буенча боерылмаган эшләргә көчләйләр. Авыл йирләрендә чапаннар ябынып йөрмәк бер хәл иде. Шәһәрләрдә чапаннар ябынып җәяү урамга чыксак, урыс малайлары ике җиңемезгә асылынып сөйриләр, вә чапанымызны башымыздан тартып төшерәләр, вә һәртөрле сүзләр берлә безне үчекләп хәкарәт кылалар[38]. Безләр урысча белмәгәнгә, урыс малайларының хәкарәт иткәннәрен аңламай вә гарьләнмәймез. Безнең хөрмәтле түрәләр булган ирләремез дә безне химая кыла[39] алмыйлар. Шушындай

[28] Акшам – кич, эңгер-меңгер вакыт.
[29] Һиммәт – тырышлык, теләк белдерү.
[30] Иҗтиһад – тырышу.
[31] Косур – кимчелек, җитешсезлек.
[32] Мәктүб – хат, язылган әйбер.
[33] Сәрләүхә – мәкалә исеме.
[34] Бәнд – язма, кушымта.
[35] Гяһан – кайчакта.
[36] Сарт – Урта Азиядә яшәгән күчмә халыкларның гомуми исеме, үзбәкләр.
[37] Өммәһат мөэминин – мөселманнарның (өммәтнең) җитәкчесе.
[38] Хәкарәт кылу – хурлау, кимсетү.
[39] Химая кылу – яклау, саклау.

агыр[40] хәлләремезне күрә торып, һич уйламай читтән узалар. Шулай итеп, үзләренең тәгассыблары[41] берлә чапан ябынырга көчли алсалар да, үзләренең наданлыклары сәбәпле хөрмәтле аналарын вә хәрамнарын[42] урамнарда хәкарәт кылдыралар.

Хөрмәтле Вәкил әфәнде! Сез әүвәл үзеңезнең әхлак вә әфгалеңезне[43] төзәтеңез. Эшләреңезне ашкярәдә[44] дә һәм аулакта шәригатьчә йөртеңез. Суфилыкны мәйданда сатып, аулакта һәртөрле әшәке эшләрне эшләргә бил баглап йөрмәңез. Аның ары ягында безне дә укытырга вә белек нуры берлә бизәп гүзәлләндермәгә тырышыңыз...

Сезнең үзеңез өчен кирәк булган мәктәпләрнең барчасы безгә һәм кирәктер. Әнваг фөнүн[45] вә әнваг голүм[46] ирләргә махсус диеп белмәңез. Әгәр безне игътибарга алмасаңыз, безне тәрбия итмәсәңез, рәхәт күрмәссез. Аң булыңыз!

*«Вакыт», 1906, 30 март.*

***Мәхдүмә***

«Вакыт» гәзитәңезнең бишенче-алтынчы номерларында хатыннар тугрысында бәхәс ачылып, мөселман хатыннары тарафыннан ирләргә, вә ирләр тарафыннан хатыннарга протест вә контрпротестларны укып, мин дә үз тарафымнан берничә сүз язарга тиешле күрдем. Әгәр мәгъкул күреп[47], кабул итсәңез, гәзитәңезнең якындагы номерасына язмакыңызны үтенәмен.

## Вәкилә ханыма хитаб[48]

Һәмширәм[49] Вәкилә ханым! Ирләргә яздыкыңыз протестта хәлемездән шикаять итеп[50], «ирләр һәр көн иркендә вә ачык һавада сулап йөриләр, без мөслимәләр исә, читлектәге кош кеби, төне-көне һавасыз өйләрдә ябылып ятамыз, гяһ[51] авырган балаларымызны карап, гяһ егълаган балаларымызны көйләп, көне-төне җәфа тартамыз», дисез. Бу сүзләреңез бик дөрес һәм тугрыдыр, ләкин боннан авыр һәм дә «мөкаддәс[52]» хезмәтләрнең хадимә-

[40] Агыр – авыр.
[41] Тәгассыб – фанатизм.
[42] Хәрам – бу урында: хатын.
[43] Әфгаль – эш, гамәль.
[44] Ашкярә – ачык.
[45] Әнваг фөнүн – төрле фәннәр.
[46] Әнваг голүм – төрле гыйлемнәр.
[47] Мәгъкүль күрү – акылга муафыйк, урынлы күрү.
[48] Хитаб – эндәшү, мөрәҗәгать.
[49] Һәмширә – кыз туган, кыз кардәш.
[50] Шикаять итү – зарлану.
[51] Гяһ – әле, кайчак.
[52] Мөкаддәс – изге, иң мөһим.

ләре[53] без хатыннар булдыкына, үземезне бәхетсез санарга тиешле түгел, бәлки бу тугрыда ирләрдән дә бәхетлерәкмез. Чөнки без балаларымызны тәрбия кылуымыз илән бәрабәр, бөтен милләтне тәрбия кылуымыз табыладыр. Безем бәхетсезлегемез исә икенче бер ноктададыр. Ул да: мөкаддәс вә кадерле вазыйфамызны тиешенчә йиренә китерә алмаенча, балаларга кирәгенчә тәрбия бирә алмавымыздыр.

Боның да сәбәбе үземезнең яхшы тәрбия күрмәгәнлегемез, гыйлем вә мәгърифәттән хәбәрсезлегемездер.

Дәхый дә[54] «ирләр һәртөрле мәктәпләргә кереп укыйлар, белектән тәм вә зәвык табалар, вә һәртөрле гәзитә вә китап укып ләззәтләнәләр, вә бер-берсе илән татлы ултырышлар кылалар. Без мөслимәләрдә боларның һичберсе юк дисез, бәхетсезлегемезнең икенче ноктасы да ошбудыр. Ләкин боларның һәркаюсына үземез гаеплемез; чөнки бармы безнең арамызда ошбу нәрсәләрнең кирәклеген сөйләгәннәремез? Бармы безнең ошбуларны булдырырга иҗтиһад иткәннәремез[55]?

Бармы балаларымызга яхшы тәрбия, гыйлем вә һөнәр кирәклеген белеп, үгрәтергә вә укытырга иҗтиһад иткәннәремез? Бармы балаларымызны укырга биреп, балаларымызны укый икән, ничек укый икән, дип кайгырткаяннарымыз? Юк! Булса да бик аз!

Шулай булгач, бу тугрыда ирләремезне гаепләвемез дә тиешсездер. Әүвәл үз тарафымыздан тиешенчә иҗтиһад итәргә кирәк. Аның соңында ирләрдән ярдәм сорарга кирәк.

Уйлап карыйк! Күпме бездә җыелышлар була, күпме мәҗлесләр була, ул мәҗлесләрдә без ни сөйләшәмез? Бер-беремезнең кигән күлмәген, вә аның тегелүен тикшереп, икенче хатын алган кешене тикшереп, боннан башка һичкемгә файдасыз сүзләр берлән, гайбәт сөйләү берлән вакытымызны үткәрәмез. Мәҗлестә берәремез яхшы, гыйбрәтле, файдалы сүз сөйләсә, аңар колак салмыймыз, илтифат итмимез[56].

Һәртөрле тәкәллефләр[57] булса, без дә чигеннән ашкан үземезнең хәлемезгә, дәүләтемезгә карамыймыз, кием-салымны бер-беремездән арттырырга тырышамыз, бер мәҗлескә киеп барган күлмәкне икенче мәҗлескә киеп баруны хәрам кебек саныймыз, кешенең гыйлеменә, белеменә карап кадер вә хөрмәт итмимез, киеменә карап хөрмәт итәмез (Хәтта бәгъзеләремез начаррак киенгән кешеләргә кулының бөтенен биреп күрешмәенчә, бармак очы берлән генә күрешәдер). Шундай эшләрнең бидгать[58] вә тиешсез икәнлеген белгәннәремез дә әйтмимез. Имде үземезнең тарафта шундаен кимчелекләр булганның соңында, ирләрне гаепләвемез дә тиешсездер.

---

[53] Хадимә – хезмәтче.
[54] Дәхый – тагын, янә.
[55] Иҗтиһад итү – тырышу.
[56] Илтифат итү – әһәмият бирү, игътибар бирү.
[57] Тәкәллеф – күрсәтү өчен көчләп эшләү, ясалмалылык, кылану.
[58] Бидгать – элеккесенә каршы килә торган яңа бер эш.

Янә Вәкилә ханым! Ирләргә язган «Протест»тыңызда: «Укыган марҗалар безнең ирләремезне кулымыздан алып баралар. Ирләремез безне бик көнләшәләр», – диеп язасыз. Көнләшмәк – наданлык галәмәтедер. Гыйлем вә мәгърифәт иясе булган ир-зат хатыныны һичвакыт көнләшмәс, надан ирләрне укыган марҗалар да ияртмәс, иншаллаһ Тәгалә.

Рестораннарда ашап-эчеп вә аннан башка йөрәгемезне яндыра торган урыннарда йөри торган, марҗаларга корбан булган ирләргә, Җәнаб Хактан, тәүфикъ вә истикамәт[59] сораудан башка чара юк.

Кардәшләрем мөслимәләр! Бар көчемез илән үземездә булган кимчелекләремезне бетерергә иҗтиһад итеп, үземезнең арамызда гыйлем вә мәгърифәт таратып, вә балаларымызга да яхшы тәрбия бирергә вә укытырга тырышыйк! Ирләремездән дә шуңар ярдәм сорыйк!

Иншаллаһ, шул вакытта ирләремезгә дә сөйкемле вә мәхәббәтле күренермез һәм кадер вә игътибарымыз да артыр!

Аллаһ үзе муафыйк[60] әйләсен!

*«Вакыт», 1906, 11 апрель.*

***Ләйлә бинте Сабир***

## Ханымнар хакында бер мәктүб[61]

Бу аралык гәзитәләр күбәеп, төрле хәбәрләр вә мәкаләләр язылмактадыр, ләкин мин үзем бер хатын улдыгым җәһәте илә, мәшһүр ханымнарның яздыклары гүзәл мәкаләләрен укып, бу илә мөхәррирәләремез улдыгын мәмнүн улмактамын[62]. Бу соң вакытларда Вәкилә ханым мәктүбләрен, Вәкил әфәндeнең «Контрпротестын» «Вакыт» гәзитәсендә күреп, нәзар[63] дикъкатемне җәлеп итте. Вәкилә ханымның шикаятьләренә каршы Вәкил әфәнде контрпротестында безгә (хатыннарга) бер-ике гаеп исбат итәдер.

Бер ише: без, хатыннар, балаларымызны гүзәл тәрбия кылмаймыз, аларга әхлак-әдәп үгрәтмәймез имеш. Үзе тәрбиясез булып та, башкаларга тәрбия бирмәк мөмкинмедер. Без, тәрбиясез хатыннар, бер дә каралмаган, тәрбия ителмәгән, су сибелмәгән, ашланмаган (ялгамаган) алма агачы кебимез. Бу кеби алма агачыннан татлы, ләззәтле алмалар булачагын көтмәк гаделсезлек түгелмедер? Бу илә исә голүм[64], мәгариф сулары сибелмәгән, әхлак вә әдәп илә ашланмаган, тәрбия күрмәгән хатыннардан да тәрбияле, әхлаклы балалар көтмәк, вә балаларына тәрбия өйрәтдекләре өчен ул хатыннарны гаеп итмәк гакыллылыкмы булачак? Мөхтәрәм Вәкил әфәнде ничек боны хәтеренә китермәмеш! Хатыннарның икенче гаебе дә күп күлмәк кимәктә, имеш!

[59] Истикамәт – турылык, намуслылык.
[60] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[61] Мәктүб – язылган нәрсә, хат.
[62] Мәмнүн улу (булу) – шат булу, разый булу, шатлану.
[63] Нәзар – иътибар.
[64] Голүм – гыйлемнәр.

Бичара безем ханымнар җаһилә[65] вә тәрбиясез калмышлар. Аларда нәзакәт[66], гыйлем-фәлән юкка, аның илә ирләрне үзләренә җәлеп итсеннәр. Анчак бизәнеп-төзәнеп, беркадәр җәлеп итә белерләр. Бу да улмаса, ирләремезнең пәк күбе «нәзакәтле»ләргә корбан улачаклардыр. Бу бер гаеп тә, вә исраф[67] та улсын, ирләремезнең исрафларына нисбәтән, унда бер йире юктыр. Бу кеби исрафлар гомуми улмай, бәлки бай хатыннарында гына ула белер. Юкса безем кебекләр бер күлмәкне ямап-ямап та кияләр. Бу гаепнең җөмлә[68] хатыннарга иснад ителмәсе[69] хаксызлыктыр.

Әй мөхтәрәм ирләр!

Һәр шәйдән[70] әүвәл безне тәрбия итмисез. Безне голүм вә мәгариф илә ашна итәрәк[71] гүзәл әдәп вә әхлак үгрәтмисез. Үзеңезнең сәгадәтеңез[72] һәм бөтен милләтемезнең сәгадәте безнең тәрбиядәдер. Безне тәрбия итер исәңез, без дә тәрбияле, әхлаклы, голүм фөнүннән[73] хәбәрдар балалар үстерәчәкмез, милләт агачының татлы йимешләрене тәрбияле аналар йитештерәчәкләрдер. Һәр никадәр сез балаларны җыеп мәктәпләрдә тәрбия бирәчәк улсаңыз да, без, аналар, тәрбиясез улдыкта, файда әйдәмиячәктер. Зирә[74] сезләр никадәр аналарга тәрбия бирмәя чалышсаңыз да, безләр җаһилиять[75], әхлаксызлык илә тәрбия итәчәкмез, безем тәрбия аналар тәрбиясе, мәктәп тәрбиясеннән дога-нәфес улдыгы шөбһәсездер вә тәҗрибә илә сабиттыр[76]. Күп вакытлар хатыннарга укымак, язу белмәк хәрам диярәк, безем агызларымызны капладыңыз вә алларымызны багладыңыз, шәмди[77] бу хаксызлыкны куймак вакыты килмештер. Хәмед улсын[78], олуглардан хатыннар тәрбиясен ирләргә дә тәкъдим иткән вә бонык әһәмиятлелекне хис иткән затлар да бардыр. Мөхтәрәм Хаҗи Зәйнелгабидин җәнабләре[79] Бакуда кызлар мәктәбе ачты. Ләкин Хөсәеновлар[80] бондан гыйбрәт алмадылар, ир балалар өчен мәктәп

---

[65] Җаһилә – надан.
[66] Нәзакәт – матурлык, әдәплелек.
[67] Исраф – әрәм итү.
[68] Җөмлә – бөтен, барлык.
[69] Иснад итү – сылтау, эшне кешегә аудару.
[70] Шәй – әйбер, нәрсә.
[71] Ашна итү – таныштыру.
[72] Сәгадәт – бәхет, рәхәтлек.
[73] Фөнүн – фәннәр.
[74] Зирә – чөнки.
[75] Җаһилиять – наданлык, белемсезлек.
[76] Сабит – шиксез, ачык.
[77] Шәмди – хәзер.
[78] Хәмед улу (булу) – шөкер итү.
[79] Тагиев Гаджи Зәйналабдин (1823–1924) – әзербайҗан миллионеры, мөселман халыкларының мәгарифе үсешенә матди яктан зур өлеш керткән хәйрияче.
[80] Хөсәеновлар – Әхмәт, Гани, Мәхмүд Хөсәеновлар, атаклы татар сәүдәгәрләре, химаячеләр, мәшһүр «Хөсәения» мәдрәсәсенә нигез салучылар, татар мәктәп-мәдрәсәләрен тотучылар.

ачсалар да, кызларымызны гыйлем-тәрбиядән бихәбәр[81] вә белер-белмәс ханымнардан укытып заегъ иттеләр[82].

Японнар күзләре ачылдыкта үзләреннән калдырмай хатыннарыны да тәрбия иттеләр дә, бөек нәһерләре[83] кичәчәк вә рус тупларына кукс киерәчәк милләт фидаиләре[84], милләт каһарманнары йитештерделәр.

Бу вакытка кадәр җаһилиятемез сәбәпле, ирләремезә әсирә уларак, бик күп золым[85] вә җәфалык күрдек. Хокук шәргыя вә маддиямездән аерылдык, шәмди исә, һәр никадәр шикаять итсәк[86] тә, хаклымыз. Бер-ике гаепләр исбат илә, бу шикаятьләрдән ваз кичерә алмаячаксыз. Фәкать безем тәрбиямезгә игьтибар итәрәк, әмдадымыз[87] йитешсәңез, шикаятьләремез бетәчәктер.

*«Вакыт», 1906, 4 май.*

***Фәхрелбәнат Сөләйманова***[88]

**Мөселман хатыннарыннан Вәкил әфәндегә бер-ике сүз**


Хөрмәтле Вәкил әфәнде! Ханымнарга хитабән[89]: «Сез, ханым әфәнделәр, балаларны бик начар тәрбия кыласыз, аларга түземлек, якты йөз, гыйлемгә мәхәббәт, татлы сохбәт[90], татлы тел кебиләрне һич үгрәтмәйсез вә бу эшләрне әфгалеңез[91] берлә күрсәтмәйсез. Аларга әхлак дөрес бирмәйсез, бәлки алар алдында юкка-барга да кыяматләр кубарасыз, йөзеңезне бозасыз, укыган кешеләрне хурлайсыз, гайбәт берлә сохбәт итәсез. Күп чагында әшәке сүзләр сөйләшәсез, шулай итеп әшәке татар үрчетәсез», – дия язасыз.

Сүзләреңез дөрес, ләкин тәрбияле вә гүзәл татар үрчетәсеңез килсә, әүвәл кыз балаларга мәктәпләр, мөгаллимәләр тәртип кылып, ысуле тәгълимне[92] ислах[93] кылырга иҗтиһадыңызны[94] сарыф кылыңыз. Һәм дә бала тәрбиясе, йорт идарәсе, ысуле мәгыйшәт[95], хифзыссыйхәт[96] кеби гыйлемнәрне укыты-

[81] Бихәбәр – хәбәрсез.
[82] Заегъ итү – әрәм итү.
[83] Нәһер – елга.
[84] Фидаи – фидакарь.
[85] Золым – гаделсезлек, рәнҗетү.
[86] Шикаять итү – зарлану, жалоба.
[87] Әмдад – ярдәм.
[88] Фәхрелбәнат Сибгатулла кызы Сөләйманова (Сөләймания, 1865–1959) – педагог, мөгаллимә, тәрбиягә багышланган китаплар, мәкаләләр авторы.
[89] Хитабән – эндәшеп, сүзне юнәлтеп.
[90] Сохбәт – иптәшлек, юлдашлык.
[91] Әфгаль – эш, гамәл.
[92] Ысуле тәгълим – методика.
[93] Ислах – реформа, үзгәреш.
[94] Иҗтиһад – тырышу.
[95] Мәгыйшәт – көнкүреш, тормыш, яшәү өчен кирәкле нәрсә.
[96] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау юллары, гигиена.

ныз. Аннан соң тәрбияле, мәгълүматлы татарлар көтәрсез, әле ашыгычрак көтәсез.

Бу эшеңез урак күтәреп кысыр йиргә ашлык урырга баруга охшайдыр, чәчмәгәнне уру мөмкин булмаган кеби, милләтемезнең аналары улачак кыз балаларны яхшы тәрбия кылмай, тәрбияле балалар үрчү дә мөмкин түгелдер, әшәке татарлар үрчүгә сәбәп, бездән бигрәк, ирләр булса кирәктер.



*Фәхрелбәнат Сөләймания*
*(«Сөембикә», 1914, № 24)*

Җәһаләтнең[97] иң түбәндер ки се адәм үзенең белмәгәнлегене белмәведер. Без хәзер мәгълүматымыз булмаса да, белмәгәнемезне белә башлап, җәһаләтемезне икърар кыламыз[98], һәм дә кулымыздан һич эш килмәсә дә, ничек итсәк, бераз мәгълүмат алырмыз, вә ни тәрика [99] хайванлыктан чыгып, адәм сурәтенә керербез икән дия гәзитәләргә яздык, хөрмәтле ирләрдән ярдәм таләп кыламыз. Вәкилә ханымның да максуды ирләрне хурлау булмай, җәһаләтемезне игътираф кылып[100], хәлемезнең ислахы өчен юл эзләүдер занында[101] йиз.

Сез, хөрмәтле ирләр, безнең, белмәгәнемезне белерлек кадәр мәгълүматымыз була башлавына тәшәккер кылыңыз[102] да, без гаҗизәләрне тәгълим [103] вә тәрбия кылырга тәшәббес кылыңыз [104], без, бичаралар, ни кәндемез[105] тәрбия күрдек, ни бала тәрбиясенә, йорт идарәсенә мөтәгалликъ[106] бер хәреф мәгълүмат ала белдек. Ни әхлактан дәрес бирүче булды, ни дә мәгыйшәттән, шуның өчен мәгълүматсыз булып үстек.

Йортымызны яхшы идарә кыла алмадык. Ирләремезнең күңелене таба белмәдек. Үземезнең шәригать биргән хакларымызны җәһаләтемез сәбәпле җуялтып бетердек. Яхшы тәрбия кыла белмәгәнемездән, балаларымыз җеп-

---

[97] Җәһаләт – наданлык, аң-белемсезлек.
[98] Икърар кылу – тынычландыру.
[99] Тарика – юл, метод, алым, ысул.
[100] Игътираф кылу – үзенең гаебен тану, кимчелеген тану.
[101] Зан – анык булмаган, шикле уй.
[102] Тәшәккер кылу – рәхмәт белдерү.
[103] Тәгълим кылу – өйрәтү, укыту.
[104] Тәшәббес кылу – керешү, эшкә тотыру.
[105] Кәнд – үзе.
[106] Мөтәгалликъ – бәйле, мөнәсәбәтле.

тәй аяклы, гөбедәй корсаклы, тубалдай башлы булып, аякларына йөри алмай, башларыны бер якка салып, тыннарыны ала алмай тилмереп утырдылар һәм дә, саусыз булганнан, тоташ егълап җанымызны көйдерәләр иде.

*«Вакыт», 1906, 9 май.*

***Фәхрелбәнат Сөләйманова***

**Мөселман хатыннарыннан Вәкил әфәндегә бер-ике сүз**

Аның өстенә, ирләремез дә тәрбиясез булганнан, безнең шәригать биргән хакларымызны бирә алмай, безне пәк түбән дәрәҗәдә тотып, төрле иза вә җәфалар кыла иделәр. Хакымызны сорасак, түгел адәм баласы, таулар-ташлар күтәрә алмаслык авыр сүзләр берлә хәкарәт кылып[107], хәтта бер-икене биргәләп тә чыгып китәләр иде.

Безнең бу авыр хәлләремезгә каршы күз яшемезне агызудан башка бер ярдәмчемез юк иде. Кемгә генә хәлемезне шикаять кылып, дәртемезгә дәрман өстәсәк тә, «Хатыннарга шулай кирәк» дигән сүзне ишетәчәгемез билгеле иде.

Чөнки безне шул тарика[108] каһәр астында тотарга һәркем тарафыннан чикләнеп куелган иде. Ирләргә түгел, һәмҗинесләремез[109] улган хатыннардан берсенә дә бу бабдан[110] сүз ачсак, «Кызым, сабыр ит инде, нишләмәк кирәк, ирләр безгә патша булгач, алар теләсәләр ничек тотарга ихтыярлы. Башың ярылса, яулык эчендә, кулың сынса, җиң эчендә булырга тиеш», – дигән кеби сүзләрне ишетәчәк идек.

Без бичара, шулай йөрәкләремез җанып, күз яшемез илә каралган вакытларымызда җәберле балаларымыз гаять борчыгач, җәһаләтемез сәбәпле, «бет ачуы туннан» дигән кеби, балаларымызның кайсын этеп, кайсын төртеп йибәреп, начар сүзләр әйтеп, әхлакларын бозып бетердек. Янә бу гына йитмәй, бәгъзе тәрбиясез аталар, кәефләнеп кайтып, акырып-бакырып, бу балаларның аналарын кыйнап, телләренә килгән начар сүзләрене әйтеп, кулларына тугры килгән нәрсәләрне ватып, бу балаларга әхлак дәресе бирәләр иде.

Менә шулай итеп әшәке татарлар бик үрчеп китте, моннан түбән, иншаллаһ, сүз дә зәүҗ[111] берлә зәүҗә[112], ата вә бала арасында булган хакларны өйрәнерсез дә, әхлакыңызны төзәтеп, тәрбияле әфәнделәр булырсыз. Без һәм мөмкин мәртәбә тәрбияле ханымнар йитештерергә иҗтиһад кылырмыз[113].

---

[107] Хәкарәт кылу – кимсетү, хурлау.
[108] Тарика – юл, метод, ысул.
[109] Һәмҗинес – җенестәш, бер төрле.
[110] Баб – мәсьәлә.
[111] Зәүҗ – ир (хатынның ире).
[112] Зәүҗә – кәләш (ирнең хатыны).
[113] Иҗтиһад кылу – тырышу.

Шулай итеп, әшәке татарлар урынына, сез әйткәнчә, татлы телле, татлы сохбәтле[114] әфәнделәр вөҗүдкә килер[115] дия өмет итәмез. «Өметсез шайтан» диләр, без шайтан түгел ич. Хәзергә кадәр безнең күгүк тәрбиясез булмасаңыз да, артык тәрбия әсәре сездә һәм күренми иде.

Бервакыт Нижний ярминкәсенә[116] килгән сәүдәгәрдән: «Җәмәгатеңез берлә килдеңезме?» – дия бер адәм сораган икән, сәүдәгәр: «Урманга утын алып баралар мыни?!» – дия җавап биргән. Бу да артык тәрбия галәмәте түгелдер дия хәтергә килә.

Янә бәхәсемезгә кайтыйк, сез, ирләр, безне тәрбиясез дисез, үзегез безгә алга барырга бер дә юл бирмисез, галимнәр гыйлемнәре берлә, байлар пуллары[117] берлә, гакыллылар гакыллары берлә милләтемезнең яртысын тәшкил иткән таифәи нисаэне[118] тәрбия кылырга ярдәм кылсалар, бәлки без дә бераз алга атлар идек.

Сез безнең һәр нәрсәмезгә «Һи, хатыннар ни белә», дип хәкарәт[119] күзе берлә карап, һич игътибарга алмайсыз, моңа мисал уларак диюрем ки, ханымнарның биш мәкаләдән берсе гәзитәгә дәреҗ кылынмый[120], гәрчә гыйбарәсе[121] начар булса да, дәреҗ кылырга тиеш иде.

Чөнки таифәи нисаэн, гакылымыз кыска, калебемез[122] зәгыйфь улдыгыннан мәкаләләремез игътибарга алынмагач, тәрәккыйдән[123] без бөтен өметемез киселеп, адәмнәр сарәсеннән[124] чыгара, хайван кеби яшәмәгемезгә сәбәп буладыр. Янә бер мисал, бу гаҗизә туксан өченче елда һәмҗинесләремнең бала тәрбия кылуда соң дәрәҗә җәһаләт[125] вә косурларыны[126] күреп, гаять ачыганлыгымнан вә алар аңларлык телдә бу хосуска[127] гаид[128] китапларымыз булмаганнан, гәрчә үземдә һәм мәгълүмат һич дәрәҗәсендә булса да, минем кадәр дә мәгълүматы булмаган һәмҗинесләремә бер файда булмасмы өмете

---

[114] Сохбәт – иптәшлек, юлдашлык.

[115] Вөҗүд – барлык, бар булу.

[116] Нижний ярминкәсе – халык телендә Мәкәрҗә ярминкәсе. Түбән Новгород янәшәсендә, Иделнең сулъяк ярында, Макарьев монастыре янында урнашкан ярминкә. Исеме татарчалаштырылган. 1817 елдан Түбән Новгород шәһәренә күчерелә, халык телендә элеккеге исеме саклана.

[117] Пул – акча.

[118] Таифәи нисаэ – хатын-кыз (женский пол).

[119] Хәкарәт – хурлау, кимсетү.

[120] Дәреҗ кылыну – теркәү, арага кертү, бастыру.

[121] Гыйбарә – язылган сүз.

[122] Калеб – йөрәк, күңел.

[123] Тәрәккый – алга китү, прогресс.

[124] Сарә – сөендерүче, шатландыручы.

[125] Җәһаләт – наданлык, аң-белемсезлек.

[126] Косур – кимчелек, җитешсезлек.

[127] Хосус – турында.

[128] Гаид – *-гә* караган, *-гә* бәйләнешле.

илә хифзыссыйхәт[129] вә бала тәрбиясе хосусында бер рисалә[130] тәртип кылмыш идем.

Табгы[131] вә нәшер кылдырырга[132] – икътидарым[133] улмадыгыннан, табгы вә нәшер өчен күп адәмнәргә мөрәҗәгатъ кылып карасам да, һич колак салучы булмады.

Цензорга биреп, табгы кылдырырга мөсагадә алдым[134]. Шуннан соң бер адәм кулында ята-ята, нөсхәсе[135] җуелды. Янә туксан дүртенче ел гавам[136] арасында ачы бал эчү хәләл дигән хәбәрләр шаигъ улып[137], ачы балны мәҗлесләрдә кулдан-кулга йөртеп, әүвәл остазбикә абыстай кулын бисмилла дип сузарак, әүвәлдә кычкырып бисмилла әйтеп, бинте[138] шифа дия эчеп йибәреп, шулай кулдан-кулга йөрткәннәрен күреп, бер дустымың рәҗасе[139] үзеренә, исерткечнең һәркаюсы хәрамлыгы хосусында ачык ана телемездә бер рисалә тәртип кылмыш идем.

Анысы һәм табгы кылдыручы булмаганнан, ятып калган иде. Дүртенче елда тәкрар[140] Кәримовларга мөрәҗәгатъ итәрәк, шул ике рисаләне тиздән табгы вә нәшер кылырмыз дия вәгъдә бирмешләр иде. Һәйһат[141] ник табгы кылсыннар!

Чөнки аларны хатын кеше тәртип кылган, бәлки хатыннар әсәрне табгы кылу шәригатемездә дөрес тә түгелдер, ир кешенеке булса, аю такмагы кеби мәгънәсез такмак булса да, күптән табгы кылган булырлар иде.

Зан[142] гаҗизәнә мә калыр исә, хатыннар язуыны, ялгыш-йолгыш булса да, игътибарга алу лязем[143] иде. Берсе начар булса, бәлки икенчесе яхшы булыр иде.

Ирләр мосахәбәтләрене[144] мәҗлесләрдә дә сөйләшә алалар, җәмгыятьләр ясап та сөйләшәләр, безнең максуд аңлатыр өчен гәзитәдән башка һич урынымыз юк. Шөкерләр улсын, гәзитәләремез күбәйде, берсе игътибарга алмаса, берсе алыр.

*«Вакыт», 1906, 11 май.*

---

[129] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау юллары, гигиена.
[130] Рисалә – мәкалә, хат, брошюра.
[131] Табгы кылдыру – бастыру.
[132] Нәшер кылдыру – матбугатта бастырып тарату.
[133] Икътидар – көч, куәт, булдыра алу.
[134] Мөсагадә алу – мөмкинлек алу.
[135] Нөсхә – данә, экземпляр.
[136] Гавам – халык.
[137] Шаигъ улу (булу) – һәркемгә билгеле булу, халык арасына таралу.
[138] Бинт – кыз.
[139] Рәҗа – сорау, үтенеч.
[140] Тәкрар – кабатлау.
[141] Һәйһат – кире кайтаруы мөмкин булмаган бер нәрсә өчен өзгәләнгәндә әйтелә торган ымлык.
[142] Зан – ачык булмаган, берәр нәрсә турында шикләнеп карау.
[143] Лязем – тиеш, кирәк.
[144] Мосахәбәт – кара-каршы сөйләшеп утыру.

***Х.Н.***

## Бер ханым шикаяте

«Азат»ның[145] 46нчы номерында «Әхмәди» имзалы бер бәнд[146] укыдым, ханымнар хакында бер-ике сүз язмыш. «Ханымнар! Сез дә тик ятмаңыз. Һич тә безнең сүземезне сөйләүче, безгә игътибар итүче адәм юк дия, бик тиз генә кулыңызны селкеп, гайрәтеңез чикмәсен!», – дип. Без, ханымнарның, кәефләре китте. Чөнки үземезгә күрә, барлы-юклы гакылымызны җыеп, мөхәррирләргә мәктүб[147] язып, бер гәзитәгә йибәрәмез, мөхәррир әфәнделәр кулларына алып, әйләндерә-әйләндерә карый. Алай итә, болай итә дә, бик күп язган, киметеп языңыз, дип рәд кылып[148] йибәрә. Шулай итә-итә, өчесе я дүртесе, ни ахырында берсе, ни бик бәләнд[149] [...][150] берлән, яхшы! «Гәзитәгә дәреҗ ителермез[151]», – дип алып кала. Без зәгыйфәләр, әлхәмдүлилләһи, хөррият аркасында без ханымнар да адәм хисабына хисаплана башладык дия, гәзитә килүгә мөнтәзыйрә[152] булып торамыз. Гәзитәләр пи дәр[153] пи килә, атналар үтә, айлар үтә, шулай итеп, ханымнар мәктүбе сукна[154] астында истирахәт кылып[155] яталар. Ханымнарга илтифат кылырга[156] ярамый, шәригать боермый дия, әфәнделәр бик яхшы беләләр. Чөнки алар галим кеше... Яки кайберсе сәгатенә тугры килеп язылганлыктанмы, сәламәт булып дөньяга чыга, яхуд караңгыда ятып, зәгыйфь булып, сүзләре исә бөтенләй үзгәргән була. Аның өстенә тагы телне кырыкка яра торган фәрасәтле[157] әфәнделәр базарларда чәйханәгә кереп, шул хакта сүз чыкса, ире язганга хатыны кул куйган яки атасы язганда кызы кул куйган, тагы ниләр, тагы ниләр дип ул ханымны пәрәмәчкә кушып чәйниләр. Без, ханымнар, ни хәл итәек? Безгә кайда барсак та, бер кояш дип, сабыр итеп каламыз. Безнең өстемезгә дә көннәрдә бер көн кояш чыгар әле дия көтәмез. Ханымнарда гакыл ярты булса да, сабырлык-түземлек ирләргә нисбәттә[158] ике өлеш дисәк тә тугры. Чөнки азмы ханымнар ирләренең иза вә җәфаларына [...] никадәр язсам да, язып бетерүе мөмкин түгел. Мөхәррир әфәнделәр! Ханымнар

---

[145] «Азат» газетасы – иҗтимагый-сәяси, икътисади, сәүдә газетасы. 1906 елның 1 февраленнән 30 майга кадәр Казанда, атнага 3 тапкыр татар телендә 56 саны нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире Г.Апанаев, асылда Г.Камал җитәкчелек итә.

[146] Бәнд – язма, кушымта.

[147] Мәктүб – хат, язылган нәрсә.

[148] Рәд кылу – кабул итмәү, кире кайтару.

[149] Бәләнд – биек, югары, бөек.

[150] Газетада укылмый.

[151] Дәреҗ ителү – теркәү, эченә салу, арага кертү.

[152] Мөнтәзыйрә – көтеп торучы, өмет итүче.

[153] Дәр – дә.

[154] Сукна – сукно.

[155] Истирахәт кылу – ял итү, рәхәтләнү.

[156] Илтифат кылу – әһәмият бирү, игътибар итү, борылып карау.

[157] Фәрасәт – атта йөрергә өйрәнү һөнәре, ат асраучылык.

[158] Нисбәт – чагыштыру, тиңләштерү.

мәктүбен гәзитәләремезгә дәреҗ кылмасак[159], шаять язылудан туктарлар дип гөман кылмаңыз[160]! Әлхәмдүлилләһи, гәзитәләребез күбәйде, иншаллаһ, берсе язмаса, икенчесе [...], һич булмаса, әдәбият капчыгы кабул итәр дия өметемез бар.

***Идарәдән:***

Мөхтәрәмә ханым әфәнде! Төшенеңез, языңыз, тугры сүзләргә «Вакыт» сәхифәләре һәрвакыт ачыктыр.

*«Вакыт», 1906, 6 июнь.*

***Казалының[161] таләбәләре[162]***

**Казалыда укучы кызлардан аталарына ачык хат**

«Болай булсак, эшемездән берни чыкмаенча, юкка гомер сарыф итү булыр». Безем шәһәремездә кызлар мәдрәсәсе ачылганына 15нче сәнә тулмактадыр. 15 елдан бирле күзгә күренердәй бер ана күренми. Безем аналарымызда бала тәрбия итә белү юк, язу яза белү юк. Хәзерге заманда боларның һәркаюсының кирәк икәне кояш кебек мәгълүм, язу яза белмәүләренең сәбәбе – остазбикә абыстай, ирләр берлә хат язышырлар дип үгрәтмәенчә, әлифбадан төшереп иҗек, «Бакырган»[163], «Ярым алма»[164] китапларын хифыз кылдырып[165], бер-ике сәнә Коръән укыта да, мәдрәсәне тәмам кылдырып, фатыйха биреп чыгарадыр. Әлхасыйль[166], дөресен әйткәндә, әүвәле үзе яза алмый, икенче мәгълүм китаплардан башканы укыта да белми.

Элекке заманда милләтнең күтеп торган аналары шушы рәвештә һәлак булганнар, хәзердә дә һәлак булмактадырлар.

Картлар сүзе: «Үткән эшкә салават!» дип әйтүләр янә бинаэн[167] үткәненә салават әйтеп, ошбу сәнәдән башлап, остазбикә абыстай урынына заманага муафыйк[168] укыта белә торган бер мөгаллимә алдырып, безләрне, ягъни киләчәктә милләт анасы була торган таләбәләрне, дини, фәнни гыйлемнәрдән һәм дә язу үгрәтсәңез ничек булыр икән?

Язу яза беләсемез килүдән максуд ирләргә мәктүб[169] язу түгел, бәлки чит шәһәрләрдә улган туганнарымызга мәктүб күндерергә кирәк, язу белмәгәч,

---

[159] Дәреҗ кылу – теркәү, урнаштыру.

[160] Гөман кылу – уйлау, фикер йөртү.

[161] Казалы (Казалинск) – Казахстандагы шәһәр.

[162] Таләбә – укучылар, шәкертләр.

[163] «Бакырган» – Урта Азия суфи шагыйре Сөләйман Бакыргани (1186 елда үлгән) шигыре белән ачылып, аның һәм шул замандагы бүтән шагыйрьләрнең әсәрләреннән төзелгән җыентык. Беренче мәртәбә 1846 елда Казанда басылган.

[164] «Ярым алма» – дини-мифологик хикәяләр китабы.

[165] Хифыз кылдыру – ятлату.

[166] Әлхасыйль – озын сүзнең кыскасы, нәтиҗәдә.

[167] Бинаэн – нигезләнеп, таянып.

[168] Муафыйк – яраклы, туры килгән.

[169] Мәктүб – хат, язылган әйбер.

бер ир кешедән яздырырга кирәк буладыр, әүвәл исә, язганның соңында иптәшләренә сөйләп, серләремезне фаш итәдер. Моннан башка бик күп сәбәпләр бар, барын да бу урында дәреҗ итүгә[170] тугры килмәде.

Сөекле пәдәрләремез[171]!

Сез бу тугрыда әйтерсез, алай икенче остазбикә алдырырга акча юк, дип. Юк акчаны бик уңай итеп табып була. Мәсәлән, шәһәремездәге аталарымызның һәркаюсыннан уку өчен дип ай саен 30 тиеннән алсаңыз, елына кеше башына 3–4 сум була, шул расход безем шәһәрдә бер ел укытырга йитә.

Русларның шәһәремездә ике яхшы гына школалары бар, берсе ирләрнең, икенчесе кызларның. Әмма безнең икесенең дә бер җүнлесе юк. Алардан үрнәк алырга кирәк. Шәкертләр үзләренең вә мәдрәсәләренең кимчелекләреннән «Вакыт» җәридәсенең[172] бер номерында язганнар иде. Без дә, «Ятып калмаенча, атып калык!» дип, дәреҗ иттек.

*«Вакыт», 1906, 13 июнь.*

***Әхмәтҗан Биктимиров***[173]

## Хатыннарга ачык мәктүб[174]

Вакытның 33нче номерында «Бер ханым шикаяте» мәкаләсене[175] укып чыктым.

Ханымнар! Сезгә каршы язмак һәр ни кадәр нәзакәтсезлек булса да, фикерене бәян итәргә һәркемгә ихтыяр улдыгыннан, мин бу хатымны язам.

Сез, ханымнар, үзеңез берләшеп, җәмгыятьләр ясаңыз, хатыннар иттифакы[176] тәшкил кылыңыз. Мәдәни милләтләрдә бондай җәмгыятьләр бар. Бу җәмгыятьләр хатыннарны ирләрнең иза вә җәфасыннан коткарырга бик күп хезмәт итмешләр.

Надан остазбикәләр илә гайбәт сөйләшеп утырганчы, үз кирәкләреңезне үзеңез белергә тырышыңыз. Бу ки кадәр мәҗлесләреңездән, надан остазбикәләреңездән ни файда күрдеңез? Үз кирәкләреңезне үзеңез карамасаңыз, иза вә җәфадан әлбәт котыла алмассыңыз.

Сезнең хәзерге мәгыйшәтеңезнең[177] кыенлыгы наданлыгыңыз аркасындадыр. Үзара уку юлларыны тикшереңез, балалар тәрбиясене караңыз. Сезне укытырга без – ирләр тотынсак, хатын-кызларымызны котырталар, аздыралар дия ачуланалар.

---

[170] Дәреҗ итү – теркәү, арага кертү, урнаштыру.

[171] Пәдәр – ата, әти.

[172] Җәридә – газета.

[173] Әхмәтҗан Биктимиров (? – 1915) – вак сәүдәгәр, Ташкентта «Азия» газетасы нашире (1908), татар вакытлы матбугаты хәбәрчесе.

[174] Мәктүб – хат, язылган әйбер.

[175] *Н.Г.* Бер ханым шикаяте // Вакыт. 1906. 6 июнь.

[176] Иттифак – берләшмә, союз.

[177] Мәгыйшәт – көнкүреш, тормыш.

Үзара милли гыйбрәтле китаплар укыңыз, театрларда булгалаңыз! Хәлеңезне төзәтүне ирләрдән көтмәңез. Алар үз хәлләрене үзләре дә аңлый алмыйлар. Ишан сәрхүшлегеннән аерылганнары юк. Безгә карап надан калмаңыз, ханымнар!

*«Вакыт», 1906, 15 июнь.*

***«Вәкилә»***

## Мөселман байларына ачык хат

Хөрмәтле мөселманнар! Вәкилә мәктүбләренә[178] күз салдыңыз, вә күбеңез Вәкилә мәктүбләрене күтәрешеп хатыннарның хокуксызлыгына вә аларның тәрбиясезлекләренә ирләр сәбәп улдыгын күргәздеңез. Һәр ни исә мөселман хатыннарының тәрбия күрмәгә теләгәнлекләре вә бәгъзе ирләрнең дә хатыннарыны тәрбия итмәк ниятендә улдыклары мәгълүм улды. Ләкин хатыннар тәрбиясе кайчан вә кемнәр тарафыннан вә ничек башланачагы һаман һичбер гәзитәдә күрелмәйдер. Хәзергәчә сөйләнгән сүзләремез уенлычынлы иде. Бәс[179], имде бу эшкә чын күңел илә керешеп, бән[180] ошбу киләчәктәге фикеремне мәйданга куямын:

Хатыннар тәрбиясе башланса, «Хөрмәтле аналарның үз кызларын тәрбия итү»ләреннән башланачактыр. Бәнем гөманымча[181], башкача һичбер юл юктыр. Бәли[182], юллар күп булыныр, вәләкин фарызый[183] вә хыялый юлларыны сайлап, вакыт үткәрмәк юк эш улыр.

Әгәр берничә һиммәтле[184] аталар үзләренең кызларыны яхшы укытып, тәрбия кылмакчы булсалар, бергә киңәшләшеп, хосусый кызлар мәктәбе ачарлар. Ул мәктәпнең еллык кирәгенә йитәрлек акчаны яхшы исәпләп белгәч, кесәләреннән чыгарып бер имин, ягъни ышанычлы урынга тапшырырлар.

Ул хосусый кызлар мәктәбе ачылгач, анда төркичә укырга, язарга яхшы белгәннәрдән һәм русча да бераз укып белгәннәрдән берничә кыз шәкертләр кабул итәрләр. Ул хосусый мәктәптә:

1) Мөкәммәл[185] сурәттә гарәп лөгате[186] һәм гарәп әдәбияте укытылыр (?!).

2) Мөкәммәл сурәттә рус лөгате һәм рус әдәбияте укытылыр.

---

[178] Мәктүб – хат, язылган нәрсә.
[179] Бәс – шулай булгач, димәк.
[180] Бән – мин.
[181] Гөман – уй, фикер.
[182] Бәли – әйе, шулай, дөрес.
[183] Фарыз – үтәлүе тиешле булган бурыч.
[184] Һиммәтле – тырыш.
[185] Мөкәммәл – камилләшкән.
[186] Лөгать – тел.

3) Чигеш-тегеш кеби нәфис эшләр, табигый, ул хосусый мәктәптә укытылыр. Нәрсәләрнең рәсемене төшерә белмәк һөнәре дә бонда кертелер.

4) Мөкәммәл сурәттә табахәт, ягъни ашчылык фәне укытылыр. Хосусан нәбатат[187] вә сәбзәват[188] берлә итсез ашлар пешерүгә әһәмият бирелер.

5) Вәләиткә[189] даир[190] балекләрнең табигый вә тәклифсез[191] булган җәһәтләре[192] артык игътибар илә укытылыр.

6) Госманлы әдәбияты вә чыгътай төркисе мөкәммәл укытылып, әзербәйҗан вә үзбәк телләре берлән дә таныштырылыр (?!).

Бу маддәләр[193] өчен күңел тулырлык мөгаллимәләр Русия мөслимәләреннән алыныр. Булмаса, марҗадан кабул ителер. Әмма гарәп һәм госманлы әдәбиятлары өчен яхшы мөгаллимә бу йорттан табылмаячагыннан, зарури[194] Төркиядән я Мисырдан китермәк тиеш улыр.

Хосусый кызлар мәктәбенә фән гали[195] күрмәгән кемсә мөгаллим кылынмас. Русия татарларыннан (ирләрдән) һичкем мөгаллим кылынмас. Хосусан, муллалар вә мөдәррисләр аслан[196] анда керешмәсләр вә кермәсләр.

Әгәр дә хосусый мәктәпнең программасына буйсынып, ул мәктәпкә кермәк теләгән марҗа кызлары булса, ганимәт[197] беленер.

Дин вә дингә тәгаллекълы[198] нәрсәләр ул мәктәпнең программасына кертелмәс, мәгәр дингә тәгаллекълы дәресләр өчен кызларга һәфтәгә[199] берничә дәреслек вакыт вә форсат бирелер. Әнә шул вакытта кызлар ата вә аналарының һәм вәлиләренең[200] киңәше берлә үзләре теләгән йирдә үзләре теләгәнчә дин үгрәнерләр.

*«Вакыт», 1906, 12 август.*

***Зәйтүнә Фәхрия***

## Вәкиләгә рәддия[201]

«Вакыт»ның 61нче номерында без Вәкиләнең бер програмыны[202] укыдык. Боның илә без мөслимәләрнең йөз суларымызны түкдеңез. Сез чукдин

[187] Нәбатат – үсемлекләр.
[188] Сәбзәват – яшелчәләр.
[189] Вәләит – балалар.
[190] Даир – караган.
[191] Тәклиф – көчләү, көчләп кушу.
[192] Җәһәт – як.
[193] Маддә – пункт, параграф.
[194] Зарури – булмый калу мөмкин булмаган, котылгысыз.
[195] Фән гали – югары белем.
[196] Аслан – беркайчан да, һичбер вакытта.
[197] Ганимәт – ризалык.
[198] Тәгаллекълы – бәйләнешле.
[199] Һәфтә – атна.
[200] Вәли – опекун.
[201] Рәддия – кире кагу.
[202] *Вәкилә.* Мөселман байларына ачык хат // Вакыт. 1906. 12 август.

бер вә Вәкилә, Вәкилә дия баграр исәңез дә, бу илә програм тәртип итәр өчен без сезне вәкилә итдекемез юк. Шәригать чигеннән чыгып ирләргә мөсавәт[203] дәгъвасыны кылдыгыңызга канәгать итмәй, алардан дәхый[204] узып китүне фараз итеп[205], програм төземешсез. Мөкәммәл[206] суратта гарәп лөгатене[207] вә әдәбиятыны әүвәлән[208] ирләремезгә укытсыннар, аннан соң хатыннарга уку фикерене йөртерсез. Иң элек ирләр кәмаләт[209] сахибе[210] улсыннар, безгә алар артыннан барсак ярар. 2нче маддәдә[211] кызларга мөкәммәл суратта рус лөгате вә рус әдәбияты укытылыр димешсез. 18нче, 19нчы гасырның мөкәммәл рәвешчә укымыш кызлары рус вә немец егетләре өчен чукындылар. Сез шуны күрмәдеңез вә ишетмәдеңезме? Ирләремез мөкәммәл суратта рус әдәбиятыны белмәдекләре хәлдә, безләр боны белеп русларгамы барырмыз? Кыз мәктәбенә гали фәннәр күрмәгән кемсә[212] мөгаллим кылынмас, димешсез. Димәк поляк, әрмән вә гайреләрдән мөгаллим куелыныр. Сез русча укуны фараз итү илә дә татар ирләрене тәмам кеше җөмләсеннән чыгармышсыз, әгәр дә мөкәммәл суратта рус әдәбиятыны белер улсаңыз, ул вакыт ни хәлдә улырсыз! Безем аталарымыз – ислам каһарманнары, безне чит милләтләрдән тәрбия иттерүгә аслан[213] разый улмаслар. Боны исә динемез дә мөсагадә итмәс[214]. Без шул татарларның безгә ата булып торуларына бик мәртәбә ризалармыз. Дөрес, үземезнең ана телемездә голүм шәргыяләремезне[215], әдәбиятымызны вә сезнең 3нче, 4нче маддәләрдә бәян иткән[216] шәйләреңезне[217] укуны аталарымыздан сорарга хакымыз бар.

***«Вакыт»:***

Зәйтүнә ханымның бу рәддиясендә гаять катыгъ сүзләр улдыгыннан, аларны төшерергә вә бәгъзеләрене тәбдил итәргә[218] мәҗбүр улынды. Йомшак сүзләр илә мәмләкәтләр забыт ителенер[219]. Әгәр дәхый язмак улсалар, мөлаем язмаклары мәрҗүдер[220].

*«Вакыт», 1906, 5 сентябрь.*

[203] Мөсавәт – тигезлек, бердәйлек.
[204] Дәхый – тагын, тагы.
[205] Фараз итү – уйлау, фикерләү.
[206] Мөкәммәл – камилләшкән, төгәлләнгән.
[207] Лөгать – тел.
[208] Әүвәлән – иң элек, иң башта.
[209] Кәмаләт – кимчелексез, камиллек.
[210] Сахиб – ия, хуҗа.
[211] Маддә – пункт, параграф.
[212] Кемсә – кеше, зат.
[213] Аслан – һич, һичбер, һичкайчан.
[214] Мөсагадә итү – мөмкинлек бирү, булышу.
[215] Голүм шәргыя – шәригать, дини гыйлемнәр.
[216] Бәян итү – аңлату.
[217] Шәй – нәрсә, әйбер.
[218] Тәбдил итү – үзгәртү, алмаштыру.
[219] Забыт итү – беркермәгә теркәү, язып кую.
[220] Мәрҗү – өмет ителгән, үтенелгән.

***«Вәкилә»***

**Вәкиләнең җавабы**

70нче номерлы «Вакыт»та «Вәкиләгә рәддия[221]» сәрләүхәле[222] бер бәнд[223] күрелде[224]. Бу бәнднең иясе илә сүзгә килешергә ниятем юк исә дә, рәддиясе хакында берничә сүз язарга мәҗбүрият күрелде.

Хөрмәтле Зәйтүнә туганым! Рәддиянең ахырында Зәйтүнә Фәхрия дия кул куелган булса да, бу рәддиядән хатыннарга дошман күзе илә караучы ирләр исе киләдер. Гәрчә бән һәм үзем мәктүбләремне ир кешенең ярдәме илә язсам да, үземезгә, ягъни хатыннарга файдалы язулар илә файдасыз язуларны бик гүзәл фәрекъ итәмен[225]. Хатыннарга зарарлы язуларның ахырына һичбер заман «Вәкилә» имзасыны төшермәймен. Кәләлем[226] рәддияңезгә. Рәддиядә: «Ирләргә мөсавәт[227] дәгъвасы илә генә канәгать итмәенчә, алардан дәхый[228] узып китүне фараз итеп[229], програм төземешсез», динелмештер. Хәзерге хәлдә улан татарлардан узып китүне фараз итсәк вә узып та китсәк, ни истихалә[230]? Дәхый рәддиядә: мөкәммәл[231] сурәттә гарәп лөгатене[232] вә әдәбиятыны әүвәлән ирләремезгә укытсыннар», динелмештер. Боны хатыннар укытсыннармы? Бу эш аларга нидән лязем улсын? Ирләремез мөнкариз улып[233] беткәнчегә кадәр укымауны ихтыяр итсәләр, без дә, алардан узуны җаиз[234] күрмәенчә, алар илә бәрабәр инкыйраз[235] чокырына төшеп, йөзтүбән кидәлемезме? Рәддиядә: «Безгә алар артыннан барсак ярар», динелмештер. Алар безне ияртеп бара белсәләр ярар иде дә, бармыйлар бит! Рәддиядә: «Мөкәммәл сурәттә русча укымыш кызлар рус вә немец егетләре өчен чукындылар», динелмештер. Ул чукынган кызлар гаять аздыр һәм русчалары мөкәммәл улмактан башка, аларның төркичә вә гарәпчәләре һич юк яисә бик аздыр. Мөкәммәл сурәттә укыган ирләрнең дә марҗалар артыннан йөреп тәләф булганнары[236] юк дәгелдер. Без укымай, ирләремез генә укысалар, һаман шулай булыр. Әгәр ирләремез бездән күбрәк укып, без дә алар артыннан барсак, алай чукынучылар һәр ике тарафта да азрак булыр, бәлки һич тә

[221] Рәддия – кире кагу.
[222] Сәрләүхә – исем, мәкалә исеме, эпиграф.
[223] Бәнд – язма, кушымта.
[224] *Зәйтүнә Фәхрия.* Вәкиләгә рәддия // Вакыт. 1906. 5 сентябрь.
[225] Фәрекъ итү – аеру.
[226] Кәләлем – киләмен.
[227] Мөсавәт – тигезлек, бердәйлек.
[228] Дәхый – тагын, тагы.
[229] Фараз итү – уйлау, фикерләү.
[230] Истихалә – бер хәлдән икенче хәлгә күчү; мөмкин булмау.
[231] Мөкәммәл – камилләшкән, төгәлләнгән.
[232] Лөгать – тел.
[233] Мөнкариз улу – сүнү, бетү, нәселе калмау.
[234] Җаиз – дөрес, ярый торган.
[235] Инкыйраз – бетү, юкка чыгу.
[236] Тәләф булу – әрәм-шәрәм итү, бетү, бозылу.

улмас. Рәддиядә: «Рус әдәбиятыны белеп, русларгамы барырмыз?» динелмештер. Юк, кардәшем, барылмас. Бәнем яздыгым програм буенча яхшырак укып, ирләрнең асларына ут яксак, алар безне үзләре алырлык адәм улмага тырышырлар...

Рәддиядә: «Безем аталарымыз – ислам каһарманнары, безне чит милләтләрдән тәрбия иттерергә аслан[237] разый булмаслар», динелмештер.

Кардәшем Зәйтүнә! Сезнең аталарыңыз ни эш илә каһарман улдылар? Юкса, аларның милләтне инкыйраз чокырының читенә китереп, бүген я иртәгә әсфәлессафилингә[238] китәрлек итүләре «каһарманлык» саналамы? Бән[239] үз атамны вә башка һәмширәләремнең[240] аталарыны бик яхшы беләмен ки, алар һәр һәфтәдә[241] берничә белеш шәһәрләренең ишекләрене ачып, ике вә я өч хатынны әсирлектә тота алалар. Ихтимал ки, сезнекечә бу эш бөек бер сәясәт вә олуг бер каһарманлыктыр.

Җаным Зәйтүнә! Безне гарьләндермәңез. «Зәйтүнә Фәхрия» имзасыны хатын-кыз файдасы улмаган бәндләрнең ахырына куймаңыз. Вәкилә мәктүбләрене[242] милләт өчен вә хосусан хатын-кызлар өчен чын күңелдән кайгыручы бер кардәшеңез язадыр. Вәкилә мәктүбенә рәддия язуыңыз Вәкиләгә бөек бер [...][243] мөҗибдер[244]. Шуның илә бәрабәр, Вәкилә һичкемнең хәтере өчен хатыннарның хокукыны заегъ итмәгә[245] ризалык йөзе күрсәттерәчәк дәгелдер.

*«Вакыт», 1906, 26 сентябрь.*

***«Бер кыз»***

## Безне игътибарга алмыйлар

Без, хатын вә кызларның, голүм вә мәгърифәттән хәбәрсез калдыгымыз тугрысында гәзитәләрдә күп яздылар, бу исә һәркемгә мәгълүм улды. Ләкин боны игътибарга алып, чарасына керешкән адәм күрелми. Боның сәбәбе ни идеке безгә һәмишә[246] беленмидер. Ихтимал ки, «сачләре озын, гакыллары кыска» дия, безне адәмгә хисап итми торганнардыр. Ләкин шәһәремездә дарелмөгаллимат[247] дәресләрене тәмам итеп чыкмыш, вә бу көндә мөгаллимәлек вазыйфасы илә мәшгуль улмыш рус кызлары бардыр. Боларның

[237] Аслан – һич, һичбер, һичкайчан.
[238] Әсфәлессафилин – түбәннән түбәнгә.
[239] Бән – мин.
[240] Һәмширә – кыз туган, кыз кардәш.
[241] Һәфтә – атна.
[242] Мәктүб – хат, язылган нәрсә.
[243] Газетада укылмый.
[244] Мөҗиб – сораганга җавап бирүче.
[245] Заегъ итү – файдасыз итү.
[246] Һәмишә – һаман.
[247] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.

гакыллары һич тә кыска күрелми. Бәлки уку вә гүзәл тәрбия саясендә[248] хатын вә кызларның гакыллары беркадәр арта вә камилләнә торгандыр. У[249] илә исә мөселман кызлары бигрәк тә укырга тиешле иде. Безнең тугрымызда гәзитәләргә язучылар да бары бер уенчык итеп кенә язмыш улырлар. Юкса арада бер җитди эш күрелмидер. Җәһаләт[250] караңгылыгында хәбес[251] итеп, хайван мисалында надан ятканымызны әүвәле күрәләр булыр.

Шәһәремездә кызларга махсус мәктәп ачылачак хәбәре чыктыгында шатланмыш идек, ләкин ул тугрыда да бер хәрәкәт тә күрелми. Чамасы корыга шатланып кына калырмыз. Тырышучы булса, эш мәйданга чыгар иде, тырышучы юк.

Орск шәһәрендә бер кыз.

***«Вакыт»:***

Кызларны укытуны вә кызлар өчен мәктәпләр салып, ислам тәрбиясе бирүне сез ирләреңездән көтмәңез! Мыек илә эшләпә вә чапан мәсьәләләреннән югары бара алмаган бер кавемгә уйлашулар ерак!

*«Вакыт», 1906, 16 декабрь.*

**Тоз-Түбәдә кызлар**

**Тоз-Түбә кызларыннан аталарына**

Гыйззәтле[252] аталарымыз вә шәфкатьле аналарымыз! Яшьле күзләремез, хәсрәтле йөзләремез илә ялынып-ялынып әйткән ошбу сүзләремезгә игътибар күзләреңез илә карасаңыз вә әйткәннәремезгә зәррә[253] кадәр илтифат итсәңез[254] иде.

Һәркаюымның мәгълүмедер ки: голүм[255] вә мәгариф кирәк дигән сүзне гәзитәләрдә күрәмез, һәркемнең агызыннан ишетәмез. Инде шундый заманда безем Тоз-Түбәдә, гәрчә тәртипсез генә булса да, өч мәхәлләмездә дә мәктәп яки мәдрәсәләр бар. Әмма без, бичара кызлар, өчен ни мәктәп бар, ни мөгаллимә бар, ни дә безне бу көнгә кадәр исенә алып укыту, тәрбияләү кайгысында йөргән бер адәм бар! Соң без, Тоз-Түбә кызлары, әллә адәм балаларыннан түгел микән? Хәлбуки[256], без дә ирләр кебек үк адәм балалары һәм мөслимәләрмез. Адәм баласына гыйлем вә мәгърифәтсез адәмлек юк икәне

[248] Сая – күләгә.
[249] У – ул.
[250] Җәһаләт – наданлык.
[251] Хәбес – тоткын, кулга алынган.
[252] Гыйззәтле – кадерле.
[253] Зәррә – бик аз, тузан бөртеге кадәр.
[254] Илтифат итү – игътибар бирү.
[255] Голүм – белемнәр.
[256] Хәлбуки – ләкин.

һәркемгә мәгълүм. Мөслимә улдыгымыз сәбәпле, уку безгә дә фарыз[257]. Бу фарыз исә сез аталарымыз илә аналарымыз өстендәдер: безне укытмау сәбәпле бик зур бер фарызны үтәмәгән вә безләрне хайванлыктан адәмлеккә чыгармаган буласыз.

Инде бу көнгә кадәр шул фарызларны үтәмәк булсаңыз да, бу көннән соң сүзләремезгә колак асып, шул фарызларыңызны түләргә тырышсаңыз иде.

Янә меңләрчә рәхмәт укыймыз ки, шушы көннәрдә шәһәремездә булган тәрәккыйпәрвәр[258] әфәнделәр без бичараларга бер мөгаллимә китертергә йөриләр икән, дип ишеттек. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре ярдәм биреп, максудлары[259] хасыйл булса иде.

Инде сез аталарымыздан үтенәмез ки, шушы әфәнделәр илә бер сүздә булып, мөгаллимә китерүгә һәм ул мөгаллимә килгәч, безне дә укытуга тырышсаңыз иде. Һәм тәгассыб[260] пәрдәсе илә күзләреңезне пәрдәләп, мөгаллимә китерергә йөргән кешеләргә каршы төшмәсәңез иде.

*«Вакыт», 1907, 21 июль.*

***Габделәүли Гобәев***

**Тоз-Түбәдә кызлар мәктәбе**

198нче номерлы «Вакыт»та кызлар мәктәбе хакында Тоз-Түбә кызларының аталарына язылмыш мәктүбләрене[261] укыдык. Яздыклары исә дөрестер. Чөнки бу көнгә кадәр шәһәремездә кызларга махсус мәктәп юк иде вә мөгаллимә китертеп укыту чарасына керүчеләр дә күрелми иде. Ошбу сәбәптән кызларымыз надан булып йитешәләр иде. Мөселман булган хатын-кызларга да гыйлем уку фарыз булса кирәк. Аларның да шәригать хозурында бер кач вазыйфалары вә хаклары булынса кирәк.

Шәһәремездә бер абыстай кызларга үзенең көче йиткән иман шартлары, «Һәфтияк»[262] иҗекләре укытып торды, аның өчен аңа рәхмәт укыймыз. Ләкин йорт эчендә гаилә башлыгы улачак кемсәләргә «Һәфтияк» иҗекләре генә йитәрлек булмады, дәхый бик күп нәрсәләр белергә тиешле идеге мәгълүмдер.

Чит шәһәрләрдә улан халыклардан гыйбрәт алырга Тоз-Түбә халкына да вакыт йитмешдер. Шәһәремездә бер мәктәп ачылып, бер мөгаллимә китермәк бу шәһәр халкы өчен бик агыр бер эш дәгелдер. Үзенең тәрбиясендә улан

[257] Фарыз – ислам дине буенча, һәрбер мөселман эшләргә тиеш булган мәҗбүри гамәлләр.

[258] Тәрәккыйпәрвәр – прогрессив, алдынгы.

[259] Максуд – максат.

[260] Тәгассыб – фанатизм.

[261] *Тоз-түбәдә кызлар.* Тоз-Түбә кызларыннан аталарына // Вакыт. 1907. 21 июль.

[262] «Һәфтияк» – Коръәннең җидедән бер өлешен эченә алган китап.

балаларны укытмак, кирәк ир, кирәк кыз улсын, фарыз дия ишетәмез. Үземез укымадыгымыз өчен бер гөнаһлы. Вә балаларымызны укытмадыгымыз өчен икенче мәртәбә гөнаһлы улмакымыз яхшы эш булмас. Үземез гыйлемнән мәхрүм калдык, һич булмаса, балаларымыз укысын!

Гәзитәдә укып та, бик яхшы дия, үтеп китәргә ярамый. Бәлки чынлап эшкә керешергә кирәк.

Тоз-Түбә

*«Вакыт», 1907, 2 август.*

***«Сөйкемсез»***

**Башка милләттә дә, бездә дә кызлар укыйлар**

Һәр татар, баласына истинҗа[263], хәез[264] вә нифас[265] мәсьәләләрене белдерүне фарыз санаганга, угылы булсын, кызы булсын, баласын бераз укытмый калдырмаска тырыша: угылын мәктәпкә яхуд хәлфәгә, вә кызын да мөбарәк остазбикә абыстайларга тапшырадыр. Угылы мәктәптә булса, укырга, язарга өйрәнеп, хәлфәдә булса, «әбҗәд»[266] иҗекләренә өйрәнеп чыга. Әмма кызы нишли? Ул бичара нәрсәгә өйрәнеп чыга? Бездә гадәт – кызларга, бераз телләре ачылып, сүз аңлый башлагач та, анасы «бисмиллаһ» вә «әбҗәд» өйрәтә башлый. Үзе бөтенләй неграмотный хатын улса да, шулай итеп бер ел яки артыграк өйдә маташтырып, кызының саф миен ватып, бутап бетергәннән соң, кулына кызын җитәкләп вә кесәсенә биш кәпиген кыстырып, абыстайга килә: кызын китерә. Нәрсәгә дип? Кемгә дип? Нишләтергә дип? Кем ул абыстай? Нәрсә аның тәдрисханәсе[267]? Әгәр дә белсәңез иде боларның үзләрен, укыту рәвешләрен, бу тәдрисханәнең нәрсә икәнен, көләр дә идеңез, егълар да идеңез; дини һәм хәяти тәрбиягә дип кызын китергән ананың газиз баласын калдырып китә торган бу мәктәп караңгырак кына, кечкенә генә бүлмә, корт шикелле түгәрәкләнеп мыж-мыж-мыж итеп тора торган бер табын (кружок), ул табын уртасында күзлеген җеп берлә башына әләктереп куйган карчыграк кына хатын, остазбикә-абыстайдан гыйбарәттер. Абыстай йә зуррак кызы берлә, нечкә тавыш берлә «Чын адәм җәннәттә...» дип, «Мөхәммәдия»[268] көйләп, яхуд кечерәк кызы берлә «әбҗәд» өйрәтеп утырган вакытта, уң яктан: «Абыстай, кара әле, Сәхибкамал уйнап утыра», – дигәндә, сул яктан: «Абыстай, менә Миңлегөл сугыша», – дигән тавыш килгәндә, алдан: «Абыстай, кара әле, менә Заһидә китабымны актарган», – дип кыч-

---

[263] Истинҗа – пакьләнү.

[264] Хәез – күрем.

[265] Нифас – бала тудыру.

[266] Әбҗәд – борынгы гыйбрани (яһуд) әлифбасындагы хәрефләр тәртибен күрсәтү өчен ясалган, мәгънәгә ия булмаган сүзләрнең беренчесе.

[267] Тәдрисханә – белем бирә торган бина, бүлмә.

[268] «Мөхәммәдия» – төрек шагыйре Мөхәммәд Язычы угылы Чәләби (1451 яки 1453 елда үлгән) тарафыннан төзелгән көйле әсәр; эчтәлеге Мөхәммәд пәйгамбәр һәм мөселманнар турындагы дини-әхлакый үгет-нәсыйхәттән гыйбарәт.

кырганда, Заһидәсе: «Китабы арасында егетләр хаты бар», – дип бакырганда, арттан берсе: «Абыстай, мин сабагымны белдем, куйыйм», – дип өлгерми, зуррак Фәхриҗамал: «Абыстай, ул белде, куйсын», – дип кычкырып өлгерә. (Күп вакытта кызларның кечерәкләре абыстайга тыңлатырга өлгерә алмый, бәлки зуррак «Мөхәммәдия»-ханнарга[269] тыңлата. Бу «Мөхәммәдия»-ханнар – кечерәк кызның туганымы, йә ахирәт дустымы, яки матуррак чәчәк биргән булса, шул вакытта бу «ханнар» абыстайларына «Мәрьямбану белде» диләр). Шушындый төрле тавышлы концерт эчендә абыстай сабак бирә. Әле бу гына аз, зуррак кызлар икәү, өчәү бер булып, өзелеп китәрлек нечкә тавыш илә «Мөхәммәдия» яки «Бакырган»[270] да көйләп җибәрәләр. Әлхасыйль[271], мыж-мыж-мыж, бары бер мыждан гыйбарәт булып чыга. Шулай бик күңелле итеп мыжылдап утырганда, остазбикә абыстай да, картының йомышы төшеп киткәнлектән, абыстайны дәшеп ала; абыстай да икенче бүлмәгә кереп китә. Менә инде ул кереп киткәч, бу бүлмәдә сугыш дисеңме, кычкырыш дисеңме, егълаш дисеңме, уйнау-көлеш дисеңме, әлхасыйль, ниләр генә булмый инде.

Бераздан абыстайның ишеге ачыла башлавына берәүгә дә аңланмый торган, лебер-лебер-лебер-лебер иткән тавыш (звук) килә башлый; ягъни кызлар бик тырышып укый күренәләр. Ягъни вакыт абыстай чыкканчы зуррак вакыйга булып куйса: берәрсе егълап утырса, абыстай бик каты чәрелдәп: «Җүнсезләр, оятсызлар», – дигән сүзләре илә бөтен дәресханәне дер селкетә. Һәрничек тә алай була, болай була, сәгать 11 тула; «Абыстай, сабагымны куйыйм, белдем», дигән тавышлар ишетелә башлый, кызлар да бөтен өйне дер селкетеп, чабышып, чыгып та китәләр. Кем сабак алган? Кем укыган? Кем белгән? Кем нишләгән? Һич белүче һәм белергә теләүче юк. Шулай да кызлар бик зур кулдагы Коръән, «Мөхәммәдия»ләрне зур-зур букчаларга төреп, бик күп нәрсә укыган вә белгән шикелле итеп йөриләр. Ата-аналары да кызларын укытып, үз өсләреннән вазыйфаларын төшергән шикелле, үз хәлләреннән вә кызларының гыйлемдә тәрәккыеннән разый булып көн итәләр. Менә шушы хәлдә гыйлемханәгә безнең киләчәктәге милләт аналарымыз йиде яшеннән тапшырыла вә ул бичара анда (әгәр бай кызы булмаса) бик күп егълашалар, кыйнашалар, орышалар, ахирел әмер[272] бераз зурая, өйрәнеп китә, үзе зур кызлар арасына керә башлый, «әбҗәд»не мөкәммәл[273] белә, «Мөхәммәдия», «Бакырган» укый башлап, бик үк бәхетле булып җиткәнче укыса, «Миннәт әл-мосалли»дан[274] ирләр, кызлар кайвакыт балигъ вә балигалар[275] булалар, нинди тиз.... истинҗа[276] дөрес һәм ничә данә-

---

[269] Хан – бу очракта: укучы, әлеге китапны өйрәнүче шәкерт.

[270] «Бакырган» – Урта Азия суфи шагыйре Сөләйман Бакыргани (1186 елда үлгән) шигыре белән ачылып, аның һәм шул замандагы бүтән шагыйрьләрнең әсәрләреннән төзелгән җыентык. Беренче мәртәбә 1846 елда Казанда басылган.

[271] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.

[272] Ахирел әмер – иң актыкта, иң соңында.

[273] Мөкәммәл – бик яхшы, камил.

[274] «Миннәт әл-мосалли» – «Намаз укучы кешегә ярдәмлек».

[275] Балигъ, балига – җитешкән, тулы, кимчелексез; яшүсмерлектән чыгу.

[276] Истинҗа – тәрәттән соң пакъләнү.

се белән истинҗа кирәк, күпме кадәр.... кай урынга төшсә, нәҗес[277] була шикелле, кызларга бик кирәк (важный) мәсьәләләрне белә башлый. Шулай итеп, 6 яшендә килгән бер кыз 10 елдан 16 яшендә тәмам мөкәммәл, дини бер курсны тәмам итеп, кая куйсаң анда яраклы булып чыга.

Бәхетле, бик бәхетле!!!

Бу бәхетлеләр илән башка милләт кызларын чагыштырып карасак, нәрсә күрәмез? Башка кавемнең кызлары 8 елда гимназия яхуд башка мәктәпне тәмам итеп, үз динен, аның өстенә хисап, җәгърафия, тарих, гыйльме әшья[278], һәндәсә[279], физика, француз, немец лисаннары[280] вә башкаларны, әлхасыйль, санап бетермәслек, безнең хатын-кызларымыз исемен дә ишетмәгән нәрсәләрне белә. Менә инде бу аналарның вә безнең хатыннарымызның бала тәрбиясе бирберсенә мөнәсәбәтле булулыгын кара хисап белән дә белергә мөмкин.

*«Әл-Ислах», 1907, 20 октябрь.*

## «Әл-иҗтиһад» мәктәбе[281] талибәтеннән[282]

Мөхәррир әфәнде!

Безем бу мәктүбемезне могътәбәр[283] җәридәңезнең[284] бер канәренә[285] дәреҗ итүеңезне[286] үтенәмез.

Без гыйлем, һөнәр, мәгърифәт һәм уку юлына аяк басып, үземезнең, ирләремезнең аяк астында изелгән башларымызны күтәрик, без дә азрак хәрәкәтләник дип, укырга, язарга, белергә тырышсак та, Печән базары кибетенә төшүче, баш өстенә төен куйган, авызына сагыз кабып, өйләренә акбур яккан бозык хатыннар безләрне сабакка барганда-кайтканда төрле кабахәт сүзләр илә хурлыйлар, русча укып, ыштансыз йөрергә өйрәнәсез, татарча укып, егетләргә хат язасыз, диярәк. Хәтта мөгаллимәләремезнең диниләренә кадәр үзләре ни русчадан, вә ни дә татарчадан язарга, укырга белмиләр. Дин, иман вә игътикадтан[287] тузан кадәр хәбәрләре улмаса да, «Тегү, чигү, бәйләү нигә кирәк? Менә без сезнең кебек мөгаллимәләрдән, әллә нindәй марҗалардан укымадык та, үземез кәләпүш эшләп, Печән базарының матур-матур, япь-яшь егетләренә төшереп кыйммәт бәһагә сатамыз. Хисап нигә кирәк? Без менә бармагыбыз белән дә санап, кибетчеләрнең исләрен җибәрәбез. Сезгә бер дә укырга кирәк түгел, хатын-кызларга укырга

[277] Нәҗес – әшәке, пычрак.
[278] Гыйльме әшья – физика.
[279] Һәндәсә – геометрия.
[280] Лисан – тел.
[281] «Әл-иҗтиһад» мәктәбе – күренекле педагог, мөгаллимә Маһруй Мозаффариянең (1873–1945) Казан шәһәрендә кыз балалар өчен ачкан мәктәбе.
[282] Талибәт – укучылар.
[283] Могътәбәр – хөрмәтле.
[284] Җәридә – газета.
[285] Кәнар – кырый, чит.
[286] Дәреҗ итү – теркәү, урнаштыру.
[287] Игътикад – чын күңелдән ышану.

хәрам», – дип, безне шулай дөньядагы кабахәт сүзләр илә сүгәләр, безләр ничек тәрәккый[288] табыйк! Без кайчан үземезнең хакларыбызны табармыз?

Без бу хатыннарның сүзләрен колакка алып, укудан, белүдән баш тартсак, әлбәттә, бер җаһил[289] иргә очрап, үлгәнче таяк астында изеләчәгемез кояш кеби күренеп тормактадыр.

Мозаффария ханымның «Әл-иҗтиһад» мәктәбе кызларыннан.

Имзалар: Мәхмүдә Мозаффария, Җәмилә Мозаффарова, Гайнекамал Сәгыйдова, Рабига Казакова, Фәхриҗиһан Субаева, Рабига Ишморатова, Фатыйма Баязидова, Зәйтүнә Мәүлүдова (Чистапули), Нәгыймә Козлова, Миңлегаян Сәгыйдова, Маһруй Мортазинәви, Яфарбикә Фәйзуллинәви, Мәрьям Апашева, Сәгадәт Камалетдинова, Мәрьям Хәмзинәви.

*«Әл-Ислах», 1907, 19 ноябрь.*

***Маһисәрвәр***[290]

## Кызлар мәктәбенең идарәсе кемнәр кулында булырга тиеш?

Гәзитәләрдә укып вә колагыбыз берлә ишетеп күп йирдә кызлар мәктәбе бина ителдеге мәгълүмемез улдыгыннан, кызлар мәктәбенең идарәсе хакында бер кач сүз язуны мөнасиб күрдем[291]. Егерменче гасыр мәдәниятенең безем татар халкына да бераз тәэсире күрелде: мәктәп-мәдрәсәләргә бер тиен бирми торган мөтәгассыйб[292] байларымыз да йөзләр вә меңнәргә төшереп мәктәпләр бина кылдыра башладылар.

Безем шул егерменче гасыр мәдәнияте тәэсире илә бина ителмеш мәктәпләрдә дә башка гасырлардагы кеби без – ханымнарның, дәһа[293] тугрысы бөтен милләт балаларының башлыча җәһаләтләренә[294] сәбәп булган хәзрәтләр мөдирлек итәргә борыннар тыгалар. Бәнем ирләр мәктәбендә эшем юк, аны мөгаллимнәр кагыйртыр. Бәнем язуым ханымнар мәктәбе хакындадыр. Хәзрәтләр, һичкем тарафыннан мөдир тәгаен улынмадыклары хәлдә, дахили[295], хариҗи[296] идарәләренә катнашалар. Хәзрәтләр! Бу кадәре милләтне җәһаләттә калдыруыңызга канәгать итмисезме? «Өлфәт» гәзитәсе сезне «милләт хафизлары» дисә дә, мин сезне «милләт микроблары» диячәкмен.

Без, ханымнарга, хосусан, без мөгаллимәләргә, боның чарасында булынмак тиешледер. Безем бу заманда иң кадерле вакытымыз, гадәдемез[297] бик аз!

---

[288] Тәрәккый – алга китү.

[289] Җаһил – надан.

[290] Маһисәрвәр Бикмиева – Пешли авылы (хәзерге Мордовия Республикасында) мөгаллимәсе.

[291] Мөнасиб күрү – тиешле табу.

[292] Мөтәгассыйб – фанатик.

[293] Дәһа – тагын да.

[294] Җәһаләт – наданлык.

[295] Дахили – эчке.

[296] Хариҗи – тышкы.

[297] Гадәд – сан.

Безне бер карья вә шәһәргә чакырдыкларында беренче шартымыз вә беренче сөалемез: «Мәктәпнең дахили, харижи идарәсе кем кулында?» – сөале тәкъдим ителсен. Әгәр милләт микроблары – хәзрәтләр катнашкан булса, барудан иба иттерергә[298] кирәк.

Без шундый форсат вә кадерле вакытымызда ханымнар мәктәбендә дә хәзрәтләрне мөдир итеп калдырсак, соңыннан аларны чыгаруы йиңел булмас. Кызлар мәктәбенең харижи идарәсе әхлаклы вә тәрбияле гавам[299] ханымнары кулында булса булсын, ләкин хәзрәтләр вә надан абыстайлар катнашмасыннар, дахили идарәсе, әлбәттә, мөгаллимәләр кулында булырга тиешледер, зирә[300] бу заманда дахили идарәгә катнашырлык ачык фикерле ханымнар аз әле.

*«Әл-Ислах», 1907, 10 декабрь.*

***Гали Ибраһимов***[301]

**Ачык хат**

Уфа өязе, Ташлыкүл авылы[302] халкына:

Газиз кардәшләрем! Бу сәнә мөсафир[303] уларак мин сезнең авылыңызга бардым. Хөкүмәттән рөхсәт алып, школа ачкансыз, балаларыңызны укытыр өчен русча вә мөселманча мөгаллимнәр китергәнсез, өйләгә кадәр ир балаларыңыз, өйләдән соң кыз балаларыңыз укыйлар, мөгаллимнәреңез яхшылар икән. Бик яхшы, тәбрик итәмен. Мәсҗетеңездә җомга намазында булындым. Имамыңыз Нуретдин хәзрәтнең вәгазьләрене дә ишеттем. Тәртип берлән укуга, ысул җәдидәгә хилаф[304] күп нәрсәләр бәян итте. «Бездә шайтан укытуы башланды, шул укуга биреп, балаларыңызны харап итмәңез», – диде. Бу җаһил[305] мулла, һич улмаса татарча үз телендә сөйли белсә, ярар иде. Ул да юк. Боның кеби фикерсез вә мәгарифсез бер адәмнең сүзләренә карап, балаларыңызны укудан мәхрүм калдырмаңыз. Укуның ирләргә дә, кызларга да фарыз[306] булганын, вә укудан башка инсанга[307] дөнья вә ахирәт сәгадәте юклыгын онытмаңыз... Минем сезгә тәүсыям[308] шулдыр.

*«Вакыт», 1908, 10 гыйнвар.*

---

[298] Иба иттерү – каршы килү.

[299] Гавам – масса, гади халык.

[300] Зирә – чөнки.

[301] Гали Ибраһимов – Уфа өязе, Сәфәр волосте, Торбаслы авылы (хәзер Иглин районына карый) мөгаллиме.

[302] Ташлыкүл авылы – хәзер Башкортстанның Бүздәк районына керә.

[303] Мөсафир –юлчы.

[304] Хилаф – каршы, кире, тискәре.

[305] Җаһил – надан, белемсез.

[306] Фарыз – үтәлүе тиешле булган бурыч.

[307] Инсан – кеше, адәм.

[308] Тәүсыя – киңәш бирү, васыять итү.

## [Верхнеурал өязеннән[309] язалар...]

Верхнеурал өязеннән язалар: «Берничә хәмиятьпәрвәр[310] вә яңа фикерле имамнарымызның гайрәтләре саясендә[311] өяземездә типтәр халкы арасында байтак кына ысулы саутия[312] мәктәпләремез артты. Уку эшләре аз булса да, алга бара. Һәр карьядә[313] диярлек 70–80 бала укый. Күбесе ысулы саутия иләдер. Соң бер-ике сәнә эчендә халкымыз эчендә укырга-язарга белүчеләрнең күп артуы күренеп тора. Фәкать тәәссефтер[314] ки: берничә карьяләрдәге карт имамнар һәмишә[315] гыйнад[316] вә тәгассыбләрендә[317] дәвам илә ысулы саутия, тәртип вә интизамга[318] каршы торалар. Һәртөрле гореф вә гадәтләрне шәригать кеби күрсәтеп, бичара халыкны җәһаләттә[319] тоталар, халыкның әфкяр[320] вә әхлякын төзәтү бонлар кашында һичбер шәй[321] түгелдер. Мәҗлесләрдә бар сөйләгәннәре зәкят[322], гошер[323], фитыр[324], гүр сәдакасы[325] кеби мәнафигъ шәхсыяләредер[326]. Тамаклары туеп, кәефләре килгәч, хатын-кыз тугрысында сүз ачалар да, кәх-кәх көлешеп утыралар. Гавам[327] халкының имам артыннан баруы, имамнар юл күрсәтсә, халыкның каршы килмәве вә һәртөрле фидакарьлеккә хәзер булынуы әтрафымызда[328] билфигыль[329] исбат螺 ителде».

*«Вакыт», 1908, 7 февраль.*

[309] Верхнеурал өязе – Оренбург губернасындагы өяз.
[310] Хәмиятьпәрвәр – башкаларның зарар китерүеннән саклаучы.
[311] Саясе – күләгәсе, ышыгы.
[312] Ысулы саутия – аваз ысулы.
[313] Карья – авыл.
[314] Тәәссеф – үкенү, кайгыру.
[315] Һәмишә – һаман.
[316] Гыйнад – кирелек, тискәрелек.
[317] Тәгассыб – фанатизм.
[318] Интизам – тәртиплелек, кагыйдә буенча эш итү.
[319] Җәһаләт – наданлык.
[320] Әфкяр – фикер.
[321] Шәй – әйбер.
[322] Зәкят – ислам дине буенча сәүдәгәрләргә еллык кеременең 40 тан бере күләмендә салынган еллык налог.
[323] Гошер – уңышның уннан бере күләмендә дини налог.
[324] Фитыр сәдакасы – Рамазан ае ахырында, Ураза гаетенә кадәр бирелә торган сәдака. Һәр мөселман тарафыннан бирелә.
[325] Гүр сәдакасы – мәетне кабергә куйганчы, мәет янында, аның гөнаһлары кичерелсен өчен бирелгән сәдака (гадәттә бер куй, яки куй бәясендәге акча, яки бер капчык он, тавык, каз, яки йомырка бирелгән).
[326] Мәнафигъ шәхсыясе – шәхси файдалары.
[327] Гавам – халык.
[328] Әтраф – тарафлар, тирә-юнь.
[329] Билфигыль – чынлыкта, чынлап.

***Фәһимә Хәйдәрова***

## Оренбургта кызлар мәктәбе

Оренбургта Гаспринский[330] җәнабләренең чирек гасыр хезмәтен тәбрик өчен төзелгән дүрт ләйханың[331] бәнем кыска фикеречә «сиксән кыз балалалык монтазам[332] ибтидаи[333] мәктәп»не ачарга карар кылу кирәк иде.

Чөнки Оренбургта ирләр өчен ничә тәртипле мәдрәсә улса да, кызлар өчен фәкать ике генәдер. Хатын-кыз милләтнең яртысы улгач, аларга һәм уку ирләр илә тигез кирәк. Дарелмөгаллимин[334] ачканчы, әүвәл шуларны тикшерү лязем[335] иде. Укыган ирләремез өчен укыган кызлар кирәк, укыган ирләремез укымаган кыз аласылары килерме? Янә әйтәм: дарелмөгаллиминнәр ачканчы, ибтидаи мәктәпләр кирәк, хосусан[336], кызлар өчен.

Югарыда кызлар өчен ике тәртипле мәктәп бар дидек, алардан берсе мәгълүм Гани бай Хөсәенов[337] һиммәте[338] илә ачылып, мөгаллимәләре Фатыйма ханым Адамова[339] вә аның кызы Хәдичә ханымдыр. Укытулары яхшы тәртипле дисәләр дә, минем фикерем аны да бик тәртипле диясе килми. Кирәкле гыйлемнәрдән гыйльме хисап, җәгърафия, тарих, имля[340] кеби дәресләрне укытмыйлар. Мәдрәсәдә 9 сыйныфка бүленеп укыталар. Мәзкүр[341] дәресләрне дә укытмагач, ул тугыз сыйныфта ниләр генә укыталар икән? Шулай да булса, кадим[342] түгел, җәдит[343] тә түгел, бәлки җәдитрәк.

Икенчесе җәмгыяте хәйрия тарафыннан ачылмыш улып, бонысы хакында берни дә әйтә алмыйм. Менә шуның өчен дә Оренбургка бер тәртипле кызлар мәктәбе кирәк. Бу минем фикерем. Башкаларның фикере ничектер.

Оренбургта Фәһимә Хәйдәрова.

---

[330] Исмәгыйль Гаспринский (1851–1914) – Кырым татары зыялысы, төрки-татар дөньясының билгеле мәгърифәтчесе, «Тәрҗеман» газетасының нашире һәм мөхәррире, җәдит мәктәпләре өчен дәреслекләр авторы.

[331] Ләйха – проект.

[332] Монтазам – тәртипкә салынган, тәртипле, рәтле.

[333] Ибтидаи – башлангыч.

[334] Дарелмөгаллимин – ир укытучылар әзерли торган махсус уку йорты.

[335] Лязем – тиеш, кирәк.

[336] Хосусән – бигрәк тә, аеруча.

[337] Габделгани Мөхәммәтгали улы Хөсәенов (1839–1902) – эре сәүдәгәр, химаяче, мәктәп-мәдрәсәләр ачучы.

[338] Һиммәт – тырышлык.

[339] Адамова (Әдһәмова) Фатыйма Миркамали кызы – Оренбургта Гани бай Хөсәенов акчасына 1901–1902 уку елында яңа ысуллы татар кызлар мәктәбе ачучы, I Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары корылтае делегаты.

[340] Имля – язу.

[341] Мәзкүр – алда әйтелгән.

[342] Кадим – искечә.

[343] Җәдит – яңача ысул нигезендә.

***Идарә:***

Фәһимә ханымның дәлилләре никадәр куәтле булса да, алар дарелмөгаллимин урынына кызлар мәктәбе ачу кирәклеген күрсәтергә йитмиләр.

Тәртипле кызлар мәктәбе ачарга кирәк! Ләкин дарелмөгаллимин булмаса, хәзерлекле мөгаллим вә мөгаллимәләр булмаса, ничек итеп вә нинди тәртипле мәктәпләр вөҗүдкә китерергә[344] мөмкин. Шуңар күрә, без үз тарафымыздан оренбурглы кардәшләремезнең дарелмөгаллимин ачарга касд итүләрен[345] муафыйк[346] вә бик вакытлы табабыз. Шулай да булса, дарелмөгаллиминебез булды, дип, кызлар мәктәбен дә истигъна[347] мөмкин түгелдер. Шуңар күрә дарелмөгаллимин өстенә «Гаспринский наменә»[348] сылтавы белән кызлар мәктәбе ачуны да Оренбург татарларыннан таләп ителсә, артык көчләреннән тыш эш таләп ителгән булмыйдыр. Дарелмөгаллимин – кичектерүе мөмкин булмаган заруриятлыр! Моның белән бергә кызлар мәктәпләре ачу да вөҗүбтер[349].

*«Әл-Ислах», 1908, 4 май.*

***Маһисәрвәр Бикмиева***

## Безне искә төшермиләр

Татар гәзитәләре дарелмөгаллимин[350] ачу мәсьәләсен бик куәтләп язалар. Бик күп кызу-кызу мәкаләләр дә яздылар. Һаман язалар. Бу әһәмиятле мәсьәләдер.

Ләкин, тәәссефкә[351], хиҗаб мәсьәләсендә карагруһлар берлә сүгешкән гәзитәләр, мөхәррирләр иң әһәмиятле тәгълим[352] мәсьәләсендә «Ирләргә дарелмөгаллимин кирәк!» – дия кычкырдыклары вакыт, без ханымнарга «Дарелмөгаллимат[353] кирәк!» – дия ник кычкырмыйлар икән? Егерменче гасыр кәнежләре[354] авызыннан бу сүзнең ишетелмәве вә бөтенләй онытылуы безне зиядә[355] тәгаҗҗебтә калдырадыр[356]. Хөррият, мөсавәт[357] театрда гына кирәк дип беләләр микән әллә?

---

[344] Вөҗүдкә китерү – барлыкка китерү.
[345] Касд итү – ниятләү.
[346] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[347] Истигъна – мохтаҗ булмау, бары белән канәгать булу.
[348] Нам – исем.
[349] Вөҗүб – зарурлык.
[350] Дарелмөгаллимин – ир укытучылар әзерли торган махсус уку йорты.
[351] Тәәссеф – кайгыга төшү, үкенү.
[352] Тәгълим – уку, укыту.
[353] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар әзерли торган махсус уку йорты.
[354] Кәнеҗ – яшь кеше, егет.
[355] Зиядә – арту, күбәю.
[356] Тәгаҗҗебтә калдыру – шаккаттыру, гаҗәпкә калдыру.
[357] Мөсавәт – тигезлек, бердәйлек.

Бу илә исә бу бик бөек бер хатаән[358] игътикадтыр[359], андый урыннарда үзләре барудан оялмасалар иде. Безем зур чалмалы суфи хәзрәтләремез дә күптән «Мөсавәт, мөсавәт!» – дип кычкырган булырлар иде.

Гаспринскийның 25 еллык хезмәте эчендә дарелмөгаллимин салырга тиешле күрәләр. Оренбург кеби җирләрдә ошбу мөнәсәбәт илә дарелмөгаллимин бина кылдырырыга карар да бирделәр. Ни өчен дарелмөгаллимат салдырырга карар бирмиләр? Вә ни өчен безем милли гәзитәләремез дарелмөгаллимат салырга тиешле күреп язмыйлар? Дарелмөгаллиматсыз безем мөгаллимәләр кайда йитешсеннәр? Әллә хәзердә дә мәшәкать берлә үзлекләреннән мөгаллимәлек хезмәтен үтәр өчен хәзерләнгән мөгаллимәләр дә ярый димәкче булалармы? Кайда кадәре безем җәһаләтемезне[360] озайтмакчы булалар? Казанда мәдрәсәләрне берләштерү мәсьәләсендә бер мәдрәсәне дарелмөгаллимин ясауны тиеш күрәләр дә, ни өчен бер мәдрәсәне дарелмөгаллимат ясауны тиешле күрмиләр?

Ишетә шу сөальләрем милләт сөальләре улдыгыннан, гәзитәләрнең, хосусән[361]: «Вакыт», «Әхбар»[362], «Йолдыз»[363], «Тәрҗеман»[364] кеби гәзитәләребез җавап бирсеннәр!

*«Әл-Ислах», 1908, 3 июнь.*

## Хатын-кыз мәктүбләреннән[365]

«Мөхәррир әфәнде! Әйтче зинһар, ватандашларымыз булган руслар үзләренең кызларын монтазам[366] шәһәр мәктәпләрендә, гимназияләрдә укыталар. Аның илә генә дә канәгатьләнмиләр, югары мәктәпләргә йибәреп, әдәбият вә голүм тәхсил иттерәләр[367], хәтта Яурупага йибәреп укыталар. Безнең этиләр исә безнең өчен адәм гакыллы бер ибтидаи[368] мәктәп тә ачып бирмиләр; руслар кызларын укытыр өчен бөтен байлыкларын сарыф итәләр, безнең этиләр исә кызларын укытырга бөтенләй әһәмият бирмиләр. Руслар ахмак булып, безнең этиләр гакыллы микән? Юкса, монда башка бер сер бармы?»

---

[358] Хатаән – ялгышлык белән, хаталы.

[359] Игътикад – чын күңелдән ышану, инану.

[360] Җәһаләт – наданлык.

[361] Хосусән – бигрәк тә, аеруча.

[362] «Әхбар» – 1907–1908 елларда Казанда нәшер ителгән сәяси, әдәби, иҗтимагый, икътисади һәм дини газета. Мөхәррирләре – Х.Фәйзи-Чистапули һәм Б.Шәрәф.

[363] «Йолдыз» – 1906–1918 елларда Казанда нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси газета. Мөхәррире – Ә.Максуди.

[364] «Тәрҗеман» – 1883–1918 елларда Кырымда Бакчасарай шәһәрендә, төркитатар һәм рус телләрендә нәшер ителгән әдәби-сәяси һәм фәнни газета. Нашире һәм мөхәррире – И.Гаспринский.

[365] Мәктүб – хат, язылган әйбер.

[366] Монтазам – тәртипкә салынган, рәтле, тәртипле.

[367] Тәхсил итү – уку, белем алу.

[368] Ибтидаи – башлангыч.

Бу хатны идарәмезгә язучы кеше бер татар кызыдыр. Боңа мөхәррир тарафыннан җавап бирелергә хаҗәт юк. Чөнки хакыйкать мәйданда, җавап заһир[369]. Дөньяда яшәү хокукыны саклаудан гыйбарәттер. Хокукны саклау исә ялгыз гыйлем вә мәгърифәт аркасында гына мөмкин. Мәгърифәтсез кешеләр җиңелә вә аяк астында изелә. Белекле кешеләр Ходайның һәммә нигъмәтләреннән истифадә итә[370]. Җаһилләр[371] алар кулына әсир төшә баралар.

Шушы дөньяда торып, яхшы мәгыйшәт[372] итә алыр өчен Марияга кирәк булган гыйлемнәрнең шуның илә бер шәһәрдә, бер урамда вә хәтта бер йортта ук торучы Фатыймага, Гайшәгә кирәк булмавы, әлбәттә, мөмкин түгелдер. Чөнки мәгыйшәтнең кануннары бонларның икесе өчен дә бертигездер.

Хатыннарында рух вә әфкяр[373] булмаган милләтнең ирләре дә шулай була. Хатыннарның хокукыны киметү ирләрне дә хокуксызлыкка төшерә.

Бер милләт ирләр илә хатыннардан мөрәккәб улдыгыннан[374], әгәр аның хатыннардан гыйбарәт булган яртысы мәдәниятсез вә җаһил калса, ул милләтнең тәрәккый итүе[375] мөмкин түгелдер. Хосусән ки, милләтне йитештерүчеләр аналардыр. Һәммә ир вә кыз балалар иң әсасле[376] булган ибтидаи тәрбияне аналар кочагында алалар. Куркак, җаһил, фикерсез аналар кулында тәрбия ителгән балалар эченнән гали калебле[377], каһарман , фидакарь адәмнәр йитешүе мөхаль[378] түгел исә дә, бик сирәк булырга мөмкиндер.

Кызлар укытуга халкымызның әһәмият бирмәвенә ис китәр урын юк. Бу һәммә милләтләрдә шулай булып үткән. Бездә генә түгел, христиан милләтләр дә элек заманнарда кызларга гыйлем вә мәгърифәт кирәкми, алар өй эше белсәләр йитә, дигәннәр. Соңра, азрак укысалар да ярый, ләкин язу үгрәнүләре тиеш түгел дигәннәр. Бара торгач, язу үгрәнүләре генә түгел, голүм галия[379] тәхсил итүләре дә тиеш булган.

Һич шөбһәсез, бу хәл бездә дә шулай булачактыр. Хәзерендә мөселман кызларына язу үгрәтү дөрес түгел диючеләрнең балалары әүвәлге мөселман хатыннарының хатыннарга гына түгел, ирләргә дә дәрес укытканлыкларын, гыйлем вә мәгърифәт саясендә[380] генә диянәт[381] вә әхлакны саклау һәм

---

[369] Заһир – ачык, билгеле.
[370] Истифадә итү – файдалану, куллану, тоту.
[371] Җаһил – надан, белемсез.
[372] Мәгыйшәт – көнкүреш, тормыш, яшәү өчен кирәкле нәрсә.
[373] Әфкяр – фикерләр.
[374] Мөрәккәб улу – кушылу, берничә нәрсәдән оешу.
[375] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.
[376] Әсасле – нигезле.
[377] Калеб – йөрәк, күңел.
[378] Мөхаль – мөмкин булмаган хәл.
[379] Голүм галия – югары белем.
[380] Саясендә – күләгәсендә.
[381] Диянәт – динлелек, дин тотучылык.

башкалар шикелле мәгыйшәт[382] итү мөмкин булачагын бик яхшы аңлаячаклардыр. Һәм хәзерендә дә аңларга башлаучылар юк түгел. Кызлар тәрбиясенә гәрчә бик аз булса да әһәмият бирелә башланды. Фәкать ни чара ки, ирләремезнең тәгълим[383] вә тәрбияләре бик касрдыр[384]. Үзе сукыр булган кешенең башкаларны җитәкләп алып баруы мөшкел бер эштер.

Гаилә мәгыйшәтемез төзәлмәенчә торып, милли хәятымыз төзәлгән түгелдер. Хәлбуки гаилә мәгыйшәтемездә ислахка[385] мохтаҗ бик күп нәрсәләр бар. Хатыннарга әйтелгән җәбер вә золымнарны әле аңлый алганымыз юк. Ул бичараларның түгелгән күз яшьләре калебләре әдәбият вә мәгариф нуры илә йомшамаган ирләргә күп тәэсир итмидер. Хатыннарымыз һәртөрле җәбер вә золымнарга түзә. Түзмәгәнләре чахотка була да үлә. Күп әһәмият биргән кеше юк.

Һич тиешсез рәвештә икенче хатын алу, төн буйларынча сәфахәт[386] йирләрендә йөреп, исереп кайткач, хатынын кыйнау, балалары илә хатынын ташлап китеп, ризык вә нәфәка[387] йибәрмәү, аерылырга теләгән хатыннарны кыйный-кыйный аермый тоту шикелле нәрсәләр бездә бик гади бер эшләр җөмләсеннән саналалар. Бонларга берәүнең дә, Духовный Собраниенең дә күп исе китми. Хатыннар дәгъвасын айлар, бәлки елларга суза.

Шуның илә бәрабәр, бу хәлләрнең мәңгегә сузылмаячагы, бүгенге караңгы кичәнең бер якты таңы да булачагы шөбһәсездер.

* * *

Хәзерге хәлдә хатын-кызларымызның тәгълим вә тәрбияләре ни рәвештә булганлыгын күрсәтмәк өчен, аларның үзләре тарафыннан язылган ике-өч мәктүбне[388] түбәндә дәреҗ итәмез[389].

Каргалыдан Бибигафифә Габделлатыйпова имзасы илә язылган хатта бу илә диеләдер:

«Каргалы шәһәрендә мәктәп вә мәдрәсәләрнең күплеге, һәм дә муллалар вә байларның да аз түгеллеге, байларның мал вә муллаларның гыйлем илә дин вә милләт юлында иҗтиһад иткәнлекләре[390] мәгълүмдер. Ләкин без мәгъсумә[391] кыз балаларны гафләт[392] вә җәһаләттән[393] коткарырга тырышучы бик аздыр. Шулай да булса, һиммәтле[394] байларымыз 4–5 ел эчендә кызларга

[382] Мәгыйшәт – көнкүреш, тормыш, яшәү өчен кирәкле нәрсә.
[383] Тәгълим – өйрәтү, укыту.
[384] Каср – аз.
[385] Ислах – реформа, үзгәреш.
[386] Сәфахәт – бозыклык.
[387] Нәфәка – аерылган хатыннарга бирелгән акча.
[388] Мәктүб – хат, язылган әйбер.
[389] Дәреҗ итү – теркәү, арага кертү.
[390] Иҗтиһад итү – тырышу.
[391] Мәгъсум – гөнаһсыз, керсез.
[392] Гафләт – игътибарсызлык, ваемсызлык.
[393] Җәһаләт – наданлык, аң-белемсезлек.
[394] Һиммәтле – тырыш, теләк белдергән.

махсус 3–4 мәктәп салып бирделәр. Фәкать болар да ысул вә тәртип яхшы куелмаганлыктан вә укытырга әһлиятле[395] мөгаллимәләр булынмаганлыктан, файдалары аз күрелде. Боларда укучылар да күп булмады. Үткән сәнә шәһәремезгә бер мөгаллимә килеп, яхшы укыта башлаган иде. Бонда укучылар көннән-көн күбәеп, соңга таба мәктәпкә сыймый башладылар. Күп файда күрелде. Ошбу тәртип илә укытканда, Каргалыда янә 5–6 кызлар мәктәбе булганда, укытучылар табылачак иде. Ләкин мәгаттәәссеф [396], бу ел ул мөгаллимә килмәде. Башканы китерүгә күп иҗтиһад итүче булмады. Шул сәбәпле, безләр уку җәһәтеннән ятимә булып, җәһаләттә калдык. Шул мөгаллимәдән дә файдаланып калган Нәфисә ханым (Хәйрулла хәзрәт кызы) үз ханәсендә бай кызларын яхшы тәртип илә укытса да, безләргә анда барып уку мөяссәр[397] түгел. 10 мәхәлләле бер мөселман шәһәрендә кызлар укырлык монтазам бер ибтидаи[398] мәктәп тә булынмавы никадәр зур тәәссефтер[399]!»

* * *

Сибириядән Н. ханым бу илә яза:

«Хатын-кызларымызның хәлләрен уйлап күз алдыма китерсәм, күңелләрем тулып, күзләремнән яшьләр килә. Тәрбия вә әдәптән бихәбәр[400] аналар балаларын ничек тәрбия итсеннәр! Ана кочагында яхшы тәрбия алмаган балалар соңыннан ничек тәрбияле булсыннар?! Болардан нинди бер милләт йитешсен? Бүгенге аналарны гаеп итәр хәл юк. Чөнки алар заманында мәктәп вә уку мөяссәр булмаган. Алар үзләрендә юкны әлбәттә балаларына бирә алмаслар. Ләкин бу хәлне һәмишә[401] шулай дәвам иттерергә ярыймы? Әгәр хәзер монтазам мәктәпләр ачып, кызларымызны укытмасак, киләчәктә дә милләт аналары вә аларның бала тәрбияләре хәзерге шикелле булачактыр.

Ир балаларымыз өчен һәр йирдә беркадәр тәртипле мәктәп вә мәдрәсәләремез була башлады. Әмма кызларымыз өчен боларның уннан берсе кадәр дә юктыр. Хәлбуки хатын-кызлар милләтнең тәмам яртысыдыр. Бүгенге икътидарсыз[402] мөгаллимәләр вә мәгълүматсыз абыстайлар кулында шулкадәр газиз кыз балаларымызның гомерләрен әрәм итәргә аталар вә агаларның кызганмауларына тәгаҗҗеб итәрлектер[403]. Бер кызны яхшы укыту ун ир бала укытудан да файдалырактыр. Чөнки кыз бала гаилә башлыгы, балалар анасы булгач, ул үзенең гыйлем вә мәгърифәте илә бөтен бер гаиләне яктырта, балаларын гүзәл тәрбия итеп инсаният[404] юлына кертә, хәтта асрауларга вә күршеләргә кадәр аның файдасы тия, эчендә мәгълүматлы хатын

[395] Әһлиять – бер эшне белү.
[396] Мәгаттәәссеф – үкенечкә каршы.
[397] Мөяссәр – җиңел, җайлы, җиңел үтәлешле.
[398] Ибтидаи – башлангыч.
[399] Тәәссеф – үкенү, кайгыру.
[400] Бихәбәр – хәбәрсез.
[401] Һәмишә – һаман.
[402] Икътидар – көч, куәт, булдыра алу.
[403] Тәгаҗҗеб итү – гаҗәпләнү, хәйран калу.
[404] Инсаният – кешелек дөньясы.

тора торган бер йорт гади бер йорт булмый, бәлки иң гүзәл вә иң файдалы бер мәктәп була. Гыйлем вә мәгърифәтсезлек сәбәпле бозылган гаилә мәгыйшәтләре сәфаләткә[405] төшә. Хатын-кызларның күплеге, хатын-кызларның мәгыйшәт җәһәтенчә даимән ирләргә йөк булып торулары, ирләре я аталары авырган яки үлгән хатын-кызларның мәгыйшәт мәйданында бөтенләй гаҗиз калып, әллә никадәр фәлакәтләргә[406] очраулары дикъкатькә алынса, хатын-кызларымызның тәрбиясенә хәзергедән күп артык әһәмият бирелергә тиеш иде...»

* * *

Семиречинский областьтан[407] кызлар укыту хакында язылган түбәндәге мәктүб хәйли[408] күңелле булып, боннан гыйбарәттер:

«Йидесу вилаятендә моннан берничә ел мөкаддәм[409] хатын-кызларны укыту бөтенләй кирәксез нәрсә санала иде. Алар милләт аналары вә милләткә иң әүвәле рухны бирүчеләр идекен һичкем искә алмый, ялгыз үстереп йиткезеп, яхшырак мәһәр[410] акчасы алуны гына уйлыйлар иде. Йидесуда башка мөселман йирләрендәге кеби абыстайлар да күп булмаган; менә бу сәнәдә шөкерләр улсын, кызлар тәрбиясенә дә бераз әһәмият бирелә башлады. Азлап кына булса да, кызларга махсус мәктәпләр ачыла башлады. Йидесуның мәркәзе булган Алма-Ата шәһәрендә былтыр кызлар мәктәбе ачылып, 70 ләп кыз ысулы җәдидә илә бик яхшы укыганнар иде. Быел ул мәктәп янә бераз алга басты. Былтыр анда укытучы ялгыз Гафифә ханым гына иде. Быел аның янына «Вакыт»ның 659нчы номерында[411] беркадәр тәрҗемәи хәле язылган Әшрафҗамал ханымны мөгаллимәлеккә тәгаен иттеләр. Аңлы, тәрбиянең мәгънәсен белүче, ачык фикерле Әшрафҗамал ханымның мөгаллимәлеккә керешүе безнең кызлар тәрбиясендә булган өметемезне арттыра төшәдер.

Әшрафҗамал ханым үз балаларын рус мәктәпләрендә укытдыгы өчен, халык аны яратмыйлар иде. Имде шул ук халык тарафыннан мөгаллимәлеккә кабул ителүе кызлар тәрбиясе хакында әһалинең[412] дә фикере бераз алмашынганлыгын белдерәдер. Бу мәктәптә укучылар бу елда былтыргыдан ким түгелләр, мәктәп тәртипле бара. Бу ел көз Капал шәһәрендә[413] дә бик һәйбәт

---

[405] Сәфаләт – хурлык, түбәнлек.

[406] Фәлакәт – бәла, бәхетсезлек.

[407] Семиреченск өлкәсе – Россиядәге административ берәмлек, үзәге – Верный (Алма-Ата) шәһәре.

[408] Хәйли – байтак.

[409] Мөкаддәм – элек, әүвәл.

[410] Мәһәр – калым (никах вакытында ир тарафыннан кыз ягына бирелә торган мал, акча).

[411] Фәйзрахман Җиһандаров. Хатыннар мәгыйшәтеннән // Вакыт. 1910. 24 август.

[412] Әһали – кешеләр.

[413] Капал – хәзерге Казахстанның Алма-Ата өлкәсендәге авыл, мәкалә язылган чорда өяз шәһәре.

бер кызлар мәктәбе ачылды. 60 лап кызны мөгаллим Рәхимҗан әфәнде Атнабаевның[414] әһлиясе[415] 3 сыйныфка бүлеп укыта. Мәктәп тәртипле бара. Әһали вә байлар мәктәпкә яхшы күз илә карыйлар, бу мәктәпнең бик тиз алга китүе өметле. Алтай тауларының тармаклары арасында тыныч кына яткан Лепсы[416] шәһәрендә дә, фатирда гына булса да, мөгаллим Зыятдин әфәнденең әһлиясе 15 ләп кызны яңа тәртип илә укытып тора, Мамановлар авылында да, хосусый гына булса да, 15 ләп кызлар укымакталар[417]. Пишпәк[418], Токмак[419] тарафларында да яхшы гына кыз мәктәпләре бар дия ишетелә. Менә бу мәктәпләрнең берәм-берәме тиз вакытта әллә нинди милләт аналары йитештереп бирерлек булмасалар да, бер-ике сәнәдә бу кадәр укуханәләрнең вөҗүдкә чыгуы[420] вә укучы кызларның саны көннән-көн артуы мәмнүн улмаслык[421] хәлләрдән түгелдер.

Алма-Атадан алган бер хаттан аңлашылуына караганда, анда-боннан мөкаддәм кызларны үз ризалыкларыннан башка бай сарт[422] вә картларга күп мәһәр алып озаталар вә кызлар һичвакыт боңа каршы килә алмыйлар икән. Бу соңгы елларда бу хәлләр бераз үзгәрә башлаган; кызлар аталарының биргән урыннарын үзләре яратмаса, аңа бармыйлар, үзләренә көфу[423] егетләргә аталарының ризалыгыннан башка никахланалар. Бондый вакыйгалар ялгыз Алма-Атада бу ел 4 мәртәбә булган. Боның иң соңгысы 28 октябрьдә булып, кызның аталары кыз илә аны алачак егетне полициягә алдырганнар икән. Полиция кызның егеткә барырга ризалыгын белгәч, аталарын: «Сезнең кызда эшегез юк, ул теләгәненә бара», – диеп, куып чыгарган. Ләкин кыз илә егетнең мәхәлләсендәге имам ата-ананың ризалыгыннан башка никах дөрес түгел, диеп, «фәтва[424] табып», никах укымый тора. Ахыры ни булыр инде, ләкин кыз фикереннән һичвакыт кайтачак түгел ди.

---

[414] Рәхимҗан Атнабаев – «Иж-Бубый», «Рәсүлия» мәдрәсәләре мөгаллиме.

[415] Әһлиясе – хатыны.

[416] Лепсы – хәзерге Казахстанның Алма-Ата өлкәсендәге авыл.

[417] Хәзерге Казахстанның Алма-Ата өлкәсенә караган Кара-Агач дигән урында сәүдәгәр һәм хәйрияче Маман би Калкабай улы мәктәп салдыра.

[418] Пишпәк – Кыргызстанның башкаласы Бишкек шәһәренең элеккеге исеме.

[419] Токмак – хәзерге Кыргызстандагы шәһәр.

[420] Вөҗүдкә чыгу – барлыкка килү, бар булу.

[421] Мәмнүн улу – риза булу.

[422] Сарт – Урта Азиядә яшәгән күчмә халыкларның гомуми исеме, үзбәкләр.

[423] Көфу – тиң, пар.

[424] Фәтва – нинди дә булса бер эшне эшләү, дини яктан дөресме-түгелме икәнен күрсәтеп бирү.

Нижний губернасы Сергач өязе Уразай волосте Яңа Пар карьясеннән[425] килгән бер мәктүбтә дә кызлар укыту хакында сөенечле хәбәр язылмакта улып, бондан гыйбарәттер:

«Авылымызның гына түгел, хәтта бөтен Сергач[426], Василий, Кармыш[427] нахияләрендәге[428] мөселман кардәшләремнең ирләре азмы-күпме беркадәр тәхсил[429], гыйлем илә шөгыльләнсәләр дә, хатын-кыз таифәсе[430] көлл[431] тәхсил вә тәрбиядән мәхрүм иде. Шул мөшкел хәлемезне күреп, Финляндиядә сәүдә кылучы, авылымызның күзе ачык, гыйлемгә мәхәббәте бар адәмнәремез боннан бер ел мөкаддәм кызларга хас бер зур мәктәп бина кылдылар. Ләкин мәгаттәәссеф, үткән сәнә бәгъзе бер сәбәпләргә мәбни[432] бу мәктәп ачылмады. Бу үткән көз фасылында мәзкүр[433] һиммәтле сәүдәгәрләремез бил-иттифак[434] бер җәмгыять тәшкил итеп, мәктәбемезнең мәсьүл[435] мөдирлеген авылымызның тәрәккыйпәрвәр[436] мулла Лотфулла мулла Шәрифҗан угылына тапшырдылар. Баш мөгаллимә итеп Бубыйдан Рәйхана ханым бинте[437] Габдулла Батыршинованы китереп, мөгаллимәгә могыйнәлеккә[438] Галимә Гафиятулла кызыны тәгаен итеп, бу көндә мәктәбемездә 150 кыз бала ысул саутия[439] илә гыйлем тәхсил кыйлмакталардыр. Әлхәмдүлилләһи, шул өч айның зарфында[440] мөдиремезнең гүзәл идарәсе, мөгаллимәләремезнең иҗтиһад вә тырышулары саясендә[441] киләчәктә милләт аналары булачак кыз балаларымыз дөрес язарга вә дөрес укырга, әдәп вә әхлакка үгрәнеп, бөтен әтрафымызга[442] үрнәк булып киләләр.

*«Вакыт», 1911, 20 гыйнвар.*

---

[425] Хәзер Түбән Новгород өлкәсе Кызыл Октябрь районы Актүк (Яңа Пар) авылы.
[426] Сергач – хәзер Түбән Новгород өлкәседәге шәһәр.
[427] Чувашстандагы авыл.
[428] Нахия – административ бүлек, төбәк, район.
[429] Тәхсил – гыйлем алу.
[430] Таифә – төркем, җәмәгать.
[431] Көлл – һәммә, бөтенесе.
[432] Мәбни – нигезләнгән, корылган.
[433] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.
[434] Бил-иттифакъ – сөйләшеп, үзара киңәшеп.
[435] Мәсьүл – җаваплы, соралган.
[436] Тәрәккыйпәрвәр – прогрессив.
[437] Бинт – кыз.
[438] Могыйн – ярдәмче, ярдәм итүче.
[439] Ысулы саутия – аваз ысулы.
[440] Зарф – эч, дәвам.
[441] Саясе – күләгәсе, ышыгы.
[442] Әтраф – тараф, тирә-юнь.

***Фәүзия Истанбул***[443]

## Истанбулдан мәктүб[444]

Безнең кебек ватаннарыннан ерак булганнарга ватаннарыннан хәбәр алмак нинди зур шатлыклар бәхеш итсә[445], миңа да шул шатлыкларны бәхеш итә иде; фәкать бу көнге почта исә фәүкылгадә[446] бер шатлык уларак, «Сибирия» намендәге[447] гәзитәне дә китерде.

Себердә беренче дәфга[448] уларак гәзитә чыгарырга тотындыклары өчен, мөхтәрәм мөхәррире Нәүрүзов җәнабләрене[449] вә башка иштиракь иткән[450] әфәнделәрне чын күңелемнән тәрбик итәрәк, Җәнаб Хактан муаффәкыятьләр[451] телимен.

Гәзитәне караштырдыгымда, «Хатын-кыз дөньясы» сәрләүхәсе[452] илә Фатыйма-Фәридә ханым[453] һәмширәмем[454] вә Гөлсем ханымың мәкаләләре нәзар[455] дикъкатемне җәлеп итте. Нинди бөек шатлык, безнең дөньяда барлыгымыз инкяр улынмаса да, һәнүз[456] йоклавымызда дәвам иткән без татар ханымнарының да фәрьядларымыз[457] «Сибирия» гәзитәсе аркылы бер-беремезгә ишетеләчәк.

Фатыйма-Фәридә ханым һәмширәм «Хатын-кыз дөньясы»ннан язып торачакларыны вәгъдә итәләр. Мәктәпләрдән фәлән мәхрүм диярлек булган татар ханымнарын йокыларыннан уятырга мәйданга атылдыгыңыз өчен тәшәккер итәрәк[458], армый-талмый эшләвеңезне өмет итәмен. Гафу итеңез, һәмширәм! Безнең татарларда һәммә әйбергә бердән һәвәсләнү, вә бердән

---

[443] Фәүзия Габдерәшит кызы Ибраһимова (Фәүзия Истанбул, Ф.Догрул, 1887–1985) – Берлин университетында белем алган, Казанда 1909 елда басылып чыккан «Аш остасы. Ханымнарга һәдия» китабының авторы. 1925 елдан башлап, Төркия тарихында беренче булып, «Азат Нисван» («Asar-i Nisvan») дип исемләнгән хатын-кызлар журналы чыгара.

[444] Мәктүб – хат, язылган әйбер.

[445] Бәхеш итү – бүләк итү.

[446] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

[447] Нам – исем, ат.

[448] Дәфга – тапкыр, кат.

[449] Вәгыйзь Нәүрүзов – мөгаллим, журналист, «Сибирия» газетасының рәсми мөхәррире.

[450] Иштиракь – уртак булу, катнашу.

[451] Муаффәкыять – уңыш.

[452] Сәрләүхә – исем, мәкалә исеме.

[453] Фатыйма-Фәридә Нәүрүзова (1889–1914) – мәгърифәтче, кыз балалар өчен мәктәпләр ачучы, «Сибирия» газетасының мөхәррирләреннән берсе.

[454] Һәмширә – кыз туган, кыз кардәш.

[455] Нәзар – иътибар.

[456] Һәнүз – әле дә, һаман.

[457] Фәрьяд – зарлану, ярдәм сорау.

[458] Тәшәккер итү – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.

суыну хәстәлеге[459] улдыгыннан, армый-талмый сүзен катыштырырга мәҗбүр булдым.

Мәгълүмеңез 1905–1906 сәнә тарафында бик күп татар гәзитә вә журналлары чыкты. Ул вакытларда гәзитә укырлык булмасам да, безнең татарларда гәзитәләр балага, зурга махсус дип тәфрикъ ителмәдегеннән[460], һәммәсене диярлек укый вә хатыннары имзасы илә язылган мәкаләләрне күреп, тәмам илә аңламасам да (хатын наме булу игътибары булса кирәк), бик куана идем. Мәгаттәәссеф[461], һәммәсе дә бездән юк булдылар. Ягъни суындылар.

Мәкаләңездә Себердә кызлар мәктәбе юклыгыннан, угыллары өчен мәктәп ачкан аталарымызның кызлары өчен уйлап карамаганлыкларыннан бәхәс итәсез, фәкать мин бу гаепләрнең һәммәсен дә ата-аналарга гына йөкләтми, эшләүчеләрне дә мәсьүл күрәмен[462].

Күз алдымызда булган Иркутск мәктәбенең дәвам итә алмавына матди ихтыяҗыннан дип әйтеп булмадыгы кеби, Томскида да 3–4 мөгаллимәнең һәммәсенең дә үзләре баш булу максаты берлә рәхәт тора алмый. Ниһаять, таралуы өчен дә балаларны, укытучы, ата-аналарны вә байларны гаепләп булмый дип беләмен. Раст килгән[463] бер алмачы ирләр мәктәбендә мөгаллим ула алмадыгы кеби, һәр урамда раст килгән бер хатынны, тәрбия күрмәгән бер кызны да мәктәпкә мөгаллим итәргә ярамыйдыр. Төркиядә һәммә мәктәп мәгарифтән көтелдеге кеби, бездә дә һәммә акча байлардан гына көтелү гадәт булган, урталыкта күренеклек эш булмадыгы вә ике кеше бер йиргә иттифак итеп[464], эш күрә алмадыгы хәлдә, бирүчеләрне дә гаепләп булмый, янә безнең бирүчеләремез башка милләтләрдән ким түгел (йитмәсә, акча җыеп йөрүче Громов, башкалар да аз түгел).

Бердә мәкаләңездә Европейский Россиядәге һәмширәләремездән бәхәс итәрәк, аларның гимназия вә курсларда укучы кызлары булганлыгына, хәтта берничә курсы бетергән ханымнарның да булуына шатланасыз; әлбәттә, ялңыз хатыннары яхшы тәгълим вә тәрбия күргән милләтләрнең генә алга китүләреннән вә яшәргә хаклары булдыгыннан, бу ханымнарымыз берлән никадәр ифтихар итсәк[465] тә аз (фәкать гавамның[466] файдасын төшенү игътибар илә), әмма хәзерге кеби ялңыз берничә морза вә бай кызларының үз шөһрәт вә кәефләре өчен булса, без алга түгел, кирегә китәчәкмез. Берничә морза кызының алга китүе берлән татар милләте тәрәккый итсә[467] иде. Аксаковның «Багрова внука»[468] хикәясендә караганда, без руслардан да алда булыр идек. Мәсәлән, ул вакытта русларның алга киткән хатыннарыннан

[459] Хәстә – авыру, чирле.
[460] Тәфрикъ итү – аеру, бер-береннән аерым итү.
[461] Мәгаттәәссеф –үкенечкә каршы.
[462] Мәсъүл күрү – җаваплы санау.
[463] Раст килү – очрау, туры килү.
[464] Иттифак итү – бер сүздә булу, берләшү.
[465] Ифтихар итү – мактану, горурлану.
[466] Гавам – халык.
[467] Тәрәккый итү – алга китү.
[468] С.Т.Аксаковның «Детские годы Багрова-внука» әсәре турында сүз бара.

булган, Аксаковның анасы докторлар тәклиф итдеге[469] хәлдә атка атланырга оялынган, әмма безнең морза кызларыннан һәрвакыт ат өстендә йөргәннәре бар.

Шулай ук Тәфкилевләрнең[470] кызларының да рус хатыннарыннан бик күп алда булганлыкларын вә бик күп эшләрендә рус хатыннарына үрнәк булганлыкларын рус мөхәррирләре игътираф итәләр[471]. Боннан башка тарихка мөрәҗәгать итсәк, янә һәрбер тәрәккый иткән[472] милләтләрнең гавамны уяткач кына бу дәрәҗәләренә ирешкәнлекләрен күрәмез. Шуңа күрә безнең өчен хәзергә бәләкәй шәһәрләрдә вә авылларда иттифак берлән армый-талмый тырышучылар гимназия вә курсларда укучылардан да әһәмиятлерәк дип беләмез; чөнки ибтидаи[473] тәхсил[474] күргәннән соң, аръягына үзләре үк тырмаша башлаячакларына әминмен[475].

Хәзергә «Сибирия» укучыларын шуның берлә тәгъҗиз итеп[476], мәкаләмнең дәреж улындыгы[477] мәгълүм улдыкча язып торачагымны вәгъдә итәмен.

*«Сибирия», 1912, 13 май.*

***«Таян»***

## Кызлар өчен урта мәктәп

21нче февральдә булачак Романов сөлаләсенең[478] 300 еллык юбилейсе мөнәсәбәте илә, шушы сөләләнең ядкәренә[479] төрле җәмгыятьләр төрле хәерле эшләр эшләргә тырышалар. Бу мәсьәлә, соң булса да безнең матбугатта да бераз мөзакәрә ителә[480] башлады. Мөселманнардан бу зур көннең шәрәфене[481], Казан мөселманнарының күзгә күренерлек зур бер эш эшләргә теләдекләрен Казан гәзитәләре язалар.

Табигый, мөселманнарның мәркәзе булган Казанга, бондый сирәк була торган вакыйгалардан файдаланып, милләт юлында зур бер файдалы эш эшләп калырга бик тиештер. Казанның бу эшен тәбрик итеп, коры сүз илә генә калмавын, билгеле, һәрбер гыйлем мөхибе[482] арзу итәдер[483].

---

[469] Тәклиф итү – көчләү, көчләп кушу, таләп итү.
[470] Тәфкилевләр – борынгыдан килгән татар морзалары нәселе вәкилләре.
[471] Игътираф итү – үзенең гаебен тану, кимчелеген тану.
[472] Тәрәккый иткән – алга киткән.
[473] Ибтидаи – башлангыч.
[474] Тәхсил – гыйлем алу.
[475] Әмин – тыныч, ышанычлы.
[476] Тәгъҗиз – аптырату, гаҗиз итү.
[477] Дәреж улу – теркәү, эченә салу, урнаштыру.
[478] Сөләлә – нәсел, династия.
[479] Ядкяр – истәлек.
[480] Мөзакәрә итү – фикер алышу, җыелыш.
[481] Шәрәф – кадер, хөрмәт.
[482] Мөхиб – яратучы, сөюче.
[483] Арзу итү – теләк, омтылыш.

Казан гәзитәләреннән мөхтәбәр «Кояш» гәзитәсе[484] бу мөнәсәбәт илә язган бер мәкаләсендә бу көннең ядкәренә, Казан мөселманнарына урта бер кызлар мәктәбе тәэсис итәргә[485] тиешлеген гарыз иткән[486] иде. «Кояш» гәзитәсе дарелмөгаллимин[487] вә дарелмөгаллимат[488] кебек мөәссәсатның[489] болай да тәэсис ителүе мөмкин идекен язып, тәсадефи[490] бер шундый вакыйга аркасында монтазам[491] бер кызлар мәктәбе тәэсис итүнең артыграк улачагын бәян иткән иде. Шул ук фикерне «Йолдыз» гәзитәсе да тәкъвия итәдер[492]. Минемчә, бу гәзитәләрнең бу фикерләре бик тугрыдыр. Вакыйга да бит шулай. Дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллиматлар исә, лябеддә[493] булган зарур мөәссәсаттан булдыкларыннан, милләт аларны ничек булса да тәэсис итәр, тормышның теләве буенча алар ихтыярсыз да вөҗүдкә чыгарлар[494]. Әмма прогимназия яки гимназия кебек монтазам кызлар мәктәбе алай түгел. Мөселман тормышы әле аны иң зарур нәрсәләрдән хисап итми генә түгел, бәлки аны кирәкле диеп тә белми. Шуның өчен тормышның ул мәктәпләрне көчләп вөҗүдкә китерерлек дәрәҗәгә җитүен һәм заманның мөсагадәсен[495] бик озак көтәргә тугры килер. Шуңарга күрә дә, шушындый бер вакыйга сәбәпле бондый мөәссәсатне эшләп калу иң мәгъкуль[496] бер эштер.

Әгәр Казан мөселманнары шушы эшне чынлап та вөҗүдкә чыгара калсалар, хәкыйкатән[497] үзләренең дәрәҗәләренә, Русия мөселманнары арасында тоткан вәзгыятьләренә муафыйк[498] эш эшләгән булачаклардыр. Бу эш Русия мөселманнары тормышында тарихи бер вакыйга булып, мәгариф кояшының Русия мөселманнарына да үз нурыны вә йылылыкны бирә башлаганлыгына беренче галәмәт булыр иде. Бу эшнең әһәмиятен аңласалар, Казан мөселманнары бу шәрафәтне[499] үзләренә казаныргa бөтен вөҗүдләре илә иҗтиһад итәргә[500] тиешледерләр.

---

[484] «Кояш» – 1912–1918 елларда Казан шәһәрендә чыгып килгән атналык иҗтимагый-сәяси газета. Мөхәррире һәм нашире – З.Садретдинов.

[485] Тәэсис итү – төзелү, оешу.

[486] Гарыз итү – бер эш яки хәл турында телдән сөйләп яки язып тиешле урынга аңлату, җиткерү.

[487] Дарелмөгаллимин – ир укытучылар әзерли торган махсус уку йорты.

[488] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар әзерли торган уку йорты.

[489] Мөәссәсат – биналар.

[490] Тәсадефи – очраклы.

[491] Монтазам – тәртипкә салынган, рәтле, тәртипле.

[492] Тәкъвия итү – ныгыту, куәтләндерү.

[493] Лябеддә – котылгысыз, зарур.

[494] Вөҗүдкә чыгу – барлыкка килү, бар булу, хәзер булу.

[495] Мөсагадә – мөмкинлек бирү; булышу, ярдәм итү.

[496] Мәгъкуль – урынлы, аңлаешлы, лаеклы.

[497] Хәкыйкатән – чынлыкта.

[498] Муафыйк – кирәкле, яраклы.

[499] Шәрафәт – олы дәрәҗәлелек, хөрмәтлелек.

[500] Иҗтиһад итү – тырышу.

Бу соң елларда үзләренең исемнәрене яхшы ук кына ишеттерергә муаффәкъ булган[501] Казан зыялыларына милләтнең өметләре зур булганга, бу эшнең вөҗүдкә чыгуына да ышанычы куәтледер. Өмет итәмен ки, Казан зыялылары милләтнең бу өметләрен бушка чыгармаслар, үзләренә булган ышанычны йола (оправдать итә) алырлар. Аллаһ бирсен дә, шулай булсын иде.

*«Сибирия», 1913, 18 гыйнвар.*

## [Казанда...]

Казанда мөселманнарның Романов сөляләсенең[502] өч йөз еллык юбилейлары мөнәсәбәте илә гомуми җыеннары булып, бер урта кызлар мәктәбе ачарга карар биргәннәр. Шушы эш артыннан йөрер өчен И.Алкин[503], Ибраһим Терегулов[504], Мөхәммәтҗан Сәйдәшев[505] вә Һади Максудов[506] әфәнделәрдән гыйбарәт комиссия сайлаганнар.

*«Сибирия», 1913, 20 гыйнвар.*

## Казанда Романовлар ханәданы[507] бәйрәменә ядкәр калдыру мәсьәләсе

Романовлар ханәданының 300 еллык юбилее бәйрәменә иң бөек әһәмият биргән вә моңа иң нык хәзерләнгән мөселманнар Казан шәһәре мөселманнарыдыр. Алар бу хакта берничә гомуми җыелышлар ясап, киңәш иттеләр. Казан матбугаты бу мәсьәләдән һәр көн бәхәс итеп тора. Бу бәйрәм мөнәсәбәте илә берәр хәер эш эшләү мәсьәләсе бик кызу мөзакәрә ителәдер[508]. Укучыларга мәгълүм булдыгы үзрә[509], Казан мөселманнарының бу хактагы берничә гомуми җыелышлары, бу бәйрәм ядкәренә прогимназия програмы илә низамлы[510] кызлар мәктәбе ачарга карар биргән иде. Бу карарны милли гәзитәләр вә пайтәхет[511] гәзитәләре да бик яратып язганнар иде. Ләкин моны яратмаучылар да булган. Безнең ишетүемезгә күрә, мөселман эшләрен бик хәвәс белән барлап тора торган вә гайре рәсми[512]

---

[501] Муаффәкъ булу – булдыра алу, ирешү.

[502] Сөлялә – нәсел, династия.

[503] Ильяс Сәедгәрәй улы Алкин (1895–1937) – җәмәгать эшлеклесе.

[504] Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов (1852–1921) – мәгърифәтче, КТУШ укытучысы, КУда инспектор ярдәмчесе, Мәскәү мәктәпләре инспекторы.

[505] Мөхәммәтҗан Әхмәтҗан улы Сәйдәшев (1865–1914) – Казан сәүдәгәре, эшмәкәр, хәйрияче, «Бәянелхак» газетасының нашире һәм мөхәррире.

[506] Әхмәдһади Низаметдин улы Максуди (1868–1941) – мәгърифәтче, мөгаллим, дәреслекләр авторы, «Йолдыз» газетасының мөхәррире.

[507] Ханәдан – династия, гаилә.

[508] Мөзакәрә итү – фикер алышу, җыелыш.

[509] Үзрә – буенча.

[510] Низамлы – кагыйдәгә нигезләнгән, тәртипле.

[511] Пайтәхет – башкала.

[512] Гайре рәсми – рәсми булмаган.

нөфүз[513] илә аларны үзенчә йөртергә ярата торган бер түрә, мөселманнарның урта мәктәп ачуларын бик мәгъкульләп[514] бетерми, бу урта мәктәпләрнең «ышанычлы» кешеләр йитештерүенә ышанмый икән. Аның фикеренчә, әгәр дә мөселманнар хәйрат[515] эшләргә теләсәләр, бер приют ачсалар, ярап торыр, менә Казанда һәм Уфада мөселманнарның 50–40 елдан бирле приютлары бар, болардан бер дә «ышанычсыз» кеше чыкмаган (Боларга «ышанычсыз» кеше кермәгән дә дер). Хәзердә мөселманнар үзләренең ата-бабалары эшли алган чаклы бер мөәссәсә[516] эшләсәләр, ул да аз түгел, имеш.

Шушы фикер бәян ителгәннән соң, Казан мөселманнары бу мәсьәләдә ике фиркагә[517] аерылганнар. Берсе электәгечә мөселман кызларына махсус урта мәктәп ачу тарафында. Бондай мәктәпкә шәһәр уртасында 50–40 мең сумлык йорт бирүче һәм 15 мең сум акча бирүчеләр дә табылган. Әгәр дә бондый мәктәп ачылса, Казан мөселманнарыннан тыш, читтәге мөселманнарның да иганә итүләре өметле эштер. Казан мөселманнарының зыялы вә тәррәкыйпәрвәр кыйсеме ошбу фикергә кушыла, «Кояш» гәзитәсе вә «Аң» журналы[518] ошбу фикерне яклыйлар.

Икенче фирка түрә фикерен, приют ачуны муафыйк күрәләр[519]. Имамнарның күбрәге ошбу тарафта, «Йолдыз» гәзитәсендә язучылар (шул ук муллалар) ошбу фикерне яклыйлар.

Янә өченче бер фирка һөнәр мәктәбе ачуны кирәксенәләр. Яшь сәүдәгәрләр вә приказчикларның, вә хезмәт кешеләренең ошбу фикердә булулары аңлашыладыр.

Мәсьәләгә гыйнвар 28ндә биржа залында булачак гомуми җыелышта карар биреләчәктер. Бу гомуми җыелышка Казанның һәрбер мәхәлләсеннән вәкилләр вә башка мөнасиб[520] кешеләр чакырылачак. Бу мәҗлесне ясау өчен 10 кешедән гыйбарәт бер комиссия сайланган. Комиссия әгъзаларының 6 сы хәзрәтләр, 2се гәзитәчеләр, 2се сәүдәгәр хаҗилар.

Кызлар өчен урта мәктәп, кыз балалар приюты, һөнәр мәктәбе булыр әлбәттә, һәммәсе кирәк. Казанда һәркаюсына ихтыяҗ бар. Бу өч мөәссәсәдән каюсын кирәксенүчеләр, каюсының кирәклеген бигрәк белүчеләр гыйнвар 28 җыелышында күпчелек булсалар, шуларның максудынча карар бирелер. Каю сыйныф халкы бу мәҗлескә күбрәк чакырылса, шулар күпчелек тәшкил итәчәк булганга, комиссия әгъзаларының күпчелегенә карап, андагы җыелышның карарын да хәзер ук чамаларга мөмкиндер.

*«Вакыт», 1913, 26 гыйнвар.*

---

[513] Нөфүз – игътибарлылык.

[514] Мәгъкуль – урынлы.

[515] Хәйрат – изге эшләр, яхшылыклар.

[516] Мөәссәсә – оешма, учреждение.

[517] Фирка – төркем.

[518] «Аң» – 1912–1918 елларда Казанда нәшер ителгән фәнни-әдәби, иҗтимагый-сәяси журнал. Нашире һәм мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәни.

[519] Муафыйк күрү – яраклы, тиеш дип табу.

[520] Мөнасиб – яраклы, туры килгән, мөнәсәбәте булган.

**[Өч йөз еллык юбилей мөнәсәбәте илә…]**

Өч йөз еллык юбилей мөнәсәбәте илә Казан мөселманнары бик озак кычкырышканнан соң, бер кызлар гимназиясе һәм аның янында ятимәләр приюты ачарга карар биргәннәр.

*«Сибирия», 1913, 6 февраль.*

***Гомдә***

**Казанда кызлар игъдадиясе[521] һәм приюты**

Соңгы елларда Казан мөселманлык ноктаи назарыннан[522] караганда бөтенләй күздән төшеп бара иде. Ачык фикерле, арыслан йөрәкле мөгаллим вә муллалар йитештерә торган мәдрәсәләрнең суынуы, алар урынына башкача һичбер төрле мөәссәсәләрнең[523] ясалмавы, җәмгыятьләрнең дә күзгә күренерлек эшләр эшли алмавы Казан мөселманнарында рух сүнә башлаганын вә Казанның элек тоткан урынын ташлап, түбән дәрәҗәгә төшә башлаганыны күрсәтәләр иде.

Хосусән[524] Дума сайлаулары вакытында Казан гәзитәләренең фикерләрене төрле йиргә таратканлыкларын күргәч, иске юнаниларның[525] соңгы бетәргә хәзерләнгән вакытлары искә төшеп, Казан мөселманнарының да бу юлга керүенә күңелләр бик кайгыра башлаган иде.

Соңгы көннәрдә юбилей мөнәсәбәте илә һәр йирдә әүвәлдәге кеби Казан гәзитәләрендә дә юбилей бәйрәме тугрысында сүзләр күренгәли башлады. Яңа чыккан «Кояш» гәзитәсе аңлы зыялыларның юбилей хөрмәтенә «Кызлар өчен прогимназия» ачарга теләгәнлекләрен язгач, Казанның тагын бер күтәрелеп карарга теләвенә шатлансак та, соңгы вакытларда Казан мөселманнарының иттифакка[526] килә алмауларыны күреп өйрәнгәнгә, күңел ышанып бетмәде. Өстәвенә икенче почта юбилей хөрмәтенә казанлыларның гимназия ачмыйча, приют ачып кына калырга теләүчеләре барлыгын китергәч, вә «Йолдыз» гәзитәсенең дә гадәте буенча кире якка сукалый башлаганыны күргәч, күз тотып торган Казанымыздан иң соңгы өметемезне дә өзгән идек. Юбилей комиссиясендә күбрәк приютчылар – муллалар керүе бу фикерне тагын ныграк куәтли иде.

Шулай өметне өзеп, икенче кат Казанга бер мәртәбә дә өмет күзе илә карамаска торган вакытта, Казан гәзитәләре кызлар гимназиясе ачарга карар бирү хәбәрен китерделәр. Йитмәсә, казаннар бер урынына икене ачарга карар

[521] Игъдадия – мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү сыйныфлары.
[522] Ноктаи назар – караш, берәр нәрсәгә караш.
[523] Мөәссәсә – оешма, учреждение.
[524] Хосусән – бигрәк тә, аеруча.
[525] Юнанилар – греклар.
[526] Иттифак – бер сүздә булу, союз.

биргәннәр: ягъни кызлар өчен урта мәктәп тә, тәрбиясез кызлар өчен приют та ачылачак булган. Зур шатлык, Аллаһ муаффәкыять[527] бирсен.

Әгәр приютны да кызлар мәктәбе янына куеп, приюттагы кызларга урта мәктәп тәрбиясе дә бирсәләр, Казан мөселманнарына мөселманнар эчендә тагын да зуррак урын тотарга насыйп булыр иде. Шулай да бу эшләре зур муаффәкыять, боның белән казанлылар үзләренең алдагы көнгә ышанычлы күз илә карый башлаганлыкларын күрсәттеләр. Бу эшләре илә үзләрен тәбрик итәмез. Бондан соң Казан үзенең дәрәҗәсен белер, әлегәчә булган иттифаксызлыкларыны ташлап, дөньяда торырга теләгән халыклар төсле эш күрә башлар, диеп өмет итәмез. Гәзитәләр дә шаять бондый гомуми мәсьәләләрдә шәхсыятьне[528] ташлап, гомумнең күзе илә карый башларлар диеп уйлыймыз.

Гомумнең карарыннан, соңгы номерында «Йолдыз» гәзитәсе: «Каюсына акча күбрәк җыела, шунысы тиз ачылачак. Әгәр дә бер мөәссәсәнең[529] акчасы ул мөәссәсәне ачарга йитмәслек булса, анысы тәэсис кылынмый[530] калачак», – диеп, күңелгә бер шөбһә салып куя. Бондан соң да бу юлында дәвам итсә, бу гәзитә Казанны батырырга тырышучыларның бик зур кирәклесе булып чыгачактыр.

*«Сибирия», 1913, 6 февраль.*

***Ләбиб Саинов***

**Хатын-кыз кардәшләремезгә**

Бу елларда милләтнең яртысы булган хатын-кыз кардәшләремезнең алга омтылганлыклары вә чын матурлык берлә ясануны гыйлем нурында күрә башлаганлыклары күпләремезгә билгеле инде. Бу үзгәрешләр милләтнең киләчәге өчен бик зур хәерле фалдыр[531]. Фәкать, яңа алга атлау заманнары никадәр күңелле вә күркәм булса, аның кыенлыгы вә мәшәкате дә шулкадәр күп вә газаплы булачагы шөбһәсездер. Бигрәк тә хатыннарга, чөнки эш эшләргә юклыгы, Ходай кушып, кешесе чыгып куйса да, акча табылмавы, һәр икесе булса да, шәригать исеме берлә бәгъзе бер ерткыч вә күңеле бозык дин башлыкларымызның бутавы сәбәпле, үз халкымыз тарафыннан ясалган манигъларның[532] юлга аркылы төшүе вә һич булмаганда хөкүмәт ягыннан бер келтифун чыгып, юлны бөтенләй киртәләп куюы – бар да шул яңа тәрәккый[533] юлында сәфәр кылучыларга карышу өчен кырылган авырлык вә газапларның зурларыннан инде. Бигрәк тә бу газапларның иң авырлары берлә һәрвакыт җәфаланучылар, шул бичара хатын-кызларымыз, сөекле сеңелләре-

[527] Муаффәкыять – уңыш.
[528] Шәхсыять – шәхсилек.
[529] Мөәссәсә – оешма.
[530] Тәэсис кылу – төзү, оештыру.
[531] Фал – бәхет, яхшы киләчәк, хәерлелек.
[532] Манигъ – киртә.
[533] Тәрәккый – прогресс, алга бару.

мез вә шәфкатьле аналарымыздыр. Ләкин милләт эше мөкаддәс[534] бер хезмәт булганлыктан, ул юлда күрелгән бөтен мәшәкать вә барча авырлыклар берәр ләззәт кенә булып хәтерләнәчәге шикелле, тарих яфракларында да бик матур берәр бизәк булып кына күренәчәгеннән, ул манигълар милләт эше берлә шөгыльләнүчеләрне бер вакытта да талыктырмаска вә гайрәтләрен сүндермәскә тиеш. Бәлки шул мөкаддәс юлда никадәр күп авырлык вә никадәр зур мәшәкатьләр булса, тырышучының гайрәте дә шулкадәр артачак вә шулкадәр зур арзу[535] вә җан теләге берлә алга омтылу фикере көчәячәктер. Бу хезмәттә максатка барып ирешү өчен беренче шарт – читтән ярдәм көтми вә арка таянычы эзләмичә, үз гайрәтеңә таянып, ялгыз үз җенесеңнән ярдәм өмет итү берлә генә чикләнүдер.

Менә шул вакытта гына чын тырышулар зур файдалар бирәчәк вә бөтен мәгънәсе берлә тәрәккый баскычының югарысына чыгу мөмкин булачактыр; чөнки адәмнәрне кешелек дәрәҗәсенә күтәргән – үз-үзенә ышану вә үз көченә таяну гынадыр. Тартыш дөньясына сызганып чыккан гайрәтле бикә вә туташларымыз да шул рәвешле хәрәкәт итүне һичбер вакыт онытмаска кирәк. Дөрестән әйткәндә, минем бөтен язганнарым хатын-кыз иптәшләремә карап сөйләнәдер.

Менә хәзер безнең татар милләте дә шул тәрәккый юлына кергән бер юлчыдыр; ләкин әлегә кадәр үземезне вә үзлегемезне яхшы танып йитмәгәнгә күрә, һаман да үз-үземезгә ышана вә үз көчемезгә таяна алмаганлыктан, өмет ителгән кадәр тизлек берлә тәрәккый итә алмыймыз. Чөнки бездә әүвәл үзлегемез диярлек бернәрсә юк. Үзлеге булмаган бер милләт ничек үз-үзенә таянсын! Бер милләт, яртысы ирләр, яртысы хатыннар булган ике җенеснең берләшүеннән хасыйл булгач, аның үзлеге дә шул берләшкән үзлек булырга кирәк. Хәлбуки[536], бездә әлегә кадәр чәбәләнүләр ирләрдә генә иде, бу тәрәккый никадәр шау-шулы булып уртада күренсә дә, чын тәрәккый түгел, бәлки ярты гына, ялган гына вә саф башкаларга иярү генәдер.

Бездәге бөтен хәрәкәтләрнең дүрттән өч өлешеннән дә күбрәге читтән күчереп эшләү өчен чыннан күреп кылану гынадыр. Безнең арабызда чын мәгънәсе берлә эшкә бирелгән «идеалист» кешеләремез юк дәрәҗәсендә дисәм, бер өч-дүрт кеше хәтере өчен генә әйтәм, юкса чынлап та чын кешеләремез һич юктыр. Моның сәбәбе бик ачык, бу шулай булмый мөмкин түгел. Чөнки безнең беребезгә дә аналарымызның җылы куенында «заман», «милләт» дигән зур мәгънәле бер сүзне, татлы күкрәк сөтенә катыштырып имәргә насыйп булмаган, аналарымызның шәфкатьле кочагында вакыт кайнар аналар мәхәббәте берлә гомер буена онытмасын өчен, алардан ишетеп инанганымыз, беренче төпле игътикадларымыз[537] өчен дә, милләт мәхәббәте вә милләткә хезмәтнең мөкаддәслеге, игътикады бәлки һичберемезгә урнаштырылмаган. Чөнки андый аналардан әлегә кадәр безнең милләт

[534] Мөкаддәс – изге, иң мөһим.
[535] Арзу – теләк, омтылыш.
[536] Хәлбуки – ләкин.
[537] Игътикад – чын күңелдән ышану, инану.

мәхрүм иде дисәм, бик ялгышмам дип уйлыйм. Шуның өчен дә безнең эшләгән эшләребезнең күбесе рия[538] гына, беребезгә күрсәткән мәхәббәтләремез ялган гына, вә бөтен мәдәниятемез вә тәрәккыемыз буяу гына, тагы да халык теле берләрәк әйтсәм, тыштан салган ямау гына!

Бездәге чын эшләр, чын мәхәббәт вә чын тәрәккыйлар бар эшләремезне хатыннар вә туташларымызның кул берлеге берлә эшләгәндә генә булачактыр! Хәтта алай гына да түгел, бонларның һәммәсенең нигез ташын хатыннар салганда гына булачактыр! Вә шул вакытта гына безнең арамызда мөкаддәс фикер иясе вә чын эшлекле кешеләремез төркем-төркем мәйданга чыгачактыр.

Боны аңлаган кешеләр бездә бәлки бик күптер, ләкин бу хакта хатыннарымызга юл күрсәтүче вә йитәкче булучыларымыз, бик кызганыч, һич юктыр. Чөнки әлегә бер сүз, һич беребездә ана кочагында тәрбияләнгән җан вә йөрәк юк! Әдәбият дөньясына хатын-кыз хәленнән кемнәр генә аңлаганы һәркемгә билгеле булганлыктан, аннан күчеп гәзитә дөньясына карасак, хатын-кыз файдасынаниләр генә күрә алырмыз? Һич, һич вә һич...! Әгәр без үз хәлемезне белгән булсак, хатын-кызларымызның күргән вәхшәтләрен сизә алсак, аларның ай-вайларын тиешлечә аңлый белсәк, канлы Балкан золымнарын чынлап укый вә ишетә алмас, вә аларны өстән генә карап кичәр идек. Шулай булса да, безнең гәзитәләрнең иң зурлары да хатын-кыз дөньясында чыккан бик аяныч вә бик чеберчекле булган зур эшләрне белә, гәзитә алучыларның күңеленә охшарлык итеп тапканда, бер хәбәр итеп кенә язып куйгалыйлар, юкса гәзитәдә урын калмый. Хәлбуки, бәгъзе берәүләрнең атка атланып чапканын, автомобильгә утырып йөргәнен вә бер шәһәрдән икенче шәһәргә сәфәр кылганын гүя бик кирәкле бернәрсә шикелле иттереп бөтен дөньяга белдерүгә ничек тә булса гәзитәдә бер урын калдырырга уңганлык күрсәтәләр.

Гәзитәләрдән ялгыз «Сибирия» «Хатын-кыз дөньясы» дип аеры бер урын ачып, хатын-кызларымыз өчен салган «Сибирия»дә җылы кочак ачып, шәфкать колачын җәйгән иде. Менә хәзер шул «Сибирия»нең хатын-кызларымызның яхшы ук җанлы бер йиренә, Уфага килеп «Тормыш» исеме берлә чыкканын, тагы да җылырак урынга күчеп, бигрәк кайнар мәхәббәт берлә хатын-кыз иптәшләремезгә якты чырай күрсәткәнен күрәмез. Боны, әлбәттә, һәммәбездән әүвәл гайрәтле туташларымыз күреп тәкъдир итәчәкләр[539] вә чиксез зур сөенеч берлә үз хәлләреннән язып, шул бүлекне төрле куллар берлә чуарлаячаклар! Хатын-кыз дөньясы әлегә кадәр бер хисханә булганлыктан, серләре пәрдәле бер яшерен дөнья иде. Бигрәк тә аларга бик түбән карарга өйрәнгән безнең халык өчен бу дөньяның кирәкләрен вә мохтаҗлыгын белү бик кыен бер мәсьәлә булачак. Шуның өчен бу яшерен дөньяның мохбирләре дә мотлакан[540] туташларымыз үзләре булырга кирәк. Үзләренең гыйлем нуры берлә бизәнеп, чын матур милләт аналары булулары

[538] Рия – бер эшне кешегә күрсәтү өчен генә эшләү, икейөзлелек.
[539] Тәкъдир итү – бәя бирү; ихтимал, очрак.
[540] Мотлакан – шиксез, һичнигә карамастан.

өчен ни төсле ашыгычлык берлә җан атып алга омтылганлыкларын, үзләренең шул мөкаддәс хезмәтләренә аркылы төшкән манигъларының бигрәк ниләр булганын вә нинди ачы газаплар чыкканлыкларын үзләре сизгәнчә, үзләре тапкан иң әйбәт вә иң утлы сүзләре берлә тәмам йөрәккә эшләрлек итеп төзегән язулары берлә гәзитә яфракларын бизәсәләр, никадәр чибәр вә никадәр файдалы булыр иде. Үз файдагыз өчен үзегез тартышып, үз көчегезне түксәңез вә үз хакларыгыз өчен үзегез тырышсаңыз гына, милләтне вә үзегезне бәхетле итә алырсыз, туташлар! Бу вакытка кадәр сезне яшерен дөньяда калуга мәҗбүр иткән ирләргә бераз гына ышанычсыз карасагыз да, без, ирләргә, бик күп җәбер иткән булмассыз, чөнки киләчәге беремез өчен дә бик файдалы булачактыр. Шуны да әйтергә онытмыйм әле: «Сибирия» һәм «Тормыш» гәзитәләренең хатын-кызларга бик якты йөз күрсәтүе дә ирләр тарафыннан ясалган бер мәрхәмәт түгел бит! Ул гәзитәләрдә иң зур хезмәтне өстенә алган гайрәт ияләренең берничәсе, шул яшерен дөньядан яктылыкка чыккан вә хатын-кыз дөньясын үтәдән-үтә күреп белә торган чын бер милләт анасыдыр. Шуның өчен бу зур форсатны һәр яшь фикерле хатын-кыз туганнарымыз бик ганимәт[541] булып, үз хәлләреннән ухрып язган кайнар мәкаләләре берлә «Тормыш» аркылы гәзитә дөньясын яңгыратуны һичбер заман онытмаска тиешлеләр.

Әйдәгез, гайрәтле туташлар! «Тормыш»ны тормышның вә тормышымыз өчен бер зур терәк ясарга һиммәт итегез[542]!

Ләбиб Саинов

1913 октябрь 6сы. Петербург.

*«Тормыш», 1913, 18 октябрь.*

***Сания Гыйффәт Кадыйрия***[543]

### Мәктәпләремез тирәсендә

Мәктәп исеме бирелгән, мәктәп исеме илә йөртелә торган урыннар, әлбәттә, бер әмәлгә, идеягә хезмәт итәргә тиешләр.

Әгәр бер мәктәп бер әмәлгә хезмәт итмәсә, аны мәктәп дияргә дә ярамый. Әмәлсез кешедән милләт өчен файдалы нәрсә өмет итәрлек булмаган шикелле, бер идеягә хезмәт итмәгән мәктәптән дә идея иясе кешеләр чыгуы мөмкин түгелдер.

Рус я башка милләт мәктәпләрендә бер идея күзәтелгәнлектән, аннан укып чыгучылар да әмәл иясе булып, тормышта туры киләчәк уңайсызлыкларны, кара көннәрне җиңеллек белән үткәрерлек бер куәткә ия булганнары хәлдә, чиксез гайрәт вә осталык белән тормыш мәйданына атылалар да, судагы балык төсле җиңел вә тыныч кына йөзә башлыйлар.

Бу, шиксез, мәктәпләренең биргән бәхетедер.

---

[541] Ганимәт – уңыш, бәхет.

[542] Һиммәт итү – тырышу.

[543] Сания Хәбирҗан кызы Кадыйрова (Гыйффәт, 1899–1957) – шагыйрә, мөгаллимә, дәреслек һәм тәрбиягә багышланган мәкаләләр авторы.

Башка милләтләрнең шундый тыныч кына тормышларын, һәр нәрсәгә курыкмыйча, булдырырлык булып карауларын күргән вакытта күңелгә: «Безнең ник түбән соң?» – дигән сөаль килә. Чынлап та, безнең кыз, хатын өчен төзелгән мәктәпләремез нинди идеягә хезмәт итәләр? Кыз, хатын мәктәпләреннән күзәтелгән максат – иҗтимагый-әхлакый тәрбия күргән милләт аналары йитештерү булса кирәк. Мәктәпләр шул максатка хезмәт итсен өчен, укытучылар үзләре чын гыйлем белән нурланган, әхлакый, иҗтимагый тәрбияләрдән кирәгенчә өлешләнгән булулары матлуб булганлыктан[544], бездә андый сыйфатлар табылган укытучылар юк дәрәҗәсендә аз икәнлеген яшереп торырга да урын күренми. Шундый укытучыларымыз, мөгаллимәләремез булса, мәктәпләремездә укып чыккан кыз, хатыннарымыз да башка милләтләрнеке төсле һәрнәрсәгә куркусыз караучы бер әмәл иясе булырлар иде.

Бар нәрсә яхшыланыр, китек урыннар тулыр иде.

Менә мондый әмәлле аналар йитештерер өчен мәктәпләрнең заманага, мохиткә муафыйк[545] булуы тиеш. Анда шулай укытылсын ки, кяинат[546] караганда бер фикер, милләтләр хәленә караганда бер аң, тормышка караганда һәрнәрсәсеннән бер файда алырлык булсын. Мәктәптән алган гыйлемнәре, фикерләре, һөнәрләре белән егерменче гасырда үзләрен яшәтерлек булсын. Суык канлы, авырлыкларга чыдамлы, эш сөюче, батыр булсын. Тәәссеф[547]! Безнең мәктәпләр бик сай шул. Фән дәресләрен әйтмим дә. Иң күздә тотып укытыла торган дин дәресләремездән дә кирәкле нәрсәләр сеңешле, җиңел итеп белдерелми. Бер нәрсәмездә илаһи яки милли бер хис бирми. Җәгърафияләр күп йирдә хәритасыз[548] укылганлыгы шикелле, шигырь кеби нечкә фәннәремезнең дә нечкә тойгылары, гали хисләре тупас итеп, бар куәткә кычкыру эчендә белемсез хәлдә кала. Ул гына түгел, башка нәфис нәрсәләремез дә бер файдага ашмыйча, югала гына бара.

Хатын-кызларымызның болай аңсыз, белемсез хәлдә калуларына гаепле кешеләр милләтемезнең ирләре дияргә туры килә. Ирләремезнең фикерсез калуларына, әлбәттә, надан руханиларымыз сәбәпче.

Наданлыклары диннең дөреслеген күрсәтмәслек бер хәлдә булганлыктан, безне егерменче гасырда да арынып йитә алмаслык кылып, әллә нинди ялган игътикадлар[549] вә истибдадлар[550] астына батырганнар. Начар-яхшы булсын, бер нәрсә гадәт булып әверелсә, аны тиз генә бетерү, түбәннән кырып ташлау мөмкин булмаганлыктан, иске, надан дин башлыкларымызның корган тозакларын да әле һаман бетерә алмыйбыз. Шулар тәэсире сәбәпле, башкалар

---

[544] Матлуб булу – таләп ителү, эзләнү.
[545] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[546] Кяинат – бөтен яратылыш, бөтен дөнья.
[547] Тәәссеф – кайгыру, ачыну.
[548] Хәрита – географик карта.
[549] Игътикад – ышану, инану.
[550] Истибдад – деспотизм.

чакрымнар белән алга китеп торганда, без һаман аптырауда, һаман наданлык, ялкаулык эзләү астында кая китәргә белми шашкан, исергән хәлдәмез.

Бу чуалчык, тәртипсез тормыштан безне кемнәр өстерәп чыгарырлар соң? Менә инде мин бу сөальләргә үземне-үзем генә диясем килә. Безнең арамызда аңлы, фикерле ханымнар юк ук түгел бит. Кайсымыз гакыл, фикер, каләм белән, кайсымыз мал вә акча белән ярдәм итеп, безгә каршы булган коймаларга карамыйча, ватып, сындырып, башкалар артыннан җитәргә тырышу вә минутны бушка уздырмыйча ашыгудыр.

Безгә бигрәк хөкүмәттән рөхсәт илә җәмгыять хәйрияләр торгызып, эш башына мөмкин кадәр аңлырак, мәктәп эшләре белә танышрак ханымнарны менгезергә вә алар аркылы мәктәпләремезнең тәртипләнүенә, аннан укып чыккан кызларның бер әмәл иясе, ачык фикерле, ысул тәгълимнән[551] хәбәрдар булучылыгына тырышырга кирәк. Шәһәрләр генә җитми, авылларга да тәэсир итәргә, авылдагы кардәшләремезне дә истән чыгармаска кирәк. Авыл халыклары мөгаллимәне шәһәрләрдән сорыйлар, яхшырак тәхсил күргән[552], тагы да аңлырак мөгаллимәләрне йибәрергә тырышу – халкымызны агарту вә аңлау килүгә хезмәт итү өчен беренче шарттыр. Арамызда җитди, эш сөюче ханымнар бармак белән генә санарлык булып, күбесе үзләрен халыкка күрсәтү, шөһрәт казану өчен генә тырышалар. Рус гимназияләре бетергән ханымнарымыз вә башка сурәттә гыйлем вә тәрбия җәһәтеннән алда саналган бикәләремез булса да, аларның күбесе никтер милли эшләргә суык (хәтта үзләренә башка милләт кешеләре тарафыннан «татарка» диеп әйттерүгә хурланалар. Ә башкалар, киресенчә, нинди милләткә мөнасыйб[553] булсалар, шуның белән мактаналар), җиң сызганып хезмәт итәчәк урыннарда читтән көлеп кенә карап, үзләренең кәеф-сафаларына бирелеп калалар.

Бу рәвештә кайсымыз хурланып, кайсымыз зурланып, милли эшләрдән кул селтәп читтә торсак, тормышымыз һаман иске булып, үземез һаман надан, аңсыз, фикерсез «татарка» булырмыз шул. «Татар, татарка» исемен ишеткәндә хурланасымыз килмәсә, зурланырлык булганга кадәр милләтемезне күтәрик, югарылатыйк. Аның бердәнбер чарасы шул гына.

Хәзер хурлана-хурлана тырышсак, киләчәктә, иншаллаһ, мактана-мактана яшәрмез дә...

*«Тормыш», 1913, 27 октябрь.*

---

[551] Ысулы тәгълим – методика.
[552] Тәхсил күрү – гыйлем алу.
[553] Мөнасыйб – яраклы, туры килә торган.

***Фәрхинас Басыйрия***

**[Хатын-кыз галәменә...]**

Хатын-кыз галәменә гаять тә әһәмият биргән газетаңызны чын күңелемнән тәбрик итәм. Хисапсыз күп сәнәләр дәвамын теләп калам.

Түбәндә язган мәкаләмне «Хатын-кыз галәме»нә басуыңызны үтенәм.

«Тормыш» гәзитәсенең икенче номерында Петропавелда ирләргә махсус булган китапханәгә кызларга йөреп файдаланыр өчен һәфтәдә[554] ике көн ялңыз кызларга бирелгәнлеген, шул көннәрдә китапханәгә хатын-кызлар 50–60 лап килгәннәрен аңлаткан хәбәр[555] минем дикъкатемне җәлеп кылганлыктан, түбәндәге сүзләрне язарга мәҗбүр булдым.

Безнең Касыйм шәһәрендә җәмгыять хәйриянең, бик зур булмаса да, ярыйсы гына бер китапханәсе булып, Русиядә мәшһүр булган русча-татарча гәзитәләр вә журналларның һәркаюсы мәртәбә килеп торадыр. Китапханәнең һиммәтле [556] әгъзалары бер-ике аңлы ханымнарымызның соравы буенча һәфтәдән бер көнне ялгыз хатын-кызларга билгеләгәннәр иде. Асылымыз биттә, киемдә, дип белгән безнең ханымнар боңардан аз файдаланалар. Рәхәтләнә-рәхәтләнә, шатлана-шатлана килеп, бер һәфтәлек[557] матбугат галәменнән төрле-төрле хәбәрләрне укып китүгә бик аз әһәмият бирәләр.

Касыйм шәһәрендә ике мең кадәр мөселман бар. Билгеле, шуларның яртысы хатын-кызлардыр. Ысул җәдидәнең чыккан елларында ук Касыймда хатын-кызларга яңа рәвештә укыту башланган. Шул сәбәптән, Касыйм хатын-кызларының һәммәсе диярлек үз ана телләрендә яхшы гына яза беләләр. Менә шулай укый-яза белә торып та, китапханәгә 5–6, иң күп булганда 8–9 ханым йөриләр. Менә бу күңелсез рәкымнәр[558] безнең хатын-кызларыбызның укуга булган рәгъбәтсезлекләрен[559] күрсәтәдер. Әгәр дә хатын-кызлар күбрәк йөрсәләр, һәфтәдән берничә көнне яки һәр көннән берничә сәгатьне хатын-кызларга аеруны сорарга мөмкин иде. Ни өчен соң безнең хатын-кызлар укуга болай рәгъбәтсез? Матбугаттан ләззәтләнмиләр? Гәзитәләр, журналлар укырга, аңларга икътидарлары[560] булса да, укымыйлар? Укырга да теләмиләр? Минем боларга: «Мәктәпләрдә кызларымызны укуга рәгъбәтле итеп тәрбия итә алмавымыз», – дип җавап бирәсем киләдер. Әгәр дә мөгаллимәләремез мәктәпләрендә кечкенә генә булса да китапханәләр ясап, шул китапханәләрдә файдалы, укырга күңелле рисаләләр[561] булдырсалар, буш вакытларда, я махсус уку вакытлары ясап, шәкертләргә гәзитәләр, журналлар укысалар, шәкертләрдән укытсалар, ни язылганын сөйләп

---

[554] Һәфтә – атна.
[555] Петропавел хәбәрләре // Тормыш. 1913. 27 октябрь.
[556] Һиммәтле – тырыш.
[557] Һәфтә – атна.
[558] Рәкым – цифра.
[559] Рәгъбәт – омтылыш.
[560] Икътидар – булдыра алу, көч җитү.
[561] Рисалә – хат, мәкалә, брошюра.

аңлатсалар, әлбәттә, күп файдасы тияр, хатын-кызларымызның матбугаттан ләззәт табып, матбугат илә шөгыльләнүләренә сәбәп булыр иде.

Безнең Касыйм хатын-кызлары мода җәһәтеннән рус ханымнарыннан ничә вә ничә дәрәҗә артык кылансалар да, гыйлем җәһәтеннән, уку җәһәтеннән алар янында ля шәй[562], җанлы курчаклар булып калалар.

Хатын-кызлары тәрбияле булган милләтнең генә йир йөзендә яшәячәген хатын-кызларымызга аңларга кирәк. Киемнәр, зиннәтләр илә күп булышмаенча, күбрәк уку берлән шөгыльләнергә, тышларын бизәү урынына, эчләрен, рухларын гыйлем-мәгърифәт илә бизәргә вакыт җитте...

Касыймлы Фәрхинас Басыйрия

*«Тормыш», 1913, 20 ноябрь.*

***Өммегөлсем Терешкавия***[563]

## Безнең хәл

Шушы көннәрдә «Сөембикә» журналы укып, гаять тә шатландым. Әлхәмдүлилләһи, без татар хатын-кызларының хәлен аңлаган ирләр дә күренә башладылар. Моның өчен һәр татар хатыны вә һәр татар кызы куанырга тиеш! Чөнки мондый ирләр күбәю белән мөтәгассыйб[564] аталарының кулында изелгән мискинә[565] кызлар, рәхимсез йөрәкле ирләренең камчылары астында тапталган хатыннар, акрын-акрын гына башларын күтәреп, нурлы, ямьле, гүзәл дөньяга чыга ала башлаячаклар.

Мондый журнал чыгарып, без хатын-кызны «наданлык йокысыннан» уятырга тырышкан мөхтәрәм мөхәррир әфәндегә бөтен милләт вә бөтен татар хатын-кызлары галәме исеменнән тәшәккер итәм[566]! Яшәңез, мөхәррир әфәнде! Яшәсен «Сөембикә» ханым! Яшик алар белән бергә үк без – татар хатын-кызлары! Шул яшәгәнлегебезне бөтен дөньяга белдертер, җанлы икәнлегебезне аңлатыр өчен, курыкмастан, өрекмәстән, фикерләребезне ирләргә сөйлик, йөрәгебезне әрнеткән кайгыларыбызны «Сөембикә» ханымның бәгъренә куйыйк!.. Йитәр!.. Моңар тикле без күп изелдек! Инде моннан соң караңгы йир астыннан якты дөньяга чыккан язгы матур чәчәкләр шикелле, без дә, әби-бабалар бөркәнгән «җаһәләт чапаны» астыннан нурлы «мәгърифәт галәменә» чыгыйк!! Үземезне дөньяга танытыйк!

Ханымнар! Каюыңызга да мәгълүмдер: без дә, ирләр шикелле адәм балалары. Без дә, алар шикелле, Аллаһы коллары. Ләкин без үземезнең кем икәнлегемезне аңламау сәбәпле, ирләремезгә кол булып беткәнмез. Аларны үземезгә хуҗа иткәнбез. Алар нинди генә пычраклык кылсалар да, «ирләр

---

[562] Ля шәй – бер ни түгел, әһәмиятсез.

[563] Терешкавия Өммегөлсем – мәгърифәтче, мөгаллимә, тәрбия темасына багышланган мәкаләләр авторы.

[564] Мөтәгассыйб – фанатик.

[565] Мискинә – ярдәмчесе булмаган, мескен.

[566] Тәшәккер итү – рәхмәт белдерү.

тиешсезгә бер эш тә эшләмиләр» дип, уйларлык кызганыч хәлгә килеп төшкәнбез. Боларның барчасы өчен дә, югарыда әйткәнемчә, үземез генә гаепле. Чөнки без – «озын чәчләр», «кыска гакыллар», «ир хакы – Аллаһы хакы», «ир хакы – Пәйгамбәр хакы» дип, ирләремезгә артыграк башымызны иеп, аларның аяклары астында, фил аягы астында изелгән тычкан шикелле, изелеп калганбыз. Үз хәлемезне үземез бу чиккә китереп терәткәч, ирләремезнең безне кыйнаулары, безне «озын чәчләр», «кыска гакыллар» диюләре табигый бер эшдер.

Без – татар хатын-кызларыны кыйнау кемнән калды икән? Әллә кайчаннан бирле шушы сөаль мине өзәдер. Әмма борынгы әбиләремезнең башына мондый сөальләр бер дә килмәгән. Чөнки алар үзләренең ирләре тарафыннан кыйналулары «тиеш бер эш» кенә диеп иман китергәннәр.

Аларның бу иманнарының раст икәнлеген исбат итәргә теләгән төсле, бабаларымыз кыш көннәрендә аларны чана тәртәсенә бәйләп ярганнар. Аннан шуның белән генә канәгатьләнми, өйгә алып кереп, эскәмиягә салып бәйләп камчылары тузганчы аларның аркаларын телгәләгәннәр... Ярабби! Ярабби! Бу нинди ерткычлык! Бу нинди шәфкатьсезлек тә, бу нинди вөҗдансызлык!!! Аллаһ аларны ник бу тикле шәфкатьсез итеп яраткан икән? Бу тикле таш йөрәкле булгач, ник ул аларны дүрт аяклы ерткычлар гына итеп яратмый, адәм сурәтле җанварлар итеп яраткан да, хатыннарга ирекле кылган икән?!

Бичара татар кызы ундүрт яшькә йитү белән, «чапан зинданы» эченә кереп, якты дөньядан мәхрүм була. Ул мескен, мәхлук, үзенең мондый кызганыч хәлгә төшүен дин, шәригать буенча фарыз эш дип, уйлый ... Озак та үтми, «ир» исемле җанвар килеп, ул байгышны – кыз кирәк теләсен, кирәк теләмәсен, үзенең үткен тырнаклары арасына эләктереп алып та китә.

Мөгаллимә: Өммегөлсем Терешкавия

*«Сөембикә», 1913, №4, б.3–5.*

## Хатын-кыз дөньясы

Уфаның Мариинский гимназиясендә мөселманнардан 19 кыз, 2нче кызлар гимназиясендә 7 кыз, частный кызлар гимназиясендә 21 кыз укый. Хәлбуки[567], шул гимназияләрнең һичберсендә мөселманча дин дәресләре укытылмый. Уфа мөселманнары башка эшләрдә бик шәп диндарлык күрсәтергә тырышсалар да, бу гимназияләрдә Уфаның бөек гаиләләренең, хәтта бәгъзе голямәсенең[568] кызлары укыса да, бу көнгә кадәр шул мәктәпләргә дин дәресе куйдыруны искә алучы булмаган.

Хәлбуки, юлы илә тырышканда, боларның һәркаюсына берәр дин мөгаллимәсе куйдырырга мөмкин булачак.

---

[567] Хәлбуки – ләкин.
[568] Голямә – галим.

Мөселманнарның дини вә башка шундый ихтыяҗлары үтәлмәүгә бик күп сәбәпләр булса да, иң зур сәбәп – үзләрендә тырышу юклык. Башка халыклар, балаларын мәктәпләргә биргәннән соң, родительский комитетларга керергә тырышалар. Балаларны мәктәпкә бирү илә өсләреннән бурыч төште дип тормыйлар. Аларның ул мәктәбендә матлубка[569] муафыйк[570] сурәттә тәрбия ителүләренә дә дикъкать итәләр. Уфа мөселманнары да, хосусан кыз аталары, тиешле урынга мөрәҗәгать итеп, үзләренең балаларына дин тәрбиясе бирелүне сорарга тиешле. Дини, милли тәрбия күрмәгән кешеләр ничаклы зур укысалар да, милләт өчен файдалы булып чыкмыйлар. Милләт анасы буласы кызларның милли тәрбиядән мәхрүм калулары бигрәк тә ярамый. Чөнки безнең бар өмет-көткәнебез шуларда. Алар да милләтебезне танымасалар, дини тәрбия күрмәсәләр, безгә милләт егетләрен кем җитештерсен?

*«Тормыш», 1914, 11 гыйнвар.*

**Хәзерге мәсьәлә**

Үткән 1913нче елның 23нче декабрендә Петербург шәһәрендә бөтен Русиядәге халык мәгарифе эшен тикшерү өчен мөгаллимнәр съезды ясалды[571]. Бу съездга халык мөгаллимнәреннән алты меңнән артыграк кеше килгән иде.

«Ил» гәзитәсенең[572] язуына караганда[573], бу съездда Кавказдан 15ләп, Идел буендагы шәһәрләрдән унлап, җәмгысы 25 ләп мөселман мөгаллимнәре булганнар. Мөселман ханымнарыннан Кавказдан барган мөгаллимә Хәнифә ханымнан[574] башка кешенең булганлыгы мәгълүм түгел. Мөгаллимә Хәнифә ханым съездда мөселман хатын-кызларының тәрбиясенә әһәмият бирү кирәклеген вә мөселман кызларына махсус мәктәпләрнең арттырылуы тиешлеген аңлаткан. Шундый зур съездда мөселман хатынының чыгып сүз сөйләве, бигрәк тә үз җенестәшләре булган хатын-кызларны кайгыртуы, алкышланмаслык эш түгелдер. Бу съездның «Инородецлар секциясе» исемендәге шөгъбәсенә[575] Дума әгъзаларымыздан Гайсә мирза

[569] Матлуб – таләп ителгән, соралган.

[570] Муафыйк – яраклы, туры килгән.

[571] Халык мәгарифе буенча I Бөтенроссия съезды 1913 елның декабре – 1914 елның гыйнварында уза. Анда Россия империясенең төрле почмакларыннан килгән укытучылар катнаша. Гомуми мәҗбүри белем бирү планы тикшерелә.

[572] «Ил» – иҗтимагый-сәяси газета, 1913–1914 елларда Петербург шәһәрендә, 1914–1918 елларда Мәскәүдә басыла. Нашире һәм мөхәррире – Г.Исхакый.

[573] Петербургта съезд // Ил. 1914. 2 гыйнвар.

[574] Хәнифә ханым (Ганифә Малик-задә) – мәгърифәтче, мөгаллимә, Бакуда Тагиевның кызлар мәктәбе мөдирәсе (1901–1909).

[575] Шөгъбә – бүлем, бүлек.

Еникиев[576] бер доклад керткән. Докладында мөселман хатын-кызлары хакында ошбу сүзләр бар:

«Мәктәп тәшкил итү эшләрендә һәм училищный советта мөселманнарның иштиракь итүләре[577], мөселман халкының хатын-кызлары арасында аларның дине вә гадәте булган хосусиятләренә муафыйк[578] сурәттә мәгарифнең таралуына бик күп ярдәм итәр иде.

Мөселман хатын-кызларының уку эшләрен тәртипле бер юлга кую мәсьәләсе шундый тизлектә хәл кылынырга тиешле булган мәсьәләдер ки, ул мөселманнар өчен мөһим булган мәсьәлә хакында хәзер әһали[579] дә, хөкүмәт тә тавыш-тынсыз калырга тиеш түгел. Безнең фикеремезчә, кирәк кадәрле мәгълүматка малик[580] булган мөселман хатыннарыны мәктәпләр инспекторлыгына кую мөселман хатын-кызлары арасында уку эшләренең тугры юлга куелуына бик зур хезмәтләр күрсәтер иде. Мөселман хатын-кызларының хәзерге рәвештә артта булуларына әһали белән бәрабәр, мөселманнарның дине, гадәт вә хосусиятләренә муафыйк сурәттә кызлар мәктәбе ачарга рөхсәт бирми, аларның мәгариф эшендә аяныч хәлдә калуларына сәбәп булган мәгариф даирәсенең вәкилләре дә гаепледер».

Гайсә әфәнде Еникиевның үз милләттәшләренең хатын-кызларын бу дәрәҗәдә игътибарга алуы, әлбәттә, шөкерана кылырлык бер эштер.

Әлбәттә, милләтнең бишеге булган хатын-кызлар галәме наданлыктан чыгарылып, мәгариф яктысы белән яктыртылса, милләт тәрәккый итәчәктер. Бу соңгы сүзне мөхтәрәм мөхәррирләремездән Гаяз әфәнде (Исхак булса кирәк)[581] дә «Мәктәп» журналының[582] бу сәнә беренче номерында дәреҗ ителгән[583] мәкаләсендә тасдыйк итә[584].

Ул: «Авылларда, хосусан, мишәр авылларында, ире, кызы бергә укытыла торган мәктәпләрдә мөгаллимәләргә әһәмият бирә төшәргә, кайсысын алырга дигән фикер булганда, мотлакан[585] мөгаллимәгә артыклык бирергә тиеш», – дип, хатын-кызның бишек янында вә өй эчендә генә түгел, хәтта мәктәп вә мәдрәсәләрдә дә милләтнең тәрбиячесе булуын тәрҗих итә[586].

---

[576] Гайсә Хәмидулла улы Еникиев (1864–1931) – сәяси эшлекле, педагог. III нче һәм IV нче Дәүләт Думалары депутаты, Вятка губернасының Халык мәгарифе коллегиясе әгъзасы, мәктәпләр бүлеге җитәкчесе (1918–1923).

[577] Иштиракь итү – уртак булу, катнашу.

[578] Муафыйк – кирәкле, яраклы.

[579] Әһали – халык.

[580] Малик – ия, хуҗа.

[581] Мөхәммәтгаяз Гыйлаҗетдин улы Исхаков (Гаяз Исхакый, 1878–1954) – мәгърифәтче һәм язучы, татар милли хәрәкәте әгъзасы.

[582] «Мәктәп» – фәнни-педагогик журнал, 1913–1914 елларда чыга. Мөхәррире һәм нашире Ш.Ш.Әхмәров.

[583] Дәреҗ итү – теркәү, арага кертү, урнаштыру.

[584] Тасдыйк итү – раслау.

[585] Мотлакан – һич нигә карамастан.

[586] Тәрҗих итү – өстен күрү, башкадан артык күрү.

Хатын-кызның мәктәпләрдә тәрбия ягыннан мөгаллимнән берничә мәртәбә өстен булачагы шөгъбәсез инде. Шулай булгач, хәзер милләтнең иң нык тырышкан вә иң беренче чиратта хәл ителергә тиешле булган мәсьәләсе хатын-кызларны укыту мәсьәләсе булырга тиеш.

Шунда гына чын эшлекле милләт йитешер. Шунда гына алдагы көнемезгә өметле күз белән карарга ярар.

*«Сөембикә», 1914, №8, б.1–2.*

***Сара***

## Карья[587] кызларында уку ничек?

Уку тугрысында шул бер балык башы чәйнәлә диләр. Шулай шул!.. Чәйнәп-чәйнәп тә файдасыз дип ташлау үзе тугры килми. Чөнки һәр нәрсәнең башы, мәдәниятнең баскычы, милләтнең барышы уку-укыту илә улганга, билгеле, һәмишә шуннан сүз башлыйсы килә.

Безнең Буа өязендә авыл йирләрендә кызларны укыту һәм аларны заманча тәрбияләү бөтенләй юк диярлек. Милләтнең яртылашын тәшкил иткән авыл кызлары шулкадәр җаһилиятьтә[588] торганда, шәһәр йирендәге генә бай кызларының уку-укытуда алга китүләре илә милләт ни дә кылачак түгел. Моны мин бик батырланып әйтә алам.

Тарафымызда үзләренчә бик тәрәккыйпәрвәр[589] муллалар булса да, авылда кызлар мәктәбен ачу тугрысында бер авыз улсын, сөйләгәннәре вә шул тугрыда уйлаганнары да юк. Әле кызлар мәктәбе бер якта торсын, ир балалар мәктәбе дә һәмишә[590] иске мунча, иске таш кабиленнән[591] дәвам итә. Моны шуннан да белергә мөмкин. Бөтен Буа өязенә читтән бер мөгаллим килдеге ишетелгәне, күрелгәне юк.

Муллалар үзара талашып, судлашып йөргәнгә, андый гомуми милләт файдасын күзәтергә бушамыйлар. Әгәр минем сүземне ялган диюче улса, мәйданга чыксын. Мин аңар берәм-берәм санап күрсәтермен. Хасыйл[592] гына дөньяның нинди генә почмагын карагыз, безнең Буа өязеннән гафләттә[593] торган һич бер йир таба алмассыз.

Кайсы гына милләтне караганда да, аның тәрәккые[594] мәдәниятенең авыл йирләренә, ягъни гавам[595] арасына тамырлануы иләдер. Мәдәният олуг гаиләләрдә генә булып, карьяләрдә, гавам арасында улмаса, әлбәттә, аннан көткән

[587] Карья – авыл.
[588] Җаһилиять – наданлык, белемсезлек.
[589] Тәрәккыйпәрвәр – прогрессив.
[590] Һәмишә – һаман.
[591] Кабил – төр.
[592] Хасыйл – нәтиҗә.
[593] Гафләт – игътибарсызлык, ваемсызлык.
[594] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[595] Гавам – халык.

кадәр файда чыкмаячактыр. Шуның өчен дә, авыл йирләрендә кызларга махсус мәктәпләр ачып, аларны да милли рух белән тәрбияләргә вакыт йитә инде, муллалар!

Талашуыңызны куеңыз. Милләт сездән көтә. Сезгә мәктәп салырга да, мөгаллим китерергә дә ярдәм итүче күп. Сез шуны, бисмилла, дип, алдыңызда тиешле эшләрен күреңез, меңләп, миллионлап милләт аналарын заманча тәрбия итәргә вакыт йитмәдеме?

Суыксу карьясендә[596] Сара, мулла Мирза әһлиясе[597].

*«Сөембикә», 1914, № 12, б.10–11.*

***Сания Гыйффәт Кадыйрия***

**Хатын-кыз галәмендә**
(1914нче ел эчендә)

Милләтләрнең мәдәниятле булулары хатыннарына туктый. Хатыннарында белем вә аң тәрәккый иткән[598] милләтләрнең шул нисбәтендә мәдәниятләре дә тәрәккый итә. Хатыннар – мәдәния баскычлары, тәрәккый кораллары. Алар бәхеткә дә, бәхетсезлеккә дә өстери алалар, һәр ике як аларның гына кулында. Аналар белемле булсалар, милләтләренә каһарман, даһи ирләр, галиҗәнаб[599], җитди вә тугры фикерле аналар багышлыйлар. Төптән җитешеп килгән аналар сәбәпле, милләтләрдә мәдәният туа, зурая, белем вә аң милләтнең һәр төпкәсенә тарала. Гаиләләр аңлы булганда, мәктәпләрдән алынган тәрбия вә мәгълүматлар сөзмәле була. Хатыннар мәдәнияттә ирләр белән бергә агарга, һәр тугрыда бергә катышып, ярдәмләшеп көн күрергә тиешлеләр. Укытуда, җәмгыять, гыйльми вә иҗтимагый эшләрдә бергә хәрәкәт итәргә без, хатыннар, бурычлымыз. Шулай булса да, безнең үземезгә генә караган эшләремез дә күп. Безнең үземезгә махсус әдәбият, җәмгыять вә мәктәпләремез бар. Боларга хезмәт итеп эш иттерү – безнең өстемезгә йөкләтелгән бер вазыйфа. Хатыннар ирләрдән, ирләр хатыннардан башка ярты гына кеше булганга, без үземезгә караган эшләрдә ирләрнең дә фикер вә ярдәмнәренә мохтаҗмыз. Ләкин һәр эшне мөмкин кадәр үземез генә башкарып алып барырга, ирләрне дә иң аптырап калган вакытымызда гына ярдәмчеләр итеп карарга кирәк. Без күптәннән инде ирләр чәйнәп биргән ашны ашап, борган якка борылып, сөргән яктан сөрелеп, алар кулында курчак булып тордык. Хәзер инде үзебез эшли белергә вакыт.

Хатын-кыз галәме үзенең менә шул олуг мәсъүлиятеннән[600] хисап бирергә, шул зур вазыйфаларын үтәп, үтәмәгәнлеген хәтеренә төшерергә

---

[596] Иске Суыксу авылы – хәзер Татарстанның Буа районына карый.
[597] Әһлия – тормыш иптәше, хатыны.
[598] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.
[599] Галиҗәнаб – бөек, мөхтәрәм.
[600] Мәсъүлият – җаваплылык.

бурычлы. Моның өчен бик еракка китмичә, үткән 1914нче елда эшләнгән эшләремезне күздән үткәрү җитсә кирәк. 1914нче елда без ни эшләдек соң? Үземезгә йөкләнгән мәдәни вазыйфаларымызны үти алдыкмы? Әдәбият һәртөрле дәрәҗәгә менү өчен баскыч булганга, сүземне әүвәл шуннан башлыйм. Аңлы милләтләр һәрнәрсәдән элек, тел вә әдәбиятларын киңәйтергә, баетырга тырышалар. Гәзитә вә журналлары, әдип, мөхәррирләре бөтен тырышлыклары белән шуңар гына сарылалар. Соңгы берничә ел эчендә бездә дә бу хис туып, арта барганлыгы күп аңлы кешеләрне шатландыра. Күптән түгел генә «Таһир-Зөһрә»[601], «Йосыф-Зөләйха»[602] кебек китапларны да рәтләп укый алмаган татар хатын-кызлары кулында бөтенләй башка рухта, башка телдә, башка дәрт бирә торган китаплар. Ул аларны укый, рәхәтләнә. Тормышка чагыштыра, тәнкыйть кыла. Боларны да ваксына. Фикере тагы югарыракка омтыла. Башка милләтләрнең әдәбиятына нисбәтле, безнең әдәбиятымыз көннән бер тамчы кадәр генә булса да, истигъдадлары[603] чапан, табигый матурлыклары кершән-иннек астына качырылган кыйммәтле татар туташларын шактый гына үстереп, табигый зиннәтләр белән бизәде. Аларга махсус китаплар чыгып, хокукларын танытты. Алар өчен «Сибирия», «Тормыш», «Ил» гәзитәләрендә махсус баблар[604] ачылып, фикерләрен күтәрде. Аларга махсус журнал, роман вә хикәяләр чыкты, мәктәпләр ачылды. Алар арасыннан матур гына каләмле мөхәррирәләр йитеште. Менә бу хәлләремезне 20нче гасырга чагыштырып караганда бик түбән булса да, фәтрәт[605] дәверенә чагыштырганда шатланырлык. Хатын-кызга махсус әдәбият җөмләсеннән санарга яраса, бу ел «Сөембикә» журналы вә «Мөгаллимә»[606] исемле әсәрләрдән башка, әдәбият исеменнән күзгә күренерлек әсәрләр чыкмады. «Сөембикә» журналы да хатын-кызларга егерменче гасырның бирергә теләгән мәгълүматларын бирә алмый. Фәхрелбәнат ханым[607] сәркатибә ителеп чакырылудан элек, ул хатыннар журналы төсле дә күренми иде. Хәзер шактый гына хатын-кыз мәкаләләре күренсә дә, күзгә бәрелерлек мөһим мәкаләләр чыкканы юк.

Мәктәпләребезгә килсәк, һаман шул иске мәктәпләр, һаман шул буяу, баш ватулар, санаигъ нәфисәдән[608] бик ерак, гимнастика, музыкага бөтенләй мохтаҗ түгел төсле. Мөгаллимәләремез йитешсез-рухсыз. Үзләрендә тулы мәгълүмат булмаганга, дәрес вакытында балаларга китапта язылганнан тыш мәгълүмат бирә алмыйлар. Мөгаллимәләремез шул хәлдә булган вакытта, мәктәпләремезнең алга китүен көтәргә юл да күренми. Мөгаллимәләр

---

[601] «Таһир-Зөһрә» – Сайядиның «Дастане Бабахан» (XIV гасыр ахыры – XV гасыр башы) әсәре.

[602] «Йосыф-Зөләйха» – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы (1233).

[603] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.

[604] Баб – бүлек, бүлекчә.

[605] Фәтрәт – ике вакыйга арасында үткән вакыт, хәрәкәтсезлек.

[606] «Мөгаллимә» – Г.Исхакыйның шул исемдәге әсәре (1913).

[607] Фәхрелбәнат ханым Сөләймания.

[608] Санаигъ нәфисә – матурлык сәнгате.

йитештерә торган урыннарымыз да юк. Мөфти хәзрәт исеменә ачылачак дарелмөгаллиматымыз[609] бөтенләй онытылып бетә язды диярлек. Артыннан йөреп, булдырырга тырышучыларымыз да күренми. Мөгаллимәләремез мөкәммәл[610] булмаганда, мәктәпләрдән мәдәнияткә өстерәүче аналар ничек йитешсен дә, аңлы-әхлаклы гаиләләр ничек хасыйл булсын. Җәй көне Уфада вә башка бер-ике урында «җәйге курс» исеме белә мөгаллимәләргә махсус курслар ачылса да, болар белемгә сусаган мөгаллимәләрне каныктырырлык түгелләр. Курста укытучылар арасында икътидарлыраклары[611] төртеп кенә күрсәтерлек. Безне мондый вак-төяк көчләр генә һаман максатка йиткерә алмый.



Казанда беренче мөслимә табибәләребездән Маһипәрвәр Дәүләткилдиева. Шаһбазгәрәй һәм Хәдичә Әхмәроваларның кызы. *(«Сөембикә», 1914, № 9)*

Еш-еш кына хатын-кызга махсус төрле мәүзугъларда[612] лекцияләр укылса, вак-төяк курсларга караганда әллә ни кадәр файда китерер иде. Бу лекцияләргә ихтыяҗымыз бик зур булса да, әле бары бер мәртәбә Уфада гына укылды. Әһәмиятен яхшы төшенә алмаганлыкларыннанмы, бу лекцияне тыңларга мөгаллимәләр оясы булган Уфадан бары бер-ике генә мөгаллимә барган иде. Ешрак булгаласа, ихтимал күбрәк килгәләп, хатын-кызларымызның иҗтимагый эшләргә дә күнегеп китүләренә сәбәп булыр иде. Минемчә, алга омтылырга теләгән мөгаллимәләремез өчен Русиядәге төрле курсларга керәргә хәзерләнү – иң муафыйк[613] бер юл. Губерна шәһәрендәге тәрбия вә тәгълим курсларына безнең мөгаллимәләремез бик җиңеллек белән керә алырлар иде.

Санымызга күрә җәмгыятьләребез дә бик аз. Хәлбуки[614], мәктәпләр дәрәҗәсендә юк җәмгыятьләргә дә ихтыяҗымыз зур. Җәмгыятьләр булса, шактый гына эшләр эшләп була. Уфа, Оренбург җәмгыятьләре бу ел үз галәмнәренә генә түгел, ватанга да онытылмаслык сәдакать[615] вә изгелекләр кылырга тотындылар.

[609] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[610] Мөкәммәл – камилләшкән, төгәлләнгән.
[611] Икътидар – булдыра алу, көч җитү.
[612] Мәүзугъ – проблема, тема.
[613] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[614] Хәлбуки – ләкин.
[615] Сәдакать – турылык, дуслык, туры сүзлек.

Уфа ханымнар җәмгыяте[616] Уфада 500 ләп кыз, 11–12 русча-татарча мөгаллимә, 14–15 балалы бер ятимханә тәрбияләдеге хәлдә, үз исеменнән мәҗрух[617] гаскәрләр хастаханәсе тәрбия кылуны да өстенә алды. Оренбург ханымнары җәмгыяте исә, бер һөнәр мәктәбе тәрбия кыла, бу ел мәҗрух гаскәрләр өчен тәртип киленгән комитетка кирәкле нәрсәләрне тегеп хәзерләде, Петроградта корылган мөселман җәмгыятьләре союзына да катнашырга карар бирделәр. Ачылганына 2 ел чамасы гына булган бу җәмгыять эшлеклелеге берлә үзен танытып килә.

Күптән түгел генә Баку мөслимәләре дә бик киң программа белән бер җәмгыять ачтылар[618]. Әлегә эшләгән эшләре әгъзалар сайлау кеби эшләрдән генә гыйбарәт булса да, тиздән бу җәмгыятьнең дә мондый мөһим заманда байтак зур эшләр күрсәтәчәгенә өмет зур. Аерым бер җәмгыятьләре булмаган хатын-кызларымыз да төрле комиссияләр ясап, иганәләр җыеп, мәҗрух гаскәрләргә киемнәр хәзерләп үз вазыйфаларын үтәделәр. Казан мөселман хастаханәсенә иганә җыеп, үз материаллары белән керләр тегеп бирделәр. Шунда бер мөслимә табибә вә мөслимә шәфкать һәмширәләре[619] мәҗрухларны карамактадыр.

Авылларда мөселман учительницаларының иҗтиһадлары[620] белән күп ярдәмнәр җыелганы шикелле, Троицк, Каргалы вә башка урыннарда да хатын-кызларымызның бу тугрыда күрсәткән иҗтиһадлары дикъкатькә алынырлыктыр. Хәтта Кырымда Сәгыйдә ханым бер комитет ясап, Кырым атлы бүлеге өчен бик зур иганәләр җыйды. Шуларны илтер өчен аңар махсус вагоннар бирелеп, Петроградка бик күп кием вә ашамлыклар илтеп тапшырды. Петроград кеби курсистка вә зыялы ханымнарымыз кайнаган урында бер җәмгыятькә рөхсәт алыну тиешле булса да, мәгаттәэссеф[621], бу ел мондый бер хәрәкәт күренмәде. Шулай да андагы хатын вә туташлар «Нәшре мәгариф» җәмгыятенә катышып хезмәт итәләр. 16нчы июньдә ясалган съездга[622] хатын-кызларымызның хокуксызлыгы дикъкатькә алынып, доклад керттеләр. 6нчы декабрьдәге мөселман съездына[623] Мәрьям Базаревская белән Әминә Сыртлановалар[624] катнаштылар. Әминә ханым мәркәз комитетка да әгъза ителеп сайланды. Учительница, гимназистка, курсисткаларымыз

---

[616] «Уфа мөселман ханымнар җәмгыяте», 1907 елда оештырыла, рәисәсе Мәрьям Солтанова.

[617] Мәҗрух – яраланган, яралы.

[618] «Баку мөселман хатын-кызлар хәйрия җәмгыяте», рәисәсе – Сона Тагиева, урынбасары – Рәхилә Гаджибабабекова (Терегулова).

[619] Һәмширә – кыз туган, кыз кардәш.

[620] Иҗтиһад – тырышлык кую, тырышу.

[621] Мәгаттәэссеф – кызганычка каршы.

[622] 1914 елның 15–25 июнендә Петербургта узган IV Бөтенроссия мөселман съезды турында сүз бара.

[623] 1914 елның 6–10 декабрендә Петроградта узган Мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләренең Бөтенроссия съезды турында сүз бара.

[624] Әминә Мәхмүт кызы Сыртланова (1884–1939) – җәмәгать эшлеклесе, шәфкать туташы.

елдан-ел артканлыгы шикелле, табибәләр, фельдшер-акушеркалар, һөнәр вә музыка мәктәпләрендә укучылар да күренә башлады. Хәзер Петроградта Сара ханым профессорлыкка хәзерләнә[625]. Димәк, укыган-омтылган вакытта нинди генә эшне булса да, булдырырга хатын-кызларымызда истигъдад[626] бар икән.

Авылларга күз салсак, анда гел әүвәлге каралык, караңгылык. Мәктәпләр әүвәлге агышы белән агалар, үзгәргән җирләре юк. Андагы хатын-кыз һаман үкле, аңсыз, кызганыч бер хәлдәләр. Ирләре кул астында һаман изелә, кыйналалар. Бу изелүнең баш сәбәбе, әлбәттә, хатын-кызның хокукы ригая кылынмаганлыктыр[627]. Хокуксыз яшәп тә, эшләп тә булмый. Хокук булмаганда, безгә һаман да изелергә туры киләчәк. Бу ел 12нче мартта чыккан закон буенча һәр хатын үзенең иренең рөхсәтеннән башка үзенә паспорт алып, аерым тора ала. Элек ире рөхсәт итсә генә паспорт бирелергә мөмкин иде. Ирләренең золымыннан бизар[628] булган хатыннарга бу закон уңайлы булды.

Бу елгы бәхетсез вакыйгаларның берсе дә Фатыйма-Фәридә ханымның вафатыдыр.

Татар хатыннары кеби, төрек хатыннары да, ничә йөз еллардан бирле шәригать биргән хокукларыннан файдалана алмыйча, зинданда яткан төсле яшәп киләләр иде. Мәмләкәттә мәшрутиять[629] игълан ителү аларны бөтенләй икенче хәлгә китерде. Алар аяксыз иде, аякландылар, телсезләр иде, телләнделәр. Җәмгыятьләр ачтылар, гәзитә вә журналлар чыгардылар. Аларны бер тиенгә санамаган хөкүмәт тә бу ел игътибарга алып, мәгариф назыйре хатын-кызга дарелфөнүннәргә[630] кереп укырга рөхсәт итте. Зыялы төрекләр вә төрек гәзитәләре бу әмерне бик шатлык белән каршы алдылар. Төрек ханымнары телеграфханәләргә кереп тә хезмәт итәргә тотындылар. Фатыйма, Галия, Нигяр[631], Ләйлә, Нәзиһә Бәшар, Әминә Сәмия[632], Салмә Сөрут, Халидә Әдибә[633] ханым кеби мөхәррирәләрнең исемнәре әдәбият галәмендә еш күренә башлады.

---

[625] Бу хакта тулырак китапның 275–276 битләрендә басылган Искәндәр Ишмөхәммәдовның «Татар кызларыннан профессор булырга хәзерләнгән Сара ханым» мәкаләсеннән укыгыз.

[626] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.

[627] Ригая кылыну – игътибар бирелү.

[628] Бизар – зарлы.

[629] Мәшрутиять – конституциялелек.

[630] Дарелфөнүн – югары уку йорты, университет.

[631] Нигяр ханым (1956–1918) – төрек шагыйрәсе. Үзенең эшчәнлеге өчен Солтан Абдул Хәмид II тарафыннан шәфкатьлелек ордены белән бүләкләнә.

[632] Әминә Сәмия – төрек язучысы, Европада белем алган, хатын-кызның җәмгыятьтәге роленә багышланган әсәрләр авторы.

[633] Халиде Эдиб Адывар (1884–1964) – Төркиянең сәяси һәм җәмәгать эшлеклесе, төрек хатын-кызларының азатлыгы өчен көрәшүче; журналист, педагог, язучы.

Апрель аенда Тәлгать бәк кул астында ачыкта калган – химаясез[634] кызлар өчен дарелшәфикә[635] ачарга карар бирелде. Тәгавын ислам җәмгыяте[636] ачылып, хатыннарга махсус унике лекция укылды вә шуның тарихка гаид[637] кыйсемен Халидә Әдибә ханым укыды. Хатыннарда булган бу омтылыш ирләрнең дә дикъкатен үзенә җәлеп итте. Алар да кызу-кызу моназарәләргә[638] ябыштылар. Матбугат галәме шаулады. «Сабилерришад» журналында[639] Мәхмүд Әсгать әфәнде илә Рәшид бабаның[640] бу хакта кызу моназарәләре дә булып алды. Вакыты илә мин шул мәкаләләрне тәрҗемә кылып, «Тормыш» гәзитәсендә бастырган идем.

Шәрекъта хатын-кыз мәсьәләсенең учагы саналган Мисырда да 1914нче елда хатын-кыз хәрәкәте үз юлында дәвам итте. Хидью[641] анасы идарәсендә ханымнар җәмгыяте ачылды. Мисыр көллиясендә профессорлар тарафыннан хатыннарга махсус лекцияләр укылды. Кызлар гимназияләре вә дарелмөгаллиматлары, журналлары елдан-ел яхшырак тәрәккый итә бара.

Һиндыстанда да быел хатыннарга махсус гали мәктәп ачылды. Шәрекънең башка йирендәге хатын-кызлар һаман шул әүвәлге аяныч хәлләрендә, йоклыйлар.

Аурупа хатын-кызларындагы гыйльми хәрәкәтнең ис китәрлек рәвештә алга киткәнлеге безгә мәгълүм. Алар инде доктор-адвокат, инженер булудан күптән үткәннәр. Алар хәзер ирләр белән бер хокукта булуны дәгъва кылалар.

Бу хәрәкәтнең иң кайнаган урыны хәзер Ингелтерәдер[642]. Анда хокук дәгъва итеп тартышучы ханымнар төрле митинг, җәмгыятьләр төзеп, полициягә каршы сугыш ачып, ихтиляльләр[643] чыгардылар, шәһәрләрдә төрле һәлакәтләр ясадылар. Боларның беренче теләкләре – ирләр белән тигез булу, ирләр кебек парламентларга сайлану. Ингелтерә хатыннарының бу таләпләре бу ел парламентта рәд ителде[644]. Алар бәлки тагын да дулашырлар, төрле хәрәкәткә тотынырлар иде, ләкин сугыш башлану сәбәпле, мәмләкәтләренә төшкән авырлык боларны бу хәрәкәттән тыелырга мәҗбүр итте. Алар хәзер мәмләкәтне саклау юлында үзләренә төшкән вазыйфаны үтәү белән мәшгульләр.

---

[634] Химая – яклау, саклау.

[635] Дарелшәфика – шәфкать йорты, ятимханә.

[636] Тәгавын ислам җәмгыяте – мөселманнарның үзара ярдәм җәмгыяте.

[637] Гаид – бәйләнешле.

[638] Моназарә – сүз көрәштерү, бәхәсләшү, дискуссия.

[639] «Сабилерришад» – Төркиядә чыгып килгән журнал; анда татарлардан Габдерәшит Ибраһимов, Әхмәдмөнир Ибраһимов һ.б. мәкаләләрен бастырган.

[640] Рәшит баба – Габдерәшит Ибраһимов.

[641] Хидью – патша, әмир.

[642] Ингелтерә – Англия.

[643] Ихтиляль – баш күтәрү, чуалыш ясау, бунт.

[644] Рәд итү – кабул итмәү, кире кайтару.

Болар бар да хатын-кызларның 1914нче елда эшләгән эшләре. Моннан үти торган бурычларымызның бик күбесе 1915нче ел хисабына өелеп калганлыгы аңлашыла. Инде 1915нче елда өстемезгә төшкән эшләрне мөкәммәл[645] итеп алып барырга тырышу барымызга да йөкләнеп калган бер бурыч. Барымыз да үз вазыйфамызны белеп хәрәкәт итсәк, Аурупадагы апаларымыз артыннан без дә җитәрмез, без дә адәм, бездә дә кан, җан вә милли намус бар бит...

*«Тормыш», 1915, 1 гыйнвар.*

***Әхмәд Таҗетдин***

**Кыйраәт китаплары**

(Мәктәп кирәк, мәктәптән дә әүвәл китап кирәк)

Бу елны миңа бер кызлар мәктәбе программасы төзергә тугры килде. Шәһәремездәге «Эш» китапханәсенә мөрәҗәгать иттем. Өемә дүрт сыйныфлы кызлар мәктәбенә кирәк булачак китапларның һәртөрлесеннән берәр нөсхә[646] йибәрүен үтендем. «Эш» китапханәсе мөдире, үтенечемне кабул итеп, бер извозчик йөге китапны ханәгә китереп аударды. Китапларны күргәч, күплегенә хәйран калдым. Китапханә мөдире миңа дүрт сыйныфлы бер мәктәп өчен сигез сыйныфка аера алырлык китап йибәргән, дигән уйга төштем. Ибтидаи[647] мәктәпләр өчен язылганнарын аерып алып калырмын да, башкаларын кире йибәрермен, дидем. Аерырга тотындым. Ахырында күрәм ки, миңа йибәрелгән китапларның һәммәсе ибтидаи мәктәпләр өчен язылган китаплар имеш..! Тагын да таңга калдым. Димәк ки, бездә ибтидаи мәктәпләр өчен китапка байлык бу дәрәҗәдә..! Ифрат дәрәҗәдә шатландым. Ничек шатланмыйм, моннан егерме еллар элек милли китапханәсендә ибтидаи мәктәпләренә дәрес китабы буларак «Бәдәвам»[648] илә «Кисекбаш»тан[649] башка бер нәрсәсе дә булмаган татарның егерме ел эчендә бу кадәр китаплары булган. Егерме ел кадәр аз бер мөддәт[650] эчендә дистәләп мөәллифләр[651], педагоглар йитешкән. Тугрысын әйткәндә, мин бу кадәр мәктәп китабына байлыкны бер уезный шәһәр китапханәсендә түгел, мәдәният вә интибаһка[652] бездән бер гасыр элек аяк баскан госманлыларның пайтәхете[653] булган Истанбул китапханәләрендә дә күргәнем юк иде.

---

[645] Мөкәммәл – камилләшкән, тәгәлләнгән.

[646] Нөсхә – данә, экземпляр.

[647] Ибтидаи – башлангыч.

[648] «Бәдәвам» китабы – дини-дидактик әдәбият үрнәге; мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланылган.

[649] «Кисекбаш» – «Кисекбаш китабы», XIV–XV йөзләрдә язылган татар әдәбияты үрнәге, кульязма һәм китап рәвешендә киң таралып, мәдрәсәләрдә дәреслек итеп кулланылган.

[650] Мөддәт – ара, вакыт.

[651] Мөәллиф – китап төзүче.

[652] Интибаһ – уяну, күз ачу.

[653] Пайтәхет – башкала.

Алдымда зур гына бер чүмәлә тәшкил иткән бу китапларны фәнгә аерырга тотындым. Нәтиҗәдә шушы якүн[654] хасыйл булды: 25 мөәллиф тарафыннан язылган әлифба, 49 фәкыйһ[655] тарафыннан төзелгән гыйльме халь[656] китаплары, 35 мөәррихнең[657] тәтәббыгат[658] тарихиясе саясендә вөҗүдкә килгән «Тарих әнбия»[659] вә ислам, 55 педагогның сәнгать калямиясе бәрәкәтендә мәйданга чыккан кыйраәт китаплары[660], унлап фән әл-тәҗвид, 18 төрле җәгърафия китаплары вә башкалар.

Алдымыздагы китапларын тарика[661] фәннәргә аерып беткәч, китапларның аерым-аерым өелеп торуы миңа яхшы гына тәэсир итте. «Яңа гына мәгариф юлына аяк баскан татар өчен бу кадәр тәхәссыс[662] күп түгелме соң?» – дигән бер сөаль зиһенемнән яшен шикелле үтеп китте. Дистәләп мөәррихләремез, педагогларымыз булуны күңел никтер арзу[663] итсә дә, ләкин боларның бу кадәр аз мөддәт эчендә гөмбә шикелле тишә алуына ни өчендер күңел ышанмады. Артык баягы шатлык урынына күңелгә шөбһә төшә башлады.

Бер вакытлар Казанда сәясиләремез бик күбәеп киткән иде. «Болгар», «Сарай» тирәләре[664] татарларның гадәтән[665]сәясәт мәркәзе булган иде.

Бу мөәррихләр вә педагоглар теге депутатларымыз шикелле булып чыкмасын дидем дә, тизрәк хакыйкатькә мөтталигъ булыр[666] өчен алдымдагы китапларны карарга тотындым. Иң әүвәл кыйраәт китаплары сайлый башладым.

Кулым китапларны әрле-бирле әйләндерә башлагач та, фикерем әллә кайларга китте. Русларның хифзыссыйхәткә[667] муафыйк[668] зур сарайдай школалары янында үземезнең каравыл өе кебек кечкенә генә мәктәпләремез күз алдыма килде. Ни өчен без кечкенәдән үк балаларымызны шул сарайдай школаларга биреп укытмыйбыз да, шул тавык алачыгы кеби тар, кечкенә, кысынкы өйләрдә, үз алдымызга мең мәшәкать илә мәктәпләр тәрбия кылып маташамыз? Безләрне бу мәшәкатьләргә катлануга мәҗбүр иткән куәт нинди

---

[654] Якүн – җыенысы, барысы,

[655] Фәкыйһ – шәригать законнарын яхшы белүче, юрист.

[656] Гыйльме халь – ислам дине нигезләре турында башлангыч мәгълүмат бирә торган фән.

[657] Мөәррих – тарихчы.

[658] Тәтәббыг итү – тикшерү, эзләнү.

[659] «Тарихы әнбия» – пәйгамбәрләр тарихы.

[660] Кыйраәт китабы – уку китабы, хрестоматия.

[661] Тарика – юл, ысул.

[662] Тәхәссыс – үзенчәлек, белгечлек.

[663] Арзу – теләк, омтылыш.

[664] «Болгар», «Сарай» – Казанның Печән базары өлешендәге номерлар, кунакханәләр.

[665] Гадәтән – гадәт буенча.

[666] Мөтталигъ булу – ирешү, белү.

[667] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.

[668] Муафыйк – туры килгән, яраклы.

куәт? Нинди идея безне сарайдай школалардан әүвәл каравыл өедәй мәктәпләргә таба тарта? Безләрне бу мәшәкатьләргә катланырга мәҗбүр иткән куәт дин, безләрне сарайдай школалардан әүвәл каравыл өедәй мәктәпләргә таба өстерәгән идея исә милли мәүҗүдемезне[669] саклау идеясе. Шулай булгач, минем бу ибтидаи мәктәпләремез өчен китап сайлаганда һәр нәрсәдән алда тотачак идеям – китапның дини вә милли рухта язылганлыгына соң дәрәҗә дикъкать итүдер. Шуның өчен мин алдымдагы китаплар арасыннан теле, ифадәсе[670] гаять җиңел, дини вә милли рухта язылган хикәяләрдән, милли ганганәләремезне[671] җырлаган шигырьләрдән төзелгән китапларны эзләдем. Ләкин, мәгаттәәссеф[672], илле биш данә кыйраәт китабы эчендә бу рухта язылган бер китап булсын, тапмадым. Юкса, бездә булып та, «Эш» китапханәсендә булмадымы? Бу китапларның күбесе Крылов басняларының, Толстой хикәяләренең бозык тәрҗемәләре иде. Бу кыйраәт китапларының кайберләрен бер-беренә чагыштырып карадым. Араларындагы аермаларны ялгыз исемләренең вә мөәллифләренең башкалыгында, хикәя тәртибенең үзгәлегендә вә тәрҗемәләрнең дөрес вә ялгышлыгында таптым. Икенче тәгъбир илә әйткәндә, Толстой илә Крыловның Васька илә Санькага дип теккән пиджакларны безем бер мөәллиф әфәнде Гайнетдингә кидергән, икенчесен Шәмсетдингә... әмма пиджак гайн[673] пиджак!? Хәтта кайберләрендә шундый хәлләргә очрала ки, ифадәсен[674] түгел, исемнәрен генә булса да үзгәртергә лязем[675] күрелмәгән. Гайн илә копия иткән. Менә шуннан яңгырлы елдагы гөмбә шикелле бездә мөәллифләр күбәюенең серен аңладым. Табигый, һәрбер инсаниячек[676] икмәкне табарга мәҗбүрдер. Ләкин һәрбер гади кешенең безнең иң мөһим мәсьәләләремездән булган кыйраәт китапларымызны бугазына васита[677] кылуы милли бер җинаятьтер.

Вакыйган бөтенләй юк суи зан[678] итеп булмый, бәлки бу илле биш әфәнде эчендә милләтенә бөек бер мөкаддәс[679] хезмәт итү нияте илә каләм уйнатканнары да бардыр. Ләкин бу әфәнделәр һәр нәрсәдән әүвәл шуны хәтерләреннән чыгармаска тиешле иде: ибтидаи мәктәпләр безнең милли нигеземез. Аның беренче нигез ташы кыйраәт китапларыдыр. Бу нигез ташын башлап салучылар һәрхәлдә яңа гына каләм уйнатмак тәҗрибәсенә башлаган

---

[669] Мәүҗүд – яшәеш, барлык.
[670] Ифадә – аңлату, аңлатып бирү.
[671] Ганганә – сүзнең кешедән кешегә күчүе; сүзне кешедән кешегә күчерүчеләр.
[672] Мәгаттәәссеф – үкенечкә каршы.
[673] Гайн – бөтенләй, үзе, нәкъ үзе.
[674] Ифадә – аңлату, аңлатып бирү.
[675] Лязем – тиеш, кирәк.
[676] Инсан – кеше, адәм.
[677] Васита – эш, гамәл.
[678] Суи зан – начар уй.
[679] Мөкаддәс – изге, мөһим.

эфәнделәр булмастан, милләтнең бабасы саналган гали мәгълүматлы моктадир[680] адәмнәремез булырга тиешләр.

Бөек Исмәгыйль бәк Гаспринский безгә ысуле саутия[681] үгрәтте. Ун ел «Һәфтияк»[682] вә «Корән Кәрим» күтәреп йөреп тә, укый-яза белмәү хурлыгыннан милләт балаларын коткарды. Хәзер бөек Исмәгыйль шәрафәтендә[683] һәрбер ибтидаи мәктәптәге милләт балалары укый-яза беләләр. Ләкин алар милли тәрбиядән мәхрүмдерләр. Инде аларны татар угылы, мөселман итеп чыгару өчен кулларына дини вә милли рухта язылган кыйраәт китаплары бирергә кирәк. Моны эшләп чыгару вазыйфасын бөек Исмәгыйль үзеннән соңгы бөекләргә калдырып китте.

Шул бөекләремез кайда соң?!

Троицк

*«Тормыш», 1915, 28 гыйнвар.*

***Хәтимә-Нәзифә***[684]

**Кыз балаларны яшьли укудан алу**

Бер халыкның дөньяда сәгадәт[685] вә рәхәт яшәве өчен иң беренче лязем[686] булган нәрсә – укымак, белмәк, вә шул белгән берлә файдаланмактыр. Шулай ук бер милләтнең тәрәккый итүе[687] өчен ул милләтнең һәр җәһәттән мәгарифле вә мәгълүматлы хадимнәргә[688] бай булуы ляземдер. Әгәр чынлап дикъкать берлә карасак, бу икенең соңгысы өлгесенә һич аерылмаслык итеп бик нык бәйләнгәнне күрәмез. Нинди генә милләтне алмыйк, аның алга китүе «белем» вә «тырышлык» аркасында гына мөмкин икәне бик ачык күренә. Шулай булгач, безгә милләтемезне алга йибәрү бары безнең уку вә белүемез вә аңар һәр җәһәттән мәгарифле вә мәгълүматлы хадимнәр йитештерү берлә генә булачак.

Мәгарифле вә мәгълүматлы хадимнәр ничек вә кайдан йитешәчәкләр? Әлбәттә, хатыннарымызның уку вә белү юлында атлаулары вә Ходай тарафыннан бирелгән үзләренең киң хокуклары берлә файдаланулары аркасында гына. Шулай булгач, безгә мөмкин кадәр ирләремездән артык, хатыннарымызның укуына иҗтиһад итәргә[689] кирәк. Нинди генә юл берлә

---

[680] Моктадир – көчле, сәләтле.

[681] Ысулы саутия – аваз ысулы.

[682] «Һәфтияк» – Коръәннең җидедән бер өлешен эченә алган китап.

[683] Шәрафәт – олы дәрәҗәлелек, хөрмәтлелек.

[684] Хәтимә-Нәзифә – мөгаллимә, Мәскәү мөслимәләр комитеты рәисе, татар вакытлы матбугатында тәрбия мәсьәләләре турында мәкаләләр язган.

[685] Сәгадәт – бәхет, рәхәтлек.

[686] Лязем – тиеш, кирәк.

[687] Тәрәккый итү – алга китү.

[688] Хадим – хезмәтче.

[689] Иҗтиһад итү – тырышу.

булмасын, аларның тәрәккый итүләренә һич каршы килмәскә, бәлки киресенчә, бу юлда гайрәт итеп, аларга һәр яктан ярдәмдә булынырга тиешле.

Бер милләтнең хатыннары никадәр хөр вә тәрәккыйга малик булса[690], ул милләт шулкадәр үк мәсгуддер[691]. Хәзер, әлхәмдүлилләһи, безнең дә күп йирдә кызларымыз өчен мәктәпләр вә анда укучы туташларымызның саны киткән саен артып тормактадыр. Болар һәммәсе дә күңелгә сөенеч вә шатлык бирә. Шуның берлә бергә үк, күңелне ачыттыра торган нәрсәләр дә очрый. Болар, әлбәттә, барысы да үземезнең аңламавымыз вә каршылыгымыз аркасында килгән нәрсәләр. Кызларымызны мәктәпләргә укырга бирәмез. Анда укуның тәменә кереп, тырышып кына укыганда, яшьләре 14–15кә йиттеме, «зур булганнар, бар укулары йитәр», дип укудан туктатып, шул мәгъсум[692] балаларымызны киләчәктәге сәгадәттән мәхрүм итәмез. Ата-анасының шундый мөгамәләсенә каршы үзендә көч вә куәт сизмәгән яшь кызлар ихтыярсыз аларның сүзенә буйсынып, мәктәпне калдырып, укудан аерылырга мәҗбүр булалар.

Ярый ла, кайсы-берсе үзендә бераз куәт сизеп вә аңлап, бу юлда кулыннан килгән кадәр тырышып, ата-анасына ялына-ялварып булса да тыңлатып, тагы берәр елга укуны суза. Күбесе үзендәге көчсезлек яки ата-анасының каршылыгы аркасында берни дә эшли алмый, укуны ташлап мәхрүм кала. Шундый кызларның хәле, әлбәттә, бик аяныч.

Әгәр без, милләтемезнең тәрәккый итүене вә балаларымызның сәгадәттә яшәүләрене эстәсәк, кызларымызны вакытсыз укудан тыю урынына, бу юлда үземез тырышлык итеп, мөмкин кадәр аларның «белем» арттыру вә укуларына иҗтиһад итәргә кирәк. Аларның үсүләренә карамый, бәлки үскән вә яшьләре арткан саен, ата вә аналар артыграк тырышлык итеп, аларның укуларында кимчелек күрсәтмәскә тиешле. Укуны дәвам иттерү өчен яшь артуның ни зарары бар? Зур булса да, алар урамда йөрмәенчә тормый, йөрергә чыга вә кирәк йомышына бара. Мәктәпкә барып кайту урамда эшсез йөрүдән мең мәртәбә артык.

Бик күп ата вә аналар «зур булды», дип, балаларыны мәктәптән алалар. Әмма үз йомышлары берлә кыз балаларны тиешле-тиешсез йөртүдән һич тартынмыйлар...

Балаларымызны мәктәпкә йөртүдән тыю берлә без аларны начарлыктан саклый алмыймыз. Бәлки киресенчә, мәктәптә кирәгенчә укып, күзләре ачылса, алар үзләре яхшыны яманнан аерып, безнең урынсыз саклавымызга хаҗәтләре дә калмас. Никадәр зур булсаң да, укуның һичбер гаебе вә ояты юк. Бәлки, иң укыр вакытларында «зур булганнар», дип кызларымызны яшьли 14–15кә йитәр-йитмәс вакытта укудан туктату иң зур гаеп вә гафу ителмәслек бер кимчелектер.

---

[690] Малик булу – ия, хуҗа булу.
[691] Мәсгуд – бәхетле, игелекле.
[692] Мәгъсум – гөнаһсыз, керсез.

Әгәр без милләтемезне сөйсәк, вә аның алга китүенә чын күңелемез берлә эстәсәк, кызларымызның укуларына бөтен көчемезне сарыф кылмак, аларны бер 3–4 ел укыткач та, «зур булдылар, безнең балалар остазбикә булачаклары түгел, яза-укый белсәләр ярар», дип, аларны мәгариф юлыннан аермыйк. Яшьләре теләсә ничәгә генә йитмәсен, аңар илтифат итмик[693], бары укысыннар, белсеннәр, милләтемезгә чын хадим[694] булсыннар вә һәр җәһәттән хадимләргә сусап тора торган милләтемезгә киләчәктә хөр, җөсарәтле[695] вә мәгълүматлы балалар йитештерүче булыр. Шул чакта гына без мәсгуд яшәрмез һәм милләтемез дә тереклек итәр.

*«Шура», 1915, №12, б.373–374.*

***Хәтимә-Нәзифә***

## Кызлар мәктәпләренең ислахы[696]

Хәзерге көндә кирәк шәһәрләрдә, кирәк авылларда булсын, күп йирдә ирләр мәктәбе кебек үк, кызлар мәктәбе дә елдан-ел арта бара. Һәркем диярлек кызларга да, ирләр кебек үк, укуның бертигез кирәклегене аңлаган, һәркем шул юлда тырыша. Моннан берничә еллар элекке хатыннарның уку юлында булган хәрәкәтләренә әйләнеп карасак, никадәр зур аерма күрәмез. Бу үзгәрешләр, әлбәттә, хатын-кыз өчен сөенмәслек эшләрдән түгел. Ирләребез гыйлем-мәгърифәт юлында никадәр алда булып та, хатыннарымыз аның түбәнге беренче баскычында гына торсалар, моннан, әлбәттә, киләчәк яшь буыннарымыз өчен һичбер файда булмаячак. Киләчәктә милләт хадимнәрене[697] йитештерүчеләремез шул мәктәпләрдә укучы кызларымыздыр.

Шуларның барысыны искә алып һәм милләтемезнең истикъбалене[698] төшенеп, безгә ирләр мәктәбеннән бигрәк, кызлар мәктәбенә әһәмият биреп, мөмкин кадәр аларның ислахы хакында тырышырга кирәк. Хәзерге вакытта, әлхәмдүлилләһи, һәр мәктәптә диярлек үзенә махсус програм бар. Һәркайсында тәртип берлә укытыла. Шулай да булса, програмнар кирәгенчә төзелгәнме? Алар бераз ислахка мохтаҗ түгелләрме? Әгәр аларны үзгәртергә тиеш табылса, ничек вә кемнәр тарафыннан үзгәртелергә кирәк?

Чынлап уйлаганда, бу хатын-кыз өчен никадәр мөһим бер мәсьәлә булса, шулай ук ирләремез өчен дә әһәмиятсез түгелдер. Бу мәсьәләнең хатыннарга тәгаллеге[699] никадәр зур булса, ирләргә тәгаллеге шулай укдыр. Шуңар күрә, бу мәсьәлә ир вә хатыннар өчен гомуми бер мәсьәлә итеп каралырга тиеш. Әгәр кызлар мәктәбемез никадәр тәртипле, никадәр програмы киң вә

---

693 Илтифат итү – игътибар итү.
694 Хадим – хезмәтче, хезмәткәр.
695 Җөсарәт – батырлык, кыюлык.
696 Ислах – реформа, үзгәреш.
697 Хадим – хезмәтче, хезмәткәр.
698 Истикъбаль – киләчәк, булачак.
699 Тәгаллекъ – бәйләнеш.

кирәгенчә төзелгән булса, шулкадәр анда яхшы вә мәгърифәтле аналар йитешәчәк һәм шулай ук киләчәктә милләтемезнең терәге булачак балалар да шул аналар кулында тәрбияләнәчәк.

Алма агачыннан ерак төшми, диләр. Әгәр хәзер ана булачак кызларымыз мәктәпләрдә кирәгенчә тәрбия алмасалар, алардан туган балалар нинди тәрбия күрәчәкләр вә ул балалардан милләт ни көтәчәк.

Бәлкем боңа каршы «һәр мәктәпнең програмы бик яхшы, шуннан артык төзәтүгә хаҗәт юк», диючеләр дә булыр. Шулай да булса, яхшыны тагы да яхшылайтсак, нур өстенә тагы да нур булып төшмәсме? Әгәрдә киңәйтергә вакыт мөсагадә итми[700] дисәк, ул чакта вакыт сыйдырырлык кадәр киңәйтеп (анысы булса-булмаса да, ул кадәр үк әһәмиятле түгел), бигрәк ислах итәргә тырышырга кирәк. Әле безнең көн мәктәпләрдә (кайсы берсене чыгарганда) програмнар вакыт сыйдырырлык кадәр дә кирәгенчә куелмаган.

Фәннәр укылса да, югарырак сыйныфларда күбрәк гарәпчә укытуга әһәмият бирелә.

Боннан гарәпчә кирәкмәс дигән сүз аңлашылмасын, мин аны әйтергә теләмим. Ул да кирәк. Шулай да булса, аны бераз киметеп, мөмкин кадәр башка кирәкле фәннәр кертелсә, вә аның өстенә кызларның киләчәктәге тормышлары өчен тәгаллеге булган башка мөһимрәк нәрсәләр арттырылса, тагы да яхшырак булмас иде мени?

Хәзерге көндә бит мәктәпләремез – безнең бөтен терәгемез. Кызларымыз ни алса да, ни белсә дә, шул мәктәпләремездән алалар. Мәктәптән чыгу берлә алар ана була, вә шуның берлә бергә үк мөстәкыйль тормышка башлый. Әгәр алар мәктәптә кирәгенчә тәрбия алмаса, кирәгенчә белмәсә, ул шул зур вазыйфаны ничек үти, ничек үзенең гаиләсене бәхетле итәр? Башка милләтләрне алсак, анларда мәктәпләрдән башка да хатын-кызның тәрбиясенә зур әһәмият бирелә. Хатын-кызга махсус журналлар һәм тормышка тәгаллеге булган вакытлы гына лекцияләр укыла. Хәзерге көндә бит әле бездә андый нәрсәләр юк, бәлкем киләчәктә һәммәсе дә булыр. Шулай да киләчәкне генә көтеп тормый, икенче юл берлә булса да, кызларымызны чын ана ясап йитештерергә вә аларны мөстәкыйль тормышка тиешенчә хәзерләргә кирәк. Боңар бер юл булса, ул да мәктәпләремездер. Шуңар күрә мәктәпләремезнең чын-чыннан ислахына керешеп, аларны кирәгенчә юлга салсак, шәт бераз көтелгән кадәр аналар йитешер һәм милләтемез дә кирәгенчә алга атлар иде.

*«Вакыт», 1915, 14 июль.*

## Авыл кызларының теләге

Верхнеурал өязеннән Тамьян волосте Габделҗәлил[701] исемле авылымызда кыйраәтханә[702] ачылмыш иде. Бу кыйраәтханәнең ачылуы без яшүсмер кызлар өчен бигрәк тә файдалы булды. Атнага өч мәртәбә кыйраәтханәгә

[700] Мөсагадә – мөмкинлек бирү; булышу, ярдәм итү.
[701] Хәзер Башкортстан Республикасының Әбҗәлил районында.
[702] Кыйраәтханә – уку өе, китапханә.

кереп, теләгән китабымызны сорап алып укыймыз. Кыйраәтханәгә керү нәүбәтемез[703] булмаган көннәрдә, өйләребезгә алып кайтып укыймыз вә файдаланамыз. Без, яшь кызлар, кыйраәтханәгә кереп файдаланырлык гыйлемне тәртип белән укыла торган мәктәпләрдә укып алганымыз юк. Фәкать ул җирдәге абыстайлардан берничә еллар «Бәдәвам»[704] вә «Сөбател-гаҗизин»[705] кеби китаплар укыганда эләгеп калган бер гыйлем. Безнең бу берничә еллар «Бәдәвам», хикәя китапларын укып файдаланырлык түгел. Шуның өчен дә без, яшүсмер кызлар, мәктәпләр башлыгы имамнарымыздан вә һиммәт[706] иясе байларымыздан без бичараларны да исләренә алып, кызларга берәр мәктәп салдырып бирүләрен вә тәртип берлән укыта торган мөгаллимә китерүләрен үтенәмез.

Укучы кызлар:

Сабира Галиева, Мөкәррәмә Фәттахетдинова, Хәдичә Муллашәйхелсәләмова, Сафинә Мөхәммәдҗанова, Нуркамал Мәһдиева.

*«Тормыш», 1916, 29 март.*

---

[703] Нәүбәт – мөмкинлек, чират.

[704] «Бәдәвам» китабы – татар дини-дидактик әдәбият үрнәге; мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланылган.

[705] Суфи Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин» әсәре татар мәктәп һәм мәдрәсәләрендә төрки телдән ярдәмлек буларак файдаланылган.

[706] Һиммәт – тырышлык.

# II БҮЛЕК

# «ДИНИ РУХ, МИЛЛИ ТОЙГЫ БИРӘ ТОРГАН ТӘРБИЯ ЙОРТЫНДА УКУЧЫ КЫЗЛАР»

Хатын-кыз мәктәпләре, аларның ачылу тарихы, эшчәнлеге, мөгаллимәләре һ.б.

## [Эстәрлетамак шәһәрендә…]

Эстәрлетамак шәһәрендә мөгаллим Нәҗметдин әфәнде Хәмзин яздыгына күрә, мәзкүр[1] шәһәрдә имам вә мөдәррис Мөхәммәтгариф хәзрәт кызларга махсус мәктәп тәэсис итеп[2], икътидарлы[3] мөгаллимәләр куеп, күбесе дә фәкыйрь балалары улмак, үзе кызларны укытмыш. Кичен быел сентябрь башында җыелып, укырга башлаган кыз балаларның ошбу ел 17нче апрельдә гомуми сурәттә имтиханнарыны иҗраэ ителмеш[4].

Мәҗлескә хазир улан[5] хатыннар, бикәләр балаларның укуларыннан риза улып, мөнасиб[6] һәдияләр[7] таратмышлар, мөгаллимә вә мөдирәләргә һәм тәхсин[8] вә рәхмәт укып таралмышлар. Гыйбадулла әфәнде Госманов[9] мөгаллимәгә айга ун сум вазыйфа биреп тормыштыр.

*«Вакыт», 1906, 8 июнь.*

## [Уфа шәһәрендә...]

Уфа шәһәрендә мөселман кызларына махсус дини мәдрәсә бина итәр[10] өчен, шәһәр идарәсе «Николаевский» мәйданда урын бирмеш, мәктәп булып тордыгы мөддәттә[11], боның бәрабәренә һичбер налог салыначак дәгелдер.

*«Вакыт», 1906, 17 август.*

[1] Мәзкүр – искә алынган.
[2] Тәэсис итү – кору, оештыру.
[3] Икътидарлы – булдыра алган, көче җиткән.
[4] Иҗраэ итү – үтәү, эшкә ашыру.
[5] Хазир улу – катнашу, килү.
[6] Мөнасиб – яраклы, туры килә торган.
[7] Һәдия – бүләк.
[8] Тәхсин – мактау.
[9] Гыйбадулла Госманов – «Тормыш» газетасы нашире.
[10] Бина итү – нигез салу.
[11] Мөддәт – ара, вакыт.

## [Ислам кыз балаларыны...]

Ислам кыз балаларыны укытыр өчен бер фатир алып, фатир хакыны һәм дә утын мәсарифыны[12] Бәдретдин Назыйров илә Ногман Сабитов үз кесәләреннән тотарга вәгъдә иттеләр. Бонда улан мөгаллимәгә сәүдәгәр Сабирҗан Шәмгулов[13] һәр айга 10 сум вазыйфа бирергә вәгъдә итте.

*«Вакыт», 1906, 19 август.*

## [Казан гәзитәләре...]

Казан гәзитәләре хәбәренә күрә, Яңа бистәдә[14] мөселман кызларыны мөселманча, русча укытырга вә һөнәр үгрәтергә бер мәктәп ачылмыштыр.

***«Вакыт»:***

Заман шулкадәр көчледер ки, хәтта никадәр үзсүзле улан Казан халыкларыны да йиңде.

*«Вакыт», 1906, 3 октябрь.*

## [Мәскәүдә...]

Мәскәүдә Хәбибулла әфәнде яздыгына күрә: беренче мәхәллә хозурында сәүдәгәр Хаҗи Дунаев кызы Хәдичә ханым үзләренең ханәләрендә ахунд Агиев тарафыннан рөхсәт алып, кыз балаларны укыта имеш. Мәзкүр әфәнде исә: «Имде балаларымызга уку ишеге ачылды. Ир балаларымызны һәм ысул җәдидә[15] илә укытырга вә бер мөгаллим улса да китерергә ахунд хәзрәт рөхсәт итсә, гүзәл улыр иде», – диядер.

*«Вакыт», 1906, 3 октябрь.*

## [Оренбургтагы хосусый кызлар гимназиясендә...]

Оренбургның хосусый кызлар гимназиясендә бу сәнә өч мөселман кызы укымактадыр. Мөселманча дин дәресләре укытыр өчен мөәзин Заһидулла әфәнде Хәйруллин тәгаен улынмыштыр. Аның жалуниясенең беразы гимназия идарәсеннән, вә беразы укучы кызларның аталарыннан биреләчәкдер. Бу гимназиягә мөселманча мөгаллим куйдырырга иҗтиһад итүче[16] табибә Разыя ханым[17] җәнабләредер.

*«Вакыт», 1906, 5 октябрь.*

---

[12] Мәсариф – тотылган акчалар, чыгымнар.

[13] Сабирҗан Сәйфетдин улы Шәмгулов – Уфа сәүдәгәре, химаяче, кибетләр, кунакханәләр тоткан. Ярлы мөселманнарга ярдәм җәмгыяте идарәсе әгъзасы. Революциядән соң Мәскәүдә кибет ача.

[14] Яңа Бистә – Казан шәһәренең тарихи үзәгендә, Иске Татар бистәсенең көньяк-көнчыгышында барлыкка килгән бистә.

[15] Ысул җәдидә – аваз ысулы белән укыту.

[16] Иҗтиһад итүче – тырышучы.

[17] Сүз беренче татар табибәсе Котлыярова-Сөләйманова Разыя Таҗетдин кызы (1866–1923) турында бара.

## [Мөселман җәмгыяте тарафыннан...]

Мөселман җәмгыяте тарафыннан Форштадта[18] ачылачак кызлар мәктәбендә укытыр өчен шул мәктәпнең попечителе Шакир әфәнде Мөлеков[19] тарафыннан, Адамова кызлар мәктәбендә[20] икмаль итмеш[21] бер кыз мөгаллимәлеккә тәгаен кылынмыштыр.

*«Вакыт», 1906, 17 октябрь.*

## [6нчы декабрьдә...]

6нчы декабрьдә чәршәмбе көн кич сәгать 5 тә мөселман әгъзаларының гомуми җыены улды. [...]

Җәмгыятьнең рәисе Фатыйх Кәримов[22]: җәмгыять тарафыннан ачылмыш ике кызлар вә бер ирләр мәктәбендәге уку вә тәртипләрене карар өчен бер гомуми җәмгыять тарафыннан тәгаен ителгән дүрт-биш кешенең бонларны барып карадыкларыны, Форштадтагы ирләр һәм кызлар мәктәбене ярарлык вә Банный озеродагы[23] кызлар мәктәбене ислахка[24] мохтаҗ тапдыкларыны бәян иттегеннән соң, никадәр вак балалар булса да, кызлар мәктәбене ирләрнең барып караулары халык арасында сүз чыгуга сәбәп булдыгы җәһәте илә, бондан соң ул кешеләрнең анда бармаячакларыны сөйләде. Җәмәгать кызлар мәктәбене хатыннар вә абыстайлар аркылы тәфтиш иттерүне[25] мәгъкуль[26] табып, боны советка тапшырды. […]

*«Вакыт», 1906, 9 декабрь.*

***Җиһангир***

## [«Вакыт»та «Иркутск шәһәрендәге…»]

«Вакыт»та: «Иркутск шәһәрендәге мөселман кызлары мәктәбе, укытучы табылмадыгыннан, ябылмыштыр», – дия язылмыштыр.

Иркутскида кызларга махсус мәктәп әүвәлдән юк булып, кызлар остазбикәләрнең казан тирәсенә җыелышып укый, ләкин бернәрсә белә алмайлар иде.


---

[18] Форштадт – Оренбург шәһәренең бер өлеше.
[19] Шакир Садыйк улы Мөлеков (1881–1938).
[20] Фатыйма Адамова мәктәбе.
[21] Икмаль итү – тулысынча җитлекле итү, камилләштерү.
[22] Фатыйх Гыйльман улы Кәримов (1870–1937) – җәмәгать эшлеклесе, педагог, журналист, «Вакыт» газетасы мөхәррире.
[23] Оренбург шәһәрендә.
[24] Ислах – үзгәртү, яхшырту.
[25] Тәфтиш иттерү – тикшерү.
[26] Мәгъкуль – урынлы, аңлаешлы.

1905нче елда Шәфигуллин җәнабләре[27] кызлар өчен махсус бер мәктәп ачып, яхшы мөгаллимә табылмаганлыктан, бу кызлар да имам Лотфи вә мөгаллим Вафа әфәнделәр тарафыннан укытыла иделәр. Бу мәктәптә алты ай укыган кызлар бик яхшы имтихан биреп, күрергә килүчеләр тарафыннан афәриннәр ишеттеләр. Ләкин бу ел бәгъзе надан муллаларның «Кызларның уку, язу белүе шәригатькә хилаф[28]», – дигән сүзләренә алданып, бәгъзе кешеләр кызларыны яшь мөгаллимнәрдән укытуга каршы тордыкларыннан, мәзкүр[29] мәктәп бер ай кадәр ябылып торган иде. Ләкин соңра, ноябрьдә бу мәктәп ачылды. Иркутск мөселманнары арасына котыртып, фетнә салып йөрүчеләрне мәхәллә халкы үз араларыннан чыгарганлык сәбәпле, боннан соң бу мәктәпнең тыныч сурәттә дәвам итүе шөбһәсездер.

Иркутск.

*«Вакыт», 1907, 18 гыйнвар.*



Иркутск кызлар мәктәбендә укучы шәкертләр.
Уртада, сул якта Нәфисә ханым Шәфигуллина
*(«Сөембикә», 1914, №9)*

---

[27] Бертуган Заһидулла һәм Шәйхулла Шәфигуллиннар – атаклы Иркутск сәүдәгәрләре, химаячеләр, чыгышлары белән хәзерге Татарстанның Акъегет авылыннан. Заһидулла Шәфигуллин (1840–1919) 1870 елда туган авылында ирләр мәктәбе, 1872 елда кызлар мәктәбе ача. Шәйхулла Шәфигуллин (1854–1919?) – II гильдия сәүдәгәр, Иркутск шәһәр думасы депутаты, 1905 елда кызлар мәктәбе ача. Бу мәктәпнең назыйрәсе һәм мөгаллимәсе Ш.Шәфигуллинның хатыны Нәфисә ханым Шәфигуллина була.

[28] Хилаф – каршы, кире, тискәре.

[29] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.

### [Орск шәһәрендә...]

Орск шәһәрендә Газизә ханым идарәсендә улан кызлар мәктәбендә 50дән артык кыз балалар укып, ошбу гыйнвар 6нчы көнендә мөслимәләр хозурында имтиханнары улмыш. Уку, язу, тәҗвид, гыйльме хисап вә мөһиммат[30] диния дәресләреннән имтихан бирмешләр вә соңра да чигеш, нәкышь[31], челтәр кеби кул һөнәрләреннән эшләр куштырмышлар.

*«Вакыт», 1907, 20 гыйнвар.*

***Закир Ишмөхәммәдов***

### Хөрмәтле мөхәррир әфәнде!

254нче номер «Вакыт»та мохбиреңез «Әгерҗедә Каюм хәзрәт әһеле[32] Заһирә ханымның кыз балаларны програм тәртип итеп, яхшы укыта башлады...», – дия язмыштыр[33].

Мөселман дөньясында кызлар мәктәбе түгел, хәтта програм вә тәртип илә укылмакта улан ирләр мәктәпләрене дә күрмәдегем сәбәпле, мәзкүр[34] мохбиреңездән вә яки Заһирә ханымның кәндүсеннән[35] «Вакыт» аркылы җавап язмакларыны үтенәдер идем ошбу хосусларда:

1) мәктәбеңездә кабул origin ителмеш програм ни шәйдән[36] гыйбарәттер вә ниләр укытасыз?

2) мәктәбеңездә ничә сыйныф бар?

3) каю сыйныфларда ниләр укытыладыр?

4) мәктәбеңездә дин дәресләре генәме укыладыр, юкса шәл бәйләү, калфак чигү кеби кул һөнәрләре дә, җәгърафия, хисап вә тарих кеби дөнья гыйлемнәре дә укыламы?

Гәрчә җәридәләремездә[37]: «фәлән мәдрәсәдә уку тәртипкә салынды вә програм кабул ителде», дия язылса да, бу «ысул җәдидә» нидән гыйбарәт вә «програм» ни кеби шәй идеге хакында мәгълүмат күрмәдегем сәбәпле, бу илә сөальләр язып, җавапны көтеп торырга мәҗбүр улдым.

Әгәр дә һәрбер мәктәп тарафыннан үзләренең програм вә тәртипкә салу рәвешләре язылынып чыкса, мәҗмүгыннан[38] җыеп гүзәл програм чыгармак бәлки мөмкин улыр иде.

Омск.

*«Вакыт», 1908, 5 гыйнвар.*

---

[30] Мөһиммат – әһәмиятле, кирәкле.
[31] Нәкышь – бизәк, рәсем, сурәт.
[32] Әһеле – хатыны.
[33] [Әгерҗедән сәүдәгәр Гыйззәтулла әфәнде...] // Вакыт. 1907. 9 декабрь.
[34] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.
[35] Кәндү – үз, үзе.
[36] Шәй – әйбер, нәрсә.
[37] Җәридә – газета.
[38] Мәҗмугъ – барлык.

## [Уфа өязе…]

Уфа өязе Шәрип волосте Гомәр авылыннан[39] язалар:

«Авылымызның 2нче мәсҗет имамы Миңлеислам Госмановның иҗтиһады[40] саясендә[41], ошбу сәнә авылымызда кыз балалар мәктәбе ачылды вә 40тан зиядә[42] кызлар җыелып, тәртипле ысул илә уку вә язу үгрәтелмәккә башланды. Мәхәллә кешеләренә мәшәкатьсез йорт алынды. Имам әфәнденең әһлиясе[43] Мәрьям ханым бер тиен вазыйфасыз уларак, һәр көн иртә сигез сәгатьтән көндез икегә кадәр иҗтиһад илә укыта. Балалар да яхшы гына укып укый-яза белергә башладылар. Уфалы мөхтәрәм Хәсән әфәнде Кәримов ибтидаи[44] ике-өч сыйныф өчен кирәкле китапларны да ихсан итте[45]. Инде шул хезмәтләргә каршы ни әйтергә кирәк? Диячәксеңез ки: әлбәттә, рәхмәт әйтергә вә тәшәккер укырга[46] тиеш. Хәлбуки[47] мәхәлләнең бәгъзе бер надан, мөтәгассыйб[48] вә фикерсез адәмнәренең котыртулары буенча, үз файдаларын үзләре аңламаган бәгъзе бер бичаралар: балаларымызга әллә нәстәләр өйрәтеп маташмасыннар, парталарга утыртып, кара тактага яздырып укытмасыннар, безнең балалар марҗа кызлары түгел, безнең кызларымыз язу белеп писарь булачак, вә хисап белеп конторщик булачак түгел, «Әфтияк»[49] иҗеге укылса йитәр, дип шау-шу чыгаралар. Фәкать бәрәкәт бирсенгә: мәктәпнең дөньяга килүенә сәбәп булган адәм игътибарлы, ачык фикерле, чын мөселман калебле[50] вә иманлы бер зат улдыгыннан, үз тамырларына балта чабучы бу мескеннәр илә һич низаглашмый, үзенең гайрәт вә мәтанәтеннән[51], халыкка вә хаклыкка хезмәтеннән аерылмый. Алай сөйләүчеләрне мәгъзүр күреп[52], илтифатка алмыйдыр[53]».

*«Вакыт», 1908, 15 гыйнвар.*

## Бубый

Вятка губернасы Сарапул өязе Бубый[54] карьясеннән[55] язалар:

---

[39] Хәзер Башкортстанның Кушнаренко районына керә.
[40] Иҗтиһад – тырышу.
[41] Сая – күләгә, ышык.
[42] Зиядә – арту, күбәю.
[43] Әһлиясе – хатыны, тормыш иптәше.
[44] Ибтидаи – башлангыч.
[45] Ихсан итү – ярдәм итү, булышлык итү.
[46] Тәшәккер уку – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.
[47] Хәлбуки – ләкин.
[48] Мөтәгассыйб – фанатик.
[49] «Әфтияк» («Һәфтияк») – Коръәннең җидедән бер өлешен эченә алган китап.
[50] Калеб – йөрәк, күңел.
[51] Мөтанәт – ныклылык, чыдамлылык.
[52] Мәгъзүр күрү – гозерле.
[53] Илтифатка алу – әһәмият бирү.
[54] Хәзерге Татарстанның Әгерҗе районындагы авыл.
[55] Карья – авыл.

«Бубый карьясе бу соң елларда үзенең мәктәп-мәдрәсәләр вә мөдәррисләренең гайрәтләре саясендә[56] күп йирләрдә танылды. Бу карьядә итмәктә улан затлар Истанбул мөлкиясендә[57] укымыш Гобәйдулла әфәнде[58] һәм дә әсәрләре илә мәгълүм борадәре[59] Габдулла әфәнделәрдер[60]; берничә еллардан бирү мәдрәсәне тәртип вә низамга куеп килмәктә һәм бу тугрыда соң дәрәҗәдә иҗтиһадларыны[61] сарыф итмәктәләрдер; [...] һәм кызлар мәдрәсәсенең һәр әсбабы йирендә улыб, фөнүн җәдидәдән[62] кирәкле шәйләр[63] һәм тегү-чигү эшләре вә өстәгеләрә русча лисан[64] укытылмактадыр. Русчага махсус мөгаллимә бар. Һәр тарафтан килгән кызларның микъдары 150 гә кариб[65] улып, иҗтиһад илә укытмакта улан мөгаллимәләр шу[66] мөдәррис әфәнделәрнең әһлияләре[67] вә һәмширәләредер[68]. Мөгаллимнәргә һәр айга 200 рублядән зиядә[69] жалуния сарыф улынмактадыр, мәсҗет вә мәдрәсә файдасына улыр диярәк, бондан өч сәнә мөкаддәм[70] мәсҗеттә сандык куймышлар иде. Хәзерендә сандыкның мең рублядән зияда акчасы бар, һәм дә Бубый байларының зәкяте[71] акчалата алынып, мәдрәсә файдасы өчен банкка салынмактадыр; җомгаларда хотбәләр өч сәнәдән бирле үз лисанымызда укылып, гыйлем юлына ярдәменнән, гыйлемә тәргыйб[72], уку вә балалар тәрбиясеннән әсәрле сурәттә сөйләнмәктәдер.

Җәнаб Хак бу кеби эшлекле кешеләремезне милләтемездә күп-күп әйләсен, Бубый илә безнең Әгерҗе карьясенең[73] арасы мәсафә[74] җәһәтеннән 5 кенә чакрым булса да, гыйлем, иҗтиһад вә әхлак төзеклеге арасында йөзләрчә

---

[56] Сая – күләгә, ышык.

[57] Мөлкия – хөкүмәткә караган.

[58] Гобәйдулла Габделгаләм улы Нигъмәтуллин-Бубый (Гобәйдулла-Мөхәммәдфәйзи, 1866–1936) – педагог, Иж-Бубый авылы мәдрәсәсе җитәкчесе һәм мөдәррисе, дәреслекләр авторы.

[59] Борадәр – ир туган, иптәш.

[60] Гобәйдулла Габделгаләм улы Нигъмәтуллин-Бубый (1871–1922) – педагог, дин галиме, дәреслекләр авторы.

[61] Иҗтиһад – тырышлык.

[62] Фөнүн җәдидә – яңа фәннәр.

[63] Шәй – әйбер, нәрсә.

[64] Лисан – тел.

[65] Кариб – якын.

[66] Шу – шул.

[67] Әһлиясе – хатыны, тормыш иптәше.

[68] Һәмширә – кыз туган, кыз кардәш.

[69] Зиядә – арту, күбәю.

[70] Мөкаддәм – элек, алда.

[71] Зәкят – ислам динендә бай, сәүдә белән шөгыльләнүчеләргә еллык керемнең 40 тан бер өлеше күләмендә салынган налог.

[72] Тәргыйб – кызыктыру, кызыксындыру.

[73] Татарстандагы шәһәр, Әгерҗе районының административ үзәге.

[74] Мәсафә – ике урын арасындагы ераклык.

чакрым аермалар бар! Мәктәпләр вәйран[75], имамнар хәйран, байлар өметсез бер хәлдә, туңмышлар да калмышлардыр!».

*«Вакыт», 1908, 2 февраль.*

## [Сарапул өязе…]

Сарапул өязе Әгерҗе карьясендә[76] Каюм хәзрәт әһлиясе Заһирә ханымның ысулы саутия[77] илә кыз балалар укытуына вә тегү-чигү эшләре үгрәтүенә тәшәккер итәрәк[78], 14 кеше кул куеп, идарәмезгә хат язмышлардыр.

*«Вакыт», 1908, 5 февраль.*

## [Атбасардан[79]…]

Атбасардан хәбәр бирелдегенгә күрә: Мөгаллимнең русча вә мөселманча укымыш рәфыйкасе[80] кызлар мәктәбе ачып, ысулы саутия илә укытырга башлаган. Корбан гаетендә хосусый имтихан ясаган. Күрергә килгән хатын-кыз таифәсе[81] балаларның яхшы җавапларын ишетеп, пәк мәмнүн булганнар[82]. Беренче сыйныфтагы 7–8 яшьлек балалар өч ай эчендә укырга-язарга үгрәнгәннәр. Мөгаллимә өченче сыйныф кызларына хәфтәдә[83] 2 көн (дүшәмбе вә пәнҗешәмбе көннәре) тегү вә бәйләү кеби кул эшләре үгрәтмәктәдер. Ир балалар мәктәбендә мөгаллим әфәнде җәгърафия, тарих, хисап, сарыф төрки[84], инша[85], хөсне хат[86] кеби кирәкле вә мөһим нәрсәләр укытмактадыр.

*«Вакыт», 1908, 5 февраль.*

## [Спас өязеннән…]

Спас өязеннән язылдыгына күрә: Бер су буенда Олуг, Урта вә Түбән Тигәнәле[87] атлы өч мөселман авылларының берсендә дә рәтле мәктәп юктыр. Кызлар тәрбиясе бөтенләй зәбун[88] хәлдәдер. Имамнар укыту мәсьәләсенә күп әһәмият бирмиләр, мужиклар үзләре боның әһәмиятене белмиләр. Бонлар

---

[75] Вәйран – ватык, җимерек.
[76] Карья – авыл.
[77] Ысулы саутия – аваз ысулы.
[78] Тәшәккер итү – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.
[79] Атбасар – хәзерге Казахстанның Акмулла өлкәсендәге шәһәр.
[80] Рәфыйка – иптәш, тормыш иптәше.
[81] Таифә – төркем, җәмәгать.
[82] Мәмнүн булу – шатлану, шат булу.
[83] Хәфтә – атна.
[84] Сарыф төрки – төрки телләрнең морфологиясе.
[85] Инша – язу.
[86] Хөсне хат – матур язу.
[87] Зур Тигәнәле, Урта Тигәнәле һәм Түбән Тигәнәле авыллары – хәзерге Татарстанның Алексеевск районындагы авыллар.
[88] Зәбун – начар, зәгыйфь, әһәмиятсез.

күбесенчә ишаннарга йөреп мөридлек итәләр[89]. Нурлыгата исемле имамның гайрәте саясендә Казан сәүдәгәрләреннән Ибраһим Арслановның[90] һиммәте[91] илә 400гә төшереп бер мәктәп салынмыш вә мөгаллим китертеп бер кыш гүзәл генә укытылмыш исә дә, Чистайда укып чыккан әхлаксыз вә хасид[92] Габдрахман исемле бер имамның ысул саутиягә[93] каршы килеп, халыкның фикерене чуалтуы сәбәпле, бу мәктәпне тәрәккый иттерүе дә[94] бик көчтер. Ошбу заманда да ысул җәдидә бәхәснең дәвам итүенә никадәр тәәссеф улыныр[95].

*«Вакыт», 1908, 5 февраль.*

## [Хвалын өязе…]

Хвалын өязе Мастак карьясеннән[96] язалар:

«Өч мең җан кадәр халкы улан авылымызда кызлар укытыр өчен һич бер рәтле мәктәп юкка күрә, чәчәк кеби яшь балаларымызның гомерләре уку вә укыту эшләреннән хәбәрсез абыстайлар вә карчыклар тирәсендә черемәктә иде.

Хәмед[97] улсын, авылымызның сәүдәгәрләреннән Сөләйман әфәнде Сүнчәләев бер мөгаллимә китертеп, ике сәнәдән бирле кызларымызны ысулы саутия вә тәртип илә укытмактадыр. Әлбәттә, һәр йирдә улдыгы кеби, бездә дә боңа каршы килүчеләр күп булды. Ләкин хаклыкның ахырда өскә чыгачагын белеп, гайрәт ияләре бу сүзләргә колак бирмәенчә, үз эшләрендә дәвам иттеләр.

Инде, авылымызда 4 бүлмәдән гыйбарәт бер таш бина сатылачак улдыгыннан, Сөләйман әфәнде кызлар мәктәбе өчен шуны 800 сумга сатып алып, бер йөз сумны үзе вә 200 сумны бер ханым иганә иттеләр. Боны мәктәп формасында эшләтеп тәмам иттерергә дәхый дә[98] 1,500 сум кадәр акча хаҗәт улдыгыннан, кызлар тәрбиясенең әһәмиятене аңлаган хәйрәт сахибләремез[99] иганәттә булышырлар дия өмет итәмез. Чөнки Сөләйман әфәнде 3–4 меңле бер авыл бае улдыгыннан, бу эшкә гел үзенең генә көче йитмәячәктер».

*«Вакыт», 1908, 9 февраль.*

---

[89] Мөридлек итү – иярү.

[90] Ибраһим Габделмәҗит улы Арсланов (1841–1908) – Казан сәүдәгәре, икмәкбакалея товарлары сату белән шөгыльләнүче фирма хуҗасы.

[91] Һиммәт – тырышлык.

[92] Хасид – көнче, көнләшүче.

[93] Ысулы саутия – аваз ысулы.

[94] Тәрәккый иттерү – алга җибәрү, үстерү.

[95] Тәәссеф улыну – үкенү, кайгыру.

[96] Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районына караган авыл.

[97] Хәмед – мактау, мактап сөйләү, шөкер итү.

[98] Дәхый – тагын, янә.

[99] Хәйрәт сахибе– сәдака бирүче, спонсор.

## [Казан җәмгыять хәйриясенең...]

Казан җәмгыять хәйриясенең идарәсе Народный училище директорларына мөрәҗәгать итеп, кызлар мәктәбе ачарга рөхсәт сораган. Директор низам[100] буенча русча укытуны кабул итү шарты илә генә рөхсәт бирелəчәгене белдерткән.

*«Вакыт», 1908, 9 февраль.*

## [Казанда кызлар мәктәбе ачу…]

Казанда кызлар мәктәбе ачу мәсьәләсе тәрәккыйпәрвәр[101] Казан бикәләре арасында бу арада шактый сөйләнә башлаган. Махсус хатыннар җәмгыяте ясарга да карар бирелеп, уставы тиздән губернаторга бирeләчәк имеш. Берничә хәйрәт ияләре[102] хатыннар тарафыннан кызлар укыту өчен ун мең сумга якын иганә дә вәгъдә ителмештер.

«Әхбар».

*«Вакыт», 1908, 19 февраль.*

## [Орск шәһәреннән…]

Орск шәһәреннән бер ханым язадыр:

«Шәһәремездә берничә елдан бирле яхшы гына тәртип илә укыта торган Газизә абыстай һәр сәнә 60–70 кадәр кыз балаларны укыта, бай хатыннарын вә абыстайларны дәгъвәт итеп[103], шулар хозурында балаларны имтихан кыладыр иде. Бу ел дәхый 2нче мартта гүзәл рәвештә имтихан мәҗлесе булып, укучы кыз балалар имтиханга килүче абыстайларның дикъкатьләрен[104] җәлеп кылырлык дәрәҗәдә яхшы имтихан бирделәр. Хосусән[105] абыстайның кызы Мөнәвәрә ханым балаларга тегү, чигү, нәкышьләү[106] кебек кул һөнәрләрен яхшы гына үгрәткән икән. Балаларның теккән вә чиккән нәрсәләре имтихан мәҗлесендә күрсәтелеп, һәркем тарафыннан тәхсин ителде[107]. Кечкенә генә кыз баланың уку-язу, Коръән, тәҗвид[108], гыйльме халь[109] вә игътикад[110] белүләре өстенә, хисап, җәгърафия, тарих вә гыйльме әшъядан[111] байтак кына нәрсә белеп, зиһен вә фикер ачулары вә кул һөнәрләре үгрәнүләре никадәр

---

[100] Низам – тәртип.

[101] Тәрәккыйпәрвәр – прогрессив.

[102] Хәйрәт иясе – сәдака бирү, спонсор.

[103] Дәгъват итү – чакыру, өндәү.

[104] Дикъкать – игътибар.

[105] Хосусән – бигрәк тә, аеруча.

[106] Нәкышь – бизәк, рәсем, сурәт.

[107] Тәхсин итү – мактау.

[108] Тәҗвид – Коръәнне дөрес уку кагыйдәләре.

[109] Гыйльме халь – ислам дине нигезләре турында башлангыч мәгълүмат бирә торган фән.

[110] Игътикад – чын күңелдән ышану.

[111] Гыйльме әшъя – физика.

сөенечле бер хәлдер. Боннан берничә ел әүвәлләре бондый хәлләрне күрермез дия өмет тә итә алмай идек. Газизә абыстай укытуны киткән саен тәрәккый[112] иттерә бара. Аңа һәм бинте[113] мөхтәрәмәсе[114] Мөнәвәрә ханымга күп рәхмәтләр укыймыз. Ләкин байларымыз да һиммәт итеп[115], гүзәл вә монтазам[116] һәм хифзыссыйхәткә[117] муафыйк[118] рәвештә кызлар мәктәбе салдырырга тиештер. Укучы кыз балалар йитмештән зиядә[119] вә имтиханга килүче ханымнар йөзгә якын улдыгыннан, имтихан мәҗлесе бик тыгыз иде».

***«Вакыт»:***

Газизә абыстай вә Мөнәвәрә ханымның бу илә тәртип илә укытуларына афәрин. Ләкин йөзләрчә кеше чакырып, шунлар хозурында балаларны имтихан итмәк ысул тәгълим[120] кагыйдәсенә муафыйк дәгел исә дә, балаларының укыган вә белгәннәрен күрсәтеп, халыкның уку вә гыйлемгә мәхәббәтләрене җәлеп итү касды[121] илә, хәзергә бездә бу кагыйдәгә ригаять ителмәүчелек[122] мәгъзүр тотылса[123] кирәк.

*«Вакыт», 1908, 15 март.*

## [Уфадан язалар...]

Уфадан язалар:

Уфалы мөгаллимә Хәдичә ханым Нурмөхәммәдова үзенең укытдыгы кыз балаларны май башында имтихан кылырга карар бирмеш исә дә, сәламәтлеге юклыктан, чарасыз 24 мартта уфалы остазбикәләр вә башка ханымнар хозурында имтихан итте. Кыз балалар ана телендә уку-язу, кыйраәте төрки[124], тәҗвид[125] вә Коръән, имля, хөсне хат[126], сарыф[127], нәхү[128], тарих, җәгърафия, гыйльме халь[129] вә игътикад[130] кеби кирәкле нәрсәләрдән гүзәл имтихан би-

---

[112] Тәрәккый – прогрессив, алга җибәрү.
[113] Бинте – кыз бала.
[114] Мөхтәрәм, мөхтәрәмә – хөрмәтле, хөрмәткә лаек.
[115] Һиммәт итү – тырышлык кую.
[116] Монтазам – тәртипле.
[117] Хифзыссыйхәт – гигиена.
[118] Муафыйк – туры килгән.
[119] Зиядә – артык.
[120] Ысул тәгълим – методика.
[121] Касд – максат.
[122] Ригаять итү – игътибар итү, кайгырту, карау.
[123] Мәгъзүр тоту – аклау.
[124] Кыйраәте төрки – төркичә уку китабы.
[125] Тәҗвид – Коръәнне дөрес уку кагыйдәләре.
[126] Хөсне хат – матур язу.
[127] Сарыф – морфология.
[128] Нәхү – синтаксис.
[129] Гыйльме халь – ислам дине нигезләре турында башлангыч мәгълүмат бирә торган фән.
[130] Игътикад – чын күңелдән ышану.

реп, җөмлә[131] ханымнарны мәмнүн иттеләр[132]. Хәдичә ханымның иҗтиһадына[133] тәшәккер улыныр[134].

*«Вакыт», 1908, 5 апрель.*

## [Уфа өязе Шәрип волосте Гомәр авылыннан…]

Уфа өязе Шәрип волосте Гомәр авылыннан яздыкларына күрә:

Имам Миңлеислам Госманов әһлиясе[135] Мәрьям ханым идарәсендә улан кызлар мәктәбендә имтихан булып, күрергә авыл хатыннары килгәннәр. Кечкенә генә балаларының укымак, язмак, иман, ислам, гыйльме халь, тәҗвид вә Коръән белдекләрене, вә боның өстенә хисаптан да беркадәр мәгълүматлары улдыгыны күреп, хәйран калганнар вә ысул саутия[136] илә болай тәртипле укытучы Мәрьям ханымга тәшәккерләр әйтеп киткәннәр. Яңарак ачылганда, авыл халкы бу мәктәпкә хилаф торганнар[137] икән. Нәтиҗәне күргәч, үзләре дә рәхмәт укыганнар.

*«Вакыт», 1908, 10 апрель.*

***Имтиханда булучы***

## [21нче апрельдә…]

21нче апрельдә Бишбалтада Сәгадәт ханым Әмирхания[138] мәктәбендә сынау-имтихан булды. Имтихан гүзәл сурәттә үтте.

Имтихан тыңларга килгән ханымнарның кайсыберсе укучы кызларга бүләкләр дә алып килгәннәр иде.

*«Әл-Ислах», 1908, 4 май.*

***Имтиханда булган бер ханым***

## [«Бәянелхак»ның 308нче номерында…]

«Бәянелхак»ның 308нче номерында[139]: «Мөгаллимә Маһруй Мозаффария[140] ханымда имтихан башланды. Гүзәл рәвештә булып, тыңларга килүче ханымнар гаять мөтәэссирә улмак[141] илә бәрабәр, бик мәмнүнә булып тарал-

---

[131] Җөмлә – барлык.

[132] Мәмнүн итү – риза, канәгать.

[133] Иҗтиһад – тырышлык.

[134] Тәшәккер әйтү – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.

[135] Әһлия – тормыш иптәше, хатыны.

[136] Ысул саутия – аваз ысулы.

[137] Хилаф тору – каршы тору.

[138] Сәгадәт Зариф кызы Әмирханова (1882–1911) – Фатыйх Әмирханның бертуган апасы, Казанның Бишбалта бистәсендә кызлар мәктәбе җитәкчесе.

[139] Казан хәбәрләре // Бәянелхак. 1908. 17 апрель.

[140] Маһруй Мозаффария (1873–1945) – педагог, Казанда кызлар мәктәбе җитәкчесе.

[141] Мөтәэссир булу – тәэсирләнү.

дылар. Имтихан программа илә иҗрәэ улынарак[142], бу тәртип шәһәремездә әүвәл мәртәбә улып, моннан соң мөгаллимәләремезгә үрнәк улса кирәк», – дигән сүзләрене укып, бән[143] дә бу мәктүбемне[144] язарга мәҗбүр улдым.

14нче апрель дүшәмбе көн бән дә имтихан мәҗлесендә булдым. Бән килгәнче, Коръән имтиханын тәмам итмешләр имеш. Башка дәресләр имтиханы иде. Маһруй ханым әүвәл үк сабак урыны билгеләгән булганлыктан, имтихан вакытында кызларның урынын актарып-актарып та таба алмагач, кызы да: «Абыстай, минем урыным үз китабымда мәгълүм иде», – дию җавап бирде. Нәүбәт шигырьләргә йиткәч, шигырьләр кат-кат укылды. Шигырьләр укыганда, кызларының артларыннан куып барган кеби, ашыгып-ашыгып укыдылар. Бәгъзеләре исә бер-берсенә: «Ашыкма, ашыкма дим», – дигән кеби сүзләр сөйләделәр.

Кунак ханымнардан бер-ике ханым: «Бик кычкырышмагыз», – дисәләр дә, «Син кунак, кунак булсаң куркак бул», – җавабын алдылар. Янә бер кызына тарих имтиханы әмер булгач, тарихны бөтенләй ялгыш-йолгыш укып бетерде. Янә берсенә җәгърафия[145] имтиханы әмер булгач, ул кыз да җавабында: «Мин бикләмәдем», – дип кычкырды.

Кунак ханымнарның Коръән укыганнарын ишетәселәре килеп утырсалар да, ишетү насыйп булмады. Хәтта бер-ике ханым Маһруй ханымнан укымакларын үтенеп карасалар да, Маһруй ханым да: «Ишетәсеңез килсә, әүвәл килегез иде. Программада әүвәл Коръән язылган», – дип мөтәккәббиранә[146] җавап бирде.

Нәүбәт шигырьләргә килгәч, гәрчә шигырьләр бер генә мәртәбә язылган булса да, кат-кат укытты. Шигырьләргә килгәч, программа бөтенләй бозылды.

Маһруй ханым кебек башка мөгаллимәләргә дә урын билгеләү вә кызларының белмәүләре берлә үрнәк булырлык идеген фәһемләдек[147].

«Бәянелхак»ка язучысы да үзе яки кызларыдыр.

***Идарә:***

Үз мохбиребез дә шуңар якын хәбәр китергән иде.

*«Әл-Ислах», 1908, 4 май.*

**Маһруй Мозаффария ханымның идарәсендәге мәктәп**

Печән базарында Маһруй Мозаффариянең үз йортындагы кызлар мәктәбендә 25нче август дүшәмбе көн дәрес башланып, түбәндәге тәртип илә укытылачактыр:

---

[142] Иҗраэ булу – үтәү, эшкә ашыру.
[143] Бән – мин.
[144] Мәктүб – хат, язылган әйбер.
[145] Җәгърафия – география.
[146] Мөтәкәббиранә – тәкәбберлек белән, теләмичә генә.
[147] Фәһем – аңлау, төшенү.

Дәресләр һәр көн иртән сәгать 8 дән 12 гә кадәр дәвам ителеп, бу вакытларда уку, язу, хисап һәм сәнәгатьтән[148] дәресләр биреләчәктер.

Тәфсыйле[149] – программаларда, өяздән килеп укырга теләүче ханым вә туташларга үз йортымызда торыр өчен урыннар бар. Ирадәсе[150] бар хатын вә туташлар рәхим итсеннәр.

Маһруй Мозаффария.

*«Әл-Ислах», 1908, 6 август.*

## Кызлар мәктәбе

Сембергә Акчуриннар[151] тарафыннан бу ел кызлар өчен мәктәп ачылачактыр.

*«Әл-Ислах», 1908, 21 август.*

## Кызлар өчен мәктәп

Том байлары үзара акча җыешып, кыз балалар өчен бу ел мәктәп ачачакларыннан шундагы мохбиремез яза.

*«Әл-Ислах», 1908, 21 август.*

## Уфа хәлләре

Кызлар гимназиясенә яңа баштан ике татар кызы (шул җөмләдән берсе Гыйниятулла казый кызы[152]) керде.

Ирләр мәктәбенә бу сәнә бик аз улып, балаларын мәктәпкә бирмә келәгән[153] бәгъзе татарларга, мәктәп идарәсе: «Кабул итәргә рус та бик күп әле», – җавабы илә рәд иткәнгә[154], берничә татар баласы мәктәпкә керә алмый калган.

*«Әл-Ислах», 1908, 21 август.*

---

[148] Сәнәгать – һөнәрчелек.

[149] Тәфсыйль – җентекле.

[150] Ирадә – теләк.

[151] Акчуриннар – Сембер төбәгендәге татар сәүдәгәрләре һәм фабрикантлар, җәмәгать эшлеклеләре, химаячеләр, мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр салуга, китаплар бастыруга матди ярдәм иткәннәр.

[152] Фаразлавыбызча, сүз мөселман дини һәм җәмәгать эшлеклесе, Оренбург Диния нәзарәте казые Гыйниятулла Капкаев (1856–1930) кызы турында бара.

[153] Бирмә келәгән – бирергә теләгән.

[154] Рәд итү – кабул итмәү, кире кагу.

*Сабир әл-Хәсәни*[155]

### Уфада кызлар мәктәбе

Уфа шәһәрендә 1нче мәсҗет җиварында[156] кызлар мәктәбе 1907нче сәнә бина ителеп[157], кыш буе кызлар тәгълим ителде[158]. Имде управа тарафыннан бирелгән урынга Николаевский площадьта хәзергә сәрмая[159] азлыгы сәбәпле, агачтан гына бина улыначак, ике башында ике мөгаллимә укытырлык, уртасында мөгаллимәләрә фатир булырлык итеп эшләнмәктәдер. Соңра әһел һиммәтнең[160] ихсаны[161] булып, кифая[162] кадәр сәрмая җыелса, планда тасдыйк кылынган[163] тарызда[164] таштан бина кылыначак.

Ошбу сәнә Уфада ханымнар җәмгыяте тәэсис кылынып[165], идарәсе гамәлендә даимдер. Ханымнар җәмгыяте идарәсе кызлар укыту хосусында күп мәртәбә җыелып, мөшавәрәт итештеләр[166]. Җәмгыять, сәрмаясе нисбәттә кызлар укытуына әһәмият биреп, ошбу көзге тәхсилгә[167] 1нче вә 3нче мәсҗет даирәсендәге ике кызлар мәктәбенә нәзарәт[168] вә тәрбия итәргә вә 2нче мәсҗет (Нижгородта) җиварындан буш торган ирләр мәктәбен сорап, анда һәм кызлар мәктәбе ачарга карар бирелде.

Кыз балаларны укыту хәзергә «Мөгаллимләрә нәмунә[169]» нам[170] програм буенча ибтидаи[171] вә рөшди[172] уларак ике кыйсемгә бүленеп, кызларга ләземе[173] улмаган бәгъзе дәресләр урынына идарәи бәйтия[174] вә кул һөнәрләре – чигү, тегү, нәкышь[175] төшерү, челтәр бәйләү кеби маддәләр[176] артты-

---

155 Мөхәмматсабир Мөхәмматҗан улы Хәсәнов (1866–1924) – сәясәтче, ахун, Уфадагы 3нче мәхәлләнең имамы, мөдәррис, II Дәүләт Думасы депутаты.

156 Җивар – тирә-як, янында.

157 Бина ителү – нигез салыну.

158 Тәгълим ителү – уку, укыту.

159 Сәрмая – капитал, акча.

160 Әһел һиммәт – тырышлык куйган кешеләр.

161 Ихсан – ярдәм, булышлык итү.

162 Кифая – җитәрлек.

163 Тасдыйк кылу – раслау.

164 Тарызда – рәвештә, тәртиптә.

165 Тәэсис кылу – төзү, оештыру.

166 Мөшавәрәт итү – киңәшү.

167 Тәхсил – уку, белем.

168 Нәзарәт – карау, күзәтчелек итү.

169 Нәмунә – үрнәк.

170 Нам – исем, исемле.

171 Ибтидаи – башлангыч.

172 Рөшди – урта.

173 Лязем – тиеш, кирәкле, туры килгән.

174 Идарәи бәйтия – йорт эшләре, хуҗалык эшләре.

175 Нәкышь – бизәк, рәсем, сурәт.

176 Маддә – бүлек.

рылды. Ошбу сентябрь 15 ендә тәгълимгә кызлар кабул ителеп, октябрь башыннан соңга калганнары кабул ителмәскә карар бирелде.

Җәмгыятьнең сәрмаясе хәзергә азлык сәбәпле, мәктәп идарәсене вә мөгаллимәләр мәгаишене[177] тәэмин итү өчен балаларның куәт вә икътидарларына[178] карап, хәсән[179] ихтыярлары илә мәктәп файдасына акча алыначак. 1нче мәсҗет җиварындагы кызлар мәктәбендә дамелла Җиһангир[180] остазбикәсе Гайшә ханым[181] баш мөгаллимә булып, бер-ике мөгайянә[182] алыначакдыр.

Яңа бина кылына торган мәктәптә Яхъя хәлфә әһлиясе Хәдичә ханым вә тугмасы Камилә ханым булачак, вә зарур улдыкта, ихтыяҗ кадәр мөгайянәләр алыначактыр. Бу мәктәпләр өстеннән уку вә укытуларын дикъкать итмәк өчен, хатыннарның үзләреннән назыйрә[183] булачактыр. Ахыргы җыелышларында назыйрә булучылыкны Мәрьямбикә бинте Тимербулат Солтановага[184] хәвалә итмешләр[185].

Ошбуда зикере[186] сәбәкать итмеш[187] мөгаллимәләр әүвәлдә дә укытып килгән, кызлар тәрбиясенә төшенгән, хезмәтләре күрелгән затлардыр. Садретдин әфәнде нәзарәтендә улан ике йирдәге кызлар мәктәбе һаман да шул ук Садретдин әфәнде тәрбиясендә калачак булды. Аллаһы Тәгалә һиммәт итүчеләрә[188] ярдәм биреп, һиммәт вә сәгыйләрен[189] арттырып, милләтемезнең яртысы улан хатыннар җенесен тәрәккый иттерүгә[190] нәсыйхәт әйләсен.

Вәкил имам Сабир әл-Хәсәни.

*«Вакыт», 1908, 27 сентябрь.*

---

[177] Мәгаиш – тормыш, яшәү.

[178] Икътидар – көч, хәл.

[179] Хәсән – гүзәл.

[180] Җиһангир Талха улы Абызгилдин (1875–1938) – Уфадагы 1 нче җәмигь мәчетенең имам-хатыйбы, «Госмания» мәдрәсәсе мөдире.

[181] Гайшә Лотфулла кызы Абызгилдина – мөгаллимә, Уфада кызлар мәктәбе оештыручы, Җиһангир Абызгилдинның тормыш иптәше.

[182] Мөгайянә – билгеләнгән кеше.

[183] Назыйрә – караучы.

[184] Мәрьям Тимербулат кызы Солтанова – күренекле хәйрияче, Уфа мөселман ханымнар җәмгыятенең җитәкчесе, ятимәләр өчен балалар йорты, башлангыч мәктәп, мәдрәсәләр һәм китапханә ача.

[185] Хәвалә итү – йөкләү, тапшыру.

[186] Зикер – искә алу.

[187] Сәбакать итү – беренче булу.

[188] Һиммәт итүче – тырышучы.

[189] Сәгый – тырышлык.

[190] Тәрәккый иттерү – алга җибәрү.

## Кызлар укыту

Уфа шәһәренең Нижгород мәхәлләсендә[191] борадарән Яһудиннар мәсарифы[192] илә кызлар мәктәбе ачылмышдыр. Мәктәпнең нәзарәтен[193] Мәрьямбикә Солтанова үзе өстенә алып, Мәгъфуфә ханым Тәкаеваны мөгаллимә вә ике ханымны аңа мөгайянә[194] тәгаен итте. Мәктәптә йөздән зиядә[195] кызлар укымактадыр.

*«Вакыт», 1908, 18 ноябрь.*

***«Мавия»***

## [Орскида]

Орскида, әлегәчә иске ысулда укытыла торган Газизә остазбикә мәктәбендә, быел Мөнәвәрә ханымның иҗтиһады[196] илә яңа тәртип һәм кул эшләре өйрәтү кертелмештер.

Үткән сәнәдә Габбас әфәнде Киникиев[197] бер кызлар мәктәбе бина итмеш[198] иде. Читтән мөгаллимә китермичә, үземездәгеләр илә генә канәгатьләндегеннән, бу мәктәптә уку бер төрле генә барадыр.

Безнең Орскида, укыган кызлар байларга чыгып, муллалар укытмаган бай кызы алдыкларыннан, мөгаллимә табылмыйдыр. Яхшы укытырлык мөгаллимәне читтән китермиенчә чара юктыр.

*«Вакыт», 1908, 18 ноябрь.*

## Мөгаллимәнең вафаты

Кузнецк өязе Индерка авылыннан[199] яздыкларына күрә:

Уральскида кызлар мәктәбендә мөгаллимәлек иткән Мәфтуха туташ Үзбәкия вафат итмештер. Мәрхүмә 20 яшендә булып, ысул саутия[200] илә иң яхшы укытучылардан саналмышдыр. Шул сәбәпле иртә вафатына тәәссеф улыныр[201].

Аллаһының рәхмәтендә булсын!

*«Вакыт», 1909, 29 гыйнвар.*

---

[191] Нижгород мәхәлләсе – хәзерге Нижегородка, Уфаның көнбатыш өлешендәге район.

[192] Мәсариф – тотылган акча.

[193] Нәзарәт – идарә итү.

[194] Мөгайянә – билгеләнгән кеше.

[195] Зиядә – артык.

[196] Иҗтиһад – тырышлык, теләк.

[197] Габбас Курамша улы Киникиев (1843–1914тән соң), Орск сәүдәгәре, Орск шәһәр думасы гласные.

[198] Бина итү – нигез салыну.

[199] Хәзер Пенза өлкәсенең Сосновоборск районына карый. Госман авылы буларак та билгеле.

[200] Ысул саутия – аваз ысулы.

[201] Тәәссеф улыну – кайгыру, борчылу.

## Кызлар имтиханы

Мөгаллимә Багбостан ханымның[202] кызлар имтиханы иртәгә башланып, апрельнең 23ндә бетәчәктер.

*«Вакыт», 1909, 18 апрель.*

***Ф.С.***

## [Нижний шәһәрендә...]

Нижний шәһәрендә ир балалар мәктәбендә һәм Әшраф Әннисаи вә Әминә ханымнар идарәсендә кызлар мәктәбендә имтихан булды. Имтиханда 100 гә кариб[203] ханымнар хазир булганнар[204] иде. Кыз балаларның гүзәл тәхсилләреннән[205] шат булып, аларга бүләкләр өләштеләр.

*«Вакыт», 1909, 9 май.*

## Имтихан

Мөгаллимә Сәхибҗамал ханымның кызлар мәктәбендә 7нче майда имтихан булды. Карарга килүче хатын-кыз 100дән артык иде. Кызлар бик яхшы уку-язу һәм кул һөнәрләре өйрәнгәннәр. Кызларга бүләкләр өләшелде.

*«Вакыт», 1909, 16 май.*

## Адамова мәктәбендә имтихан



*Фатыйма Адамова*

Фатыйма ханым Адамованың кызлар мәктәбендә ун көн имтихан булып, 14нче майда тәмам улмышдыр.

Имтихан күрергә Оренбургның үзеннән, Каргалы, Бозаулык вә Чебенледән бик күп ханымнар килгәннәр. Имтиханда хазир булган ханымнарның дикъкатьләренә күрә, кызлар имтиханны бик яхшы биргәннәр. Затән[206] бу мәктәп Оренбургтагы кыз мәктәпләренең иң яхшысы улып, Фатыйма абыстайның үз кулыннан килгән кадәр гайрәт вә сәбаты[207] саясендә[208] бонда күп кызлар уку, язу, кул һөнәрләренә, дин

---

[202] Багбостан Вилдан кызы Мөэминова (1884–1963) – мәгърифәтче, Оренбургта кызлар мәктәбен һәм Кабан авылында мөгаллимәләр хәзерләү курсларын оештыручы.

[203] Кариб – якын.

[204] Хазир булу – катнашу.

[205] Тәхсил – уку, белем.

[206] Затән – нигездә.

[207] Сәбат – чыдамлылык, ныклык, тотнаклылык.

[208] Сая – күләгә, ышык.

вә диянәт[209] үгрәнеп чыктылар. Хәзерендә бонда йөздән артык кызлар укымактадыр.

*«Вакыт», 1909, 16 май.*

### [Хвалын өязе...]

Хвалын өязе Иске Мастак авылында Сөләйман Сүнчәләевнең һиммәте[210] илә дәвам итмәктә улан кызлар мәктәбендә гүзәл рәвештә ысул җәдидә берлә укытыладыр. Имтиханда хазир[211] улан ханымнар вә имтихан итүче карт хәзрәт кыз балаларның яхшы уку вә язуларына афәрин укымышлар.

*«Вакыт», 1909, 20 май.*

### [Бөгелмә өязе Бәйрәкә[212] карьясеннән[213]]

Бөгелмә өязе Бәйрәкә карьясеннән Мусин әфәнденең язуы буенча, бу карьядә «Мәдрәсәи Гобәйдия»дә[214] 700 шәкерт, Мөнир мөдәррис мәдрәсәсендә 200, Фәттах мулла мәктәбендә 60 шәкерт тәхсил итмешләр[215]. Һәм дә 8 остазбикә хозурында 220 кыз бала укымышлар.

Шу илә ки, Бәйрәкә мәктәп вә мәдрәсәләрендә 1180 гадәд[216] укучы бар. Әбиләргә сабакка йөрүчеләр бу хисаптан хариҗдыр[217].

*«Вакыт», 1909, 26 май.*

***Гайнелхәят Гобәева***

### [Тоз-Түбә шәһәрендә[218]…]

Тоз-Түбә шәһәрендә җәмгыять хәйрия тарафыннан идарә ителмәктә булган кызлар мәктәбенең имтиханында 300 гә кариб[219] ханымнар хазир булдылар[220]. Имтихан һәйәтенә җәмгыять хәйрия тарафыннан 10 ханым сайлан-

---

[209] Диянәт – динлелек, дин тотучылык.
[210] Һиммәт – тырышлык.
[211] Хазир булу – катнашу.
[212] Хәзер Татарстанның Ютазы районына керә.
[213] Карья – авыл.
[214] «Гобәйдия» мәдрәсәсе 1812 елда Самара губернасы Бөгелмә өязе Бәйрәкә авылында (хәзер Ютазы районы) ачыла. Җитәкчеләре Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуат (1785–1845) һәм аның уллары Мөхсин (1870–1930), Мәсгуд (1874–1921) Гобәйдуллиннар.
[215] Тәхсил – уку, белем алу.
[216] Гадәд – сан, данә.
[217] Хариҗ – тыш, тышкы якта.
[218] Тоз-Түбә (Соль-Илецк) – Оренбург өлкәсендәге шәһәр.
[219] Кариб – якын.
[220] Хазир булу – катнашу.

мыш иделәр. Имтиханда балаларның дәресләреннән вә кул эшләреннән бик мәмнүн калган[221] кунаклар кыз балаларга бүләкләр өләштеләр.

Мөгаллимә Гайшә ханым вә мөгайнәләренең[222] иҗтиһадлары[223] тәхсингә[224] лаектыр.

*«Вакыт», 1909, 26 май.*

## [Уфада...]

Уфада 1нче мәхәлләдә мөгаллимә Гайшә ханым мәктәбендә бу сәнә дәресләр гүзәл укылдыгын вә имтиханда хазир булган[225] ханымнарның мөгаллимәдән бик риза булып рәхмәт укыдыкларын Хәдичә ханым Нурмөхәммәдия язадыр.

*«Вакыт», 1909, 26 май.*

## [Төмән шәһәреннән]

Төмән шәһәреннән 24 ханымның имзалары илә алдыгымыз мәктүбтә[226] мөгаллимә Хәлимә ханым Габидованың гүзәл укытуына, кыз балаларны рәнҗетми вә биздермәй тәрбия кылуларына рәхмәт укып вә тәшәккер әйтеп[227] язалар.

*«Вакыт», 1909, 26 май.*

**К.**

## [Вятка губернасы Әгерҗе карьясендә[228]...]

Вятка губернасы Әгерҗе карьясендә[229] Габделкотдус әфәнде идарәсендәге ир балалар мәктәбе, Әминә вә Сәүдә ханымнар идарәсендәге кызлар мәктәбе гүзәл рәвештә дәвам итәләр. Кызлар мәктәбенең имтиханында 300 гә кариб[230] хатыннар хазир булмышлар иде. Кызларның укуларын вә кул эшләрен бик яратып, укытучы вә өйрәтүчеләргә рәхмәт укып таралдылар.

*«Вакыт», 1909, 28 май.*

---

[221] Мәмнүн калу – риза, канәгать булу.
[222] Мөгайянә – билгеләнгән кеше.
[223] Иҗтиһад – тырышлык, теләк.
[224] Тәхсин – мактау.
[225] Хазир булу – катнашу, булу.
[226] Мәктүб – хат, язылган әйбер.
[227] Тәшәккер әйтү – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.
[228] Карья – авыл.
[229] Әгерҗе – хәзер Татарстанның Әгерҗе шәһәре.
[230] Кариб – якын.

***И.Г.***

**[Бөгелмә каласында...]**

Бөгелмә каласында Шакир Хәкимов[231] тәрбиясендәге ир балалар һәм кызлар мәктәпләрендә имтихан булды. Укытучыларга һәм һиммәт итүчегә[232] тәшәккер[233] итәләр.

*«Вакыт», 1909, 28 май.*

***М.***

**[Одесса шәһәрендә...]**

Одесса шәһәрендә мулла Сабирҗан хәзрәт идарәсендәге мәктәптә 36 гадәд[234] ир вә кыз балага имтихан буды. Имтиханга ирләрдән вә хатыннардан килүчеләр күп иде. Балаларга мөкяфәтләр[235] өләшеп, мөгаллим Таҗетдин әфәндегә тәшәккер әйтеп таралдылар.

*«Вакыт», 1909, 28 май.*

***Х.И.***

**[Пермьдә...]**

Пермьдә ибтидаи[236] вә рөшди[237] кыйсемнәрендә 170 балага имтихан булды. Борадәран[238] Агафуровлар[239] шәкертләргә һәдия[240] өләштеләр. Тимкиннар[241] 100 кадәр фәкыйрь шәкертләргә киемлек бирделәр.

Җәй өчен эстәгән[242] балаларга «Тәрәккыюнь ислам»[243] җәмгыяте тарафыннан русча сыйныфы ачыладыр.

Ибраһим хаҗиның кыз мәктәбендә 50 кадәр кыз ысул җәдидә илә укыйлар һәм кул эше өйрәнәләр. Яшьләр арасында уку, мәгърифәт нәшеренә хезмәт итүчеләргә тәшәккер итәмез.

*«Вакыт», 1909, 28 май.*

---

[231] Шакир Габделлатыйп улы Хәкимов – Бөгелмәнең II гильдия сәүдәгәре, химаяче.

[232] Һиммәт – тырышлык.

[233] Тәшәккер – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.

[234] Гадәд – сан, данә.

[235] Мөкяфәт – бүләк, премия.

[236] Ибтидаи – башлангыч.

[237] Рөшди – урта.

[238] Борадәран – бертуган.

[239] Агафуровлар – атаклы Екатеринбург сәүдәгәрләре.

[240] Һәдия – бүләк.

[241] Тимкиннар – Пермь сәүдәгәрләре, химаячеләр, Пермь шәһәрендәге җамигъ мәчетне салуда матди ярдәм күрсәтәләр.

[242] Эстәү – теләү, арттыру.

[243] «Тәрәккыюнь ислам» – мөселман тәрәккыйпәрвәрләре җәмгыяте, мәгариф, мәктәп-мәдрәсәләр эшчәнлегенә матди ярдәм күрсәткәннәр.

## [Омск шәһәрендә...]

Омск шәһәрендә М.-Н. һәм Ш.Д. ханымнарның хосусый мәктәпләрендә кызларга ысул җәдидә берлә укытылып, кул һөнәрләре өйрәтеләдер.

Имтиханда булган ханымнар үзләренең мәмнүниятләрен[244] изһар итеп[245] таралдылар.

*«Вакыт», 1909, 28 май.*

***М.Н.***

## [Троицк шәһәрендә…]

Троицк шәһәрендә кыз балалар остазбикәләрдә укып йөриләр. Сабаклары әлифбадан соң һәммәсе иске китаплардыр. Карчыклар «гарәп укытамыз» дип, бер дә аңлатмыйча, яшь кыз балаларның башларын әвәрә итеп бетерәләр. Бәгъзе фикерлерәк адәмнәр үз балалары өчен читтән, Бубыйдан мөгаллимә китерттеләр. Алар бик яхшы укытсалар да, бик аз кызларны гына файдаландыра алалар.

Бер остазбикә янына үткән ел мөгаллимә куйганнар иде. Тынышмадылар. Ләкин һәммәсе алай булмас. Әгәр һәрбер остазбикә янына бер мөгаллимә куелса, укулар бераз алга китер иде.

*«Вакыт», 1909, 30 май.*

## Кызлар мәктәбе

Адамова кызлар мәктәбендә дәресләр ошбу августның 17 сендә дүшәмбе көн башланачактыр.

*«Вакыт», 1909, 13 август.*

***Нуретдин Йосыфов***

## Мөгаллимә кирәк

Минзәлә өязе Иске Баграш (Елховой)[246] авылына ибтидаи кызлар мәктәбенә мөгаллимә кирәк. Айлык мәгаше нәкыд[247] акча 18 сум; ашау өчен дәхый[248] 7 сум бирәмез. Фатир, йылыту, яктырту, мебель, посуда бездән. Укыту вакыты 6 айдан ким булмас. Мөгаллимәнең ибтидаи тәгълимгә[249] икътидарлы[250] булуы вә күркәм холкы булуы беренче дәрәҗә шартдыр. Бу игъланны укыгач, килергә теләүче кеше тизлектә хат яки телеграм йибәрсен,

---

[244] Мәмнүният – риза булу.

[245] Изһар итү – күрсәтү.

[246] Иске Баграж, ш.ук Елховой – Татарстан Республикасының Әлмәт районындагы татар авылы.

[247] Мәгаше нәкыд – кулга бирелә торган акча.

[248] Дәхый – янә, тагын.

[249] Тәгълим – өйрәтү, укыту.

[250] Икътидар – көч, куәт; булдыра алу.

үзенең кайда укыганлыгын, хәзердә мәшгуль булган хезмәтен, ничек риза булачагын вә адресын бәян итсен.

Мәктәпнең мөрәббисе[251] Нуретдин Хәсәнетдин угылы Йосыфов.

Адресымыз:

Ст. Кичуй Самарск. губ. Нуртдину Хуснутдиновичу Юсупову

Телеграм өчен: Кичуй, Юсупову.

*«Вакыт», 1909, 19 сентябрь.*

***Үз мохбиребездән***

**[Хөкүмәт мәктәпләренә бала бирү хосусында...]**

Хөкүмәт мәктәпләренә бала бирү хосусында казанлылар бик алга баралар. Хосусан бу ел Казанда мөселманнар бигрәк каушаганга охшыйлар. Иң иске фамилияләрдән булган Апанаевлар[252] эченнән генә хөкүмәт мәктәбенә бу ел керүчеләр 6 гадәд[253] булган. Бер фамилиядән бер елда шулкадәр кергәч, азсынырлык түгелдер.

Кызларны укыту да шулай ук мода булып бара. «Инде фәләннәр укыткач, безгә укытмый ярамый», – диючеләр еш-еш ишетелә.

Әлегәчә бусагасыннан татар узмаган музыкальный, художественный һәм технический мәктәпләрдә дә быел мөселман шәкертләре бар. Фельдшерскийда да арта; быел реальный училищеларда 8, коммерческий училищеда 16 мөселман укыйдыр.

Дүрт кызлар гимназиясендә һәркаюсында мөселман кызлары бар. Күбрәге Котова гимназиясендә[254] – 13, вә Мариинскийдадырлар[255].

Казан университетына бу ел керүчеләр 7 булып, 2 се мәдрәсәләрдә хәтме көтеб иткән[256] егетләрдер.

Хосусый мөгаллим тотып укучылар елдан-ел бергә-бер артадыр.

*«Вакыт», 1909, 19 сентябрь.*

**Уфада кызлар мәктәбе һәм пансионы**

Уфада 1нче мәхәлләдәге ысул саутия[257] ибтидаи[258] вә рөшди[259] кызлар мәктәбендә 15нче сентябрьдә уку башланды. 1 октябрьдән соң шәкерт кабул итмәячәкләр. Мәктәпнең бер башында өяздән килгән кыз балалар өчен

---

[251] Мөрәбби – тәрбияче, караучы.

[252] Апанаевлар – атаклы Казан сәүдәгәрләре һәм химаячеләр.

[253] Гадәд – сан, данә.

[254] Александра Котованың шәхси кызлар гимназиясе.

[255] Казанда 1859 елда ачылган, императрица Мария Александровна исемен йөрткән беренче шәхси кызлар гимназиясе.

[256] Хәтме көтеб итү – тәмамлау, укып бетерү.

[257] Ысулы саутия – аваз ысулы.

[258] Ибтидаи – башлангыч.

[259] Рөшди – урта.

пансион ачылды. Һәр айга 10 сум бәдәл[260] белән укучы кызларны гүзәл сурәттә тәрбия ителәчәкдер. Пансионга 15нче октябрьгәчә кыз балалар кабул ителә.

Бу мәктәп илә пансионның икътисади идарәсе «Ханымнар җәмгыяте» кулында булып, гыйльми идарәсе Гайшә ханым Абызгилдина тасрифындадыр[261].

*«Вакыт», 1909, 22 сентябрь.*

***Үз мохбиремездән***

## [Уфада «Мөслимә ханымнар җәмгыяте»…]

Уфада «Мөслимә ханымнар җәмгыяте» кыйраәтханәләр[262] ачарга рөхсәт алды. Бу кыйраәтханәдә фәкать мөселман матбугаты гына булачак вә ханымнар гына кереп укыячак. Урыны Мәхкәмәи шәргыянең бер флигелендәдер. Бу тугрысы илә ханымнар җәмгыяте ирләр җәмгыятеннән уздырды.

*«Вакыт», 1910, 16 март.*

***Хәйрулла Госмани***[263]

## Илектәге[264] кызлар мәктәбе хакында

Бу мәктәпкә полиция килеп: «Инспектор бу мәктәпне ябарга әмер итте», – дип, укытуны туктатырга кушып киткәннәр. Иртәгесен балаларның аталары полициягә барып, моның сәбәбен сораганлар. Анда: «Менә үз арагыздан бер кеше инспекторга шушы язуны биргән», – дип, бер язу укып күрсәткәннәр. Аталар: «Бу ялгыш, без рәсми школа ачып, учительница китергәнебез юк. Тик искедән, 20 елдан бирле укыткан абыстаебыз Казанга дәваланырга китдеке сәбәпле, бер абыстай китереп шуның квартирына кызларыбызны язу вә кул эшләре үгрәттерергә йөретәбез», – дигәч, мәэмүрләр[265]: «Алай булса, безем тарафтан манигъ кылырга[266] юл юк», – дип, укытырга мөсагадә иткән[267] вә ялгыш хәбәр бирүчене судка бирергә тиешле табылган. Менә хакыйкать хәл шуннан гыйбарәттер.

Мөгаллим Хәйрулла Госмани.

*«Вакыт», 1910, 27 март.*

---

[260] Бәдәл – бәя, хак.

[261] Тасриф – сарыф итү.

[262] Кыйраәтханә – уку залы, уку өе.

[263] Хәйрулла Габдрахман улы Госманов (1866–1915) – мулла, II Дәүләт Думасы депутаты, Каргалы мәдрәсәсе мөдәррисе.

[264] Илек авылы – хәзер Оренбург өлкәсенә карый.

[265] Мәэмүр – түрә, берәр эшне үтәүче кеше.

[266] Манигъ кылу – тыю, тоткарлау.

[267] Мөсагадә итү – мөмкинлек бирү, булышу.

## Кызлар имтиханы

Апрельнең 19 ыннан 23 сенә кадәр мөгаллимә Багбостан ханым фатирында кыйраәт[268], язу, гыйльме халь[269], Коръән, сарыф гарәби[270], хәдис, гакаид исламия, ысул тәгълим вә тәрбия, җәгърафия, тарих ислам, тарих нисван, әхлакъ, хисап, кул эшләре дәресләреннән имтихан булачагыны вә тыңлыйсы килгән ханымнарга имтихан мәҗлесенә керергә рөхсәт иттекене мәзкүрә[271] мөгаллимә ханым хәбәр итәдер.

Фатиры:

Банный озерода, Власовский урамда, Коровин йортында.

*«Вакыт», 1910, 13 апрель.*

## Имтихан

Банный озерода Габделхәким хәлфәнең әһлиясе[272] Рокыя ханымның кызлар мәктәбендә май 1еннән башланып, 3 сенә кадәр имтиханнар булачак. Күрергә теләгән ханымнар рәхим итсеннәр. Мәктәп Хөсәен Такташев йортында.

*«Вакыт», 1910, 27 апрель.*

## Кызлар имтиханы

Яңа Бистәдә Татар урамында Фәхретдинов йортында майның 4, 5, 6 көннәрендә мөгаллимә Фәйрүзә ханымның кызлар имтиханы булачагыны вә имтихан иртә сәгать 9 дан алып кич сәгать 7 гә кадәр дәвам итеп, күрергә теләгән ханымнарга керергә рөхсәт иттегене гәзитәмезгә басарга үтенәләр.

*«Вакыт», 1910, 29 апрель.*

## Медаль алган мөселманнар

Үткән җәй Казан выставкасында куйган нәрсәләрнең яхшылыгына вә ияләренең һөнәрләренә түбәндәге мөселман фирмаларына медаль биргәннәр: [...]

Казанда мөселманча-русча кызлар мәктәбендә шәкерт кызларның эшләгән кул һөнәрләре өчен мактау кәгазе (почетный лист) бирелгән.[...]

*«Вакыт», 1910, 29 апрель.*

---

[268] Кыйраәт – уку.

[269] Гыйльме халь – ислам дине нигезләре турында башлангыч мәгълүмат бирә торган фән.

[270] Сарыф гарәби – гарәп теле морфологиясе.

[271] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.

[272] Әһлиясе – хатыны.

### Мөгаллимә кирәк

Казан университетында хезмәт итүче татарлар бик күп булганга, шуларның балаларына язу вә уку өйрәтер өчен мәрхүм профессор Любимов[273] шәрәфенә[274] университет йортында ачылган бер мәктәп бар. Ул мәктәптә һәм русча, һәм дә мөселманча укытыла. Ир вә кыз балалар бергә укыйлар иде. Бу ике актык елда анда мөгаллимәлек вазыйфасын Камалова әда иткән[275] булса да, быел җәй ул ханым мөгаллимәлектән истигъфа иткән[276] икән. Хәзер шуның урынына бер яхшырак мөгаллимә кирәк икән.

*«Вакыт», 1910, 29 май.*

### Кызлар мәктәбе

Габдрахман әфәнде Әхмәровка[277] кызлар мәктәбе ачарга рәсми рөхсәт килде. Бу мәктәп даимән Мөхәммәд хәзрәт хәлиләсе[278] Маһитап абыстай Бикмәт химаясендә булачак. Баш мөгаллимә Бубыйдан китерелгән Мәрьям Тукай-Черкастыр. Аның янына бер могавин[279] мөгаллимә дә булачак. Әхмәров вә иптәшләренең бу хосустан һиммәтләре вә Маһитап абыстайның галиҗәнаблеге шаян тәкъдирдер.

*«Вакыт», 1910, 29 июнь.*

### Кызлар укыту

Берничә еллардан бирле кызлар укытып килмәктә булган мөгаллимә Багбостан ханым быел Оренбургта Покровский плошадьта берничә бүлмәле зур фатир алып, балаларны шунда укыта башлаган. Читтән китерелгән кыз балаларны үзендә тотып тәрбия итеп укытырга да кабул итә икән. Өязләрдән кыз балаларын шәһәргә йибәреп укытырга теләүчеләр өчен бу бик уңгай бер эштер. Фатиры, ашау-эчү, яту-торуы ышанычлы мөгаллимәнең үз өендә булгач, ата-аналарның күңелләре тыныч булырга мөмкиндер.

*«Вакыт», 1910, 30 сентябрь.*



Багбостан Мөэминова
*(«Сөембикә», 1915, №8)*

[273] Мөгаен, Казан император университеты профессоры Н.М. Любимов күз алдында тотыла торгандыр.
[274] Шәрәфенә – исеменә.
[275] Әда итү – үтәү.
[276] Истигъфа итү – эштән азат ителү.
[277] Габдрахман Әхмәров – мәгърифәтче, мөгаллим, Троицк шәһәрендә «Сөембикә» кызлар мәктәбен ачучы.
[278] Хәлилә – хатын, тормыш иптәше.
[279] Могавин – ярдәмче.

*Үз мохбиремездән*

## Кызларны укыту

Фәезханованың кызлар мәктәбе[280] елдан-ел зурая, укучыларны үзенә җәлеп итә киләдер. Моннан йиде ел әүвәл 7 шәкерт илә ачылган бу мәктәптә бу ел 75 шәкерткә кадәр алынган, моннан артык шәкерт алу урын юклыгыннан мөмкин булмаган. Бу мәктәптә бу елга кадәр ике мөгаллимә укытып килгән иде. Быел исә Фәезхановага икенче могавинә[281] итеп Мәдинә туташ Терегулова тәгаен ителгән.

4 ел боннан әүвәл 8 кыз илә ачылган Әхмәтҗан Мостафа[282] идарәсендәге кызлар мәктәбендә бу ел 40 кыздан артыклык урын булмаганга, мәктәпкә алынмыйча, байтак кызлар укудан мәхрүм калалар.

Боннан бер ел әүвәл ачылган Аитова ханымның[283] мәктәбендә быел 80 нән артык бала кабул ителмәгәнгә, кыз балалар яңадан иске остазбикәләр хозурына кайтырга мәҗбүр булдылар.

Бу уку тарафына гөруһ-гөруһ[284] сөрелүләр, актыккы ике-өч елның биргән нәтиҗәләредер.

Моннан 3–4 ел мөкаддем[285] Яңа Бистәдә мөселман кызларын укытыр өчен ачылган мәктәпнең халык һөҗүменнән куркып ябылуы, кара халыкның укуга каршы хәрәкәтенең көчлелегенә чарасызлыкны күрсәтеп торган бер эш икәнлеген уйлаганда, Казан халкының бүгенге көндә укуга сарышулары байтак күңелне шатландыра һәм тынычлык бирә торган эшләрдәндер.

*«Вакыт», 1910, 5 октябрь.*

*Үз мохбиремездән*

## Кызлар мәктәбе

Мөселман кызлары вә хатыннары өчен хөкүмәт рөхсәте илә прогимназия программасы илә хосусый мәктәп ачыладыр. Мәктәпнең мөдирәсе Крижановская ханым элек берничә еллар Казанда кызлар институтында мөгаллимә булып торган, әлегәчә дә мөселман кызларын укытдыгыннан керешкән эшендә тәҗрибәсе бар.

---

[280] 1904 елда Фәезханова Әминә Хөсәен кызы тарафыннан ачылган русча-татарча кызлар мәктәбе.

[281] Могавинә – ярдәмче, ярдәм итүче.

[282] Мостафин Әхмәтҗан Мөхәммәтрәхим улы (1860–1938) – мәгърифәтче, Казанда мөселман кыз балалар мәктәбен ачучы, «Укытучы» журналы хезмәткәре.

[283] Фатыйха Габделвәли кызы Аитова (1866–1942) – күренекле педагог, Казанда кызлар мәктәбе җитәкчесе, 1916 елда әлеге мәктәп нигезендә, Россиядә беренче мөселман кызлары өчен гимназия ачыла.

[284] Гөрүһ – төркем.

[285] Мөкаддәм – элек, әүвәл.

Мәктәп хәзергә ике сыйныф булып, бара-бара үсәчәк. Кул эше өйрәтү өчен махсус мөгаллимә куелган. Шәригать вә дин ислам дәресләре укытырга мөгаллимә Габидуллина ханым чакырылган. Мәктәп Әхмәтҗан Сәйдәшев[286] йортында булып, октябрь 23 дә ачыладыр.

*«Вакыт», 1910, 24 октябрь.*

***С.Калмаканов***

## Семипалатта[287] кызлар мәктәбе

Быел беренче октябрьдә 7нче мәсҗет хозурында тәртипле кызлар мәктәбе ачылды вә мөгаллимәләргә «Бубый»да җитешкән вә яртысы гына тәҗрибә күрелгән бер ханым тәгаен ителде. Мәктәп ачу мәҗлесендә мәхәлләнең имамы Әкрам хәзрәт вә мәктәпнең мөрәббиләре[288] җыелган иделәр. Коръән уку, дога, гыйлемнең, махсус кызлар укыту, тәртипле аналар йитештерүнең кирәклеге хакында мөәссир[289] нотыклардан соң бу илә карар бирелде:

1) Мәктәп һәр ел 15 августта ачылып, уку 15 майгача сузыла.

2) Мәктәпнең тышкы эшләрен идарәгә шәһәрнең фикерле байларыннан Нәбиулла хаҗи Хәмидов илә Гарифулла әфәнде Төхфәтуллин сайланды.

3) Дәрес китаплары мөдир, мәктәп мөрәббиләреннән мәгълүматлы өч зат вә мөгаллим арасында булган мәслихәткә муафыйк[290] тәгаен ителәчәк.

4) Җәй көне һаваның иң яхшы бер вакытында, фикерле мөрәббиләр иҗтиһады илә иҗарәгә[291] пароход алып, мәктәп файдасына ханымнар махсус сәер (гуляние) ясалыр.

5) Мәктәпнең малы җәһәте мөсагадә иттерсә[292], чигү машинасы алырга вә рус мөгаллимәсе чакырып булса да, олуграк кызларны чигү эшенә өйрәтергә;

6) Мәктәп хозурында кечкенә генә китапханә ачып, ханымнарга файдалы роман, әдәби рисалә вә газеталар алырга вә кызларга укырга бирергә.

7) Мәктәп файдасына Управадан ярдәм сорарга (мәктәп мөрәббиләреннән икесе гласный булып, бу илә ярдәм бирдерергә тырышачакларын) сөйләделәр.

Мәктәп мөрәббиләре күбесе приказчиклар. Кызлар айга 3 сум биреп укыталар. Эшләренә рәваҗ[293] телимез.

*«Вакыт», 1910, 4 ноябрь.*

---

[286] Әхмәтҗан Сәйдәшев (1840–1912) – Казан сәүдәгәре, эшмәкәр, хәйрияче, «Баянелхак» газетасын оештыручы, нашире.

[287] Казахстандагы Семипалатинск шәһәре.

[288] Мөрәбби – тәрбияче.

[289] Мөәссир – күңелдә эз калдыручы.

[290] Муафыйк – туры килгән.

[291] Иҗарә – аренда.

[292] Мөсагадә итү – ярдәм итү.

[293] Рәваҗ – уңыш.

## Русча укыту (Казан)

Әхмәтҗан әфәнде Мостафа идарәсендәге кызлар мәктәбенең ибтидаи[294] өченче сыйныфыннан башлап атнага 6 дәрес русча укыта башладылар. Фатыйха ханым Аитова идарәсендәге 5нче мәхәллә кызлар мәктәбенә русча дәресләр кертергә мәгариф мәэмүрләре[295] җитди рәвештә тәүсыя иткәннәр[296].

*«Вакыт», 1910, 16 декабрь.*

***Вилдан Гайнуллин***

## Мәктәпне тарату

(Идарәгә мәктүб[297])

Богырыслан өязе Ирсай нам авылда[298] 96 кеше (49 ир вә 47 хатын) рәсман[299] дин ислам кабул иткәннәр вә уку яшеннән 17 ир вә 15 кыз балаларын берәүнең өендә гади бер кешедән зарурият диния укыттыра иделәр.

22 январьда бонлар башына тәэссефле[300] бер вакыйга килде. Авылларына урядник килеп, җыелган укучы балаларны тараткан, вә укытучыларын приставка йибәртәчәк булган.

Авыл халкы бер кеше йибәреп, вакыйганы миңа белдергәч, игътибарлырак бер ага илә Ирсайга бардык вә урядникны күреп бу илә тәфтишкә[301] һәм дә мәзкүр кемсәне приставка озатырга сәбәп ни идекене сорадык. Урядник җавабында: беренче – бу авылда начальстводан изенсез[302] школ ачкансыз; икенчедән, бу кемсә һичбер свидетельствосыз мөгаллим имеш; өченчедән, бу школда мөселман балаларыннан тыш язычник (мәҗүси) вә православный мәзһәбендә булганнарның да балаларына дин өйрәтергә җөрьәт кылалар, дип заявление бар, диде.

Заявление нинди кешедән, дип сорасак та: «Анысын мин әйтмим. Телдән-телгә йөргән җәберләргә күрә: агачны кисүгә балта сабының ярдәме булган, имеш. Аз бер шәхси сәбәп илә шундый эшләр эшләнсә, тәэссеф кылынмаслык түгелдер».

*«Вакыт», 1911, 29 гыйнвар.*

---

[294] Ибтидаи – башлангыч.
[295] Мәэмүр – берәр эшне үтәүче кеше, түрә.
[296] Тәүсия итү – киңәш бирү, бер эшне тапшыру.
[297] Мәктүб – хат.
[298] Хәзер Башкортстанның Мишкә районына керә.
[299] Рәсман – рәсми рәвештә.
[300] Тәэссефле – кайгылы.
[301] Тәфтиш – тикшерү.
[302] Изен – рөхсәт.

## [Самара вилаят земствосы]

Самара вилаят земствосы үз хисабына кызларга махсус гали дәрәҗә дарелмөгаллимат[303] ачарга карар бирде. Боннан чыкканнар гимназия вә әмсали[304] мәктәпләрдә мөгаллимәлек итәчәкләр.

*«Вакыт», 1911, 29 гыйнвар.*

***Бәдретдин Гыйбадуллин***

## Эстәрлетамакта укучылар

Шәһәремездә русча булсын, мөселманча булсын, уку елдан-ел алга барганлык күренәдер. Элеккеге «мал-алтын дәвере» янына «гыйлем дәвере» дә якынлаша башлады.

Эстәрлетамакта 1нче таш мәсҗет мәхәлләсендә мөселманча укучылар 513 бала булып, 368е ир, 145е кыз; 2нче мәхәлләдә укучы 445 баланың 215е ир, 230ы кыз; 3нче мәхәлләдәге 125 укучының 100е – ир, 25е – кыз. 4нче мәхәлләдәге 260 укучы башына 180е ир, 80е кыздыр. Шәһәрдә бөтен мөселманча укучы балалар 1343 булып, 863е – ир, 480е – кыздыр.

Русча укучы ир балалар: мәдрәсә хозурында рус классында 141, 4 класслы городскойда 11, быел ачылган реальныйда 1, русча класска төштән соң йөрүчеләр 80. Бөтенесе – 232.

Русча укучы мөселман кызлар: русский-башкирский земский школда 56; кызлар гимназиясендә – 4, бөтенесе – 60.

Шәһәрдә укучы бөтен мөселман баласы 1555 булып, 1015е ир, 540ы – кыздыр.

Мөселманчасы күбесе ысул җәдидә илә укытып, мөгаллимнәр дә, мөгаллимәләр дә аз булса да жалуния алалар. Ысул кадим илә укытучылар бар, бонларның хәлфәләре жалуния алмыйдыр.

Шәкертләр җөмләсендә 35 ятим бала. «Тәрҗеман»[305] чыгуга 25 ел тулу ядкяре уларак ачылган «Исмәгыйлия»[306] мәктәбендә укыйлар. Хәмитле мөселманнарның иганәсе илә бонда шәкертләргә бушлай ашау, эчү, уку әсбаплары биреләдер.

Мөгаллим Бәдретдин Гыйбадуллин.

*«Вакыт», 1911, 19 февраль.*

---

[303] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар әзерли торган уку йорты.

[304] Әмсали – үрнәк.

[305] «Тәрҗеман» – 1883–1918 елларда Бакчасарай шәһәрендә И.Гаспринский мөхәррирлегендә чыккан газета.

[306] «Исмәгыйлия» – Эстәрлетамак шәһәрендә Исмәгыйль Гаспринский исеменә атап ачылган җәдиди мәктәп.

***Г.Г.***

## Орскида кызлар мәктәбе

Шәһәремезнең байларыннан булган мәрхүм Әхмәтҗан хаҗи Рәхмәтуллинның [307] җәмәгате Маһруй ханым [308] илә угылы Хәкимҗан әфәнде мәрхүмнең васыять итеп калдырган акчасына, җәмгыять хәйриянең шәһәр управасыннан йирләренә 3 мең сумга төшереп мәктәп салдырдылар.

Боңача укучы кызларның саны күп булса да (80 бала), кечкенә генә бер өйдә газап чигеп укый иделәр. Хәзер мәзкүр[309] һиммәт ияләре[310] мәктәптә мөкәммәл[311] парталар, кара такта вә башка уку әсбапларын да йитештерергә өсләренә алдылар. Мәктәпне «Әхмәтҗан мәктәбе» дия атаячаклары ишетелә. Бу зур һиммәте өчен мәрхүм Әхмәтҗан хаҗиның рухы мөяссәр булсын[312].

Орск мөселманнары җәмгыятенең бер гомум нәүбәт мәҗәлләсендә Орскидагы ибтидаи[313] мәктәпләрне ислах итү[314] мәсьәләсе каралып, Орскидагы барлык мәктәпләргә бер төрле програм төзү өчен, 14 кешедән мөрәккәб[315] комиссия сайланган иде. Комиссиягә сайланучылар хәзрәтләр, мөгаллимнәр вә ачык фикерле башка адәмнәрдер. Комиссия 20 ләп маддәдән гыйбарәт гомуми бер програм төзидер.

*«Вакыт», 1911, 12 март.*

***А.Б.***

## Кызлар мәктәбе

Пермь өязендә Олуг Мул карьясендә[316] ничә ел буш яткан «Ятабной дом» тиешле урыннан сорап алып, тиешенчә яхшы төзәттерелгән вә шунда кызлар мәктәбе ачылган иде. Бу мәктәптә 100 дән артык зиядә[317] кыз балалар укып, мөгаллимә ханымның фазыйләте[318] саясендә[319] кул һөнәрләренә дә яхшы өйрәнделәр. Мәүлид Шәриф кичәсендә мәктәп шәкерт кызларның һөнәрләренә выставка диярлек дәрәҗәдә зиннәтләнгән, кул эше һәртөрле чәчәкләр, кызларның аз заманда куллары ничек эшкә күнгәнне күрсәтергә кифая

[307] Әхмәтҗан Рәхмәтуллин – мәгърифәтче, сәүдәгәр, Орск шәһәрендә мәдрәсә ачучы.
[308] Маһруй Борнаева-Рәхмәтуллина – Орскида кызлар мәктәбен ачучы, аның мөдирәсе.
[309] Мәзкүр – алда искә алынган.
[310] Һиммәт ияләре – тырышлык куючылар.
[311] Мөкәммәл – бик яхшы, камил.
[312] Мөяссәр булу – җиңел, җайлы, җиңел үтәлешле булу.
[313] Ибтидаи – башлангыч.
[314] Ислах итү – реформа ясау, үзгәртеп кору.
[315] Мөрәккәб – җыелган, тупланган.
[316] Карья – авыл.
[317] Зиядә – артык.
[318] Фазыйләт – яхшы эш.
[319] Саясендә – күләгәсендә.

итәрлек[320] дәрәҗәдә иде. Кызларның Мәүлид Шәриф укуларын тыңлаучы ханымнар бик әсәр биреп, күбесенең күзеннән шатлык вә тәэсир яшьләре агызмыштыр.

*«Вакыт», 1911, 19 март.*

***Г.М.***

**[Ташкентта яңа ачылган кызлар мәктәбе]**

Ташкентта яңа ачылган кызлар мәктәбе файдасына сентябрьнең 15ендә татарча театр уйналган иде. Килүче аз булдыгыннан, доходы расходка да йитәрлек булмады.

*«Вакыт», 1911, 30 сентябрь.*

**Учитель вә учительница кирәк**

Минзәлә шәһәренә мөселман учителе кирәк. Мәгаше[321] 400 сум. Кади карьясенә мөселманча учительница кирәк. Мәгаш 300 сум. Килергә теләгән кешеләр әгәр урында булсалар, шул йирдә булган инспектордан рөхсәт кәгазе алып, урында булмасалар, мөгаллимлек шәһадәтнамәләрен һәм элек хезмәт иткән йирләрендә ничек тәгълим вә тәрбия биргәнлекләре хакында тасдыйкнамә[322] алып, Минзәлә народный училищелар инспекторына мөрәҗәгать итәргә тиеш. Башкалар мәгълүмат алырга вә хәбәрләшергә теләүчеләр өчен адрес будыр:

Г. Мензелинск

Мулле Усманову.

*«Вакыт», 1912, 5 гыйнвар.*

**[Фатыйма-Фәридә ханым идарәсендәге...]**

Фатыйма-Фәридә ханым идарәсендәге 1нче кызлар мәктәбендә имтихан апрель 16нда дүшәмбе көн башланып, пәнҗешәмбе көнгә кадәр дәвам итәчәктер. Гыйлемгә мәхәббәте булган ханым, әфәнделәр имтихан мәҗлесенә рәхим итсеннәр. Имтихан иртә сәгать 9 ярымда башланадыр.

*«Сибирия», 1912, 14 апрель.*

**Минзәлә хәбәрләре**

Минзәләдә рәсми ирләр мәктәбе ачылганга 2 сәнә булып, мәктәптә 110 шәкерт укыйдыр. Мәктәп икесе рус лисаны[323] вә өч дин мөгаллиме улмак үзрә[324], барысы 5 мөгаллим тарафыннан идарә ителәдер. Мәктәп мөселманча

[320] Кифая итәрлек – җитәрлек.
[321] Мәгаш – хезмәт өчен алынган акча.
[322] Тасдыйкнамә – раслау кәгазе, таныклык.
[323] Лисан – тел.
[324] Үзрә – буенча.

ислам рухында мөкәммәл тәрбия бирүе илә бәрабәр русча ибтидаи мәктәп правасын бирәдер. Уку мөддәте[325] 5 сәнә.

Минзәләнең бер кимчелеге, рәсми кызлар мәктәбе улмаудыр. Фәкать имам Исмәгыйль Госманов әфәнде[326], киләсе уку елыннан бу кимчелекне дә тутырырга ниятләп торадыр. Исмәгыйль әфәнде мохбиреңезгә киләсе елдан рәсми кызлар мәктәбенең катгый ачылачагын сөйләде.

Хөкүмәт мәктәпләрендә Минзәлә мөселманнарыннан укучылар булып, реальныйда 7 бала, городскойда 10 бала укыйлар. Приходскойга керергә теләүчеләр күбрәк булса да, бары 10 гына кабул ителгән.

Кызлар гимназиясендә бары ике генә (5–6 классларда) мөслимә булып, алар да авыллардан килеп укучылар, шәһәрнең үзеннән берәү дә укучы юк.

*«Сибирия», 1913, 25 гыйнвар.*

***Мәһруй Мозаффария***

**«Көл гыйлем әфзаль мин җәһлән»**[327]

Безнең Казан ханымнарыннан уртача гына көнкүрешле ханымнарның кул һөнәрләре дә юк түгел. Үземезнең милли булган киемнәремездән кәләпүш, калфак, читек эшләү илә мәшһүрләрдер. Бөтен Русия татарларына кәләпүш кидертүче безнең казанлы ханымнары диярлектер. Ләкин милли киемнәр эшләү илә милләткә бер тиенлек файда китерә алганымыз юк. Кәләпүш, калфак эшләүдән максудымыз – өс-башларымызны бер-беремездән арттырырга тырышудыр. Эчләремезгә гайбәт тутырып, тышларымызны курчак ясап йөрүләремездән ни мәгънә чыга. Истикъбальләремез[328] өчен һич тырышуымыз, юк-бар кайгыбыз ачау, эчү, киенү, мал арттыруда кирәкле нәрсәләрдән мәгълүмат алып, балаларымызга дин вә әдәп үгрәтеп, үземездән арткан малларымызны милләт юлына сарыф кылсак, менә без шул вакыт инсан[329] дәрәҗәсенә керә алырмыз дип беләм.

Мәҗлес вә җәмгыятьләремездә истикъбалемезне яд итеп уку вә укыту, үземезгә файдалы һөнәрләр үгрәтү вә үгрәнү мәсьәләләрендә бәхәс ачсак, үзебез өчен файдалы эш кылган булыр идек.

Бу соң елларда уку-укыту эшләренә әһәмият бирүче ханымнар күренгәләсә дә, бик сирәк, күбрәге үз файдасына тырышып, фәкыйрә вә ятимәләр өчен тырышучы бик аз.

Бу соң елларда шәһәремезнең могътәбәр ханымнарыннан Фатыйха ханым Аитованың мәктәп ачып, фәкыйрә вә ятимә кызларны монтазам[330]

---

[325] Мөддәт – срок, ара.

[326] Исмәгыйль Госманов (Госмани) – мулла, Уфа губернасындагы Килем авылы, Минзәлә, Оренбург һ.б. мәдрәсәләрдә мөгаллимлек итә.

[327] «Һәр гыйлем наданлыктан, белемсезлектән кадерлерәк» мәгънәсендә.

[328] Истикъбаль – киләчәк, булачак.

[329] Инсан – кеше, адәм.

[330] Монтазам – тәртипкә салынган, рәтле, тәртипле.

тәрбия итүе шатлыклы хәлләремездәндер. Аллаһы Тәгалә озак вакытлар дәвам итәргә насыйп итсен.

*«Сибирия», 1913, 30 гыйнвар.*

***Разыя Җәмилева***

## [Бөре өязе мәшһүр Борай карьясендә[331]…]

Бөре өязе мәшһүр Борай карьясендә 5нче, 6нчы майда ике көн Мәрьям ханым Әхмәрованың кызлар мәктәбендә 270 кадәр кызларга сәнәви[332] имтихан булды. Карья һәм әтрафтан күп ханымнар килгәннәр иде. Кызларның уку-язу, хисап, җәгърафия, тарих һәм дин дәресләре өстенә, 23 төрле әгъла[333] вә чиста кул һөнәрләре өйрәнүләренә зиядә[334] тәхсин иттеләр[335]. Мәрьям ханым өч сәнәдән бирле ошбу рәвештә иҗтиһад кылып[336], авылда «кул һөнәре түгел, уку-язу нигә кирәк» дигән бер халыкка, бу көн шулкадәр гыйлемгә ихлас баглатуына имтиханда булган без, хатыннар, аеруча тәшәккер итәмез[337], һәм шул тәшәккеремезне милли гәзитәмез аркылы ишеттерүне үземезгә бурыч саныймыз. Бер косур[338] булса, ул да мәктәпнең кечкенә булуыдыр. Әлбәттә, моны байларымыз игътибарга алырлар дип өмет итәмез.

*«Вакыт», 1913, 17 май.*

## [Уфа мөселманнарында уку…]

[...] Җәмгыять хәйриянең беренче мәктәбе Сары мәдрәсәдә 120 кыз, 3 мөгаллимә һәм бер мөгаллим (бусы Мөхәммәтҗан казый Исмәгыйлев);

Гайшә ханым Абызгилдина мәдрәсәсендә 131 кыз, 4 мөгаллимә;

Спасский урамындагы кызлар мәдрәсәсендә 30 кыз, бер мөгаллимә;

Сафрун пристанендагы мәдрәсәдә 30 кыз, бер мөгаллимә;

Тайсуганский полянка мәдрәсәсендә Идел аръягында 25 кыз, бер мөгаллимә;

Иске Уфада Пасадский урамында 31 кыз, бер мөгаллимә;

Ключевский урамында 30 кыз, бер мөгаллимә;

Бу мәктәпләр җәмгыять хәйрия тарафыннан тәрбия ителә;

Болардан башка, Садрый Назыйров[339] тәрбиясендә ике мәктәп булып, икесендә 150 кыз, 4 мөгаллимә;

---

[331] Хәзер Башкортстанның Борай районы үзәге.

[332] Сәнәви – еллык.

[333] Әгъла – иң югары дәрәҗәдә.

[334] Зиядә – арту, күбәю.

[335] Тәхсин итү – мактау.

[336] Иҗтиһад кылу – тырышу.

[337] Тәшәккер итү – рәхмәт әйтү.

[338] Косур – кимчелек.

[339] Садретдин Назыйров, сәүдәгәр, химаяче, Уфада «Назыйрия» мәдрәсәсен һәм башка мәктәпләрне ачкан.

Тимер юл түбән ягындагы Яһудиннар тәрбиясендәге мәктәптә 55 кыз вә ике мөгаллимә;

Хәкимовлар тәрбиясендәге мәктәптә 55 кыз;

5нче мәхәлләдәге кызлар мәктәбендә 60 кыз.

Бөтен Уфада 717 кыз бала укыйдыр. Моннан соң Уфадагы рус мәктәпләрендәге ир вә кызларның да саннарын күрсәтеп китәчәкбез.

*«Тормыш», 1913, 18 октябрь.*

**Уфадагы рус мәктәпләрендә укучы мөселман кызлары:**

Мариинский женский гимназиядә барлыгы 19 кыз укыйдыр. Болардан 3се бу ел тәмам итәләр;

Икенче женский гимназиядә 7 кыз укыйдыр (соңгы класста бу сәнә бер дә мөселман кызы юк);

Частный женский гимназиядә 21 кыз укыйдыр. Мөдирәнең сөйләвенә караганда, частный гимназиядәге мөселман кызлары «башкаларга караганда һәркайда беренче баралар» икән. «Хосусый рәсем дәресләреннән аларда аеруча истигъдад[340] булып, мөселман кызларының эшләгән рәсемнәре Киевтагы «Российская выставка»га да җибәрелгән. Аларныкыннан шәп чыккан рәсемнәр булмаган. Безнең мөселманнарда күп бәхетләр наданлык астында изелә. Эшләнми калып, харап булалар», – ди.

Мариинский женский двухклассный приходской училищеда 5 кыз. Шул ук школаның кечке педагогический курсында 15 кыз;

Первый городской русско-башкирский женский училищеда 65 кыз укый;

Русско-башкирский женский двухклассный училищеда пансионда укучылар 42 кыз булып, йөреп укучылар 40 кыз. Барлыгы 82 кыз.

Барлык рус мәктәпләрендә укучы кызлар исә 214 гадәддер[341].

*«Тормыш», 1913, 27 октябрь.*

***Маһирә Шакирова***

**Петропавел кыйраәтханәсе[342]**

Без, Петропавел хатын-кызлары, мөселман кыйраәтханәсенең идарәсенә гариза биреп, хатыннар кереп укыр өчен дә көн билгеләүне үтенгән идек. Әгәр дә әгъзалары гаризамызны кабул итеп, шимбә вә чәршәмбе көннәрне безгә билгеләделәр һәм без керә торган көнне кыйратханәдә торыр өчен бер назыйрә[343] куйдылар, бу эшләре өчен аларга чын күңелемездән рәхмәтләр укыймыз.

---

[340] Истигъдад – сәләт.
[341] Гадәд – санда.
[342] Кыйраәтханә – уку өе, китапханә.
[343] Назыйрә – мөдирә.

Без шимбә, чәршәмбе дүрт күз илә көтеп, шул көннәрдә 50–60 лап җыела вә укый идек. Байтагымызның күзләре ачыла башлаган иде. Шатлыгымыз сөйләп бетерерлек булмады.

Фәкать шатлык озакка бармады. Һәрнәрсәгә каршы торучы мәшһүр бер баебыз безнең тәрәккыебезгә[344] аяк чалырга кереште. Шуның тәэсире илә базар вә мәйданнарда халык безгә каршы күтәрелә башлады. Аларга бер ялганчы тәрәккыйпәрвәр[345] кушылып, хәзер безне кыйраәтханәдән мәхрүм итәргә йөриләр. Боларның эшенә без чын күңелдән протест итеп, саф күңелле әфәнделәрне үзебезгә ярдәм итәргә чакырабыз.

Кыйраәтханәгә йөрүче хатын-кызлар исеменнән Маһирә Шакирова.

*«Тормыш», 1913, 8 ноябрь.*

## [Ханымнар гаризасы...]

Ханымнар гаризасы: Казан ханым вә туташлары җыелып, Казан «Көтапханәи[346] исламия»сенең[347] һәйәт[348] идарәсе исеменә гариза биреп, атнасына бер, я ике көн көтапханәгә хатын-кызлар кереп укырга тәгаен кылынуны үтенмәкче булганнар. Һәм йөзгә якын ханым вә туташлардан имза да җыйганнар инде.

«Көтапханәи исламия» һәйәте боны берсүзсез кабул итәрләр, атнасына ике көнне хатын-кызларга кереп укырга тәхсыйс итәрләр[349] дип, тәмам ышанабыз. Артыннан йөрүче ханым вә туташларга чын күңелебездән рәхмәт укыйбыз.

*«Сөембикә», 1913, №2, б.17.*

## [Минзәлә өязе Әлмәт-мулла волосте Сарман авылында[350]...]

Минзәлә өязе Әлмәт-мулла волосте Сарман авылында 1907 елда вакыф[351] акчадан егерме аршин озынлыкта бер кызлар мәктәбе ачылып, авылның кыз балалары шул мәктәптә бик яхшы гына укып килгәннәр икән. Бу ел шул эшнең башында торып, вакыф акча белән мәктәпне салдырган кешенең мәктәпне сатып, бөтен авыл балаларын укудан мәхрүм итеп калдырганын зарланып язалар. Дөрес булса, бик начар эштер.

*«Вакыт», 1913, 13 декабрь.*

---

[344] Тәрәккый – алга китү, прогресс.

[345] Тәрәккыйпәрвәр – алга китү, прогресс яклы кеше.

[346] Көтепханә – китапханә.

[347] «Көтепханәи исламия» – 1906 елда педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Әхмәдһади Максуди тарафыннан Казан шәһәрендә ачылган җәмәгать китапханәсе. Китапханә хәзерге Тукай урамы, 37/20 йортында урнашкан була. 1929 елда «М.Вахитов исем. Көнчыгыш китапханәсе» итеп үзгәртелә.

[348] Һәйәт – комитет, комиссия.

[349] Тәхсыйс итү – бер нәрсәгә раслау, билгеләү.

[350] Хәзер Татарстанның Сарман районы үзәге.

[351] Вакыф – берәр кеше тарафыннан килерен җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек.

***Мәһруй Мозаффария***

**Яңа һәм мөһим эш**

Шөкерләр улсын, безнең Казан ханым вә туташлары да күзләрен ачып тәрәккый[352] юлына әһәмият бирә башладылар. Бу ел Казан хатын вә туташлары арасында бик мөһим яңа эш булып китте. Ул исә «Көтепханәи исламия»гә һәфтәдә[353] бер яхуд ике көн кереп, китап, журнал һәм гәзитәләр моталәга кылу[354] максады илә йөздән зиядә[355] ханым вә туташларның имзасы илә гариза бирелүедер. Ул бирелмеш гариза «Көтепханәи исламия»нең мөәссисе[356] вә фәхри[357] назыйры[358] Әхмәдһади әфәнде Максудиның иҗтиһады[359] саясендә[360] тиз көннән вөҗүдкә чыкты[361]. Дүрт күз илә көтеп алган көтепханәбез 8нче декабрьдә якшәмбе көн ханым вә туташлар өчен сәгать 12 дә ачылып, Зәйнәб ханым Максудия[362] көтепханәнең тарих вә әхваленнән бераз нотык сөйләде. Иҗтиһад итеп йөрүче ханым вә туташларга да тәшәккер кылып[363], соңра остазбикә вә мөгаллимәләрдән дога кылуларын үтенде. Абыстай вә мөгаллимәләр көтепханәнең дәвамын теләп, шатлык илә дога кылдылар. Алкин йортындагы кызлар мәктәбеннән ибтидаи[364] 4нче сыйныф шәкертләре (20 кыз) һәм мөгаллимәләр дә килгәннәр иде. Һәркаюсы ишектән керү илә көтепханәнең дәфтәренә имзаларыны куеп, гәзитә вә китап моталәгасенә керештеләр. Соңра кыйраәтханәнең[365] дәвамын теләп, һәр якшәмбе көн бару нияте беләң, кыйраәтханәнең тәмиз[366] вә бик пөхтә булуына мәмнүнә булып[367], өйләренә кайтып киттеләр.

Ни сәбәпледер, бәгъзе ханым вә туташлар көтепханәнең дәфтәренә имзаларын куймый чыгып киттеләр.

11 декабрь.

*«Сөембикә», 1913, №4, б.15.*

[352] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[353] Һәфтә – атна.
[354] Моталәга кылу – уку, өйрәнү.
[355] Зиядә – артык, күп.
[356] Мөәссис – нигез салучы, коручы, башлаучы.
[357] Фәхри – хөрмәтле, мактаулы.
[358] Назыйр – мөдир.
[359] Иҗтиһад – тырышу.
[360] Сая – күләгә, ышык.
[361] Вөҗүдкә чыгу – бар булу, тормышка ашу.
[362] Зәйнәб Максудова – Әхмәдһади Максудиның тормыш иптәше.
[363] Тәшәккер кылу – рәхмәт белдерү.
[364] Ибтидаи – башлангыч.
[365] Кыйраәтханә – китапханә.
[366] Тәмиз – чиста, пакъ, пөхтә.
[367] Мәмнүн булу – риза булу.

***Мохбир***

**Троицк ханымнары**

Троицк ханымнары кыйраәтханәгә кереп, китап, гәзитә һәм журналлар укып файдалану өчен, үзләренә махсус көн тәгаен кылуны сорап, гариза биргәннәр иде. Гаризалары кабул ителеп, тасдыйк кылынды[368]. Имде 10нчы декабрьдән башлап, сишәмбе, пәнҗешәмбе көннәрдә кыйраәтханәгә фәкать хатын-кызлар гына керәчәк. Ул көннәрдә ирләр кермәячәк. Хатын-кызларның керү вакытлары иртән сәгать 9 дан 11 гә кадәр, өйләдән соң сәгать 1 дән 4 ярымга кадәр. Һәм дә махсус назыйрә[369] куелды.

*«Сөембикә», 1913, №4, б.15.*

***М.Салихова***

**Кыйраәтханәдә хатыннар**

Троицк. 10нчы декабрьдә беренче мәртәбә ханымнарга китапханә ишеге ачылды. Әүвәлге көнне килүче ханым вә туташларның саны 70 кә, икенче мәртәбә 96 га йитте. Ханым-туташлар тәртипле, бик яхшы ригая кылып[370], тәнзыйматка хилаф[371] бер эш күрсәтмәделәр. Килүчеләр арасында яшьләр, урта яшьле ханымнар бар иде. Китаплардан күбрәк роман вә хикәяләр укыдылар. Бәгъзе мөгаллимәләр генә тарих вә башка милли китаплар алгаладылар. Билгеле сәгать йиткәч, һәрберсе китап вә журналларны урыннарына куеп, чыгып киттеләр. Моннан соң да шул хәл дәвам итсә, Троицк ханымнары үзләренең тәрбияле ханымнар улдыкларын ачык сурәттә исбат итәчәкләрдер.

*«Тормыш», 1913, 22 декабрь.*

**Рус мәктәбендә мөселман кызлары**

Уфаның Мариинский гимназиясендә 19, Икенче гимназиядә 7 мөселман кызы укый икән. Шул гимназияләрнең берсеннән аларга исламча дин дәресләре укытылмавыннан зарланып, «Тормыш»ка язганнар.

*Вакыт, 1914, 15 гыйнвар.*

---

[368] Тасдыйк кылу – раслау.
[369] Назыйрә – мөдирә.
[370] Ригая кылу – игътибар итү.
[371] Тәнзыйматка хилаф – каршы, ярамаган.

***Гайшә бинте Сәлим***

## Тәсхыйх[372]

«Вакыт»ның 1366 номерында «Сарман авылының кызлар мәктәбе сатылды» дип тәәссеф кылып[373] язылган бер мәктүб[374] күренгән иде. Монда нинди булса бер аңлашылмау булырга кирәк. Чөнки ул мәктәп сатылмады. Пристав тарафыннан тәнбиһ[375] ясалгач, рәсми бер кеше нәзарәтендә[376] булсын дип, икенче мәхәллә имамының ишек алдына күчерелеп салынды.

Бу мәктәп моннан 7 ел элек шул авылда торучы Мөхәммәдша хаҗиның һиммәте[377] аркасында салынып, һәр ел шул зат тарафыннан жалуния бирелеп, мөгаллимә китерелеп тора иде. Күчереп салыну илә дәресләр башланып, элеккедәгечә бик яхшы дәвам итәдер.

Күктәкә авылында[378] мөгаллимә Гайшә бинте Сәлим.

*«Вакыт», 1914, 15 гыйнвар.*



Хәдичә Әхмәрова
*(Сөембикә, 1914, №8)*

## [1901нче елга кадәр...]

1901нче елга кадәр Казанда кызлар өчен мәктәп юк иде дисәк, аз хата итмәс булырмыз. Дөрестә дә, кызлар өчен тәртипле бер мәктәп юк иде. Әүвәл боны бар итүче Хәдичә ханым Әхмәрова[379] булды. Хәдичә ханым Әхмәрова татар кызлары укыр өчен бер мәктәпнең дә булмавына эче әрнеп, ничек тә бер кызлар мәктәбе ачарга кирәксенде. Инспекторларга мөрәҗәгать итте. Татар кызлары өчен бер мәктәпнең кирәклеген аңлатты. Бу мәктәпне ачарга ничек тә булса ярдәм итүләрен үтенде. Ниһаять, инспектор Браковскийның тырышуы саясендә[380] 1901 ел, 7нче гыйнварда кызлар мәктәбе ачарга рәсми рөхсәт алынып, хөкүмәт тарафыннан тасдыйк ителде[381]. Һәм Хәдичә ханым

---

[372] Тәсхыйх – дөресләү.
[373] Тәәссеф кылу – үкенү.
[374] Мәктүб – хат.
[375] Тәнбиһ – кисәтү.
[376] Нәзарәтендә – карамагында.
[377] Һиммәт – тырышлык.
[378] Күктәкә авылы – хәзер Татарстанның Азнакай районына керә.
[379] Хәдичә Шаһиәхмәт кызы Әхмәрова (1861–1945) – Казанда беренче булып хөкүмәт хисабына татар кызлары өчен рус-татар мәктәбе ачучы, тәрҗемәче, КТУШ инспекторы Шаһбазгәрәй Әхмәровның тормыш иптәше.
[380] Саясендә – күләгәсендә.
[381] Тасдыйк ителү – раслау.

Әхмәрова шул мәктәпкә почетный назыйрә[382] булып тәгаен ителде. Боны ачкан вакытта Хәдичә ханым күп авырлыклар күрде. Күп сүзләр ишетте. Күп кеше, кызлар өчен кирәкмәгән рус мәктәбе ача дип, аны шелтәләде. Ләкин Хәдичә ханым аларның берсенә дә карамады. Үзе кирәк дип белгән нәрсәне эшләде. Ул анда русча классы белән генә калмады. Кызларга татарча укуны да кирәксенде. Казанның берничә олуг могътәбәр[383] кешеләренең мәслихәте[384] белән, Печән базары мулласы Хуҗаәхмәт хәзрәт[385] рафикасы[386] Маһруй ханым Мозаффариягә мөрәҗәгать итеп, аның татарча кыйсеменә[387] мөгаллимә булуыны сорады. Маһруй ханым да мөтәгассыйб[388] адәмнәрнең кыңгыр карауларына күп илтифат итми[389], үзенең батырлыгы белән мөгаллимәлекне кабул итте. Шул ук елны кул һөнәре кыйсеменә дә рөхсәт алынып, аның өчен янә махсус мөгаллимә куелды. Шул елдан бирле бу мәктәптә укып чыккан туташларымызның гимназиягә кереп укыганнары гына 30дан артыктыр. Хәзер бу мәктәптә русча класста ике учительница, кул эшендә бер, мөселманча кыйсемендә шул ук Мозаффария ханымдыр. Менә шул кызларымызга беренче юлбашчы булган Хәдичә ханым Әхмәрованың рәсемене кариэләремезгә[390] гарыз итәмез[391].

*«Сөембикә», 1914, №8, б.3–4.*

***«Татар угылы»***

### Сембер губернасында хосусый кызлар мәктәбе

Бу ел март башларында хосусый бер йомыш илә Сембердә һәм дә мөселманнарның күплеге вә мөселман фабрикалары, мәдрәсәләре илә мәшһүр Зөя Башында[392], мәшһүр миллионер Акчуриннарның Гурьевкадагы фабрикаларында булдым. Менә шул булынган йирләремдә мөселман фабрикаларының эшләре, мөселман хезмәтчеләренең хәлләре илә танышлыгым кеби, бигрәк бу өч йирдәге соң заманда гына салынган кызларга махсус булган мәктәпләрнең матди, мәгънәви җәһәтләренә[393] әһәмият биреп, кызлар мәктәбенең хәле илә якыннан таныштым. Сембер, Зөя Башында,

---

[382] Назыйрә – мөдирә.
[383] Могътәбәр – хөрмәтле, зыялы, затлы.
[384] Мәслихәт – киңәш.
[385] Хуҗаәхмәд хәзрәт Мозаффари (1838–1907) – Печән базары мәчете имамы.
[386] Рәфыйка – иптәш, тормыш иптәше.
[387] Кыйсем – өлеш.
[388] Мөтәгассыйб – фанатик.
[389] Илтифат итү – әһәмият бирү, игътибар бирү.
[390] Кариэ – укучы.
[391] Гарыз итү – бер эш яки хәл турында телдән сөйләп яки язып тиешле урынга аңлату, җиткерү.
[392] Зөя Башы – хәзерге Ульяновск өлкәсенең Барыш районындагы авыл.
[393] Җәһәт – як.

Гурьевкада кызлар мәктәбенең миңа биргән тәэсирен мөхтәрәм «Тормыш» укучылары илә уртаклашмакчы булам. Иң элек Сембердәге кызлар мәктәбе хакында бераз мәгълүмат биреп, соңра рәт илә Зөя Башындагы мөхтәрәмә Маһруй, Мәргубә, Бәдриҗамал ханым Акчуриналарның [394] тәрбияләрендә булган мәктәпләр илә Гурьевка фабрикасындагы кызлар мәктәбе хакында үземнең тәэсиратымны язмакчы булам.

Бер милләтнең тәрәккыйсе[395] өчен аналар йитештерү тиеш булса да, без, Русия мөселманнары, бу гомуми кагыйдәне ригая кылып[396], иң элек кызларымызны укытмыйча, ир балаларны гына укыта башладык. Кызлар тәрбиясе икенче дәрәҗәгә генә түгел, өченче дәрәҗәгә төште. Хәмед[397] булсын, соңгы заманнарда бу хатамызны сизә башладык. Шул мөнәсәбәт илә кызлар тәрбиясенә ирләремездән бигрәк аналар, туталарымыз үзләре әһәмият бирә башладылар. Хәмитле[398] бай гаиләләре, бай хатыннары үзләре мәктәп ачып, матди җәһәтен тәэмин итеп, кызларымызны укыта башладылар. Казандагы хосусый кызлар мәктәбен Аитова ханым[399] ачты. Һәм үзе тәрбия кыла. Зөя Башындагы ике данә кызлар мәктәбе ачып, матди җәһәтен тәэмин итүчеләр әлеге мөхтәрәмә Мәргубә, Бәдриҗамал, Маһруй ханымнардыр. Максаттан читкәрәк чыгылды, хөрмәтле укучылар, гафу итегез.

Сембер каласы – Идел буендагы калаларның сәүдә, гыйлем җәһәтеннән түбән урын тотучыларыннан берседер. Чөнки Сембер яңа гына тимер юл илә башка калаларга тоташты. Идел күпере ясалып йиткәч, Сембернең икътисади җәһәте күтәрелер. Шулай булса да, Сембердәге руслар, яһүдләр, поляклар вә башка милләтләр тик ятмыйлар. Бөтен сату алар кулында, һәр төрле гыйлем, һөнәр йортлары байтак. Фәкать бу көнгә кадәр Сембер мөселманнары гыйлем вә икътисади җәһәттән бик түбән урын тотып килделәр.

Алдыгым мәгълүматка күрә, Сембердә өч мең кадәр мөселман бар. Йорт-йир илә торучылар да байтак. Фәкать шул өч мең мөселман исеменнән эшләнгән бернәрсә дә юк. Мәсҗет-мәдрәсә Акчуриннар тарафыннан салынган. Ягучы-яктыртучы янә алар. Сембер халкының әүвәлге һәм хәзерге хәзрәтләре яңа тәртип илә укытуга каршы торганга, мәдрәсә тәртипкә салынмады. Ир вә кыз балаларны укытыр өчен дә мәхәллә исеменнән ибтидаи[400] мәктәпләр ачылмаган. Бары Хәсән әфәнде Акчуринның[401] һиммәте[402] илә яңа тәртип илә укыла торган бер данә ирләр вә бер данә кызлар мәктәбе ачылып, бу көнгә кадәр дәвам итмеш. Ниһаять, укучы кызлар

[394] Акчуриннар гаиләсеннән чыккан мөгаллимәләр.
[395] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[396] Ригая кылу – игътибар итү.
[397] Хәмед – мактау, шөкер итү.
[398] Хәмит – мактаулы, мактауга лаеклы.
[399] Аитова ханым – Казандагы кызлар мәктәбе җитәкчесе Фатыйха Аитова.
[400] Ибтидаи – башлангыч.
[401] Хәсән Тимербулат улы Акчурин (1866–1916) – I гильдия сәүдәгәре, фабрикант, хәйрияче; 1914 елда Гурьевка авылында эшчеләр өчен китапханә ачкан.
[402] Һиммәт – тырышлык.

күбәйгәч, монтазам[403] кызлар мәктәбе ачу кирәклеге аңлашылмыш. Бу шәрәфле эшне дә Сембернең ике бае – Абушаев[404] илә Бәхтиев[405] җәнабләре эшләгәннәр: кызлар мәктәбе салып бирергә теләдекләрен белдермешләр.

Җәмәгать хадимнәреннән мөхтәрәм Ибраһим әфәнде Акчурин җәнабләре[406], бу гүзәл фикерне тәкъвия итеп[407], үзе кала идарәсендә гласный булганга күрә, аның һиммәте илә кызлар мәктәбен салыр өчен кала идарәсеннән каланың матур урамыннан бушлай йир алырга муафыйк булганнар[408]. Ибраһим әфәнде бу хосуста байтак хезмәт иткән. Мәктәпкә рәсми сурәттә изен[409] алып бирүне дә Ибраһим әфәндегә тапшырганнар. Ибраһим әфәнде аны да эшләргә муафыйк булган. Кызлар мәктәбе салырга изен бирелгән. Кызлар мәктәбе ачу хакында мөгаллим Мирза Салих әфәндедәнең дә хезмәтләре күп булган. Шулай итеп, гел Акчуриннарга гына салынып яткан Сембер мөселманнары, Абушаев, Бәхтиевлар кеби һиммәтле сәүдәгәрләр саясендә кызлар мәктәбенә дә ия булганнар. Менә шул кызлар мәктәбе бу ел көз ачылып, дәрес укыла башлаган.

Һәр никадәр кызлар мәктәбенә ирләрне кертмәсәләр дә, мин читтән килгән мөсафир[410] булгангамы, миңа керергә рөхсәт бирделәр. Минем янымда Фатыйха ханым[411] илә ханым Солтанова[412] да бар иде. Кызлар мәктәбе агачтан ике кат итеп салынган. Бик мөкәммәл[413], зур, якты, сыйныф саен бүлмә бар. Йөз илледән артык кыз укый. Дүрт мөгаллимә укыта. Сыйныфларның саны йиде имеш. Фәкать, бу хосустан тугры мәгълүмат ала алмадым. Чөнки кызлар мәктәбе тарафыннан мәгълүмат бирерлек бер ир яхуд бер ханымны да күрә алмадым. Сембер хәзрәтенең шәригате буенча мөхтәрәмә мөгаллимә ханымнар качындылар. Беренче, икенче, өченче, дүртенче, бишенче сыйныфларда булдык. Аларга укыган дәресләреннән сөальләр бирдек. Кувә-фикрияләрен[414] аңламак өчен, програм тышындагы сөальләр бирелде. Җавап бирүче шәкертләр байтак булды. Фәкать милли мәктәптә бирелгән фикер, аң бик түбән. Хәзергә моны гаепләргә мөшкел. Чөнки рәсми мәктәп бу ел гына ачылган. 6–7 сыйныфларга керсәк тә, анда укучыларны

---

[403] Монтазам – тәртипле, тәртипкә салынган.

[404] Мөхәмммәткәрим Абушаев – күренекле сәүдәгәр, химаяче. Сембер шәһәрендә мөселман хәйрия җәмгыяте әгъзасы, кызлар мәктәбенә матди ярдәм күрсәтеп торган.

[405] Зариф Бәхтиев – сәүдәгәр, фабрикант, Сембер шәһәр думасы гласные, Мөселман хәйрия җәмгыяте әгъзасы, мәктәпләргә ярдәм итеп торган.

[406] Ибраһим Акчурин – сәүдәгәр, фабрикант, җәмәгать эшлеклесе, «Сембер сукно җитештерүчеләр җәмгыяте» башлыгы, Сембер шәһәр думасы гласные.

[407] Тәкъвия итү – ныгыту, куәтләндерү.

[408] Муафыйк булу – яраклы, кирәкле, урынлы табу.

[409] Изен – рөхсәт.

[410] Мөсафир – юлчы.

[411] Фатыйха ханым – Фатыйха Аитова.

[412] Солтанова – Мәрьям Солтанова.

[413] Мөкәммәл – тәмамланган, камилләшкән.

[414] Кувә-фикрия – фикерләү сәләте, фикерләү көче.

күрмәдек. Чөнки ул бичара мәгъсум[415] кызлар да, Сембер мулласының шәригате тәэсире астында яшиләр икән.

Сөйләүләренә караганда, сыйныфтан башлап чыгучы хәзрәтнең үз кызы булган, аның артыннан башка кызлар да чыкканнар. Без мәктәптә булындыгымыз чакта, сыйныфларга кереп йөргәндә, әлеге югары сыйныфта укучы мөхтәрәмә шәкертләремез коридор буена чабып безнең арттан йөрделәр. Төркемнәре илә без булынган сыйныфның ишеге төбендә тордылар. Мөгаллимә ханымнар да алар илә бергә иделәр. Менә яңа гына ачылган каладагы кызлар мәктәбендә хиҗаб[416] ничек саклана. Мондый кызларны дин, шәригатьне тотмый дип әйтергә мөмкинме? Менә ничек хәзрәт кызлар мәктәбенә тәэсир итә. Мондый хәзрәтләр тәэсире астында булган мәктәпләрдән зур файда өмет итәргә ярыймы? Мәктәп аркылы ялгыш фикер, начар игътикад[417] киләчәктә милләт анасы булачак кызларымызга да ирелешсә, безнең хәлемез ни улачак? Әллә никадәр мал, һиммәт вә зур өметләр илә салынган кызлар мәктәбендә бу кимчелекне, бу вәхшилекне гади бер эш дип кенә узарга ярамый. Бу хосуста мөхтәрәмә мөгаллимәләрнең нәзар[418] дикъкатьләрен җәлеп итәм. Дини рух, милли тойгы бирә торган тәрбия йортында укучы кызларның бүредән курыккан куйлар кеби коридор буена чабып йөрүләре бу мәктәпнең хәзрәт, урам татарларының тәэсире астында улдыгын бик ачык күрсәтсә кирәк. Мәктәпне салучыларга, дәвамына ярдәм итүчеләргә рәхмәт әйтеп, киләчәк уку елында мөгаллимә ханымнарның шәкертләренә җитди тәрбия бирүләрен, мәктәпкә якын торучы затларның мәктәпнең гыйлем-әдәп урыны улдыгына дикъкать итүләрен тәүсыя итеп[419], сүземезне кисәм.

Мәктәптә фән дәресләре, файдалы кул һөнәрләре аз үгрәтелә икән. Һәр хәлдә, киләчәктә бу мәктәпнең тәрәккыйсен чын күңелемнән телим. Бу көнге кимчелекләрне сөйләү киләчәктә ислах улынырга сәбәп булсын иде.

*«Тормыш», 1914, 23 март.*

***«Татар угылы»***

## [Үткән мәкаләмдә Сембердәге кызлар мәктәбе...]

Үткән мәкаләмдә Сембердәге кызлар мәктәбе турында кыска гына мәгълүмат биргән идем. Бу мәкаләмдә Сембер губернасында Зөя Башындагы кызлар мәктәбе хакында бераз язып үтмәкче булам. Максатка керешүдән элек, Зөя Башы хакында бер-ике сүз әйтеп үтүне тиеш күрәм. Зөя Башы бер авыл булса да, аның халкы уездный каланыкы кадәр бар. Зөя Башында 10 меңгә якын мөселман бар. Табигый, бу хисап тәхминидер[420]. 8 мәсҗет, йидесе

[415] Мәгъсум – гөнаһсыз, керсез.
[416] Хиҗаб – пәрдә, йөз өрткеч, оялчанлык.
[417] Игътикад – чын күңелдән ышану, инану.
[418] Нәзар – карау, караш.
[419] Тәүсыя итү – киңәш бирү.
[420] Тәхмини – чама белән, якынча.

манаралы, зур, мөкаммәл[421] мәсҗеттер. Берсе манарасыздыр. Имам, мөдәррисләренең саны мәсҗетләрдән күбрәк, чөнки кайсы мәсҗетләрдә икешәр имам. Зөядә искедән бирле берничә данә мәдрәсә дәвам итеп килсә дә, бу соңгы елларда ул мәдрәсәләрнең исемнәре генә калмыш. Бу мәдрәсәләрдә заманга муафыйк тәрбия бирелмәгәнгә күрә, шәкертләр таралып бетмешләр. Ирләргә махсус күзгә күренердәй, заманга муафыйк тәрбия бирә торган мәктәп ике-өч данә генәдер. Зөя Башында шулкадәр халык күп булса да, кызлар укытуга һич әһәмият бирмәгәннәр. Бичара тута-сеңелләремез төрле әбиләр кулында укыячак булып, җитди тәрбиядән мәхрүм булып калганнар.

Зөя Башы халкы, Зөянең рухани вә зыялылары, байлары хатын-кыз тәрбиясенә бер тиенлек тә әһәмият бирмәгәннәр. Шуның өчен дә Зөя Башы хатын-кызлары матур кием кию, ашау-эчү, өйдән-өйгә йөреп, кунак сыйлашып мәгънәсез сүзләр сөйләүдән башка, милләт вә җенестәшләре булган тута-сеңелләренә хезмәт итмиләр. Йорт идарәсен, бала тәрбиясен аңламыйлар. Ирләренә тормыш-аркадаш була белмиләр. Шуның өчен Зөя Башы хатын-кызлары ирләренә, гаиләләренә бер дә тәэсир итә алмыйлар. Гаилә тормышы тәртипсездер. Зөя Башының хатын-кызлары гыйльми, икътисади җәһәттән[422] бик түбән урын тоталар. Шуның өчен дә, Зөя Башының ирләре дә салкын табигатьле, гомуми эшләргә, бигрәк тә уку-укыту эшләренә, бер дә әһәмият бирмиләр. Мөгамәләләрдә бик дорфа, телләре дә бик каты.

Зөя Башы халкы Сембер халкы кеби гел Акчуриннарга гына ышанып яталар. Мәхәллә халкы исеменнән бернәрсә дә эшләмиләр. Хәлбуки[423] Зөя Башы халкы күп акча табалар. Сәүдәгәрләре күп, байлары да байтак. Яхшы тәрбия күргән затлар хисапка кермиләр. Менә шундый караңгылыкта яткан Зөя Башы халкын агартмак, аларга тәрбияле аналар йитештермәк изге нияте илә биш-алты ел элек мөхтәрәмә Маһруй ханым Акчурина бер йорт иҗарәгә алып[424], кызларга махсус ибтидаи[425] мәктәп ачмыш. Мәктәпнең матди җәһәтен, бөтен расходын үзе күтәрмеш. Яхшы мөгаллимәләр китертеп, бичара кызларны тәрбия итә башлаган. Укучылар күбәйгәч, махсус урын сатып алып, бик зур, бик матур итеп рәсми рөхсәт илә үткән ел, ничә меңнәр сарыф итеп, кызлар мәктәбе салдырмыш. Менә шул кызлар мәктәбен Фатыйха, Мәрьям ханымнар[426] илә бергә зиярәт иттек[427]. Мәктәптә йөз иллегә якын кыз балалар укый. Ирле-хатынлы бер мөгаллимә, бер мөгаллим укытадыр.

Мәктәп ибтидаи дүрт, рөшди[428] бер сыйныфтан гыйбарәт. Укучы балаларның күбесе фәкыйрьләр. Барысы бер төсле киенгәннәр. Шәкертләрнең аң-

[421] Мөкәммәл – камилләшкән, төгәлләнгән.
[422] Җәһәт – як, тараф.
[423] Хәлбуки – ләкин.
[424] Иҗарәгә алу – вакытлыча файдалану, арендага алу.
[425] Ибтидаи – башлангыч.
[426] Текстта Ф.Аитова, М.Солтановалар турында сүз бара.
[427] Зиярәт итү – күрешергә бару.
[428] Рөшди – урта.

фикерләрен тикшерү нияте илә байтак сөальләр бирдек, яхшы җавап бирүчеләр булды.

Фәкать безнең милли мәктәпләрдә балаларның зиһеннәрендә үткенлек аз күренәдер. Гади сөальләргә дә иркенләп җавап бирә алмыйлар. Гомумият илә ир вә кыз шәкертләремездә рухилык хис итәдер. Моның өстенә, тел вә татарча сөйләшү зәгыйфьтер. Милли әдәбият илә бер дә таныш түгелләр. Безнең милли мәктәпләрдәге зуррак ир вә кыз шәкертләр үзенең дәресен үгрәнүдән башка бер нәрсә дә укый алмыйлар. Бигрәк тә кыз шәкертләремез шулай, бу кимчелек мөгаллимә-мөгаллимнәрдән булса кирәк. Чөнки чын тәрбия күргән мөгаллимә-мөгаллимнәрнең саннары бик аз. Милли мәктәпләрдә шәкертләргә махсус китапханәләр юк. Шулай да булса, милли мәктәпләр өсләренә йөкләнгән бурычларның байтагын үтиләр. Шәкертләрдә милли тойгы, дин хисе нык йирләшә башлаган. Меңнәрчә кешеләр укый торган зур, милли хезмәтне һиммәтле[429] бер мөселман хатыны үтидер. Менә бу мәктәпне салучы, тәрбия итүче мөхтәрәмә Маһруй ханым Акчуринадыр. Мәктәпнең бинасы бик мөкәммәл [430]. Һәрнәрсәсе йитешкән. Дин дәресе илә кирәк кадәр фәннәр дә укытыладыр. Бу зур хезмәт өчен Маһруй ханымга күп рәхмәт әйтергә бурычлымыз. Татар хатыннарының күбесе чүпрәк калыбы булып торганда, Маһруй ханымның бу һиммәте, бу хезмәте бөтен мөселман хатын-кызларына үрнәктер. Бу мәктәпнең бер кимчелеге бар, исә ул да мөгаллимәләрнең азлыгыдыр. Табигый бу кимчелек акрынлык илә үтәлер.



Бәдриҗамал Гыйззәтулла мирза Сәйфуллин кызы Акчурина
*(«Сөембикә», 1914, №9)*

Бу мәктәпкә башка, мәрхүм Ягъкуб Акчуринның рәфыйкасы[431] мөхтәрәмә Мәргубә вә килене Бәдриҗамал ханымнарның тәрбиясендә, бик мөкәммәл кызлар мәктәбе бар. Мәргубә ханым да әүвәлләре бер йорт алып, шунда кызларны укыттырган. Соңра үз йортына бик мөкәммәл итеп мәктәп салдырган. Бу мәктәпне үз йортына салуга да сәбәп: Зөя Башы халкының кызлар укытуга салкын карауларыдыр. Мөхтәрәмә Мәргубә ханым сатып алырга муафыйк[432] урын тапмаган. Сигез мәхәлләле Зөя Башы халкы үзләренең кызларын укытыр өчен мәктәп салырга урын бирергә дә һиммәт итмәгәннәр. Шуның өчен йортына салдырган. Бу мәктәптә алтмыш кыз бала укыйдыр. Яртысы фәкыйрь балалары. Бу монтазам [433] кызлар мәктәбен дә кереп карадык.

[429] Һиммәтле – тырыш.
[430] Мөкәммәл – тәмамланган, камилләшкән.
[431] Рәфыйка – иптәш, тормыш иптәше.
[432] Муафыйк – яраклы.
[433] Монтазам – тәртипкә салынган, тәртипле, рәтле.

Акчуриннарның үз тәрбияләрендә йитешкән мөгаллимә Шәрифҗамал ханым укытадыр. Мөгаллимә ханымның дәресен тыңладык. Бик яхшы укыта икән. Без дә, шәкертләргә үз дәресләреннән вә читтән сөальләр бирдек. Бик яхшы җавап бирделәр. Бу мәктәпнең шәкертләренә аң-фикер яхшы ук йирләшкән. Ялгыз бер кимчелек бар исә: ул да кыз шәкертләремездә ялгыз татар кызларына махсус булган боеклык, рухсызлыктыр. Белсәләр, аңласалар да, бирелгән сөальләргә батыр җавап бирә алмыйлар. Бу мәктәптә рус теле укытыла һәм дә кул һөнәрләре дә мөкәммәл үгрәтелә икән. Кул һөнәрен мөхтәрәмә Бәдриҗамал ханым Акчурина үзе үгрәтәдер.

Кызлар бәйләргә, чигәргә, тегәргә бик яхшы үгрәнгәннәр. Кул һөнәрләре үгрәнмәк өчен махсус зал ясалган. Бу мәктәпләр хәзерге кызлар мәктәпләренең иң яхшыларыннан саналырга ярыйдыр. Монда да мөгаллимәнең бер генә булуы бик уңгайсызлык итәдер. Мөхтәрәмә Бәдриҗамал ханымның үзенең сөйләвенә күрә, бу мәктәп тагы да зурайтылачак вә мөгаллимәләр арттырылачакдыр. Бу мәктәпнең тәрәккыйсе өчен һәртөрле чаралар кылыначак икән. Фәкать Зөя Башының чүпрәк калып хатыннары һәнүз[434] мәктәп караучыларына, мөгаллимәгә тел озайталар, мөнәсәбәтсез сүзләр сөйliләр икән. Татар милләтенең иң зур милли ихтыяҗыны үтәүче, тәрбияле аналар йитештерергә үзләренең акчаларыны, газиз вакытларыны сарыф итүче мөхтәрәмә Маһруй, Мәргубә, Бәдриҗамал ханым Акчуриналарга, бу мәктәпләрдә укытучы мөхтәрәмә мөгаллимә ханым вә мөгаллим әфәнделәргә чын күңелемнән рәхмәт әйтәм. Киләчәктә бу мәктәпләрне тагы да мөкәммәл бер хәлгә куеп, Сембер губернасындагы мөселман хатын-кызларыны укытырга мөгаллимәләр йитештерергә муафыйк булсыннар. Бу мәктәпләрнең дәвамын тәэмин итәр өчен, вакыфлар калдырырга Ходай насыйп итсен. Башка хөрмәтле хатыннар да моннан гыйбрәт алып, акчаларыны тутасеңелләрене укытырга тотсыннар иде.

*«Тормыш», 1914, 30 март.*

***Мохбир***

**Авылда кызлар мәктәбе**

Бәләбәй өязе Иске Турай авылыннан[435] язалар:

Базары һәм волость идарәсе булган бу авылда 30 елдан бирле дәвам итеп килгән ир мәктәбе булса да, кызлар мәктәбе юк иде. Үткән көз Уфаның бөек хәйрәт ияләреннән[436] мәшһүр Садретдин әфәнде Назыйров, мең ярымга төшереп, 22 аршин озынлыгында кызлар мәктәбе салдырды. Бу мәктәп салдыргачтын, күрше вә хәтта 50–60 чакрым йирләрдән килеп кызлар укый башладылар. Авылдан вә читтән җыелган балаларның саны 150 гә тулды. 6–7

[434] Һәнүз – әле дә, һаман да.
[435] Иске Турай авылы – хәзер Башкортстанның Ярмәкәй районына керә.
[436] Хәйрәт иясе – хәйрияче.

еллардан бирле авылда ысул саутия[437] белән балалар укытып тәҗрибә күргән мөгаллимә Шәмсия ханым илә Шәмсия ханымның тәрбиясендә йитешкән кызлар мөгаллимәлек иттеләр. 20–21, 22 вә 23нче март көннәрендә имтиханнар булды. Имтиханга авыл могътәбәрләре[438] илә әтрафдан[439] 300 кадәр абыстай вә карчыклар җыелган иделәр. Балаларның бик яхшы укыганлыклары мәгълүм булды. Кул һөнәрләре дә үгрәтелә иде. Анысы бигрәк тә имтиханга килгән халыкның дикъкатен җәлеп итте. Мәҗлестә булган ханымнар фәүкылгадә[440] бер куану белән Назыйров җәнабләренә рәхмәт укып таралдылар.

*«Вакыт», 1914, 2 апрель.*

## Тукай авылыннан

Оренбург өязе Тукай авылында[441] җәмгыять тарафыннан шул көнгә кадәр бер кызлар мәктәбе салынмавыннан зарланып язганнан соң, Гайшә Госманова исемендә бер ханымның берничә еллардан бирле кыз балаларны җыеп укытып китүенә рәхмәт укыйлар. Мәктүбтә язылганына күрә, Гайшә ханым да һәр ел уку эшләрен тәртипкә салып, канва белән чигү, челтәр, һәртөрле күлмәк, кием тегү вә башка шундый өй эшләре үгрәтә башлаган. Өч мәхәлләле зур бер авыл халкы балаларының уку вә укыту эшләрене игътибарга алмаган вакытта, үз йортына бала җыеп, һәр ел 60–70 бала тәрбия кылып, елдан-ел аларның алга китүләре өчен кайгырган бер ханымга никадәр тәшәккер кылынса[442] да ярыйдыр. Фәкать коры бер тәшәккер кылып кына калырга да ярамыйдыр. Кулдан килгән кадәр матди ярдәм дә булып, мәктәпнең йитешмәгән йирен йиткерергә, мәктәп әсбаплары алып бирергә, мәктәп урыны кечкенәлек итә торган булса, зуррак бер бина салып, иркенрәк бер мәктәп ясарга кирәк. Хаҗәт булса, ярдәмче мөгаллимә алып укыту ягын да киңәйтергә ярый. Өч мәхәлләле зур бер авылга шул көнгә кадәр кызлар мәктәпсез тору зур бер кимчелектер.

*«Вакыт», 1914, 3 апрель.*

***С.Адирова***

## [Эстәрлетамак өязе...]

Эстәрлетамак өязе Дуван Табын волосте Кырмыскалы авылыннан[443] язалар:

Күптән түгел кызлар школасында укыган мөселман кыз балаларына дин вә ана теле дәресләреннән имтихан булды. Боңа кадәр халык школада дин вә

[437] Ысул саутия – аваз ысулы.
[438] Могътәбәр – хөрмәтле.
[439] Әтраф – тирә-як.
[440] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[441] Тукай авылы – хәзер Оренбург өлкәсе Александровский районына карый.
[442] Тәшәккер кылу – рәхмәт әйтү.
[443] Кырмыскалы авылы – хәзер Башкортстанның Кырмыскалы районына карый.

ана теле дәресләре укытыла дигән сүзгә бик ышанычсыз карыйлар, анда дин вә ана теле дәресләренең яхшы укытылуыны күңелләренә дә китерә алмыйлар иде. Бу имтиханга килгән хатын-кыз үз күзләре белән школда укыган кыз балаларның яхшы тәртипле мәктәпләрдә укыган кыз балалар кадәр дин вә ана теле дәресләрендә, чигеш вә канва белән төрле рәсемнәр ясаганлыкларыны күргәч, бик куанышып чыктылар. Бу школда 40 кадәр кыз бала укый вә һәркаюсы ибтидаи[444] дәрәҗәдә дин вә ана теле дәресләре белән кул һөнәрләре беләләр (бик матур итеп Петербург мәсҗетенең рәсеме чигелгән иде). Русча белән мөселманча бик яхшы укытып, өстәвенә (бу көнгә кадәр авыл кызларының төшенә дә кермәгән) кул һөнәрләренә дә үгрәткәнен күргәч, авыл халкы – хосусан хатын-кыз җәмәгате – школаның мөдире һәм учительницасы Мәдинә туташ Солтангалиева җәнабләренә никадәр тәшәккер итсәләр[445] дә аздыр.

*«Вакыт», 1914, 16 апрель.*

### Кыз балаларга мәктәп юк

Алабуга өязендә Малмыж – Казан юлы өстендә Морт[446] исемендә ике мәхәлләле зур бер авыл бар. Әһалисе[447] сәүдәгәр, хәлле булсалар да, кыз балалары өчен шул көнгә кадәр бер мәктәп салынганы юк икән. Алабуга имамы Әхмәдзәки әфәнде Хуҗахановбу авылда уку яшендә 200дән артык кыз бала булып, бу балаларның тәртипле, монтазам[448] мәктәптән мәхрүм булып торганлыкларын яза. Ике мәхәлләле зур вә бай бер авылда шул көнгә кадәр кыз балалар мәктәбе булмау хакыйкатьтә тәәссеф ителергә[449] тиешледер.

*«Вакыт», 1914, 27 апрель.*

***Каюм Кулаткый***

### Әстерханда хөкүмәт урта мәктәпләрендә укучы мөселман кызлары

Әстерхан хатыннары, Әстерхан туташлары 1905нче елның гомуми дулкыны илә уйгану дәверенә аяк бастылар. Бу көнгә кадәр ханым вә туташларыбыздан хөкүмәт мәктәпләренә кереп укучылар юк иде. Ханым вә туташларга махсус булган милли мәктәпләребез дә юк диярлек иде. Ләкин татарлар арасына мәдәният исе аңкытып, татар дөньясына нур вә зыя[450] биргән 20нче гасырның 5нче елы ханым-туташларыбызга да тәэсирсез калмады. Аның башта Шәрекътан исеп, соңрак Гаребтән искән җылы җиле

[444] Ибтидаи – башлангыч.
[445] Тәшәккер итү – рәхмәт әйтү.
[446] Морт авылы – хәзер Татарстанның Алабуга районына карый.
[447] Әһалисе – халкы.
[448] Монтазам – тәртипкә салынган.
[449] Тәәссеф итү – кайгыру, борчылу.
[450] Зыя – матур, күркәм.

Әстерхан ханым вә туташларының чапаннары астына да кереп өлгерде һәм бәгъзе бер милли агаларыбызның тырышлыклары илә аларның наданлык җепләреннән тегелгән чапаннары ташланып, менә рәсемдә күрелгән кыяфәткә кереп, хөкүмәт мәктәпләренә агыла башладылар: җаһил[451], мөтәгассыйб[452] имамнарның һөҗүмнәре, кара гавәмнең[453] кыйль вә кал[454] бу саф күңелле гыйлем гашыйкалары саналган туташларыбызга манигъ[455] була алмадылар. Хәят вә заман аларны химая кылды[456]. Күзе ачык тәрәккый[457] вә мәдәниятпәрвәр милли агаларыбыз аларга ярдәм итте.



Әстерханда хөкүмәт урта мәктәпләрендә укучы мөселман кызлары

Әстерхан туташларыннан хөкүмәт мәктәбенә беренчелек шәрифене[458] алырга наил булган[459] туташ рәсемдә сул яктан 2нче булып утырып төшкән

[451] Җаһил – надан, белемсез.
[452] Мөтәгассыйб – фанатик.
[453] Гавәм – халык.
[454] Кыйль вә кал – имеш-мимеш, юк-бар сүз, төрлечә сөйләүчеләр.
[455] Манигъ – киртә.
[456] Химая кылу – яклау, саклау.
[457] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[458] Шәриф – игътибарга лаек.
[459] Наил булу – ирешә алган, ирешә торган.

Мөбәйнә туташ Таначиева булды. Бу туташ Букәй казакъларыннан булган Ибраһим әфәнде Таначиевның кызы булып, үткән сәнә кәмаль муаффәкыйять[460] илә Әстерхан кызлары гимназиясене икмаль[461] итте. Хәзердә гали хатыннар мәктәбенә китәргә тора.

Хөкүмәт мәктәбенә керүдә икенчелек шәрифене алган туташларыбыз: Шәмсеҗиһан Кәримова (утырганнардан уң якта беренче) һәм Мәрьям туташ (утырганнардан сул якта беренче) булды.

Шәмсеҗиһан туташ хәзер дә Әстерханның фельдшерский мәктәбендә укыйдыр. Мәрьям туташ кызлар гимназиясенең 5нче сыйныфында укый. Бу ике туташ һәр икесе хөкүмәт мәктәпләрендә укыдыклары хәлдә, үзебезнең милли әдәбиятыбызны тәгъкыйб кылып[462], вакытлы матбугатыбызны укып вә күздән кичереп киләләр. Хаҗәр вә Суфия туташлар да (өстәлгә тотынып төшкәннәр) гимназиянең 4–5нче сыйныфында укыйлар. Калган туташларыбыздан кайсы 2нче, кайсы 3нче, кайсы 4нче сыйныфларында укыйлар. Бу рәсемдә күрсәтелгән туташлардан башка да хөкүмәт мәктәпләрендә укучы берничә туташ бар. Милләтебезнең яртысыны тәшкил иткән вә хәят миллиябездә иң мөһим урын тоткан хатын-кызларыбызның хөкүмәт мәктәпләренә кереп укулары вә шуның илә бәрабәр үзләренең хәлсез, көчсез, мәзлум[463] татар милләтенә мәнсуб[464] татар кызлары идекләрен онытмый, әдәбият вә матбугатыбызны тәгъкыйб кылып килүләре, истикъбалебездә[465] гаять парлак өметләр тудыралар. Бу туташларыбызга саулык, укуларында муаффәкыять теләдек соңра, бер-ике сүз әйтеп китүдән каләмене тота алмыйм. Сез – татарның тәрәккыять милли вә мәдәниясенә нигез салучы саф йөрәкле татар калебле[466], татарны сөюче, татар бәхете өчен тырышучы милләт балалары йитештерәчәк аналар булачаксыз. Мин сезгә ышанам. Сез моннан соң хөкүмәт мәктәпләренә кереп укыячак туташларыбызга мәгънәви остаз саналачаксыз. Моннан соң хөкүмәт мәктәпләренә кереп укыячак туташларыбыз әхлакта, мөгамәләдә, нәзакәттә сездән үрнәк алачаклар. Сез шуларны хәтердә вә күз алдында тотып, киләчәк яшь буынга хакыйкый мөгаллимәләр булырга тырышыңыз. Сезнең кайгыруыңыз татар кайгысы, уеңыз татар уе, хезмәтеңез татар хезмәте булсын. Сезгә тәүсыям[467] шушы.

*«Сөембикә», 1914, №13, б.4–5.*

---

[460] Муаффәкыять – уңыш.
[461] Икмаль – тулысынча җитлекле итү, камилләштерү.
[462] Тәгъкыйб кылу – күзәтү.
[463] Мәзлум – изелгән, җәберләнгән, рәнҗетелгән.
[464] Мәнсуб – бер урынга билгеләнгән.
[465] Истикъбаль – киләчәк, булачак.
[466] Калеб – йөрәк.
[467] Тәүсыя – васыять, киңәш.

***З.И.***

## Каргалыда Гәүһәр ханым Рәмиева мәктәбе

Каргалыда Гәүһәр ханым Рәмиева[468] тарафыннан тәрбия кылына торган кызлар мәктәбендә 3 майдан башлап 6 на кадәр имтиханнар дәвам ителде. 6 сыннан башлап 3 көнгә кадәр ирләргә дә кул эшләрен күреп калырга рөхсәт иттеләр. Имтиханнар һич моңа кадәр булмаган рәвештә рухлы вә низамлы чыкты. Хатын-кыз хисапсыз күп булып, бөтен ишек алды, бакча, өйләр шыгрым тулы иде. Татар тарихы, гыйльме әшъя[469], татар нәхү вә сарыфы[470], русча кеби кыз мәктәпләренә яңа кереп килә торган фәннәрдән бик яхшы имтихан бирделәр.

Кызлар машина кебек бикләүне ташлап, сораганга гаять аңлы, ачык, тәмле иттереп җавап бирүләре бигрәк күңелле иде. Һәр көнне рухлы нотыклар, үлгән йөрәкләребезгә хәят бирә торган шигырьләр соң дәрәҗәдә күркәмлек бирделәр.

Кул эшләре ис китәрлек күп һәм төрле иде. Моңа кадәр безнең Каргалыга кермәгән мөһим нәрсәләрдән: 24 данә һәртөрле узорда Пенза, Оренбург шәлләре, бик нәзек җептән косынкалар, прошивкаларын үзләре эшләп теккән соң модадагы күлмәкләр, балалар күлмәге, һәртөрле яхшы эшләнгән оеклар, җептән эшләнгән одеяллар, бик нәфис художественный картиналар, бу картиналар: урман, су кырында камышлар, уртасында аккошлар йөзә, хакыйкатән һәркемнең дикъкатен җәлеп итәрлек матур күренеш! Һәм дә җептән бәйләнгән сөлгеләр вә челтәр кием, мендәр читләре, паласлар, простынялар, һәр төштә атластан сачкәләр эшләнеп, уртасына гаҗәеп осталык берлә эшләнгән хикмәтле сүзләр, шамаильләр, әлхасыйль[471], ике бүлмә шыгрым тулган булып, бу эшләрнең күбесе безнең Каргалыда беренче мәртәбә аяк басулары. Инде Каргалы кызлары һөнәр вә нәфасәттә зур бер адым атладыгы кеби, мәктәпкә русча кертелеп, әүвәл мәртәбә укытылуы мөхтәрәм Гәүһәр абыстайның һиммәте[472] саясендә[473], ошбу мәгълүматыбыз Әминә ханымның иҗтиһады[474] илә булды.

Бу кадәр искелекне сөймәгән бу йирдә хәзерге көнемездә һава дәрәҗәсендә кирәкле русчаның мәктәпкә кереп укытыла башлавы дәхый бик зур адым дисәк ярыйдыр. Бу кадәр мәктәпләр тәрбия кылучы мөхтәрәмә милләт анасы Гәүһәр ханымга чын күңелебездән рәхмәтләр укыймыз, һәм дә армыйталмый бөтен гомерен укыту вә һөнәр өйрәтергә сарыф иткән мөхтәрәмә Әминә ханым Габдрахманова җәнабләренә озын гомерләр телибез. Һәм мон-

---

[468] Гәүһәр Рәмиева – мәгърифәтче, Оренбург губернасы авылларында кыз балалар өчен мәктәпләр ачучы, Шакир Рәмиевнең тормыш иптәше.

[469] Гыйльме әшъя – физика.

[470] Татар нәхү вә сарыфы – татар теленең морфологиясе һәм синтаксисы.

[471] Әлхасыйль – бер сүз белән әйткәндә, нәтиҗәдә.

[472] Һиммәт – тырышлык.

[473] Сая – күләгә, ышык.

[474] Иҗтиһад – тырышлык.

нан соң безне мәхрүм итми ошбу рәвешчә килеп дәвам иттерүен үтенеп калабыз.

*«Вакыт», 1914, 8 май.*

### Каргалыда Гәүһәр ханым Рәмиева мәктәбе

Гәзитәмезнең үткән номерында Каргалыда Гәүһәр ханым Рәмиева тәрбиясендә булган кызлар мәктәбендә имтихан булып, имтиханнан соң мәктәптә укыган кызларның кул эшләре дә күрсәтелгәнлеге язылган иде. Имтихан мөнәсәбәте илә мәктәпнең мөгаллимәсе Әминә ханым Габдрахманова вә берничә укучы кызлар тарафыннан шунда җыелган ханымнарга хитаб кылынып[475], мөһим-мөһим нотыклар сөйләнелгән икән, бу нотыкларның җыелган ханымнарга бик бөек бер тәэсир биргәнлеген язалар.

Мөгаллимә Әминә ханым тәгълим вә тәрбия хакында мәкамгә мөнасиб бик яхшы бер нотык сөйләгән. Нотыгында хәзер кыз балалар өчен дә уку-язу вә хосусый йорт-ханәләре белән генә калырга ярамый, урта вә гали дәрәҗә дәүләт мәктәпләреннең керем гомуми вә җәмәгать хезмәтләренә мөселман кызларыннан хадимәләр җитештерергә, мәсәлән, хәзерге көндә иң бөек бер ихтыяҗ булган акушерлыкка, фельдшерица, табибәлек хезмәтләрен үтәрлек кешеләр чыгарырга тиешлеген сөйләгән. Бу хакта тарихтан мисаллар алып күрсәткән. Гомер буе ирләргә генә таянып торырга ярамаганлыгын белдергән. Халыкның иҗтимагый вә икътисади дәрәҗәсен күтәрер өчен хатыннарның да ирләр белән кулга-кул тотынышып мәйданга чыгулары лязем[476] булганлыгын бик яхшы аңлаткан, хатын-кыз тәрбиясе һич игътибарга алынмый торган бер заманда мәйданга чыгып, халис[477] Хода ризалыгы өчен үз хираҗатеннән мәктәп салдырып кыз-балаларыгызны тәрбия кылырга бөек бер ярдәм иткәнлеге өчен мөхтәрәм милләт анасы Гәүһәр ханымга мең-мең рәхмәтләр укып, озын гомерләр теләргә, гомерлек юлдашы булган мәрхүм Шакир әфәнде Рәмиев җәнабләренең[478] рухына дога кылырга, Каргалы хатын-кыз



Гәүһәр Рәмиева мәктәбе мөгаллимәсе Әминә ханым Габдрахманова *(«Сөембикә», 1914, №18)*

[475] Хитаб кылу – эндәшү, мөрәҗәгать итү.

[476] Лязем – тиеш, кирәкле, туры килгән.

[477] Халис – чын.

[478] Шакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев (1857–1912) – татар сәнәгатьчесе, алтын приискалары хуҗасы, хәйрияче, нашир.

дөньясының тәрәккый тормышында бу ике исемнең беренче сәхифәдә язылырга тиешле булганлыгын белдергән. Җыелган ханымнар һәркаюсы бер авыздан: «Ходаның рәхмәтендә булсыннар», – дип дога кылганнар. Рөшди[479] сыйныфта укыган шәкертләрдән Зәйнәб ханым Ягъкубова адәм баласы өчен өчен гыйлем вә мәгърифәтнең һәр нәрсәдән бөек бер зиннәт булганлыгын олуглар тарафыннан сөйләнгән тарихи сүзләр белән бик яхшы бәян иткәннән соң: «Вакыт! Милләтнең нам бер яртысы булган хатын-кызларга да наданлык белән сугышырга вакыт!» дигән. Менә шул ихтыяҗны үтәү юлында бөек бер хезмәт күрсәткән мөгаллимәбез Әминә ханымга бөтен шәрикләребез[480] белән рәхмәт укыйбыз. Милләтемезнең бөек бер ире мәрхүм Шакир әфәнде Рәмиев җәнабләренең рухына дога кыламыз, дигән. Гайшә бинте Хәбибрахман Рәхимова ханым Гәүһәр абыстайның иҗтиһады аркасында үзләренең гыйлем вә мәгърифәт алып, аңлы халык рәтенә керергә муафыйк булуларына[481] шатлык кылып, кул эшләренә әһәмият биргән вә шуны мөкәммәл[482] вә монтазам[483] сурәттә Каргалы кызлары арасына керткән өчен, мөгаллимә Әминә ханымга бөтен сыйныфташлар исеменнән тәшәккер кыйлганлыкларын белдергән. Башкалар да һәркайсы бик зур бер рух белән гыйлем, мәгърифәт вә кыз балаларның тәрбиясе әсасендә нотык сөйләгәннәр.

Мәктәп ачып, киләчәккә милләт анасы булган кыз балаларга тәгълим вә тәрбия бирү юлында фәүкылгадә[484] бер һиммәт күрсәткән[485] Гәүһәр абыстай белән, 6–7 ай эчендә уку-язу, гомуми мәгълүмат бирә торган бик күп дәресләр өстенә, һич хәтергә килмәгән дәрәҗәдә күп кул һөнәрләре өйрәткән һәм русча да укыткан мөгаллимә Әминә ханымга рәхмәт укыганнар. Мәрхүм Шакир әфәнде Рәмиевнең рухына дога кылганнар.

*«Вакыт», 1914, 9 май.*

***Гафифә Галиева, Сара Заһидуллина,***
***Әсма Закирова, Мәхфүзә Вәлиева***

**Казанда мөхтәрәмә Фатыйха ханым Аитовага ачык хат**

Мөхтәрәмә Фатыйха ханым! Сез: «Казан шәһәре китапханәсенең мөселманнар өчен булган шөгъбәсенә кереп, гәзитә вә китаплар моталәга кылучы[486] ханым вә туташларның укыган гәзитә вә рисаләләрен[487] укырга яраклымы,

[479] Рөшди – урта.
[480] Шәрик – укучы.
[481] Муафыйк булу – туры килү.
[482] Мөкәммәл – камил.
[483] Монтазам – тәртипле, тәртипкә салынган.
[484] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[485] Һиммәт күрсәтү – тырышу.
[486] Моталәга кылу – уку, өйрәнү.
[487] Рисалә – хат, брошюра, китап.

түгелме?» – диеп назыйрә[488] булып килеп, китапханәнең бер кешенең дә хакы булмаган гомуми урын икәнен белми тикшереп йөрисез. Сезнең кебек ханымнар гомуми китапханәнең тынычлыгын бозганга күрә, китапханәгә әүвәл ачылган вакытларда 120 ханым вә туташ кереп файдаланса да, ахыр вакытларда 40–45 кенә калдылар.

Фатыйха ханым! Без сезгә үз тарафымыздан шуны да әйтмәкче буламыз: сез үзегезнең идарәгездәге кызлар мәктәбендә укый торган мәгъсумә[489] кызлар янына әллә нинди читтән эш өйрәнергә диеп килеп йөри торган кызларны һич әхлакларын тәфтиш итми[490], мәктәптә укый торган мәгъсумә кызлар белән катыштырып әхлаксызлыкка өйрәтәсез. Янә бөтен милли матбугатымыз кызлар мәктәбендә мөгаллимә вә учительницалар мөслимәдән булуны мәгъкуль күргәндә[491], мәктәбегездә моннан әүвәл укыткан Мәрьям ханым Еникиева һәм Мәрьям туташ Мөхетдиноваларны[492] усал кайнаналар шикелле ачуланып, истигъфа кылырга[493] мәҗбүр иттегез. Чыккач саф мөселман акчасы, саф мөселман мәктәбенә рус учительницалары тәгаен кылдырырга сәбәпче булдыгыз. Учебный начальстволар да, мөслимә учительницалар түзә алмый истигъфа кылгач, рус учительница тәгаен кылдылар. Мөгаллимәләр хакында сөйләргә дә ярамый, мөслимә булган өченме, яки башка сәбәптәнме, мәктәбеңезнең алты еллык дәвамында 20ләп мөгаллимәне куып чыгардыгыз.

*«Тормыш», 1914, 9 май.*

**Мөхтәрәм «Сөембикә» идарәсенә**

Түбәндәге игъланымызга журналыңызда урын бирүеңезне үтенәмез.

Укучы туташлар вә мөгаллимәләр дикъкатенә – киләчәк көзгә сентябрь башыннан Троицк шәһәрендә Яушевлар[494] тарафыннан рәсми рөхсәтнамә белән яңа бер кызлар мәктәбе ачылачак.

Мәзкүр[495] мәктәптә мөдирә үткән сәнә Әхмәров кызлар мәктәбендә мөгаллимәлек иткән Мөхлисә ханым Бубый[496] булачак. Мәктәп гүзәл бинада, барысы 8 сыйныфлы булып, 4 се ибтидаи[497], 4 се рөшди[498] улачак. Ибтидаи

---

[488] Назыйрә – караучы, тикшерүче.

[489] Мәгъсум, мәгъсумә – гөнаһсыз, керсез, кимчелексез.

[490] Тәфтиш итү – тикшерү, эзләү.

[491] Мәгъкуль күрү – урынлы дип табу.

[492] Мәрьям Мөхетдинова – мөгаллимә, Казанда 1917 елның 24–27 апрелендә узган Бөтенроссия мөслимәләренең беренче съездында катнаша.

[493] Истигъфа кылу – гафу үтенү.

[494] Яушевлар – татар морзалары нәселе, сәүдәгәрләр.

[495] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.

[496] Мөхлисә Габделгалләм кызы Нигъмәтуллина (М.Бубый, 1869–1937) – мәгърифәтче, Иж-Бубыйда кызлар мәктәбе мөдирәсе, Мөселман Үзәк Диния нәзарәте казыясы.

[497] Ибтидаи – башлангыч.

[498] Рөшди – урта.

3нче сыйныфтан русский класс башланачак. Татарча һәм русча укытырга тәҗрибәле мөгаллимәләр чакырылды. Шулар җөмләсеннән Мөхлисә ханым Бубый үзе, кәримәсе[499] Мөнҗия туташ Бубый, Гайшә туташ Фәйзия вә гайреләр мөгаллимәлек итәчәкләр. Мәктәпнең 8нче сыйныфы фәкать мөгаллимәләр җитештерер өчен генә махсус булып, мәзкүр сыйныфка мәктәпнең 7 сыйныфын тәмам иткән кызлар яхуд шул 7 сыйныфка торырлык мәгълүматы булган туташлар имтихан белән кабул ителәчәкләр. 8нче сыйныфта укып чыккан туташларга мөгаллимәлек шәһадәтнамәсе[500] биреләчәк. Мәктәптә кройка (кием кисү) һәм кул эшләре дә үгрәтелеп, шулар өчен махсус мөгаллимә чакырылды.

Быел мәктәпнең беренче елы булганлыктан, кабул имтиханнары өчен беренче сентябрьдән октябрь башына кадәр бер ай вакыт тәгаен иттек. Имтихан соңында мәктәпнең кайсы сыйныфына булса да кабул итәргә мөмкин.

Укучы туташларга тору мәсьәләсендә мәшәкать чигәргә тугры килмәсен өчен, мөдирәмезнең тәхет[501] нәзарәтендә[502] бер пансион да ачтык. Аена 15 сум белән шунда торырга мөмкин. Теләгән кешеләргә мөдирәмезнең карамагында уларак хосусый квартирларда торырга да мөсагадә ителер[503]. Уку хакы мәктәпнең 7 сыйныфында 25 шәр сум; 8нче сыйныфта 30 сум булачак.

Мөрәҗәгать өчен адрес:

ст. Агрыз, Сарап. уезда, дер. Иж-Буби

Мухлисе Боби.

Август 10нан соң Мөхлисә ханым Бубый Троицкида торачак булганлыктан, түбәндәге адрес белән Троицкига мөрәҗәгать итәргә тиеш:

г. Троицк, господину Л. Ш. Яушеву.

Мөхлисә ханым Бубыйга.

*«Сөембикә», 1914, №18, б.19–20.*

***Гайшә Абызгилдина***

**Уфада кызлар мәдрәсәсе идарәсеннән игълан**

Ханымнар җәмгыяте идарәсендәге кызлар мәктәбенең һәркайсында укулар ошбу 14–15 уку елында сентябрь башында башланып, май башына кадәр дәвам итәчәктер.

Сентябрь 10нарына кадәр килеп йитә алмаган таләбәләр[504] кабул ителмәс. Шуңа күрә дә вакытында килеп йитәргә иҗтиһад итсеннәр[505].

---

[499] Кәримә – кызы.

[500] Шәһадәтнамә – таныклык язуы, диплом, аттестат, белешмә язуы.

[501] Тәхет – ас.

[502] Тәхет нәзарәтендә – контроле, күзәтүе астында.

[503] Мөсагадә итү – мөмкинлек бирү, булышу.

[504] Таләбә – укучылар, шәкертләр.

[505] Иҗтиһад итү – тырышу.

Читтән килгән кыз таләбәләр беренче мәхәлләдәге мәктәп өчен яхшы вә иминиятле фатир табу хакында шул мәктәпнең баш мөгаллимәсенә мөрәҗәгать итсәләр, яхшы фатир табылыр.

Килгән таләбәләрнең паспорты булу, сәламәт булу, уку хакын вә үз мәгыйшәтен[506] әда итәрлек[507] икътисади куәте булу, сигез яшьтән ким булмаулары шарттыр.

Мәктәпләрдә ибтидаи[508] вә рөшди[509] сыйныфлар булачактыр. Шуның илә бәрабәр[510] рус теле дә укытылачактыр.

1нче мәхәлләдәге ханымнар җәмгыяте мәктәбенең мөгаллимәсе Гайшә Абызгилдина.

*«Тормыш», 1914, 14 август.*

***Багбостан***

**Истанбул хатирәте**

Истанбулга баруымнан беренче максатым – Дарелхәлифәттә[511] булган ислам кардәшләремез – төрек ханымнарының тәгълим[512] вә тәрбия эшләре, йорт-көнкүреше, хәят[513] иҗтимагыяләре[514] илә танышу булганлыктан, ике ай ярымлык сәяхәтемнең иң күп вакытын шул юлга сарыф кылдым. Кирәк Истанбулның үзендә, вә кирәк булса Эдирнедә[515] булсын, төрек ханымнарының һәр табәкасы[516] илә таныштым. Мәктәп вә мәдрәсәләрен, һәйәт тәгълимия[517] вә программаларын күрдем. Җәмгыятьләрендә, «Кадынлар журналы»ның[518] идарәханәсендә, мәгариф җәмәгать хадимнәре[519], мөхәррирә вә әдибәләрнең хосусый вә гомуми мәҗлесләрендә булдым. Кирәк хосусый утырыш, вә кирәк гомуми җыелышларында булсын, төрек ханымнарының хәтергә килмәгән бер рәвештә уянганнарын күрдем. Русиядә икән вакытымда төрек ханымнары хакында бик түбән фикерләр ишетергә тугры килә иде. Күп кешеләр Истанбул ханымнары арасында булган тәрәккыятьне[520] бик җөзьи[521] итеп күрсәтәләр, Аурупа мәгънәсе илә фикер иясе ханымнары бармак

[506] Мәгыйшәт – тормыш, көнкүреш; яшәү өчен кирәкле нәрсә.
[507] Әда итү – үтәү, түләү, тәэмин итү.
[508] Ибтидаи – башлангыч.
[509] Рөшди – урта.
[510] Бәрабәр – бергә.
[511] Дарелхәлифәт – Хәлифә йорты, Төркия.
[512] Тәгълим – белем бирү, уку-укыту.
[513] Хәят – тормыш, гомер.
[514] Иҗтимагый – җәмгыятькә бәйләнешле.
[515] Эдирне – Төркиядәге шәһәр.
[516] Табәка – катлау.
[517] Һәйәт тәгълимия – укыту комиссиясе.
[518] «Кадынлар дөньясы» («Kadinlar Dünyasi») – Төркиядә 1913–1921 елларда хатын-кызлар өчен нәшер ителгән журнал.
[519] Хадим – хезмәткәр.
[520] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[521] Җөзьи – әһәмиятсез.

санынннан артмый, тәгълим вә тәрбия эшләренә әһәмият бирелми, хокук мәсьәләсен төрек ханымнары авызларыннан чыгарырга куркалар, хиҗаб вә ачык йөрү мәсьәләләре иң әһәмиятсез мәсьәләләрдән санала. Вә яхуд әһәмият бирелә икән, икенче ягыннан әһәмият бирелә – фәлән вә фәлән диләр иде. Бу фикер бер Истанбулдан кайткан кешеләр авызыннан гына ишетелми, матбугатта да бәгъзән[522] күренеп кала иде.

Ихтимал, төрек ханымнары элегрәк шулай булса да, булганнардыр, әмма хәзер якыннан танышканның соңында, мин ул монда укыган вә ишеткән фикерләрнең хакыйкатьтән бик ерак вә бөтенләй ялгыш идеген күрдем. Төрек ханымнары арасында гаять җитди бер фикер кузгалышы – хәрәкәт бар. Бәгъзе ханымнар илә булган мосахәбәләремне[523] бөтен мәүзугъ[524] вә тәфсыйл[525] фикерләре илә ачык вә тугъры әйтеп язсам, укучылар минем бу сүзләремнең һич мөбаләгасез[526] идекләрен бик яхшы тасдыйк итәрләр[527] иде, фәкать тәсаувырга[528] бәгъзе сәбәпләр аркасында хосусыйлык сыйфатын алган вә хатыннарның үз араларына гына махсус булган бу фикерләрнең күбесен шул көе гаммәнең[529] нәзариенә[530] кую мөнасиб[531] күрелмидер. Шуның өчен хәзерлек мин сәяхәтемдә күргәннәремнең гомуми ягын гына язып китәргә тиешле күрәмен. Шулай булган вакытта да югарыдагы сүзләремнең мөбаләгасыз идекен күрсәтә алырмын дип өмет итәмен.

Истанбулда 800гә якын мәсҗет бар икән, менә шул мәсҗетләрнең янында ир балалар мәктәбе булган кебек, кыз балалар мәктәбе дә булганлыгы аңлашылды. Аның өстенә, төрле программада һәр төрле урта мәктәпләре бар. Мәгариф нәзарының рөхсәт вә мәгавәнәте[532] аркасында кызлар мәктәбе белән бергә ирләр мәктәпләренең бик күпләрен күрдем. Игъдади[533] (гимназия), хәрбия[534], мөлкия[535], бәхерия[536], тыйббия[537], тешчелек, акушер вә фельдшерлык.

Хөласа[538]: шундый исемнәр белән Аурупа дөньясында нинди мәктәпләр булса, анда да шул мәктәпләр бар. Дарелфөнүннәре[539] ике йирдә: берсе хокук,

[522] Бәгъзән – кайчак, кайвакыт.
[523] Мосахәбә – кара-каршы сөйләшеп утыру.
[524] Мәүзугъ – проблема.
[525] Тәфсыйл – аерып-аерып аңлату, җентекләү.
[526] Мөбаләга – арттыру, күпертү.
[527] Тасдыйк итү – раслау, дөрес дип әйтү.
[528] Тәсаувыр – сурәтләп күз алдына китерү, гәүдәләндерү.
[529] Гаммә – халык.
[530] Нәзар – игътибар, уйлау.
[531] Мөнасиб – яраклы.
[532] Мәгавәнәт – булышлык.
[533] Игъдади – хәзерләү.
[534] Хәрбия – хәрби.
[535] Мөлкия – хөкүмәткә караган.
[536] Бәхерия – диңгез.
[537] Тыйббия – медицина, табиблык.
[538] Хөласа – нәтиҗәдә.
[539] Дарелфөнүн – университет.

әдәбият, табигыять, илаһият[540] кеби берничә шөгъбәгә[541] аерылган, икенче берсе яңа ысулда гаять яхшы бер бинада тыйббия шөгъбәсеннән гыйбарәттер. Бу мәктәпләрнең кәмаләт[542] вә фазыйләтләрен[543] Русия вә Аурупа мәктәпләренә чагыштырып тәгъриф итәрлек[544] икътидарым[545] булмаганлыктан, ул хакта сүз озайтмыймын. Кызлар мәктәбе исә күп йирдә үзләренең монтазам[546] вә җитеш бер рәвешкә куелулары белән миңа бик яхшы тәэсир калдырдылар. Үзләре дә олуг бу мәктәпләрнең соң дәрәҗәдә игътибарсыз бер хәлдә тордыгы хәлдә, хәзер елдан-ел ислах ителдекләре[547] вә гакылга килмәгән бер рәвештәге миллиләштердекләрен сөйләделәр. Кызлар өчен тәэсис ителгән[548] мәктәпләрдән: дарелмөгаллимат[549], инас[550] солтан, кыз санигъ[551] мәктәбе, инас рөшдиясе[552], иттихад[553] вә тәрәккый[554] мәктәбе, дарелгорфән[555], дарельәйтәм[556], дареләдәб[557], инас нәмунә[558] рөшдиясе вә башка берничә мәктәпләрен якыннан күреп өйрәндем. Бу мәктәпләрнең һәркаюсында дин вә тел дәресләреннән башка гомуми мәгълүмат бирә торган фәннәр өстенә, һөнәр, сәнәгать[559], гимнастика, музыка дәресләре дә кертелгән. Электә бары ярты-йорты ибтидаи[560] мәктәпләр белән ялгыз бер дарелмөгаллиматлары булган. Хәзер исә, югарыдагы белән һәр йирдә урта мәктәпләр вә һөнәр курслары ачылган. Бу мәктәпләрнең вөҗүдкә килүләренә[561] башлыча сәбәп истибдад[562] дәвереннән соң башланган бер гомуми үзгәреш булса да, асыл җан кертүчеләр ханымнардыр. Бу юлда соң дәрәҗәдә гайрәт иткән[563] ханымнар

[540] Илаһият – теология.
[541] Шөгъбә – бүлек.
[542] Кәмаләт – бөтенлек, җитешкәнлек.
[543] Фазыйләт – өстенлек, яхшы сыйфатлылык.
[544] Тәгъриф итү – таныту, таныштыру.
[545] Икътидар – көч, куәт, булдыра алу.
[546] Монтазам – тәртипкә салынган, рәтле.
[547] Ислах ителү – яхшыландыру, реформа ясау.
[548] Тәэсис итү – оештыру.
[549] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[550] Инас – хатын-кыз.
[551] Санигъ – сәнгать, һөнәрчелек, профессия.
[552] Рөшдия – башлангычтан югары (урта) мәктәп.
[553] Иттихад – фикер бердәмлеге.
[554] Тәрәккый – прогресс, югарыга ашу, алгарыш.
[555] Горфән – йола буенча, урнашкан гадәт-гореф буенча.
[556] Дарельәйтәм – ятимханә.
[557] Дареләдәб – тәрбия йорты.
[558] Нәмунә – үрнәк, өлге.
[559] Сәнәгать – промышленность, һөнәрчелек.
[560] Ибтидаи – башлангыч.
[561] Вөҗүдкә килү – бар булу.
[562] Истибдад – чикләнмәгән власть, абсолютизм.
[563] Гайрәт итү – тырышлык.

бар. Шуның белән бергә, ханымнар бу хакта үзләренә бөек бер юлбашчылык иткән мәгариф назыйры[564] Шакир бәк җанәбләренә дә миннәтдарлар[565].

Хатын-кызларның мәгариф эшләренең юлга салынуында Шакир бәкнең фәүкылгадә[566] бөек бер иҗтиһад кылганлыгын[567] сөйлиләр. Бу ел дарелмөгаллимат янына бөек бер бина башланып ята. Бина кызлар өчен махсус дарелфөнүн[568] булачак. Бонда: әдәбият, риязият[569] вә табигыять шөгъбәләре булачак. Тиздән тыйббия кисеме дә тәэсис ителәчәге һәм сөйләнелә. Моңа кадәр урта мәктәпләрдә мөдирә вә мөгаллимәлек итәр өчен җитәрлек төрек ханымнары булмаган. Германия һәм Балтикадан китерткәннәр. Хәзер шул мәктәпләрдә Аурупа тәрбиясе күреп, гали мәктәпләргә керерлек хәзерлек алган төрек кызлары Франция, Германия вә Англия гали мәктәпләренә китәләр. Тәхсил бетереп[570] кайтканнары да бар.

Әүвәлләрдә дә бу хәл булгалаган икән, ләкин бик аз булган. Хәзер исә һәр ел берничә төрек кызы Аурупага китеп, берничәсе тәмам итеп кайтып тора. Шунлыктан берничә ел эчендә кызлар өчен ачылган урта мәктәпләрнең һәркаюсы төрек ханымнары, төрек мөгаллимәсе вә төрек мөдирәләренең идарәсенә керәчәге аңлашыла. Төрек кызлары никадәр мәгълүмат алмасын вә никадәр яхшы бер тәрбия күрмәсен, аларга шул көнгә кадәр там[571] хокуклы мөстәкыйль бер инсан баласына караган кебек карау юк икән. Төрек ханымнары шуннан бик рәнҗи дә вә чарасыз булдыкларын аңлаттылар. Аннан соң төрек мөгаллимәләре никадәр тырышсалар вә никадәр фидакарьлек күрсәтсәләр дә, аларга шул көнгә кадәр читләргә бирелгән вазыйфа бирелмәгән. Бер мәктәп вә бер сыйныфта укыган немец, француз кызларына айга ун лира мәгаш[572] бирелдеге хәлдә, төрек кызларына шуның ялгыз яртысы бирелдекне сөйләделәр. Шулай булганы хәлдә, төрек ханымнары үзләренең вазыйфаларында косур[573] күрсәтмиләр.

Дарелмөгаллимат, инас солтан, кыз санигъ мәктәбе дигән мәктәпләренең һәрберендә 7–8 йөз шәкерт-кыз булып, иң кечкенә мәктәпләрендә 2–3 йөз шәкерт бар. Яңа мәктәп ачылу илә кызларның тулып калганын сөйлиләр. Элек мәктәпкә йөрү иң ихлассыз[574] эшләнә торган бер буш вакыт үткәрүдән гыйбарәт булса, хәзер иң ләззәт белән үтәлә торган бер мөкаддәс[575] эш хәленә килгән.

---

[564] Назыйр – министр.
[565] Миннәтдар – рәхмәтле, ярдәм өчен шатлык белдерү.
[566] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[567] Иҗтиһад кылу – тырышлык кую, тырышу.
[568] Дарелфөнүн – югары уку йорты, университет.
[569] Риязият – математика.
[570] Тәхсил бетерү – гыйлем алу, уку йортын тәмамлау.
[571] Там – тулы.
[572] Мәгаш – хезмәт хакы.
[573] Косур – кимчелек, җитешсезлек.
[574] Ихлас – күңел бирү.
[575] Мөкаддәс – изге, мөһим.

Мәктәпләрнең күбесе хөкүмәт тарафыннан тәэмин ителгәннәр. Хөкүмәт мәктәпләре өстенә, әллә никадәр хосусый мәктәпләр дә бар. Хөкүмәтнең боларга да ярдәм иткәнен сөйләделәр. Истанбул кызлары пайтәхет[576] кызы булу вә үзләренә махсус ягымлы, матур милли киемнәр киюләре белән дә бик җыйнак, матур вә бик зарифлар[577], мәктәп кызлары бигрәк тә матур вә һәр тугърыда үзләрен тота беләләр. Вә барлыгы бер төстә киенәләр, кирәк мәктәптә, вә кирәк өйләрендә булсын, үзләрен гаять тәмиз[578] вә гаять тәрбияле, әдәпле тоталар.

Мәктәпләр ләйле (пансионлы) вә нәһари[579]. Ике төрле. Ләйле мәктәпләрдә ашау-эчү, яту-тору бүлмәләре, гыйбадәт урыннары аерым, хифзыссыйхәткә[580] муафыйкъ[581] зурайтып эшләнгән. Гаять пөхтә, һәр урынга үзенә махсус карауччы вә эш күрүче хезмәтчеләре бар. Мәктәпнең һәр китапханәсе, музаханәсе[582], мунчасы бар. Дарелфөнүн янында ирләр өчен дә конферанс (лекция) заллары бар. Айда ике мәртәбә конферанс бирелә икән. Бу залда тарих вә иҗтимагый төрле мәүзугъларда[583] шәкертләргә махсус нотыклар[584] сөйләнә, кинематограф лентасы белән дөньяда булган һәртөрле вакыйгалар, яңа чыккан нәрсәләр (ихтираг[585] вә кәшфият[586]) күрсәтелеп тора.

Партада утырып арыган вә талган балаларга кинематограф ленталарында булган файдалы вә кызык вакыйгалар күрсәтелү илә, балаларга рухлары күтәрелеп, арганлыклары онытылып йөзләрендә шатлык яктылары күренә, өстенә шул арада җилдләрчә[587] китаплар актарып алынмый торган мәгълүмат алынадыр. Берничә мәктәпләрдә риязый бәдәния [588], «гимнастика» өчен ясалган әсбабы[589] җитеш аерым монтазам[590] бүлмәләр, гөлләр, чәчәкләр утыртылган матур мәктәп бакчалары бар, имтихан вакытларына тугры килгәнлектән, дәрес бирү ысулларын күрә алмадым. Имтиханнарын күп күрдем. Берничә мәктәпләрендә икешәр, өчәр көн төрле дәрестән имтихан вакытларына бардым. Имтиханда һәр йирдә төрек кызларының гаять тере, кыю вә үткен булганлыкларын күрдем. Тартынып, оялып, ык-мык итеп торулар, сүз сорагач, тукталып, аптырап торулар һич күренмәде. Дарел-

---

[576] Пайтәхет – башкала.
[577] Зариф – ягымлы.
[578] Тәмиз – чиста, пөхтә.
[579] Нәһари – көндезге (дневной).
[580] Хифзыссыйхәт – сәламәтлек, гигиена.
[581] Муафыйкъ – яраклы.
[582] Музаханә – музей.
[583] Мәүзугъ – проблема, тема.
[584] Нотык – чыгыш.
[585] Ихтираг – ачыш.
[586] Кәшфият – яңа барлыкка китерелгән гыйльми, фәнни һәм техник яңалыклар.
[587] Җилд – том.
[588] Риязый бәдәни – физкультура.
[589] Әсбаб – җиһазлар, кирәк-яраклар.
[590] Монтазам – тәртипле.

мөгаллимат мөдирәсе мөхтәрәмә Сәмия ханымның мөсагадәсе[591] илә дарелмөгаллимат имтиханында берничә көн дәвам иттем. 13 яшьлек бер кыз баланың чалмалы, фәсле байтак мәляэ[592] вә мөдәрис һәм зыялылар алдында сораган бер сүзгә туктаусыз ярып җавап биреп торуы шул көнгә кадәр хәтеремнән чыкмый.

Төрек ханымнары арасында шундый үткен, гайрәтле, кабилият[593] вә истигъдадлы[594] яшь кызлар җитешкәнен күргәч, бу халыкның истикъбале[595] өметле идегендә шөбһә килергә урын калмады. Дарелмөгаллимат, кыз санигъ мәктәбе, инас солтан мәктәпләрендә ана мәктәбе (балалар бакчасы) шөгъбәләре[596] бар. Бу шөгъбәләргә 3 яшеннән 8 яшенә кадәр булган балаларны кабул итәләр. Боларның үз кулларына китап бирелми. Һәрнәрсә хакыннан шифаһи[597] мәгълүмат бирелә. Әхлак дәресләре сөйләнә. Бу шөгъбәләрдә һәрнәрсә җиңел. Теле ачылган вак балаларның һәркаюсы аңларлык рәвештә һәрнәрсә алга куелып, гамәли рәвештә өйрәтелә. Музыка (пианино) белән һәртөрле милли көйләр, ватан маршлары, зиһеннәре йөкли алган кадәр өйрәтелә. Үзләреннән сүз, нотык сөйләтәләр. Һәр сүзгә муафыйк әгъзаларын килешле рәвештә хәрәкәтләндерәләр. Гаять оста вә матур сөйлиләр.



Бәлкыйс Шәүкәт ханым белән Фәтхи бәк
*(«Сөембикә», 1914, №10)*

Хатын-кыз мәктәпләренең күбесендә төрек теле соңында я француз, я немец, я инглиз теле өйрәтү бар. Теләгән кешеләр әҗнәби[598] телләредә ике-өч тел белергә мөмкин. Белгәннәре һәм дә бик яхшы белгәннәре бар. Кайбер

[591] Мөсагадә – тырышлык.
[592] Мәляэ – төркем.
[593] Кабилият – сәләт.
[594] Истигъдад – сәләтле, булдыклы.
[595] Истикъбаль – киләчәк.
[596] Шөгъбә – бүлек.
[597] Шифаһи – телдән.
[598] Әҗнәби – чит.

гаиләләр арасында французча, немецча мөкәммәл[599] сөйләшүчеләрнең бик еш очраганлыгы аңлашылды. Соңгы елларда кирәк мәктәпләрдә, вә кирәк өй эчләрендә, музыка бик тәрәккый иткән. Бераз хәле булган гаиләләрнең һәркаюсында пианино бар. Төрек кызлары пианинода уйнап, янына саф вә нәзек бер тавыш белән шәркый сөйләгән (җырлаган) вакытларда күздән яшьләр килеп, тәэсиремнән үземнең кайда икәнемне онытa торган идем. Белмим, төрек ханымнарының ябык торыштан хасыйл булган моңнары, белмим, музыка вә шигырьләрендә булган нәзакәт[600] вә нәфасәт[601] шулкадәр тәэсир итәме? Музыка катыш төрек шәркыйсы сөйләгән вакыт адәм бөтен дөньясыннан ваз кичәдер. Билхасса[602] Бешикташта «Иттихад тәрәккый» инас мәктәбе минем күңелемдә бик тирән тәэсир калдырды. Гаять монтазам вә киң юлга салынган бу мәктәптә Мадмуазель Руута ханым мөдирәлек итә. Мөгаллимәләре мәгъруф[603] төрек ханымнарыннан Харкә, Хәдичә, Бәлкыйс Шәүкәт[604] җид[605] ханымнар икән. Яһүди вә ярмани[606] мөгаллимәләре дә бар икән. Бу мәктәпкә махсус дәгъвәт[607] буенча барган идем. Имтихан ахырында гаять мөәссәр[608] бер сурәттә кызлар тарафыннан төрекчә, французча мәнзумәләр[609] укылды. Күңелемдә иң тирән бер тәэсират[610] калдырган мәктәп шушы мәктәп булды.

Оренбурглы мөгаллимә Багбостан

*«Сөембикә», 1914, №22, б.4–8.*

## Килем авылында[611] Җантуриннар[612] мәктәбе

«Ил» газетасының 35нче санында Хәлим Госмани әфәнде «Килемдәге вакыфның хәле» исемле бер мәкаләчек бастырган иде. Ул мәкаләсендә Килемдә Суфия ханым Җантурина[613] тарафыннан салдырылган мәктәпләрнең эшсезлегеннән, вакыф малыннан хисап бирелмәвеннән зарлана. Бу мәктәп-

[599] Мөкәммәл – камил, яхшы.
[600] Нәзакәт – нечкәлек, нәфислек.
[601] Нәфасәт – гүзәллек.
[602] Билхасса – аерым алганда.
[603] Мәгъруф – танылган.
[604] Бәлкыйс Шәүкәт – төрекләрнең беренче очучы кызы.
[605] Җид – тырыш, җитди.
[606] Ярмани – немец.
[607] Дәгъвәт – чакыру.
[608] Мөәссәр – йогынты ясалган, тәэсирле.
[609] Мәнзумә – дастан.
[610] Тәэсират – тәэсир.
[611] Килем авылы хәзер Башкортстанның Бүздәк районына керә, бу авылда татар морзалары Тәфкилевләрнең утары урнашкан була.
[612] Җантуриннар – Букәй Урдасы казакъ ханнары нәселе дәвамчылары, мәгърифәтчеләр, химаячеләр.
[613] Суфия Сәетгәрәй кызы Җантурина (Тәфкилева) (1874–1911), мәгърифәтче, хәйрияче, Килем авылында ир балалар һәм кыз балалар өчен мәктәпләр, туку остаханәсе ача.

ләрнең ничек мәйданга китерелүе, мәйданга чыкканнан соң мөгаллим вә мөгаллимәләренә каршы нинди мөгамәләләр кылынганлыгы, Килемнең гыйзамәтле[614] (олы) мәсҗете михрабында никадәр ләгънәтләр яудырылганы бу әфәндегә бик билгеле булу сәбәпле, ул турыда сүз дә кузгатмыйм.

Суфия ханым сәламәт чагында бу мәктәпләрне милләтебезнең иң эшлекле җәмәгать хадимнәреннән булган Сәлимгәрәй әфәнде Җантурин җәнабләре[615] белән бергә идарә кылалар иде. Суфия ханым үлгәннән соң, мәктәпләр аның тарафыннан куелган мөтәвәллиләр[616] белән Сәлимгәрәй әфәнде кулында калды. Һәр ел диярлек мәктәпләр вакыфы булган йирләрдән килгән файда аларның чыгымына йитми. Йитмәгәнен Сәлимгәрәй әфәнде үз кесәсеннән тутырып килә.

Килем мәктәпләренең милләткә хезмәт итеп-итмәвен белер өчен, Суфия ханым үлгәннән соң, аның өч ел эчендә эшләгән эшләрен күз алдына китерү йитсә кирәк. Өч елда ир һәм кызлар мәктәпләренә 682 шәкерт кабул кылынган. Өч ел эчендә шуларның 49ы төрле гозер вә сәбәпләр буенча мәктәпләргә дәвам итә алмаганнар. Шуларның 192се ибтидаи икенчегә күчкәннәр. 1913нче елны ирләргә махсус рөшди сыйныфын 9 шәкерт бетереп, Уфадагы «Мәдрәсәи Галия»нең беренче вә икенче тахсыйри[617] сыйныфларына кергәннәр. Кызлар рөшдисен 5 туташ тәмам итеп, боларның өчесе шул мәктәптә мөгаллимә булып калганнар. 1913нче ел 14нче апрельдә корылган кул эшләре выставкасында бу мәктәп шәкертләре үзләре эшләгән һөнәрләрен күрсәткәннәр. Кызлар мәктәпләрендә кул һөнәрләре яхшы гына алга киткән. Янә бу мәктәпләр Сәлимгәрәй әфәнде һиммәте белән тирәяктагы мәктәп вә мәдрәсәләргә арзан бәһа белән китаплар өләшеп, авыл мәктәпләренә җиңеллек күрсәткән. Мәктәпләрнең кыйраәтханәләре аз булса да тәртипкә куелган.

Мөгаллим вә мөгаллимәләрнең белем вә икътидарларын үлчәү Хәлим әфәнделәр кулыннан килә торган бер эш түгел. Ул анчак[618] мәктәп вә мәдрәсәләрнең үз әһелләренә мәгълүм бер мәсьәлә. Хәлим әфәнденең бу мәктәп вә мәдрәсәләргә кергәне вә мөнәсәбәте булмаганы хәлдә, мөгаллимнәрнең икътидарларын үлчәве, аз булганда берәр шәгассыйт (интрига) арттыру, берчак әйткәндә, тәрбия исеменнән бер җинаятьтер. Килем мәктәпләре вакыфы бүгенгә кадәрле рәсми тасдыйк ителмәгән, иттерү дә мөмкин булмаган. Вакыфны Суфия ханым үзе куйган мөтәвәллисе идарә итә. Мәрхүмәнең варисларына хисабын биреп тора.

Шул сәбәпләргә күрә, Хәлим әфәнденең «Ил»дә бастырган мәкаләсе нинди булса берәр тәэсир астында язылгандыр, дип уйлыймыз.

*«Тормыш», 1914, 10 октябрь.*

---

[614] Гыйзамәтле – олы.

[615] Сәлимгәрәй Сәетхан улы Җантурин (1864–1926), эре алпавыт, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче, Уфа губернасыннан Беренче дәүләт думасы депутаты; Килем авылында балалар приюты ача, «Лөгать» (1911) авторы.

[616] Мөтәвәлли – вакыф эше белән шөгыльләнүче.

[617] Тахсыйри – хәзерлек.

[618] Анчак – ул вакытта.

## Уку дөньясында

Унбиш-егерме еллар гына элгәре уку-укыту дигән эшләр бик аз иде. Менә Бәләбәй өязе Мерәс[619] школасында 1887нче елда бары алты гына бала, 1907нче елда [?] бала укыган. Ошбу егерме ел эчендә 15 бала школа тәмам иткәннәр.

Бу соңгы елларда халык бөтенләй үзгәрде. Һәркемнең телендә уку-укыту. Шул ук Мерәс школасында 1911нче елда 70 ир, 40 кыз бала укыганнар. 1912нче елда 82 ир, 59 кыз бала булган.

Школьный сеть буенча, Мерәс авылында кызлар школасы 1926нчы елда гына ачылырга тиеш булса да, бу авылда укучы кызлар күп булганга, 1913нче елда сетьтән тыш кызлар школасы ачылды.

Земстволар авылларга школалар ачу юлында елдан-ел артыграк тырышсалар да, мөселманнардан укытучылар чыкмый. Шул сәбәпле булса кирәк, мөселман араларына төрле мөселман булмаган укытучылар куелдылар.

Мөселман булмаган укытучыларның безгә карашлары шулай: Бервакыт мин [...] авылында булдым. Анда өч учительница бар икән. Өчесе дә рус кызлары. Сүздән-сүз чыгып, уку-укыту тугрысында да сүз башлагач, «Укучы кызлар күпме? Сезгә аларны укыту һәм татар арасында торулар кыен түгелме?» – дип сорадым. Балалар күп юк, әмма шулай булса да татар баласыны укытыр, шулай ук татар арасында тору бик кыен, дип җавап бирделәр. Татар арасында алай төрле уңайсызлыклар күргәч, ник үз халкыгыз арасында торырга, урнашырга тырышмыйсыз, – дидекемдә: «Бөтен дөнья православный булып бетмичә, кыямәт булачак түгел», – дигән сүзне ишеттем. Моннан соң [...] учительницасына очрап, аның татар арасында тормышын сораштым: «Тору бик рәхәт, хәзер дә мин үзем дә татар булып беттем инде. Хәтта исемемне дә татарча «Әминә» дип йөртәм», – диде. Моннан ике ел гына элгәре укучы кызлар 60 булып та, быелда бик аз булуның сәбәбен сорашкач: «Әй, алар укыса-укымаса, минем анда эшем юк, менә 26 кыз кергән иде, 8е чыгып китте инде, мин бер дә кайгырмыйм, миңа акча булса җитә», – диде.

Бу учительница исемен «Әминә»гә әйләндерсә дә, бу исем татарларның күзен буяу гына. Бу елга чаклы безнең җомга көннәр зур бәйрәмнәремездән саналса да, бу ел «Әминә» учительницаның җомга көндә укытканы күренә. Җомгалар, без хәзергә сирәкләп, бара торгач, бөтенләй онытылмаса ярар иде, дип төрле уйлар төшә.

Кызлар школага кергәндә, учительница аларга: «Әгәр дә чыгып китсәгез, биш сум штраф түләрсез», – ди икән. Фәкыйрь халык шул штрафтан куркып, баласыны укуга йибәрми, имеш.

Учитель вә учительницалар школаларда дин укытучыларга күп игътибар итмиләр. Аларны үз карамакларында, үз кулларында тоталар; күбесенчә күбрәк гаепне дин укытучыларына аударалар. Дин укытучыларымыз учитель-учительница шулай куша, диләр дә, иртән сәгать 6–7 дән кереп 8 гә кадәр укыткан булалар. Директор вә инспекторларның 1912нче елда Уфа шәһәрен-

---

[619] Мерәс авылы – хәзер Башкортстанның Кызыл Кама районына карый.

дә булган җыелышларында төзелгән инструкциянең 13нче параграфынча, яз вә көз көннәрендә укуны сәгать 8 дә башлап, калган вакытларда 9 да башларга тиеш. 13нче параграф дин укытучыларының үзләре теләгән көннәрне вә сәгатьләрне алуда ихтыярлы идекен күрсәтә. 137нче параграф буенча инструкциядә күрсәтелгән правилолар илә эш кылырга начальный школаларда укытучыларның һәркаюсы мәҗбүриләр. Шуның өчен безнең дин укытучыларымыз 13, 14 маддәләргә аерым игътибар итсәләр, яхшы булыр иде.

*«Тормыш», 1914, 7 ноябрь.*

### Бакуда мөслимәләр җәмгыяте

«Икъбаль» гәзитәсендә[620] язылдыгына күрә, Баку мөселман ханымнары «Инас[621] җәмгыять хәйриясе» исемендә бик киң программалы бер җәмгыять ачарга булганнар. Җәмгыятьнең максуды бондан гыйбарәт:

1) мөселман ханымнарының әхвәл, мәдәния вә икътисадияләрене күтәрү;

2) гаҗиз мөселман хатыннарына ярдәм вә химая итү[622];

3) мөселман хатыннары арасында мәгариф таратырга тырышу;

4) гали, игъдади[623] вә ибтидаи[624] мәктәпләрдә укыган мөселман кызларына ярдәмдә булыну. Боның өчен бу җәмгыять ошбу эшләргә тәшәббес итәчәк[625];

5) эш эшләп тамак туйдырырга көче йитмәгән гаҗиз вә авыру хатыннарны химаясенә алачак;

6) фәкыйрә мөселман кызларыны дарельәйтәмнәргә[626] вә һөнәр мәктәпләренә, вә игъмаләтханәләргә[627] биреп тәрбия итәчәк;

7) фәкыйрь вә ятим хатыннарга дарелгаҗизин[628], дарельәйтәм, хастаханә вә һөнәр (эш) йортлары ачачак;

8) мөрәббия[629], даяләр[630] йитештерү, гомумән тәгълим вә тәрбия үгрәтү өчен хосусый курслар, карт хатыннар өчен гомуми курслар ачачак;

9) кулинария курслары (аш пешерергә, кондитер нигъмәтләре хәзерләргә үгрәтә торган мәктәп) вә алар янында һөнәр мәктәбе, игъмаләтханәләр ачачак;

---

[620] Бакуда 1912–1915 елларда чыгып килгән көндәлек иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета.
[621] Инас – хатын-кыз.
[622] Химая итү – яклау, саклау.
[623] Игъдади – хәзерләү.
[624] Ибтидаи – башлангыч.
[625] Тәшәббес итү – керешү.
[626] Дарельәйтәм – ятимнәр йорты.
[627] Игъмаләтханә – эш урыннары.
[628] Дарелгаҗизин – картлар йорты.
[629] Мөрәббия – тәрбияче.
[630] Дая – бала караучы.

10) мөселман кызлары өчен һәр йирдә мәктәпләр ачтырырга тырышачак, мөмкин булган кадәр үзе дә ачачак;

11) мөселман хатыннары өчен лекцияләр вә башка шундый гомуми дәресләр тәэсис итәчәк;

12) фәкыйрь вә мескен укучы кыз балаларга җәйлек истирахәт[631] урыннары (колонияләр) ачачак;

13) дәрес китаплары вә гомуми кыйраәтханә[632] өчен башка һәртөрле китаплар нәшер итәчәк;

14) җәмгыятьнең төп идарәсе янында әгъзалар вә гомум мөселман хатыннары өчен китапханә ачачак, буш бирү вә яхуд арзан хак белән сату өчен җәмгыять китапханәсендә тәгълим вә тәрбиягә гаид[633] рисаләләр[634] тотылачак;

15) авыл мәктәпләрендә укыган истигъдадлы[635] вә кабилиятьле[636] шәкертләрдән авыл мәктәпләре өчен мөгаллимәләр хәзерләргә тырышачак. Безнең өчен дарелмөгаллимат[637] вә «мөгаллимәләр курсы» кеби хосусый кызлар мәктәпләре ачачак.

Җәмгыятьнең фәгалиятен[638] киңәйтү өчен Баку губернасының мөселманы күбрәк шәһәр вә касабәләрендә[639] шөгъбәләр[640] ачылачак.

Җәмгыятьнең сәрмаясе[641] ошбу урыннардан җыелачагы фараз ителәдер: 1) әгъзалык акчалары, 2) иҗтимагый вә хөкүмәт мөәссәсәләреннән[642] (шәһәр вә земство идарәләре вә башка шуның кеби урыннардан), 3) иганә, васыять, вакыф вә башка шундый урыннардан; 4) җәмгыять тарафыннан биреләчәк театр вә әдәбият кичәләре, лекция вә нотыклардан.

Идарә: Бакудагы мөселман хатын-кызларының бондый гали эшкә керешүләрене чын күңелемездән тәбрик итәмез. Хатын-кызларымыз гаҗизәләр, мескенәләрдер ки, аларны тәрәккый[643] юлында аз гына хәрәкәт, аз гына кыймылдау бөек урын алачактыр. Баку кеби байлары, зыялылары күп бер шәһәрдә мөселман ханымнарының бондый гали эшкә тәшәббесләреннән максатларының тиз вөҗүдкә чыгачагында[644] шөбһә итмимез. Әйдәңез, мөхтәрәм ханымнар! Вакыт йитде. Күзләремезне ачыйк. Эчке Русиядәге мөселман

---

[631] Истирахәт – ял итү, эштән бушап тору.
[632] Кыйраәтханә – уку өе, библиотека.
[633] Гаид – бәйләнешле.
[634] Рисалә – мәкалә, брошюра.
[635] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.
[636] Кабилиять – сәләтлелек, булдыклылык.
[637] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[638] Фәгалиять – эшчәнлек.
[639] Касабә – район.
[640] Шөгъбә – бүлем, бүлек.
[641] Сәрмая – акча, капитал.
[642] Мөәссәсә – оешма, учреждение.
[643] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[644] Вөҗүдкә чыгу – бар булу, тормышка ашу.

ханымнарына да һиммәт[645], гайрәт күрсәтергә, хатын-кызларымызның хәлләренә бакып, аларның хәлләрене ислахка тырышырга кирәк.

Казан, Уфа, Оренбург кеби байлары, зыялылары бар мөселман ханымнары һөнәр мәктәпләре, һөнәр йортлары, кулинария курслары ачарга тәшәббес итсәләр, вөҗүдкә чыгуы авыр булмаячактыр. Һиммәт гайрәт лязем[646], һиммәт гайрәт булганда нинди авыр, нинди читен эшләр дә җиңеләячәктер.

*«Сөембикә», 1914, №2, б.17–18.*

***«Вакыт»***

**Музыка мәктәбендә мөселман ханымнары**

Федотова ханымның музыка мәктәбендә мөселман ханымнарыннан: Хөсниҗамал Карабаева (казакъ), Хәдичә Ядкәрова һәм Вәлиева ханымнар мөдавәмәт итәләр[647]. Хөсниҗамал ханым Карабаева өченче ел дәвам итәдер. Калган икесе бу ел кергәннәр.

Вәлиева ханым ирле – гаилә анасыдыр. Иргә чыгып, йорт-йир көтә башлаган ханымнар арасында мәктәпкә йөреп, музыка үгрәнергә тырышучыларның булуы, мөселман ханымнары арасында сәнаигы нәфисәгә[648] көчле бер һуш туып барганлыгын күрсәтәдер.

*«Сөембикә», 1914, № 3, б.18–19.*

***Хәтимулла Мөхәммәтфазыл***

**Җантуриннар мәдрәсәсендә**

Иске Килем авылында Җантуриннарның ирләр һәм кызлар мәдрәсәсендә 282 шәкерт дәрескә дәвам итә. Һәр ике мәдрәсәдә бишәр сыйныф булып, биш мөгаллим вә биш мөгаллимә тарафыннан дәрес бирелә. Мөгаллимнәрнең күбесе «Галия»[649] мөәзиннәреннән булып, мөгаллимәләр исә, мөдирәдән башкасы, шул Җантуриннар кызлар мәдрәсәсендә укып йитешкән ханымнар.

Мәдрәсәнең кыйраәтханәсенә, үткән еллардагы шикелле, бу ел да уку китаплары арттырылды.

Шәкертләргә уку вә язу әсбабы хәзерли торган «Авыл китапханәсе» лязем[650] булачак. Уку вә язу нәрсәләрен җәйдән үк хәзерләп куйганга күрә, китап вә башка әсбапның бәһасе бик арзан булды. Бинаән[651], галия укучыларга соң дәрәҗә җиңеллек ясалды.

Мәдрәсәнең мөдире Хәтимулла Мөхәммәтфазыл.

*«Тормыш», 1915, 1 гыйнвар.*

---

[645] Һиммәт – тырышлык.
[646] Лязем – тиеш, кирәк.
[647] Мөдавәмәт итү – дәвам.
[648] Сәнаигы нәфисә – матур сәнгать.
[649] «Галия» – «Галия» мәдрәсәсе.
[650] Лязем – тиеш, кирәк.
[651] Бинаән – бәйле рәвештә, нигезләнеп, шулай итеп.

***И.Мөхсинов***

**Авылларда**

Бәләбәй өязе Каръяуды волосте Байбулат[652] авылында яшь мулла Мөхәммәд әфәнде илә мөәзиннәренең тырышуы аркасында бик яхшы кызлар мәктәбе ачылды. Мөгаллимә вазыйфаны мулла үзе бирә. Авылның могътәбәрләреннән [653] Хәбибулла әфәнде үзенең бер өен кызлар мәктәбе итеп тотарга рөхсәт итте. Аның өчен акча алмый. Халык бу затларга бик күп рәхмәтләр укый. Инде ирләр мәктәбендә мөгаллим китерелсен иде, дия башлаганнар. Моннан соң йир өләшкәндә артып калган гомуми йирне мәктәп файдасына вакыф[654] итәчәкләрен сөйлиләр.

*«Тормыш», 1915, 4 гыйнвар.*

***Г.С.***

**Троицк**

Соң елларда монда кызлар укытуга хәйле әһәмият бирелергә башлады. Ачык фикерле хәзрәтләр вә голәмамыз дә һәрвакыт кызлар укытуның тиешлеген халыкка төшендерә торалар. Хәзерендә Троицкида барлыгы 15ләп йирдә кызлар укыйлар. Ләкин мәгаттәәссеф[655] бонлардан унлабы иске ысулча булып, бары биш-алтысы гына тәртипле вә яңа ысулдадыр. Бу соңгылар җөмләсеннән берсе былтыр гына ачылган Гайния ханым Яушева [656] мәктәбедер.

Боның мөдирәсе моктәдир [657] мөгалимәләребездән бубыйлы мәшһүр Мөхлисә ханым булып, назыйрәләре Гайния вә Хәдичә ханым Яушевалардыр. Бу мәктәпнең програмы яхшы ук киң булып, укылуы вә беленүе матлуб булган[658] нәрсләрнең күбесен җамигъдыр. Дәрес ысуллары да яхшы куелган.

Мәүлид бәйрәме бу ел яхшы ук тантаналы үтте. Ләкин, менә мәктәп шәкертләрен бергә җыеп, Троицк ханымнары шәрәфенә гүзәл бер әдәбият кичәсе ясыйсы җирдә, һәрбер мәктәп үзенә аерым-аерым әдәбият кичәләре ясап һәм кечкенә булды, һәм күңелсез булды. Шаять киләчәк бәйрәмнәрдә моны алдан ук исәпләп, хәзерләнеп куярлар дип өмет итәбез.

*«Вакыт», 1915, 24 гыйнвар.*

---

[652] Башкортостанның Чакмагыш районындагы авыл.

[653] Могътәбәр – хөрмәтле, зыялы, затлы.

[654] Вакыф – берәр кеше тарафыннан килерен җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек.

[655] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.

[656] Гайния Яушева – Троицк шәһәрендә беренче дарелмөгаллимат ачучы, мөдирәсе.

[657] Моктәдир – көчле, сәләтле.

[658] Матлуб улу – таләп ителү, соралу.

***Троицкилы***

## Троицкида кызлар мәдрәсәсе



Мөхлисә Бубый

Троицкида мөхтәрәм Латыйф әфәнде Яушевның[659] анасы Гайния абыстай тарафыннан кызларга махсус тахсыйриясе илә дүрт сыйныфлы яңа бер мәдрәсә тәэсис ителде[660]. «Мәдрәсәи Гайния» аталган бу мәдрәсә шәһәрнең урта бер йирендә булып, бинасының матурлыгы вә хыйфзыссыйххәткә муафыйк булуы илә заманымызда бер кызлар мәдрәсәсе дияргә ярыйдыр. Баш мөгаллимәсе дә ысул тәгълимгә муафыйк хатын-кыз тәрбиясендә беренчелек дәрәҗәсен алып килгән Бубый абыстае Мөхлисә ханымдыр. Бу мәдрәсәдә баш мөдирәдән башка, 5 мөгаллимә укыта. Бер мөбассыйрәсе[661] бар: бәгъзе хәлле кызлардан уку хакы алынса да, фәкыйрьрәкләрдән һичнәрсә алынмый, буш укыйлар. Гайния абыстай матди ярдәм өстенә, шул мәдрәсәдә укучыларның кирәк уку, вә кирәк болай тәрбия ягыннан булсын, ни кирәк шуны йитештереп тора. Әдәбият кичәләре, уку мәҗлесләре ясалса, һәммә кызларга, дәрәҗәләренә күрә бүләкләр, һәдияләр[662] таратып, күңелләрен күтәрә, укуларында тырышып дәвам итүгә тәргыйб[663] вә тәшвикъ итә[664]. Шунлыктан бонда укыган кызлар гыйлем юлында булган зәхмәтләрнең һичберсенә хис итми, шат күңел, бөек дәрт вә хәвәс белән тырышып укыйлар. Мондый монтазам[665] вә заман рухына мөнасыйб[666] бөек бер мәдрәсә бина кылып, аңа да тиешле чын гыйлем иясе мөгаллим вә мөрәббиләр[667] җәлеп итә белгәнлекләре өчен Латыйф әфәнде Яушев илә мөхтәрәмә анасы Гайния абыстай шаян тәхсин[668] вә лаек тәшәккердерләр[669]. Җәнаб Хак бондый һиммәт ияләренең[670] әмсален[671] арттырсын.

*«Вакыт», 1915, 4 февраль.*

---

[659] Латыйф Мөхәммәтшәриф улы Яушев – Троицк сәүдәгәре, хәйрияче.
[660] Тәэсис ителү – төзелү, оештырылу.
[661] Мөбассыйрә – күзәтүче.
[662] Һәдия – бүләк.
[663] Тәргыйб итү – кызыктыру, кызынсындыру.
[664] Тәшвикъ итү – кызыксындыру.
[665] Монтазам – тәртипле.
[666] Мөнасыйб – яраклы, туры килгән.
[667] Мөрәбби – тәрбияче.
[668] Шаян тәхсин – мактауга лаеклы.
[669] Тәшәккер – рәхмәт белдерү.
[670] Һиммәт ияләре – тырышлык куючы, ярдәм итүче.
[671] Әмсал – мисаллар.

### Фатыйха ханым Аитова мәктәбе

Казаннан болай язалар: былтыр бераз кеше тарафыннан Фатыйха ханым Аитова җәнабләренең кызлар мәктәбе өчен програм төзелгән иде. Мәктәп 8 еллык булып, шәһадәтнамәле мөгаллимәләр чыгарачак иде. Мәгариф министерствосы тасдыйкына[672] җибәрелгән бу программа хәзер әйләнеп кайтмыштыр. «Рус теле вә әдәбияты; рус тарихы вә географиясе төрки телдә укытылу мөмкин түгел; бәгъзе дәресләр урта мәктәпнекеннән зуррак ителеп кертелгән. Шул сәбәпле бу программны тасдыйк кылып булмый», – диелгән. Бу мәсьәләдә бәгъзе Казан депутатлары да хәер хаһәнә сурәттә[673] ярдәмләшәләр икән. Хәзер мәктәп өчен яңа програм төзелеп тәкъдим ителәчәктер.



Фатыйха Аитова

*«Вакыт», 1915, 8 февраль.*

***С.Г.***

### Троицк

[...] Троицкиның алга килгән бер җәһәтеннән зикер итеп үтәргә тиешле ки – авылда кызлар мәктәбенең күбәюе вә төзелүедер. Моннан 5–6 ел мөкаддәм Габдрахман әфәнде Әхмәров иҗтиһады[674] берлә рәсми рөхсәтле бер ибтидаи[675] кызлар мәктәбе ачылган иде. Шул мәктәп яхшы гына дәвам итә. Мөгаллимәләре дәрәҗәсенә күрә икътидарлы[676] гына. Русча да яхшы укыла.

Быел мәрхүм Шәриф Яушев[677] әһлиясе[678] Гайния абыстай бер дарелмөгаллимат ачарга рөхсәт сорап, тиешле урынына гариза бирде. Мәктәп «рөшди»[679] кыйсеме[680] берлә ошбу үткән көздән үк ачылып китте. Хәзер дә Мөхлисә Бубый абыстай идарәсендә дәвам итә. Биналары бер дәрәҗәгә кадәр җитеш. Рәсми рөхсәте чыгып, устав вә програмы буенча эшкә керешкәндә, биналары тагын да арттырылачак. Мәктәпнең устав вә програмы Дума вә советта кабул ителеп, вә патша хәзрәтләренең тасдыйкыннан үтеп, канун

---

[672] Тасдыйк – раслау.
[673] Хәер хаһәнә сурәттә – яхшы теләк күрсәтеп.
[674] Иҗтиһад – тырышлык.
[675] Ибтидаи – башлангыч.
[676] Икътидар – булдыра алу, көч җитү.
[677] Мөхәммәтшәриф Әхмәтҗан улы Яушев – сәүдәгәр, хәйрияче.
[678] Әһлия – тормыш иптәше, хатын.
[679] Рөшди – урта.
[680] Кыйсем – бүлек.

булып чыккан, вә үткән 1914 ел июльдә 2006нчы статья астында нәшер ителгән «Хосусый мәктәпләр низамына»[681] муафыйк тәртип ителгән. Бу дарелмөгаллиматның янында бу ибтидаи нәмунә мәктәбе булачак. Уставы буенча укытучылар арасында мөгаллимнәр дә булырга мөмкин.

Бонлардан башка, кызлар өчен ике русча укыла торган мәктәп ачылган. Тройцкида андый яңа мәктәпләр ачыла тору иҗек ысулы берлә укытып ятучы карт абыстайларга да тәэсирсез калмаган. 100–120 кызны үзе генә укытучы абыстайлар да, иптәш мөгаллимнәр алдырып, кайсыберләре русча укытырга да мәҗбүр калганнар. Шулай итмәгәндә, карт абыстайлы вә мөһиммә әл-мөслиминнән[682] дәрес сөйләү авторитетлары гына җитмәгәне күренгән.



Троицкида Г.Әхмәровнның кызлар мәктәбендә укучы 3нче сыйныф шәкертләре
*(«Сөембикә», 1914, № 14)*

«Вакыт»ның 1667нче нөсхәсендә Гайшә Чинаева имзасы астында басылып чыккан мәктүбтә[683] зикер ителгән мәктәп тә башта иҗекче бер мәктәп булып, әхвәл әхбар ителүе берлә исемен үзгәртергә мәҗбүр булган бер мәктәптер. Фәкать бу мәктәп, шул мәктәптә укучыларның яздыклары кеби, ысул вә програм җәһәтеннән ислах ителеп беткән бер мәктәп түгел. Бу мәктәпнең мактала торган җире ялгыз билге вә әхбаб[684] бер җәһәтедер. Ләкин ысул тәгълимнән хәбәрдар моктәдир[685] мөдирә вә мөгаллимәләр булмаган вакытта ул бина вә ул әсбапларның үзләре генә бер нәрсә дә бирмиләр. Бу мәктәптәге мөгаллимәләрнең саны, мәзкүр мәктүбтә язылганча, 809 кешедән гыйбарәт булмый, ялгыз бер абыстай укытадыр. 120–130 кадәр кызның барлыгы бер бүлмәгә җыелып утыралар. Абыстай аларга аерым-аерым диярлек дәрес бирә. Ярдәмгә соңгы сыйныф кызларын яки үзендә укып чыгып, буш вакыты булган туташ вә ханымнарны чакыра.

---

[681] 1914 елның 14 июлендә чыккан «Правила о частных учебных заведениях, классах и курсах Министерства народного просвещения, не пользующихся правами правительственных учебных заведений» турында сүз бара.

[682] Мөһиммә әл-мөслимин – мөселманнар өчен кирәкле.

[683] Троицкидан // Вакыт. 1914. 31 декабрь.

[684] Әхбаб – сөелгән.

[685] Моктәдир – сәләтле, көчле.

Мәктәп эчендә соңгы ысулда тәртип вә тәрбия күргән бер мөгаллимә юк. Исемен үзгәртү, яңа ысул вә тәртип белән фәлән кадәр мөгаллимә укыта дип игълан кылулар элегрәк тәэсирсез калмасалар да, хәзер андый гына «яңалыклар» белән яшь буын халкын җыеп тору заманы күчеп барадыр.

Үткән гыйнварда Троицк мәдрәсәләренә мәхәллә мәгариф мәэмүрләреннән[686] бер кәгазь килде. Бу кәгазьдә Троицкида булган мәктәп-мәдрәсәләрнең рус теле укытырга тиешле булганлыклары бәян ителеп, дәвамнары өчен губернатордан рәсми рөхсәт алсыннан диелгән иде. Бу кәгазьне алгач, бәгъзе мәдрәсә идарәләренең шуңа муафыйк бәгъзе тәдбирләрдә[687] булганлыклары аңлашылды.

*«Вакыт», 1915, 1 март.*

## Җәйге дәресләр

5нче майдан игътибарән дүрт сыйныф рөшдидән[688] гыйбарәт кызлар өчен җәйге дәресләр башланачак. Һәр фән өчен укытып тәҗрибә күргән затлар алыначак. Дәресләр егерменче рамазанга кадәр дәвам итәчәк. Укырга хисле ханым һәм туташлар рәхим итсеннәр. Артык мәгълүмат алыр өчен адрес: Уфа, Никольская, 47, Г. Такаевой.

Садретдин Назыйров мәктәбендә мөгаллимә Газыймә Тәкаева.

*«Тормыш», 1915, 29 март.*

***Әхмәд Зыятдин***

## [Минзәлә өязе...]

Минзәлә өязе Нөркәй авылында[689] 12нче мартта кызлар мәктәбендә имтихан мәҗлесе булды. Муллабыз бу эшкә аркылы торса да, мөәзин бик тырышып, бу мәктәпне дәвам иттерә. Алдагы көзгә мөәзин хәзрәт кызлар өчен буе 12, иңе 8 аршынлы махсус мәктәп бинасы салдырырга карар бирде.

*«Тормыш», 1915, 9 апрель.*

***Гөлсем Сәбатетдинова***

## [Уфа өязе Олуг Күл авылы...]

Уфа өязе Олуг Күл авылының кызлар мәктәбендә 29нче мартта имтихан булды. Җыелган халык мәктәпне вакыф итүче Акчурина ханымга күп рәхмәтләр укыдылар. Имтихан мәҗлесендә Сәет әфәнде Туктаров мәктәп файдасына җыелган иганәне тапшырды. Иганә итүчеләр: Ярулла Мостафин – 7 сум 50 т; Әхмәтгали Сәбатетдинов, Габдрахман Рахманкулов, Мәгъсум

---

[686] Мәэмүр – эшне үтүче кеше, түрә.
[687] Тәдбир – алдан күреп эшләү.
[688] Рөшди – урта.
[689] Зур Нөркәй авылы – хәзер Татарстанның Сарман районына карый.

Рахманкулов (соңгы икесе Кырмыскалыныкы)[690] 5 әр сум; Әхмәтҗан Сәбатетдинов 3 сум; биш кеше 1 әр сум. Барлыгы 30 сум 50 т.

*«Тормыш», 1915, 9 апрель.*

***К.Б.***

**Казачий авылында бер кызлар мәктәбе мөнәсәбәте илә**

Оренбург өязе Ажурный станциясендә мөгаллимә Миңлевафа Уразаева иҗтиһады[691] илә 7 елдан бирле кыз балаларның яхшы гына бер тәртип белән уку-язу үгрәнеп, гомуми мәгълүмат бирә торган бәгъзе дәресләрдә укып килгәнлекләрен язалар. Һәр ел булган кебек, бу елда да 3 апрельдә имтиханнары булган. Шәкерт кызларның үз дәрәҗәләрендә яхшы гына укыганлыклары аңлашылган.

Казачий мөселман авыллары вә билхасса[692] Җаекның түбән ягы Гани бай мәрхүмнең[693] (Аллаһның рәхмәтендә булсын) һиммәте[694] илә һәркемнән элек ысул җәдидә мөгаллимнәре күрергә муафыйк[695] булдылар. Зубачы[696] вә Чеснакай[697] авылларыннан берничә хәлфә вә имамнар Гани бай мәрхүмнең ярдәме илә Каргалыга барып, анда ачылган беренче дарелмөгаллиминдә[698] тәгълим ысулы күреп кайттылар. Берничә еллар Гани бай бу мөгаллимнәргә жалуния биреп, дәрес китаплары өләшеп торды вә өстләреннән кешеләр (Каргалының Садыйк түрәне) йибәреп нәзарәт иттерде[699]. Ләкин, бердән, жалуния киселеп, икенчедән, халык арасында туган мәгънәсез кара тәгассыб[700] галәбә итеп[701], бу беренче ысул җәдидә мөгаллимнәре урыннарыннан чыктылар яки, калсалар да, яңа тәртип белән вә яңа китапларыны ташлап, искечә, тәртипсез укытырга мәҗбүр булдылар. Мәктәпнең иң мәсьүлиәтле[702] бер кыйсеме[703] ни диния, вә ни ахирәт, ни низам, вә ни дә мәдәнияттән хәбәре булмаган бер кыйсем – аңсыз хәлфә кулында һәм әһәмиятсез кешеләр идарәсендә калды. Бер мәртәбә ысул җәдидә белән тәгълим башланып та, аның соңында яңадан иске хәленә кайткан бу барыш (реакция) шушы көнгә кадәр хөкем сөрде. Шуның аркасында образование вә

---

[690] Кырмыскалы – хәзер Башкортстандагы район үзәге.
[691] Иҗтиһад – тырышлык.
[692] Билхасса – махсус, төбәп.
[693] Гани бай – Гани Хөсәенов.
[694] Һиммәт – тырышлык.
[695] Муафыйк – туры килгән, хуплау.
[696] Зубачы – Оренбург өлкәсендәге авыл.
[697] Чеснакай – Оренбург өлкәсендәге авыл.
[698] Дарелмөгаллимин – ир укытучылар әзерли торган махсус уку йорты.
[699] Нәзарәт итү – карау, тикшереп тору.
[700] Тәгассыб – фанатизм.
[701] Галәбә итү – шау-шу итү.
[702] Мәсьүлият – җаваплылык.
[703] Кыйсем – өлеш.

аңнары белән башкаларга караганда нисбәт кабил[704] булмаслык дәрәҗәдә алда булуны дәгъвә иткән Казачий мөселманнары, уку вә укыту, гыйлем, мәгариф вә мәдәният җәһәтендә[705] иң артта калган бер халык булып чыктылар. Ни яхшылап русча укымадылар, вә ни үз мәктәпләрендә тиешле бер тәрбия күрә алмадылар. Бу хәл Казачий мөселманнары арасында бик күңелсез бер манзара[706] тәшкил итеп торган вакытта, соңгы елларда яңадан аң вә фикер ияләре заһир була[707] башладылар (Ходай насыйп итсен дә, бу инде төпле бер юлга керүнең башы булсын!). Югары як Казачий мөселманнары арасында ысул җәдидә өр-яңадан рәваҗга керде[708]. Тәртипле мәктәп белән ысул белгән мөгаллим тәмам йирләшеп[709], җәмгыять хәйрия, ак бурыч ширкәте, җәмәгать кибете, ссуда-сберегательный касса кеби күмәк (кооперативный) эшләр күрелә башлады. Түбән як авылларында, билхасса Чеснакай вә Аҗурныйда, әйтерлек тәртипле монтазам мәктәпләр булмаса да, ысул җәдидә китаплары кабул ителә башлап, мөгаллим алуга бик нык бер иҗтыяҗ хис итүләр күренде. Шулай итеп, бик якын бер арада тәртипле мәктәпләрнең вөҗүдкә килүләрен[710] өмет иттерә торган галәмалар тугды.

Югарыда язылган кызлар мәктәбе башка йирләргә нисбәтән бик җөзьи[711] вә бик кечкенә бер эш булса да, менә шул өметнең туууына сәбәп булган гамәлләрнең берничәләреннән вә шул игътибар илә шаян зикер[712] вә лаек тәшәккер[713] бер хәлләрдәндер.

Кирәк соңгы еллардагы яңа тәҗрибәләр, вә кирәк искедә булган мәктәп вә мәдрәсәләремезнең дәвам вә бәкаләре[714], безнең эшләремезнең күбрәк хосусый тәшәббес[715] (нинди булса бер һиммәт иясенең чыгып башлап җибәрүе) белән башланганлыгы вә шул кешенең иҗтиһад вә сәбате[716] белән дәвам иткәнлеге аңлашылды. Зур мәдрәсәләремездән һәркаюсы дип әйтерлек нинди дә булса бер нөфүз[717] иясе хәзрәт яки байның һиммәте илә мәйданга килеп, аларның мәйданнан җигелүләре илә юк булдылар. Шуңа каршы бик күп җәмгыять тарафыннан башланган ширкәтләрнең тәэсис ителеп[718], эшкә тотынгач, арада бер сәбәпле көч булмау аркасында ябылганлыклары күз

[704] Кабил – булдыклы, сәләтле.
[705] Җәһәт – өлкә, юнәлеш.
[706] Манзара – күренеш.
[707] Заһир булу – күренү.
[708] Рәваҗга керү – таралу.
[709] Йирләшү – урнашу.
[710] Вөҗүдкә килү – барлыкка килү.
[711] Җөзьи – өлешле, вак.
[712] Шаян зикер – тиешле дәрәҗәдә искә алу.
[713] Тәшәккер – рәхмәт әйтү.
[714] Бәка – яшәү; үзгәрми саклану.
[715] Тәшәббес – эшкә тотыну.
[716] Сәбат – ныклык, даимилек.
[717] Нөфүз – абруй.
[718] Тәэсис – төзелү, оешу.

алдымызда. Югарыда исеме язылган ханым укыткан авылда да берничә мәртәбә кызлар мәктәбе ачу мәсьәләсе кузгатылды, бервакыт кызлар мәктәбе өчен бина да салынды. Ләкин башында торган эш күрерлек бер мөгаллимә я абыстай булмаганлыктан, тәмамияткә[719] ирешми калды. Җәмәгать катышып та, бер эш чыкмаган авылга моннан 7 ел элек бер иттифакый[720] ханым тугры килде, вә шунда йирләшеп, балалар укыта башлады. Хәзердә «кызлар мәктәбе», «имтихан», «ысул җәдидә» дип әйтерлек 40–50 кадәр балалы бер хосусый мәктәп мәйданга килде.

Билгеле ки, бик иттифакый тугры килгән вә тәгълим тәрбиядә чын мәгънәсе илә мөкаддәр[721] дип әйтүе авыр булган бер ханым тарафыннан ачылган бу мәктәп матлуб булган[722] нәтиҗәне биреп бетерә алмас. Аны таләп кылырга да ярамый. Ләкин шул бер тәшәббеснең бу авылда, һич шөбһәсез, ысул җәдидәгә бер юл салып җибәрәчәген инкарь итеп булмый. Кыз балалар түгел, ир балаларга тәртип кирәклеге тиешенчә аңланмаган бер җирдә, кыз балалаларга тәртип бирү, язу үгрәтүнең никадәр «хәрам» булачагы бәянга мохтаҗ булмаса кирәк. Менә шул халык эчендә бу ханым беренче мәртәбә кызлар өчен тәртип кирәк, уку-язуга үгрәнү фарыз идекен дәгъва кылды һәм билфигыль[723] шуны исбат итте вә яхуд итәчәк. Шунлыктан авылларда заһир булган[724] бу каһарман ханым да тәкъдир ителергә, аңлы бер сыйныф тарафыннан ярдәм күрергә мөстәхикътырлар[725]. Тәҗрибә безгә милли хәятымызның моннан соң да шундый халык арасыннан чыккан һиммәтле затлар аркасында гына юлга салынып китергә мөмкин булганлыгын күрсәтте. Вакыты килер дә, бу затлар икенче бер олуграк, мөстәхикърак кешеләр белән алмашынырлар вә шулар арасында бездә дә башка мәдәният, милләтләрдәге кебек, җәмәгать эше, әфкяр[726] гомумия куәте туар. Кыйсмәтемез[727] шулай икән, халык моны аңларга вә шуңа муафыйк[728] һәр җирдә бер төрле чарасы күрелергә тиеш.

*«Вакыт», 1915, 12 апрель.*

### Каргалыда кыз балалар имтиханы

Каргалыда Назыйрә ханым Гайнуллина идарәсендә булган Мөхәррәмовларның кызлар мәктәбендә 18, 19 һәм 20 апрель көннәрендә имтиханнар булып, 21, 22 вә 23 апрельдә ирләргә шул мәктәптә укыган кызларның кул

---

[719] Тәмамият – тәмамлану.
[720] Иттифакый – очраклы.
[721] Мөкаддәр – билгеләнгән.
[722] Матлуб – көтелгән, таләп ителгән.
[723] Билфигыль – чынлыкта, чынлап.
[724] Заһир буган – күренгән.
[725] Мөстәхикъ – хаклы, лаеклы.
[726] Әфкяр – фикерләр.
[727] Кыйсмәт – өлеш.
[728] Муафыйк – туры килгән, хуплау.

һөнәрләре күрсәтеләчәген белдерәләр. Выставка көннәрендә һәркемгә кереп, кыз балаларның кул эшләрен күрергә рөхсәттер.

*«Вакыт», 1915, 16 апрель.*

***Мирхәбиб Сәлахетдинов***

**Казалы**

Үткән ел Садретдин әфәнде Сәйфелмөлеков тарафыннан кызлар мәктәбе салынган иде. Быел шул мәктәптә шәһәрнең кыз балалары бик яхшы укып, 26 апрельдә имтихан бирделәр.

Кул һөнәрләре дә үгрәтелгән иде. 1 вә 2 майда кул һөнәрләрен карар өчен ирләргә дә керергә вакыт тәгаен ителде. Кул һөнәрләрен күрер өчен халык күп килде. Руслар вә рус мөгаллимәләре кереп карап бик тәхсин иттеләр. Мәктәп салдырып, балаларны укытуга сәбәп булган Садретдин әфәнде илә мөгаллимә ханымга никадәр тәшәккер кыйлынса да, аздыр.

*«Вакыт», 1915, 8 май.*

***Ф.-Б.Сөләймания***

**Имтихан**

Апрельнең 19ннан башлап май 3енә кадәр Фатыйха ханым Аитова кызлар мәктәбендә имтиханнар булды. Мөгаллимәләрнең икътидарына[729] күрә, кызларның яхшы гына тәхсил кылганнары[730] күрелде. Монда иң әүвәл күзгә чалына торган нәрсә – Фатыйха ханымның иҗтиһады[731], армый-талмый, көн-төн тырышып, милләт кызларын адәм ясау, алга йибәрү өчен бөтен рәхәтне фида итүедер[732].

Фатыйха ханым – татар милләтендә мисле[733] аз табыла торган надирелвөҗүд[734] улан ханымнарымыздандыр. Фатыйха ханым нинди генә милли эш булмасын, алдан йөгерә, һәркемнән артык хезмәт итә. Малын, җанын алмый, бөтен көчен милләт юлына сарыф итә, бөтен кайгысы – мәктәбене алга җибәрү, милләткә мөгаллимәләр хәзерләп бирүдер.

Мөселманнар лазареты тугрысында күрсәткән хезмәтләре, ватан өчен сугышучы гаскәрләремезгә кылган ярдәмнәре генә дә Фатыйха ханымның иҗтиһады ни дәрәҗәдә күрсәтмәктәдер. Фатыйха ханымның гафу итүенә ышанып, шуны гына әйтәсем килә ки, ошбу тәгътыйль[735] вакытында тәхет идарәсендә улан мөгаллимә ханымнарны мөгаллимәләр курсына йибәреп, мәгълүматларыны арттырса, яки киләчәк көзгә Уфа мәктәпләре кеби мәктәптә тәрбияләнгән киңрәк мәгълүматлы бер-ике мөгаллимә китереп,

[729] Икътидар – булдыра алу, көч җитү.
[730] Тәхсил кылу – гыйлем алу.
[731] Иҗтиһад – тырышлык кую, тырышу.
[732] Фида итү – корбан итү.
[733] Мисле – ошаган, төсле, кебек, шикелле.
[734] Надирелвөҗүд – сирәк табыла торган нәрсә, бердәнбер.
[735] Тәгътыйль – каникул.

матди җәһәттән[736] тәмамән мөкәммәл[737] булган мәктәпне мәгънәви җәһәттән дә мөкәммәлләштерсә, бигрәк гүзәл улыр иде.

*«Сөембикә», 1915, №14–15, б.29.*

### [Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт идарәсендәге...]

Зыяэтдин әл-Камали хәзрәтләре [738] идарәсендәге курсларда укучы мөгаллимәләр үткән җомгада 2нче мәхәлләдәге Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт мәсҗетенә җомга укырга барганнар. Мөгаллимәләр җомганы мәсҗетнең аскы катында, ирләр өске катында укыганнар.

Уфа ханымнарының җомга вә мәсҗет йөзене күрүләре, Аллаһка хакыйкый бәндә, чын мөслимә булганлыкларын мәйданга куюлары, шаять шушы тарихтан башланып китсә кирәк. Исламның хакыйкатен аңламаганнарының сүзенә колак салына торган заман түгел. Һәр мәхәлләдәге ханымнарның да гыйбадәт итүләре, мәсҗеткә барып чын хотбә һәм вәгазь ишетүләре дини бер вазыйфаларыннандыр. Инде чын мәгънәсе белән мөселман булырга вакыт. Ислам дине ханымнарга да тигез бер дин. Аның гыйбадәтләре дә ханымнарга да гыйбадәт.

*«Тормыш», 1915, 7 июль.*

***Хаҗәр Галиәкбәр***

### Гомуми кыйраәтханәдә Орск мөслимәләре

Бу ел июльнең 12 сендә Орск ханымнарының гомуми кыйраәтханәгә[739] йөри башлауларына ел тулды. Кыйраәтханәдә ханымнарга махсус көн тәгаен ителүен сорап, 40 тан артык ханым вә туташлар мөрәҗәгать иткәннәр иде. Кыйраәтханә ачылган айларда көненә 20–30, вә хәтта 40лап кеше кереп файдалансалар да, соңыннан азайганлык хис ителә башлады. Билхасса[740], соңгы җәйге айларда бик аз керделәр. Шулай да бу беренче елда кереп укучы ханымнарның саннары канәгать ителмәслек түгелдер. Шул үткән бер ел эчендә кыйраәтханәгә кереп файдаланучыларның саннары 1408гә тулды. Гәзитә вә журналлар өстенә 59 җилд[741] китап укырга бирелгән. Һәр җилддә берничә китап бар. Шуларны аерып исәпләгәндә, 4579 китап бирелгән буладыр. Беренче ел өчен, билгеле, бу канәгать итмәслек түгелдер. Фәкать шуның белән бергә, кыйраәтханәдән истифадә кылучыларның [742] артырга

---

[736] Җәһәт – як, тараф.

[737] Мөкәммәл – камилләшкән, төгәлләнгән.

[738] Зыя Камали (Пәрвазетдин Җамалетдин улы Камалетдинов, 1873–1942), мәгърифәтче, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен оештыручы һәм аның җитәкчесе.

[739] Кыйраәтханә – уку залы, уку өе.

[740] Билхасса – атап, төбәп, махсус рәвештә.

[741] Җилд – данә.

[742] Истифадә кылучы – файдаланучы.

тиеш булган кадәр артмаганлыкларын да әйтми китеп булмый. Сәбәбе: яшь ханымнарымыз күбрәк модага бирелеп барган күренәләр. Башлап мөгаллимәләремез уку юлын күрсәтергә тиеш иделәр, хәлбуки[743] бонлар арасында да матур күлмәкләр киеп урамнарда йөрүне гадәт итеп алучылар күбрәк күренә. Шулай булгач, алардан укыган шәкерт туташларның кыйраәтханәгә терәлеп торган йирләрдән дә көненә бер мәртәбә кыйраәтханәгә керми тәрәзәдән үткән-барганны карап бушка вакыт уздыручылар булуын гаеп итеп булмыйдыр ки: зиядә[744] силә[745] шаян[746] тәәссефтер[747].

Орск кыйраәтханәсендә ханымнарга махсус көннәрдә назыйрә: Хаҗәр Галиәкбәр.

*«Вакыт», 1915, 21 июль.*

***Газыймә Тәкаева***[748]

## Җәйге курсларымыздагы кызлар имтиханы

Мөхтәрәм Садретдин әфәнде Назыйров җәнабләре 1905 елда кызлар өчен ике мәктәп тәэсис итеп[749], беренә Камилә ханым Касыймияне вә беренә мине кабул кылынды. Шул елдан игътибарән тәгълим дә булынып, 9 елдан бирле халыкның теләвенә бинәэн[750] җәйге дәресләр ясый килдем. Бу елгы имтиханда Уфаның имам вә мөдәррисләре илә Казан вә Мәскәүдән килгән мөгаллим вә мөгаллимәләр хазир булдылар[751]. Салихҗан казый Урманов[752] хәзрәтләре дә тәнәззел[753] тәшриф боерганнар[754] иде. Имтиханда, гадәткә хилаф[755] уларак, «Мәдрәсәи Галия» мөдәррисләреннән (хәзер дә Зыя әл-Камал идарәсендәге курста мөгаллим) Тәкый әфәнде Бәдигыйга[756] остаз кәнеж[757] имтихан кылуга ихтыяр бирелде.

---

743 Хәлбуки – ләкин.

744 Зиядә – артык, күп.

745 Силә – ташкын.

746 Шаян – тиешле дәрәҗәдә.

747 Тәәссеф – үкенеч, кайгыру.

748 Газыймә Тәкаева – Уфадагы «Назыйрия» мәктәбе мөгаллимәсе, җәйге педагогик курслар оештыручы.

749 Тәэсис итү – төзү, оештыру.

750 Бинаэн – нигезләнеп, таянып.

751 Хазир булу – катнашу.

752 Салихҗан Урманов – Оренбург мөселман диния нәзарәте казые, «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия» журналының мөхәррирләре коллегиясе әгъзасы, «Милләт мәҗлесе» депутаты (1917–1918).

753 Тәнәззел – түбәнчелек итеп.

754 Тәшриф боеру – олылау, хөрмәтләү.

755 Хилаф – каршы, кире, тискәре.

756 Тәкый Бәдигый (1884–1955) – педагог, «Галия» мәдрәсәсендә гарәп теле укытучысы, дәреслекләр авторы.

757 Кәнеж – яшь кеше.

Имтихан әүвәл Коръәннән нәхүгә[758] татбикъ[759] илә башланып, икънагый[760] җаваплар бирелгәнлектән, Тәкый әфәнде кызларның фәһемнәренә[761] өметен зурайтып, зур-зур сөальләр бирә башлады. Кызлардан һаман җаваплар яхшы чыкканлыктан, шатлыгына изһар килеп[762], югары тавыш белән рәхмәтләр әйтә иде. Соңгырак утырган кызлардан берәр-икешәр аять укытып, нәхүгә татбикъ илә мәгънәсен сөйләтеп, Коръән имтиханы тәмам булды.

Хаҗиәхмәт хәзрәт Вәлиев аякка басып, Бәдигъ әфәндегә хотабәнә[763]: «Кызлар бу кадәр һиммәт[764] вә гайрәт күрсәттеләр, 3нче вә 4нче дәрес әл-әннәхәвиләренең[765] гыйбарәләреннән фәһем вә ифһам күвәләрене[766] белү матлуб[767] иде», – дидекендә, Бәдигъ әфәнде: «Бу кадәр кувәләре барлыкны исбат иттеләр инде, күрәсе калмады», – диде.

Тарих мөгаллиме имтихан сәгатендә тәхәллеф иттекеннән[768], табигый, җавап йомшак чыкты. Чөнки тәгъкыйб иткән[769] китапларыннан читтәге нәрсәләр сорыйлар иде.

Иншаны бәгъзе кызлар бик начар язсалар да, бәгъзеләре яхшы яздыкларыннан, тәгълими генә бер нәрсә итеп карыйсы килгән хасидларны[770] чыгарырлык булды.

Кыйраәт гарәбияне[771] хикәясе белән сөйләп бирүләре икънагый[772] булдыгыннан, хәдисләр тугрысында, хөсне хат[773] белән имтихан кылуга хаҗәтсез табылдылар.

Җәгърафия яхшы чыгып, хисап та имтияз[774] казанырлык булды. Гыйлем әшъя[775] вә башка дәресләрдән имтихан кылуга, шәкерт вә башка кешеләр дә бик арыганнар иде. Шул сәбәптән имтихансыз гына калдырдылар.

Ахырында курста иштиракъ иткән[776] үз шәкертләремездән Тәгъзимә туташ Сафуанованың хезмәте (програмнан хариҗ[777]) күргәзелде. Җәгърафия

---

[758] Нәхү – синтаксис.
[759] Татбикъ итү – яраштыру, килештерү.
[760] Икънагый – канәгатьләнерлек.
[761] Фәһем – аңлау, төшенү.
[762] Изһар килү – күрсәтү.
[763] Хотабәнә – вәгазь сөйләгән кебек, ораторлык.
[764] Һиммәт – тырышу.
[765] Нәхәви – нәхүгә караган.
[766] Ифһам кувәсе – аңлату көче, осталыгы.
[767] Матлуб – көтелгән, таләп ителгән.
[768] Тәхәллеф итү – соңга калу, артта калу.
[769] Тәгъкыйб итү – күзәтү.
[770] Хасид – көнче, көнләшүче.
[771] Кыйраәт гарәбия – гарәпчә уку.
[772] Икънагый – канәгатьләнерлек.
[773] Хөсне хат – матур язу.
[774] Имтияз – укудагы уңышлар өчен бирелә торган мактау кәгазе.
[775] Гыйльме әшъя – физика.
[776] Иштиракъ итү – катнашу.
[777] Хариҗ – тыш.

һәм тарихны хәриталарга[778] карап сөйләүләре, хәдис вә башка дәресләре дә яхшы чыктыгыннан, Зыяэтдин хәзрәт Камали, Салихҗан казый Урманов Тәгъзимә туташка аеруча рәхмәтләр укыдылар.

Аннан соң Хаҗиәхмәт хәзрәт Вәлиев аякка калкып, бөтен җан иясе җәйге ямьле айларда ләззәт белән үз рәхәтеннән йөргән бер заманда, бөтен рәхәтләрене фида кылып[779], иҗтиһад[780] кылган туташларга рәхмәтләр укып, милләтнең сәгадәте[781] кызлар илә ирләрнең һәр икесенең бертигез тырышуларында, мәфһүмендә[782] нотык сөйләде. Зыя хәзрәт Камали да шул мәальдә[783] нотык сөйләдекеннән соңра, Салихҗан казый Урманов элекке заманда кызларда уку гадәте булмадыгыннан кайгыга калдырачак бер вакыйганы бәян кылды, вә үзенең бу хәлен күреп шатланып та, әүвәлге кайгылары беткәнлегене сөйләп, уку вә укытуның милли вә иҗтимагый әһәмиятене бәян итте. Ахырдан Бәдигый әфәнде аякка калкып, соңыннан килгән халыкларга хитабән[784] үзенең имтихан башыннан бирле мөмәйиз[785] булдыгын бәян итеп, укучыларның да, укытучыларның да зур иҗтиһад вә һиммәт күрсәтдекләрене сөйләде.

Менә имтиханымызның хөлясасы[786] шуннан гыйбарәт. «Тормыш»та берсе үзенең шәхси гаразларына[787] катыштырып, бердән-бергә һөҗүм иткән икән, югарыдагы тәфсилияттән соң, аның язганнарының нинди бер максат белән язылганлыгы аңлашылса кирәк. Югарыда язганнарымның дөреслегенә имтиханда булучылардан мөхтәрәм Зыяэтдин әл-Камали хәзрәтләре илә Хаҗиәхмәд хәзрәт Вәлиев һәм Тәкый әфәнделәрне шаһид күрсәтәм. Язганнарым хилаф вакыйгъ[788] улса, гәзитә аркылы бәян итсеннәр сөкүтләре[789] тасдыйкдыр.

«Тормыш»да «ысул тәгълимнән бер нәрсә дә үгрәтелмәгән» гыйбарәсе бар иде. Тәгълим вә тәрбиядән аларның максатлары нәрсәдер, безгә мәгълүм булмады. Гади тәгълим вә тәрбия тарикълары[790] булса, ул бездә гамәли сурәттә күрсәтелде. Китап ачып бер сөальгә бер җавап бирү тарикы илә имтихан кылынмаган икән, анысы да тәгълим вә тәрбия үгрәтүне мәктәп идарәсе аеруча имтихан кылып күрсәтергә хаҗәт күрмәгәнлектәндер. Юк-бар нәрсәләр табып, курсымызда укыганнарның тәгълим вә тәрбия юлында алган

---

[778] Хәрита – карта.

[779] Фида кылу – үз-үзен аямыйча чын күңелдән эшләү; берәр максатка ирешү өчен үзен корбан итү.

[780] Иҗтиһад – тырышу.

[781] Сәгадәт – бәхет, рәхәтлек.

[782] Мәфһүм – төшенелгән нәрсә, эчтәлек, мәгънә.

[783] Мәаль – шул мәгънәдә, күздә тотылган максат.

[784] Хитабән – эндәшеп, сүзне юнәлтеп.

[785] Мөмәйиз – яхшыны яманнан аера белүче.

[786] Хөласа – нәтиҗә.

[787] Гараз – начар теләктә булу.

[788] Вакыйгъ – чынлык.

[789] Сөкүт – дәшми тору.

[790] Тарикъ – юл, ысул, метод.

кыйммәтләрене киметергә тырышучылар ни дисәләр-дисеннәр, әмма без үз белдегемезчә хезмәтемездә дәвам итәчәкмез.

«Мәдрәсәи Назыйрия»дә мөгаллимә Газыймә Тәкаева (Уфа)

*«Вакыт», 1915, 24 июль.*

***Зәйнәб Камалетдинова***[791]

**Зәйнәб Камалетдинова мәктәбе тарафыннан идарәгә мәктүб**

Үткән ел вә аннан алдагы елларда берникадәр әфәнделәр кызларны мәктәбемдә кунып укырга кабул итүемне үтенгәннәр иде. Ләкин үткән елдагы квартирларымыз никадәр зур булса да ләйле[792] шәкертләр кабул итәргә мөсагыйд[793] түгел иде. Шунлыктан гаять күңелсез булса да, мәзкүр[794] әфәнделәрнең үтенечләрен кабул итә алмаган идем. Шул вакыт берникадәр әфәнделәр китергән кызларын да алып киткәннәр вә бәгъзеләре дә шәһәрдәге белешләрендә калдырып, укуларын дәвам иттергәннәр иде.

Бу сәнә дәхый бәгъзе әфәнделәр тарафыннан ләйле шәкерт кабул итүемезне сорап хатлар килгәләде. Ул вакыт катгый күзәткән бер квартирымыз булмадыгыннан, һичбер төрле җавап бирә алмаган идек. Бу көн исә мәктәп өчен зур квартир хәзерләдек. Ләйле шәкертләр өчен дә аерым бүлмәләр булачак. Бу сәнә өчен читтән мөгаллимәләр дә дәгъвәт иткән идек. Ул мөгаллимәләр дә, үземез дә, ләйле шәкертләр илә бергә булыначакларыннан, ләйле шәкертләрнең тәрбиясе тагы бер кат тәкмил ителәчәктер[795]. Шәкертләр теләгән микъдарга җитсә, тәрбияләре өчен аерым бер хатын алыначактыр. Мәктәбебезгә ләйле уларак шәкерт бирергә теләгән әфәнделәрнең бу көннән игътибар иттерүләрен үтенәмез.

Бу сәнә киң програм хәзерләнде. Русча өч отделение үтелеп, моның өчен дәрес башыннан ахырына кадәр мәктәптә булынмак шарты белән мөстәкыйль бер учительница хәзерләнде.

Хәбәрләшү өчен адресы: Оренбург, Заурачн. роща, дача Марии Серовой. З.Камалетдиновой.

*«Вакыт», 1915, 16 июль.*

**[Хәзерге көндә Казан...]**

Хәзерге көндә Казан «Кыйраәтханәи гомумия»сенә[796], ачылган көннәрдә ирләрдән һәр көнне 25–30 кеше кереп файдалана. Бер вакытлар кыйраәтханәдән ханымнарга да файдалану мөмкин булсын дип тартышып, кыйраәтха-

---

[791] Зәйнәб Камалетдинова (Зәйнәб Камалия) – Оренбургта кызлар мәктәбе мөдирәсе.

[792] Ләйле – кунарга калучы.

[793] Мөсагыйд – мөмкинлек бирә торган.

[794] Мәзкүр – алда әйтелгән.

[795] Тәкмил ителү – тулыландырылу.

[796] Кыйраәтханәи гомумия – җәмәгать китапханәсе.

нәне һәфтәгә[797] бер мәртәбә үзләренә махсус ачтыруга муафыйк булган[798] Казан ханымнары хәзерге көндә бөтенләй онытып йибәрделәр. Ханымнарга махсус ачылган көндә кыйраәтханәгә бары 5–6 гына ханым укырга керә икән.

*«Тормыш», 1915, 9 август.*

**Багбостан ханымның мәктәп програмы**

Мөгаллимә Багбостан ханым үзе тарафыннан тәэсис ителгән[799] кызлар мәктәбенең мөфрәдат[800] програмын аерым рисалә[801] шәкелендә[802] бастырып чыгарган. Рисаләнең башында «Гая[803] вә имлямыз» сәрләүхәсе[804] илә бер бәнд[805] язып, мәктәптән күзәтелгән максат хакында мәгълүмат биргән, мәктәпкә кабул итү шартлары вә мәктәптә ригаясе[806] тиеш булган кагыйдәләр белән әйтелгән. Соңра мәктәптә укылган дәресләрнең мөфрәдат програмы мөфассал[807] сурәттә күрсәтелгән вә һәфтәлек дәресләре күрсәтелгән бер җәдвәл[808] куелган.

Русча телнең учебный планы рисаләдә русча уларак бәян ителгән. Бу програмның тәкъдир[809] вә интикады[810] үзенең әһеле[811] булган педагогларымызга гаидтер[812]. Без үз тарафымыздан бары шуны гына әйтеп үтәргә тиеш табамыз ки: Багбостан ханым мондый бер програм бастырып бик яхшы иткән. Кяшки[813] һәммә мәктәп вә мәдрәсәләремезнең шундый басылган мөфассал програм вә кагыйдәләре булсачы, мәктәпләрнең ислахы юлында мондый програмнарның файдасы күп тиячәк, шөбһәсез. «Мәдрәсәи Хөсәения»мез тәртипле вә тәэминле[814] бер мәктәп булып, егерме елдан артык дәвам итдеге хәлдә, шулай кулга тотарлык итеп үзенең програмын һәнүз[815]

---

[797] Һәфтә – атна.
[798] Муафыйк булу – туры килү.
[799] Тәэсис итү – төзү, оештыру.
[800] Мөфрәдат – ялгыз булган әйберләр.
[801] Рисалә – брошюра, китапчык.
[802] Шәкел – форма.
[803] Гая – төп теләк.
[804] Сәрләүхә – исем.
[805] Бәнд – кушымта.
[806] Ригая – игътибар итү.
[807] Мөфассал – җентекле, тулы.
[808] Җәдвәл – таблица.
[809] Тәкъдир – бәя бирү; ихтимал, очрак.
[810] Интикад – тәнкыйть.
[811] Әһел – бер эшкә карата яраклылык, аны башкара алу.
[812] Гаид – *-га* караган, *-га* бәйләнеше булган.
[813] Кяшки – Эх, әгәр дә!
[814] Тәэмин – булдыру, җитештерү.
[815] Һәнүз – әле дә, һаман.

бастырып чыгара алмаган иде. Бу бабда[816] шәһәремездә беренче мисалның кызлар мәктәбеннән күрелүе аеруча шаян[817] мәмнүнияттер[818].

*«Вакыт», 1915, 22 август.*

***Гайшә Абызгилдиния***

**Кызлар мәктәбе**

Уфадагы беренче мәхәллә кызлар мәктәбе бу сәнәдә ханымнар җәмгыяте тарафыннан хифзыссыйхәт[819] вә ысуле тәгълимгә муафыйк[820] итеп төзелде.

Хөрмәтле ханымнар җәмгыятенең бу һиммәтенә[821] тәшәккердән[822] гаҗизәмез. Мәктәпнең бинасы яхшы ислах ителдеге кеби, эчтәге эшләре дә ислах ителәчәктер.

Елдагы программасы өстенә, бу ел рус теле дәресләре һәм дә кул һөнәрләре дә гыйлавә ителәчәк[823]. Мәктәп бу елда елдагы рәвешчә ибтидаи[824] вә рөшди[825] кыйсемнәргә[826] бүленеп, монтазам[827] хәлдә дәвам итәчәк. Бинаән галәйһи[828] кыз шәкертләргә игълям итәмез[829] ки, мәктәпкә кабул имтиханнар сентябрь башында башланачак (Уфадагы кызларның шул көндә килеп йитүләре матлубтыр[830]) вә сентябрь унына кадәр дәвам итәчәк. Мәктәп бинасын төзәтү эше тәмам булып бетмәдегеннән, имтиханнар хосусый фатирымызда башланачак (Фатирымыз Случевский переулок, 11 номерлы йортта). Кабул имтиханнары һәр көн иртә белән 9 сәгатьтән 12 гә кадәр дәвам итәчәк.

Өяздән килгән кыз балалар өчен мәктәпкә якын, әминиятле[831] фатирлар бар. Рәисәмезнең бәянына күрә, бәлки гүзәл бер урыннан фатир алынып, пансион да хәзерләнер.

Мәга әлихтирам[832], мөдир вә баш мөгаллимә Гайшә бинте ахунд Лотфулла Абызгилдиния.

*«Тормыш», 1915, 23 август.*

---

[816] Баб – мәсьәлә.
[817] Шаян – лаеклы.
[818] Мәмнүният – риза, канәгать булу.
[819] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау юллары, гигиена.
[820] Муафикъ – яраклы.
[821] Һиммәт – тырышлык.
[822] Тәшәккер – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.
[823] Гыйлавә итү – өстәү, кушу.
[824] Ибтидаи – башлангыч мәктәп.
[825] Рөшди – урта мәктәп.
[826] Кыйсем – өлеш, бүлек.
[827] Монтазам – тәртипкә салынган, тәртипле, рәтле.
[828] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шул нигездә, шул сәбәпле.
[829] Игълям – белдерү, аңлату.
[830] Матлуб – таләп ителгән, соралган.
[831] Әминият – ышанычлы.
[832] Мәга әлихтирам – ихтирам белән.

## Багбостан ханым мәктәбе

Шәһәремезнең могътәбәр[833] мөгаллимәләреннән Багбостан ханым бу ел кызлар мәктәбе өчен тагын да зуррак бер квартир алган. Беренче сентябрьдән игътибарән өч уку елына айга 150 сум чек белән нотариуста могаһәдә[834] ясалган. Багбостан ханымның бу мәктәп бинасы шәһәрнең уртасында вә һәр тарафтан йөреп укучыларга да якын, хифзыссыйхәткә муафыйк[835] зур заллы вә берничә сыйныф бүлмәледер. Шундук читтән килеп укучыларга пансион бүлмәләре дә булачак. Җомга көн 28нче августта бу квартир тәмам илә Багбостан ханым кулына күчеп, шул көн мәктәптә укучы балалар вә аларның мөрәббияләре[836] хозурында дога мәҗлесе булачагы хәбәр ителәдер.

Багбостан ханым мәктәбенең мөфассал[837] программа вә кабул шартлары басылып чыкканлыгы газетамызда язылган иде. Фәүкылгадә[838] әхвәл сәбәпле, бу ел читтән килүчеләргә программада күрсәтелгән пансион хакы бераз киметелергә тиешле табылган. Программада бәян ителдегенә күрә, бу ел бу мәктәптә русча өч шөгъбә дә[839] мөстәкыйль бер класс булып дәвам итәчәк. Адресы: Балтенковский переулок[840], дом Спицына.

*«Вакыт», 1915, 26 август.*

## Кызлар мәктәбе

Ханымнар җәмгыяте идарәсендәге «Сары мәктәп»тә 28нче августта җомга көн укучы кызлар кабул итү башланачак, бинаән галәйһи кыз шәкертләргә игълям итәбез[841]: мәзкүр[842] көннән калмыйча, иртән сәгать 9 дан 12 гә кадәр язылырга рәхим итсеннәр. Бу ел мәктәпнең эчке идарәләре ислах ителәчәк, кул һөнәре өйрәтеләчәк һәм русча да мәгълүмат биреләчәк.

Мәктәп идарәсе

*«Тормыш», 1915, 27 август.*

---

833 Могътәбәр – хөрмәтле.
834 Могаһәдә – договор.
835 Муафыйк – яраклы, туры килгән.
836 Мөрәбби – тәрбияче.
837 Мөфассал – җентекле, тулы.
838 Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
839 Шөгъбә – бүлем, бүлек.
840 Хәзер Трофимовский тыкрыгы (Оренбург).
841 Игълям итү – белдерү, хәбәр итү.
842 Мәзкүр – югарыда әйтелгән.

*Габделхәмит Әл-Мөслими*[843]

## Оренбургта хатыннар

Бу соңгы тәрәккыять[844] вә интибаһ[845] дәверемездә хәйли[846] мөһим бер урын тоткан Оренбург мөселманнарының хатын-кызлары тугрысында кыскалык берлә булса да «Сөембикә» журналында бераз яза төшсәк, шаять зарар булмас.

Бу мәкаләдә Оренбург ханымнарының тәрбия вә иҗтимагый җәһәттән китешләре хакында озын мөляхәзә[847] вә интикадларга[848] кереп китәргә бу урын мөсәгыйд[849] түгелдер.

Соңгы заманның тәэсире ба[850], хосусый 5–6нчы елларның дулкыны Оренбург мөселман хатын-кызларына да тәэсирсез калмады. Хәзерендә башка шәһәр, башка йирләрдәге мөселман ханымнарымызда, аз булса да, хәерле өметләр, матлуб[851] гамәлләр күрендеге шикелле, Оренбург мөселман ханымнары да бу тугрыда башка йирләрдәге ханымнардан артык булмасалар, әлбәттә, ким дә түгелләрдер. Оренбург ханым вә туташларында файдасыз күренешләр, күстереш яки ни дә булса бер исем яхуд шөһрәт өчен генә эшләүләр, кыйланышлар, җәгъли[852] күренешләр берсе дә юктыр. Алар күп эшләрен тавышланмыйчарак, сиздермәстән генә эшләргә яраталар. Оренбург ханымнары «Ура алмаган зур күсәк күтәрә» мәкале кабиленнән[853], булдыра алмастай эшләргә тотынып, ярты юлда калуга күрә, кечкенә булса да нәтиҗәсе күренердәй эшләрне эшләүне яраталар. Оренбург шәһәре мәүкыйг[854]җәгърафиясе уңай булу сәбәпле булса кирәк, башкорт, казакъ, сарт[855] шикелле гарәп мәдәниятенә күп өйрәнмәгән бер халыкның күп килә вә аралаша торган бер урыныдыр; тагын да дөресрәк итеп әйткәндә, шундый халыкларның ноктаи тәлякыйсыдыр[856]. Оренбургта яши торган халыкларга алар берлә, әлбәттә, күп вакытта эш күрергә тугры киләдер. Тоймасның тәэсире булмый калмас дигән кабилдән, югарыда мәзкүр[857] халыкның тәэси-

[843] Габделхәмит Гатаулла улы Мөслими – Оренбург мөгаллиме, укыту-тәрбия мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр авторы.

[844] Тәрәккыять – алга китү, прогресс.

[845] Интибаһ – уяну, күз ачу.

[846] Хәйли – байтак, яхшы ук күп.

[847] Мөляхәзә – фикер йөртү.

[848] Интикад – тәнкыйть.

[849] Мөсагыйд – мөмкинлек бирүче, ирек бирүче, рөхсәт итүче.

[850] Ба – белән.

[851] Матлуб – көтелгән, таләп ителгән.

[852] Җәгъли – ясалма.

[853] Кабил – төр, төркем.

[854] Мәүкыйг – урын, яшәү урыны.

[855] Сарт – Урта Азиядә яшәгән күчмә халыкларның гомуми исеме, үзбәкләр.

[856] Тәлякый – очрашу, юлыгышу.

[857] Мәзкүр – әйтеп үтелгән, югарыда әйтелгән.

ре, кирәк тел вә шивә[858] җәһәтеннән булсын, вә кирәк башка җәһәттән булсын, Оренбургка вә андагы мөселман ханым вә туташларына да, әлбәттә, юк түгелдер.

Фәкать шунысы бигрәк гаҗәптер ки, югарыда мәзкүр халыклардан бигрәк нык тәэсир иткәне сартлардыр. Оренбург ханым вә туташларында (бигрәк тә моннан 15–20 еллар элек) сарт рәсеме, сарт гадәте, сарт киеме, сарт чапаны бик нык йирләшкән булган. Шул сәбәпле бу көндә дә әле, Оренбургның Николаевский вә Гостинно-дворский урамнарында йөргән чакта яурупача киенгән халыклар, иң соңгы мода вә фасонда киенгән мадамнар арасында чапанына капланып, дүмбәскәдәй, җанлы кибән кабиленнән йөрүче ханымнарны еш-еш очратырга тугры киләдер. Ләкин бу соңгы вакытларда мондый хәлләр, шундый сарт гадәтләре көннән-көнгә диярлек бетеп-кимеп барганы сизеләдер. Уфа вә Казан хатын-кызлары шикелле, барчасы да һәр рәвештә биля хиҗаб[859] йөри алмасалар да, ләкин хәзерендә инде ачык йөрүчеләре һәм үзләрен тота белүчеләре дә, әлбәттә, байтак булып, көннән-көн күбәеп бармактадыр. Сарт гадәте, сарт рәсеме нык йирләшкән, аның өстенә бу көндә дә «Дин вә мәгыйшәт»[860] әрбабы[861] шикелле, гакес[862] әлхәрәкәтчеләрнең мәркәзе булган Оренбургның мөселман ханым вә туташлары арасында бу соңгы вакытларда русча укучылар, хөкүмәт мәктәпләренә керүчеләре дә күбәя башлады. Нинди сәбәп иләдер, Оренбург туташлары иң күп укый торган гимназия Комарова гимназияседер[863]. Бүтән гимназияләрдә елда 4–5 тән артмадыгы хәлдә, бу Комарова гимназиясендә 15–16 дан алып егермегә якын мөселман гимназисткалары булгалыйдыр. Мөселман ханым вә туташларыннан бу гимназияне икмаль итүчеләр дә[864] булгалый башлады.

14нче елда З.Дәүликамова ханым икмаль кылган иде. Үткән язда Ризаэтдин хәзрәт[865] мәхдүмәсе[866] Зәйнәб туташ берлә Закир ахунд Рәмиев кызы Диләфрүз туташлар һәр икесе муаффәкыять[867] берлә тәмам иттеләр.

Бу ел Оренбургта тагын бер хосусый кызлар гимназиясе ачылды. Бу гимназиядә татар-төрек теле рус вә мөселман кызларына аермаенча, гомуми рәвештә, рәсми дәресе уларак үтеләдер. Бу гимназиягә татар-төрек теле мөгаллимәсе ителеп, шәһәремездә берничә сәнәләрдән бирле гүзәл вә тәртипле кызлар мәктәбе тәрбия иткән Зәйнәб ханым Камалия җәнабләре

---

[858] Шивә – җирле сөйләм, диалект.

[859] Биля хиҗаб – хиҗабсыз.

[860] «Дин вә мәгыйшәт» – 1906–1918 елларда Оренбургта чыгып килгән сәяси, дини һәм әдәби журнал.

[861] Әрбаб – ияләр.

[862] Гакес – капма-каршылык, кире, тискәре.

[863] М.Д.Комарова-Колмакованың хатын-кызлар гимназиясе, 1903 елда ачыла, 1906 елда гимназия статусын ала.

[864] Икмаль итү – тәмамлау.

[865] Ризаэтдин Фәхретдинов (1859–1936) – мәгърифәтче, педагог, галим, язучы.

[866] Мәхдүмә – кызы.

[867] Муаффәкыять – уңыш.

куелды. Зәйнәб ханым мөселман кызлары мәктәбе тугрысында хәйли муаффәкыять вә сәмәрәле[868] хезмәтләр күрсәткән иде. Бу яңа вазыйфасында да гүзәл хезмәтләр күрсәтсә кирәк, муаффәкыять телибез.

Инде мөселман кызлар мәктәбе тугрысында да бераз язып үтик: Оренбургта кызлар укытучылар бик күп булса да, боларның түбәндә закир ителәчәкләреннән[869] башкалары хакларында сүз сөйләп яки интикад итеп[870] торудан түбәннәрдер. Шуның өчен алар хакында күп сүз озайтылмый. Оренбургта яхшы вә гүзәл рәвештә дәвам итеп торган кызлар мәктәпләре ошбулардыр:

1) Багбостан ханым мәктәбе. Бу мәктәп күп сәнәләрдән бирле гүзәл вә муаффәкыятьле[871] рәвештә дәвам итмәктә улып, бу елда 130 (йиде сыйныф)лап шәкерт укымактадыр. Бу Багбостан ханым мәктәбенә, «Мәдрәсәи Хөсәения» мөдире могавине[872] Хәнәфи әфәнде Бакировның[873] рәфикасы[874] (мәшһүр Габдулла Шнаси[875] әфәнде сеңлесе) Сәкинә ханым Бакированы мөгаллимә булып керә икән дип сөйлиләр. Фәкать һаман да кергәне юк әле.

Мәзкүр Сәкинә ханым керсә, бик яхшы бер эш булыр иде. Чөнки Сәкинә ханым Бубый кызлар мәктәбендә укуы өстенә, берничә сәнәләр гимназиядә русча укыган. Аның өстенә, фазыйль[876] затлардан мөселманча гыйлемне тәкмил иткән, хәзерге хәлдә ханымнарымыз арасында сирәк очрый торган бер ханымдыр.

2) Зәйнәб ханым Камалия мәктәбедер. Бу мәктәптә 4–5 сәнәдән бирле камил муаффәкыять берлә дәвам итмәктә улып, елдан-ел тәрәккый итә[877] бармактадыр. Хәзерендә бу Зәйнәб ханым мәктәбе: хифзыссыйхәткә[878] муафыйк[879] ике этажлы зур бер йортка күчеп, ләйле (пансионлы) вә нәһари[880] уларак гүзәл рәвештә дәвам итәдер. Бу Зәйнәб ханымның йиде сыйныфтан гыйбарәт улган мәктәбендә бер йөз (100) чамасы шәкерт укымактадыр.

3) Фатыйма Адамова абыстай мәктәбедер. Матди җәһәте билгеле бер вәридәт[881] (вакыф) берлә тәэмин ителгән бу мәктәп Оренбургта кызлар

---

[868] Сәмәрә – нәтиҗә, җимеш.
[869] Закир итү – телгә алу, телгә алып сөйләү, искә алу.
[870] Интикад итү – тәнкыйть.
[871] Муаффәкыять – уңыш.
[872] Могавин – ярдәмче, булышчы.
[873] Хәнәфи Кәрим улы Бакиров (1884–1934) – мәгърифәтче, 1911 елдан «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта, мәдрәсә нигезендә ачылган укытучылар институтының беренче директоры (1917–1918), табигать фәннәре буенча дәреслекләр авторы.
[874] Рәфика – тормыш иптәше, хатыны.
[875] Габдулла Сабир улы Ибраһимов (Шнаси, 1885–1938) – мөгаллим, татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен дәреслекләр авторы.
[876] Фазыйль – намуслы.
[877] Тәрәккый итү – алга китү.
[878] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау, гигиена.
[879] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[880] Нәһари – көндезге.
[881] Вәридәт – керемнәр.

исемендә ачылган яңа мәктәпләрнең иң карты булып, заман берлә күп сатулашмыйча, […] бер рәвештә дәвам итмәктәдер. Бу мәктәп шикелле билгеле бер матди тәэминате булган бер мәктәпнең, башка мәктәпләр берлә кояш кабул улынмас дәрәҗәдә; гүзәл вә үрнәк булырлык бер дәрәҗәдә дәвам итәргә тиеш булдыгы хәлдә, матди җәһәттән гаять кысынкылык берлә дәвам иткән бүтән мәктәпләрдән дә түбән бер рәвештә дәвам итүе шатланырлык хәлләрдән түгелдер.

4) Гайниҗамал ханым Назыйрова[882] мәктәбе. Бу Гайниҗамал ханым бик күп еллардан бирле Оренбургта кызлар укыта килә. Мәктәбене кулыннан килгән кадәр ислах итү юлындадыр.

Моннан укып чыккан ару гына мәгълүматлы кызларга еш-еш кына очрарга тугры килә. Бу Гайниҗамал ханым мәктәбендә ике елдан бирле русча да укылмакта улып, моның өчен махсус бер учительница тотмактадыр. Мөселман кызларына мөһим улган кул һөнәрләре вә идарәи бәйтия[883] дәресләрен дә укыта икән.

5) Мөселман җәмгыять хәйриясе тарафыннан тәрбия ителгән Форштадтагы кызлар мәктәбедер. Бу мәктәп бер җәмгыять тарафыннан тәрбия ителгәнлектән, ихтимал моннан зуррак өметләргә дә урын бардыр. Фәкать, тәэссефкә каршы[884], бу мәктәп тугрысында ни дә әйтергә мөмкин түгел. Чөнки моның хакында, ачыграк вә тулырак мәгълүмат алу өчен тырышып карадык исә дә, муаффәкъ була[885] алмадык. Ләкин шуның илә бәрабәр каринәләрнең[886] дәляләтенә[887] күрә, бу мәктәпкә алай бик яхшы күз берлә карарга имкян[888] юк шикелле күренә. Моның бар кадәр хезмәте бик фәкыйрь балаларга хәреф язу, танытудан гына гыйбарәт улса кирәк дип уйладык.

6) Маһирә ханым Гонних[889] тарафыннан мөселман кызларына һөнәр мәктәбедер. Кисү-тегү шикелле һөнәр өйрәтү максаты берлә ачылган бу мәктәп үзенең вазыйфасын яхшы үтәп килмәктәдер. Мөселман кызлары өчен гаять зарур улган бу мәктәпнең тагы да тәрәккый итүен укучыларның саннары дәхый[890] дә арта төшүен арзу итмәктәдер[891].

7) Мөслимәләр җәмгыяте тарафыннан мөселман кызлары өчен ачылган кисү-тегү мәктәбедер. Рәисе вә әгъзалары байбикә вә могътәбәраннан[892] гыйбарәт улган бу мәктәпнең хәзергә кадәр дәвам итү эшендә адәм әйтерлек

---

[882] Гайниҗамал Назыйрова – Оренбургта кызлар мәктәбе ачучы, аның мөгаллимәсе.

[883] Идарәи бәйтия – хуҗалык эшләре.

[884] Тәэссефкә каршы – үкенечкә каршы.

[885] Муаффәкъ булу – булдыра алу, ирешү.

[886] Каринә – сүз сөйләшеннән аңлашылган мәгънә.

[887] Дәляләт – дәлиллек.

[888] Имкян – мөмкин булу, мөмкинлек.

[889] Маһирә Гонних – махсус белемле тегү остасы, Оренбургта кызлар өчен һөнәр мәктәбе ачучы.

[890] Дәхый – тагын, тагын да.

[891] Арзу итү – теләк, омтылыш.

[892] Могътәбәран – ихтирам ителә торган кешеләр.

җүнле-башлы бер эш тә күрсәткәне юктыр. Мондан ары нишләр? Анысын киләчәк күрсәтер.

Һәрхәлдә, моннан ары бу мәктәпкә вә әгъзаларына җитдирәк хәрәкәтләр теләп каламыз.

Болардан башка да Оренбургта оек, шәл бәйләргә өйрәтүче ханымнар булса да, аларын хәзергә калдырдык. Икенче бер вакыт бер мөнәсәбәт берлә аларны да иншаллаһ язсак кирәк.

*«Сөембикә», 1915, №1, б.14–17.*

***Имам Хәсән Вахидов***

**Аблай авылында кызлар мәктәбе**

Бәләбәй өязе Аблай авылында[893] Мөсалим әфәнде Исәнбердинның тәрбиясендә 7–8 еллар әүвәл ибтидаи вә рөшди кыйсемнәрдән гыйбарәт бер кызлар мәктәбе ачылган иде. Бу мәктәп шул вакыттан бирле елдан-ел ислах кылынып, йитешмәгән йирләре төзәтелеп килде. Хәзер дә кирәк бина, вә кирәксә уку җәһәтеннән, бу тирәдә беренче мәктәп санала. Программы киң, дин дәресләре өстенә кул һөнәрләре, тегү-чигү дә өйрәтелә. Мөгаллимә ханымнар да бик тырышып укыталар. Бу елда 150 кадәр бала укый. Үткән ел мәктәпнең беренче шәкертләре чыгып, тирә-як авылларда мөгаллимәлек итә башладылар. Шулардан Күчәрбай[894] вә Калмыш[895] авылында укытучы Заһирә вә Фатыйха ханымнарның бик яхшы укытканнары беленә.

Мәктәпнең бинасы да бик зур. Мөсалим әфәнде үз хуторында торып, авылындагы өч өлештән гыйбарәт булган зур өен кызлар мәктәбенә бирде. Ашханә вә ашау бүлмәсе аерым бинада. Кофе кайнатырга, плитә кыздырырга, мәктәп ягарга хезмәтчеләр куелган. Шәкертләргә хезмәт юк. Ягарга кирәк кадәр атнага 1–15 йөк утынны Мөсалим әфәнде үз атлары белән һәрвакыт хутордан җибәреп тора. Ягу вә яктыртуга мөгалиммәләр белән хезмәткәрләргә жалуния да Мөсалим әфәнде үзе бирә. Мәктәпнең еллык мәсарифы [896] мең сумнан аша. Бу эшләре өчен Мөсалим әфәндегә бу тарафтагы аңлы адәмнәр, бигрәк тә кыз шәкертләр вә аларның аталары бик хәер-дога кылалар. Һәркемнең авызыннан: «Мондый монтазам [897] кызлар мәктәбе тәрбия иткән баебызга Аллаһ үзе гомер бирсен», – дигән сүзләр ишетелә.

*«Тормыш», 1916, 29 март.*

[893] Аблай авылы – хәзер Башкортстанның Чакмагыш районына карый.
[894] Күчәрбай авылы – хәзерге Башкортстанның Благовар районына карый.
[895] Иске Калмыш авылы – хәзер Башкортстанның Чакмагыш районына карый.
[896] Мәсариф – тотылган акча, чыгым.
[897] Монтазам – тәртипкә салынган.

## Сабирҗан әфәндегә

Хөрмәтле байларыбыздан вә җәмәгать хадимнәреннән[898] Сабирҗан әфәнде Шәмгулов үзенең Казан вилаятендәге туган иле булган Кырлай[899] авылының гыйлем вә мәгарифтән мәхрүм бер хәлдә яшәвен игътибарга алып, үткән көз көне баш мөхәрриребезнең күрсәтүе буенча микъдар мөгаллимнәремездән вә газетабызда язышучылардан Кыям әфәнде Юлдаш[900] белән Бубый кызлар мәктәбен икъмаль иткән[901] Мәрхәбә туташ Батыршиналарны мөгаллим вә мөгаллимә итеп җибәргән иде. Шул авылдан идарәмезгә язылган мәктүбтә[902] мөгаллим һәм мөгаллимә әфәнденең бик гүзәл сурәттә укытулары вә елга һәртөрле гыйльми хезмәтләрдә булындыклары бәян ителәдер.

Сабирҗан әфәнде башлаган бу мөкаддәс эшне тагы да әсаслар[903] ак сурәттә дәвам иттерү өчен ирләр вә кызлар өчен бик гүзәл мәктәпләр салдыра башлаган. Менә шул һиммәте[904] өчен икенче мәхәллә картларыннан вәкяләт белән Гыйбадулла әфәнде Нәҗметдинов Сабирҗан әфәндегә рәхмәтләр укып илнең тәшәккерен[905] әйтәдер.

*«Тормыш», 1916, 17 апрель.*

***С.Туктаров***

## [Уфа өязе Бишунгар волосте ...]

Уфа өязе Бишунгар волосте Олуг Күл авылына мәрхүм Тимербулат Акчурин[906] тарафыннан ирләр мәктәбе вә Зөһрә ханым Акчурина (хәзердә Әхтәмова) тарафыннан кызлар мәктәбе салынган иде. Һәр мәктәптә мөгаллим вә мөгаллимәләр бик тырышып бала укыталар. Авыл картлары мәктәп салып биргән мәрхәмәтле вәли[907] нигъмәтләренә бик зур рәхмәт укыйлар.

Бу ел мәктәпнең килере – ир балалардан: 62 сум 80 тиен, кыз балалардан – 41 сум; төрле кешеләрдән – 96 сум 25 тиен. Барлыгы: 223 сум 75 тиен.

Мәктәпнең чыгымы: ир балалар мәктәбендәге хәдимгә 8 сум 50 тиен; лампа, уты һәм башка кирәкләр – 66 сум 40 тиен. Кыз балалар мәктәбенә тотылган: 45 сум 60 тиен. Мәҗмугъ чыгымы: 284 сум 30 тиен.

---

[898] Хадим – хезмәтче, хезмәткәр.

[899] Кырлай – Татарстанның Арча районындагы авыл.

[900] Кыям Исхак улы Юлдашев (1890–1955) – шагыйрь, мөгаллим, совет чорында китап сәүдәсе директоры.

[901] Икъмаль итү – тәмамлау.

[902] Мәктүб – хат.

[903] Әсас – нигез, төп, фундамент.

[904] Һиммәт – тырышлык.

[905] Тәшәккер – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.

[906] Тимербулат Курамша улы Акчурин (1826–1906) – фабрикант, сәүдәгәр. 1881 елда Старо-Тимошкино авылында аз керемлеләр өчен ашханә ача.

[907] Вәли – ия, хуҗа.

Ачык калган 60 сум 55 тиенне картлар вә мәктәп мөдирләре Хәсән әфәнде Акчуриннан[908] өмет итәләр.

***«Тормыш»:***

Мәзкүр[909] 96 сум 25 тиен иганә кылган затларның спискасы да идарәбезгә килде. Ләкин урын тарлыктан, ваклап яза алмыйбыз. Тимербулат хаҗи угылларының, хосусан мөхтәрәм Хәсән әфәнде Акчурин җәнабләренең әткәйләре тарафыннан ачылган мәктәпне дәвам иттерүләре үтенеләдер.

*«Тормыш», 1916, 11 май.*

***С.Аягузи***

**Авылларда кызлар мәктәбе**

Заман үзенекен эшли. Әүвәлге елларга нисбәтле соңгы елларда шәһәрләремездә тәртипле, заманымызга муафыйк[910] мәктәпләр күренгәли башлады. Бу тәртипле мәктәпләрнең ир балалар өчен булганы күк, кызларымыз өчен дә бар. Бу мәктәпләремез, әлһәмдүлилләһи, елдан-ел тәрәккый итеп[911] килә. Шәһәрләремездә булган тәртипле мәктәпләремезнең тәрәккый вә тәгалиләренә[912] аңлы мөгаллим вә мөгаллимәләремез сәбәп булганнары күк, һиммәтле[913], динле, иманлы вә кодсиятьле[914] байларымыз да сәбәп булдылар. Шәһәремездә ялтыраган мәгариф нурларының яктылыгы шәһәрләремездән ерак-ерак булган авылларымызга да төшә башлаган. Электән дә авылларда мәктәп вә мәдрәсәләр булса да, алар хатын-кызлар өчен, бәлки бөтенләй тәрбия өчен тәэсис ителгән[915] нәрсәләр булмаганнар. Гаилә тәрбиясендә иң зур роль уйнаучы әгъза – ата; хәят иҗтимагыянең ярымы ирләрдә икән, калган кыйсеме[916] хатыннар тәсаррыфында[917] булуы һәркемгә мәгълүм бер хакыйкать исә дә, гомумән әһел исламиядә[918] өзләшеп калган инкыйраз[919] гадәтләре, әүвәлге елларда авылларда да камил игътинаэ[920] илә сакланып килдеге күренеп тора. Гаилә хәяте дигән мәүзүгъ[921] хәтергә килү илә, дүрт стена арасында ябылган, көянтә астында черегән авыл хатын-кыз сурәтләре

---

[908] Хәсән Акчурин (1866–1916) – фабрикант, сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче.

[909] Мәзкүр – искә алынган.

[910] Муафыйк – яраклы, туры килгән.

[911] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.

[912] Тәгали – бөекләнү, югарылану.

[913] Һиммәт – тырышлык.

[914] Кодсиятьле – изгелекле.

[915] Тәэсис итү – төзү, оештыру.

[916] Кыйсем – өлеш.

[917] Тәсарруф – кулда.

[918] Әһле ислам – мөселманнар.

[919] Инкыйраз – бетү, юкка чыгу.

[920] Игътинаэ – әһәмият бирү, игътибар.

[921] Мәүзугъ – проблема.

күз алдына килеп баса. Менә бу сурәтләр, күз алдына килеп баскан инсан[922] никадәрле гафиф[923] вә битараф булмасын, ул хосуста уйларга вә фикерләргә мәҗбүр була. Ник әүвәлге вакытларда ук хатын-кызларның инсанлыгына, аларның тәкъва тәрбияләренә[924] игътибар итмәгәннәр икән дигән сүзне ихтыярсыз әйтеп куя. Хатын-кызларымыз ислам назарында вә инсаният мөхакәмәсендә[925] дә аң, гыйлем вә тәрбия бирелергә чын-чыннан тиешле бер мәхлуклар[926] түгелме икәннәр? Тәннең рухы булган күк, гыйлем вә тәрбия рухының да рухы түгелме дип тә уйлана. Инсанлык хокукын казанмак өчен әүвәлге елларда хатын-кызларымызга хәзерге заман кызларына бирелгән аң вә тәрбия ник бирелмәде икән? Хәзерге туташларымызның аң вә тәрбиясенә караганда, әүвәлге заман хатын-кызларымыз миңа аң вә белемнәрдән бөтенләй мәхрүм кеби күренеп киттеләр. Мин фәкыйрь Кавказдан Казанга килгәч, тарих материаллары эзләп авылларга чыктым. Авылларда байтак вакытлар калырга тугры килде. Мин авылларда уку-укыту эшләренә артык дикъкать итеп карап йөрдем. Бу авылларда соңгы елларда башланган уку-укыту эшләре үзем сәяхәт итеп күргән Кавказия вә Төркестан шәһәр вә авылларында булган уку вә укыту эшләреннән тәмаман башка икән, шул сәбәпле мин фәкыйрь Кавказ вә Төркестанда булган сеңел вә апаларымызны үзем йөреп күргән Казан, Вятка губернасы мөселман авылларында булган кызлар мәктәбендә укучы кызлар вә укытучы мөгаллимәләрнең иҗтиһад вә гайрәтләре илә таныштырасым килеп, Казан өязе Курса авылы кызлар мәктәбеннән башлыйм. Мин боны һәркайда сөеп укыла торган «Сөембикә» журналы аркылы сеңел вә апайларым мәйданына куярга телим. Могътәбәр «Сөембикә» журналы минем «Авылларда кызлар мәктәбе» дия башланган вә бик озын булачак бер мәкаләмә шаять урын бирер дип уйлыйм.

Менә Казаннан бик ерак түгел Курса исемле бер авыл бар икән. Бу авылда 8 сыйныфлы кызлар мәктәбе бар. Бу мәктәптә Курса авылының[927] үз кызлары тәрбия ителгән күк, чит авыллардан да бик күп кызлар килеп укыйлар икән. Бонда берле-икеле авыл муллаларының кызлары укыган күк, гавам[928] кызлары да укыйлар.

Авылының сәдакасы ел тәүлегенә 12 арба гошер[929], 6 куй корбан тирәсеннән артмаган бер авыл мулласы да ике кызын, бердән елның авырлыгына бакмый, бу Курса мәктәбендә укытканын күрдем. Әлбәттә, бу хәзрәт кызларымызга укуның мотлака фарыз идекенә иман китергән булырга кирәк. Бу Курса мәктәбендә кызлар өчен пансион бар. Бу мәктәпнең бар расходы мәктәп тәрбиячесе мөхтәрәм Гариф хәзрәттән икәне аңлашылды. Бу мәктәп

[922] Инсан – кеше, адәм.
[923] Гафиф – саф, бозылмаган, гыйффәтле.
[924] Тәкъва тәрбия – дни тәрбия.
[925] Мөхакәмә – хөкем чыгару.
[926] Мәхлук – җан иясе.
[927] Курса авылы – хәзер Татарстанның Арча районына карый.
[928] Гавам – гади халык.
[929] Гошер – яңа җыеп алынган ашлык, яшелчәдән бирелә торган сәдака.

берничә сәнәләрдән бирле дәвам итеп баруы өстенә, програмы да яхшы гына күренде. Бонда кызларга тарих, хисап, җәгърафия, татар вә гарәп телләре бик яхшы укылуы белән бергә, кул эшләре дә мөкәммәл итеп эшләнеп бара икән. Үз куллары белән эшләгән эшне күреп, тәгаҗҗеб иттем[930]. Һич авыл кызлары эшләгән эшкә охшамыйлар. Гаять нәфис, гаять нәзек. Бу мәктәптә укып чыккан кызларның бик күбесе әтраф авылларга чыгып мөгаллимәлек итәләр дип сөйлиләр. 13 яшенә кадәрле көянтә астында изелгән, көянтә илә су ташудан башка бер нәрсә дә белмәгән бер авыл кызы, бу мәдрәсәдә берничә ел укыганнан соң, башка бер калыпка кергәнлеге күренеп тора. Бу кызлар мәктәбендә кызлар үзара һәр җомга җәмгыять ясап, җәмгыятьтә һәрбер кыз үзеннән бер мәүзугь алып, җәмгыятькә чыгып нотык сөйли икән. Боларның бик оста сөйләүчеләре дә була диделәр. Менә бер тәртип кызларымыз да сүз куәсен арттырырга ифрат зур файдасы күрелгәнлектән, бу тәртипнең һәркайда мәкъбүлияткә чыгуын[931] өмет итәргә ярый. Әлегә кадәр бездә сөйләшә белмәүчелек яки гайбәттән башка сөйләшергә сүз тапмаучылык хөкем сөрә иде. Менә бу сөйләү тәртибе белән укыган кызларымызның сүзле, күркәм сохбәтле булуларын[932] инде өмет итәргә ярый.

Мин авыл тормышыннан язгач, моннан бик аз гына элекке хәлгә күз салып, шул бик аз гына элекке хәл белән хәзерге хәлне чагыштырып карыйсым килә. Шул аз гына вакыт эчендә хатын-кызларымыз тормышында күрелгән тәрәккый әйтеп бетергесез зурдыр.

Кызлар үзара һәм җомга җәмгыяте ясап, бер тема алып, нотык сөйли икән. Болар бик оста сөйләүчеләр була диделәр, сүз куәсен арттыруның никадәр файдасы барлыгын, бу тәртипне һәркайда урнаштыруны өмет итәргә ярый.

Бу авыл мәктәбендә кызлар өчен пансион бар. Мәктәп тәрбиячесе мөхтәрәм Гариф хәзрәт икән. […]

*«Сөембикә», 1916, №3–4, б. 51–56.*

***Гариф Галиәкбәров***

**[Орск җәмгыятенең кызлар мәктәпләренең…]**

Орск җәмгыятенең кызлар мәктәпләренең бу ел уку башыннан бирле йомшак барганлыклары сизелә. Җәмгыяь ел саен җәй айларында читтән яхшы мөгаллимәләр китертеп, йитештерү сыйныфлары ача килә. Алай да елдан-ел мөгаллимнәр кытлыгы көчәя бара. «Әхмәдҗания»дә баш мөгаллимә Кәримә ханым Фәйзуллина, авыру сәбәпле, хезмәттән истигъфа итте[933]. Ул мәктәпне яхшы гына идарә итеп килә иде. Аның урынына һәнүз[934] мөгаллимә эзләү юлында булынса да, уңгайсыз вакыт булганлыктан, яхшы мөгаллимә

[930] Тәгаҗҗеб итү – гаҗәпләнү, ис китү.
[931] Мәкъбүлияткә чыгу – кабул ителү.
[932] Күркәм сохбәтле булу – яхшы юлдаш булу.
[933] Истигъфа итү – эштән азат ителү.
[934] Һәнүз – һаман да.

табылмый. Җәмгыятьнең карары илә мәүкыйт[935] уларак, 4нче рөшди сыйныфлары ябылып тора. Мөгаллимә табылса, янә ачылачак. Хәзер «Әхмәдҗания»дә 3 сыйныф рөшди дәвам итә. Мөгаллимәләр дә тәҗрибәсез, яшүсмер кызлар булганлыктан, чак-чак кына сөйрәлеп килә. «Әхмәдҗания»дә 3 мөгаллимә вә 60 ка якын шәкерт бар. Ибтидаи[936] 4 сыйныфлы мәктәп «Габбасия»дә 131 шәкерт, 4 мөгаллимә. Анда да баш мөгаллимә вә мөдир Зәйнәб туташтан башкасы тәҗрибәсез яшь кызлар. Ул мәктәп тә, мәгаттәәссеф[937], борынгы барышын югалтты. 1нче мәхәлләдә (карт) Газизә абыстай идарәсендәге ибтидаи 4 сыйныфлы мәктәптә 133 шәкертне 4 мөгаллимә укыта. Боның хәле дә әүвәлге икенең хәленнән аермасыз. Урта дәрәҗәдән дә түбән. Бу мәктәптә берничә еллардан бирле укытып килгән Фатыйма Сәгыйриянең китүе мәктәп өчен яхшы ук сизелерлек кимчелек ясады. Җәмгыять тарафыннан сайланган мөфәттиш вә мөфәттишәләр[938] һәрдаим мәктәпләрнең әхвален тикшереп, алган мәгълүматларыннан «җәмгыять» идарәсенә хәбәр бирә, доклад күндереп торалар. «Җәмгыять» үз тарафыннан мәктәпләрнең ислахына тырыша. Үзенең тиешле әмерен ирештереп тора.

*«Вакыт», 1916, 30 декабрь.*

***Нигъмәтулла Нурулла угылы***

**Алма-Атадан (Җидесу вилаяте)**

Алма-Атада күп еллардан бирле Габделвәлиевләр тәрбиясендә яхшы гына монтазам[939] вә алты сыйныфтан гыйбарәт булып, ирләр вә кызлар мәктәбе дәвам итеп килмәктәдер. Бу мәктәпләрнең мөдире Алма-Атаның зыялыларыннан Зәйнетдин хаҗи Таҗетдинов[940]. Хәзерендә ирләр мәктәбендә баш мөгаллим Габдулла Сатыев[941] вә кызлар мәктәбендә баш мөгаллимә Гафифә ханым Дәүликамова булып, мәзкүр мәктәпләр бу елда ачылып, укулар башлады.

Бу мәктәпләр Алма-Ата әтрафыннан ысул җәдидә берлән укытыла торган мәктәпләрнең картрагы һәм хезмәте күбрәк тигәнедер. Боларда һәр елда 200ләп татар, кыргыз, таранчы[942], сарт балалары тәхсил итәләр[943]. Моннан башка ир һәм кызлар өчен «Туземный» мәктәп дәвам итеп килмәктәдер. Бу

---

[935] Мәүкыйт – срок, билгеләнгән вакыт.

[936] Ибтидаи – башлангыч.

[937] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.

[938] Мөфәттиш, мөфәттишә – тикшерүче, инспектор.

[939] Монтазам – тәртипле.

[940] Зәйнетдин хаҗи Таҗетдинов – сәүдәгәр, химаяче.

[941] Габдулла Габделкәбир улы Сатыев (1886–1958) – педагог, дәреслекләр авторы, «Хөсәения», Уфадагы «Госмания», «Галия» һ.б. мәдрәсәләрдә укыта.

[942] Таранчы – Россия империясе территориясендә яшәүче уйгырларның 1917 елга кадәрге атамасы.

[943] Тәхсил итү – белем алу.

мәктәпләрдә дә укучылар соң дәрәҗәдә күп. Ләкин туземный мәктәпләрдә ана теле вә дин дәресләренә урын азрак бирелгән булуы бераз уңайсызлыйдыр. Алма-Атада дәхый күптән түгел Гыйззениса ханым идарәсендә кызлар мәктәбе дәвам итеп килмәктәдер. Бу мәктәп 4 сыйныфлы булып, бу ел Гыйззениса ханымның тырышуы аркасында 5нче сыйныфы да ачылды. Бу мәктәпнең матди ягы тәэмин ителмәгән булса да, мөгаллимә ханымның һиммәте саясендә[944] тукталмый һәр елны 50ләп кызлар тәрбияләнеп килә. Алма-Ата әтрафында ысул җәдидә юк дип әйтерлек дәрәҗәдә аз таралган. Гомумән Җидесу вилаяте ибтидаи[945] мөгаллим вә мөгаллимәләргә соң дәрәҗәдә мохтаҗлар. Менә без шушы әһәмиятле мәсьәләне тизрәк хәл итеп, Алма-Ата әтрафында ибтидаи мөгаллим вә мөгаллимәләр хәзерләргә телимез. Ибтидаи мөгаллимнәрне хәзерләргә бердәнбер ансат юл булса, ул да мәзкүр 6 сыйныфлы мәктәпләр янында мөгаллим вә мөгаллимәләр хәзерли торган сыйныфлар ачудыр. Бу ел Алма-Атада дәхый күңелле бер эш булса, ул да Исхак Габделвәлиев[946] угылларының тиҗарәтханәсе[947] тәрбиясендә бер һөнәр мәктәбе вөҗүдкә килүдер[948]. Моның өчен Уфа җәмгыять хәйриясе һөнәр мәктәбен тәмам иткән Сөнгатулла әфәнде мөгаллим булып килде.

*«Вакыт», 1917, 4 гыйнвар.*

***Габделгазиз Мортазин***

**Алабайталда кызлар мәктәбе**

Оренбург өязе Алабайталда[949] икенче мәхәллә хозурында кызлар мәктәбе ачылды. Оренбургтан мөгаллимә китертелеп, тәртип белән уку башланды. Мәктәп өчен мәхәлләмезнең могътәбәрләреннән Мөшәрриф әфәнде Халидов бер өен бер ел мөддәт[950] илә бушлай биреп торды. Мәктәп бинасын салу хакында Оренбургтан Нигъмәтулла хәзрәт илә бәгъзе һиммәт ияләренә[951] киңәш кылган идем. Алар бу эш башланса, ярдәм итәргә вәгъдә кылдылар. Мәхәлләмез фәкыйрь. Шуның өстенә халык буңа кадәр укыту юлына зур иганә кылып өйрәнмәгән. Шунлыктан читләрнең ярдәменә ихтыяҗымыз зурдыр. Ошбу хәлне игътибарга алып, һиммәт итүчеләр булса, бик зур бер кардәшлек күрсәткән булачаклардыр.

*«Вакыт», 1917, 8 гыйнвар.*

---

[944] Һиммәте саясендә – тырышлыгы белән.
[945] Ибтидаи – башлангыч.
[946] Исхак Габделвәлиев – Алма-Ата шәһәрендә I гильдия сәүдәгәр, химаяче, мәчет-мәдрәсәләр, китапханә сала.
[947] Тиҗарәтханә – сәүдә йорты, кибет.
[948] Вөҗүдкә килү – барлыкка килү.
[949] Алабайтал – хәзер Оренбург өлкәсенең Беляев районына керә.
[950] Мөддәт – вакыт, срок.
[951] Һиммәт ияләре – тырышлык куючылар, ярдәм итүчеләр.

***Ф.Төхфәтуллин***

**Катыш мәктәп**

Катыш мәктәп – ир вә кыз балалар бергә укый торган мәктәпдер. Инкыйлабка [952] кадәр гомумән Русиядә хатыннар хокукы начар ригая кылына [953] иде. Без, татарлар, үземез хокуксыз милләтләрдән булуымыз сәбәпле, хатыннарымыз да хокуксыз иде. Инде үз хокукымызны кайтарып алгач, хатыннар хокукын да ригая кылып, шәригать тарафыннан манигъ[954] булмаган йирләрдә һәрбер хокукны бирмәкче булдык. Шулай итеп, рәсми хатыннарны бер дәрәҗәгә китерсәк тә, вакыйган аларны үзебез берлә бертигез итә алмадык әле. Без аларга һәрбер хокукны бирдек, дию берлә, хәзергәчә көнгә сеңелеп килгән караштан котылып булмый. Мәсәлән, хатыннарның җәмәгать намазларына йөрүе дөрес булуы шәргый дәлилләр берлә ачык исбат кылынса да, без күземезне йомамыз я дөнья кубарып нигазлашамыз. Хатыннар хокукын кирәгенчә тәэмин кылыйк дисәк, бар көчебезне яшь буынга юнәлдереп, ир вә кызларны бер мәктәптә тәрбия кылырга тиешлебез.

Русия татарларының уку-укыту тарихына карасак, өченче дәвер башланганын күрәмез. Беренче дәвер күп еллар дәвам иткәннән соң, 20 еллар чамасы моннан элек бетә башлый. Бу дәвердә укыту ана телендә булмау сәбәпле, кирәгенчә гыйлем алу бик аз кешеләргә генә мөяссәр [955] булган. Икенче дәвер 20 еллар моннан элек башланып, инкыйлабка кадәр дәвам итә. Бу дәвер элеккесеннән шуның белән аерыла: без мәктәпләремезне ислахка[956] керешкәч тә, һәрбер православный динендә булмаган милләтне йоту әсасенә[957] бина кылынган[958] хөкүмәт мәктәпләремез аркасында йотылудан котылачагымызны белгәч тә, укыту эшенә катышып, милләт хисен уята торган газиз мәктәпләремезне берәм-берәм яба башладык.

Инде инкыйлабтан соң өченче дәвер башлана. Бу дәвер үткәннәреннән дәхый аерыла. Бу дәвердә ысулы җәдидә вә ысулы кадим низагысы булачак түгел, шулай ук хөкүмәт тә катышачак түгел.

Шушы дәвернең беренчесендә кызларны укыту юк дәрәҗәсендә иде. Язу язарга өйрәтү исә хәрам дип таныла иде. Икенче дәвердә исә, кызларны укыту эше бер дәрәҗә күтәрелеп, кызларны язу язарга өйрәтергә ярамый дигән игътикад[959] да йомырылды. Шулай булса да, ир балаларны укыту берлә бер даирәгә йитмәде, күп йирләрдә кызлар өчен аерым мәктәпләр дә булмый, бары абыстайларның мал яки аш өйләренә генә калды. Бик күп урыннарда Идел буе татарлары арасында быел көздән үк алты еллык яңа типта

[952] Инкыйлаб – революция.
[953] Ригая кылыну – кайгырту.
[954] Манигъ – киртә.
[955] Мөяссәр – җиңел, җайлы.
[956] Ислах – реформа.
[957] Әсас – нигез, база.
[958] Бина кылыну – нигезләнү.
[959] Игътикад – ышану, инану.

мәктәпләр ачылачак. Инде шул мәктәпләрдә, мөмкин булса, һәр җирдә ир вә кыз балалар бергә укысыннар иде.

Мондый катыш мәктәпләрдә ир вә кыз балалар бер-берсенә иптәшлек, тиңдәшлек күзе берлә карап үсәчәкләр. Яшьтән шул игътикад эчендә үскән кеше хатыннарны үзеннән ким күрмәс вә аларның хокукларына тәгъди[960] итмәс. Гомумән мондый мәктәпләрдә шәкертләр уку җәһәтеннән вә әхлак (нравственный) җәһәтеннән югары торырлар. Русиядә биш еллар гына моннан элек ачыла башлаган высший начальный катыш мәктәпләр бик яхшы нәтиҗәләр күрсәтеп торалар. Аннан башка укыту эшләре бездә матди яктан начар тәэмин ителгәнгә күрә, ирләр вә кызлар өчен аерым мәктәпләр салмый, бары бер зур мәктәп яки бар кадәрен киңәйтеп кенә салсак, безнең өчен бик зур җиңеллек булыр иде.

Катыш мәктәпләрнең иң күп таралган йире Америкада. Анда ел саен шундый мәктәпләрнең саны артып тора. Америка халкының әхлак (нравственность) ягыннан Яурупага караганда югары торуы ирләр берлә кызларны бер йирдә тәрбия итүдән дип уйлана.

Кыскасы, катыш мәктәп галимнәр тарафыннан һәр ике якның тәрәккыесы[961] өчен файдалы табылган. Шәт без мөселманнар да, һич булса, ибтидаи мәктәпләремезне катыш итүдән курыкмамыз.

*«Шура», 1917, №13, б.306.*

***Мөхәммәдкамал Мозаффаров***[962]

**Катыш мәктәп**

Ошбу елгы 13нче «Шура»да Ф.Төхфәтуллин әфәнде катыш мәктәпне мәслихәт күреп[963], Американы мисал итеп яза. Уку яшендә санала торган 8 яшеннән 10 яшенәчә булган ир-ат һәм кыз балаларны берлектә бер мөгаллим вә яки мөгаллимәдән укытуны тиеш саный. Ләкин Америкада һәрбер мәслихәт булган эшләрне Русия мөселманнары түгел, Төркия мөселманнары да алмаганнар. Алган булсалар, Төркиядә бу көннәргә кадәр мәктәп-мәдрәсәләр ир вә кыз балаларга аерып йөртелми, бергә катыш булып беткән булыр иде. Һәм бу эш мәслихәт булса иде, Русиядә күптән кабул ителеп, «женский школа», «женский гимназия», «женские курсы» кебек исемнәр онытылып та беткән булыр иде. Ләкин болар үз исемнәрендә ел саен артып торалар.

Безгә моны иске хөкүмәт вакытында ислам дошманы булган Ильминский, шәһәрдә Малмыж инспекторы тәкъдим итте, әмма без моның зарарларын дәлилләп, берлә исбат итеп каршы тордык, кабул итмәдек һәм ышкулны кызларга һәркайда аерым, ирләргә аерым ышкулалар тәгаен ителде.

---

[960] Тәгъди – гаделсезлек.

[961] Тәрәккый – алга китү.

[962] Мөхәммәдкамал Мозаффаров (1855 – ?) – мәгърифәтче, мөгаллим, Малмыжда рус-татар, кызлар өчен һөнәр мәктәпләре оештыручы, үз өендә мөселманнар өчен китапханә ача.

[963] Мәслихәт – уңыш, файда; киңәш.

Инде ышкуллар урынына дини милли мәктәп-мәдрәсәләр ачарга имкян булгач[964], янә мөселманнарга матлуб булмаган[965] бернәрсә күрсәтәләр. Хәзер инде сүзләрне этрафлыча[966] уйлап сөйләргә кирәк. Мәктәп-мәдрәсәләргә чын нигез сала торган вакыт икәнен хәтердән чыгармаска тиешле. Бер илдә муафыйк[967], мәслихәт булып танылган нәрсәмезне, икенче илдә бу нәрсә ярамый икән, дип, хатаны ихтираф итү[968] читен булыр. Америкада ригаять кылуы[969] тиеш булмаган бәгъзе бер нәрсәләрне мөселманнарда ригаясе лязем саналуны хәтердән чыгармаска тиешле. Ирләргә салынган рөшди кызларымызга да мәктәп-мәдрәсәләр вә һөнәр урыннары ачып, бонларны салдырырга, мөгаллим вә мөгаллимәләр хәзерләргә иҗтиһад кылу[970] тиешле.

Нинди генә кечкенә йирне мисал итсәләр дә, уку яшендәге балаларның унбиш-егермедән ким булуы уйланмый, аннан да ким булса, мәктәп-мәдрәсә бар йиргә үзләренең барулары лязем. Ирдән-кыздан кырыклап бала булса, һөнәрдә бер укытучы кифая килә[971]. Өч сәгать ирләр, өч сәгать кызлар укырга мөмкин. Ләкин бергә түгел, бәлки берсе чыккач, икенчеләре керүле була. Һәр ки халыкның теләмәгән пилюлясын йоттырырга тырышмаска кирәк.

*«Шура», 1917, № 17, б.401.*

[964] Имкян булу – мөмкин булу, мөмкинлек.
[965] Матлуб булган – таләп ителгән, соралган.
[966] Әтраф – тирә-юнь.
[967] Муафыйк – яраклы.
[968] Ихтираф итү – эштә зур тәҗрибәле булу.
[969] Ригаять кылу – кайгырту, карау.
[970] Иҗтиһад кылу – тырышу.
[971] Кифая итү – җитәрлек, кирәк кадәр булу.

# III БҮЛЕК

# «ШАТЛЫКЛЫ ВӘ ТАНТАНАЛЫ БӘЙРӘМ КИЧӘЛӘРЕН БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КҮРҮЕМЕЗГӘ СӘБӘПЧЕ БУЛУЫ ӨЧЕН...»

Кызлар мәктәпләрендә, хатын-кыз җәмгыятьләрендә кичәләр, бәйрәмнәр үткәрү тарихы

***Исмәгыйль Госмани***

**Бәраәт бәйрәме**[1]

Адамова кызлар мәктәбендә[2] бәраәт бәйрәме көнне шәкерт кызлар мәктәпкә килеп, Коръән вә догалар укымышлар. Тыңлау вә тәбрикләнү хәзерләнде, бәгъдәлзаһыр[3] русча укылачак дәресләр 21 августта башланачак, мәгәр бу сәнә шәкертләрдән, хәленә карап, бераз парә[4] алачакмыз.

Мөдир Исмәгыйль Госмани

*«Вакыт», 1910, 8 август.*

**Мөслимәләр өчен беренче уку мәҗлесе**

Оренбург мөслимәләр җәмгыяте үзенең әгъзаларына мәгънәви файда итү һәм җәмгыятьнең сәрмаясын[5] арттыру өчен бу декабрь 10сында сишәмбе көн Габделхәмид Хөсәенов йортында уку мәҗлесе ясыйдыр.

Програм шу илә:

1) Коръән уку вә вәгазь-нәсыйхәт – мөгаллимә Фатыйма Адамова, мөгаллимә Багбостан Мөэминова, мөгаллимә Мөслимә Шәфигова;

2) мөселман хатын-кызлары арасында мәгърифәт һәм укуның таралуы – мөгаллимә Зәйнәб Камалетдинова;

3) балалар тәрбиясе хакында – мөгаллимә Гайшә Госманова;

4) шәригать назарында[6] хифзыссыйхәт[7], сәламәтлекне саклау – мөгаллимә Сәлахова;

---

[1] Бәраәт бәйрәме, Бәраәт кичәсе – Шәгъбән аеның беренче көнендә үткәрелә, бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн санала; ислам дине тәгълиматы буенча, бу төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

[2] Адамова мәктәбе Оренбург шәһәрендә була.

[3] Бәгъдәлзаһыр – соңрак.

[4] Парә – өлеш, кисәк.

[5] Сәрмая – акча.

[6] Шәригать назарында – шәригать күзлегеннән караганда.

[7] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау юллары, гигиена.

5) табиблар карамагында хифзыссыйхәт – табибә Разия ханым Сөләйманова;

6) дикламацияләр, Тукаев шигырьләре, Гобәйдулла Рәдүди[8], Мәҗит Гафури һәм Сәгыйть Сүнчәләй[9] шигырьләре – шәкерт кызлар бергә кушылып укыйлар;

7) Пушкин һәм Лермонтов шигырьләре – Рабига Шәрәфетдинова;

8) Салават шәриф һәм мөнәҗәтләр – кыз шәкертләр бергә кушылып укыйлар.

*«Сөембикә», 1913, №4, б.15–16.*

***Мәрьям Фәхретдинова***

**Казалы кызлар мәктәбендә әдәбият кичәсе**

22нче декабрьдә Казалы кызлар мәктәбенең мөдирә вә мөгаллимәсе Гайшә ханым Хантимерия тарафыннан кыз балаларга махсус әдәбият кичәсе ясалды. Милли шигырь вә гыйбрәтле әсәрләр укылды. Тәгълим, тәрбия вә әхлак хакында әсәрле вәгазьләр сөйләнде. Ханымнар күп иде. Бик мәмнүн булып[10], рәхмәтләр укып чыктылар. Бондый күңелле вә файдалы кичәләр ясап, ханымнарымызның рухларын күтәргән өчен Гайшә ханымга самим калебтән[11] тәшәккер[12] итәргә бурычлымыз.

*«Вакыт», 1915, 3 гыйнвар.*

***Гайшә Абызгилдиния***

**[14нче гыйнвар...]**

14нче гыйнвар чәршәмбе көн кич сәгать (4)тә ханымнар җәмгыятенең 1нче мәхәллә кызлар мәктәбендә «Мәүлид шәриф» укылачак. Ирадәсе[13] булган ханым вә әфәнделәргә ишек ачык булачак, мәҗлескә рәхим итүләрен үтенәмез.

*«Тормыш», 1915, 13 гыйнвар.*

---

[8] Гобәйдулла Габделмөэмин улы Рәдүди (1885–1912) – мәгърифәтче, шагыйрь, «Хөсәения» мәдрәсәсендә, Багбостан мәктәбендә мөгаллимлек иткән.

[9] Габдулла Тукай (1886–1913), Мәҗит Гафури (1880–1934), Сәгыйть Сүнчәләй (1888–1937) – күренекле татар шагыйрьләре.

[10] Мәмнүн булу – риза, канәгать булу.

[11] Калеб – йөрәк.

[12] Тәшәккер – рәхмәт сүзе.

[13] Ирадә – теләү, омтылу.

**[Гыйнварның 14ндә...]**

Гыйнварның 14ндә, чәршәмбе көн ханымнар җәмгыятенең 2нче мәхәллә хосусындагы кызлар мәктәбендә, кич берлә сәгать 6да Мәүлид кичәсе [14] булачак. Теләгән ханым вә туташлар рәхим итсеннәр.

Һәйәть тәгълимия[15] әгъзалары

*«Тормыш», 1915, 13 гыйнвар.*

**Багбостан ханым мәктәбендә уку мәҗлесе вә балалар акшамы**[16]

15нче гыйнварда Мәүлид ән-Нәби мөнәсәбәте илә Багбостан ханым мәктәбендә иртә беләң сәгать 10нан бергә кадәр олуглар өчен уку мәҗлесе булган. Баш мөгаллимә Багбостан ханым тарафыннан Мөхәммәд (гәм)нең тәрҗемәи хәле, сәйяр шәрифәсе[17], өммәһат мөэминин (р.г.)[18] фәзаил[19] вә хосусыятьләре бәян ителгән.



Багбостан ханымның кызлар мәктәбендә Мәүлид кичәсе
*(«Сөембикә», 1915, № 8)*

[14] Мәүлид кичәсе – Мәүлид бәйрәме, Мәүлид ән-Нәби, Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көненә багышланган дини бәйрәм, рабигыль-әүвәл аеның 12сендә үткәрелә.

[15] Һәйәт тәгълимия – укыту комиссиясе.

[16] Акшам – кич, кичә.

[17] Сәйяр шәрифә – кадергә лаек юл йөрүе, ил гизүе.

[18] Өммәһат мөэминин – өммәтнең җитәкчесе.

[19] Фәзаил – артыклык, өстенлек, яхшы сыйфатлар.

Соңра могавинә[20] мөгаллимәләр тарафыннан бәгъзе дини вә гамәли сүзләр сөйләнеп, шәкертләр тарафыннан бу көн өчен махсус хәзерләнгән шигырьләр һәм дикламацияләр укылган. Кич белән сәгать 6дан 8гә кадәр балалар акшамы ясалып, бонда һәм Мөхәммәд (гәм)нең тәрҗемәи хәле вә мәнакыйбы[21] сөйләнгән. Хор белән һәм ялгыз, ялгыз шул көнгә мөнасиб[22] һәртөрле шигырьләр укылган. Мәҗлесләрнең һәр икесендә ханымнар гаять күп булып, бинага сыймаганнар, мәхрүм булып киткәннәр. Олуг вә кечек могътәбәран[23] һәм зыялылардан шәһәремезнең гыйлемгә һәвәсле бөтен аналары, ханым вә туташлары хазир булганнар[24]. Бу көн мәктәп бинасы төрле төстә фонарьлар вә флаглар илә зиннәтләнгән. Ай вә йолдыз галәмәтләре куелып, өстенә «Мәрхаба[25] Мөхәммәд Мостафа (слгм)» дип язылган гаять хуш бер ләүхә[26] куелган. Уку мәҗлесе вә әдәбият кичәсенә иштиракъ иткән[27] балалар, һәркаюсы бер төстә ак киемнәр киенеп, бер төстә бантлар такканнар. Кич Мәрьям Гобәйдуллина вә Рабига Камалова туташлар тарафыннан мәктәптә укыган шәкертләргә һәртөрле татлы нигъмәт вә йимешләр белән чәй мәҗлесе хәзерләнеп, зыяфәт[28] бирелгән. Кирәк иртәнге уку мәҗлесе, вә кирәк балалар акшамы вә зыяфәт булсын, һәркаюсы бик күңелле булып, хазирунның[29] күңелендә тирән тәэсират калдырганнар. Милли вә дини бөек бәйрәмнәремезне һәркем күңелендә тирән тәэсират калдырырлык бер рәвештә каршы алып, мәктәптә укыган вакытында укудан мәхрүм калган ханым вә туташларымызның рухларын яңарта торган бер хәлгә китергәнлекләре өчен мәктәп идарәсе вә мөгаллимә ханымнар тәкъдиргә[30] лаектырлар. Мәктәптә укыган яшь иптәшләренең күңелләрен табарга тырышып, зыяфәт биргән вә шуның аркасында яшь туташларымыз арасында дуслык вә мәхәббәт артырга сәбәп булган Мәрьям Гобәйдуллина вә Рабига Камалова туташлар аерым сурәттә шаян[31] тәшәккердерләр[32].

*«Вакыт», 1915, 20 гыйнвар.*

[20] Могавинә – ярдәмче.
[21] Мәнакыйб – мактаулы эшләр.
[22] Мөнасиб – яраклы, туры килә торган.
[23] Могътәбәран – ихтирам итела торган кешеләр.
[24] Хазир булу – катнашу.
[25] Мәрхаба – хуш килдегез.
[26] Ләүхә – вывеска, плакат.
[27] Иштиракъ итү – катнашу.
[28] Зыяфәт – кунак итү.
[29] Хазирун – катнашучылар.
[30] Тәкъдир – эшләгән эшкә бәя бирү.
[31] Шаян – лаек, яраклы, тиешле дәрәҗәдә.
[32] Тәшәккер – рәхмәт сүзе.

***Фәгыйлә һәм***
***Маһидилбәр Сәйфелмөлековалар***

**Казалыдан**

Кызлар мәктәбендә гыйнвар 12 сендә тәҗрибә имтиханы булып, Мәүлид эн-Нәби мөнәсәбәте илә шәкертләргә ун көнгә тәгътыйль[33] бирелде. Имтихан вакытында шәкертләрнең гүзәл имтихан бирүләреннән мөгаллимә Гайшә ханым Хантимированың да иҗтиһады мәгълүм булып, имтиханда хазир булган[34] ханымнар тарафыннан яхшы тәкъдир[35] ителде. Гыйнвар 14 ендә Гайшә ханым тарафыннан тантаналы Мәүлид кичәсе ясалып, «Мәүлид шәриф» укылды.

Мәүлид кичәсенә алдан хәзерләнеп, 75 кадәр кыз шәкерт һәркаюсы ефәкатласка пәйгамбәремезнең исем-шәрифләрене чигеш илә язып, шамаил вә ләүхәләр[36] хәзерләп, гөл чәчәкләре илә мәктәпнең диварыны тәмам зиннәтләгән иделәр.

Һәрбер кыз шәкерт ал тасмага «Бүген Мәүлид шәриф бәйрәме» дия чигеш илә язып, күкрәк аркылы бантлап ал-гөл чәчәкләр илә бизәнгән иделәр. Кичә өчен махсус хәзерләнгән, бер төсле киенгән кыз шәкертләрне һәм дә эче-тышы төрле фонарьлар, ләүхәләр илә бизәлгән мәктәпне күргәндә, ханымнарның сәнәгать[37] вә нәфасәткә[38] никадәр истигъдадлы[39] вә никадәр рухлы икәнене күреп, мөгаллимә Гайшә ханымның фәгалиятьле[40], эшлекле юлбашчы идекене дә икърар итми[41] мөмкин түгел иде.

Мәүлид шәриф ахырында патша хәзрәтләре вә ханәдане галиләренең[42] сәламәтлекләренә, рәгыятенең[43] тынычлыкларына дога кылып, файдалы солых теләп, сугыш сафында булган каһарман ага-этиләремезнең калганнарына тәгъзия[44] бәян ителде.

Соңра милләтемезнең бөек атасы мәрхүм Исмәгыйль бәк Гаспринский хәзрәтләренә вә туганына 100 ел тулу мөнәсәбәте илә мәрхүм Шиһаб хәзрәт Мәрҗани[45] рухына һәм дә Казалыда милли эшләрдә күп хезмәтләре күренгән мәрхүм Габделгани бай Хөсәеновның рухына озын догалар кылынды.

---

[33] Тәгътыйль – каникул.
[34] Хазир булу – катнашу.
[35] Тәкъдир – бәя бирү; ихтимал, очрак.
[36] Ләүхә – вывеска, плакат.
[37] Сәнәгать – сәнгать.
[38] Нәфасәт – гүзәллек.
[39] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.
[40] Фәгалиять – эшчәнлек.
[41] Икърар итү – тану.
[42] Ханәдане гали – бөек династия.
[43] Рәгыять – халыклар.
[44] Тәгъзия – үлгән кешенең якыннарын юату, күңел юату.
[45] Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани (1818–1889) – күренекле мәгърифәтче, тарихчы, дин галиме.

Юлбашчылык итеп, тәдбирле[46], иҗтиһадлы[47] хезмәтләре вә бу көнгә кадәр хәтеремезгә килмәгән шатлыклы вә тантаналы бәйрәм кичәләрене беренче мәртәбә күрүемезгә сәбәпче булуы өчен, мәктәпнең мөдирә вә мөгаллимәсе Гайшә ханымга һәм дә тәртипле мәктәп йитештереп, иҗтиһад кылган аталарымызга без, Казалы ханымнары исеменнән, тәшәккер[48] итеп, самими рәхмәт укыймыз.

Фәгыйлә һәм Маһидилбәр Сәйфелмөлековалар

*«Вакыт», 1915, 23 гыйнвар.*

***«Кардәш»***

**Ташкентта балалар иртәсе**

18нче гыйнварда Мәүлид мөнәсәбәте илә,Ташкентта «Хива» театрында[49] «Балалар иртәсе» булды. Өч бүлемдән гыйбарәт иде.

Беренче бүлемдә:

1) Патша хәзрәтләренә дога кылынды;

2) Ир вә кыз балалардан гыйбарәт 70 кешелек хор тарафыннан «Мәүлид бәйрәм» шигыре әйтелде;

3) Мәктәп балалары тормышыннан алынып язылган «Абзыйның килүе» исемле (русчадан тәрҗемә) бер пәрдәлек пьеса уйналды.

Икенче бүлемдә:

1) Крыловның ике баснясы, Тукайның «Сөткә төшкән тычкан», «Төлке һәм йөзем йимеше» нам[50] шигырьләре вә бәйрәм догасы – барысы да бер шәкерт тарафыннан укылды;

2) 20 ләп вак вә зур кызлардан бәйрәмгә мөнасиб[51] җанлы сурәт ясалды;

3) «Бала белән күбәләк», «Бичара куян»[52] тәкълиде[53] ясалды (Болар икешәр шәкерт тарафыннан иҗраэ ителделәр[54]; күбәләк берлән куян урынындагылары үзләрен муафыйк[55] рәвештә киендерелгән иделәр).

Өченче бүлем:

1) Югарыда әйтелгән 70 кешелек хор тарафыннан «Кара урман», «Салкын чишмә» вә «Галиябану» көйләренә моңлы, милли җырлар җырланды;

2) Татар яшьләре тарафыннан төзелгән балалайка оркестрында үземезнең иң сөекле мәшһүр көйләрдән 5–6 көй уйналды;

---

[46] Тәдбирле – эшне ахырын уйлап эшләнгән.

[47] Иҗтиһадлы – тырышлык куеп, тырышып эшләнгән.

[48] Тәшәккер – рәхмәт сүзе.

[49] «Хива» театры бинасы (электротеатр) Ташкентта 1909 елда төзелә. 1917 елда янгын чыгып, бина юкка чыга.

[50] Нам – исем.

[51] Мөнасиб – яраклы, туры килә торган.

[52] «Бала белән күбәләк», «Бичара куян» – Г.Тукай шигырьләре.

[53] Тәкълид – иярү, охшатып эшләү.

[54] Иҗраэ итү – үтәү, эшкә ашыру.

[55] Муафыйк – яраклы, туры килгән.

3) Музыканың кушылуы берлән хор тарафыннан «Мәүлид бәйрәм» шигыре әйтелде.

Хор бер тавыштан гына гыйбарәт булмыйча, өч төрле тавышның бергә кушылуыннан гыйбарәт – яңа өслүбтә булганга, ир балалар белән кыз балалар берләшкәнгә, вә алар янына гимназиядә укучы 10лап туташ та кушылганга, бик рухлы вә бик тәэсирле булып чыкты. Халык бик нык алкышлаганга күрә, хорчылар һәрбер көйне икешәр кат әйтергә мәҗбүр булдылар.

Пьесага килгәндә, мәгълүмдер ки, «балалар театры» бездә бик яңа бер нәрсә: Русия мөселманнарының мәркәзеннән саналырлык бер-ике шәһәрдән башка җирдә ул әле уйналганы вә мәйданга чыкканы да юк иде. Балалар театры өчен язылган пьесалар да бөтенләй юк дәрәҗәдә. Шулай булса да, мөмкин булган йирләрдә балалар театры төзү, балаларны сәхнәләргә чыгарып, алардан үз тормышларын уйнаттыру вә шулай итеп аларны киләчәккә хәзерләү бик әһәмиятле бер эш булса кирәк.

Менә шуларны игътибарга алып, Ташкенттагы «Балалар иртәсе»ндә дә кечкенә генә бер пьеса куелды. Бу пьесаның бөтен рухы өч балада гына. Менә шул балалар ролен уйнаучылар русча-татарча ирләр мәктәпләренең ике шәкерте вә кызлар мәктәбенең бер шәкерте, көтелмәгән дәрәҗәдә оста вә килешле уйнадылар. 9 белән 12 яшь арасында булган бу өч баланың сәхнәдә табигый вә бер дә аптырамыйча кыланышлары, ачык итеп сөйләүләре тамашачыларны хәйран калдырды. Уен беткәч, халык зал яңгыратып кул чаптылар, уйнаучы балаларны ике-өч кат сәхнәгә чыгарып алкышладылар.

Балалар өчен алдагы рәтләрдә, ханымнар өчен уң якта аерым урыннар хәзерләнгән вә бөтен зал халык белән шыгрым тулган Ташкент мөселманнарының иң олуг түрәләре, иң зур байлары да хатын-балалары берлән килгәннәр иде.

Бу «балалар иртәсе» русча-татарча мәктәпнең мөгаллимнәре, кызлар мәктәбенең бер-ике мөгаллимәсе тарафыннан кузгатылган бер эш булып, аларга да Ташкентның иң могътәбәр[56] затлары булышлык иттеләр. Иртәнең мәсъүл[57] мөдире Диваев җәнабләре[58] бик зур хезмәтләр күрсәтте, зур гына түрәләрдән саналган бу затның армый-талмый эшләве, иң мәсъүлиятле вә иң авыр эшләрне булдырып чыгаруы шаян[59] тәхсиндер[60].

Еникиева, Диваева, Яушева, Әмидова, Илькина, Богданова ханымнар үзләреннән барлык нәрсәләрен китереп, буфет төзеделәр дә, шунда бик тырышып хезмәт иттеләр.

Гимназиядә укучы яшьләрдән Байбурова, Яушева, Ягъкубова, Бәхтиярова, Ишаева, Абызгилдина ханымнар, төрле чәчәкләр белән бизәкләгән бик

---

[56] Могътәбәр – хөрмәтле, зыялы, затлы.

[57] Мәсъүл – җаваплы, соралган.

[58] Фаразлавыбызча, сүз мәгърифәтче, галим, Ташкентта беренче үзешчән театрга нигез салучы, татар мәктәбе мөдире Әбүбәкер Диваев (1856–1932) турында бара.

[59] Шаян – лаек, яраклы, тиешле дәрәҗәдә.

[60] Тәхсин – мактаулы эш.

матур программалар хәзерләп, шуларны сатып йөрделәр, тамашачы ханымнар арасында тәртип саклауга хезмәт иттеләр. Бу ханым вә туташларның шундый олуг хезмәтләре вә изге бәйрәмемез хөрмәтенә ясалган кадерле балалар иртәсендә кулларыннан килгән чаклы ярдәмдә булулары безнең өчен фәүкылгадә[61] күңелле бер эш булды. Алар бу эшләре берлән үзләренең аңлы вә ачык фикерле, гали тойгылы татар кызлары икәнлекләрен вә киләчәктә сызганышып хезмәт итәргә хәзер булдыкларын күрсәттеләр.

Бу ханым вә әфәнделәрнең хезмәтләрен күргән вакытта күздән яшьләр килә иде. Аларның бу хезмәтләренә әһали[62] тарафыннан никадәр тәшәккер кылынса да, аздыр.

*«Вакыт», 1915, 27 гыйнвар.*

## Гайшә ханым мәктәбендә Мәүлид

«Тормыш»ның үткән номерларыннан берсендә Уфа имамнарының әүвәлге карары буенча остазбикә Гайшә ханым Абызгилдина җәнабләре идарәсендәге кызлар мәктәбендә якшәмбе көн кич Мәүлид бәйрәме ясалачагы язылган иде. Хәзрәтләрнең карары алмашыну сәбәпле, мәзкүр[63] мәктәптәге Мәүлид кичәсе дә дүшәмбе көнгә күчерелгән. Мәүлид кичәсе кичке сәгать 5тә башланачак. Тыңларга теләүчеләрнең шул вакытка рәхим итүләре үтенелә.

*«Тормыш», 1916, 3 гыйнвар.*

## Тукай кичәсе

Ханымнар җәмгыять хәйриясе карамагында булган 3нче мәхәлләдәге кызлар мәктәбендә милли шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев вафатына 3 ел тулу мөнәсәбәте илә Тукай кичәсе ясалды. Шагыйрьнең шигырьләре укылып, рухына догалар кылынды.

*«Тормыш», 1916, 3 апрель.*

***Ф.Сөләймания***

## Уфа хатирәләре

Уфа шәһәренә килү берлә, иң әүвәл минем күземә чалынган нәрсә ничә мөфтиләргә мәкам[64] булган эшлекле Екатерина ханым[65] тарафыннан тәэсис кылынган[66] иске Рухани собрание бинасы берлә, әүвәлдә казыйларга махсус булган иске йортлар булды. Бу иске биналар минем күңелемдә иң тирән серләр калдырган иске хатирәләрне исемә төшереп, ирексез мине мазыйга[67]

---

[61] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[62] Әһали – кешеләр.
[63] Мәзкүр – әйтеп үтелгән, югарыда әйтелгән.
[64] Мәкам – урын, дәрәҗә, торган урын.
[65] Патшабикә Екатерина II.
[66] Тәэсис кылу – төзү, оештыру.
[67] Мазый – үткән.

кайтып, уйланырга мәҗбүр итте. Бу фәнага[68] йөз тоткан иске биналар эчендә кемнәр тормаган, нинди генә вакыйгалар булмагандыр дисең. Хәзерге көндә алар үткән гомерләрен, эчләрендә торган кешеләрен сагынып, моңланып утыралар төсле. Әнә без торган флигельдә бер вакытларда эчендә тулып, гөрелдәп утырган кунаклар, Хәлил казыйның тантаналы мәҗлесләрен сагынып тавыш-тынсыз гына моңаеп утырган төсле. Шулай шул, бу дөньяга кемнәр килеп, кемнәр китмәгән дисең.

Уфа шәһәре, бездән соңгы егерме биш ел эчендә күләме бераз зурайса да, шәрыклыктан һаман да чыгып йитә алмаган. Трамвай юк, извозчиклар бик аз, бары да бик начар, урамнар гаять пычрак, баткак, урам аркылы чыкканда аяктан калуш төшеп кала, апрель булса да, урам читләрендә, хосусый Собрание янында, Каф тавы кадәр кар өелеп, урамны пычратып ята. Ләкин Уфа мөселманнарының милли хезмәтләре, милли алга омтылулары, мәктәп-мәдрәсәләренең тәрәккый итүе[69], һөнәр мәктәбендәге кечкенә генә татар балаларының эшләгән искиткеч гүзәл эшләре Уфаның бу кимчелекләрен капларга йитәрлекдер. Бу сәфәрдә минем иң артык нәзар[70], дикъкатемне җәлеп иткән нәрсә – Уфа мөслимәләрендәге хәрәкәт вә фәгалиять[71], кызларга махсус мәктәпләрнең күплеге, аларга бик зур әһәмият бирелү, хосусән[72] мөхтәрәмә Мәрьям ханым Солтанованың армый-талмый милли хезмәтләр артыннан йөрүе, шул юлда үзенең бөтен рәхәтен фида итүе[73] булды.

Икенче апрельдә мәрхүм Тукаевның вафатына 3 ел тулу мөнәсәбәте берлә ханымнар җәмгыяте тарафыннан ачылган кызлар мәктәбендә Мәрьям ханым вә мөгаллимә Марзия туташның иҗтиһады[74] берлә балалар кичәсе ясалып, мин дә шул кичәдә хазир булдым[75].

Бөтен зал төрле чәчәкләр, төрле төстәге фонарьләр берлә зиннәтләнгән, Тукаевның рәсеме берлә берничә шигырьләре язылган зур картина гаять гүзәл чәчәкләр берлә бизәлеп, стенага куелган булып, бүлмәгә аерым бер матурлык, башка бер рух биргән иде.

Мөхтәрәмә Марзия туташ тарафыннан ачылып, әүвәл укучы кызлар хәтем иткән[76] кәлям шәриф[77] Тукаев рухына багышланды. Соңра мөгаллимә Марзия туташ гаять гүзәл нотык сөйләп, Габдулла әфәнденең тәрҗемәи хәлен укыды. Аның артыннан Абруй ханым гаять мөәссәр[78] көй берлән Тукаевның

[68] Фәна – юкка чыгу, бетү.
[69] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.
[70] Нәзар – игътибар.
[71] Фәгалиять – эшчәнлек.
[72] Хосусән – аеруча, аерым алганда.
[73] Фида итү – үз-үзен аямыйча чын күңелдән эшләү; берәр максатка ирешү өчен үзен корбан итү.
[74] Иҗтиһад – тырышлык кую, тырышу.
[75] Хазир булу – катнашу.
[76] Хәтем итү – Коръән уку.
[77] Кәлям шәриф – кадерле сүзләр.
[78] Мөәссәр – йөрәгенә үтеп кергән.

берничә шигырьләрен укыды, аннан соң укучы кызлар тарафыннан берәм-берәм дә, хор берлә дә Тукаевның мәкамгә[79] муафыйк[80] шигырьләре укылып, кечкенә курчак шикелле генә кызлар тарафыннан кыска гына, матур гына нотыклар сөйләнде. Соңра, бер кечкенә кыз күбәләк булып чыгып, «Күбәләк»[81] җырын бик матур итеп җырлады. Кичә гаять күңелле булып, татар кызларының татар шагыйрене искә төшереп, аны чын күңелдән ихтирам итүләре күңелгә әллә нинди шатлыклар биреп, киләчәккә зур өметләр уятты.

Яшәсен Уфа ханым вә туташлары, яшәсен милләт анасы Мәрьям ханым! Мәҗлескә ханым вә туташлар бик күп җыелган, чәй өстәле дә ханымнар вә мөгаллимәләр тарафыннан гаять гүзәл тәртип кылынган иде. Марзия туташ мәрхүм мөфти хәзрәтнең якын кардәше булып, Мәрьям ханым Солтанова тәрбиясендә торып, Гайшә ханым Абызгилдиновадан гүзәл тәхсил күргән[82] гаять тәрбияле, сөйкемле, гыйлемгә ихласлы, эшендә иҗтиһадлы, чын мәгъ-нәсе берлә мөгаллимә булып, бөек фамилиядә тәрбия күргәнлеге һәрбер кыланышыннан күренеп тормактадыр.

Мәрьям ханым атнада бер көн ханым вә туташлар өчен уку кичәсе ясарга тиешле урыныннан рөхсәт алган. Моннан соң һәр атнада истибдад[83] заманында укый алмый калган ханымнарга гүзәл мәгълүмат бирәчәкләр. Шуның кеби файдалы эшләр Казан шәһәре кеби мөселманнары гаять күп булган, хатын-кызлары җәһаләттә[84] калып, әхлаклары бозылган шәһәрдә бигрәк тә эшләнергә кирәк иде. Ни эшлисең, тәәссефкә каршы[85] Казан ханымнары тирән вә татлы йокыларыннан уяна алмыйлар шул әле.

*«Сөембикә», 1916, №13, б.227–228.*

## Мәүлид мәҗлесләре вә Тагиевның бөек иганәсе

Соңгы елларда мәүлид ае Русия мөселманнары арасында да ислам мәмләкәтләрендә каршы алынган кебек каршылана башлады. Мәүлид ае керү илә Коръән укыту, хәтем кылдыру[86], Мәүлид эн-Нәби мәҗлесләре ясау баш-лана. Бөтен мәктәп вә мәдрәсәләрдә шәкертләргә бу айның әһәмияте вә кадере аңлатыла. Мәүлид эн-Нәби көннәрендә мәктәпләр, мәдрәсәләр төрле төстә флаглар, фонарьлар вә чәчәкләр илә зиннәтләнә. Гыйльми вә әдәби мәҗлесләр ясала. Бу мәҗлесләрдә сөйләнгән сүзләр, укылган хотбә[87], шигырь һәм сала-ватлар тыңлаучыларның күңелләрендә тәэсир калдыралар. Ислам мәм-

[79] Мәкам – көй, мотив.
[80] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[81] Г.Тукайның «Бала белән күбәләк» шигыренә язылган җыр.
[82] Тәхсил күрү – гыйлем алу.
[83] Истибдад – чикләнмәгән власть, абсолютизм.
[84] Җәһаләт – наданлык, аң-белемсезлек.
[85] Тәәссеф – үкенечкә каршы, кызганычка каршы.
[86] Хәтем кылу – Коръәнне укып чыгу.
[87] Хотбә – вәгазь.

ләкәтләрендә бу ай күптәннән шулай каршы алына. Фәкать анда бу хәл гадәти бер мәрасим[88] хәленә кереп киткәнлектән, тәэсире мәхдүд[89] бер даирәдә була. Әмма Русия мөселманнары арасында яңа бер эш булганлыктан, фәүкылгадә[90] бөек тәэсир калдыра. Билхасса[91] кызлар мәктәпләрендә ясалган мәүлид мәҗлесләре илә әдәбият кичәләре бик зур тәэсир калдыралар. Бу мәҗлесләргә шәһәрнең яки авылның гыйлем вә мәдәнияткә ихласлы һәммә хатын-кызлары җыела. Бонларга мөгаллимәләр тарафыннан, мәҗлесләрдә Мәдинә яки Мисыр кариэләре[92] тарафыннан укылган кебек үк, моңлы вә матур мәкамнәр[93] белән гарәпчә «Мәүлид» укыла. Шәкерт-кызлар тарафыннан кушылып хор белән, яки берәм-берәм милли шигырьләр укыла. Мәҗлес ахырында ислам дөньясында килгән мәшһүр хатын һәм ирләрнең тәрҗемәи хәлләре сөйләнеп, дин вә милләтнең тәрәккый[94] вә тәгалисе[95] юлында хезмәт итүгә юллар вә үрнәкләр күрсәтелә. Хөласа[96], бу мәҗлесләр шулкадәр яхшы вә матлуб[97] бер рәвешкә кереп баралар ки, бонларның тирән бер тәэсир калдырачагында шөбһә юкдыр. Шуның өстенә, бу айда ясалган мәҗлесләрнең мәктәп вә мәдрәсә һәм җәмгыять дөньясына матди җәһәттән дә бик зур файдалары бар. Һичбер мәктәп яки мәдрәсә юктыр ки, анда Мәүлид ән-Нәби мәҗлесе ясалып, мәктәп, мәдрәсә яки мөгаллим вә мөгаллимә файдасына могыйн[98] бер микъдар иганә ителми калсын. Элек бу акчалар вак-төяк сәдака сурәтендә генә җыела иделәр. Соңгы елларда мөһим бер сурәт алдылар. Мәүлид мәҗлесләренең күбесендә мәктәп яки мәдрәсә файдасына вакыф ясар өчен зур-зур сәрмаяләр[99] җыела башлады. Мәсәлән, бу ел Чиләбедә Мәүлид мөнәсәбәте илә ясалган бер мәҗлестә кызлар мәктәбе салыр өчен 60 мең сум кадәр иганә бирелгән. Бакуда мөслимәләр җәмгыяте тарафыннан ясалган мәҗлестә 4 мең сум иганә булган. Мәүлид мөнәсәбәте илә ясалган галия бәйрәмендә бу мәдрәсә өчен Гыйбадулла әфәнде Госманов тарафыннан 20 мең сум иганә кылынганлыгы, Мәскәү җәмгыяте әгъзаларыннан 10 мең сум иганә булганлыгы, бәйрәм мәҗлесендә һәм ун мең сумнан артык иганә бирелү хәбәре булды. Шуның өстенә, быел Бакуда бу мөнәсәбәт илә тагын да шаян[100] зикер[101] бер мәҗлес булды. Сафа җәмгыяте илә Дагыстан һәм Дахили Русия[102] мөселманнарының җәмгыятьләре тарафыннан

[88] Мәрасим – рәсми мөгамәләләр.
[89] Мәхдүд – чикләнгән.
[90] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[91] Билхасса – атап, төбәп, махсус рәвештә.
[92] Кариэ – укучы.
[93] Мәкам – көй, мотив.
[94] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[95] Тәгали – бөек булу, бөекләнү.
[96] Хөласа – нәтиҗә.
[97] Матлуб – көтелгән, таләп ителгән.
[98] Могыйн – ярдәмче, ярдәм итүче.
[99] Сәрмая – акча, капитал.
[100] Шаян – лаек, яраклы, тиешле дәрәҗәдә.
[101] Зикер – искә алу, искә төшерү; телгә алу, әйтеп узу.
[102] Дахили Русия – Эчке Россия.

гомуми бер күрешү мәҗлесе ясалып, Бакуда булган бөтен Кавказ, Русия һәм Дагыстан мөселманнарын берләштерә торган бер мәҗлес төзелде. Бу мәҗлес мөнәсәбәте илә Кавказның мәшһүр хәйрият ияләреннән Зәйналабдин хаҗи Тагиев җәнабләре мәзһәб[103] аермасыннан башка бу җыелышта булган Кавказ, Дагыстан вә Дахили Русия мөселманнарына мәсҗет салыр өчен 150 мең сум иганә кылды. [...]

*«Вакыт», 1917, 6 гыйнвар.*

## Юлык авылында

Оренбург губернасы Юлык авылында[104], Гәүһәр ханым Рәмиева тарафыннан тәрбия ителмәктә булган кызлар мәктәбендә тантаналы Мәүлид мәҗлесе ясалып, мәҗлестә 300 кадәр ханым вә туташлар булганлыгын, гыйльми нотыклар вә милли шигырьләр укылып, бик яхшы тәэсир калдырганлыгын бәян итеп, бу мәҗлесне ясаучыларга тәшәккер[105] бәян итеп язалар.

*«Вакыт», 1917, 27 гыйнвар.*

---

[103] Мәзһәб – дин, бара торган юл.
[104] Юлык авылы – хәзер Башкортстанның Баймак районына карый.
[105] Тәшәккер – рәхмәт сүзе.

# IV БҮЛЕК

# «ГАЛИМ ВӘ МӨГАЛЛИМНӘР ХАЛЫККА БЕЛЕМ, ФИКЕР ВӘ РУХ БИРСӘЛӘР, МАТДИ КУӘТНЕ БИРҮЧЕ – ГАДИҺӨНӘРЧЕЛӘРДЕР»

Кызлар мәктәпләрендә кул һөнәрләре өйрәтү,
хатын-кыз һөнәр мәктәпләре, курслар һ.б.

## Фатыйха ханым Аитова мәктәбе

Бу елгы җәйне ике сыйныфта 80 кадәр кыз баланың укып имтихан биргәнлекләре гәзитәмездә язылган иде. Хәзер Фатыйха ханым кызлар өчен шушы мәктәп бинасында кул эше өйрәтү өчен җәйге курслар ачмакчы. Бу курсларга Казанның кызлар гимназиясендәге кул эше мөгаллимәләреннән берәрен алмакчы булып торадыр. Һөнәр өйрәтү кышын мәктәптә укыган шәкертләр өчен генә махсус булмаенча, һәр теләгән кыз бала кабул ителәчәктер. Хәле йиткәннәрдән бу дәресләр өчен акча алынса да, фәкыйрь балалар буш өйрәтеләчәк. Шул ук мәктәп хозурында бер китапханә булындырып, татар телендә басылган һәрбер китапны алып, анда кую фикере дә Фатыйха ханымда бар. Ул китапханә дә тиздән ачылачак. Китап бары хатын-кызга гына биреләчәк.

*«Вакыт», 1910, 29 май.*

## Кызлар өчен һөнәр мәктәбе

«Йолдыз»ның хәбәренә күрә: Казанда Фатыйха бикә Аитова тарафыннан ачылган кыз балалар мәктәбендә җәй буенча, өч ай, кырыклап кызга тегү һөнәре өйрәтелгән. 15 ләбе калмый йөреп, тәкмил иткәннәр[1]. Көн дә килә алмаганнары хәзер тәкмил итәчәкләр. Бу мәктәптә кыш көне дә дәресләрдән соң кул һөнәрләре өйрәтеләчәктер.

Фатыйха бикә үзе һәркөн мәзкүр[2] мәктәпкә килеп, нәзарәт итеп[3] йөрмештер.

*«Вакыт», 1910, 14 сентябрь.*

---

[1] Тәкмил итү – тәмам итеп бетерү.
[2] Мәзкүр – әйтеп үтелгән, югарыда әйтелгән.
[3] Нәзарәт итү – карау, тикшереп тору.

## Кызлар өчен кул һөнәрләре

Бер «фәкыйрь ата» идарәмезгә мөрәҗәгать итеп, кыз балаларга кул һөнәрләре өйрәтү мәсьәләсенә дикъкать итүемезне үтенде. Сүзенә күрә:

Бу ата үзенең мәктәптәге кызларына, дин вә дөнья гыйлемнәреннән тыш, кул һөнәрләре дә белдерергә тели. Мөгаллимә дә бу җәһәткә[4] хәйли[5] игътибар кылып тырыштыра.

Фәкать «фәкыйрь ата»ның күңеле шатланырлык нәтиҗә күрелми. Чөнки кызларын чолгау-чалма яулыгы, сөлге башы чигәргә өйрәтәләр, кружево ясаталар.

Бу нәрсәләр, бердән, «фәкыйрь ата» кесәсенә сизелерлек кыйммәт төшә. Икенчедән, ни кызларның үз киләчәкләрендә, ни хәзер, бөтен гаилә өчен һич матди файдалары юкдыр. Чөнки сандыкларга тутырып, кияүгә киткәнче, дуамал асрарга калалар.

Хәлбуки[6], бонлар урынына күбрәк оек бәйләү, тегү кебек һөнәрләр өйрәтсәләр, фәкыйрь кызлар боның илә кәсеп кыла, гаиләләренең тормышын җиңеләйтә, яки үзенә придан хәзерли алырлар иде. Бонлар һәр көн акча китерә торган эшләрдер.



Яшь туташлар кул эше белән шөгыльләнә *(«Сөембикә», 1914, №15)*

[4] Җәһәт – як, тараф.
[5] Хәйли – байтак, шактый күп.
[6] Хәлбуки – ләкин.

* * *

Соң чакларда мөселманнардан тиешле тегүче юклыкка да зарлана башладылар. Мөселман тегүчеләренә эш киткән саен ваклана бара, рәтлерәк итеп вә яхшы нәрсәдән тектерергә теләгән кеше яһүд хозурына барып, мәсәлән, тройкага 12–15 сум түләргә мәҗбүр була. Болай кыйммәт түләү халкымыз өчен бер зыян булса, элек мөселман тегүчеләренә бирелә килгән киемнәрнең хәзер яһүдләргә ычкынуы икенче бер зыян. Бу шактый исәпли торган мәсьәләдер.

Истигъдадлы[7] яшь тегүчеләремезне тегү мәктәпләренә яки яхшы мастерскойларга йибәреп, мөлкәт хасыйл иттереп кайтарылса, мөселманнарның икътисади хәле күтәрелергә шактый файдасы тимәсме икән?

Японнар үзләренең тәрәккыятьләре[8] өчен чит дарелфөнүннәргә[9] барып уку илә генә кифаяләнмәгәннәр[10], бәлки читкә кешеләр йибәреп тегүчелек, тимерчелек, сәгатьчелек вә әмсал[11] һөнәрләр өйрәтеп кайтаралар. Галим вә мөгаллимнәр халыкка белем, фикер вә рух бирсәләр, матди куәтне бирүче – гади һөнәрчеләрдер.

*«Вакыт», 1911, 29 март.*

***«Вакыт мохбире»***

**Кызларга кул һөнәрләре өйрәтү**

Богырыслан өязе Иске Котлумбәт авылындагы[12] ибтидаи[13] мәктәптә 23 кыз укый. Бонлар гомуми дәресләрдән тыш оек (носки), ашъяулык (эскәтер), прошивка, кружево бәйләү, төрле нәрсәләр кисү, машина илә тегү кеби төрле кул эшләренә өйрәнәләр.

Элгәре сагыз чәйнәүдән башка эш белмәгән кызлар бүген һәр төрле рисунокларда эскәтер бәйлиләр. Кул һөнәре атнага ике кат (һәр дүшәмбе вә пәнҗешәмбе) өйрәтеләләр. Кызларны өҗрәтсез[14] уларак ике рус ханымнары өйрәтәләр. Бере Мөселман бурыч җәмгыятенең кятибәсе[15] Евгения Краснова, икенчесе Дәфгы ихтыяҗ[16] җәмгыятенең кятибәсе Юстина Курничковадыр. Беренче уларак бер зур эскәтер бәйләп бетереп, мәктәп назыйрына[17] тапшыручы икенче сыйныф шәкерте Зөбәйдә туташ Сафиулла кызы Сәйфуллина

[7] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.
[8] Тәрәккыять – алга китү, прогресс.
[9] Дарелфөнүн – югары уку йорты, университет.
[10] Кифая – җитәрлек, кирәк кадәр булу.
[11] Әмсал – мисаллар.
[12] Иске Котлумбәт авылы – хәзер Оренбург өлкәсе Переволоцкий районына керә.
[13] Ибтидаи – башлангыч.
[14] Өҗрәт – эш хакы, хезмәт хакы.
[15] Кятиб – секретарь.
[16] Дәфгы ихтыяҗ – ихтыяҗны бетерү (ярдәм итү)
[17] Назыйр – мөдир.

булды. Мәктәп идарәсе аңа афәрин укыды. Мәктәп назыйре мулла Ибраһимов балаларның кул эшләренә өйрәнүләренә аерым әһәмият бирәдер.

*«Вакыт», 1912, 3 гыйнвар.*

## [Иркутскида...]

Иркутскида имам Габидулла әфәнденең тырышуы илә бу сәнә июнь башыннан мөселман кызларына махсус русча курслар ачылган. Барысы 19 кыз укыйдыр.

Габидулла әфәнденең көзгә мөселман кызларына махсус кисү-тегү кебек эшләрне өйрәтер өчен «Ручной труд» ачарга йөрдеген хәбәр итәләр.

*«Сибирия», 1912, 29 июль.*

***Фатыйма-Фәридә***

## [Хатын-кызга бер дә права бирмәенчә...]

Хатын-кызга бер дә права бирмәенчә, өйдә генә ябып яткырганда да, алар бик күп нәрсәне белергә мәҗбүрдерләр. Өйнең бөтен тәрбиясе: ашарга-эчәргә хәзерләү, кисү-тегү кеби эшләр хатыннарның иң беренче вазыйфалары булганга, шул һөнәрләр хакында махсус кагыйдәләрне белмәгән бер хатын ана исемен алырга, йортны идарә кылырга лаек түгелдер. Безнең аналарымыз кызларны үз яннарында булыштырып, яшьтән үк югарыда сөйләнгән эшләрне гамьле рәвештә өйрәтсәләр дә, бүгенге хәлләрнең үзгәрүе сәбәпле, аналарымыз өйрәткән эшләр илә генә канәгатьләнерлек түгелдер.



Фатыйма-Фәридә
*(«Сөембикә», 1914, №12)*

Әүвәлдә майның кадагы 15 тиен, ит 5 тиен, он поты бер сум улган вакытта пешергән ашларны хәзер ул вакыттагы форма илә пешереп булмый. Иң беренче кирәкле нәрсәләрнең бәһасе үзгәрү илә ашларымыз да үзгәрәдер. Әбиләремез, аналарымызның өйрәткән юлы илә генә пешергәндә, без бу көндә күп мәсарифка[18] дучар булырга тиешдер. Шуның кеби тегү эшендә дә әүвәлге күлмәкләремез артык сырлы булганга, аналарымыз өйрәткәнчә тегеп кия аладыр идек. Хәзер ул күлмәкләр ташланып, Яурупа модасы илә киенә башладык.

[18] Мәсариф – тотылган акчалар, чыгымнар.

Хәлбуки[19] Яурупа модасы илә күлмәк тегәр өчен үзенә махсус тегү гыйлеменә өйрәнергә кирәк, юкса үземез тегәмез диеп, белер-белмәс яурупача тегеп маташсак, материя әрәм итүдән башка эшкә ярамаячактыр. Шуның өчен игътибарсыз киемнәремезне маржага биреп тектерергә, һәрбер күлмәккә биш-алты сумнарымызны маржага биреп, болай да тар булган икътисади хәлемезне тагы да тарайтырга мәҗбүр буламыз. Алай итмәс идек, безнең дә кеше төсле киенәсемез килә, үземез тегә белмимез. Татардан тегүче юк.

Безнең аз-маз ачылган кызлар мәктәпләрендә кул һөнәре дия бәйләү, чигү кеби һөнәрләр өйрәтелсә дә, бу да әсаслы[20] түгелдер. Кисү-тегү кеби эшләребез дә өйрәтелмәгәнгә, мәктәпләремез бу ихтияҗымызны тутыра алмыйлар (Казанда Фатыйха ханым Аитова идарәсендәге мәктәптә кисү-тегү һөнәрләре өйрәтелсә дә, бондыйлар бик аздыр).

Хатын-кызны сәфаләттән[21] коткару өчен аларны һөнәргә өйрәтү бик тиештер. Ләкин без хәзер никадәр тырышсак та, үземез мондай һөнәр мәктәпләрене максадымызга муафыйк[22] итеп тиз ача ала алырмыз диеп уйлый алмыйм. Җәмгыятьләремез, булса ир балалары өчен дә, әллә никадәр газапланганнан соң гына берәр мастерской ача алалар. Шуның өчен үземез ачканчы яисә ачканны көтеп ятканчы, ватандашларымыз руслар тарафыннан ачылган шундай мәктәпләргә кереп, үземезнең белемемезне арттыру, икътисади хәлемезне яхшырту чарасына керешү бик тиештер. Мондай һөнәр мәктәпләре күп шәһәрләрдә була.

Безнең Томскида 1905нче елда шәһәр идарәсе тарафыннан Себердә беренче мәртәбә мөкәммәл[23] һөнәр мәктәбе ачылмыштыр. Бу мәктәпкә бер класслы мәктәптә имтихан биргән, русча шәһадәтнамәсе[24] булган кызларны кабул итәләр. Уку мөддәте[25] 3 ел булып, кисү-тегү, бәйләү-чигү, рәсем кеби кул һөнәрләреннән башка гомуми фәннәрдән – рус теле, хисап, кәсер гади[26], кәсер әгъшари[27], физика, тарих, җәгърафия, отчетоводство кебек мөһим булганнарны укыталар. Дин, милләт аермасына карамый, һәрбер 11 яшьтән ким булмаган бала кабул ителәдер. Хакы бары айга 1 сум улып, рәсем өчен янә 3 сум алынадыр.

Ибтидаи[28] мәктәп бетерүенә шәһадәтнамәсе булмаса, яисә бары һөнәр генә өйрәнергә теләсә, дүртенче курска курсистка исеме илә кабул ителеп, бер елда мөкәммәл рәвештә кисү-тегү һөнәре өйрәтеләдер. Боның хакы елга

[19] Хәлбуки – ләкин.
[20] Әсас – нигез, база.
[21] Сәфаләт – хурлык, түбәнлек.
[22] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[23] Мөкәммәл – камилләшкән, төгәлләнгән.
[24] Шәһадәтнамә – таныклык язуы, диплом.
[25] Мөддәт – ара, вакыт.
[26] Кәсер гади – гади вакланма.
[27] Кәсер әгъшари – унарлы вакланма.
[28] Ибтидаи – башлангыч.

30 сум. 15 сумны мәктәпкә кергәндә бирергә кирәк. Метрический сведениедән башка документ кирәкмидер.

Бу мәктәп махсус фәкыйрь халыкка ярдәм булсын, алар тиешле һөнәрне өйрәнеп, башкаларга мохтаҗлыктан котылсыннар өчен тәэсис ителгәнгә[29], безнең мөселман кызларына бу мәктәптән файдалану бик тиештер.

Безнең йорт анасы булырга теләгән кызларымызга шул югарыда яздыкым һөнәрләрне өйрәнми һич мөмкин булмаганга, ихтыяҗ вакытында идән юучы, көрәүче булганчы, үзенең энәсе илә көн күрсә, тагы да яхшы булачактыр. «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми», бабаларымызның сүзедер.

*«Сибирия», 1912, 19 август.*

***Мәрьям Ягъкубова***

**Кызлар мәктәбендә кул эшләре**

Хәзерге көндә кай йирләрдәге кызлар мәктәбе програмын күрергә тугры килсә, мотлакан[30], програм арасына кул эшләре һөнәре кертелгәне күреләә. Әмма бу идарәи бәйтиягә[31] даир[32] иң мөһим сәнәгать[33] улдыгы хәлдә, чынлап өйрәтелми. Безем мәктәпләремездә өйрәтелмәктә улган: бәйләү, чигү (гладью), шитье, строчка кеби һөнәрләрне тәшрих кылып[34] караган вакытта, боларның вакыт заегъ итүдән[35] башка һичбер файдасы күренми. Мәсәлән: мәктәптәге бер ханым строчка илә бер тастымал башын аз дигәндә бер атна эшли, әсбабын сатып ала, шуңа вакытын сарыф итеп, башка дәресләренә зарар итә. Хәлен ки, шуның әзерен сатып алса, моңарга чыккан әсбабның хакын гына бирә. Баягы бер атна вакыты файдага кала. Бу кеби һөнәрләр укыган вакытта, һөнәр өйрәнү җәһәтеннән файдалы кеби күренсәләр дә, ана булгач, андый вак-төяк – бәйләү, чигүләр илә шөгыльләнергә вакыт тапмый, киләчәктә ихтыяҗга төшкән вакытта, ул һөнәрләр илә мәгыйшәткә[36] һичбер файда китерә алмый. Шуның өчен кызлар мәктәбендәге бәйләү-чигү кеби һөнәрләрне түбән сыйныфларда кул күндерер өчен генә өйрәтелеп, зуррак сыйныф талибәләренә кисү-тегү һөнәре өйрәтелсә, гаилә арасына керәчәк ханымнарымызга матди[37] зур файдасы булыр иде. Хәзерге көндә күп ханымнарымызның өйләрендә тегү машиналары була торып, мөкәммәл тегү тәртипләрен белмәдекләреннән, рус модисткаларына акча әрәм итүләре ханымнарымызның иң файдалы һөнәрдән мәхрүм идекләрен ап-ачык күрсәтә. Шуңа күрә, мәктәпләремездә бу көннән үк тегү эшләре мөкәммәл сурәттә өйрәтелә

[29] Тәэсис ителү – төзү, оештыру.
[30] Мотлакан – һичнәрсәгә карамастан.
[31] Идарәи бәйтия – йорт, хуҗалык эшләре.
[32] Даир – бәйләнешле.
[33] Сәнәгать – һөнәрчелек.
[34] Тәшрих кылу – ачыклау.
[35] Заегъ итү – бушка, файдасызга үткәрү.
[36] Мәгыйшәт – көнкүреш, тормыш.
[37] Мадди – матди.

башласа, әллә безнең мөселман ханымнары да модисткаларга әрәм була торган акчаларын кесәләрендә калдырып, гаилә өчен файдалы кешеләр булып йитешерләр иде. Караңгы көнгә төшкән вакытларында да йиңеллек берлә котылырга иде. Дөрест, русларның кул һөнәрләре мәктәпләре булса, бәйләү-чигү кеби һөнәрләр безгә дә зарар итмәс иде. Шулар илә бергә тегү һөнәрләре дә өйрәтелер иде. Әмма бездә андый мәктәпләр кайда?

Алма-Ата.

*«Сибирия», 1913, 16 гыйнвар.*

***Г.Хатый***

**Малмыжда мөселман кызлар өчен һөнәрханә**

Мәгариф мөхәррирләремездән берсе татар галәмен паралич сугып, ярты як әгъзалары хәрәкәтсез калган ма фалиҗ[38] кешегә охшаткан иде. Ягъни безнең яртыбыз булган хатын-кыз галәме эшсез, хәрәкәтсез ята; мәгыйшәт[39] мәйданында икенче яртыбыз гына хезмәт итә, дигән иде. Хәзер инде бу сүзне бөтенләй кабул итәргә хаклы түгелмез; чөнки хатын-кызларымызның хәрәкәте вә алардан бер кисемнең гомуми хезмәт мәйданына омтылулары инде күз алдымызда. Ләкин шулай да күп йирләрдә мәзкүр[40] сүзнең хөкеме бакый[41] әле. Безнең Малмыж өязе дә шул җөмләдән...

Бездә хатын-кыз хәяте бөтенләй юк диярлек. Кызларымызның бер кыйсеме[42] елның бер-ике аенда, иген эшләрендә ирләремезгә булышлык итәләр дә, калган вакытларны дүрт стена эчендә, эшсез сагыз чәйнәп уздыралар. Элеккеге заманнарда бер кыйсем авыл кызлары, кышның озын көннәрен җеп җегерләү, киндер сугу ... кеби кул эшләре белән уздыралар иде һәм бу аларга яхшы табыш та бирә иде. Ләкин соңгы вакытта гайре мөтәнаһи[43] фабрика вә заводларның тәкъдим итдекләре төрле материялар ул һөнәрне дә бик әһәмиятсез дәрәҗәгә төшерде, кызлар эшсез күренә башладылар. Аларның бөтен хезмәт вә мәшгулиятләре казан арулау, кашык-аяк жуу [...] тирәсендә генә калды.

Бу хәрәкәтсезлектә кызларымызны гаепләр хәл юк; чөнки татар кызы ялкау түгел, ул кулыннан килгәнен һәрвакыт эшләргә хәзер. Мәсәлән, Түнтәр дигән авылда башка авыллардан алып кайтып бәгъзе бер кызлар мех теркәү белән шөгыльләнәләр. Алар көне буенча эшләп, 4–5 тиен акча хасыйл кылдыклары хәлдә, иренмичә эшлиләр, иртәдән кичкә кадәр шул эш белән утырып, шул әһәмиятсез «тиеннәр» белән булса да, авыр тормыш көрәшендә аталарына ярдәм кылалар.

---

[38] Фалиҗ – паралич.
[39] Мәгыйшәт – көнкүреш, тормыш.
[40] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.
[41] Бакый – калучы, калдык.
[42] Кыйсем – өлеш.
[43] Гайре мөтәнаһи – иге-чиге булмаган.

Менә шундый фидакарьлек күз алдында торганда, алар эшне сөйми, ялкау дип әйтергә тел бармый. Тик эшне белүче, белдерүче вә файдалы эшләрне башлап йибәрүче генә юк.



Малмыж шәһәрендә мөслимәләр өчен һөнәр мәктәбендә укучылар
*(«Сөембикә», 1914, №17)*

Хатын-кыз галәмендәге мәзкүр гаталәт[44], үзенең күп файдалы хезмәтләре илә бөтен тирә халкы тарафыннан сөелгән Мөхәммәткамал абзый Мозаффаровның дикъкатен җәлеп иткән иде. Ул моннан ике ел элек Малмыж земский управасына мөрәҗәгать итеп, мөселман кызларына махсус һөнәрханә ачылуын таләп кылды вә аның булышлыгы илә Малмыж земствосы «Ткацкая мастерская» исемендә мөслимәләр өчен бер һөнәрханә ачып бирде. Бу номер «Сөембикә»дә рәсемнәре дәреҗ ителгән[45] кызлар шунда укучы кызлардыр.

Һөнәрханәдә шәл, яулык, сөлге, ашъяулык, кием вә күлмәклек материяләр сугарга өйрәтәләр. Өйрәнүчеләр акча түләмиләр, хәтта бераз өйрәнгәч, эшләгән эшләре өчен земство үзе бераз акча бирә. Керер өчен русча белү, махсус образование-фәлән шарт ителми. Тик русча цифр белү вә үз исемен русча куя алу кадәр мәгълүмат та җитә. Һөнәрханә Малмыж земствосы тарафыннан булганга, анда керер өчен Малмыж өязе кызлары алда тотылалар, ягъни артык урын булганда гына чит өяз кызлары кабул ителәдер.

---

[44] Гаталәт – эшсезлек, эшсез тору.
[45] Дәреҗ итү – теркәү, эченә салу, арага кертү.

Өйрәнү мөддәте[46] өч ел. Өч ел укыган кызларга имтихан булып, шәһадәтнамә бирелә. Алар шунда ук һөнәрханәләрдә айга 25–30 сум кадәр вазыйфа белән мөгаллимәлек итә алалар. Мөгаллимәлек итәргә теләмәгән кызлар үз өйләрендә дә эшли алалар. Аларга земство сугу өчен кирәк булачак стан вә башка коралларны бирә вә эшләгән нәрсәләрен сатып алып торадыр.

Мәзкүр һөнәрханә инде ике ел дәвам итте, киләсе елда берничә кыз шуны тәмам итәчәкләр. Алар тәмам кылып чыгу илә, бәгъзе мөселман авыллары үзләренә шундый һөнәрханәләр ачып, мәзкүр кызларны мөгаллимә итеп куймакчы булып торалар. Шулай итеп, бу эшнең безнең якта әсаслы[47] рәвештә тәрәккый итүе[48] өмет ителмәктәдер.

Миңа алар эшләгән эшләрнең коллекциясен күрергә тугры килде. Эшләрнең ныклык вә матурлыгына тәгаҗҗеб иттем[49]. Сөяк вә кузналар тыгылып ясалган станнарда тупас киндер сугучы татар кызларының шундый нәфис материаллар хәзерләүләре хакыйкатән[50] дә күңелгә төрле өметләр бирәдер.

Хөласа[51]: кулында шундый һөнәре булган кызның бервакытта да мохтаҗлыкка төшмәячәген шуларның эшләрен күргәч тасдыйк иттем[52].

Бу мәкаләне «Сөембикә»гә язудан максатым – «Сөембикә» укучы ханымнарны Малмыждагы мәзкүр һөнәрханәгә дәгъва итү генә түгел; чөнки андагы гына урын, әлбәттә, күп булмас. Ләкин шундый һөнәрханәләр башка йирләрдә дә бармы? Аннан файдаланучы татар кызлары күпме? Менә шулар миңа мәгълүм түгелдер.

Булмаган йирләрдә Малмыж һөнәрханәсеннән үрнәк алсалар, гүзәл булыр иде. Минем максатым да нәмунә[53] күрсәтмәктер.

*«Сөембикә», 1914, №17, б.12–14.*

***З.С.***

**Беренче адым.**
**Оренбургта хосусый һөнәр мәктәбе**

Бу ел монда Маһирә ханым Гонних тарафыннан хосусый рәвештә рәсми булган кисү-тегү мәктәбе һәм модный мастерской ачылды. Мастерскоенда һәр сезонның үзенә муафыйк[54], соңгы мода буенча хатын-кызлар өчен төрле киемнәр: пальто, сак, костюм вә соң мода күлмәкләр тегәргә заказлар алына. Мәктәптә өйрәнер өчен, кирәк Оренбургның үзеннән, кирәк читтән, 12 яшьтән башлап шәкертләр кабул ителә. Маһирә ханым читтән килүче

[46] Мөддәт – ара, вакыт.
[47] Әсас – нигез, төп.
[48] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.
[49] Тәгаҗҗеб итү – гаҗәпләнү, ис китү, хәйран булу.
[50] Хакыйкатән – чынлыкта.
[51] Хөласа – нәтиҗә.
[52] Тасдыйк итү – раслау.
[53] Нәмунә – үрнәк.
[54] Муафыйк – яраклы, туры килгән.

шәкертләр өчен мәктәп алдында үз карамагында махсус пансион ачып, теләгән кешеләрне бөтен тәрбияләре берлә шунда торырга кабул итәдер. Курс тәмам итеп чыгучыларга, ибтидаи[55] мәктәпләрдә инспекторлар кул астында һөнәр мөгаллимәсе булу вә үзләреннән мастерской ачу өчен кулларына правалы шәһадәтнамәләр (свидетельстволар) биреләчәктер. Мәктәп бу җәһәте[56] берлә ханым вә туташларыбызның дикъкатьләрен үзенә тагын да ныграк җәлеп итәр дип күңелгә киләдер. Хәзер Оренбург вә әтрафыннан[57], хәтта Уфа, Пенза вә Ташкент якларыннан мәктәп хакында төрле мәгълүмат сорап, һәр көн хатлар килеп тора икән.

Маһирә ханым үзе башта Мәскәүдә кисү-тегү мәктәбе (Школа кройки и шитья) тәмам итеп, Нижний ремесленный управасы хозурында эшнең нәфислеге җәһәтеннән беренче дәрәҗә имтихан тотып диплом алган, вә шуннан соң байтак практикадан соң әлеге һөнәр мәктәбен ачкан. Мастерскойга заказлар килү вә мәктәпкә өйрәнер өчен шәкертләр язылу көтелгәннән шактый югары чыкканга, бу яңа эшнең яхшы юлга салыначагын вә мәктәпнең ханым вә туташларымыз арасында рәваҗ[58] табачагын күрсәтәдер. Изге сәгать!

Маһирә ханымның мөслимә кардәшләренә юлбашчылык итеп, бик вакытлы уларак бу яңа эшне башлавы, йөзләр вә меңнәрчә милләт акчасының, рус вә еврей мадамнарының кесәләренә агып, аларны баетуына бер ниһаять бирер[59] вә шул милли агымны икенче бер файдалырак якка борып җибәрергә сәбәпче булыр дип өмет итәдер.

*«Тормыш», 1914, 3 сентябрь.*

## Җәмгыятьләр җыены

25 мартта Уфа җәмгыять хәйриясенең гомуми җыены булды. Ничектер бу юлы халык бик күп җыелды. Байтактан бирле инде мондый фәүкылгадә[60] җыенда бу чаклы кеше җыелганы юк иде. Җәмгыятьнең гомуми җыеннарында күренми торган кешеләр күренде. Фәкать бу җыен бер эш өчен икенче мәртәбә җыелу иде. Моннан соң Уфа халкы беренче чакыруда ук шулай килергә өйрәнсеннәр иде инде.

Җыен Петербургтагы мөселман комитетының Уфа шөгъбәсен ачу өчен ясалган иде. […]

Моннан соң Уфа кызларына һөнәр өйрәнү мәсьәләсе мәйданга куелды. Байтак кеше хатын-кызның гади генә күлмәкләрне 6–7, хәтта 9 сум түләп руслар вә яһүдләрдән тектерүләреннән зарландылар. Ничек булса да,

---

[55] Ибтидаи – башлангыч.
[56] Җәһәт – юнәлеш.
[57] Әтраф – тирә-як.
[58] Рәваҗ – таралу.
[59] Ниһаять бирү – соңгы чик булу.
[60] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

тегүчеләрне үзебезнең татар кызларыннан йитештерүне тиешлеген сөйләделәр. Моның өчен махсус һөнәрханә ачу тугърысында ханымнар җәмгыяте белән килешеп, тиешле тәдбирләрен[61] күрергә идарәгә тапшырылды. Фәкать һөнәрханәне ялгыз кала кызларына кисү-тегү эшләре өйрәнүгә генә хасламыйча, монда сәрпинкә[62] вә башка материяләр тукырга (сугырга) да өйрәттерүне тиеш таптылар. Монда туку һөнәре өйрәнгән кызларны авылларга йибәреп, авылларда һөнәрне таратырга тырышу тиеш диештеләр. Авылларда бу һөнәр таралганда, аларны артель рәвешенә салынса, земствоның да ярдәм итәчәге сөйләнде.

Аннан соң мәсҗет алларында вә башка урыннарда саилчелек кылып[63] торучы татар кызларын җыеп, мастерскойларга бирергә карар бирелде. Боларның тәрбиясен җәмгыять үз өстенә күтәрәчәк булды. Каладагы бәгъзе бер яһүд мастерскойларының буш өйрәтергә алганлыкларын сөйләделәр. Хәзердән бу эшкә керешер өчен 6 кешелек махсус комиссия сайланды. Бу комиссиягә сайланучылырга Бәдретдин Нәзыйров, Нәбиулла Габидуллин, Шакир Зәйнуллин, ахун Гайнанов, Имаметдин Бәхтизин һәм Нургали Алмаевлар. [...]

*«Тормыш», 1915, 27 март.*

***Х.Латыйф***

**Мөселман авылында һөнәр өйрәтү**

Әстерхан вилаяте Новая Казанка (Яңа кала) авылыннан[64] язалар:

Могътәбәр[65] сәүдәгәрләремездән Галим Хәсәнов йортында 30 кадәр кыз балалар өҗрәтсез[66] кыш буе һәр көн өйләдән соң 2 сәгать кул эше өйрәнеп чыктылар. Өйрәтүчеләр үз кызлары: Фатыйха туташ илә мөгаллимә Маһипәрваз Хәсәнова ханымнар иде.

27 вә 28 март көннәрендә шул кызларның өйрәнгән һөнәрләре һәркемнең күз уңына куелды. Пәнҗешәмбе ханым вә туташларга, җомга көн ирләргә кереп күрергә рөхсәт иде. Карарга килүчеләр күп булды. Бу эшләрне күргән вакытта 9–10 яшьләр кызларымызның икътидарларына[67] хәйран калмаслык түгел иде. Һәр эше нечкә вә нәфис итеп эшләнгәннәр. Эчендә машина эшенә каршы торырлыклары бар. Төрле фасонда шәлләр, фуфайка, оек кеби эшләргә бигрәк тә әһәмият бирелгән. 25 төрле эш булып, кем тарафыннан эшләнгәнлеге вә күпме торганы һәркаюсының өстенә язылган иде. Фатыйха туташның үз тарафыннан эшләнгән нечкә вә нәфис пензенский шәл 25 сум тора диделәр. Авылымызда беренче мәртәбә баш калкыткан бу кул эшлә-

---

[61] Тәдбир – эшне ахырын уйлап эшләү, алдан күрү.
[62] Сәрпинкә – бик сирәк итеп тукылган җиңел мамык тукыма.
[63] Саилчелек кылу – теләнү.
[64] Жаңақазан – Көнбатыш Казахстандагы авыл.
[65] Могътәбәр – абруйлы, хөрмәтле.
[66] Өҗрәт – эш хакы, хезмәт хакы.
[67] Икътидар – кулдан килү, булдыра алу.

ренең күренеп, кечкенә кызларымызда да шундый истигъдадның[68] барлыгы беленде. Яшь туташларымызның милләтенә юлбашчылык итүләре һәркемне мәмнүн[69] итте. Күргәннәр һәммәсе дә тәшәккер[70] бәян иттеләр[71]. Галимулла әфәндегә бондый күптән сусап килгән бер эшкә тәшәббес[72] илә авылымызда үрнәк күрсәтүе өчен рәхмәт әйтеп чыктылар.

Борадәран[73] Сәгыйдевләр бина иткән[74] монтазам[75] кызлар мәктәбендә бу ел 4нче ел укулар дәвам итәдер. Без бу эшне ике елдан бирле бөтен авыл халкы бер булып кызлар мәктәбеннән, хосусан[76], рөшди[77] сыйныфымызда көтә идек.

Мәктәпнең төп максаты да кызларымызны кул эшләре белән таныштырып, идарәи бәйтия[78], тәрбия әүляд[79] кеби кирәкле мәгълүматлар илә шифаһән[80] булса да, белештерү иде. Шул максатымызга бинаән[81], без игъланнары буенча ике кыш инде читтән мөгаллимәләр алдырдык. Ләкин бонларның берсе дә безнең өмет вә максатымызга тугры чыкмады.

Һөнәрне бер якын куйганда, былтыргы мөгаллимә тәкрар иттерде[82]. Бу елгысы шәрган[83] әл-ислам укытты. Дөрес, бу дәресләр үз тугрыларында әһәмиятледер. Шулай да булса, бу барыш, әлбәттә, безгә һич бер яктан да өмет вә максатымызда юл булып күренмидер.

Гомумән, мәктәпләремездә кабул ителгән мөштәрәк[84] бер програмымыз юк. Һәр авыл вә һәр калада мәктәптән көткән төпле бер максат була. Игълан буенча читкә чыккан мөгаллим вә мөгаллимә булсын, иң элек бара торган авылның шул максат вә програмы белән танышып, шуңа җавап бирерлек булып-булмавын игътибарга алырга тиеш иде. Юкса, болай чакыручылар да, чакырылмышлар да уңгайсыз бер хәлдә калырга мөмкин.

*«Вакыт», 1915, 17 апрель.*

---

[68] Истигъдад – сәләтлелек.
[69] Мәмнүн – риза, шат булу.
[70] Тәшәккер – рәхмәт әйтү.
[71] Бәян итү – аңлату, әйтү.
[72] Тәшәббес – бер эшкә керешү, тотыну.
[73] Борадәран – бертуган.
[74] Бина итү – нигез салу.
[75] Монтазам – тәртипле.
[76] Хосусан – бигрәк тә, аеруча.
[77] Рөшди – урта.
[78] Идарәи бәйтия – хуҗалык эшләре.
[79] Тәрбия әүляд – балалар тәрбиясе.
[80] Шифаһән – телдән сөйләп.
[81] Бинаән – бәйле рәвештә, нигезләнеп.
[82] Тәкрар итү – кабатлау.
[83] Шәрган – шәригать буенча, шәригать карашы буенча.
[84] Мөштәрәк – уртак.

***Разыя Сөләйманова***

**Мөслимәләр җәмгыятенең һөнәр мәктәбе**

Мөселман кызларының һөнәр үгрәнергә гаид[85] дәрәҗә мохтаҗлыкларын игътибарга алып, мөслимәләр җәмгыяте «Кисү-тегү мәктәбе»ен яңадан ачарга карар бирде. Мәктәп ошбу алдымыздагы август башында ачылачак. Мәктәпне ачудан максуд: бердән, мөселман кызларына эш үгрәнеп, һөнәр ияләре чыгару, икенчедән, мөселман хатын-кызлары өчен арзан бәһагә кием тегә торган бер урын хәзерләүдер.

Мәктәпкә барлыгы 30 шәкерт кабул ителәчәк. 15е буш, калган 15е айга 3 сум уку хакы түләү шарты илә алыначак.

Шундук эчке һәм тышкы киемнәр тегәргә, оек бәйләргә вә аяк киемнәре хәзерләргә заказ да кабул ителәчәк. Алыначак заказлар өчен җәмгыять тарафыннан бик арзан бер хак тәгаен ителеп, гомуми бер такса куелачактыр.

Мәктәпнең идарәсен җәмгыять идарәсе үз өстенә алды. Җәмгыять әгъзаларының да хәер хаһанә[86] нәзарәт итеп[87], мәктәпнең яхшы бер юлга салынып, камил муаффәкыять[88] белән дәвамына ярдәмче булулары өмет ителәдер.

Идарә әгъзаларыннан: табибә Разыя Сөләйманова.

*«Вакыт», 1915, 15 июль.*

***Гами***

**Кул эшләре**

Кул эшләре дигәч үк, әлбәттә, хәтергә кулның, бармакларның, күзләрнең дикъкать, игътинаэ[89] вә игътибар куәтләренең иштирагы[90] сәбәпле вөҗүдкә[91] чыккан берәр эш киләдер. Шуның өчен шул мәзкүр[92] нәрсәләрнең эшләнүе, чарлануы-шомартылуы, гомумият берлә әйткән вакытта, тәрбия ителүе искә төшеп, кул эшләренең хәкыйкатән[93] файдалы бер дәрес икәне үз-үзеннән аңлашылмактадыр.

Кул эшләренә, педагогия тәрәккый иткән[94] милләтләр әллә кайчаннан бирле әһәмият биреп килдекләре кебек, Япон сугышыннан соң, ягъни 1906 сәнәдән бирле, безнең Русия мәмләкәтендә дә бик нык әһәмият бирелеп киләдер. Безнең Русиядә мондый хәрәкәтле, җанлы тәрбияви дәресләргә бигрәк әһәмият бирелә башлау, Япон сугышыннан соң булды.

---

[85] Гаид – бәйләнешле.
[86] Хәер хаһанә – яхшы теләк белән.
[87] Нәзарәт итү – идарә итү.
[88] Муаффәкыять – уңыш.
[89] Игътинаэ – бик нык игътибар итү, дикъкать итү.
[90] Иштиракь итү – катнашу.
[91] Вөҗүд – бар булу, тормышка ашу.
[92] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.
[93] Хәкыйкатән – чыннан да.
[94] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.

Ишетәбез бу урында кул эшләренең әһәмияте, вә ул әһәмият бирелүнең ни өчен икәнлеге хакында бераз бәянатта[95] булынмакчы буламыз.

Ибтидаи[96] вә урта мәктәпләрдә кул эшләренә әһәмият бирелү, башка мәдәни милләтләрдә дә шәкертләргә мөстәкыйль бер һөнәр өйрәтү максаты берлә булмыйча, бәлки шәкертләрне педагогия теләгенә муафыйк[97] тәрбия вә тәгълим итү, ялгыз шундый кул эшләре шикелле һөнәрләр вә остасы берлә генә мөмкин булганлыктандыр. Юкса ибтидаи вә урта мәктәпләрнең һичберсенең максат вә планнары мөстәкыйль бер өйрәтү түгелдер, бәлки шәкертләрне бөтен истигъдадларын[98] үстереп, кеше ясап чыгару вә гали мәктәпләргә хәзерләүдер.

Шул кабилдән[99] бездә дә кызлар өчен ачылган мәктәпләрдә кул эшләре яхшы куелып, алга китеп бара икән! Мин аңа шул сәбәпле, анда укыган бөтен кыз шәкертләр бер һөнәр иясе булырлар, яхуд тегүче, чигүче, рәсемче, тагын әллә нәрсәче шикелле сәнгать әһеле[100] булып чыгарлар дип карамыйм. Өйрәнсәләр өйрәнерләр, фәкать андагы кыз шәкертләрнең (ул һөнәрләрне би тәмамән[101] өйрәнгән тәкъдирдә дә) барысы да тегүче булып калулары мөмкин түгелдер. Әгәр булса, ул тәкъдирдә һәрбер мәктәп күргән кешенең тегүче булып калуы лязем[102] булмасмы? Ул вакытта тектерүче кем генә калыр соң!

Соң, алай булгач, аңа ни өчен ул кадәр шатлана соң диярсез түгелме?

Аңамы? Аңа мәктәпләремездә, хәтта ирләремезнекендә дә, шулай кул эшләре, гимнастика, рәсем, уен шикелле мөмарәсәләр[103] кертелеп, яхшы юлга куелса, ул вакытта мәктәп вә мәдрәсәләремездән чыккан шәкертләремез кеше булып чыгарлар. Ягъни төсләре качып, яңаклары ябышып, күзләре эчкә батып, чәһрәләре[104] алынып, истикъбаленнән[105] өметләрен өзеп, куркак, гайрәт вә сәбатсыз[106], бик җөзьи[107] газемнәрдән[108] дә гаҗиз булып чыкмыйча, бәлки истикъбальгә өметле, йөзләреннән хәят балкып тора торган, мөтәшәббис[109], гайрәтле, хәятнең бик җөзьи хадисәләренә[110] дә түзә алмый аптырауда кала торган булмыйча, бәлки хәятнең бөтен авырлыкларына күкрәк

[95] Бәян итү – аңлату.
[96] Ибтидаи – башлангыч.
[97] Муафыйк – кирәкле, яраклы.
[98] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.
[99] Кабил – төр, төркем.
[100] Әһел – кеше.
[101] Би тәмамән – тулаем.
[102] Лязем – тиеш, кирәк.
[103] Мөмарәсә – тәҗрибәлелек.
[104] Чәһрә – йөз, төс, кыяфәт.
[105] Истикъбаль – киләчәк, булачак.
[106] Сәбат – чыдамлылык, ныклык, тотнаклылык.
[107] Җөзьи – вак, кечкенә.
[108] Газем – тәвәкәллек.
[109] Мөтәшәббис – бер эшкә бирелеп тотынучы, башлап керешүче.
[110] Хадисә – вакыйга, хәл.

киереп, мәгыйшәт[111] юлында очраган һәрбер авырлык вә манигъларны[112] тибеп аударырлык булып чыгарлар. Менә шуның өчен шатланамыз. Безне шатландырган нәрсә әнә шул.

Кул эшләре, рәсем, гимнастика, уен шикелле нәрсәләр шәкертләргә бөтен дәрес җәдвәлләрен[113] тотырып каплап торган голүм риязият[114], табигыять[115], тарих, җәгърафия[116], дин вә игътикад[117] шикелле дәресләрнең бик озак вакытларда да бирә алмаган фикер, тәшәббес[118], дикъкать вә мөхакәмә[119], гайрәт вә сәбат куәтләрен бик мәхдүд[120] сәгатьләрдә дә бирә алалар. […]

*«Сөембикә», 1915, №20, б.15–17.*

**Кисү-тегү мәктәбе**

«Оренбург мөслимәләре җәмгыяте» тарафыннан ачылган кисү-тегү мәктәбендә эш өйрәнүчеләрнең саны 30га якынлашкан. Мөгаллимә (мастерица)лыкка оста поляк ханымы алынган. Мәктәпнең яхшы куелып, укучыларның мәмнүн булганлыклары ишетелә. Укучылар эчендә яхшы зур вә хәлле гаиләләрдән дә байтак ханым вә туташлар бар. Хәзердән заказ алынып, мәктәпнең мөгаллимәсе мәсьүлияте[121] тәхетендә[122] теләгән рәвештә тегелеп бирелә. Эш хакы арзан. Җәмгыять вә эш өйрәнүче мөселман ханымнарына ярдәм йөзеннән мөселман хатын-кызларының заказларын чит мастерскойларга бирми, «Кисү-тегү мәктәбе» мастерскоена бирүләре матлубтыр[123].

Мәктәп Каратаевский урамда Коннев йортында.

*«Вакыт», 1915, 27 август.*

**Кызлар мәктәбе**

Харипуновский урамда Хөсәенов йортында мөгаллимә Маһикамал ханым Юнысова кызлар мәктәбендә 26нчы августта игътибарән кабул башланып, беренче сентябрьдә дәресләр башланачагын хәбәр итәләр. Кул һөнәре дә укылганлыгын белдерәләр.

*«Вакыт», 1915, 27 август.*

---

[111] Мәгыйшәт – көнкүреш, тормыш.
[112] Манигъ – тыючы, тоткарлаучы, киртә.
[113] Җәдвәл – расписание.
[114] Риязият – математика.
[115] Табигыять – табигать турындагы фән.
[116] Җәгърафия – география.
[117] Игътикад – ышану, инану.
[118] Тәшәббес – керешү, эшкә тотыру.
[119] Мөхакәмә – хөкем чыгару.
[120] Мәхдүд – чикләнгән.
[121] Мәсьүлиять – җаваплылык.
[122] Тәхет – ас (астында).
[123] Матлуб – соралган нәрсә.

# V БҮЛЕК

# «ЫСУЛ ТӘРБИЯГӘ ВАКЫЙФ МӨГАЛЛИМӘЛӘР ЙИТЕШӘ БАШЛАСА ГЫНА, КЫЗЛАР АРАСЫНА ГЫЙЛЕМ ВӘ ФИКЕР КЕРӘ»

Мөгаллимәләр әзерләү

*«Вәкилә»*

## Дарелмөгаллимат[1]

Газетадан күренәдер ки, ирләремез үзләре өчен тырышалар. Җәмгыятьләр ачалар, съездлар ясыйлар, партияләргә керәләр, белмим ниләр вә ниләр эшлиләр. Соңгы хәбәрләргә күрә: Казанда мөгаллимнәр мәктәбе ачарга рөхсәт алынмыш, Уральскида һәм ачмакчы булалар. Бер чук йирләрдә мәктәп вә мәдрәсәләр ислах ителеп[2] тора. Фәкать, әй хөрмәтле ирләр! Безне – хатыннарны, сөекле кызларыңызны ни өчен бер дә искә төшермисез? Кызларның милләт анасы икәнене, бер кызга тәгълим[3] вә тәрбия бирүнең 10–15 ир баланы укыту дәрәҗәсендә файдалы улдыгыны, әгәр аналар мәгарифсез вә тәрбиясез улсалар, ирләрне укытырга тырышуларыңыз – төпсез иләк илә су ташымак, кабиленнән файдасыз китәчәгене шаять үзеңез бик яхшы белә торгансыздыр. Алга киткән милләтләрнең тәрәккый итүләренә[4] иң башлыча сәбәп – хатын вә кызларын тәрбия итү идеке дә шаять, сезгә мәгълүмдер.

Хәлбуки Русиядәге шулкадәр миллионнарча мөселман кызлары өчен монтазам[5] вә эшкә ярарлык һичбер мәктәп юк, кызлар укытырга махсус һичбер китап юк, тәгълим вә тәрбия гыйлемен белгән бер мөгаллимә юк. Безнең кызларымыз гомергә шулай «Тәҗвид»[6], «Мөхәммәдия»[7], «Әммали»,

---

[1] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.

[2] Ислах итү – үзгәртү, яхшырту.

[3] Тәгълим бирү – өйрәтү, укыту.

[4] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.

[5] Монтазам – тәртипле, рәтле.

[6] «Тәҗвид» – Коръәнне дөрес итеп уку турындагы кагыйдәләр.

[7] «Мөхәммәдия» – төрек шагыйре Мөхәммәд Язычы угылы Чәләби (1451 яки 1453 елда үлгән) тарафыннан төзелгән көйле әсәр, эчтәлеге Мөхәммәд пәйгамбәр һәм мөселманнар турындагы дини-әхлакый үгет-нәсихәттән гыйбарәт.

«Кисекбаш»[8] вә «Бакырган»нар[9] илә вакыт кичерерләр микәнни? Безгә үземезнең телемезне, әдәбиятымызны белеп фикер ачарга, дин вә әхлак дәресләре өстенә дә, йорт карау, тегеш-чигеш кеби һөнәрләр үгрәнергә, тарих, җәгърафия, хисап, хифзыссыйхәт[10] кеби һәр адәмгә беленмәсе лязем улган шәйләрне[11] белергә бер дә насыйп булмас микәнни? Әй, ирләр! Кайчанга кадәр сез безне илтифатсыз[12] калдырачаксыз? Кайчан безне дә хокуклы инсан саный башлап, үз кәефеңез өчен генә яратылган мәхлуклар[13] хисап итүдән ваз кичәчәксеңез? Безнең өчен хәзерге хәлдә иң беренче дәрәҗәдә хаҗәт булган нәрсә – мөгаллимәләр йитештерер өчен монтазам бер «дарелмөгаллимат»тыр. Ысул тәрбиягә вакыйф[14] мөгаллимәләр йитешә башласа гына, кызлар арасына гыйлем вә фикер керә башлар. Һич булмаса, бөтен Русиядәге мөселман кызларына махсус бер дарелмөгаллимат ачыңыз. Без укырга хәзермез. Боның артыннан үземез дә йөрер идек, ләкин сез безгә хокук, сөйләшергә һәм чыгып йөрергә ирек бирмисез. Инде безләрне өйләрдә дүрт стена арасында бикләп, «качак мал» шикелле яшереп яткыра торган булсаңыз, безгә кирәк мәктәпләрне салыңыз, мөгаллимәләр хәзерләңез, китаплар язып биреңез. Әгәр бонларны да эшләмәсәңез, кыямәт көнендә Ходай хозурында безнең кулымыз сезнең якаңызда улачактыр. Бондан хәбәреңез улып торсын!

*«Вакыт», 1906, 31 октябрь.*

## Мөгаллим вә мөгаллимәләр

Мәктәпләр ачылып, уку вакытлар йитте. Төрле тарафтан идарәмезгә хатлар яки җаваплары түләнгән телеграмнар килә; ышанычлы вә икътидарлы[15] мөгаллим вә мөгаллимә сорыйлар яки гәзитәмездә үзләрен игълан иткән мөгаллим вә мөгаллимәләрне, «ышанычлы вә икътидарлы булсалар, безгә йибәреңез, хакында тормамыз», диләр.

Фәкать мәгаттәәссеф[16], без бу мөрәҗәгать итүчеләрне мәмнүн итәрлек[17] җавап бирә алмыймыз. Чөнки бөтен Русия мөселманнары өчен бер данә

[8] «Кисекбаш» – «Кисекбаш китабы», XIV–XV йөзләрдә язылган татар әдәбияты үрнәге, кулъязма һәм китап рәвешендә киң таралып, мәдрәсәләрдә дәреслек итеп кулланылган.

[9] «Бакырган» – Урта Азия суфи шагыйре Сөләйман Бакыргани (1186 елда үлгән) шигыре белән ачылып, аның һәм шул замандагы бүтән шагыйрьләрнең әсәрләреннән төзелгән җыентык. Беренче мәртәбә 1846 елда Казанда басылган.

[10] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау юллары, гигиена.

[11] Шәй – әйбер, нәрсә.

[12] Илтифат – әһәмият бирү, игътибар.

[13] Мәхлук – җан иясе.

[14] Вакыйф – белүче, аңлаучы.

[15] Икътидарлы – булдыра алучы, көчле.

[16] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.

[17] Мәмнүн итү – риза, канәгать итү.

дарелмөгаллимин[18] вә дарелмөгаллимат[19] та булмагач, башкаларга табылмаган мөгаллим вә мөгаллимәләр безгә ничек табылсын! Һәм дә үземез имтихан итмәгәч, вә һичбер дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллиматтан шәһадәтнамәсе[20] булмагач, гәзитәмезгә игълан куйган бер мөгаллим вә мөгаллимәнең гыйлеме, фикере, әхлагы вә икътидары хакында без ничек итеп шәһадәт бирик? Бу, әлбәттә, мөмкин түгелдер. Һәр ел шушы хәл булып тора. Һәр ел мөгаллим вә мөгаллимәгә фәүкылгадә[21] ихтыяҗ күрелә, ләкин мәгаттәәссеф, дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллимат ачу хакында халкымызда җитди бер хәрәкәт күрелми. Ихтимал ки, хөкүмәт рөхсәт бирми, дип әйтерләр. Мөселманнар ныгытып сорасалар, хөкүмәтнең рөхсәт бирмәү ихтималы юктыр. Чөнки мөселманнарның 5–10 мең ибтидаи[22] мәктәпләренә мөгаллим вә мөгаллимә йитештерер өчен һичбер данә дарелмөгаллимин, дарелмөгаллиматлары юклыгы вә шунлардан башка урында мөгаллим вә мөгаллимәләр йитештерүе мөмкин түгеллеге, мөгаллим вә мөгаллимәсез мәктәп дәвам итүе гайре мөмкин итдеге хөкүмәтнең үзенә мәгълүмдер.

Бинаән галәйһи[23], татарларның дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллимат ачарга сорамаулары өчен хөкүмәт үзе тәгаҗҗеб итә[24] торгандыр.

Дөрес, Оренбургта вә Бәйрәкәдә мөгаллимнәр курсы ачарга рөхсәт соралып та, бирелмәде. Ләкин шул бирелмәү берлән калды. Артыннан йөрелмәде. Русиядә һәр эшнең артыннан күбрәк йөрү, төрле юллар илә каткат мөрәҗәгать итү гадәттер.

Әгәр эш акча ягыннан калса, моны хөкүмәт бирмәсә, үземез бирик: ашамый-эчми торып бәдәнемезне үтерергә разый булмыйбыз. Моңарга акча табамыз. Әмма тәгълим вә тәрбия бирмәенчә, рухымызны, балаларымызның хәят мәгънәвияләрене[25] үтерергә, милләтемезнең истикъбалене[26] һәлак итәргә ни өчен разый булып торамыз? Боңа ни өчен акча таба алмыймыз?

*«Вакыт», 1909, 20 август.*

***«Уфа кешесе»***

**Зарлану түгел, хакыйкать хәл**

Үткән ел 20 майда Оренбург мөфтисе хаҗи Мөхәммәдъяр Солтановның[27] мөфтилек хезмәтенең 25 еллык юбилей бәйрәме булдыгы Русиядә вә гайре[28]

---

[18] Дарелмөгаллимин – ир укытучылар хәзерли торган уку йорты.

[19] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.

[20] Шәһадәтнамә – таныклык язуы, диплом.

[21] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

[22] Ибтидаи – башлангыч.

[23] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шул нигездә, шул сәбәпле.

[24] Тәгаҗҗеб итү – гаҗәпләндерү.

[25] Хәят мәгънәвия – яшәү мәгънәсе.

[26] Истикъбаль – киләчәк.

[27] Мөхәммәдъяр Мөхәммәтшәриф улы Солтанов (1836–1915) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, 1886–1915 елларда (вафатына кадәр) мөфти булып тора.

[28] Гайре – бүтән, башка.

мәмләкәтләрдә[29], хәтта бөтен дөньяда дияргә мөмкин, чөнки «агентство телеграммаларында да бар иде». Бу юбилейны бөек итеп ясаудан Русия мөселманнарының максатлары да, шул мөнәсәбәт илә милләтемезнең истикъбале өчен лябед[30] менә булган бәлки бу гасырда динемезнең әсасы[31] хөкемендә тотылачак дәрәҗәдә хаҗәт вә зур күрелгән дарелмөгаллимин[32] вә дарелмөгаллимат[33] мәсьәләсе иде. Хәтта ки мөфти Солтановның шәхесе өчен түгел, бәлки 26 губерна мөселманнарына баш булган Оренбург мөфтисе хөрмәтенә дия иде. Уфага җыелмыш 3000 гә якын әһали[34] тарафыннан бер җәмгыять булып, бу җәмгыять 26 губернада булган мөселманнардан вәкил хөкемендә каралып, берничә сәгать мөзакәрәдән[35] соң, Уфага бер дарелмөгаллимин вә бер дарелмөгаллимат ачар өчен иттифак[36] илә карар бирелде. Гәзитә укучыларга бу бик мәгълүм һәм, бу карарны йиренә йиткерер өчен, боңа устав вә програмнар төзеп, тиешле урынына биреп, рөхсәт сорарга юбилей һәйәтендә[37] булган берничә затны – «29» кешене вәкил кылдылар. Бу һәйәттә голәмадан[38], юристтан, сәүдәгәрдән, мәэмүрләрдән[39] бар иде. Бу уставлар җәй фасылында хәзерләнә башлап, тәкрар[40] җыелышып, ахирел әмер[41] бер устав һәм програмнар вөҗүдкә китерделәр[42]. Бу устав-програмнарны вөҗүдкә китерү бик мөшкел[43] булды. Мөзакәрә вә бәхәсләр күп булды. Устав шәригатькә дә, законга да туры килсен өчен, интихаб[44] килергә дип 18 төрле мәдрәсәләр хакында булган уставлар үрнәк тотылды. Һәм дә юбилей һәйәтенең фикере дә, шаять бу уставта йитешмәгән йир булса да, аз булыр. Аларны соңра да төзәтелер. Әүвәлдә бер мәртәбә хөкүмәт илә таныштырып вә киңәш итеп карарга кирәк. Бу исә, әлбәттә, Петербургка барып, анда Дума әгъзалары илән мәслихәтләшеп[45] эшләнер дип, һәйәт әгъзаларыннан 4 затны йибәрү мәгъкуль[46] күрелде һәм болар мөфти Солтанов илә бәрабәр Петербургка киттеләр. Бу эш юбилей һәйәтенә бик гүзәл тәэсир итте. Чөнки ничә миллион мөселманнарның сайланмыш вәкилләре булып, өсләренә илтизам

[29] Мәмләкәт – ил, дәүләт.
[30] Лябед – бик кирәк.
[31] Әсас – нигез, төп.
[32] Дарелмөгаллимин – ир укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[33] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[34] Әһали – кешеләр.
[35] Мөзакәрә – фикер алышу, җыелыш.
[36] Иттифак – бер сүздә булу, союз.
[37] Һәйәт – комиссия, комитет.
[38] Голәма – галимнәр.
[39] Мәэмүр – чиновник.
[40] Тәкрар – кабатлау.
[41] Ахирел әмир – соңгы чиктә.
[42] Вөҗүдкә китерү – барлыкка китерү, булдыру.
[43] Мөшкел – авыр.
[44] Интихаб – сайлау.
[45] Мәслихәтләшеп – киңәшләшеп.
[46] Мәгъкуль – урынлы.

кылган[47] эшләрене бер төрле әда кылган[48] кеби бер шатлык хасыйл итте. Ләкин эшләр бөтенләй балгыксыз күренә башлады. Безнең депутатларымыз Петербургка барып, Дума әгъзаларына мөрәҗәгать итсәләр, безнең ничә айлар иҗтиһад кылып[49] ясаган уставларымызны бөтенләй эштән чыгарганнар. Һәм дә юбилей һәйәтенең фикерене дә үзгәрткәннәр. Уставны үзләре берничә көндә төзәтеп тә бирмәкче булганнар. Ахирел әмер безнең барган депутатларымыз Петербургта торырга арыгачтын, аларны Уфага кайтуга мәслихәт күргәннәр[50]. Уставны 8нче гыйнвардан калдырмай Уфага юбилей һәйәтенә төзәтеп йибәрмәкче булганнар. Имде бу вәгъдәләренә дә ике айдан артты. Берничә мәртәбә телеграм да бирелде. Һаман да килгән юк әле. Бәгъзе депутатлар хат язалар: «Уставны, җәй фасылында Уфага җыелышырмыз, шунда бергәләп ясармыз», – дип, хәзерләнмеш уставны яратмаенча, тиз генә төзәтәсе әфәнделәр төзәтә башлагач, эшнең йиңел түгел икәнен сизгәннәр булырга кирәк. Әлбәттә, ясалган уставны хөкүмәт даирәсенә тәслим итү[51] тиешле иде. Чөнки аны тиз генә, тәфтиш кылмаенча[52] гына, үтәр дип утвердить итмәсләр бит. Байтак кына объяснение дә сорарлар. Ул вакытта да төзәтеп булыр иде. Бәгъзе депутатларымыз җәй буенча устав төзәтеп, көз фасылында Думага тапшырып, Дума аркылы үткәрергә фараз кылалар[53] икән. Ләкин IV Дума сайланса, анда кемнәр үтәр икән? Ул Думага кергәч тә, ничә еллардан соң гына каралырга тиешле булыр. Чөнки 5 ел эчендә IIIнче Думаның эшләгән эшләре бармак берлән генә санарлык бит. Бу хосуста[54], әлбәттә, Дума әгъзаларының бер сәяси фикерләре улса кирәк? Юбилейда җыелган төрле халыкның дарелмөгаллимат вә дарелмөгаллимин ачылган тәкъдирдә, вәгъдә кылган суммалары сәламәт кулларында торса, бик хуш. Бу заманда аларга да ышанып бетәргә ярамый. Хосусан[55] бәгъзеләре, ике ел эчендә рөхсәт булып, ачылган тәкъдирдә, бирмәкне вәгъдә иттеләр. Ике елдан артып киткән тәкъдирдә, ихтыяр үзләрендә каладыр диләр. Боны да төшенемле, бу милләт эше хосусый, шәхси интерес өчен кичектерү мотлака[56] тиеш түгел дип беләмез. Бу хәбәрләрне ишеткәч, Уфада дарелмөгаллимин һәйәте һаман да сылтау итеп Дума әгъзаларына аударып торалар. Җыелышмыйлар да, иҗтиһадлары да күренми – вәлсафа[57].

*«Сибирия», 1912, 3 апрель.*

[47] Илтизам кылу – йөкләү.
[48] Әда кылу – үтәү.
[49] Иҗтиһад кылу – тырышу.
[50] Мәслихәт күрү – уңай дип табу.
[51] Тәслим итү – тапшыру, бирү.
[52] Тәфтиш кылу – тикшерү, ревизия.
[53] Фараз кылу – уйлау.
[54] Хосус – очрак.
[55] Хосусан – бигрәк тә, аеруча.
[56] Мотлака – ничек кенә булмасын.
[57] Вәлсафа – рәхәт, кайгысызлык.

***Г.Г.***

## Дарелмөгаллимин[58], дарелмөгаллимат[59] хакында бер-ике сүз

Һәркемгә мәгълүм ки, мөфти хәзрәткә юбилей ясалмактан максат мөфти хәзрәтенә хөрмәт кенә улмаенча, бәлки бу мөнәсәбәт илә татар милләтенә файдалы булган бер мөәссәсә[60] салмак иде. Әгәр бу фикер улмаса иде, бу кадәр зур итеп бу юбилей ясалмаячак иде. Һәр йирдән, халык тарафыннан килгән вәкилләр, хосусый мәктүб[61] вә телеграмнар дарелмөгаллимин, дарелмөгаллиматның бик кирәк улдыгыны белдерделәр. Һәм гомуми мәҗлестә дарелмөгаллимин, дарелмөгаллимат ачарга карар бирелде. Фәкать ләйха[62], «устав» ясауны юбилей комитетына тапшыру мәгъкуль күрелде[63]. Шарты да шулдыр: юбилей комитеты дарелмөгаллимин, дарелмөгаллимат уставыны төзегән вакытта, мәктәп-мәдрәсә эшләренә әһали[64] һәм дә Русиянең низамнарыннан[65] хәбәрдар улган затларның фикерләрене сорап, мөшәвәрәт[66] мәслихәт[67] илә эш кылыначак иде. Һәм дә кичектермәй матлуб[68] иде. Тәмам ләйха тәртип улынгач, матбугат васитасы[69] илә халыкка белдереләчәк, әрбаб[70] тарафыннан тәнкыйть улыначак иде.

Хәлбуки, 1911нче елның декабренә кадәр юбилей комитеты өстенә алган вазыйфасы хакында матбугат аркылы бернәрсә белдермәде. Анчак[71] хосусый мохбирләрдән шул аңлашылды: «Юбилей комитеты юбилей вакытында күп эшләмәк илә арыганга, үзләренең дә әүвәлдән хезмәтләре күп улганга, ял итәләр, кымыз эчәләр, көзгә саф фикер илә эшкә тотыначаклар», имеш. Көз килде. Бернәрсә улмады. Декабрь аенда юбилейга катышкан бәгъзе әфәнделәр русча-мөселманча устав үрнәгене алдылар. Боның янында бер язу да бар иде. «Комитет әгъзалары дарелмөгаллимин, дарелмөгаллимат өчен устав проекты төзеделәр. Боны төзегән вакытта бик күп мәшәкать чиктеләр. Бүгенге, киләчәк хәлләр уйланды. Йитмәгән йире калмады. Сез дә караңыз, мәгъкуль улса, фикереңезне языңыз. Ләкин соңыннан фикереңез кабул улынмас исә, үпкәләмәңез. Мөфти хәзрәт декабрь ахырында Петербургка барачактыр». Уйлаштык, без дә үз фикеремезне язып йибәрдек. Башка йирләрдән дә бу ляйханың кимчелекләрене күрсәтеп йибәрделәр. Фәкать, мөфти хәзрәт вәкилләре илә

---

[58] Дарелмөгаллимин – ир укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[59] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[60] Мөәссәсә – оешма, учреждение.
[61] Мәктүб – хат, язылган әйбер.
[62] Ләйха – проект.
[63] Мәгъкуль күрелү – урынлы, аңлаешлы, табылу.
[64] Әһали – кешеләр.
[65] Низам – кагыйдә, тәртип.
[66] Мөшәвәрәт – киңәшләшү, фикер алышу.
[67] Мәслихәт – уңыш, файда; киңәш.
[68] Матлуб – көтелгән, таләп ителгән.
[69] Васита – арадаш, ике арада эш йөртүче.
[70] Әрбаб – хуҗа, ия.
[71] Анчак – бары тик.

14нче декабрьдә Петербургка киткән иде. Бинаән галәйһи[72] язылган фикерләрнең бушка китүе беленде. 2нче мөфти хәзрәт чыннан шул дарелмөгаллимин, дарелмөгаллимат эше әһәмиятле диеп белсә, бу кадәр ашыгып русларның зур бәйрәмнәре вакытында Петербургка бармас иде. Бәхетсезлеккә каршы, Дума членлары да ләйха хәзерләгәннәр имеш. Татар халкы мөшәвәрәт илә эш эшләргә өйрәнмәгәнгә күрә, һәркем үзенә ләйха ясаган.

Менә шулай итеп, бу бару Петербург урамыны таптаудан гыйбарәт булып калды. Хәзер 1912нче ел үлде. Тиздән юбилей булып үтүгә бер ел тулачактыр. Бер ел эчендә комитет ни эшләгәндер? Без, вәкилләр, подробный отчет көтәмез. Көтмәгә хакымыз да бар. Чөнки милләтнең сәгадәтенә[73], хәятенә[74] сәбәп булган эшне өстеңезгә йөкләп алып калдыңыз. Әгәр бу эш сезнең хәлеңездән килмәслек улса, ул вакыт вәкилләргә белдерергә тиеш иде. Милләтнең хәяте, мөкаддәраты[75] илә уйнарга, шаярырга ярамыйдыр. Тәкрар[76] рәҗа итәм[77]. Бу хосуста хакыйкатьне белдереңез. Мәсьүлиятьнең[78] иң агыры – юбилей комитетындадыр. Әгәр тагы бу кадәр озак вакыт үтсә, вәгъдә кылынган акчалар һәм дә мөфти хәзрәт тарафыннан вәгъдә ителгән 86 дисәтинә йир дә югалачактыр. Чөнки мөфти хәзрәт бу йирне вәгъдә иткәндә, ике ел эчендә бу эшнең вөҗүдкә чыгуыны шарт итте. Мөфти хәзрәт үзе дә дарелмөгаллимин, дарелмөгаллиматка тизлек илә рөхсәт алу хосусында чын ихласы илә тырышырга тиештер. Мәскәүгә, Петербургка барганда, анчак шушы милләт эше илә барырга кирәк. Үз эшене, үз йомышыны теләсә кай вакытта эшләсен. Әгәр мөфти хәзрәт, сез үзеңез бу эшкә чынлап керешмәсәңез, иҗтиһадта[79] кимчелек күрсәтеп, дарелмөгаллимин, дарелмөгаллимат ачылмый калса, үзеңез үлгәч, сезгә «юбилей» дога мәҗлесе урынына «.....» мәҗлесе ясарлар. Ачык әйткәндә, милләт сезгә бик рәнҗеячәктер. Ул вакыт мөфтилек заманындагы кимчелекләрне берәм-берәм санарлар. Менә шушы хакыйкатьләрне күз алдыңызга китереп, үзеңез һәм дә комитет әгъзалары ничек кенә улса да, ниндәй мәшәкатьләр күрсәңез дә, милләтнең ничә гасырлардан бирле дүрт күз илә көткән дарелмөгаллимин, дарелмөгаллиматны ачарга рөхсәт алырга ашыгыңыз. Милләт үзенә кылынган хезмәтне һичбер вакытта онытмас.

*«Сибирия», 1912, 3 апрель.*

[72] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шул нигездә, шул сәбәпле.
[73] Сәгадәт – бәхет, рәхәтлек.
[74] Хәят – тереклек, яшәеш.
[75] Мөкаддәрат – язмыш.
[76] Тәкрар – кабатлау.
[77] Рәҗа итү – сорау, үтенү.
[78] Мәсьүлиять – җаваплылык.
[79] Иҗтиһад – тырышлык, теләк.

***Нукайский***[80]

## Уфада дарелмөгаллимин[81] һәм дарелмөгаллимат[82] тәэсис кылу[83] хакында юбилей комитетына читтән килгән фикерләр

Мөфти хәзрәт Солтанов наменә[84] ачылган дарелмөгаллимин һәм дарелмөгаллиматның устав ләйхаларын[85] төзеп, юбилей комитеты үткән сәнәнең ахырында фикер бәян итәр өчен, бераз затларга йибәргән иде. Шул хакта байтак фикерләр, намәләр[86], мәктүбләр килде. Боларның һәркаюсын матбугатка куеп бетү хәзергә мөмкин булмаганлыктан, бу мәктүбләрнең ияләрен һәм ни нәрсә әйтергә теләгәнлекләренең рухын гына әйтеп, «Вакыт» укучыларын кыскача гына таныштырамын.

Бик күп мәктүбләр уставны «бик мәгъкуль[87] һәм мәкъбүл[88]» дип кенә язып, комитет төзегән ләйхага аерым вә мохалиф[89] бер фикер бәян итмәгәнгә вә бәгъзеләре андагы нәрсәләрне изах[90] вә тәэйид иткәнгә[91] күрә, мин ул хатларны язмыймын. Болар арасында кыйммәтле Кавказ мөфтисе Хөсәен әфәнде Гаибов җәнабләренең[92] дә мәктүбе бар. Ул әйтә: «Ибтидасеннән[93] интиһасына[94] кадәр дикъкать илә укыдым. Минем гыйндемдә[95] һичбер косур[96] мөляхәзә улынмады[97]. Мөндәриҗатенең[98] җөмләсе[99] шәргъгә[100] вә

---

[80] Килдебәков Мөхәммәтһади Нурмөхәммәт улы (1881–1949) – мәгърифәтче, тәрҗемәче, журналист. «Госмания» мәдрәсәсе мөгаллиме. Уфа, Минзәлә земстволарында татар мәктәпләре бүлеге инструкторы. Свердловскида Татар педагогик техникумы директоры.

[81] Дарелмөгаллимин – ир-атлар өчен педагогик уку йорты.

[82] Дарелмөгаллимат – хатын-кызлар өчен педагогик уку йорты.

[83] Тәэсис кылу – төзү, оештыру.

[84] Нам – исем.

[85] Ләйха – проект.

[86] Намә – хат, язу.

[87] Мәгъкуль – урынлы, акылга ярашлы.

[88] Мәкъбүл – яраклы табылу, яхшы табылу.

[89] Мохалиф – каршы килә торган.

[90] Изах итү – ачык итеп аңлату.

[91] Тәэйид итү – ныгыту, раслау.

[92] Мирза Хөсәен әфәнде Йосыф угылы Гаибов (1830–1917) – Кавказ мөфтие (1879–1912), Кавказ сөнни рухани идарәсе рәисе. Шәригатьнең хатын-кыз мәгарифенә киртәләр куймавын раслый.

[93] Ибтида – башлангыч, баш.

[94] Интиһа – ахыры.

[95] Гыйндемдә – каршымда.

[96] Косур – кимчелек, җитешсезлек.

[97] Мөляхәзә улыну – дикъкать белән карау, тикшерү.

[98] Мөндәриҗат – эчтәлекләр.

[99] Җөмлә – кайбер өлеше.

[100] Шәргъ – ислам шәригате, ислам кануны.

канунә муафыйк булдым[101], вә комитетның хакларында догаи хәердә булдым», – ди. Мәктүбенең ахырында бу хәерле эшнең ике гамде[102] вә әһәм[103] ике сәмәрә[104] вә нәтиҗә тәүлид иткәнен[105] бәян итеп, аларның беренчесе – мөфти Солтанов җәнабләренең намен мәңгелеккә калдыру, вә икенчесе – дареттәгълимнәрнең[106] лөзүме[107] икәнен аңлату һәм боларның шәригатьтә күркәм вәһем[108] эш идекләрен аять вә хәдисләр илә тәэйид итәдер.

Бәгъзе затлар, төзелгән уставка аерым фикерләр вә гыйлавәләр[109] илә бәян итәләр.

Троицк –

Зәйнулла хәзрәт Рәсүлев[110], Габдрахман мәхдүм Рәсүлев[111], ахунд Әхмәдхаҗи Рахманколов[112]:

«Уставларыңызны яраттык. Хезмәтеңезгә тәшәккер[113] вә афәрин укыймыз. Фәкать ике маддә калмасын иде:

1) Шул дарелмөгаллимин һәм дарелмөгаллимат хозурында читтән килгән кешеләргә дә мөгаллимлеккә имтихан тоту мөмкин булсын;

2) Мөнасиб күргән[114] урында бер шөгъбә[115] ачу хакына малик[116] булсын.

Оренбург –

Шәһәр имамнары исеменнән Нигъмәтулла хәзрәт Тимошев[117]:

«Дарелмөгаллимин һәм дарелмөгаллимат уставларында «дини» кайде[118] калмасын иде. Тәҗвид[119] һәм хөсне хат[120] дәресләре әйтелсен. Голүм диния[121] дәресләре, бу көнгә кадәр Русиянең мөселман мәдрәсәләрендә мәгъмүл

---

[101] Муафыйк булу – хуплау.

[102] Гамдь – ният.

[103] Әһәм – бик әһәмиятле.

[104] Сәмәрә – нәтиҗә.

[105] Тәүлид итү – җитештерү, барлыкка китерү.

[106] Дареттәгълим – уку йорты.

[107] Лөзүм – кирәклек.

[108] Вәһем – күз алдына китерелгән уй.

[109] Гыйлавә – өстәмә.

[110] Зәйнулла бине Хәбибулла бине Рәсүл (Зәйнулла ишан, 1833–1917) – дин эшлеклесе, суфи, мәгърифәтче.

[111] Габдрахман Рәсүлев – Зәйнулла Рәсүлевнең улы.

[112] Рахманколов Әхмәтхаҗи (1821–1921) – дин эшлеклесе, педагог, 1840 еллар ахырында Троицкида «Әхмәдия» мәдрәсәсенә нигез сала.

[113] Тәшәккер – рәхмәт.

[114] Мөнасиб күрү – яраклы, туры килгән.

[115] Шөгъбә – бүлек.

[116] Малик – ия.

[117] Тимошев Нигъмәтулла Фәйзулла улы (1872–1926) – дин эшлеклесе. Кәрван-Сарай мәчете имамы, «Оренбург мөселман җәмгыяте» әгъзасы.

[118] Кайд – билге, тамга.

[119] Тәҗвид – Коръәнне дөрес уку турындагы кагыйдәләр.

[120] Хөсне хат – матур язу.

[121] Голүм диния – дини гыйлемнәр.

булып [122] килгән дәрес китапларыннан, яхуд шул китаплар әсас тотылып[123]тәэлиф улынганнардан[124] гына укытылсын. Дарелмөгаллиматта комитет әгъзалары фәкать хатыннардан гына булсын. Мәшһүр педагог Фармаковский [125] фикеренә бинаән [126], шәкертләр һәммәсе комитет тарафыннан билгеләнгән милли киемдә булырлар, дип бер маддә арттырылсын».

Орск –

Ахунд Мөхәммәдзарим Гыйлаҗетдинов:

«Комитет әгъзалары һәм дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллиматта башкача хезмәт итүчеләр, 3–5 ел кеби, мөгайян[127] мөддәткә[128]интихаб ителсен[129]».

Имам Галиулла Салихов:

«Анда бер урында дәресләрне санаганда «вә гайреләр» диелгән. Бу «гайреләр»дән морад: гыйльме сарыф[130], гыйльме нәһү[131], гыйльме мәган[132], гыйльме бәян[133] булсын. Зиран[134]: игътикад[135] тәфсир[136], хәдис[137] вә әхлак китаплары, әлбәттә, гарәби булса кирәк, төркичә тәрҗемәләрен укытудан һич бер «могтад[138] бәһа» булган мәгънә чыкмасын; һаман төрки, һаман төрки булыр; голүм гарәбиягә истигъдад[139] бетәр. Инде болар гарәби китаплардан укылса, гыйльме сарыф, гыйльме нәһүләрдән лябед[140]. Шул сәбәпле боларны ачык әйтергә кирәк».

Каргалы –

Сәгыйдь бистәсендә 13 имам болай әйтәләр:

«Укылган китаплар әһле сөннәт вә җәмәгать мәзһәбенә[141] мохалиф[142] булмасын; әүвәл мөгаллимнәр вә шәкертләр диянәтсез[143] булалар. Кирәчәк

---

[122] Мәгъмүл булу – кулланылу.
[123] Әсас тотылу – нигез итеп алыну.
[124] Тәэлиф улыну – төзелү, китап итеп язылу.
[125] Фармаковский В.И. (1842–1922), педагог, Сембер, Оренбург, Псков губерналарында халык училищелары инспекторы, педагогика буенча хезмәтләр авторы.
[126] Бинаән – таяныгп.
[127] Мөгайян – билгеләнгән.
[128] Мөддәт – ара, срок.
[129] Интихаб итү – сайлау.
[130] Гыйльме сарыф – морфология.
[131] Гыйльме нәһү – синтаксис.
[132] Гыйльмел мәган – семантика.
[133] Гыйльме бәян – стилистика.
[134] Зиран – аста.
[135] Игътикад – ышану, инану.
[136] Тәфсир – Коръән сүзләренә аңлатма.
[137] Хәдис – Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре.
[138] Могтад – гадәт ителгән, гадәтләнгән.
[139] Истигъдад – сәләтлелек.
[140] Лябед – бик кирәк, котылгысыз.
[141] Әһле сөннәт вә җәмәгать мәзһәбе – Хәнәфи мәзһәбе.
[142] Мохалиф – каршы килә торган.
[143] Диянәтсез – динилеге чикле.

шәкертләр – ирләр 15, кызлар 14 яшеннән артык булса да ярасын. Уфа имамнары алда тотылмасын, ул Уфага хас[144] түгел. Комитет әгъзалары мөтәдәйин[145] вә төзек игътикадлы[146] булсыннар. Дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллиматтагы кешеләр дүрт мәзһәбнең берсеннән хариҗ[147] булмасын. Шәкертләр «исламия» вә «милли» киемдә булынып, җомгалар, мәсҗетләргә барганда чалмадан йөрсеннәр.

Бирск –

Борай авылында[148] бер ахунд хәзрәт бигрәк тә каты әйтә:

«Комитет әгъзаларының голосы бер булсын. Шул комитет әгъзалары эчендә өч данә зәват[149]кирам[150], аслан[151] тәбдилсез[152] әгъза булсыннар», – ди һәм бу кешеләрне хәзердән сайлап вә тәгаен итеп тә куя.

Касыйм –

Мөдәррис Хәсән Таһиров:

«Уку теле – гомумән үземезнең телемез булса иде. Әхвәл заманга караганда, җәгърафия, һәндәсә[153] шикелле фәннәрне мәмләкәт[154] лисанында[155] укыту хөкүмәтнең матлабы[156] идеке аңлашыла. Шул хакта ни эшләрмез икән?»

Екатеринбург –

Имам Гыйрфан әфәнде Рахманкулов, Һади Таһири вә башка бераз затлар:

«Ләйханы гомум тел илә тар вә йомшак таптык, ләкин әхваленең кидешенә нәзарән[157] әсасенә иштиракъ итәмез[158]. Фәкать, Уфа имамнары кайдан төшереп калдырсаңыз да ярар иде. Мәктәпнең ләвазим[159] ияләре ниндәен хокуклы хаиз[160] булулары бәян ителмәгән», – диләр.

Омск –

Имам Ниязмөхәммәд Сөләйманов[161] әйтә: «Тәгълим[162] теленә әһәмият бирелергә, аны аерым бер маддә итәргә тиеш. Дарелмөгаллиминдә, дәресләр

---

[144] Хас – бер нәрсәгә, бер генә эшкә билгеләнгән.
[145] Мөтәдәйин – диндар, бик динле.
[146] Игътикадлы – чын күңелдән ышанган, инанган.
[147] Хариҗ – тышында, тыш.
[148] Борай авылы – хәзерге Башкортстанның Борай районына карый.
[149] Зәват – затлар.
[150] Кирам – затлы, хөрмәтле.
[151] Аслан – һич.
[152] Тәбдилсез – үзгәрешсез.
[153] Һәндәсә – геометрия.
[154] Мәмләкәт – ил, ватан.
[155] Лисан – тел.
[156] Матлаб – таләп ителгән әйбер.
[157] Нәзарән – караганда.
[158] Иштиракъ итү – катнашу.
[159] Ләвазим – кирәкле булган.
[160] Хаиз – ия.
[161] Ниязмөхәммәд Сөләйманов – дин эшлеклесе, вәгазьләр китабы авторы.
[162] Тәгълим – укыту.

арасында, илаһи мөнәҗәтләр[163] юк; дарелмөгаллиматтагы кеби, дарелмөгаллиминдә дә боның булуы, рухны күтәрер өчен лязем. Комитет әгъзалары «мәгълүматлы» кешеләр булсын. Нәмунә[164] мәктәбе ачу, мөмкин генә түгел, лязем булсын».

Томск –

Хәмзә хәзрәт, Хәлил хәзрәт, мөгаллимнәр вә башка затлар уставны муафыйк күргәннәр. Фәкать ошбу фикерләрен үзләреннән кушалар: «Төрки-татар тарихы, хөсне хат дәресләре арттырылсын. Уку хакы бик югары билгеләнеп, фәкыйрьләргә авыр кылмасын. Имам вә мөгаллим балаларына бераз тәсһиләт[165] иҗраэ кылынсын[166]. Торлак[167] ясау лязем булсын. Дарелмөгаллиматта мөгаллимнәр ирләрдән булса, кызлар йөзләренә пәрдә уратып утырсыннар», – дигәннәр һәм бәйрәмнәр хакында бераз әфкяр[168] бәян иткәннәр.

Семипалат –

Габделхак хәзрәт:

«Солтания» исемендә булмасын иде. Солтан ләфызы[169]солтан вә тәсәллыттан[170] мәэхуз[171], деспотиянә мөшариктер[172]. Беренче иҗтимагъ[173] илә башланган эшне шулай тәсмия кылу[174] хәерле фал[175] түгел, мөфти хәзрәткә нисбәт[176] бирү касд ителсә[177], «Мөхәммәдъярия», «Йария», «Мөхәммәдия», «Шәрифия», «Ислахия» кеби исемнәр илә аталсын. Уфа имамнары алда тотылсын. Шәкертләр милли татар киемендә булсыннар. Мөгаллимнәрнең диянәт[178] җәһәтләреннән мөляхәзә кылынсын. Әхвәл арттырылып, имамнары метрика низамнары[179] вә гайреләр һәм тәфсир, хәдис тәкрар[180] укылсын. Дарелмөгаллимат уставында мөгаллимнәрнең ирләрдән булмавы ачык әйтелгән. Шәргый хиҗаб[181] игътибар ителсен иде. Кызларга илаһи мөнәҗәтләр хаҗәт түгел. Поплар җанында җырлап йөргән кызлар шикелле, шау-

---

[163] Мөнәҗәт – Аллаһны мактап әйтелгән, көйгә салынган тезмә әсәр.
[164] Нәмунә – үрнәк.
[165] Тәсһиләт – ташлама.
[166] Иҗраэ кылыну – эшләнү, үтәлү.
[167] Торлак – тору урыны.
[168] Әфкяр – фикерләр.
[169] Ләфыз – сүз.
[170] Тәсәллыт – кеше өстеннән үзе теләгәнчә хөкем итү.
[171] Мәэхуз – алынган.
[172] Мөшарик – катнашучы.
[173] Иҗтимаг – кушылу, җыелу.
[174] Тәсмия кылу – исем бирү, исемләү.
[175] Фал – юрау.
[176] Нисбәт – мөнәсәбәттә.
[177] Касд ителү – максат ителү.
[178] Диянәт – динлелек.
[179] Низам – тәртип.
[180] Тәкрар – кабат, кабатлау.
[181] Хиҗаб – тотнаклылык, оялчанлык.

шуга сәбәп булыр. Минемчә, хатыннар – куйлар, ирләр – аларны аулаучылардыр. Ни микъдар ара ачык булса, шул кадәр һәйәт[182] иҗтимагыя[183] мөстәфид булачаклартыр[184]».

Семидән Рәхмәтулла әфәнде Елкыбаев та «Солтания» сүзен мәгъкуль күрми[185] һәм мөгаллимнәрне тасдыйк[186] вә таред итү[187] кем хакы икәне ачык бәян ителмәгән, ди. Башкаларын муафыйк күрә[188].

Акмулла[189] –

Хөҗҗәтелхәким Мәхмүдов[190] әйтә: «Дарелмөгаллимат програмы ирләрнекенә караганда таррак булса да ярый. Кыз балалар кеби ир балалар да 14 яшеннән кабул ителсен. Төрки-татар тарихы кирәк. Гашурә[191], рәгаибләрне[192] бәйрәм итү тиешле түгел. Хиҗаб мәсьәләсе игътибарга алынсын. Аның дини икәне онытылсын. Әтрафтан[193] килгән фикерләрне тәхкыйк[194] вә тәдкыйкъ итмәк[195] өчен гыйльме исламиядән 20–30 кадәр кеше чакырылсын», – ди. Аның мәктүбе озын булып, бер рисалә булырлыктыр.

Иркутск –

Имам Габдерәшитов:

«Дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллиматның Идарәи рухания[196] нәзарәтендә[197] булуы бик гариб[198], ул үзе мохтәсар[199] хәлендә; Уфа имамнары алда тотылмасын; читтән килеп имтихан кылыну мөмкинлеге булсын; училищный комитет әгъзалары, кирәк имамнардан, кирәк гайре имамнардан булса да, әһлиятле[200] затлар интихаб ителеп, Духовный собрание тарафыннан тасдыйк

---

[182] Һәйәт – тышкы кыяфәт, күренеш.
[183] Иҗтимагыя – җәмгыятькә бәйләнешле.
[184] Мөстәфид булу – файдаланылу.
[185] Мәгъкуль күрү – урынлы, акылга ярашлы дип санау.
[186] Тасдыйк итү – раслау, дөреслеген тану.
[187] Таред итү – тарату, урнаштыру.
[188] Муафыйк күрү – яраклы дип табу
[189] Акмулла (Акмолинск) – хәзер Казахстан башкаласы Нур-Солтан.
[190] Хөҗҗәтелхәким Мәхмүдов (1871–1937) – дин эшлеклесе, «Ислах көтепханәсе» журналының баш мөхәррире, Диния нәзарәтенең голәмалар шурасы әгъзасы (1926), мөселман хокукларына багышланган хезмәтләр авторы, 1917 елда кыска вакыт эчендә вакытлы мөфти булып тора.
[191] Гашурә – мөхәррәм аеның унынчы көне, бәйрәм көне.
[192] Рәгаиб – рәҗәб аеның беренче җомгасы, бәйрәм көне.
[193] Әтраф – тарафлар, төрле яклар.
[194] Тәхкыйк итү – хакыйкатьне табу.
[195] Тәдкыйк итү – җентекләп тикшерү, аныклык кертү.
[196] Идарәи рухания – Диния нәзарәте.
[197] Нәзарәт – күзәтчелек.
[198] Гариб – күрелмәгән, ишетелмәгән (хәл).
[199] Мохтәсар – кыска.
[200] Әһлиятле – булдыклы, булдыра торган.

ителсен», – ди. Китаплар сайлау мәсьәләсен һәйәт тәгълимиягә[201] тапшырмаенча, читтән әһлиятле затлар чакырып интихаб ителүен муафыйк күрә.

Чита –

Ахунд Солтангалиев: «Ишгар[202], ишкял[203] вә рәсем дәресләре калмасын. Уфа имамнары алда тотылмасыннар. Бәйрәмнәр азрак күренә, күбәйтелсен. Читтән матди ярдәм иткән кешеләр фәхри[204] әгъза булып, алар комитетта тавыш бирү хакына малик булмасыннар[205] иде. Мөдирнең икътидар[206] гыйльмиясе тәгаен ителсен», – ди.

Манчыл[207] –

Ахунд Йосыф хәзрәт Сәгыйдов: «Оренбург идарәи руханиясенең тәхет нәзарәтендә булган һәммә губерналардан шәкерт кабул кылынсын. Имамнар ма сива[208] күрелсен», – ди.

Эстәрлетамак –

Имам Мөхәммәдгариф Рәмиев Мәхкәмәи Шәргыяи тәхет нәзарәтендә булуга гаҗәпкә кала. «Мулла берлә мөәзин фәтвасы яки мәзлумә[209] фә фәкыйрь хатыннар шикаятен берничә ай яки елларга яраса да, мәдрәсә идарәләре алай түгел, аның һәр эше, вакыты һәм сәгате кыйммәт. Анда бер шөгъбә[210] арттыру фикере хыял мәхыз[211], боңа хөкүмәт мөсагадә итмәс[212]», – ди. Гашурә, рәгаибләрне бәйрәмгә кертүне муафыйк күрми, аның урынына Фәтхе Мәккә көне (8нче рамазан шәриф көне) куелуын артыграк күрә.

Күрдем[213] –

Ахунд Гариф Киеков[214] уставны мәгъкуль күрдем, ди. Байтак имамнар, мөгаллимнәр вә попечительләр берлә карап ошаттык, фәкать таләбәгә яшь тәгаен ителмәүне һәм Уфа имамнары анда тотылмауны игътибарыңызга куямыз, ди.

Буа –

---

[201] Һәйәт тәгълимия – укыту комитеты.

[202] Ишгар – язу белән, язмача белдерү.

[203] Ишкял – кыенлыклы.

[204] Фәхри – мактаулы, лаеклы.

[205] Малик булу – ия булу.

[206] Икътидар – булдыра алу, куәт.

[207] Олуг Манчыл (Ембай) – Төмән өлкәсендәге авыл.

[208] Ма сива – моңардан башкалары.

[209] Мәзлүмә – җәберләнгән, изелгән.

[210] Шөгъбә – бүлек.

[211] Мәхыз – тик, өчен, фәкать.

[212] Мөсагадә итү – ярдәм итү, булышлык итү.

[213] Күрдем – хәзер Башкортстанның Тәтешле районында урнашкан авыл.

[214] Гарифулла Гали улы Киеков (Гарифулла Чокрый, 1861–1918) – галим, мәгърифәтче, тарихчы, дин эшлеклесе, мөдәррис. Күрдем авылында мәдрәсә ача, өяз ахуны булып тора.

Дамелла Нургали хәзрәт Хәсәнов[215] әйтә:

«Дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллимат програмнары да гүзәл күренәдер. Гакыйбәте[216] хәерле улгай иде. Минем тарафтан әйтелгән сүз шул: мәсләк[217] мөтәвассыйт[218] берлә барылып, яңалык, искелек кеби нәрсәләре бер тараф итәрлек булсын. Дарелмөгаллиматта кызлар мәсьәләсе генә бераз җайсыз күренә. Үзеңезгә мәгълүм, кызларны мәхрәмнәрдән[219] башка читкә йөртүләре бик хәтәр. Хосусан кызларның мондый вакытлары гыйш-гыйшрәт заманнары, бик алама вакытлардыр. Чит милләтләрнең мәктәпләрендә гашыйк, мәхәббәт бик күп ишетелә. Карчыкларга тапшырсаң, гаҗүзә[220] вә саирә[221] макирәләрнең[222] фетнәләре берлә тәварих[223] тулган. Инде читтән анда кызларны йибәрмәсәңез, ул дарелмөгаллиматтан Уфа халкы да гына мостафид булалар[224], читләр мәхрүм калалар. Шул хакта ни эшләрсез икән, берәр тәдбир итсәңез[225] иде. Бу сүзем дарелмөгаллиматны нәфи[226] түгел, бәлки гараз[227] шөбһәдер», – ди.

Пермь –

Имам Лотфулла Байчурин[228]:

«Училищный комитет әгъзалары үз вазыйфаларын камил әда итүләре[229] шарт ителсен һәм үземезнең мохтаҗ улдыкымыз һәм хөкүмәтнең матлабе улдыгы рус телен һәфтәгә[230] акыл 12 сәгатьтән ким булмасын иде», – ди.

Нижний –

Имам Габдрахман әфәнде Сөләймани укыла торган дәресләр арасына байтак фәннәрне арттырып күрсәтә, болай булмаганда, һаман да шул «иске мунча – иске таш» булачак, ди. Мөдир өчен дә байтак фәннәр бүленеше яки гимназия дәрәҗәсендә фөнүни, һәм Мәхкәмәи шәргыя тарафыннан имтихан илә мөсбәт булган[231] голүм диниясе булуы лязем булсын, ди.

---

215 Нургали Хәсәнов (әл-Буави, 1852–1919) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог, «Нурия» мәдрәсәсе мөдире, дин гыйлеме буенча китаплар һәм дәреслекләр авторы.

216 Гакыйбәт – ахыр, азак.

217 Мәсләк – юл.

218 Мөтәвассыйт – уртача, тигез.

219 Мәхрәм – шәригать буенча тыелган нәрсә (өйләнешергә ярамый торган кардәш).

220 Гаҗүзә – карчык.

221 Саирә – юлчы хатын-кыз.

222 Макирә – хәйләкәр хатын-кыз.

223 Тәварих – тарихлар.

224 Мөстәфид булу – файда күрү.

225 Тәдбир итү – тиешле чара күрү.

226 Нәфи – кире кагылган.

227 Гараз – вакытлы хәл.

228 Лотфулла Байчурин – дин эшлеклесе, мәдрәсәләр өчен дәреслекләр авторы.

229 Әда итү – үтәү.

230 Һәфтә – атна.

231 Мөсбәт – исбат ителгән.

Уфа имамнары алда тотылу тәхдиден[232] урынсыз күрә һәм олуг бәйрәмнәр һичбер милләттә 12 көннән ким булмаганын бәян итеп, шәкертләр өчен куелган бәйрәмнәр аз һәм кыска, ди.

Малмыж –

Камал Мозаффаров һәм Гыйззәтулла Хәмидуллин:

«Ел ахырында мәгариф министрына хисаптан копия йибәрелсен, дөхуль имтиханы[233] 15 көн иртәрәк булсын, ятим вә ятимә мулла балалары түләүдән мәгаф булсыннар[234]. Духовный собраниенең бөтен составы училищный комитетта сайлаусыз әгъза булсыннар, дин эшләрендә кайсыларның фикерләре алда тотылсын, сайлау ике төрле (яшерен дә, ачык та) булсын», – диләр.

Әстерхан –

Ахунд Мохтар Салихов:

«Бер үк Коръән мәга[235] тәҗвид кала күрмәсен! Ибтидаи[236] вә рөшди[237] сыйныфларны тәмам иткән кешеләр керсеннәр. Уфа имамнары сайлау җәһәтеннән алда тотылсын, әмма хокук җәһәтеннән алда тотылмасын. Сайлау яшерен тавыш берлә булмасын», – ди.

Бондан башка фикерләрне киләчәктә язармын.

*«Вакыт», 1912, 22 апрель.*

***Үз мохбиремездән***

**Уфада кызлар курсы**

Ике сәнәдән бирле дәвам итә торган Уфадагы җәйге кызлар курсларында бу сәнә 30лап кызлар укыйлар.

Әүвәлге елда 5, икенче елда 20, бу сәнә 30 га җитте. Әүвәл бу курслар ачылгач, бәгъзе бер фанатик хәлфә вә муллалар донослар илә яптырырга йөрсәләр дә, Җиһанша әфәнденең иҗтиһады[238] аркасында курслар дәвам итә килделәр. Шушында укучы кызлар Җиһанша әфәндегә янә югарырак мәктәп ачуын үтенеп, гәзитәмез аркылы үзләренең тәшәккерләрен[239] бәян итәләр.

*«Сибирия», 1912, 29 июль.*

**Уфа**

Уфаның земский управасы гомуми җыенында мөселманнар өчен дарелмөгаллимин[240] (учительская семинария) ачарга карар биргән.

---

[232] Тәхдид – чикләү.
[233] Дөхуль имтиханы – керү имтиханы.
[234] Мәгаф булу – гафу ителү.
[235] Мәга – белән.
[236] Ибтидаи – башлангыч.
[237] Рөшди – урта.
[238] Иҗтиһад – тырышу.
[239] Тәшәккер – рәхмәт сүзе.
[240] Дарелмөгаллимин – ир укытучылар хәзерли торган уку йорты.

Мөфти исеменә ачылачак дарелмөгаллимин илә дарелмөгаллимат[241] эшен караучы комиссия, бу ике мәктәпне дини итеп ачарга ясаган һәм рөхсәт өчен тиешле урыннарына мөрәҗәгать иткән («Дин мәгыйшәт» журналы үзенең максуды булуга шатланыр инде).

*«Сибирия», 1913, 25 гыйнвар.*

***Фәүзия Габдерәшит***

**Мөгаллимәләр өчен мәктәп**

(Идарәгә мәктүб[242])

Гомумән ислам хатыннарының гыйлемнән аз хәбәрдар булуларыны вә гаилә тәрбиясендә бик күп яклардан надан булуларын нәзар[243] игътибарга алып, моннан берничә еллар мөкаддәмнән[244] бирле тәрбияле аналар үстерү, дин вә дөнья ягыннан мөкәммәл[245] дәрәҗәдә хәбәрдар мөгаллимәләр тәрбия итү өчен бер мәктәп ачуны хыялда үстерә идем.

Җәнаб Хакның гыйнаяте[246] илә бу елдан игътибарән[247] хыялымдагы шул һәдәфкә[248] васыйл булу[249] өчен тәрбия вә тәгълим өметендә оста мөгаллимәләрнең иштиракы[250] илә кызларга махсус мәктәп ачтык, вә бу ел марттан игътибарән ибтидаи[251] шөгъбәсенә[252] шәкертләр кабул итә башладык.

Мәктәпнең бирәчәге мәгълүмат: ибтидаи, рөшди[253] вә игъдадый[254] дәрәҗәләрендә улачактыр.

Гомумән мәктәпләрдә кабул ителгән вә дәрәҗәләренә бүленгән голүмнәрдән башка, балалар тәрбиясе, мөгаллимәлек вә йорт эчендә табибәлек, аш пешерү, тегеш вә чигеш кебек беренче лязем[255] голүмнәр дә шәкертләрнең теләгенә, истигъдадына[256] карап тәгълим ителергә булып, програмга кертелде.

Шулай ук чит йирләрдән киләчәк шәкертләр өчен истихзарый[257] сыйныфлар да ачылды.

---

[241] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[242] Мәктүб – хат.
[243] Нәзар – игътибар, уйлау.
[244] Мөкаддәм – элек, әүвәл.
[245] Мөкәммәл – камилләшкән, төгәлләнгән.
[246] Гыйнаять – булышлык, ярдәм.
[247] Игътибарән – әһәмият биреп, искә алып, игътибарга алып.
[248] Һәдәф – төбәү ноктасы, максат.
[249] Васыйл булу – ирешү.
[250] Иштиракъ – катнашу.
[251] Ибтидаи – башлангыч.
[252] Шөгъбә – бүлек.
[253] Рөшди – урта.
[254] Игъдадый – хәзерләү класслары.
[255] Лязем – тиеш, кирәк.
[256] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.
[257] Истихзарый – искә төшерү, кабатлау, хәзерлек.

Һиндыстаннан вә Мисырдан да шәкерт ханымнарның килүе өметле булганга, мәктәбемездә теләүчеләргә ихтыярый сурәттә: татарча, гарәпчә, инглизчә вә русча берлә музыка (пианино) дәресләре күрсәтеләчәктер. Бу дәресләр җөмләсе[258] практика ысулында булачактыр.

Чит мәмләкәтләрдән килүче шәкертләрнең төрле кеше йортында торып укуларыннан тәрбияләренә нәкыс[259] килү ихтималы нәзар игътибарга алынып, мәктәбемезнең янында бер дә пансион ачарга карар ителде.

Пансионда торып укучы ханымнарның әхлакларына вә дини тәрбияләренә дикъкать итәр өчен аерым мөрәббияләр[260] дә хәзерлектәдер.

Мәктәп илә пансионның бергә иҗарәте[261] 150 тәңкәдер (тәхсил[262] заманы 9 ай игътибар ителгән). Тәхсил акчасы икегә бүленеп, беренче кыйсеме[263] сентябрь башында дәресләргә шөругъ[264] ителгән чакта, вә икенче кыйсеме январь башында түләнеләдер.

Мәктәбемезнең идарәи вә икътисади ягы Истанбулның могътәбәр вә гали ханымнары тарафыннан тәэмин ителгәнлектән, матди файда вә зарары һичбер шәхескә гаид булмыйча[265], ялгыз җәмгыять бәшәриягә[266] хезмәт вә галәм исламга тәрбияле вә мәгълүматлы аналар бирүдән гыйбарәттер.

Шушы сәбәпләргә мәбна[267], балаларын укытырга бирү нияте илә мөрәҗәгать итүче ата вә аналарның тәрбияи фәнния вә диниядә балаларының камил тәрбияле вә мөтәдәйин[268] булачакларыннан имин булулары тиештер.

*«Шура», 1913, № 15, б.3 (т.б.).*

***В.Н.***

**Татар дөньясы**

Татарлар уку-укыту эшен кирәксенсәләр дә, ибтидаи[269] мәктәпләрне, дини мәдрәсәләрне төпле нигезгә куя алмыйлар. Шәкертләребезне заманга муафыйк[270] итеп тормышка хәзерләп чыгара алмыйлар. Моның рәсми, гайре рәсми сәбәпләре бар. Рәсми сәбәпләр: татар мәктәп-мәдрәсәләре хакындагы законнар бик иске, яңа правилолар, мәктәпләр хакындагы әмерләр бертигез йөртелмидер. Алар татарларның рухына бик үк муафыйк булып бетмиләр.

[258] Җөмләсе – барысы.
[259] Нәкыс – кимчелек, җитешсезлек.
[260] Мөрәбби, мөрәббия – тәрбияче, караучы.
[261] Иҗарә – вакытлы файдалану, аренда.
[262] Тәхсил – уку, гыйлем алу.
[263] Кыйсем – өлеш.
[264] Шөругъ – керешү.
[265] Гаид булу – карау, бәйләнешле булу.
[266] Бәшәрия – кешелек.
[267] Мәбна – нигезләнгән, корылган.
[268] Мөтәдәйин – динле кеше, диндар.
[269] Ибтидаи – башлангыч.
[270] Муафыйк – яраклы, туры килгән.

Иске мәдрәсәләребезнең күбесе халыкка файда бирә алмадыклары кеби, үзләренең барлыкларын да мең бәла белән генә асрыйлар. Аларның акчалары юк. Башында торырга кешеләре, файдалы дәресләрен укытырга мөдәррисләре юк. Акча да, мөдәррис тә булмагач, андый мәдрәсәләрнең дәвам итмәве бик табигый бер эш. Фәкать файда бирә торган дини, милли мәдрәсәләргә кирәк кадәр акчаның табылмавы, мөдәррисләрнең булмавы бик гаҗәп, коточкыч бер эштер.

Ибтидаи мәктәпләремез дә бик начар хәлдә дәвам итәләр. Рәтле мөгаллим, файдалы дәрес китабы, дәвам иттерергә акчасы, вакыфы юк. Мөгаллим, мөгаллимә йитештерергә урын юк. Ялгыз русча укып, учитель булган татар егетләренең саннары йөзгә бер процент юк. Учительләр илә мөгаллим арасында мөнәсәбәт бик аз. Максат бер булса да, рух бер түгел. Кызлар тәрбиясе артык начар. Әүвәлләре укый белә, яза белми торган остазбикәләр мөгаллимәлек итәләр иде. Хәзер исә укый-яза белә торган абыстайлар мөгаллимәлек итәләр вә бу мөгаллимәләрнең дә фән, ысул тәгълимнән, милли әдәбияттан хәбәрләре бик аз. Әхлаклары төзек түгел. Кызлар мәктәпләре бик кәйфә сурәттә дәвам итәләр. Мөгаллимәләр җитештерә торган рәсми урынымыз юк. Хөкүмәт мәктәпләрендә укучы кызларымызның саны аз улу илә бәрабәр, алар милли мөгаллимә була алмыйлар. Чөнки телләре зәгыйфь. Милли тойгылары аз. Милли мәктәпне тәмам иткән кызларның яшьләре зураю сәбәпле, рус мәктәпләренә керә алмыйлар. Хөкүмәт мәктәпләрендә укучы кызларга дин, тел дәресләре укытылмыйдыр. Чөнки татарлар моны кирәксенгәннәре юк. Әгәр кирәксенсәләр, гимназиялärдәге кызларга дин, тел дәресләре өйрәтер өчен дин мөгаллимәләре куяр иделәр. Уфада утыздан артык мөселман кызы урта мәктәптә укыйлар. Дин, тел дәресе мөгаллимәсе юк. Шуның өчен дә рус мәктәпләрендә укучы кызлар әдәби кичәләрдә, урамнарда үзара да русча сөйләшеп йөриләр. Башка калаларда да шулай. Татар мулласының күбесе татарча, гарәпчә, русча сөйләшә белмиләр. Татар кызының үзе татарча, ата-анасы татарча-русча сөйләшә белмәсә, андый милләткә дини, милли мәдрәсә-мәктәп кирәкми дә торгандыр шул.

Менә югарыда сөйләнгән ихтыяҗларның беразын үтәү, китекләрен тутыру нияте белән булса кирәк, елдагыча бу елда Уфада мөгаллимәләргә махсус язгы курслар ачарга йөрүчеләр бар. [...] Табигый бу хәбәрләрне, курслар хакындагы игъланнарны милли матбугатта укып шатланырга тиештер. Фәкать мин бу хәбәрләрне күреп кайгырам. Бу кайгымны «Тормыш» укучылары илә дә бүлешергә телим.

Кайгырам шуның өчен: Уфада мөгаллимәләр курсының ачылуы бик матлубтыр[271]. Бу курс Уфа губернасындагы мөгаллимәләр өчен булса да, хисапсыз файда бирәчәктер. Фәкать мөгаллимәләр Газыймә ханымның «Вакыт», «Йолдыз» гәзитәләрендәге игъланына күрә, бу курсның гомуми улдыгы аңлашыладыр. Мөгаллимә Газыймә ханым Тәкаеваның язгы мөгал-

[271] Матлуб – теләнгән, соралган.

лимәләр курсы хакындагы игъланы «Тормыш» идарәсенә дә килгән иде. Бу игълан идарәгә килгәч, бу курс хакында җитди мәгълүмат алмак өчен, мөхтәрәмә мөгаллимә Газыймә ханым Тәкаеваның квартирына бардым. Кордаш Газнәви әфәнде мине бик яхшы кабул итте. Минем килгәнемне мөгаллимә ханымга хәбәр бирде. Берничә минуттан соң күрергә мөмкин булдыгыны сөйләде. Фәкать берничә минут үткәч, мөгаллимә ханымның хасталыгыны хәбәр иттеләр. Шулай итеп, шундый мөһим йомыш илә барсам да, мөгаллимә Газыймә ханымның курсы хакында үзене күреп мәгълүмат ала алмадым. Кордаш Газнәви аркылы шул сөальләрне бирдем: «Мөгаллимәләр курсы рәсмиме?», «Рөхсәт алынганмы?», «Програмы ничек?», «Күпме вакыт дәвам итәчәк?», «Мөгаллим, мөгаллимәләр кемнәр?», «Уку хакы никадәр?», «Нинди фәннәргә артык әһәмият биреләчәк?», «Бу курста ничә мөгаллим укый алачак?»

Алган җавабым шул: курска рөхсәт-фәлән юк. Рәсми түгел. Елдагы гадәт буенча гына ачылып киләдер. Уку мөддәте[272], уку хакы, мөфассал[273] програмы, күпме мөгаллимәнең кабул улыначагы мәгълүм түгел. Һәйәт тәгълимиядән[274] мөгаллимә Газыймә Тәкаева, мөгаллим Фәтхелислам әфәнде Тәкаев. Фәтхелислам әфәнде иркендә мөгаллим. Моннан башка кемнәрнең укытачагы мәгълүм түгел. Русча да укылачак имеш.

Мөгаллимә Газыймә ханымның, иптәшләренең хаҗәтләрене үтәү, кимчелекләрене тутыру нияте илә, мөгаллимәләргә махсус язгы курс ачуы бик мөһим, бик зур эштер. Моңа барымыз да шатланырга тиеш иде. Фәкать курс хакында «Тәрҗеман» аркылы алынган җавап, матлубның хилафына[275] чыкты. Чөнки кулда програм, рөхсәт юк. Һәйәт тәгълимия йитәрлек түгел. Моның өстенә, Уфадагы хатыннар җәмгыяте исеменнән мөгаллимәләр курсы ачарга җыеналар. Мөгаллимә Газыймә ханымның моннан да мәгълүматы юк.

Һич булмаса, мөгаллимә Газыймә ханым хатыннар җәмгыяте тарафыннан ачылачак курска кушылып, бергәләшеп ачарга, бергә эшләргә тиеш иде. Әгәр Русиянең һәр йиреннән илле, йөз данә мөгаллимә килсә, Газыймә ханымның курсы боларның теләкләрене үти алачакмы? Яхуд бер калада мөгаллимәләргә махсус ике курс булырга мөмкинме? Бу исә татарларның үзләренә махсус бер сердер. Моның хикмәтен мин аңламыйм. Бу кадәр башбаштаклык итүдә бер хикмәт бар дип әйтә алмыйм. Үткән ел ачылган мөгаллимәләр курсы да шатлык илә каршы алынмады. Төрле яктан һөҗүмнәргә очрады. Газеталарда төрле хәбәрләр таралды. Шулай да улса курс ачылды. Ике айга якын дәвам итте. Төрле йирләрдән байтак мөгаллимәләр килеп укыдылар. Фәкать мөгаллимәләргә махсус булган курска хатыннар җәмгыятенең кайсы әгъзалары үпкәләгәннәр. Шул үпкә басылмаганга күрә, бу елда хатыннар җәмгыяте курс ачу хакында бик акрын хәрәкәт итәдер. Хәлбуки[276] курс кирәк

---

[272] Мөддәт – вакыт, срок.
[273] Мөфассал – тулы, җентекле.
[274] Һәйәт тәгълими – укыту комиссиясе.
[275] Хилаф – каршы, ярамаган эш.
[276] Хәлбуки – ләкин.

һәм дә укырга килгән мөгаллимәләрнең теләкләрене үтәрлек булырга тиеш. Курс ачыламы, юкмы, дия идарәгә күп хатлар киләдер. Менә бу мәкалә барысына да бердән җавап булыр дип беләм. Хәзергә курсның исеме генә бар. Киләчәктә ничек булып чыгар, янә язармын. [...]

Татарларда һәр нәрсә бар. Фәкать яхшы мәктәп, яхшы мөгаллимә, мөгаллим, халык илә хөкүмәт арасында васита[277] булырлык, чын мәгънәсе илә халык файдасына хезмәт итәрдәй яхшы имамнар гына юк. Булса да бик аз. Мин үз тарафымнан имамнар, мөгаллимнәр, мөгаллимәләр йитештерә торган гыйлем йортлары, җәйге тәрбия курслары ачарга тәүсыя итәр[278] идем. Мондый мөһим эшләрнең башында, татар милләтенең киләчәген төшенеп, аның бәхетле булуына хезмәт итүче, әһел[279] булган затларның булынуын теләр идем. Ходай насыйп итсен дә, шуларны күрсәк иде. Алдашудан, хакыйкатьне яшерүдән, шәхси файдаларга гына әсир булудан котылырга вакыт. Милләт шул чакта гына бәхетле булыр.

*«Тормыш», 1914, 30 март.*

***Маһруй Мозаффария***

**Мөгаллим вә мөгаллимәләргә ачык хат**

Яз йитте. Балалар имтиханга, мөгаллим вә мөгаллимәләр истирахәткә[280] хәзерләнәләр. Имтихан йитә дип һәр бала шатлана-шатлана имтиханга хәзерләнә. Имтихан кирәкме? Кирәк түгелме? Хәзергә ул турыда язарга теләмим. Фәкать имтиханнан соң җәйге тәгътыйль[281] вакытында мөгаллим вә мөгаллимәләр өстендә янә бер эш, бер вазыйфа кала. Шул тугрыда гына бер-ике сүз әйтмәкче булам.

Безнең хәзер иң игътибарга алырлык эшебез – мөгаллимәләребез, аларның хәлләре, укулары, укытуларыдыр. Мөгаллимәләребез кыш укыта. Ләкин җәйдә тәгътыйль вакытында мәгълүматларын, белемнәрен арттыру өчен янә укыйсылары килгәнлеге сизелә. Шуның өчен мөселманның күбе мөгаллим вә мөгаллимәләрнең иң җыела торган урыны булган шәһәребез Казанда берничә мөгаллим вә мөгаллимәләр җыелышып, җәйге курс ачсак, ничек булыр иде икән? Үткән ел Уфада ачтылар, укыттылар. Бәлки бу ел да ачарлар, укытырлар. Ләкин мин Казан мөгаллим вә мөгаллимәләренең ул эшкә тәшәббес итмәүләренә[282] тәэссеф итәм, кайгырам. Үткән җәйдә Казанда шундый мөгаллимәләр укырдай курсның булмавыннан аптырап йөргән берничә мөгаллимәне мин үз күзем белән күрдем. Ихтыяҗыбыз нисбәтендә ул сан бу ел күбрәк булыр дип уйлыйм. Шуның өчен вакытны бер дә

[277] Васита – арадашчы.
[278] Тәүсыя итү – киңәш бирү, эшне тапшыру.
[279] Әһел – белгеч.
[280] Истирахәт – ял итү, эштән бушап тору.
[281] Тәгътыйль – каникул.
[282] Тәшәббес итү – керешү, эшкә тотыру.

үткәрми, бу көннән хәзерлик, сөйләшик. Һәм тиешле урынына мөрәҗәгать итеп, рөхсәт алып эшкә башлыйк.

*«Сөембикә», 1914, № 11, б.19.*

***Газыймә Тәкаева***

**Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!**

48нче номерлы гәзитәгезнең баш мәкаләсендә[283] безнең тарафтан ачылачак курста һәйәт тәгълимиянең[284] азлыгы, уку мөддәте[285], мөфассал[286] програмның юклыгы, күпме укучы кабул ителәчәге хакында ачык мәгълүматның юклыгы күргәзеләдер.

Бу хакта борадәранем[287] Газнәви яңлыш мәгълүмат биргән булса кирәк. Бинаән галәйһи[288], шушы тәсхихны[289] басуыгызны үтенәмен.

1) һәйәт тәгълимиядән хәзергә мөгаллимә Газыймә Тәкаева илә мөгаллим Фәтхелислам әфәнде күргәзелсә дә, укучылар күп булып, бер мөгаллимә илә бер мөгаллимнең җитешмәве ихтималы булганга, дәхый икъдарлы[290] бер мөгаллим яки мөгаллимә алыначактыр;

2) уку мөддәте[291] май числосының 5 ндә башлап, август башына кадәр булачак;

3) уку хакы аена 2 сум, читтән килүчеләрдән үз квартирымызда ятып укырга теләүчеләр булса, квартир хакы илә бәрабәр 4 сум, йиймәк[292] – эчмәкләре безем өстемездә булган тәкъдирдә, аена 15 сум алыначак;

4) програм исә, ошбу көнгә кадәр «мәктәб Назыйрия»дә укытылып килгән програмымыз бар, шул програмымызны нәмунә[293] тотып, бәгъзе йирләрене арттырып, ислах вә изах ителеп[294] укытылачактыр;

5) мәктәбемездә 50 дән артык кыз сыярлык урынымыз бар. Илледән артык алынмаячактыр. Кызлар утыздан арткан тәкъдирдә, янә укытыр өчен янымызга бер мөгаллим яки мөгаллимә алыначактыр;

6) русча укылу хәзердән катгый мәгълүм түгел, әгәр җыелган кызлар теләсәләр генә, учительница алыначактыр.

---

[283] *В.Н.* Татар дөньясы // Тормыш. 1914. 30 март.
[284] Һәйәт тәгълими – уку комиссиясе.
[285] Мөддәт – срок.
[286] Мөфассал – җентекле, тулы.
[287] Борадәран – бертуган.
[288] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шул нигездә, шул сәбәпле.
[289] Тәсхих – төзәтү, дөресләү.
[290] Икъдарлы – көче җитә торган.
[291] Мөддәт – срок.
[292] Йиймәк – ашау.
[293] Нәмунә – үрнәк.
[294] Изах ителү – ачык итеп аңлату.

***Идарә:***

Мөгаллимә Газыймә ханым изахәтеннән[295] аңлашылдыгына күрә, бу курс мөгаллимәләргә улмыйча, кызлар өчен ибтидаи[296] тәрбия бирә торган бер нәрсә булачак. Чөнки ибтидаи мәктәпнең програмын никадәр үзгәртсәң дә, мөгаллимәләр өчен аның әһәмияте юк. Шулай да булса, Газыймә ханым рөхсәт алуны, програмның ничек булдыгыны тәфсилле итеп язмыйдыр. Газыймә ханым үзе Уфада ибтидаи мәктәптә мөгаллимәлек итдеке хәлдә, Уфаның зыялы хатыннары, мөгаллимәләре илә бер дә киңәшми, гади бер эш итеп кенә мөгаллимәләр курсы ачарга җыенуына тәгаҗҗеб итәмез[297]. Газыймә ханым бу хосуста хатыннар җәмгыяте әгъзалары илә дә фикер алышмаган. Фәкать без бу курсның көтелгән файданы бирүенә ышана алмыймыз.

*«Тормыш», 1914, 2 апрель.*

***М.Ягъкубова***

**Мөгаллимәләр курсы**

Дөньяда тормыш кирәкләремез бик күп булып, йитешмәгән йирләремез дә әйтеп бетергесездер. Заман үткән саен, ихтыяҗларымыз да күбәеп, аша бара. Бүгенге эшемез иртәгә ярамаган шикелле, иртәгенең аргы көнгә ярамавы бездә табигый. Безнең күп эшләргә хәзерлексезлегемез, һәммә нәрсәне йиңелгә санап, гаять читен вә мәсьүлиятле[298] булган эшләремезгә дә өстән генә карап, әһәмиятсез санавыбыз киң адымнарымызны тарайта. Бездә мөляхәзәсезлек[299], эшнең нәтиҗәсенә илтифат итмәүчелек бик нык хөкем сөрә. Безнең эшләремезнең күбесе бер әсаска[300] куелмадыгыннан, һәрвакыт урта юлда кала яисә шулай ярты-йорты булса да алып барырга тырышыла. Әсаслы, төпле бер нигезгә корылмаган эштән файда чыкмавы, аның нәтиҗәсез калуы хәзер ачык аңланды. Моңа һәркем үз-үзеннән төшенә башлады. Югарыда әйткән күп ихтыяҗларымызның иң мөһиме, иң кирәклесе дә хәзердә мөгаллимәләремезнең азлыгы, аларның йитешмәведер. Кызларыбыз өчен яхшы тәртипле мәктәпләремезнең юклыгы, күптән сөйләнеп килгән дарелмөгаллиматларымызның бөтенләй онытылып баруы мөгаллимәләргә ихтыяҗны елдан-ел арттырадыр. Шул ихтыяҗ вә кимчелекләремезне тутыру максаты белән, укучы яшь кызларымызның укуга һәвәсләреннән, аларның мөгаллимә булырга теләгән дәртләреннән файдаланып, «мөгаллимәләр курсы» исемендә Уфада курс ачучылар еш кына күренә башлады. Үткән 1912нче елда ялгыз Уфада «мөгаллимәләр курсы» исеме белән дүрт урында курс ачылды. Аларның берсе – «Ханымнар җәмгыяте» тарафыннан ачылган рәсми курс иде. Калган өчесе мөгаллимә Газыймә Тәкаева, Камилә Касыймова, Хәдичә ханым Нур-

---

[295] Изахәт – аңлатма.
[296] Ибтидаи – башлангыч.
[297] Тәгаҗҗеб итү – гаҗәпләнү.
[298] Мәсьүлиятле – җаваплылык.
[299] Мөляхәзәсезлек – игътибар, уйлап фикер йөртмәү.
[300] Әсас – нигез.

мөхәммәтовалар кул астында ачылган гайре рәсми курслар иде. Бу курсларның һәркайсына әтрафтан азмы-күпме мөгаллимәләр җыелып, бер-ике ай укуда дәвам итеп, таралдылар. Бу курслардан күпме файдалана алганнардыр, анысы үзләренә билгеле.

Гәзитәләрдәге игъланнарга күрә, бу сәнә Уфада янә мөгаллимәләр курсы ачу артыннан йөрүчеләр барлыгы беленде. Ләкин бу курс ачу һаман шул әүвәлге йөзеннән бер дә үзгәрмәгәнгә ошый. Мадам ки[301] дарелмөгаллиматларымыз юк икән, ысуле тәгълим манигы[302] булган җәйге курслар күптән ислах кылынырга тиеш иде инде. Әүвәл эшләр бездә бөтенләй башка юл белән бара. Менә әүвәлге үз тәртибе, үз белдеге белән генә укытып килгән мөгаллимә Газыймә ханым бу җәй өенә курс ачарга теләгәнлеген игълан итә. «Тормыш»ның 49нчы санында ул, 50гәчә ханымнар җыярга теләгәнлеген белдерә[303]. Газыймә ханымның ни дәрәҗәдә тәрбия күргәнлеген, аның укыту эшендәге икътидарын[304] Уфаның күзе ачык ханымнардан байтак белүчеләр бардыр. Мин үзем дә Уфада үскәнлегемнән, андагы мөгаллимәләр хәле белән байтак танышмын. Хәзергә курс ачарга теләгән Газыймә ханымны да бик яхшы беләм. Ул үзе баштан һичбер юньле мәктәп күрмәгән. Затән[305], ул вакытларда низамлы[306] мәктәпләр дә булмаган. Газыймә ханым исә соң көннәрендә, олыгайгач, өйдә генә рәфигыннан[307] аз-маз мәгълүмат алып, юклы-барлы бер көч белән генә мөгаллимәлек итеп киләдер. Газыймә ханымда, түгел мөгаллимәләр курсы ачып, аны идарә кылу, бәлки мин аңарда ибтидаи[308] мәктәптә дә заман теләгәнчә алып барырлык икътидар таба алмыйм. Ул курстагы һәйәт тәгълимиядән укучылар канәгатьләнерлек нәтиҗә чыгар дип уйламыйм. Бу сүзләр ачы аңлашылмасын. Газыймә ханымның шәхесенә ихтирамым бик зур. Тик мин бу мәсьәләне милли вә мөкаддәс эш булуы җәһәтеннән сөйлим. Хәзерге мөгаллимәләремезнең теләкләре бик зур һәм шулай булырга да кирәк. Аларның бөек өметләрен урынына йиткезү өчен, үзе тәртипле мәктәп күрмәгән, уку-укыту ысулларын яхшылап белмәгән бер ханымның мондый бер эшкә керешүенә тәгаҗҗеб итәм[309]. Аның бу курска тәшәббесе[310] фәкать саф зиһенле, яшь йөрәк ханымнарымызның зиһеннәрен генә бутау булачагына һич шөбһә итмим. Инде һәр нәрсәне үз әһеленә[311] тапшыра торган вакыт йиткән. Алдын-артын уйламый, һәркайдан бер калкып чыгып, «курс» исеме белән кычкыра торган

---

[301] Мадам – дәвам иткәнчә.
[302] Манигъ – тыючы, тоткарлаучы.
[303] *Газыймә Тәкаева.* Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде // Тормыш. 1914. 2 апрель.
[304] Икътидар – кулдан килү, булдыра алу.
[305] Затән – нигездә.
[306] Низам – кагыйдә.
[307] Рәфикъ – тормыш иптәше, ир.
[308] Ибтидаи – башлангыч.
[309] Тәгаҗҗеб итү – гаҗәпләнү.
[310] Тәшәббес – бер эшкә тотыну.
[311] Әһел – белгеч.

заман түгел. Әле 1912нче елга «Хатыннар җәмгыяте» тарафыннан ачылган курста да (ул елны мин үзем дә шул курста укыдым) яхшы ук шөһрәт чыгарган ирләр мөгаллимлек итсәләр дә, ханымнарның нарасыйлыгы бик күп иде. Әлбәттә, ул вакыттагы мөгаллимнәр белән Газыймә ханымны мин чагыштыра алмыйм. Аларның арасында әллә никадәр аермалар табам. Шулай булгач, аның курс исеме белән кычкыруы буш фарс, тиешсез бер хыял гына димен. Бинаән галәйһи[312], аңлы яшь ханымнар, чит йирләрдән расходланып, Уфага мондый курслар исеменә килмәсләр дип уйлыйм. Газыймә ханымга да мәгълүматтан тәүсигъ итү[313] өчен берәр курска керүен тәүсыя кылам[314].

*«Тормыш», 1914, 2 май*

***Әсма Вәлиуллина***
***Кәримә Мәмлиева***
***Фәгыйлә Мөхәммәдиева***
***Тәгъзимә Сафуанова***

**Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!**

Хакыйкать наменә ошбу рәддиямезгә[315] гәзитәңездә урын бирүеңезне чын күңелемездән үтенәмез.

Могътәбәр «Тормыш» гәзитәсенең 59нчы номерында «Мөгаллимәләр курсы» гонваны[316] илә М. ханым Ягъкубова тарафыннан озын мәкалә язылып[317], Ягъкубованың күп сүзләре, хосусан мөгаллимә Газыймә ханым хакында булган сүзләре, хакыйкатьтән ерак булдыгыннан, вөҗданан хакыйкать хәлне гаммәгә[318] мәгълүм кылырга мәҗбүр булдык.

Мәкалә сахибәсе[319] мөгаллимә Газыймә ханым Тәкаеваның бу илә курслар ачарга икътидары[320] булмауны вә аның низамлы мәктәпләр күрмәгәнен, бәлки зурайгач кына рәфигыннан аз-маз мәгълүмат алып, юклыбарлы көч белән генә мөгаллимәлек иттегене сөйләгәннән соң, мөгаллимә Газыймә ханымның түгел мөгаллимәләр курсы ачып идарә кылуы, бәлки ибтидаи[321] мәктәпне дә заман теләгәнчә алып барырлык икътидар тапмыйм, диеп сөйли вә әтрафтан ханымнарның Уфага килмәүләрене һич вә кайда мәэмүл[322] түгел идекен бәян итеп, мөгаллимә Газыймә ханымга берәр курска кереп укырга тәүсыя[323] илә сүзене тәмам итә. М. ханым Ягъкубованың бу

[312] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шул сәбәпле.
[313] Тәүсигъ итү – киңәйтү, артыру.
[314] Тәүсыя кылу – теләү.
[315] Рәддия – кире кагу.
[316] Гонван – мәкалә исеме.
[317] *М.Ягъкубова.* Мөгаллимәләр курсы // Тормыш. 1914. 2 май.
[318] Гаммә – халык.
[319] Сахибә – хатын-кыз автор.
[320] Икътидар – көч.
[321] Ибтидаи – башлангыч.
[322] Мәэмүл – булуы күздә тотылган.
[323] Тәүсыя кылу – васыять итү.

сүзләренә бәгырьләремез кайнады. Мөхтәрәмә мөгаллимә Газыймә ханым ничә елдан бирле һimmәтле[324] Садретдин әфәнде Назыйри җәнабләренең 2нче мәктәбендә мөгаллимәлек итә. Вә һәр елны никадәр шәкертләр укытып, халыкның рәхмәтләрен ишетергә муафыйк була. Мөгаллимә Газыймә ханымның үзеннән йитешкән мөгаллимәләре һәр елны төрле әтрафта соңгы ысул илә мөгаллимәлек итәләр. Вә һәр тарафта әһали[325] мөгаллимәләренең укытуыннан мәмнүн калалар[326]. Газыймә ханымның 9 сәнәдән бирле «Назыйрия» мәктәбендә мөгаллимәлек итүе вә укытуыннан әһали мәмнүн булып, елдан-ел мөгаллимә Газыймә ханым да шәкертләрнең күбәюе вә үзеннән йитешкән әллә никадәр мөгаллимәләре һәр йирдә мөгаллимәлек итеп, әһалинең мәхәббәтен җәлеп кылулары Газыймә ханымның М.Ягъкубова дидекенчә булмый, бәлки милләтемезнең барышы нисбәтендәге мөгаллимәләремезнең икътидарлыкларыннан булдыгын ачык күрсәтсә кирәк.

М.Ягъкубованың мондый сүзләре илән гәзитә сәхифәләрен ишгаль итеп[327], газизә остазымыз Газыймә ханымны тәхъкыйрь итүенә[328] түбәндә исемнәре мәзкүр[329] ханымнар җитди сурәттә үпкә бәян итәмез. М. ханым Ягъкубованың сүзләренә әһалинең әһәмият бирмәүләрен, курска киләчәк ханымнарның да курска килүдән күңелләре суынмауны тәүсыя кыламыз. М.Ягъкубовага ошбудан курслар муафыйкъ булмаса, мөкәммәл, заманага муафыйк курслар ачып, дидекенчә милләтемез өчен иң мөһим вә кирәкле булган ошбундай милли вә мөкаддәси эшләргә тәшәббес итүене[330] үзеннән үтенәмез.

Мөгаллимә Газыймә ханым Тәкаева шәкертләреннән мөгаллимәләр: Әсма Вәлиуллина, Кәримә Мәмлиева, Фәгыйлә Мөхәммәдиева, Тәгъзимә Сафуанова.

*«Тормыш», 1914, 7 май.*

***Габди***[331]

**Мөгаллим вә мөгаллимәләргә**

Мөтәрәккый[332] милләтләрнең һәр сыйныфы үзләренең хокукларын химая[333] вә башларына килгән бәлаләреннән котылу өчен үзләренә махсус җәмгыятьләр тәэсис кылганнар[334]. Мәсәлән: руханилар, мөгалимнәр, студентлар, приказчиклар, эшчеләрнең – һәркаюсының махсус җәмгыятьләре бар.

---

[324] Һиммәтле – тырыш, булдыклы.
[325] Әһали – халык.
[326] Мәмнүн калу – канәгать, риза булу.
[327] Ишгаль итү – яктырту.
[328] Тәхъкыйрь итү – хурлау, мыскыл итү.
[329] Мәзкүр – искә алынган, билгеле.
[330] Тәшәббес итү – керешү.
[331] Габди – Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов (1887–1938) – җәмәгать һәм сәясәт-дәүләт эшлеклесе, күренекле татар язучысы, тел галиме, дәреслекләр авторы.
[332] Мөтәрәккый – алга киткән.
[333] Химая – ялкау, саклау.
[334] Тәэсис кылу – төзү.

Аларның гали сыйныфларын тәшкил иткән рухани, студентлары шул җәмгыятьләре аркасында искиткеч эшләр эшләдеке кеби, түбән сыйныфларны тәшкил иткән приказчик вә эшчеләре дә шул җәмгыятьләре аркасында күп эшләр эшлиләр: балаларын укытыр өчен мәктәпләр тәэсис итәләр. Үзләренең мәгълүматларын тәүсигъ[335] өчен ахшам[336] дәресләре ачалар. Тәгътыйль[337] вакытларында сәламәтлекләрен арттыру өчен сайфияләр[338] ачалар. Авыру яки башка берәр манигъ[339] сәбәпле берәрсе эштән тукталырга мәҗбүр булса, мәгыйшәтен тәэмин кыйлалар, үлсә, балаларын тәрбия кыйлалар. Шуның кеби әллә никадәр файдалы эшләр эшлиләр. Алар җәмгыятьләр ачалар, эшлиләр – чөнки яшәргә телиләр.

Безнең татар милләтендә дә хәзерге вакытта беркадәре җәмгыятьләр булып, үз даирәләрендә яхшы гына эшләр эшлиләр. Мәсәлән: Уфа, Пермь җәмгыять хәйрияләре һөнәр мәктәпләре тәрбия кылалар. Уфадагы «Мөселман ханымнар җәмгыяте хәйриясе» әллә никадәр кызлар мәктәпләре тәрбия кыла. Оренбургта «Русча укучыларга ярдәм җәмгыяте» милли тәрбия илә рус мәктәпләренә хәзерли. Хөласа[340], кайда гына берәр җәмгыять исеме булса, шунда яхшы сәмәрәсе[341] күренеп тора. Ләкин, мәгаттәәссеф[342], милләтнең иң мөһим кыйсемене[343] тәшкил итмеш мөгаллим вә мөгаллимәләремезгә махсус җәмгыятемез юк. Шуның өчен анларга тәвәкъкыф иткән[344] милли мәктәпләремез дә көтелгән файдаларны бирми. Мәсәлән, яхшырак мөгаллимнәр чыгара торган мәктәпләремез өч-дүрт кенә данә булып, анлардан күп булса елга 40–50 мөгаллим чыга; хәлбуки[345], 25миллионлы бер милләткә ул кадәре генә мөгаллим җитми. Шунлыктан мәктәпләремезнең күбесе гыйлем вә тәрбиядән хәбәре булмаган мөгаллимнәр кулында тәрбияләнә. Алар тәгътыйль вакытларында мәгълүматларын тәүсигъ кылырлар иде, вакытлы курсларымыз юк.

Мөгаллимнәремезнең хәлләре бигрәк аяныч, чөнки анларга махсус рөшдидән[346] өстен мәктәпләремез хәзер дә юк. Мәктәпләремездәге програм вә дәрес китаплары да соң дәрәҗә чуалчык булып, алар тугрысында җитди мөзакәрә кылып[347], бер карарга килгәнемез юк. Хәтта бездән өметне өзеп, бәгъзе земстволар үзләре китаплар интихаб кылып[348], безгә програм тәртип

[335] Тәүсигъ – арттыру, киңәйтү.
[336] Ахшам (акшам) – кичке.
[337] Тәгътыйль – каникул.
[338] Сайфия – дача.
[339] Манигъ – каршылык, киртә.
[340] Хөласа – кыскасы.
[341] Сәмәрә – җимеш.
[342] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.
[343] Кыйсем – өлеш.
[344] Тәвәкъкыф итү – тукталу, урнашып, эш алып бару.
[345] Хәлбуки – ләкин.
[346] Рөшди – урта.
[347] Мөзакәрә кылу – фикер алышу.
[348] Интихаб кылу – сайлап алу.

кыла башладылар. Халәнки[349], ул мөгаллим вә мөгаллимәләр вазыйфасы иде. Әгәр дә шул нәрсәләрне нәзар дикъкатькә[350] алып яшәргә теләсәк, әлбәттә, безгә мөгаллим вә мөгаллимәләремезнең мәгълүматларын тәүсигъ өчен җәйге курслар ачуы, бәгъзе манигълар сәбәпле хезмәтсез калган мөгаллим вә мөгаллимәләремезнең хәлләрен яхшырту, мәктәпләремезгә дәрес китаплары интихаб кылып, програмнар тәртип кылу, гыйльми сәяхәтләр ясау, гыйльми бер җәридә[351] чыгару, үземезнең хокукларымызны химая кылу өчен бер җәмгыять кирәк. Рөхсәт алу, матди җәһәтләрен карау, урын тәгаен кылу кебек мәсьәләләр матбугат васитасы илә[352] мөзакәрә кылынып хәл кылына торган мәсьәләләрдер. Шул фикергә мөгаллим вә мөгаллимәләрнең нәзар дикъкатьләрен җәлеп итәмен.

*«Тормыш», 1914, 11 июль.*

## [15 июльдә…]

15 июльдә Газыймә ханым Тәкаева идарәсендә булган җәйге курста имтиханнар башланды. Ханымнар өчен җәйге курсның имтиханын күрик дип байтак халык җыелган иде. Иртә белән бер имам һәм студент та булдылар. Кызлар яхшы җавап бирәләр, ләкин 40 градуслы эссе көндә калын кара шәл ябынып утыру кирәкмәс иде. Ул кызлар көз көне мөгаллимә булып авылларга китәчәкләр.

*«Тормыш», 1914, 16 июль.*

***Мәрьям Кәримия***

## Мөгаллимәләр курсы

Күршеләремез руслар, әллә никадәр дарелмөгаллимин[353], дарелмөгаллиматлар[354] булдыгы хәлдә, һәр елны йөз-меңнәр тотып, дистәләп мөгаллим вә мөгаллимәләр өчен курслар ачалар. Әллә кайдан профессорлар чакырып, мөгаллим, мөгаллимәләрнең мәгълүматларын киңәйтәләр; артыгы белән ысул тәгълимнән[355] хәбәрдар итәләр. Бу эш бер русларда гына түгел, башка милләтләрдә дә шулай. Ник бу эштән берәр данә булсын, дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллимате булмаган безнең татар милләте генә мәхрүм иде. Фәкать соң заманда милләтемезнең аңлы сыйныфы бу эшкә әһәмият бирә, һәм һәр ел диярлек берничә урында мөгаллим-мөгаллимәләр өчен җәйге курслар ача башлады. Җөмләдән берсе бу ел Бәләбәйдә мөгаллимәләр курсы булды.

---

[349] Халәнки – чынлыкта.
[350] Нәзар дикъкатькә – игътибар үзәгенә.
[351] Җәридә – газета.
[352] Васитасы илә – аркылы.
[353] Дарелмөгаллимин – ир укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[354] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз мөгаллимәләр хәзерли торган уку йорты.
[355] Ысул тәгълим – укыту ысулы, методы.

Курс майның 15еннән башлап, 27нче июльгә кадәр дәвам итте. Курста барысы 45 кыз булып, дүрт сыйныфка бүленеп укытылды. Иң югары сыйныфны ике ханым тәмам итте. Болардан башка янә 15 ханым беренче рөшдидән[356] имтихан биреп, һәммәсе русча шәһадәтнамә алдылар.

Курсның программасында күбрәк урын ысул тәгълим, фән һәм кул һөнәрләренә бирелгән иде. Килгән ханымнар һәрберсеннән яхшы мәгълүмат алып таралдылар.

Гомумән, курсның программасындагы бәгъзе кимчелекләр илә мөгаллим әфәнделәрнең уку вакытында берничә көн читтә, кунакта йөреп килүләре шикелле килешсезлекләрне санамадык, курс яхшы муаффәкыятьле[357] үтте.

Ялгыз үз тырышлыклары илә мөгаллимәләр курсы ачып, милләтемез эченә аңлы вә ысул тәгълимнән хәбәрдар мөгаллимәләр таратулары өчен мөгаллим Газыйм әфәнде илә ахун Хурамшин җәнабләренә тәшәккер итәмез[358].

*«Тормыш», 1914, 20 август.*

***Вәли Хангилдин***[359]

## Ханымнар арасында

«Мәдрәсәи Галия»не бетергәннән соң, бу ел җәй көне Уфада калырга тугры килде. Табигый, шәһәрдә эшсез тамак туйдырып булмый. Бигрәк тә безнең кебек татар шәкертләре бер көн эшсез торды исә, икенче көнне ашарга таба алмаганнан, истирахәт итәчәк[360] заманында, бөтенләй киресенчә, төрле авырлыклар йөкләргә тугры килә. Менә мин шул җөмләдән булдым. Уфалыларга билгеле, быел Уфада ханымнар тарафыннан дүрт күз белән көтелсә дә, артыннан тырышып йөрүчеләр булмадыгыннан, мөгаллимәләр курсы булмады. Кыш буе косурларын[361] төзәтергә сусап торган мөгаллимәләремез, әллә ачылыр әле өмете илә Уфага җыелдылар. Ләкин ни чаклы көтсәләр дә, теләкләре кабул булмады. Кайтып китәргә мәҗбүр булдылар. Бәгъзеләре һаман да калып, хосусый укырга мөгаллим эзли башладылар. Бер көнне мине дә берничә ханым килеп тапты. Менә миңа май числосыннан шул көнгә кадәр ханымнар дөньясы арасында буталырга, аларның гыйлем, фикер җәһәтләре илә танышырга туры килде. Ләкин тәәссефкә, мин авыл галәмене үземнең бу көнгәчә уйлаганымның бөтенләй киресенчә таптым.

Ханымнарыбызның гыйлем җәһәтләре бик түбән икән, ибтидаи[362] сыйныфларга хак илә тәрбия бирерлек мөгаллимәләрнең бик сирәк икәнен

---

[356] Рөшди – урта.

[357] Муаффәкыятьле – уңышлы.

[358] Тәшәккер итү – рәхмәт әйтү.

[359] Вәли Нигъмәтулла улы Хангилдин (1891–1971) – мәгърифәтче, мөгаллим, галим, татар тел белеме буенча хезмәтләр авторы.

[360] Истирахәт итү – ял итү.

[361] Косур – кимчелек, җитешсезлек.

[362] Ибтидаи – башлангыч.

күрдем. Шулай була торып, бәгъзеләренең рөшди[363] сыйныфларын тәрбия иттек диюләренә бик кайгырдым.

Дөрес, боларның бәгъзеләре үзләренең косурларын беләләр, ләкин ихтыярсыз үзебезнең ятлап алганны укытырга мәҗбүр булабыз, диләр. Моның өчен үзләренең укыган мәктәпләренең идарә итүчеләрен, андагы мөгаллимәләрнең икътидарсызлыгын [364] сәбәп күрсәтәләр. Чынлап та, аңлашылдыгына күрә, рөшди сыйныфлардан тәрбия итә торган мәктәпләр гел буяудан гыйбарәт икәне күренә. Шуның өчен дә, алар моннан соң ханымнар мәктәбеннән үтенәләр: мөмкин кадәр мөгаллимә чыгара торган мәктәпләргә икътидарлырак мөгаллимәләр куелсын иде. Кем тугры килсә, шул мөгаллимә булып, балаларның башларын черетмәсен иде, диләр. Менә бу сыйныфның шундый зарланулары мине бу юлларны язарга мәҗбүр итте. Затән[365], ханымнарның мәктәпләре болай без аңлаганча идарә ителә торган булса, бик түбән, гыйльми җәһәте байтак әхлакка мохтаҗ икәне күренә.

*«Тормыш», 1914, 24 август.*

**Гәзитәләремездән**

Мөгаллимәлеккә имтихан. 15нче сентябрьдә Оренбургта мөгаллимә Нәйрә ханымның курсында укыган 2 ханым әфәнде «Мәдрәсәи Хөсәения» мөгаллимнәреннән төзелгән имтихан комиссиясе хозурында мөгаллимәлеккә имтихан биргәннәр. Имтиханда аларның яхшы мәгълүматлы икәнлекләре аңлашылып, мөселманча мөгаллимәлек шәһадәтнамәсе бирергә булганнар. Бу хәбәрне язган «Вакыт» гәзитәсе үз тарафыннан шул фикерне бәян итә. «Һәр йирдә шулай икътидарлы мөгаллимнәр тарафыннан имтихан комиссияләре ясалып, теләгән ханымнарны шул комиссия хозурында имтихан үткәреп, соңрак кулларына шәһадәтнамә бирелсә, мөгаллимә алучыларга мөгаллимәләрнең мәгълүматы билгеле булыр, вә шул шәһадәтнамә Идарәи руханиягә[366] җибәрелеп тасдыйк ителсә[367], рәсмият өчен дә беркадәр ярар иде. Шәһадәтнамә[368] бирә торган махсус дарелмөгаллиматларымыз булмаганлыктан, хәзерлек бу бердән-бер чара һәм дә һич артка ташларга ярамый торган бер чарадыр.

Имтихан комиссияләре һәр шәһәрнең үзендә бер мөдәрриснең иштиракы[369] илән ясалып, мөмкин булганда, бу комиссиягә ханымнардан да берәр кеше катыштырырга ярыйдыр.

*«Тормыш», 1914, 5 октябрь.*

---

[363] Рөшди – урта.
[364] Икътидарсызлык – кулдан килмәү, булдыра алмау.
[365] Затән – нигездә.
[366] Идарәи рухания – Оренбург мөселман диния нәзарәте.
[367] Тасдыйк ителү – раслану.
[368] Шәһадәтнамә – свидетельство.
[369] Иштиракъ – тырышлык.

***Һади Таһири***

**Кызлар гимназиясе хакында**

Могътәбәр «Шура» мәҗәлләсенең[370] 20нче гадәдендә[371] бала тәрбиясе хакында язган мәкаләсендә Габделхәмит әл-Мөслими әфәнде милли кызлар гимназиясе ачарга тиеш таба[372]. Мәкаләсенең әүвәлендә хәзерге хәлдә дип әйтсә дә, соңга табарак «бүген яхуд иртәгә димимен», диядер.

Фикер касыйрмән[373] күрә, безгә гимназияләрдән хаҗәт кылмак вә хосусан кызлар гимназиясеннән дәм[374] өрмәк иртәрәк. Безгә ысуллы вә тәртипле ибтидаи[375] мәктәпләр кирәк. Шәһәрләрнең күбесендә тәрбияле мәктәпләр булса да, карья[376] җирләрендә, галәлхосус[377], Русия мөселманнарының мәркәзе булган Казан әтрафындагы[378] карьяләрдә, тәртипле мәктәпләр аз. Милләтнең күбрәк кыйсеме[379] карьяләрдә яшиләр. Мадамәгә[380] карьяләрдә тәрбия йирендә булмаса, вә анда тәртипле вә ысуллы мәктәпләр булмаса, безнең милләт тә тәрбия йирендә булмас. Шәһәрләрдә икамәт итмәктә[381] булган кешеләрнең күбрәге шул ук карьядан күчеп килгән буладыр. Юньлебашлы ибтидаи мәктәпләре булмаган бер милләткә гимназияләр ачуга мәслихәт[382] бирмәк, бер кечкенә генә урам кибете ачарлык сумма вә сәрмаясы[383] булмаган бер кешегә магазин ачуга мәслихәт бирмәк кеби урынсызрак мәслихәт булмасмы? Югарыда күп карья вә авылларда тәртипле мәктәп ибтидаиләр юк дидем. Бу сүзләрне исә мин ирләр мәктәбе хакында әйттем. Кызлар мәктәбе хакында эшләр бөтенләй башкача. Алар әле һәнүз[384] остазбикә-абыстайларның бәрән вә бозау ояларыннан чыкканнары юк.

[370] Мәҗәллә – журнал, җыентык, китап.

[371] Гадәд – сан.

[372] *Мөслими Габделхәмит.* Тәдрис вә тәрбия мәсьәләсе // Шура. 1915. №20. Б.635–636.

[373] Касыйр – җитәрлек булмаган, кыска.

[374] Дәм – сулыш.

[375] Ибтидаи – башлангыч.

[376] Карья – авыл.

[377] Галәлхосус – бигрәк тә, аеруча.

[378] Әтраф – тараф.

[379] Кыйсем – өлеш.

[380] Мадамә – һәрвакыт булганча.

[381] Икамәт итү – яшәү, тору.

[382] Мәслихәт – киңәш.

[383] Сәрмая – капитал, акча.

[384] Һәнүз – һаман да, әле дә.

Укыганнары исә, һәнүз шул «Бәдәвам»[385], «Кисекбаш»[386], «Йосыф»[387] вә «Бакырган»[388] китаплары. Бонлар һәм тиз бетмәсләр. Хосусан язып маташучыларымыз шундый гимназияләрдән дәм өреп, бу тарафларны хәтерләреннән чыгарсалар.

Әлхасыйль[389], әүвәл безгә ибтидаи мәктәпләрне күбәйтергә, булганнарыны тәртипкә куярга вә булмаган урыннарга булдырырга иҗтиһад кылырга[390] кирәк. Мадамәгә бездә ибтидаи мәктәпләр йирендә булмаса, халкымызда ибтидаи тәгълим тиешенчә тәгъмим ителмәсә[391], безнең милләт тәрәккый[392] тапмас. Тәкрар итәмен[393], безләр әүвәл ир вә кыз балаларымызны ибтидаи мәктәпләрдә тәртип илә күңелләренә кече яшьтән үк милли рух сеңдереп тәрбия кылырга кирәк. Аннан соң рөшди[394] вә игъдади[395] мәктәпләр үзүзеннән акрынлап булса да вөҗүдкә чыгар[396]. Бер фарыз, мөселман әфәнде әйткәнчә, милли кызлар гимназиясе ачтык. Моның башка тарафыннан күз йомып, бу гимназиягә рус дарелфөнүннәреннән[397] чыккан студентлар тәгаен кылдык. Бу әфәнделәр һәрбер фәнне русча вә рус програмы вә кавагыйде[398] илә укыганнар, бонлар ничек итеп татар кызларына татарча дәрес бирсеннәр? Тәкрар булса да, дәхый[399] әйтәмен, ир вә кыз балалар өчен тиешенчә ибтидаи мәктәпләре булмаган без татар милләтенә, түгел милли кызлар гимназиясеннән хаҗәт, хәтта милли ирләр гимназиясеннән хаҗәт кылу да иртәдер.

Казан әтрафындагы ир балалар мәктәбенең (кыз балалар мәктәбе тарафта торсын) ни дәрәҗәдә идекен беләсе килгән кешегә «Йолдыз»ның соңгы

[385] «Бәдәвам» китабы – татар дини-дидактик әдәбият үрнәге; мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланылган.

[386] «Кисекбаш» – «Кисекбаш китабы», XIV–XV йөзләрдә язылган татар әдәбияты үрнәге, кульязма һәм китап рәвешендә киң таралып, мәдрәсәләрдә дәреслек итеп кулланылган.

[387] «Йосыф» – «Кыйссаи Йосыф» («Йосыф китабы») – XIIIнче гасырның беренче яртысында шагыйрь Кол Гали тарафыннан иҗат ителгән поэма. Коръәндәге «Йосыф» сурәсенә нигезләнгән. Мәктәп-мәдрәсәләрдә киң кулланылган.

[388] «Бакырган» – Урта Азия суфи шагыйре Сөләйман Бакыргани (1186 елда үлгән) шигыре белән ачылып, аның һәм шул замандагы бүтән шагыйрьләрнең әсәрләреннән төзелгән җыентык. Беренче мәртәбә 1846 елда Казанда басылган.

[389] Әлхасыйль – бер сүз белән әйткәндә, нәтиҗәдә.

[390] Иҗтиһад кылу – тырышу.

[391] Тәгъмим ителү – бөтен җиргә тарату.

[392] Тәрәккый – алга китү.

[393] Тәкрар – кабатлау.

[394] Рөшди – урта.

[395] Игъдади – хәзерләү.

[396] Вөҗүдкә чыгу – бар булу, тормышка ашу.

[397] Дарелфөнүн – югары уку йорты, университет.

[398] Кавагыйд – кагыйдә.

[399] Дәхый – тагын, тагы.

номерларында учитель Ф.Сәйфи әфәнденең мәкаләсене күздән кичерү илә тәүсыя итәмен[400]. Шуннан соң бәлки гимназияләрдән тәүбә итәрсез.

Екатеринбург

*«Шура», 1915, №1, б.25.*

***Газыйм Касыйми***[401]

## Мөгаллимәләр курсы хакында

Бәләбәйдән

Үткән ел җәй фасылында «Мөгаллимәләр өчен (итлак җаиз булса)[402] курс» ачмыш һәм курсыбызда 50–60 кадәрле ханым вә туташлар укып, канәгать хасыйл итмешләр[403] иде. Шул мөнәсәбәт белән «Бу ел да курс ачмыйсызмы?» дип, һәр тарафтан хатлар килә. Бу хатларның һәркаюсына аерым-аерым җавап язу мөмкин булмадыгыннан, барына бердәм гәзитә аркылы җавап язуны мәгъкуль[404] күрдек. Шулай илә ки, үткән елда да рөхсәт алу, укыту өчен бина табу хосусларында әллә никадәр читенлекләргә очрарга тугры килгән иде. Бу елның фәүкылгадә[405] бер ел икәнен игътибарга алганда, ул авырлыкларның тагы артыграк булачагы билгеле. Чөнки мәктәп һәм мәдрәсә биналарын хәзердән гаскәр өчен әшгал итәргә[406] торалар. Дәхый бу көннән игътибарән һәр йирдә укуларны туктатып торганда (губернатордан махсус телеграм илә Бәләбәйнең һәммә урта мәктәпләрендә укулар туктатылды; түбәннәрендә озакламый туктатылачак, диләр. Мәктәп-мәдрәсәләрдә дә тиздән тукталуы ихтимал), өр-яңадан башлап укытырга рөхсәт алу, ихтимал, мөмкин дә булмас. Боларның барысыннан катгый назар[407], үткән елгы курсыбызның мөдәррисәсе Әсма ханым, укыта башлаган көненнән игътибарән җәен вә кышын туктамый укытып, байтак кына сәламәтлеге белән видагълашырга[408] туры килдегеннән, докторларның кушуы буенча бу ел җәй укытмаска, бәлки ял итәр өчен берәр авылга барырга ният итеп тора.

Менә шушы югарыдагы сәбәпләргә мөнби[409], без бу ел курслар ачмаска карар бирдек.

Мөгаллим Газыйм Касыйми.

*«Тормыш», 1915, 1 апрель.*

---

[400] Тәүсыя итү – киңәш бирү.

[401] Газыйм Касыйм улы Касыймов (1891–1937) – педагог, дәүләт эшлеклесе, «Ярлылар тавышы» газетасы мөхәррире, БАССР мәгариф комиссары (1924–1926), Казан педагогия институты ректоры (1931–1937).

[402] Итлак җаиз булса – исем бирү дөрес булса.

[403] Хасыйл итү – нәтиҗә ясау.

[404] Мәгъкуль – урынлы.

[405] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

[406] Әшгал итү – шөгыльләнү, куллануга алу.

[407] Катгый назар – -га карамастан.

[408] Видаг – озату, сабуллашу.

[409] Мөнби – дөреслеккә куеп.

### Казанда мөгаллимәләр өчен җәйге курслар

Быел җәй Казанда мөгаллимәләр өчен тәгълим вә тәрбия курслары ачылырга уйлана. Курслар өчен Аитова ханым мәктәбенең бинасы алыначак. Курслар Фәхрелбәнат ханым Сөләймания тәхет идарәсендә[410] берничә мөгаллимнең иштирагы[411] белән ачылып, май башыннан август башына кадәр (3 ай) дәвам итәчәк. Ике сыйныфтан гыйбарәт булачак. Програмы шактый киң булачак. Рөхсәт сорап гариза бирелгән.

*«Вакыт», 1915, 7 апрель.*

### Мөгаллимәләр дикъкатенә

Беренче майдан башлап Зыя хәзрәт[412] вә иптәшләре тарафыннан укытылачак мөгаллимәләр дәресене дәвам итәргә туташ вә ханымнар Никольский урамында 83нче номерлы йортка Зыя хәзрәтнең әһлиясе[413] Гайшә ханым Камалетдиновага мөрәҗәгать итсеннәр.

*«Тормыш», 1915, 19 апрель.*

### [17нче майда...]

17нче майда Уфада рәсми сурәттә мөгаллимәләр курсы ачылды. Курслар Шәйхулла әфәнде Кинзикиев[414] идарәсендәге школада дәвам итәчәкләр. Хәзер курста 80 кадәр укучы бар. Курс янындагы пансионга 20 ләп туташ кергән. Курсны Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт идарә итә.

Дәресләрне «Мәдрәсәи Галия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре укыталар.

Киләсе номерда програмнары хакында мәгълүмат бирермез.

*«Тормыш», 1915, 19 май.*

### Мөгаллимәләр курсы

Курс ике сыйныфка бүленеп, сиксәннән артык ханым вә туташларга дәрес укыйлар. Курска Уфа вә башка вилаятләрдән дә килгәннәр. Курс Уфимский урамда Кинҗәкәевнең 37нче номерлы йортында булып, читтән килүчеләр шул ук йорттагы пансионда торалар. Мөгаллимә Фатыйма Әхтәмия мөбассыйрәлек[415], Миңлеҗамал ханым Мәҗидия сыйныф ханымлыгы вазыйфасын үтиләр. Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт мөдирлек итә. Дәресләр иртәнге сәгать сигездән башлап, сәгать 2гә кадәр укыйлар. Курста тәфсир[416], әхлак, исламияттә хатын-кыз хокукы, хәдис, дин, ислам тарихы,

---

[410] Тәхет идарәсендә – идарәсе астында.

[411] Иштиракъ – катнашу.

[412] Зыя Камали.

[413] Әһлия – тормыш иптәше, хатыны.

[414] Шәйхулла Кинҗәкәев (Кинзикиев) – Уфа сәүдәгәре, Бөтенрусия мөселманнарының икенче корылтае (1917) делегаты.

[415] Мөбассыйр – күзәтүче, мәктәпләрдә укучыларның өстеннән күзәтүче.

[416] Тәфсир – Коръәнгә аңлатма, комментарий.

гыйлем рух, милли тел, гарәп вә рус телләре, җәгърафия, рәсем, хисап, голүм табигыя[417] дәресләре укытылып, атнага утыздан артыграк дәрес төшә. Тәфсир, әхлак, гакыйдә[418], хокук нәсаи[419], дин, ислам тарихы дәресләрен Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт, хисап, рәсем, табигыять, гыйлем рух һәм русчаны Саттаров әфәнде, җәгърафия, милли тел дәресләрен Мәхмүд әфәнде, гарәбият, хәдис вә ысул хәдисне Тәкый әфәнде Бәдигый укытадыр. Дәресләрнең күбесе лекция рәвешендә дәвам иттерелә.

Курста фәкыйрьләр мәҗанән[420] укытылып, уртача хәллеләрдән аена 3әр, баераклардан 5әр сум алына. Курсның калган мәсарифе[421] гәзитәбезнең нашире Гыйбадулла әфәнде Госманов тарафыннан тотылачак.

*«Тормыш», 1915, 20 май.*

## Укучы туташлар дикъкатенә

Дүртөйледә мөгаллимә Нәйрә ханым Шәмсетдинова тарафыннан 15нче майдан башлап мөгаллимәләр өчен курслар ачылган иде. Курсларга кабул итү башта 15нче майга кадәр генә дип игълан ителгән булса да, тагын бик күп туташларның үтенүе буенча кабул итү вакытының 1нче июньгә кадәр кичектерелгәнен Нәйрә ханым игълан итте.

Бөтен расход айга 11 сумнан артык чыкмый, ди.

*«Тормыш», 1915, 27 май.*

## Курслар

Соңгы елларда безнең Русия мөселманнары арасында да еш-еш кына «курслар» сүзе ишетелә башлады. Мөгаллимәләр курсы хәтта бик күбәеп тә китте. Бозаяз[422] авылыннан бер ханым бик киң програм белән курслар ачачагын игълан итте. Дүртөйледә дәхый бер ханым курслар ачты. Бу ел мөгаллимә ханым арыганлык сәбәпле, Бәләбәйдә берничә ел дәвам итеп килгән мөгаллимәләр курсы ачылмады. Уфада ике йирдә мөгаллимәләр курсы дәвам итә. Шуның Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт идарәсендәгесе дәхый ике айдан артык дәвам итәчәк. Икенчесе дә шул кадәрле үк дәвам итсә кирәк. Имамнар өчен тәҗрибә курслары исә бүген ябылачак.

Менә бу курсларның барысының да Уфа вилаятендә булуы Уфа вилаятендә яшәүче халык өчен бер шәрәфтер[423]. Уфа вилаятенә караган халыкның миллион ярым җаннан артыгы мөселман идеге хәтергә алынганда, бу курсларның Уфа вә аның әтрафында[424] булуы табигый бер эштер.

[417] Голүм табигыя – табигать фәннәре.
[418] Гакыйдә – ислам гыйлеменең бер өлеше, «иман символы».
[419] Хокук нәсаи – хатын-кыз хокукы.
[420] Мәҗанән – түләүсез, буш.
[421] Мәсариф – тотылган акчалар, чыгымнар.
[422] Бозаяз – Башкортстанның Кырмыскалы районындагы авыл.
[423] Шәрәф – бәхет.
[424] Әтраф – тирә-юнь.

Курсларга булган ихтыяҗымыз вә аларның кирәклеге хакында сүз сөйләргә урын да юк. Чөнки төрле курсларның кирәклеген берничә кара көчләр истисна ителгәндә[425], һәркем аңлады. Фәкать яңа гына башланган эш булу мөнәсәбәте илә курслардан максат вә аларда укыту рәвешләрен аңлаучыларымыз бик күп булмаса кирәк.

Мәдәният галәмендә курслар икегә бүленеп, һәр икесендә аз вакыт эчендә билгеле вә махсус фәннәр хакында мәгълүмат бирү күздә тотыла. Бер төрле курслар фәннәрнең үзен укыту максуды илә ачылмыйча, фәннәрне укыту рәвешләрен – ысул-тәгълимнәрен вә тәрбия фәненең үзен белдерү өчен ачылалар. Мондый курслар күбрәк вакыт җәй көннәрендә аз мөддәт[426] белән ачылып, аларга тәрбия вә педагогия гыйлемендә мәгълүматлы затлар чакырыла вә һәр фәннең ысул тәгълиме әһел[427] тарафыннан күрсәтелә. Мондый курсларда укучылар да ысул фәненнән мәгълүматлы булалар. Махсус фәннәрне белдерү максуды белән ачылганнарында уку мөддәтләре уку елларына бүленеп, гадәттә кыш фасылларында дәвам итәләр. Җәйге курсларда төрле телләр вә фәннәрнең әлифбалары укытылмый. Бәлки мөгаллимә вә мөгаллимнәрнең фәнни мәгълүматларын киңәйтү, махсус бер телнең әдәбияты тугрысында җитди сурәттә мәгълүмат бирү максуды була.

Безгә дә курсларыбызны менә шушы әсаска[428] салырга вакыт булып килә. Хәзергә кадәрле без бер-ике ай дәвам итәчәк курс програмнарына төрле телләр вә төрле фәннәр кертәмез. Моның өстенә, укучылары да монда укылачак фәннәрне аңларлык дәрәҗәдә мәгълүматлы булмыйлар. Ибтидаи[429] мәктәп яки тәртипсез рөшдиләрдә[430] укыган ханым вә туташларны туплап, һәр фәннең әлифбасыннан яки уртасыннанрак башлап, аларның башлары сыйдыра алмаслык дәрәҗәдә мәгълүмат бирә башлыймыз. Безгә, исемнән артык эшкә, күренештән артык гамәл белән күрсәтүгә әһәмият бирергә тиешле иде. Курсларда укылачак фәннәрнең әлифбаларын үзләре укырга мохтаҗ булганнар кәгазь өстендә, матбугат сәхифәләрендә ялтыратып, милләтнең күзен буямасыннар иде. Курс кебек мөкаддәс исемнәрнең сүэ[431] гамәлгә очраулары мәдәниятебезнең табигый агымнарына каршы гакес[432] тәэсир итәргә дә мөмкин. Дөрес, башкалар кебек без дә яңа гына ачыла башлаган курсларымызның тәнкыйтьне күтәрерлек бер хәлдә булмауларын, «кәрван сәфәр хәлендә төзелә», дигән кебек сүзләрнең мәгънәләрен аңлыймыз. Ләкин 20нче гасырда мәдәниятле милләтләр эчендә яшәгән Русия мөселманнарына гыйльми вә иҗтимагый хасталыкларын төшенеп, әкренләп болардан арына башларга да вакыттыр инде. Һәр эшемез коры ялтыравыклардан, матбугат сәхифәләрендә шалтыраулардан гыйбарәт булып,

[425] Истисна итү – аерып алу.
[426] Мөддәт – ара, вакыт.
[427] Әһел – белгеч.
[428] Әсас – нигез, база.
[429] Ибтидаи – башлангыч.
[430] Рөшди – урта мәктәп.
[431] Сүэ – бәхетсезлек.
[432] Гакес – капма-каршылык.

һәр косур[433] вә гаепләремездән күзебезне йома башласак, нәтиҗә шул нисбәттә файдасыз булачак. Шуның өчен, курс ачканда мәдәниятле милләтләр тарафыннан күзәтелгән шартларның хәтеремездән чыкмавы милләт вә мәдәният наменә[434] арзу[435] һәм таләп ителәчәк эштер. Җәйге курслар мәгълүм фәннәрне яки шуларның ысул тәгълимен үгрәтү өчен ачылып, арабызда шул фәннең мөтәхассыйсраклары[436] саналганнары дәрес бирер өчен чакырылсыннар иде. Хәзерге кебек програмнарына шәкертләрнең икътидарлары йитмәслек бик күп фәннәр вә төрле телләр кертеп, андагы фәннәрне кем җитте шул укытмасын иде.

Курслар өчен дә програмы үз максатына муафыйграк[437] булганы, бер дә шөбһәсез, имамнар өчен тәҗрибә курслары булды. Програм белән генә эш бетмәгәнлектән, програмына карап кына бу курслар муаффәкыятьле[438] сурәттә дәвам иткәндер дип әйтү мөмкин түгел. Бу курсны тәнкыйтъ итүне киләчәккә калдырып, хәзергә шуны гына әйтеп үтүне тиешле күрәмез ки, киләчәк елларда да әһелләре тарафыннан бу курс дәвам иттерелсен, тәҗрибә күрсәткән косурларын киләсе елны бетерергә иҗтиһад ителсен[439] иде.

*«Тормыш», 1915, 31 май.*

***Мохбир***

**Троицкида рәсми рөхсәтле яңа мөселман мәктәпләре**

[...]

II

Шул ук хосусый мәктәпләр низамнамәсенә тәүфикан[440] Гайния ханым Яушевага да биш сыйныфлы кызлар мәктәбе ачарга Оренбург попечитель округы тарафыннан рөхсәт ителмештер. Бу мәктәптә бер тахсыйри[441] сыйныфы да булачак. Бу мәктәптә дә рус теле, рус тарихы вә җәгърафиясеннән башка фәннәр ана телендә укылачак.

Бу мәктәптә укылачак фәннәр.

Дин дәресе, татар теле, рус теле, гарәп теле, хисап вә һәндәсә[442], җәбер[443], җәгърафия, гыйльме әшъя[444], гыйлем тәшрих[445], хифзыссыйхәт[446], хикмәт вә

---

[433] Косур – җитешсезлек, кимчелек.
[434] Нам – исем.
[435] Арзу – теләк, омтылыш.
[436] Мөтәхассыйс – белгеч, специалист.
[437] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[438] Муаффәкыять – уңыш.
[439] Иҗтиһад итү – тырышу.
[440] Тәүфикан – туры китереп.
[441] Тахсыйри – хәзерлек.
[442] Һәндәсә – геометрия.
[443] Җәбер – алгебра.
[444] Гыйльме әшъя – физика.
[445] Гыйльме тәшрих – анатомия.
[446] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау турындагы фән.

кимиядән[447] кыска гына мәгълүмат, тарих (татар, рус, гомуми), ысул тәгълим, кул һөнәрләре, рәсем, хөсне хат[448], өй эшләре хакында мәгълүмат, көй илә шигырь, мусыйкы[449] (ихтыяри).

Монда ибтидаи кызлар мәктәбенә мөгаллимәләр хәзерләнәчәк.

Бу ике мәктәпнең[450] һәр икесенә мөдир вә мөдирәләр, мөгаллим вә мөгаллимәләр тәгаен итү хосусый мәктәпләр канунында күрсәтелгән тарикъ[451] иләдер. Бу мәктәп тә бу сәнә ачыладыр.

Канунда күрсәтелгән хокукны хаиз[452] мөгаллим вә мөгаллимәләрне табып, ошбу мәктәпләрне идарә итсәләр, милләтемезнең күптән дүрт күз илә көткән мөгаллим вә мөгаллимәләр чишмәсе мәйданга чыккан булачактыр. Җәнаб Хактан муаффәкыять[453] телибез.

*«Тормыш», 1915, 31 май.*

### [Гәзитә вә журналларымызда...]

Гәзитә вә журналларымызда үзенең мәкаләләр язуы белән танылган вә Казанның зур мөгаллимәләреннән булган Маһруй Мозаффария ханым Уфага килеп, Сибирский Подворьега (номер 27) төште.

Маһруй ханым Уфадагы җәмәгать эшләре белән мәшгуль булган ханымнар, андагы курслар вә гомум Уфадагы укыту эшләре белән танышыр өчен килгәнен сөйли.

Аның сүзенә күрә, Казан ханымнары арасында берничә генә ханым иҗтимагый эшләргә әһәмият бирсә дә, калганнары гомуми эшләргә бик салкын карыйлар, бер эш хосусында да бергә җыелып рәтле фикер алыша алмыйлар, хәтта аңлашырга теләүче дә юк хөкемендә икән. Безнең Уфадагы курслар юк вакытында да, мәктәп тәмам иткән туташлар яхшы мөгаллимәләрдән укып, мәгълүматларын арттыралар, кыш вакытларында да бездә шул рәвештә төрле мөгаллимнәрдән укып ятучы туташларның саны 20–30дан кимеми. «Сездә дә бу гадәт бармы?» – дип сорагач: «Бездә андый эш булганы юк, булырга охшамый да, ул рәвештә укырга рөхсәт тә итмиләр», – диде.

*«Тормыш», 1915, 7 июль.*

### Мөгаллимәләр имтиханы

Уфада Назыйровлар мәдрәсәсендә мөгаллимә Газыймә ханым Тәкаева идарәсендә мәүкыйт[454] җәйлек курслар ачылган иде. 16нчы июльдә шул

---

[447] Кимия – химия.
[448] Хөсне хат – матур язу.
[449] Мусыйкы – музыка.
[450] Мәкаләнең беренче өлешендә Троицкидагы «Вазыйфа» ирләр мәктәбе турында сүз алып барыла.
[451] Тарикъ – юл, метод, алым, ысул.
[452] Хаиз – җыйган, эченә алган.
[453] Муаффәкыять – уңыш.
[454] Мәүкыйт – бирелгән вакыт, срок.

курста укыган мөгаллимәләрнең имтиханы булачак. Курсларның мөдирәсе Газыймә ханым Тәкаева «Тормыш» гәзитәсендә ачык мәктүб[455] язып, имтиханга бөтен Уфа имамнары илә Уфа мөдәррисләрен вә берничә җәмәгать хадимнәрен[456] атап чакыра. Тәнзилә[457] тәшриф[458] бирсәләр, казый хәзрәтләре дә рәхим итсеннәр, ди.

*«Вакыт», 1915, 12 июль.*

**Газыймә ханым Тәкаева курсында имтихан**

Газыймә ханымның мөгаллимәләр өчен җәйге курслар ача башлавына бу ел 6нчы ел икән. Аның җәйге курсларында һәр елны берничәшәр дистә туташ дәрес укый килгәннәр. Үткән ел бу курста 54 кыз укыган. Бу ел исә курслар ачылган вакытта 102 туташ булган. Ураза керә башлагач, боларның бер кыйсеме[459] авылларына киткән булсалар да, 60тан артыгы имтиханга кадәр дәресләрендә дәвам иткәннәр. Курсларда укытучылар Фәтхелислам әфәнде Тәкаев, Зиннәтулла әфәнде Хөснетдинов, Гофранулла әфәнде Тәкаев, Газыймә ханым Тәкаева, Тәгъзимә туташ Сафуанова.

12нче июль якшәмбе көн шул курсларда имтихан булды. Курс идарәсенең чакыруы белән казый Салихҗан хәзрәт, Уфаның бәгъзе имамнары, Казаннан килгән Маһруй ханым Мозаффария, берничә читтән килгән ханымнар һәм шәһәр халкыннан берничә кеше хазир булдылар[460].

Имтиханга 14 кыз кергән иде. Башта тәфсир[461] вә нәхүдән[462] имтихан кылдылар. Рәттән утырган туташлар рәттән берәр аять укып, шуның мәгънәсен сөйләделәр һәм шул аятьнең тәркибен[463] тикшерделәр. Җаваплар матур күренә.

Тарих гаять начар укылган. Рәтләп җавап бирә алганы булмады дисәк, хата булмас. Кәсергә[464] йиткәнче, хисапны яхшы укыганнар. Җәгърафияләре мактарлык булмаса да, ярыйсы гына.

Инша да өйрәткәннәр. Фәкать инша язышлары канәгатьләндерерлек түгел. Әүвәл язарга биргән мәүзугълары[465] гаять авыр. «Тарих вә аның файдасы» хакында язарга кушылды. Бәгъзе кешеләр бу мәүзугъның мәсахә[466] булмаганын сөйләп карасалар да, имтихан итүче курс мөгаллиме шуны яздырырга тырышты. Туташлар бу мәүзугъка элек тә язып күргәннәр булырга

---

[455] Мәктүб – хат.
[456] Хадим – хезмәткәр.
[457] Тәнзилә – ташлама.
[458] Тәшриф – олылау, хөрмәтләрү; бару, килү.
[459] Кыйсем – өлеш.
[460] Хазир булу – катнашу.
[461] Тәфсир – Коръән сүзләренә аңлатма.
[462] Нәхү – синтаксис.
[463] Тәркиб – состав.
[464] Кәсер – вакланма.
[465] Мәүзугъ – тема.
[466] Мәсахә – киң.

кирәк ки, барысының язганы бер төсле диярлек чыккан. Аның өстенә, бик күп микъдарда гарәпчә сүзләр кыстырганнар.

Имтиханга килгән аңлырак кешеләр мөгаллимнәр курсында ысул тәрбия вә ысуле тәгълимнән дә имтихан булыр дип көтсәләр дә, бу көтүләре бушка чыкты. Курста бу фәннәр укытылмаган икән. Бу хәлне күргәч, мөгаллимәләр өчен һәммә нәрсәдән артык кирәк булган бер фәнне укытмауларына тәәссеф итәргә[467] тугры килде.

«Мөгаллимә» дигән сүзнең фәнни мәгънәсен белмәгән вә мөгаллимә өстенә ниләр йөкләнгәннән хәбәре булмаган бик күп туташларымыз мөгаллимә булып бичара балаларымызның миләрен черетүдә дәвам итәләр. Мөгаллимәләр өчен махсус курслар ачып та, шул хәлне игътибарга алмау, 6 ел буена тәҗрибә күреп тә, иң мөһим маддәне програмга кертмичә, мөгаллимәләр курсы ачу кадәр дә зур кыюлык булырмы? Башка дәресләр, вакыт азлык сәбәпле, ашыгычлык белән үткәрелсәләр дә, мөгаллимәләргә тәхсыйс кылынып[468] ачылган курсларда ысул тәрбия вә ысул тәгълим дәресләрен гаять нечкәләп укыту кирәк иде. Хәл белән хисаплашабыз, укырга теләгән кешеләрнең теләкләрен игътибарга алабыз дип, вә тәртип белмәгән мөгаллимәләр таратып, әлегә чаклы дәвам иткән тәртипсезлекнең торган саен көчәя баруына хезмәт итүгә милләт тарафыннан нинди бәһа куелачагын аңларга вакыт җиткән булса кирәк. Шуның өчен эшнең җаен алган кешеләргә эшләрендә дәвам итүне тәүсыя итү[469] вә муаффәкыять[470] теләү белән бәрабәр, мондый мөһим курсларны киләчәктә тотарга тырышуларны да тәүсыя итмичә үтеп булмый. Моннан соң укытучылары эчендә дә Зиннәтулла әфәнде кебек төпле мәгълүмат иясе булган затларны күбрәк күрсәк иде.

*«Тормыш», 1915, 14 июль.*

### Мөгаллимәләр курсында имтихан

Рәсми рөхсәт белән ачылып, Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт идарәсендә ике айдан бирле дәвам иткән мөгаллимәләр курсында 16нчы июльдә имтихан мәҗлесе булды.

Башлап Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт кыска гына бер нотык белән имтихан мәҗлесен ачты вә «Хәдис шәриф» дәресеннән имтихан итә башлый. Соралган сөальләргә шәкертләр, берничәсен чыгарып алганда, гомумән йомшак җавап бирделәр. Уку-укыту бик кыска булуы өстенә, шәкертләргә дәрес тәкърар итәр[471] өчен бер дә вакыт бирелмәү, шаять бер кимчелекнең зур сәбәбедер. Моннан соң әхлак дәресләреннән имтихан башланды. Бу дәрестә дә тулы җавап биргән шәкертләр сирәк очралды. Хәзерләнмәгәнлек монда да күренеп торды. Имтихан итүченең сөальне биреп, аз гына көткәч тә үзенең сөйләп

[467] Тәәссеф итү – үкенү, кайгыру.
[468] Тәхсыйс кылыну – билгеләнү.
[469] Тәүсыя итү – киңәш бирү, васыять итү.
[470] Муаффәкыять – уңыш.
[471] Тәкрар итү – кабатлау.

алып китүе мәҗлесне, имтиханнан бигрәк, җыелган халыкка дәрес әйтү рәвешенә кертте. Имтихан мәҗлесенә хазир булган [472] Нурмөхәммәт вә Салихҗан казыйлар китәчәк булып, мөсагадә эстәделәр[473]. Зыяэтдин хәзрәт казый хәзрәтләргә тәшәккер иткәннән[474] соң, Салихҗан хәзрәт кыскача гына бер нотык сөйләп, хатын-кызларымызның бу рәвештә укырга тырышуларына милләтемезнең бер адым алга атлавы дип караганлыгын сөйләде. Мөгаллимәләрдән берсе торып, бөтен курс исеменнән хәзрәтләргә рәхмәт укыды. Мәҗлестә булган кавказлы мөгаллим Касыймбәк әфәнде сүз алып, мөслимәләрнең бу хәлләренә шатланганлыгын вә шулай ханымнарымыз тәрбия ителгәндә генә милләтемезнең яшәячәген бәян итте. Аңа туташлардан берсе тәшәккер итеп, берничә сүз сөйләде. Бераз тәнәфестән соң ысулы тәгълим вә тәрбия, гыйльме әхваль, рух вә гыйльме вазаифеләгъза[475] фәннәреннән шәкертләрне имтихан итә башладылар. Шәкертләргә гомуми рәвештә бер сөаль биргәннән соң, имтихан кылучы мөгаллим туташлардан берсен торгызып, сөальгә җавап бирергә куша, ул җавап бирә алса, җавабын әйтә, булмаса, икенчесеннән сорала, яхуд әл-әгъли әт-тәгаен [476] укучыларыннан берсе тиешле тапкан җавапны, күбрәк урынында утырган хәлдә бирә иде. Җавапларның күбрәге канәгатьләнерлек дәрәҗәдә булмый, бәгъзе вакыт җавап сөальгә башка да булгалады. Бу хәл бәлки сөальне тәмам аңламаганнан я шәкертнең артык дәрәҗәдә каушаганлыгыннан килгәндер.

Гомумән караганда, имтихан урта дәрәҗәдәрәк булып чыкты. Бу хәлләргә курстагы ханымнарның кувәи гыйльмияләренең [477] төрле булулары, дәресләрнең лекция ысулы белән укытылуы, вакытның бик кыска булуы, куелган фәннәр бик күп булып, аз вакытта бер нәрсә алып калуның кыенлыгы кеби сәбәпләрнең тәэсире дә булгандыр. Имтиханда шәкертләргә бирелгән сөальләрнең бик җитди һәм авыр мәсьәләләр хакында булуы да уңайсызлагандыр. [...]

*«Тормыш», 1915, 19 июль.*

## Уфада Газыймә ханым Тәкаева курслары

Уфада алты елдан бирле Газыймә ханым Тәкаева тарафыннан һәр ел мөгаллимәләр өчен җәйге курслар ясалып килә вә һәр ел 30–40 мөгаллимә укып чыгалар. Үткән ел бу курсларда укучыларның саны 54кә җиткән иде. «Тормыш»та язылдыгына күрә, бу ел курслар ачылган вакытта укырга теләүчеләрнең саны 102гә барган. Фәкать руза керә башлагач, бәгъзеләре авылларына кайтып киткәннәр. 60 кадәресе имтихан вакытына кадәр укуларын дәвам иткәннәр. Шуннан 14 кыз имтиханга кергәннәр. Курс идарәсенең дәгъвәте буенча, имтиханда казыйлардан Салихҗан хәзрәт Урманов, Уфаның

[472] Хазир булу – катнашу.
[473] Мөсагадә эстәү – ярдәм сорау.
[474] Тәшәккер итү – рәхмәт әйтү.
[475] Гыйльме вазаифеләгъза – тән әгъзаларының функцияләре турындагы фән.
[476] Ли әгъли әт-тәгаен – билгеләнгән.
[477] Кувәи гыйльмия – гыйлем дәрәҗәсе.

бәгъзе имамнары, Казан мөгаллимәләреннән Маһруй Мозаффария ханым илә читтән килгән тагын берничә ханым вә шәһәр халкыннан байтак кеше булган. Һәйәт тәгълимия[478] ошбу ханым вә әфәнделәрнән гыйбарәт: Фәтхелислам Тәкаев, Зиннәтулла Хөснетдинов, Гофран Тәкаев, Газыймә Тәкаева, Тәгъзимә Сафуанова.

Бу курслар 6 елдан бирле дәвам итеп килсәләр дә, «Тормыш» мохбире язуына күрә, һәнүз[479] матлуб[480] дәрәҗәгә йитешмәгән. Мәсәлән: иң мөһим дәресләрдән тарих начар укытылган. Җәгърафияләре дә мактарлык түгел, фәннәр ялгыз хисап (кәсергә[481] кадәр) яхшы, иншалары да канәгать кылынырлык түгел, ысуле тәгълим вә тәрбия дәресләре бөтенләй укытылмаган. Дәресләр арасында иң дикъкать ителгәне – гарәпчә нәхү[482] белән тәфсир[483] дәресләре булганлыгы күренәдер.

Җәйлек курсларда вакыт аз. Шунлыктан монда укучыларның һәр фәндә бертигез яхшы булуларын таләп кылу бик үк урынлы да түгел. Шулай да курсларны идарә итүчеләр матбугат тарафыннан күрсәтелгән нокталарга дикъкать итеп, авыл мөгаллимәләренә гарәпчә вә тәфсир белән баш ваттыру урынына, аннан мөһимрәк вә зарурраk булган ана теле дәресләре илә тәгълим вә тәрбия ысулларына дикъкать итсәләр, яхшы булыр иде.

*«Вакыт», 1915, 19 июль.*

**Мөгаллимә Газыймә Тәкаева мәктәбе**

Газетабызда мөгаллимә Газыймә Тәкаеваның җәйге курсларындагы имтиханы вә киләчәктә ислах итәрлек өмет илә бик өстән генә курсның җитешмәгән йирләре хакында берничә сүз әйтеп үткән идек. Мәзкүр[484] мөгаллимә ханымның «Вакыт» газетасында үзенең җәйге курсларын яклап язган бер мәктүбе басылып чыкты. Ул үзенең мәктәбендә гарәпчә дәресләр хосусында газетамызда язылган сүзләрне тәкрар иткәннән[485] соң, ысуле тәрбия вә тәгълим хакында әйткән берничә сүзне күтәрә алмыйча, гарыз шәхсиләргә кереп китә. Ханым вә туташлар хәленә һәркемнән артык әһәмият бирмәктә, һәртөрле һөҗүмнәргә карамастан, ханымнарны мөдафәга итмәктә[486] булган газетабызның Газыймә ханым кебек бик зәгыйфә вә яңа гына аң керә башлаган бер ханымда нинди ачуы вә нинди гарызы[487] булырга мөмкин? [...]

[478] Һәйәт тәгълимия – укыту комиссиясе.
[479] Һәнүз – әле дә, һаман.
[480] Матлуб – таләп ителгән.
[481] Кәсер – вакланма.
[482] Нәхү – синтаксис.
[483] Тәфсир – Коръәннең аңлатмасы.
[484] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.
[485] Тәкрар итү – кабатлау.
[486] Мөдафәга итү – яклау.
[487] Гарыз – бер эш яки хәл турында телдән сөйләп яки язып тиешле урынга аңлату, җиткерү.

Берничә елдан бирле безнең арабызда бәгъзе бер житешмәгән ханымнар, шулар җөмләдән Газыймә ханым җәйге курслар ачып азапланалар. Боларга һәрнәрсәдән элек, курсның үзе һәм аның тәртип вә низамнары белән танышасы, аз да булса әһеленнән[488] ысул тәрбия вә тәгълим дәресләрен күреп, һич булмаганда гүзәл генә бер ибтидаи[489] мәктәп тәрбияләрлек дәрәҗәдә мәгълүматларын киңәйтәсе иде [...].

*«Тормыш», 1915, 29 июль.*

***Гөлмөнәүвәр Нугай***

## Татар укытучыларына ярдәм җәмгыяте

Безем татар галәме 1905нче елга кадәр кирәк ирләре, кирәк кыз-хатыннары булсын, тирән йокыдалар иде.

1905нче ел, ничектер татар галәменә бер куркынычлы төш күренеп, ирехатыны тирән йокыларыннан сикереп тордылар да, тирә-якларына карана башладылар, ләкин, һәммә халык укуда, укуда-укытуда. Безем татарларның куркынычлы төшләренең нәтиҗәсе шул булды: «Безгә болай ятырга ярамый икән. Иремез-хатынымыз, һәммәмез мотлакан[490] укырга кирәк», дия, шәһәрләрдән башлап авылларга кадәр, ир вә кыз балалар өчен тәртипле мәктәпләр мәйданга китерә башладылар.

Шул мәктәпләремез азмы-күпме укытучылар да чыгара башлады һәм чыгарды. Ул укытучылар да, илләрен ташлап, иң кара йирләргә китеп үзләренең гыйлемгә сусаган ир вә кыз кардәшләрен гыйлем нуры берлә нурландыра башладылар.

Күп укытучыларымыз шул юлда җаннарыны корбан иттеләр һәм һаман да корбан итмәктәләр.

Гәзитә сәхифәләрендә «фәлән мөгаллим, я мөгаллимә тырышып укыган, укытканда күкрәк хастасы берлә вафат булган», – дигән сүзләрне еш кына очратамыз. Күбесе күкрәк хастасына мөбталя булып[491] та, ничек дәвалану тугрында чаралар таба алмый йөри. Бездә күп йирдә укытучыларга ел әйләнәсендә вазыйфа бирелми, фәкать укыткан айларында вазыйфа ала да, җәй көне истирахәт итәргә[492] яхуд дәваланырга теләсә дә акчасы булмый. Ахыр бичара бу дөньядан аяк селтәргә мәҗбүр була. Безем мөгаллим-мөгаллимәләремездә авырудан башка да уңайсыз хәлләргә төшүләр бар. Мәсәлән: берәү, бер йирдә укыта иде, икенче ел ул урынына алмыйлар яхуд башка бер манигъ[493] чыга да, урынсыз урамда калырга мәҗбүр була. Соң боның өчен ни эшләргә? Үземездә булган «җәмгыять хәйрия»ләргә ярдәм сорап мөрәҗәгать итсәк, берничә кешегә ярдәм итәләр вә вәссәлам. Бондый җәмгыять-

---

[488] Әһел – белгеч.
[489] Ибтидаи – башлангыч.
[490] Мотлакан – ничек кенә булмасын.
[491] Мөбталя булу – дучар булып.
[492] Истирахәт итү – ял итү, эштән бушап тору.
[493] Манигъ – киртә.

ләремезнең саны да мәхдүд[494]. Башкача кемгә вә кая сыенырга? Шул авыруга мөбталя булган, яхуд урынсыз калган укытучыларны бондый бәлаләрдән котылдырыр өчен беренче чара, югарыда әйтдегемчә, «Татар укытучыларына ярдәм җәмгыяте» исеме берлә үземезгә махсус бер «җәмгыять» тәэсис итүдер[495].

Боның өчен без, укытучылар, үземезнең алган айлык вазыйфамыздан ай саен арттыра алган кадәр акчаны бер якка куеп, шул «җәмгыять» кассасына тапшырырга кирәк. Менә шуннан, әлбәттә, башка хәйрат[496] әһелләредә ярдәм итеп, «җәмгыяте»мез азмы-күпме суммага малик булыр[497]. Беркадәр сумма җыелгач, вәридәтен[498] арттыру өчен шул «җәмгыять» исеменнән төрле файдалы эшләр эшләп, җәмгыятьне баетырга мөмкин булыр. Бу сүзләрем шулай итсәк, яхшы булыр иде дә, фәлән, дигән сүзләр түгел. Бәлки, шушы эшне, әлбәттә, эшләргә тиешмез һәм эшлик дия иптәшләрем мөгаллимә һәм мөгаллимнәргә фикеремне тәкъдим итәм. Һәм бу фикерне игътибарсыз калдырмый, бу хакта җитди фикерләр йөртелерен чын күңелемнән үтенәм.

Мәскәү

*«Сөембикә», 1915, №2, б. 39.*

***Наразый***[499]

## Троицк шәһәрендә Гайния ханым Яушева тарафыннан ачылмыш урта дәрәҗәдәге кызлар мәктәбе хакында

Троицк шәһәре йөз еллар буенча мәгариф мәркәзе булып килгән иде. Әле дә шул мәркәзлеген югалтмый. Йөз еллар буенча Троицк хәзрәтләре мәдрәсәләр тәрбияләп килделәр. Троицк мәдрәсәләреннән чыккан голәма[500], мөдәррис, хәлфәләрнең саны юк. Боннан чыккан голәма үзләре шәкерт тәрбияләп, мөдәррисләр йитештерделәр. Шул рәвешчә, Троицк әллә ничә буын муллалар вә мөдәррисләр хәзерләде.

Мәдрәсәләремезне ислах итү фикере мәйдан алгач, Троицк боңа җавап уларак үзенең «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»сен һәм «Мәдрәсәи Рәсүлия»сен бирде.

Соң заманнар – хөкүмәт, безгә дөньяви мәктәп ачу юлын уңайлаштыргач, дөньяви мәктәп кирәк идекен күп шаулаган шәһәрләр тик яткан вакыт, Троицк берсе артыннан берсен ике мәктәп ачты: берсе ир балалар өчен «Вазыйфа» мәктәбе, икенчесе кызлар өчен ошбу 17нче сентябрьдә ачылган

---

[494] Мәхдүд – чикләнгән.

[495] Тәэсис итү – төзелү, оешу.

[496] Хәйрат – сәдака.

[497] Малик булу – ия булу.

[498] Вәридәт – керемнәр.

[499] Хәлим Фәттах улы Искәндәров (1889–1958) – педагог, татар газета-журналлары хәбәрчесе, Мәскәүдә Әсәдуллаев мәктәбе мөдире (1927), Татарстанның Арча педагогия училищесы укытучысы (1941–1948).

[500] Голәма – галимнәр.

мәктәп. Бу эш белән Троицк дөньяви мәктәпләренең дә мәркәзе булып китте. Бу мәктәпләр икесе дә урта дәрәҗәдәге мәктәпләр булып, икесе дә ибтидаи[501] мәктәпләремезгә мөгаллим һәм мөгаллимәләр хәзерли торган мәктәпләрдер.

* * *

Бу кызлар мәктәбен Гайния ханым Яушева ачып, үзе тәрбиялидер. Ибтидаине күргән кызлар бу мәктәпнең хәзерлек сыйныфына имтихан илән кабул ителәләр. Хәзерлек сыйныфыннан тыш мәктәпнең дәвамы биш ел. Шул биш елда хөкүмәтнең высший начальный училище програмы үтеләдер. Дин дәресләре, татар теле һәм әдәбияты, гарәп теле, татар тарихы һәм педагогика белән дидактикага аерым програм китерелә.

Уставы буенча бу мәктәпнең тәҗрибә сыйныфлары да ачарга хакы бар; бу сыйныфлар соңгы сыйныф шәкертләре өчен шиксез кирәк булачак. Тиеш табыла икән, мәктәпнең үз шәкертләре өчен пансион да ачарга хакы бар. Бонысы да кирәк нәрсә: бу безнең беренче дарелмөгаллиматымыз[502], аңа төрле яктан шәкертләр агылачак; аларга чит шәһәрдә мәгыйшәтне[503] йиңеләйтер өчен пансион ачу бик урынлы булачак.

* * *

Мәктәпнең програмына бераз тукталырга тугры килер. Хәзер рус педагоглары ибтидаи мәктәп мөгаллиме һәм мөгаллимәләренә высший начальный училище мәгълүматын гына аз хисаплыйлар. Учительский семинарияләр эшкә ярамый идекен күптән сөйләнеп килә. Хәзер руслар ибтидаи мәктәптә укытучының 7 ел гимназия бетереп, өстәвенә бер ел педагогический курсларны (гимназиянең 8нче сыйныфын) күргән булуын таләп итәләр. Соң вакыт (земстволарның мәгариф хакындагы беренче съезды) боның белән канәгатьләнү дә аз идекен икрар итә[504] башладылар. Шундый бер заман безгә высший начальный училище програмы белән канәгатьләнергә тугры киләдер. Бу мәктәп капылга безгә, әлбәттә, ярап тора; ләкин соңыннан без аның програмын киңәйтергә мәҗбүр булырмыз.

Бу мәктәптә начальный училище програмын үтү читен эш түгел: анда 4 елда үтелә торган нәрсәләрне без шиксез 6 елда үтә алачакмыз; безнең артык ике елымыз татар теле һәм әдәбияты, татар тарихы, гарәп теле һәм педагогикага йитеп, артып та калачак. Кайсыбер фәннәрдән генә бездә сәгать хисабы азрак куелган, ләкин хөкүмәт мәктәбенең програмын үтүгә боның да зур тәэсире булмаса кирәк. Мәсәлән, табигыятькә хөкүмәт мәктәбендә 14 сәгать куелган, Троицк мәктәбендә 12 сәгать; һәндәсәгә[505] хөкүмәт мәктәбендә 9 сәгать, Троицк мәктәбендә 3 кенә сәгать, аның каравы хисап[506] белән

[501] Ибтидаи – башлангыч.
[502] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[503] Мәгыйшәт – тормыш, көнкүреш.
[504] Икрар итү – тану.
[505] Һәндәсә – геометрия.
[506] Хисап – математика.

җәбергә[507] хөкүмәтнең 14 сәгате урынына Троицкида 26 сәгать куелган! Бонысын киметү бик урынлы булачак.

Милли әдәбиятымызга урын бик тар куелган: әдәбият тарихы дәресләренә соңгы ике сыйныф шәкертләре генә тиячәк; бонда исә милли телемезгә бары икешәр сәгать кенә вакыт куелган. Йитмәсә, милли әдәбиятымыз програмына «мөтәрҗим[508] әдәбият» (рус теленнән тәрҗемәләр) та кертелмеш. Димәк, безнең үз әдәбиятымызга дәхый да азрак вакыт калдырганнар. Безнең әдәбиятымыз, бигрәк тә безнең иске әдәбиятымыз бай; әдәбиятымызның тарихына 4 кенә сәгать йитәчәк түгел, шуның өчен аңа тәгаен ителгән вакытны арттырырга кирәк. Икенчедән, русчадан тәрҗемәләрне әдәбиятымыз тарихы сәгатьләреннән чыгарырга һәм гомумән боларны урта мәктәп програмына кертмәскә кирәк. Без боны мәктәп һәйәтенә[509] катгый рәвештә тәкъдим итәмез.

Бу мәктәп шәкертләренең физическое развитиесына һич игътибар итми; гимнастикага бер генә сәгать тә куймаган.

* * *

Бу даремөгаллимат програмының өстә күрсәтелмеш урыннары вакыты белән кирәгенчә хәл кылынырлар. Мәктәп булгач, програмын ислах итү[510] бик үк мәшәкатьле эш түгел. Без бу вакытка кадәр мәктәп юклыгыннан интегә идек. Хәзер милләтемезнең мохитенә йитешергә адымнар ясала башлады. Бу мәктәпләрнең бар булуы – һәркемгә мәгънәви зур көч бирәдер, өмет тудырадыр.

Бондый адымнары өчен мәктәпнең мөәссисенә[511] һәм бу эштә мәгънәви вә матди ярдәм итүчеләрнең барысына да рәхмәтләремезне күндерәмез.

*«Шура», 1915, №21, б.666–667.*

## Эстәрлетамактагы икенче кызлар мәктәбенә вакыф

Гәзитәбезнең нашире Гыйбадулла Госманов күптәннән бирле Эстәрлетамак өязендә берничә авылда һәм Эстәретамак шәһәренең үзендә кызлар мәктәбе тәрбия итеп килмәктәдер. Эстәрленең икенче мәхәлләсенә моннан берничә ел элек ибтидаи[512] вә рөшди[513] сыйныфлар йирләшерлек бер мөкәммәл[514] кызлар мәктәбе бина иткән[515] вә бу көнгә кадәрле шуның мәсарифын[516]

[507] Җәбер – алгебра.
[508] Мөтәрҗим – тәрҗемә.
[509] Һәйәт – комиссия, комитет.
[510] Ислах итү – килештерү, яраштыру; үзгәртү, яхшыландыру; реформа.
[511] Мөәссис – төзүче, коручы, нигез салучы.
[512] Ибтидаи – башлангыч.
[513] Рөшди – урта.
[514] Мөкәммәл – тәмамланган, камилләшкән.
[515] Бина итү – нигез салу.
[516] Мәсариф – чыгым.

үз кесәсеннән тотып килгән. Хәзер шул мәктәпне тәэмин итү максаты илә Эстәрле шәһәренә якын гына, байтак варидәт[517] китерә торган йиреннән 36 дисәтинә йирне һәм 5–6 мең тора торган мәктәп өчен салынган мәзкүр[518] бинаны кызлар мәктәбе итеп алып бару шарты илә икенче мәхәлләгә вакыф иткән. Вакыфын идарә итү өчен Эстәрле могътәбәрләреннән Һади әфәнде Ибраһимов, Гыймадетдин әфәнде Айтуганов вә өченче бер кеше сайланган.

Бу вакыфны рәсмиләштерү хосусында да тәшәббескә керешелеп[519], мәзкүр вакыфны Гыйбадулла әфәндедән кабул итеп алырга Духовный Собраниегә рөхсәт ителгән. Гыйбадулла әфәнде үзе Уфада булмаганлык сәбәпле, кияве һәм вәкил Сәлях әфәнде Хәбиров нотариус хозурында Собрание вәкиленә бу вакыфны тапшырадыр. Собрание үзеннән вәкаләтән вакыфны идарә итәр өчен ахун Сәлях хәзрәткә вәкаләтнамә бирәчәк.

*«Тормыш», 1916, 4 март.*

***Газыймә Тәкаева***

## Курслар

Беренче майдан игътибарән һәр фән өчен икътидар вә тәҗрибәсе камил затларны тәгаен кылып, мөгаллимәләр өчен җәйге курс ачарга булдык. Бу курста һәркемнең дәрәҗәсенә карап, сыйныфка куеп, кувә гыйльмиясен[520] тәүсигъка[521] иҗтиһад кылу[522] белән бәрабәр, ысулы тәгълим гыйльме вә гыйльми сурәттә күргәзеләчәктер.

Төштән соң сәгать 4тән башлап, тегү-кисү, оек һәм шәл бәйләү вә башка төрле кул һөнәрләре өйрәтеләчәктер.

Уку мөддәте[523] әккаль[524] ике ай булып, читтән йөреп укучыга айга 5 рублә, үз фатирымызда ятып укучыга 8, кер юмак расходыннан башкасы бездән булганда 25 рубля алынып, фәкыйрә яисә хәлле белән хисап килешәчәкмез. Киләчәк ханым вә туташларның мөмкин кадәр дәрес башлауга килеп йитешүләре матлубтыр[525].

«Мәдрәсәи Нәзыйрә»дә мөгаллимә Газыймә Тәкаева.

Адресы: г.Уфа, Никольская улица, №47.

*«Тормыш», 1916, 15 апрель.*

---

[517] Вәридәт – керемнәр.
[518] Мәзкүр – югарыда әйтелгән.
[519] Тәшәббескә керешү – бер эшкә тотыну; инициатива күрсәтү.
[520] Кувә гыйльмиясе – белем дәрәҗәсе.
[521] Тәүсигъ – арттыру, киңәйтү.
[522] Иҗтиһад кылу – тырышу.
[523] Мөддәт – срок, ара.
[524] Әккаль – аз дигәндә.
[525] Матлуб – таләп ителгән, соралган.

**Мөгаллимәләр курсы ачылды**

Хатын-кыз галәме, алдына салынган киртәләрне ватып-сындырып, алга баруында дәвам итә. Дөньяның аркылысыннан буена аккан мәдәни вә иҗтимагый агым, табигый хөрриятләре алыгып, тере көенчә дүрт дивар эченә күмелгән, хиҗаб исеме белән чапан вә бөркәнчекләргә уратылып курчакка әйләндерелгән мөселман хатын-кызын да үз агымына кушып ага башлады. Моңар мөселман булуымыз сыйфаты илә никадәр шатлансак, мәдәният даирәсенә керә башлавымыз җәһәтеннән[526] бигрәк тә шатланамыз.

Моннан 18 еллар элек Оренбург Каргалысында качып-посып, курка-курка гына мөгаллимнәр курсы ачкан Русия мөселманнары хәзер бөтен дөнья күзе алдында киң Русиянең һәр тарафыннан җыелган йөзләп хатын-кызны парталарга төзеп мөгаллимәләр курсы ачалар. Бу хәл Русия мөселманнарының бик зур инкыйлаб көннәре кичергәнлекләрен күрсәтү белән бәрабәр, аларның иҗтимагыятьтә яхшы ук алга китүләрен дә белдерәдер.

Чапан бөркәнмичә урамга чыккан хатын-кызны күргәндә ләгънәт укучы вә кәфер мөһерен басучыларның бу көн үз кызларын ачыктан-ачык мөгаллимәләр курсына китерүләрен хәтергә алсак, Русия мөселманнарының берничә ел эчендә хатын-кыз хосусындагы фикерләрендә зур алмашыну күрәмез. Хатын-кыз мәсьәләсе кебек мөһим бер мәсьәлә хосусында халкыбыз эчендә күрелгән бу инкыйлаб безнең иҗтимагый хәятемездәге зур адымнардан саналырга тиештер.

Мөгаллимәләр курслары өйдә генә тәрбияләнгән вә дөнья күрмәгән татар хатын-кызын киң дөньяга чыгарырга вә бер-берсе белән аралаштырып катнаштырырга сәбәпче булу җәһәтеннән дә бик мөһимдер.

Без мөгалиммәләр курсының менә шул ягына һәр җәһәттән артык әһәмият бирәмез.

Гыйльми ягына килгәндә, курсларымызның косур[527] вә кимчелекләре бик зур идекен вә безнең арабызда һәнүз[528] дә җәйге курсларның мәгънәсе аңлашылып бетмәдеген игътираф итәмез[529]. Без үткән елгы курслар ачылу мөнәсәбәте илә «Тормыш»ның 252нче санында «Курслар» сәрләүхәсе[530] белән язган мәкаләмездә[531] гыйлем наменә[532] берничә сүз әйтеп узган идек. Курс мөдир вә мөдирәләре безнең бу сүзләремезне игътибарга алмаган булсалар кирәк. Чөнки газеталарда игълан кылынган програмнарында үткән елгы косурлар артыгы белән тәкрар ителәдер. Мәсәлән: Зыяэтдин әл-Камали әфәнде идарәсендәге ике айлык курста дин дәресе, тарих мөкаддәс, гыйлем рух, табигыять, мөбади һәндәсә[533], җәгърафия, хисап, гарәп, рус вә татар телләре

[526] Җәһәт – як, тараф.
[527] Косур – кимчелек, җитешсезлек.
[528] Һәнүз – әле дә, һаман.
[529] Игътираф итү – үзенең гаебен тану, кимчелеген тану.
[530] Сәрләүхә – исем, мәкалә исеме.
[531] Курслар // Тормыш. 1915. 31 май.
[532] Нам – исем.
[533] Мөбади һәндәсә – башлангыч геометрия.

укытылачак булган. Менә бу курсларның эчләренә кермәстән, күрелгән косурларының иң зурысыдыр.

Мәгълүмдер ки, мәдәният галәмендә курслар икегә бүленәдер. Һәр ике төрлесендә аз вакыт эчендә билгеле вә махсус фәннәр хакында мәгълүмат бирү күздә тотыла. Бертөрле курслар фәннәрне үзләрен укыту максаты белән ачылмыйча, фәннәрне укыту рәвешләрен вә педагогикаларны тәгълим итәр өчен генә ачылалар. Мондый курслар күбрәк вакыт җәй көннәрендә аз мөддәтле[534], мәсәлән, ике айлык булалар. Аларга тәрбия вә педагогика гыйлеменең мөтәхассыйслары[535], мөмкин булмаганда ысул тәрбия вә тәгълимнән хәбәрдар адәмнәр чакырыла вә һәр фөнүннең ысул тәгълиме әһел[536] тарафыннан күрсәтелә.

Менә бусы җәйге курслар.

Махсус фәннәрне укыту максаты белән ачылган курсларда махсус вә билгеле фәннәр укылына булынып, гадәттә кыш фасылларында дәвам итәләр.

Мәдәният галәмендә курслар дигәндә һәркем шуны аңлый вә шул даирәдә эш күрәдер. Гыйлем, мәгариф вә аның ысуллары һәр милләт өчен уртак бер хәзинә булганга, без дә мәдәни милләтләр йөргән юлдан йөрергә вә шулар тарафыннан кабул ителгән ысуллар буенча хәрәкәт итәргә бурычлымыз. Гакес[537] хәлдә без эш вә көчемездән матлуб дәрәҗәдә файда күрә алмамыз, бер көндә атланачак адымнарны йөз көндә атларга мәҗбүр булырмыз. Ике айлык курста өч тел, фөнүннең мөбадисен укытсак, мәдәниятле милләтләр эзеннән йөрмичә, үзебезгә махсус бер юл ихтираг иткән[538] булачакмыз. Тәҗрибә вә гыйльми әсасларга корылмаган яңа ихтирагымыз безгә, әлбәттә, матлуб булган файданы бирә алмас. Шуның өчен без курслар башында торучылардан киләсе елларда мәдәниятле милләтләр тарафыннан кабул кылынган әсасларга игътибар итүләрен гыйлем хөрмәтенә теләп вә үтенеп каламыз.

Кыскасы, мөгаллимәләр өчен булган курсларымыз иҗтимагыятемез һәм фикер ягыннан булган алмашынуымыз җәһәтеннән бик мөһим урын тотса да, гыйльми җәһәттән косурлары бик күптер. Бу косурлар тизлектә тутырылырга тиеше.

*«Тормыш», 1916, 4 май.*

## Мөгаллимәләр курсында

Курска килүче мөгаллимәләр вә туташларның мәгълүмат вә аңнары бик төрле булганга, Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт мәсьүлияте[539] астында дәвам итмәктә булган курс өч сыйныфка бүленгән. Бу ел курска килүчеләрнең саннары бик күп арткан. Хәзер беренче сыйныфта алтмыш, икенчесендә илле,

---

[534] Мөддәт – ара, срок, вакыт.
[535] Мөтәхассыйс – билге.
[536] Әһел – кеше, ия.
[537] Гакес – капма-каршылык.
[538] Ихтираг итү – ачыш ясау,  уйлап чыгару.
[539] Мәсьүлиять – җаваплылык.

өченчесендә 23, мәҗмугысы – 137 хатын-кыз укымактадыр. Шуларның берсе авыру, икенчесе дәресләрне аңларлык икътидарга[540] малик булмаганга[541], курсларга дәвам итә алмаганнар. Бу елгы курслар яхшы ук эзенә салынганга охшыйдыр. Һәр өч сыйныфта татар теле вә аны тәгълим ысулы, хисап, җәгърафия вә боларны уку ысуллары дәресләре уртасында мәркәз урынын алалар икән. Башка фәннәр икенче дәрәҗәдә каралып, аларның кайберләре, мәсәлән, русча, бәгъзе бер сыйныфларда бөтенләй укытылмый.

Дин дәресләренә дә урын аз бирелгән. Зыяэтдин әл-Камали хәзрәтнең курста барлыгы 14 кенә сәгать дәресе бар икән. Мөгаллимәләр курслардан бик мәмнүн булып, дәресләрене дәвам итәләр. Курсны зиярәт итүчеләр[542] дә һәрвакыт булып торадыр.

*«Тормыш», 1916, 13 май.*

## Мөгаллимәләр курсында имтихан

26нчы июнь иртә сәгать 10да мөгаллимәләр курсында имтиханнар башлана. Казый хәзрәтләренең, мәхәллә хәзрәтләренең, мөгаллим вә мөгаллимәләрнең рәхим итүләрен үтенәм.

Адрес. Никольский урамда 47 номерлы йортта. Фәтхелислам Тәкаев.

*«Тормыш», 1916, 24 июнь.*

## [Мөгаллимәләр курсында имтиханнар]

Бүген 26нчы июньдә иртән сәгать 9 да Зыяэтдин әл-Камали хәзрәт идарәсендәге рөхсәтле мөгаллимәләр курсында имтиханнар башлана. Имтихан өч көн дәвам итәчәк. Имтиханга казый хәзрәтләрнең, мәхәллә имамнарының, мөгаллим вә мөхәррирләрнең рәхим итүләре үтенелә.

Курс идарәсе.

*«Тормыш», 1916, 26 июнь.*

## Мөгаллимәләр курсында имтихан

Зыяэтдин әл-Камали идарәсендәге рөхсәтле мөгаллимәләр курсында укулар вә имтиханнар тәмам булды.

Бу ел курска барлыгы 155 туташ вә ханым кайд ителеп[543], 5се төрле сәбәпләр белән курсны тәмам итмичә, кайтып киткәннәр. Калган 150се имтиханга кадәр курска дәвам иткәннәр. Бу ел соңгы курсны тәмам итүчеләрнең саны 20 булды.

---

[540] Икътидар – кулдан килү, көч-куәт.
[541] Малик булу – ия булу.
[542] Зиярәт итү – күрергә, күрешергә бару.
[543] Кайд ителү – теркәлү.

Курслар тыңлаучы туташ вә ханымнарның дәрәҗәләренә карап, тахсыйри[544] сыйныф, беренче вә икенче курс исеме белән өч кисемгә бүленгәннәр. Тахсыйри кыйсемендә киләчәк еллардагы курсларга дәвам итү өчен хәзерлек дәресләре бирелгән. Беренче һәм икенче курсларда тыңлаучыларның дәрәҗәләренә карап, мөгаллимәлек өчен кирәкле мәгълүматлар биргәннәр.

Дәрәҗәләренә карап, дим, чөнки курска килүчеләр арасында аз гына санда үткән ел шушы курсларда булынган, яки башкача бер уңгайлы шарт килеп, яхшы гына мәгълүмат алырга муафыйк булган[545] туташлар булса да, калган кыйсеме баштанаяк диярлек гаять аз хәзерлек белән килгәннәр. Телемезнең сарыф вә нәхүен[546] белүчеләре юк дәрәҗәсендә. Ул фәннәрне укыганнары да кагыйдә бикләүдән узмаган булу сәбәпле, телемезне белми торганнар җөмләсеннән саналырга тиешлеләр. Бик күбесе дәрес яза да белми торган булалар. Хисаптан дүрт гамәлне чын гына белгәне юк. Рәкым[547] яза белмәгәннәре дә шактый күп була. Курсларның вазыйфасы да күпчелекне тәшкил кылган менә шул туташ вә ханымнарга мөгаллимәлек өчен кирәкле мәгълүматны бирүдер. Ике айлык җәйге курсның имтиханнары хакында да менә шул ноктадан карап мөхакәмә йөртергә[548] тугры киләдер.

Бу урында курсның програмы хакында да берничә сүз әйтеп узасы бар.

Курслар ачылган вакытта, без курс идарәсе тарафыннан гәзитәләрдә игълан ителгән програм хакында үз фикеремезне язып үткән идек. Монда аны тәкрарлый тормыймыз. Тик шул тәнбиһемезнең[549] курс идарәсе тарафыннан игътибарга алынганлыгын әйтми уза алмыймыз. Чынында да ике айлык курста үтүе мөмкин булмаган гаять киң вә авыр програмны бу ел курс идарәсе курслар ачылганнан соң бик күп садәләштергән[550]; бәгъзе бер маддәләрне бөтенләй төшереп калдырган; кайбер әһәмияте икенче вә өченче дәрәҗәдә булган нәрсәләрне хәҗемен[551] кечерәйтеп, башка мөһим маддәләр өчен кирәкле вакытны аз да булса киңәйткән: мөгаллимәләр өчен ләбеддә[552] булган милли тел вә милли әдәбиятка байтак күп урын бирелгән. Игълан ителгән програмда мөгаллимәләр өчен һәммә нәрсәдән дә кирәклерәк булган ысул тәгълим маддәсе бөтенләй юк иде. Бу маддә һәм арттырылган. Хисап вә җәгърафиягә дә яхшы гына әһәмият бирелгән. Дин дәресенең хәҗеме гакыйдәи исламиягә[553] калдырылып, 4–5 мәртәбә кечерәйтелгән. Табигыять дәресе дә шул чаклы ук кысылган.

---

[544] Тахсыйри – хәзерлек.
[545] Муафыйк булу – туры килү.
[546] Сарыф вә нәхү – морфология һәм синтаксис.
[547] Рәкым – цифр, саннар.
[548] Мөхакәмә йөртү – хөкем чыгару.
[549] Тәнбиһ – кисәтү, искәртү.
[550] Садәләштерү – гадиләштерү.
[551] Хәҗем – күләм.
[552] Ләбеддә – үтә кирәк, котылгысыз.
[553] Гакыйдәи исламия – иман.

Бу ел курсларда иң мөһим дәресләрне – ана теле һәм ысул тәгълимне Галимҗан әфәнде Ибраһимов укыткан вә шул ике нәрсәгә вакытның сыйдыруы нисбәтендә яхшы гына әһәмият бирдерә алган. Хисап дәресе Җиһанша әфәнде Габдюшевка[554] булган. Ул да бик аз вакыт эчендә байтак нәрсә белдерә алган. Җәгърафияне туташларның үзләреннән укылган йирләрнең хәритәләрен [555] ясатып укытканнар. Калган дәресләр имтихан програмына кертелмәгәннәр. Имтихан програмына кергән кадәресеннән туташлар яхшы гына җавап бирделәр.

*«Тормыш», 1916, 1 июль.*

## Мөгаллимәлеккә шәһадәтнамә[556] бирү

Казанның яшь имам вә мөдәррисләреннән Исмәгыйль әфәнде Габидиның рәфикасы [557] Духовный собраниедән мөгаллимәлек шаһәдәтнамәсе алу касды[558] белән Уфага барып, мөгаллимәлеккә икътидары[559] хакында мөфти Баязитовның имзасы белән мөгаллимәлек шәһадәтнамәсе бирелгән.

Шуның кебек ахунд Мәсгуди хәзрәтләренең кәримәсе[560] Ләбибә ханым да, Духовный собраниегә мөрәҗәгать итеп, имтихан кылырга сораган икән. Мөфти Баязитов имзасы белән аңа да мөгаллимәлеккә икътидарый тәкъдир ителеп, шәһадәтнамә бирелгән.

*«Сөембикә», 1916, №20–21, б.356.*

## Мөгаллимәләр курслары

Үткән җәй Кабан авылында[561] мөгаллимәләр курслары ачкан Багбостан ханымның бу ел һәм җәй көнендә Оренбургтан ерак түгел мөселман авылларыннан бере янында кыска мөддәтле тәгълим вә тәрбия курслары ачарга хәзерләнү хәбәре ишетелде.

*«Вакыт», 1917, 3 гыйнвар.*

---

[554] Җиһанша Яхъя улы Габдюшев – педагог, «Галия» мәдрәсәсендә хисап һәм рус теле дәресләрен алып барган.

[555] Хәритә – географик газета.

[556] Шәһадәтнамә – диплом, аттестат.

[557] Рәфика – тормыш иптәше, хатыны.

[558] Касд – ният, теләк, максат.

[559] Икътидар – булдыра алу, көч җитү.

[560] Кәримә – кызы.

[561] Кабан авылы – хәзер Оренбург өлкәсенең Саракташ районына карый.

# VI БҮЛЕК

# «БАЛА ТӘРБИЯСЕ КЕМ КУЛЫНДА?»

Татар мөгаллимәләре бала тәрбиясе турында

***Фатыйма-Фәридә***

## [Бала тәрбиясе кем кулында?..]

Бала тәрбиясе кем кулында? Ананың балага тәэсире ни кадәр? Хатын-кызны укыту тормышта нинди роль уйныйдыр?

Дөньяда бу кадәр тәрәккыйгә[1] хезмәт иткән кануннардан берсе дә тәҗрибә канунудыр. Тәрәккыйның һәр баскычы тәҗрибә илә менелмештер.

Дөньяда вә ахирәттә бәхетле булу, ирләр илә генә булмаенча, ирләр үзләре дә хатыннардан туып, вә бала да анасының карынында шул анасының каны, сөте илә тәрбияләндеге кеби, дөньяга килгәч тә, баланың җан вә тәненең тәрбиясе анасының кулындадыр.

Бала өчен иң ышанычлы мәктәп – анасының кочагыдыр. Ләкин һәр тәрбиянең нигезе ана кулында кылынганга, камыр кеби һәр якка бөгеләә торган баланы хатын исеме алган һәр ана тәрбия итә алмыйдыр.

Баланың тәрбиясе өчен ананың шул юлда хәзерләнүе тиештер. Юкса сәламәтлекне саклый торган кагыйдәләрдән хәбәре булмаган ана баласыны карынында вакытта ук зарарлардан саклый алмый, баласыны сәламәт тудыра алмыйдыр.

Дөньяга килгәч тә, баланың җаны вә тәненең үсүенә хезмәт итү өчен, ананың күркәм холык илә сыйфатлануы өстенә, төп кагыйдәләреннән дә беренче ярдәм булган нәрсәләрне белүе фарыздыр[2]. Бу нәрсәләрдән хәбәре булмаган ананың кочагы тәрбия учагы, беренче тәрбияне бирә торган мәктәп булмыйдыр. Бәлки гади генә караучы буладыр. Бондай ана илә яллап куйган караучы арасындагы аерма: ананың балага артыграк мәхәббәт итүе, авырса кайгыру гынадыр. Әгәр чынлап уйласак, безнең аналарымызның нинди файда вә нинди зарарлар биргәнене белермез. Яхшы тәрбия алган, күркәм холыклы, йомшак табигатьле күпме аналарымыз бардыр? Булмавы да гаеп түгелдер. Зирә[3], чын тәрбия бирә торган мәктәпләремез булмагач, андый аналар безгә күктән төшмәс шул! Хәлбуки ананың балага тәэсире бик зурдыр. Бала анасын бик яратканга, анда булган һәр сыйфатны алырга тырышадыр. Анада булган табигать балага күчәдер. Тәрбияле ана баласына кечкенәдән үк гыйлем мәхәббәтене урнаштырадыр. Бездәге кеби «мулла килә, колагың кисәр,

[1] Тәрәккый – алга китү, прогресс.

[2] Фарыз – үтәлүе тиешле булган бурыч.

[3] Зирә – чөнки, аның өчен; нигә дисәң.

шаярсаң, мәктәпкә илтерем, мөгаллим үзеңне суктырыр» кеби сүзләре илә баланы укуга, мөгаллим вә мөгаллимәләргә дошман ясамыйдыр. Мәктәптән кайткач, дәресләрене карый, тырышуына дикъкать итәдер. Мәктәпкә йибәргәч тә, бөтен мәсъүлиятьне[4] өстеннән ташлап, үзе бер читтән карап торучы булмыйдыр. Бала күбрәк вакытны анасы янында үткәрәдер. Тәрбияле милләтләрдә аналар үзләре балаларны урта мәктәпләргә, гимназияләргә хәзерләп кертәләр. Шуның өчен анлар аналар йитештерергә ибтидаи[5] мәктәптән башлап, гали мәктәпләргә кадәр ачканнар. Тәрбияле аналарны һәрвакыт хөрмәт итәләр. Тәрбияле аналардан туган балалар, тәннәре сәламәт, гакыллары камил булып дөньяга киләләр. Вә шуның өчен дә бу кадәр гыйлем вә һөнәр таратырга, булмаган нәрсәләрне булдырырга сәбәп булалар. Бездә юк нәрсәләрне үземез кәшеф итү[6] түгел, башка кеше ясаган нәрсәгә дә авызымызны ачып карыймыз. Баланың сәламәт, үткен фикерле булуы өчен саф һавада, яхшы мөрәббияләр[7] кулында тәрбия алуы тиештер. Бу көндә яурупалылар аена 25 сумнан 50 сумга кадәр жалуния биреп, мөрәбби вә мөрәббияләр тоталар. Бездә ни эшлиләр? Бездә дә шундый мөрәббияләр бармы? Кызларының чын ана булуына тырышалармы? Кайда тырышу, кайда тәрбия бирү, бәлки көне-төне тел илә, матбугат илә безне тәхкыйрь итәләр[8]. «Дин мәгыйшәт»[9] мәҗмугасы[10] дин исеменнән безне кәнизәк[11] хәлендә, башымызга капчык кидереп тәрбия итәргә кушадыр. «Һүннә накыйсәт әл-гакыйль»[12] диеп, безне тәрбиягә яраксызга саный, үзенең ана вә туганнарыны тәхкыйрь итәдер. Мөхтәрәм пәйгамбәремез Галәйһиссәламнең ирләргә, хатыннарга гыйлем фарыз дигәнене, хатыннарга вәгазь-нәсыйхәт сөйләгәнене онытадыр. «Сибирия» газетасы хиҗабны[13] ташларга куша, диеп, каравыл кычкырадыр. Яңа дөньяга килгән газетага ифтира итәдер[14]. Хәлбуки «Сибирия»нең чыккан номерларының һичберендә хиҗаб хакында бер сүз дә булганы юктыр. Ни язылса, гыйлем-тәрбия хакындадыр. «Сибирия»нең максаты – шул ук ирләрнең дә тута вә сеңелләре булган хатын-кызга ислам тәрбиясе бирү, тормышка кирәкле нәрсәләрне өйрәтүдер. Әй «Дин мәгыйшәтчеләр», чын тәрбия алмаган бер кызга биш кат капчык кидерсәңез дә әхлагына кәфил була[15] алмыйсыз ич! Чын ислам тәрбиясе алган кызга капчык бер дә кирәкми, ул болай да үз әхлагыны үзе саклый аладыр. Безгә хәзер хиҗаб мәсьәләсе

[4] Мәсъүлиять – җаваплылык.
[5] Ибтидаи – башлангыч.
[6] Кәшеф итү – ачу, ачык беленмәгән бер нәрсәне табып мәйданга чыгару.
[7] Мөрәбби, мөрәббия – ир-ат һәм хатын-кыз тәрбиячеләр.
[8] Тәхкыйрь итү – хурлау, мыскыл итү.
[9] «Дин вә мәгыйшәт» журналы турында сүз бара.
[10] Мәҗмуга – журнал, җыентык.
[11] Кәнизәк – кол хатын, җария.
[12] «Һәр кимлек, начарлык акылдан, гыйлемнән» мәгънәсендә.
[13] Хиҗаб – пәрдә, йөз өрткеч.
[14] Ифтира итү – яла ягу, берәү өстенә ялган гаеп ташлау.
[15] Кәфил булу – тәэмин итү, гарантия бирү.

түгел, гыйлем вә тәрбия мәсьәләсе кыйммәттер. Әүвәл укырга, чын мөселман хатыны булырга тырышырга кирәк. Хиҗаб кирәкми, хөррият[16] диеп, дин вә дөньясыннан хәбәре булмаган бер кызны курчак кеби соң мода илә киендереп кую көлке булган кеби, «Һүннә накыйсат әл-гакыйль» диеп, ярты дөньямызны тәшкил иткән хатыннарны хайван дәрәҗәсендә тәрбиясез калдыру да диваналыктыр. Без боларның икесенә дә карамый, хатын-кызга уку илә чын тәрбия генә кирәк дигән юлымыз илә барачакмыз.

*Сибирия, 1912, 22 март.*

***Фатыйма-Фәридә***

**[Бу соңгы вакытларда...]**

Бу соңгы вакытларда бөтен халыкның әһәмият биргән нәрсәсе балалар булып, киләчәктә милләткә баш булачак яшьләрнең сәламәтлекләрене саклаудыр. Чөнки дөнья да шундый бер урындыр ки, анда килгән һәммә кеше бер билгеле вакытка кадәр торганнан соң, үзенең йиренә исемне саклаячак баласыны калдырып, мәңгелек йортка күчәдер. Бер милләтнең әгъзалары да бераз вакыттан үзләренең йирләрене яшьләргә калдырачаклардыр. Шуның өчен дә бөтен төрле рәхәттә яшәгән картлар бераздан юк булып, аларның йирләрене яшьләр тотачактыр. Бу яшьләр үз вакытларында яхшы торсыннар өчен, картларның, ата-аналарның аларны шул киләчәк көнгә хәзерләүләре тиештер. Бер милләтнең тәрәккыйсе[17] бу көн картлар илә генә булмаенча, киләчәктәге яшьләр иләдер.

Тырыш бер атаның никадәр вакытлар азапланып җыйган бөтен малыны бер тәрбиясез угыл ике-өч елда юк итәдер. Милләтләр дә шулай ук, киләчәктәге әгъзалары тәрбиясез-сырхау булсалар, ул милләт мөнкариз[18] буладыр. Йир йөзендә яшәргә теләгән һәр милләт балаларының сәламәт, гакыллы, тугры фикерле булуларына тырышулары тиештер. Бала тәрбиясенең нигезе аналар кулында булганга, бу хакта хатын-кыз дөньясыннан бер-ике сүз язмакчы булам. Франсәдә[19] балалар выставкасы булды. Шул выставкада кемнең баласы матур булса, шуңар беренче мәкяфәт[20] биреләчәк булды. Һәм шул мәкяфәтне ике яшьтәге бер кыз алды дигән хәбәр гәзитәләрдә байтак күренде. Моңар кадәр милләтләрнең тәрәккыйсене үлчәмәк өчен һәртөрле кул һөнәрләреннән выставкалар ясасалар да, моңар кадәрле җанлы инсаннардан[21] выставка ясалганы юк иде. Хәзер бала тәрбиясендәге әһәмиятне күрсәтер өчен вә ата-аналар балаларның сәламәт гакыллы, таза-матур булулары өчен тырышсыннар дия, балалар выставкасы да ясый башладылар. Чөнки бу соңгы елларда французларда бала туу күп кимеде. Башка халык ел саен артып

[16] Хөррият – иреклелек, азатлык.
[17] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[18] Мөнкариз – сүнгән, юкка чыккан, беткән, нәселе калмаган.
[19] Франциядә.
[20] Мәкяфәт – бүләк, премия.
[21] Инсан – кеше, адәм.

торганда, французлар кимеп тордылар. Милләт өчен бу иң зарарлы. Аның инкыйразына[22] олуг бер сәбәп булганга, французларның бик эчләре поша башлады. Ничек булса да саннарны арттырырга тырыштылар. Өч баласы булган кешегә бик күп җиңеллекләр ясалды (Аларда күбесендә бала бер генә, я ике генә була иде). Безнең татар халкы да, йир йөзендә торырга теләсә, балаларга дикъкать итәргә, киләчәк нәселнең сәламәт булуына тырышырга тиештер. «Хәстә[23] тәндә тугъры фикер булмый» диләр. Шуның өчен балаларның сәламәт булуы иң кирәкле бер эштер. Мәгаттәәссеф[24] бездә соңгы елларда балаларның бик күп булуы күренәдер. Күп гаиләдә биш-алты бала үлгән була. Һәр шәһәрдә елына никадәр бала үлә. Авыллардагы бала үлүне әйтергә дә юк. Бу эш безнең киләчәгемез өчен күңелле түгелдер. Боның сәбәбе нәрсәдә? Ни өчен бездә бу кадәр бала үлә? Моның чарасы юкмыни? Башкаларда да шулкадәр бала үләме? Менә бу сөальләр безнең өчен бик әһәмиятледер. Безнең аналар бала тәрбиясе илә таныш булмаганга, балаларны юлы илә тәрбия итмиләр. Күбесе, балалары тугач та, үз сөтләре илә тәрбия кылырга мөмкин була торып, ашказаннары һәнүз[25] бик зәгыйфь булган балаларны төрле нәрсәләр ашатып хөрмәт итә башлыйлар. Ике-өч атналык балага манный ашатдыклары кеби, ике-өч айлык булгач та, суырып юанып торсын дия, пәрәннек, икмәк, ит кеби нәрсәләр биреп, балаларның эчләрене бозып бетерәләр. Бу кадәр нәрсәләрне сеңдерә алмаганга, бичара балаларның эчләре авыртып еглыйлар, эчләре китә. Аналар да: «Баламыз еглый», «Кара егълак, эче китә, күз тигән», диеп, әллә ниндәй им-томнар илә балаларны бөтенләй эштән чыгарып, теге дөньяга китүне ашыктыралар. Берәр кешегә ачулансалар, кәефләре китсә, яше дә тулмаган балаларны кыйнап, имгәтеп бетерәләр. Ачу илә бозылган сөтләрене балаларына имезеп, балаларны да холыксыз ачучанлыкка үз сөтләре илә нык өйрәтәләр. Үзләре имезә торган аналар да, балалары елаган саен имезүләре сәбәпле, балаларны чирләтеп бетерәләр. Минем югарыда язган сүзләрем һәркемгә мәгълүм бик тәкрарланган[26] сүзләр булса да, киләчәктә язачагым нәрсәләргә мөкаддәмә[27] улмак үзрә яздым. Гәзитә сәхифәләрендә хифзыссыйхәттән[28] бәхәс итү дә бик килешеп бетми. Шулай да безнең Себернең киң сахраларында шундый искә төшерүгә мохтаҗ аналар күп булганга, киләчәктә вә баланы туганнан бераз үскәнгә кадәр ничек тәрбия кылырга кирәклеге хакындагы төп кагыйдәләрне кыскача язачагым.

*«Сибирия», 1912, 14 апрель.*

---

[22] Инкыйраз – бетү, юкка чыгу.
[23] Хәстә – авыру, чирле.
[24] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.
[25] Һәнүз – әле дә, һаман.
[26] Тәкрарлау – кабатлау.
[27] Мөкәддәмә – сүз башы.
[28] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау юллары.

***Фатыйма-Фәридә***

**Дача тирәсендә**

Дачага әүвәл килгән көндә үк безнең дачаның каршысында ярты чакрым ераклыкта бик матур яшел биналар дикъкатемне җәлеп иттеләр. Мин боларны берәр байның дачасы диеп уйласам да, соңыннан аның ятимә-фәкыйрә кызларга махсус приют икәнене ишетеп, барып карамакчы булдым. Бер көнне йөрергә чыкканда бардым. Тирәли ямь-яшел урман уртасында рәшәткә илә әйләндереп алган матур гына биналар күрдем. Капкадан кергәч, начальница – карт кына бер ханым каршы алды. Мөмкин булса, приютны карарга теләдегемне вә бераз мәгълүмат аласым килгәнене сөйләдем. Әлеге ханым да мәмнүният[29] илә күрсәтәчәгене бәян итте. Биш яшьтән унҗиде яшькә кадәр кызлар кайсы китап укып утыра, кайсы тирә-якта булган нәрсәләрнең рәсемене ясый, кечерәкләре урталыкта туп уйныйлар, даган атыналар. Һәркаюсы шат. Начальница илә гомуми йокы бүлмәсенә (спальняга) кердек. Зур бер бүлмә, ике якта кровать-сәкеләр ясап, икешәр кызга бергә урыннар хәзерләнгән. Якты, һавадар бер бүлмә. Соңра аш бүлмәсе. Ике олуг өстәл тирәсендә озын эскәмияләр, табак-савыт шкафы. Бу бүлмәнең мебелене тәшкил итә иде. Шуның янында олуг кухня. Аш пешерүче хатын янында өйрәнүче ике кыз илә кичке ашны хәзерлиләр иде. Өйнең каршысында бакча, кергәч тә, кечкенә түтәлләр ясап, матур гөлләр утыртканнар. Вак кына чәчкәле агачлар бу бакчаны бизиләр иде. Аның артында түтәл бакчасында һәртөрле яшеллекне балалар үзләре карап үстердекләрене начальница сөйләде. Һәр йирдә бер тәртип. Безнең ата-аналы балаларымыз күрми торган тәрбия урамда йөриячәк балаларга бирелә. Начальницадан алдыгым мәгълүматка күрә: бу приют моннан кырык ел әүвәл ике рус бае тарафыннан тәэсис ителеп[30], шул ук байлар тарафыннан обеспечить ителгән. Ягъни бу приютны идарә итмәк өчен банкыга илле ике мең сум акча салынган. Шуннан алган проценты илә идарә кылына. Ләкин ул гына азрак булганга, директор да ел саен үз тарафыннан ике-өч мең сумнар иганә кыла. Әүвәлге директоры үткән ел үлгән Кухтерин[31] булып, бу приютның тәрәккыясенә[32] күп хезмәт иткән. Хәзер ул үлгәннән бирле хәйриятле[33] булган Горохов[34] директор имеш. Ул да елына бер-ике мең сум иганә итәдер. Тәрбия кылына торган балалар илле кыз булып, бу көн монда кырык ике кыз бар. Башкалары каюлары кардәшләренә киткәннәр. Монда алган мәгълүматларны арттыру өчен, янә укырга телиләр. Шундагы кызлар арасында да өчесе прогимназиягә имтихан

---

[29] Мәмнүният – разый булу, шат булу; разыйлый, шатлык.

[30] Тәэсис ителү – төзү, оештыру.

[31] Иннокентий Евграфович Кухтерин (1870–1911) – Томск сәүдәгәре, атаклы хәйрияче, ятим балалар өчен приют ача.

[32] Тәрәккый – алга китү, прогресс.

[33] Хәйрият – изгелек, яхшылык, хәерлелек.

[34] Горохов – Томск губернасының балалар приютлары попечительлегенең казначысы.

биргәннәр. Приютка җиде, иң яше биш яшендәге балалар кабул ителеп, унҗиде яшькә кадәр тәрбия кылыналар. Соңра махсус сорап хезмәткә алдыклары кеби, теләүчене кияүгә дә бирәләр. Приют янында бер класслы мәктәп бар. Балалар укый-язудан башка, кул эшләре, идарәи бәйтия[35] кеби эшләрне дә өйрәнәләр. Һәркөн кизүләп (чиратлап) зуррак кызлардан аш пешерүче янына ике кыз биреп, пешерергә өйрәтәләр. Кер юганда да прачка янына ике кыз бирәләр.

Шулай итеп, фәкыйрә-ятимә кызлар урамда сәфаләттә[36] йөрүдән котылып, йылы урында үсеп, башлары бөтен киләчәк көндә гомер иткәндә кирәк булачак нәрсәләрне һәм нәзари[37], һәм гыйльми уларак өйрәнеп, кеше булып чыгалар. Приютның монда дачасы булып, калада Магистрацкий урамда үз йорты бар. Кышын анда торалар. Җәй көне балаларны тузанлы, начар һавалы калада тотмаенча, аларны саф һавалы урмандагы дачаларына алып чыгып рәхәтләндерәләр. Бу приют Мариинский аталса да, хөкүмәттән фәләннән бер дә ярдәм булмаенча, бары шул ике русның иганәсе илә тәэсис ителгән. Хәзерендә дә шуларның калдырган акчасы илә дәвам итәдер. Бу приютны күргәч, үз хәлемез хәтеремә килде. Бездә бик күп ата-аналы балалар да яхшы тәрбия ала алмыйлар. Һәртөрле күңел ача торган нәрсәләрдән мәхрүм, кирәкмәскә генә яратылган мәхлуклар булып йөриләр. Шулай да Уфада өч ел әүвәл күрдекем «Мөселман ханымнар җәмгыятенең» ятимә кызларга махсус тәэсис ителгән приюты – мөхтәрәмә Мәрьям ханым Солтанованың ничә еллардан бирле тәрбия итеп килгән ятимханәсе. Барлыгы анда мөселман кызлары да, бу кадәр мөкәммәл[38] булмаса да, яхшы тәрбия алдыкларыны, кул һөнәре өйрәнеп, сәфаләткә каршы коралландыкларыны күрдекем. Вакыт калдырдыгы гүзәл хатирәт киләчәктә дә безнең ятимә кызларымызның да шулай сыеначак йирләре табачакларыны уйлап, киләчәккә өмет артты. Ләкин егерме-утыз миллион мөселманның яртысы (ун миллион) булган мөселман хатын-кызлары өчен бонлар гына бик аз булганга, башка йирләрдә дә шундый хәерле мөәссәләремез[39] булса иде, дигән уйлар башыма берсе артыннан берсе килеп тора башлагач, биргән мәгълүматы өчен начальницага рәхмәт әйтеп, исәнләшеп, үземнең дачага кайтып киттем.

*«Сибирия», 1912, 17 июнь.*

---

[35] Идарәи бәйтия – йорт, хуҗалык эшләре.
[36] Сәфаләт – хурлык, түбәнлек.
[37] Нәзари – теоретик.
[38] Мөкәммәл – тәмамланган, камилләшкән.
[39] Мөәссәсә – оешма.

***Сания Гыйффәт***

**[Адәмнең хайваннан аерымлыгы...]**

Адәмнең хайваннан аерымлыгы гакыл вә сөйләү берләдер. Телсез кеше никадәр кызганыч булса, телле булдык та кешегә үзенең максудын тәмле итеп аңлатудан, яхуд язудан гаҗиз кеше шулкадәр кызганычтыр.

Менә мондый кызганыч мәхлуклар безнең мөселман хатыны балаларыдыр. Мескен мөселман хатын-кызлары берсе янына берсе килсә, исәнмедән соң нәрсә әйтергә аптырап калалар. Мәҗлесләрдә инде бөтенләй тын (Хатыннар мәҗлесендә булганым юкка күрә, кызлардан гына бәхәс кылам). Бер-берсе берлә якын белешләр улдыкларыны ялт-йолт минут саен бер-берсенә карап көлешеп торганнан беләсең. Бер-берсенә якын утырган булсалар, сирәк-сирәк берничә сүз генә пышылдап алалар, аны да кычкырып түгел. Балаларымызга килсәк, 6–7 яшендә дә рәтләп сөйли белмиләр.

Бер баладан берәр нәрсә хакында сораша башласаң, я көлеп тик тора, я яныңнан кача, яхуд әллә ниләр бутап бетерә. Балаларча мөлаем торышлы, тәмле җаваплы мөселман балаларына бик сирәк очрала. Башкалардагы балаларның сөйләшүләренә гаҗәпләнәм, күп вакытта шул тугрыда уйлыйм вә бу сүз рәтен белмәүләренә сәбәп итеп, кечкенәдән сөйләргә үгрәтмәвемезне күрсәтмәкче булам.

Мин һичвакыт та татар хатынын үзенең сөекле баласы берлә сөйләшеп, сөальләр биреп утырганын күргәнем юк. Эштән бушап, балаларын кулына алсалар да, ярты-йорты тел берлә сакауланып сөяләр. Бала бернәрсә хакында сораса, кая аңа аңлату, мәгълүмат бирү, «Таптың сорар вакыт, йөдәтмә, эшем бар әле», яисә «Күпне белсәң, тиз картаерсың», диеп кенә тукталалар, яхуд ул нәрсә хакында үзләренең дә мәгълүматлары улмадыгыннан (чөнки татар хатыннары күп нәрсәне белүдән мәхрүмә) ялгыш мәгълүмат биреп, баланың игътикадыны[40], саф гакылыны бозалар. Менә шундый яңлыш мәгълүматлар аркасында хаклыкны кабул итми, кешегә дә ышанмый торган мөтәгассыйб[41] (кечкенә вакытта алынган тәрбиянең зурайгач үзгәрүе мөмкин түгел дәрәҗәсендә, аз вакытта гына үзгәргәнлеге мәгълүм). Кечкенәдән сөяргә үгрәтмәвемез аркасында, телсезләрдән аз гына алда булып йитешәләр.

Монда шуны да әйтеп китәргә мөмкин: байтак җирдә кызлар мәктәбе күргәнем бар. Програмнарына төрки, Коръән кертелгән булса да, мәгаттәәссеф[42], укыган хикәяләре агыздан сөйләтелми, сөйләтелсә дә, бөтенләй китаптагы төсле үк килеп, күңелдән генә укыйлар. Хикәя нәрсәгә мисал, нәрсә хакында язылган, балаларга бөтенләй белемсез кала. Мөгаллимәләремез Коръән, төрки дәресене шулай илтифатсыз укыткач, бернәрсәдән хәбәрләре булмаган татар хатыннарын сөйләргә дә урын юк инде. Чөнки аларның боны

---

[40] Игътикад – ышану, инану; күңел беркетү.
[41] Мөтәгассыйб – фанатик.
[42] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.

укытканчы, «Шорут әс-Салават»[43] укытсалар, намаз рәтен белерләр иде, дияселәре көн кеби, һәм әйтәләр дә.

Томскида мөгаллимә: Сания Гыйффәт.

*«Сибирия», 1912, 22 июль.*

***Маһруй Мозаффария***

## [Бала тудыру вә тәрбияләү...]

Бала тудыру вә тәрбияләү хосусында без ханымнарда булган косурлыкларны[44] әйтеп узмакчы булам.

Бала тудыру вә тәрбияләү ханымнарның вазыйфасыдыр. Безем милләт ханымнарының бала тәрбияләү тугрысында бик күп косурлыклары бар. Җөмләдән берсе – бала дөньяга килү илә әби булган карчыкларымыз баланың авызына бал илә май тутыралар. Бу кайсы заманнан калган горефемездер. Бала хәстәлеге[45] илә мөбталя[46] булган анасын шул сәгатьтә аякка бастырып, госел[47] фарыз дигән булып, юындырырга мәҗбүр булалар. Соңра, икенче көнендә, унар-унбишәр хатын җыелып, мунчага алып баралар. Бала тудырган хатын илә мунчага керү бик зур савап имеш. Менә безнең милләт ханымнарының җаһилиять[48] заманасыннан калган горефләре. Яшь баланы берничә көннәрдән соңра төрле ырымлар ясап, бишеккә салу гадәте дә бар.

Баланың анасы, бишек дигән булып, яшь баланы күп селкү илә, тәмам иләнеп, бичара бала йокларга мәҗбүр була, яшь баланың агачтан яфрак төшкәнче карыны ача дип, тәртипсез имезү, яхуд ботка ашату илә баланың мигъдәсе[49] зәгыйфьләнеп, эче катып китә. Шул вакыт карчык әбиләр «үчәм» булган дип, тукмаклар илә им-том ясап йөриләр. Безнең әбиләремез арасында мондый хорафатлар бик күп, ләкин бетерү мөмкин түгел. Безнең милләт балалары яшьтән тәрбия начар булганлыктан, күбесе «английский авыру», яхуд «золотуха» хәстәлегенә мөбталя булалар. Балаларга: ата-ана вә олуг булган кешеләргә итагать[50] итүнең ысулын күрсәтмиенчә, төрле нәрсәләр илә куркытып, балаларның яшьтән йөрәкләренә курку салып, әхлаксыз булуларына үземез сәбәпче буламыз. Балаларны яшьтән тәрбия вә әхлак хөснегә[51] үгрәтеп, тиешле нәрсәләрдән мәгълүмат бирү ата вә аналарның бурычыдыр.

---

[43] «Шорут әс-Салават» – Салават шартлары.
[44] Косурлык – кимчелек, җитешсезлек.
[45] Хәстә – авыру, чирле.
[46] Мөбталя – дучар булган.
[47] Госел – коену, юу.
[48] Җаһилиять – наданлык.
[49] Мигъдә – ашказаны.
[50] Итагать – буйсыну, карышмау, кушканны эшләү.
[51] Хөсне әхлак – яхшы холык.

Шөкерләр улсын, шәһәремездә бу соң елларда җәмгыять хәйрия тарафыннан вилядәтханә[52] ачылып, яхшы гына мәгълүматлы акушеркалар куелып, надан әбиләрнең катышы улмаенча, акушеркалар күрсәткән ысул илә яхшы хадимәләр[53] тәрбия кылалар имеш. Ачыграк фикерле вә мәгълүматлырак ханымнар шунда барып бала тудыруны мәслихәт күрәләр. Яшәсен һиммәтле[54] байларымыз. Артсын тәртипле вә тәрбияле урыннарымыз.

Җитешсен милләт аналары булган туташларымыз.

Казан

*«Сибирия», 1913, 4 гыйнвар.*

***Терешкавия Өммегөлсем***

## Тәрбия хакында

Адәмне адәм иткән тәрбия булган шикелле, адәмне адәмлектән чыгарып, ишәктән ахмак, юлбарыстан җырткыч, бүредән усал, куяннан куркак ясаган да тәрбиядер. Моны һәрбер ата булган кешегә белү никадәр тиеш булса, сакчы фәрештәләр шикелле баланың һәр эшен тикшереп торган анага вә киләчәктә ана булачак кызларга тагы да артыграк тиештер. Чөнки моны гани[55] адәм өчен тәрбиянең никадәр әһәмияте барлыгын белми барганда, җанымыздан газизрәк балаларымызның «калеб[56] бакчалары» эчендәге яңа гына өретелеп тышка чыга башлаган «яхшы сыйфатлар» шикелле хуш исле, матур «рух чәчәкләрен» төртеп, харап итеп куюымыз дөнья шикелле ачык бер хакыйкатьтер.

Балаларымызны саф рухлы, йомшак холыклы, яхшы калебле итеп тәрбияләп, үзләренә, вә үзләренә булган шикелле үк башка адәмнәргә файдалары тиярдәй каһарманнар, чын адәмнәр итәрдәй итеп тәрбияләү, табигый, бик авыр эштер. Әмма, «авыр» дия яхшы тәрбиягә кул селкеп, чәчәк шикелле балаларымызны начар тәрбия белән һәлак итүемез вөҗдан карашынча да, гакыл карашынча да, инсаният карашынча да, рух карашынча да, хәзерге егерме гасыр шикелле мөтәрәккый[57] гасыр фәлсәфәсенең карашынча да гафу ителмәслек җинаятьтер. Инде мондый җинаять өчен безнең «тән» исемле бур күзеннән дә яшергән рухымыз газапланырга тиештер.

Тагы да бер кат әйтәм: адәмне чын адәм итәрлек дәрәҗәдә тәрбияләү авыр булган эш шикелле, ничек итеп тәрбияләгәндә адәмнең чын адәм булырын белү дә җиңел түгел, бәлки Тянь-Шань тавы шикелле, тауны энә белән ваткалап, йир белән тигезләүгә караганда да авырркатыр. Шулай булса да, мөмкин булмый торган эш тә түгелдер. Чөнки хәзерге «егерменче гасыр бабамыз»ның мәгълүматы безгә һәр авыр мәсьәләне хәл итеп торган

---

[52] Вилядәтханә – бала тудыру йорты.
[53] Хадимә – хатын-кыз хезмәткәр.
[54] Һиммәтле – тырыш, булдыклы.
[55] Гани – бай.
[56] Калеб – йөрәк.
[57] Мөтәрәккый – алга киткән.

шикелле, «Нинди рәвештә тәрбияләнгәндә адәм чын адәм булачак?», «Ничек тәрбияләнгәндә адәм харап булачак?» дигән мәсьәләләрне дә хәл иткәндер. Инде безгә, ягъни, без – киләчәктә аналар булачак кызларга вә хәзер аналар булып, балалар тәрбияләгән аналарга, әнә шул югарыда әйткән, «егерме гасыр бабамыз»ның тирән мәгънәле китаплары эченнән кыйммәтле фикерләрен алып, ул «егерменче гасыр бабамыз» күрсәткән юл белән, ул биргән киңәш белән эш кылырга, балаларымызны тәрбияләргә кирәктер.

Чөнки, шулай булмаганда, безнең балаларымыз: кирәк ул, кирәк кыз булсыннар – барыбер, дөньяны дер селкетә торган каһарманнар, арысланнар буласы урында, үз күләгәләреннән үзләре курка торган хиссез җанлы курчаклар гына булып калачаклар. Бу безнең зәгыйфь, болай да «картайдым, озакламый үләрмен дә» дия дөньяда яшәгән булып маташкан «милләт бабамызның» киләчәктә газапланып үлүенә зарур сәбәп булачактыр. Боңар ирләремез, аларга караганда да бигрәк мөхтәрәмә ханымнар, без – хатын-кызлар гаепле булачакмыз. Бу җөмләләрне укыгач сез, ханымнар, бәлки «Менә иске авыздан яңа сүз!.. Тәрбия шикелле авыр мәсьәлә хакында тырышмый, милләтемезне харап иткән өчен без – хатын-кызлар гаепле булыйк та имеш, безгә караганда әллә никадәр алда булган ирләремез, бездән күп дәрәҗәдә ким гаепле булсыннар имеш. Юк, бу хата! Хатын-кызга болай язарга ярамый. Без – хатын-кызлар, тәрбия шикелле авыр мәсьәләдә ирләремезгә караганда ничек күп уйлыйк, бу безгә ярамый», – диярсез.

Әмма бу «Без, хатын-кызларга, без ни хакында уйламавыбыз, «озын чәчләр» вә «кыска гакыллар», безнең эшемез идән юу, аш пешерү, ирләремезнең каршысында сөлге тотып тору, битемезне кершән белән агарту, кашымызны каралту» дигән шикелле үк килешсез фикерләр. Чөнки Аллаһы Тәгалә хәзрәте безне һич тә бу эшләр өчен генә яратмый, башка, ирләремез шикелле үк, баш белән уйлый торган эшләр, мәсьәләләр өчен дә яратмыштыр вә шуның өчен, ягъни төрле-төрле мәсьәләләр хакында уйлар өчен дә безгә Аллаһы Тәгалә ирләремезгә биргән шикелле үк кыйммәтле гакыл бирмеш. Ирләремезнекенә караганда әллә ничә мәртәбә сафрак булган рух белән рухландырдыгы кеби, табигатьтәге матурлыкны күреп ләззәтләнер өчен безне күз белән зиннәтләмеш. Музыка тавышлары белән рухымызны тәрбияләр өчен безне ишетү кувәсенә[58] патша ясамыш... Менә шушыларны белә торып, «Безнең эшемез тәрбия хакында кайгыру түгел, ә кер юу, самавыр агарту» дия, ишәкләр көләрдәй рәвештә уйлап йөрүемез югарыда әйткән Аллаһның биргән нигъмәтләре белән файдаланырга теләми, үземезгә караганда бигрәк газиз балаларымызны, алар белән үк хәлдән тайган «милләт бабамызны» хисап итү булмасмы? Ярабби, үзең мәдәт[59] бир.

*«Сөембикә», 1914, №16, б.10–12.*

---

[58] Кувә – көч, куәт.
[59] Мәдәт – ярдәм.

***Багбостан***

## Баланы тәрбия итү

Балаларны чын тәрбия илә тәрбия итмәк өчен бик күп юллар бардыр. Фәкать безнең хәзерге хәятемездә файдаланырга мөмкин булган вә иң әһәмиятлеләре гаилә эчендә булганы һәм мәктәп-мәдрәсәләрдер. Бу ике урында фәкать мәгънәви вә рухи тәрбиягә генә әһәмият бирмичә, тән тәрбиясенә дә әһәмият бирергә кирәк. Инсанга багышланган куәтләрнең кирәгенчә тәкмил[60] вә тәрәккыйсе[61] тугрысында тән тәрбиясенә тәэсире вә әһәмияте гаять зурдыр. Хәят мәйданындагы тартышта гайрәтле вә көчле инсаннар өчен максудка ирешү асатрактыр. Тереклек юллары да көчле, гайрәтлеләр өчен киңрәк ачылыр. Тән көченең башка көчләргә булган тәэсирен инкяр итәргә ярамый. Дөньяда яшәмәктә булган бөтен җан ияләре үз җенесләренең бәкасы[62] өчен җан көче белән тырышканлыклары мәгълүмдер.

Инсанга башка җан ияләренең бәкасы өчен туу, үсү йитә. Анларда истикъбаль[63] өчен хәзерләнү юк. Хәлбуки[64], инсанның бәкасы туып-үсү, бәлягатькә[65] ирешү белә генә тәэмин ителми. Анларда башка җанварларда булмаган фазыйләтләр[66], заруриятләр өчен дә истикъбальгә хәзерләнү – киләчәкне гүзәл сурәттә каршыларга тырышу фазыйләте яки зарурияте бар. Бу да инсаннарның иге-чиге булмаган тәрәккый вә үсүне кабил[67] истигъдадларының[68] бер тармагы яки анларга лязем бер шәрәфләредер.

Иске заманнарда истикъбаль өчен хәзерләнмәк, киләчәк өчен кайгырмак юк иде. Анлар үзләренең хаҗәтләрене вә вакытында хәзерләп өлгертә алалар иде. Чөнки ул вакытта хәят өчен тартышу безнең хәзерге заманыбыздагы хәленә килмәгән иде әле: тормыш та хәзерге кебек тәкәллефле[69] түгел, ул заман халкы үзләренең иң зарур хаҗәтләре үтәлсә, шуңарга канәгать иде, анлар артык тырышуны сөйми иделәр. Бәгъзе вакытта ач торырга да тугры килә иде; анлар ачлык сәбәпле кикерүне дә, туклык вакытында кикергән төсле күрсәтер өчен, Аллаһысына «хәмед»[70] укыр иделәр. Ләкин хәзерге халыкның холкы байтак үзгәрде. Иске садә[71] тормыш урынына әллә нинди тәкәллефләр берләште.

---

[60] Тәкмил – тутыру, җитештерү.
[61] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[62] Бәка – тормыш, яшәеш.
[63] Истикъбаль – киләчәк, булачак.
[64] Хәлбуки – ләкин.
[65] Бәлягать – үсеп җитү, буйга җитү.
[66] Фазыйләт – артыклык, өстенлек.
[67] Кабил – булдыклы, сәләтле.
[68] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.
[69] Тәкәллеф – күрсәтү өчен көчләп эшләү, ясалмалылык, кылану.
[70] Хәмед – мактау, мактап сөйләү.
[71] Садә – гади.

Шунлыктан тормыш кирәкләре иске заманнарга караганда йөзләрчә кат артты; ул заманның төшләренә дә кермәгән бик күп нәрсәләр заманымызның иң зарур хаҗәтләре арасына керде. Инсан хәзерге мәдәниятнең теләгән нәрсәләрен йиренә йиткерү өчен бик күп эшләргә вә эш мәйданында башкалар белә ярышырга мәҗбүрдер. Мәдәният иштикяләрен[72] кулга төшерү өчен, вакытыннан элек тырышырга-тырмашырга кирәк. Вакыты йиткәннән соң гына андый нәрсәләрне кулга төшереп булмыйдыр. Шуның өчен хәзерге заман халыклары иртәгә кирәк нәрсәләрен бүген, картлыкта кирәк була торган нәрсәләрен яшь чакларында хәзерләргә мәҗбүрләр. Заманымызның яшьләре гомерләреннән иң кызык, иң күңелле заманнарын мәктәп тирәсендә үткәрәләр ки, максудлары истикъбаль өчен хәзерләнмәктер.

Киләчәкнең кешеләрен хәзерләмәк вә хәзерләтүчеләргә ярдәм бирмәк табигатьнең теләве буенча ата-ана өстенә йөкләтелмештер. Шунлыктан ата-ананың балалары тәгълим[73] хосусында бик игътинаэ[74] белә хәрәкәт итүләре балаларына өйрәтелгән нәрсәләрнең гамьле гыйлемнәр булуы өчен әһәмият бирүләре иң бөек вазыйфаларыннан beредер. Чөнки югарыда дидекемез кебек төрле гыйлемлекләр тәхсил итү[75] истикъбаль өчен хәзерләнмәк тормыш юлында хәйрәт[76] вә аптыраш эчендә калмау өчендер. Хәлбуки, нәзарият[77], фаразыят[78] белән гомер үткәргән кешеләр мәгыйшәт[79] юлында вә һәртөрле аптырау вә караңгылыклардан имин түгелләрдер. Чөнки назарый мәгълүмат инсанга һич бервакытта катгый файданы тәэмин итмидер. Боның киресенчә, гамәли сурәттә гыйлем тәхсил итүчеләр һәр эшләрендә муаффәккыятьле[80] булырлар. Чөнки анлар хәят юлында лязем булган газим[81], сәбат[82], истикамәт[83] кебек сыйфатларга маликлардыр. Бондый адәмнәргә хәят юлындагы ишекләр ачыктыр. Тәрбия тугрысына килгәндә, аның иң мөһим ноктасы югарыда дидекемез кебек балаларның рухына дин, милләт, ватан мәхәббәтен салмактыр. Тәрбиядән асыл максуд шулдыр.

Боның әһәмияте хосусында сөйләп тормак габәстер[84]. Бинаэн галәйһи[85], балаларны тәрбия вә тәгълим хосусында ата-ана өстенә гаять мөһим өч вазыйфа йөкләнәдер:

---

[72] Иштикя – зарлану, шикаять итү.
[73] Тәгълим – уку, укыту.
[74] Игътинаэ – игътибар.
[75] Тәхсил итү – гыйлем алу.
[76] Хәйрәт – гаҗәпләнү, хәйран калу, аптырау.
[77] Нәзарият – теоретик мәгълүмат.
[78] Фаразыят – фараз итүгә корылган.
[79] Мәгыйшәт – тормыш, тереклек итү.
[80] Муаффәкыять – уңыш.
[81] Газим – алдан уйлап куючы, кыюлык итүче.
[82] Сәбат – фикердә, эштә нык торучанлык.
[83] Истикамәт – турылык, намуслылык, дөрес юнәлеш, юл.
[84] Габәс – файдасыз, буш эш.
[85] Бинаэн галәйһи – шуңа күрә, шул нигездә, шул сәбәпле.

Бере – анларның рухына дин, милләт, ватан мәхәббәте үрмәк;

Икенчесе – балаларга гамәли нәрсәләр генә өйрәтеп, хәят юлында файдасы булмый торган нәзари[86] гамәлләрне өйрәтүдән сакланмак (дөрест, нәзари гыйлемләрнең рухка бирәчәк тәэсирен инкяр итмибез. Фәкать андый нәрсәләр белә иштигаль итмәк[87] вакыты шул сабыйлык вакыты түгелдер. Баланың гакылы, хасияте өстендә хөкем итәрлек тышкы тойгыларга вә тәэсирләргә бирешмәслек хәлгә килгәч, буйга йиткәч, андый нәрсәләр белә бераз иштигале файдадан хали[88] түгелдер).

Өченчесе – тән тәрбиясенә әһәмият бирмәктер. Ир белән хатынның аерым вазыйфалары хакында сөйләдекемез вакыт шул чакларда сүземез булса кирәк.

*«Сөембикә», 1916, №15–16, 272–275 б.*

[86] Нәзари – теоретик.
[87] Иштигаль – шөгыльләнү.
[88] Хали – буш.

# VII БҮЛЕК

## «МИЛЛӘТКӘ ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТ ИТСЕННӘР!»

Татар хатын-кыз мәгарифе үсешенә зур өлеш керткән шәхесләр

### Ирләр гимназиясеннән шәһадәтнамә алган татар кызы

Бу ел Казан зыялы кызларыннан Суфия туташ Колахмәтова[1] ирләр гимназиясе хозурында «аттестат зрелости»га имтихан тотып, шәһадәтнамә алды.

Суфия туташ гимназияләрдә укымыйча, хосусый хәзерләнүчеләрдән иде.

*«Әл-Ислах», 1908, 10 июнь.*

### Мәрхүмә Суфия бикә

**Нукайский**

Солтан Сәлимгәрәй әфәнде Җантуринның җәмәгате Суфия бикә күптән бирле күкрәк сырхавы илә авырый иде.

28нче декабрьдә Истанбулдан телеграмм аның вафат хәбәрен китерде. Сәлимгәрәй әфәнденең кәндүсен[2] һәм өч яшь әүләденең[3] күз яше илә ятим калдыкларын белдерде. Җәнаб Хак һәркаюсына сабыр җәмил[4] бирсен. Сәлимгәрәй әфәнде үзе һәм ике кыз баласы янында иделәр.

Мәдрәсәи «Галия»дә бу көн мәрхүмәгә тәгъзия[5] улмак үзара матәм[6] тотылды, дәресләр туктатылды, рухына дога кылынды һәм мөдәррисләр тарафыннан шәкертләргә аның тәрҗемәи хәле вә «Мәдрәсәи Галия»гә матди хезмәтләре сөйләнде.

Ишетелдекенә бинаән, мәрхүмәнең яздырып куйган васыятьнамәсе бар имеш. Ахыр көннәрендә мәрхүмә үзе үзгәртмәгән булса, бу васыятьнамә «Мәдрәсәи Галия»гә стипендия улмак үзрә[7] 10000 сум, аның китапханәсенә 500 сум, Килем авылы мәдрәсәсенә 5000 сум васыять ителмеш икән. Бондан магада[8] Килем авылы мәдрәсәсенә бу көндәге 200 дисәтинә вакыф җире дә калган имеш. Җәнаб Хак рәхмәт итсен!

Уфа.

---

[1] Суфия Юныс кызы Колахмәтова (Агиева, 1889–1971 елдан соң), табибә, 1908–1914 елларда Петербургта хатын-кыз югары курсларында белем ала.

[2] Кәндү – үзе.

[3] Әүләд – балалар.

[4] Җәмил – матур, күркәм.

[5] Тәгъзия – үлгән кешенең якыннарын юату, күңел юату.

[6] Матәм – кайгы тоту.

[7] Үзрә – буенча.

[8] Магада – башка.

***Идарәдән:*** Суфия бикәнең вафаты өчен тәэссеф итеп[9] идарәмезгә йибәргән мәктүбендә И.Әсадуллин әфәнде мәрхүмәнең төп ватаны булган Килем карьясендә[10] ибтидаи[11] вә рөшди[12] сыйныфлы ир вә кыз балалар өчен яхшы мәктәпләр салдырып, шунларга 200 дисәтинә йир вакыф иткәнлеген вә хәзергәчә шул мәктәпләргә күп суммалар тотып килгәнлеген бәян итә вә:

«Уфа шәһәрендәге хатыннар җәмгыять хәйриясенең вөҗүдкә килүенә[13] ул зур сәбәпчеләрдән булып, матди җәһәтендә[14] күп ярдәм тигән вә «Мәдрәсәи Галия»нең бинасы салынган вакытларда мәрхүмә шуңа 18 мең сумлап иганә иткән иде», – ди.

Зәйнелгабидин әфәнде Габдеррәзаков тарафыннан язылган вә Килем авылыннан килгән мәктүбләрдә дә мәрхүмәнең яхшылыгы вә хәйрияты[15] зикер ителеп[16], рухына самими догалар кылындыгы бәян ителмәктәдер.

*«Вакыт», 1912, 6 гыйнвар.*

***Искәндәр Ишмөхәммәдов***

## Татар кызларыннан профессор булырга хәзерләнгән Сара ханым

Бу соңгы елларда мөселман галәме бик күп бәла һәм казаларга дучар булды. Яңа гына тәрәккый[17] юлына кереп, тормыш өчен тырышкан бер вакытта байларымыз, шагыйрьләремездән мәшһүр кешеләремезнең вафаты, хөкүмәтемезнең мөселманнарга шөбһәле күз илә карап, төрле йирдә булган тентү, хәбес[18] кеби кысынлыклары бары бергә җыелып, безне бик уңайсыз хәлләргә төшерде. Бу елларны үткәрү бик авыр булды. Фәкать хәзер бу караңгы болытлар аз булса да тарала, киләчәктә якты бәхетле булуымызга өмет бирә торганерактагы якты кояшның шәүләләре күренә башлады.

Шул киләчәктә бәхетле булуымыз, яхшы тормышымызга өмет бирә торган шәүләләрдән берсе булган Сара ханым Әхмәрованы күрсәтә алам. Сара ханым Русия мөселманнарыннан иң әүвәл гали мәктәптә (Казан университетында) укып, Казандагы Учительский школага инспектор булган Шаһбазгәрәй әфәнде Әхмәровның кызыдыр. Казан гимназиясене алтын медаль илә бетереп чыкканнан соң, Петербургтагы Бестужевский курсының[19] хокук шөгъбәсенә[20] кергән. Монда үзенең истигъдады, яхшы укуы илә курс

[9] Тәэссеф итү – үкенү, кайгыту.
[10] Карья – авыл.
[11] Ибтидаи – башлангыч.
[12] Рөшди – урта.
[13] Вөҗүдкә килү – барлыкка килү.
[14] Җәһәт – як.
[15] Хәйрият – изгелек, хәерлелек, ярдәм итү.
[16] Зикер итү – искә алу.
[17] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[18] Хәбес – тоткын, кулга алынган.
[19] Бестужевский курс – Петербургта хатын-кызлар өчен махсус югары мәктәп.
[20] Шөгъбә – бүлек.

идарәсенең дикъкатене җәлеп итеп, шул идарә тарафыннан профессорлыкка хәзерләнергә тәүсыя ителмештер[21]. Профессор булу өчен университет бетерү кирәк булганга, Сара ханым Петербург университетына кереп, бу ел 5нче июньдә аны да тәмам итәдер.

Безнең мөселманнардан гына түгел, руслардан да әүвәл университетның хокук шөгъбәсендә укып тәмам иткән хатын-кыз бик аз булып, профессорлык дәрәҗәсенә ирешкәннәре юк дип әйтерлектер. Шуның өчен Сара ханымның рус дарелфөнүнендә[22] профессорлыкка мендерелүе безнең өчен бик шатлыклы хәлләрдәндер. Бу вакыйга безнең милләтемезнең яртысы булган хатыннарның никадәр мөстәгыйдә[23] идекләрене бик ачык күрсәтәдер.

Соң вакытларда аз булса да гали мәктәп бетергән киң мәгълүматлы ханымнарымыз безнең моңа кадәр үз көчемезне үзебез яшереп тотканымызны ачык күрсәтәдер.

Шуның өчен Сара ханым кеби дәрәҗәгә йитүчеләр бер генә булмаенча, аның юлы илә баручы ханымнар артуны вә башкалар да аны үрнәк итеп алуларыны өмет итәмез. Сара ханым күп еллар яшәсен! Милләткә файдалы хезмәте тисен!

Петербург студентларыннан Искәндәр Ишмөхәммәдов.

*«Сибирия», 1913, 2 июнь.*

## Маһруй ханым Мозаффариянең кыскача гына тәрҗемәи хәле

1873нче сәнә миладидә Тәтеш өязе Олуг Тормы[24] карьясендә[25] дөньяга килмештер. Әткәсе Габделвәли хәзрәт шул ук карьядә 50 елга якын имамәтчелек итү[26] илә мәшгуль булмыштыр. Әнкәсе Зөя өязе Кече Кайбыч[27] карьясендә Төхфәтулла хәзрәт кызы улып, анадан ике генә яшендә ятимә калмыш вә яшь ана кулында тәрбияләнеп үсмештер. Бу иске ысул белән апасыннан төрки таныгач, әткәсеннән тәгълим вә тәрбия алмыштыр. 1891 ел 20нче сентябрьдә Казанга Печән базары мулласы Хуҗаәхмәд хәзрәткә икенче хатынлыкка бармыштыр. Ул вакыт Хуҗаәхмәд хәзрәт 52 яшендә иде. Аның әүвәлге хатыны зәгыйфә улып, әнкәсе дә бик картаю сәбәпле, сабак шәкертләрен укыту һәм барча мәхәллә эшләрен карау Маһруй ханымның үзенә калган. Авылда шул вакыттан ук ысул кадим белән булса да, сабак укыттырырга бөтен тәфсыйлате[28] белән мәхәллә эшләрен дә билфигыль[29] карарга тотынган,

---

[21] Тәүсыя итү – киңәш бирү, васыять итү.
[22] Дарелфөнүн – югары уку йорты, университет.
[23] Мөстәгыйдә – сәләтле, әзерлекле.
[24] Олуг Тормы авылы – хәзер Татарстанның Тәтеш районына карый.
[25] Карья – авыл
[26] Имамәтчелек итү – имамлык итү.
[27] Кече Кайбыч – хәзер Татарстанның Кайбыч районына карый.
[28] Тәфсыйлат – җентекләп аңлату.
[29] Билфигыль – чынлыкта, чынлап.

вә хакыйкатән[30] үзенең ара-тала белми торган сәбате[31] саясендә[32] бар авырлыкларга, барчасына күкрәк киереп, өстенә алган вазыйфаларын мөкаддәс[33] санап, әда иткән[34]. Зәүҗе[35] Хуҗаәхмәд хәзрәт үзенең имамәтенең 24нче елында бер яше тимәгән кызга никах укыган вә шул сәбәптән 1893 елда указы алынган. Шул ук елда мәзкүр[36] хәзрәтнең әнкәсе дә вафат иткән. Шөбһәсез, тормышның бу көйсез үзгәрүе Маһруй ханымга да тәэсир иткән. Янә фәләкнең[37] шундый йодрыклары белән әвәләнеп, тормышның җайсызлыкларына каршы кирәк тәдбирләр[38] уйлап торганда гына, көндәше Нәгыймә ханым да дарелбакыйга[39] күчкән. Моннан соң Маһруй ханымның хәятендә бөтенләй башка дәвер башланган. Чөнки өй тулысы балалар тәрбиясеме, мәхәллә эшләреме дисәң, бар да үз башына калган. Хәлбуки[40] бу елларда ысул җәдидә тавышлары да чыга башлаган иде. Шөбһәсез, Маһруй ханым да һәркемнән әүвәл боңа рәгъбәт иткән[41] вә бу тугрыда нинди фидакарьлекләр кирәк булса, барын да көлә-көлә эшләгән. Менә шушы гайрәт сәмәрәсе[42] уларак, Казанда ысул җәдидә тәгълиме шәрәфе[43] икенче уларак Маһруй ханымга төшмештер. 1901 елда Хәдичә ханым Әхмәрова иҗтиһады[44] белән Казанда рәсми уларак хөкүмәт тарафыннан татар кызларына махсус ибтидаи[45] мәктәп ачылмыштыр. Бу мәктәпнең дә татарча мөгаллимәсе ибтидаи тәэсистән[46] бирле шушы Маһруй ханымдыр. Маһруй ханым бу школа ачылгач, үз йортындагы кызларны да шунда дәлаләт итмештер[47]. Бу хәсән[48] иршады[49] өчен рәхмәтләр урынына бик күп кешеләрдән ләгънәтләр ишетмештер. Маһруй ханым школада иштигаль иткән[50] күк, өендә хосусый сурәттә әҗират[51] тәгълименә бирүдән гаҗиз фәкыйрә балаларны һәркөн өйләгә кадәр

---

[30] Хакыйкатән – чынлыкта.
[31] Сәбат – фикердә, эштә нык торучанлык, ныклык.
[32] Сая – күләгә, ышык.
[33] Мөкаддәс – изге, иң мөһим.
[34] Әда итү – үтәү, түләү.
[35] Зәүҗ – ир (хатынның ире).
[36] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.
[37] Фәләк – язмыш, тәкъдир.
[38] Тәдбир – эшне ахырын уйлап эшләү, алдан күрү.
[39] Дарелбакый – мәңгелек йорт, теге дөнья.
[40] Хәлбуки – ләкин.
[41] Рәгъбәт итү – омтылыш ясау.
[42] Сәмәрә – нәтиҗә, җимеш.
[43] Шәрәф – бәхет.
[44] Иҗтиһад – тырышлык, теләк.
[45] Ибтидаи – башлангыч.
[46] Тәэсис – төзелү, оешу.
[47] Дәлаләт итү – юл күрсәтү, өйрәтеп күрсәтү.
[48] Хәсән – гүзәл.
[49] Иршад – юл күрсәтү.
[50] Иштигаль итү – шөгыльләнү.
[51] Әҗират – көнлекчеләр, хезмәтчеләр.

тәрбия вә тәгълим белән мәшъгульдер. Менә милләткә шаян[52] тәкъдир хезмәт иткән мөгаллимәләремезнең иң баштагыларыннан беренчесе Маһруй ханым булып чыгадыр.

*«Сөембикә», 1914, №8, б.12–13.*

**Зәйнәб туташ Акимбетова**



Зәйнәб Акимбетова
*(«Сөембикә», 1914, №15)*

Зәйнәб туташ Казан университетында студент Искәндәр әфәнде Акимбетовның туган кардәшедер. Зәйнәб туташ урта мәктәпне бетергәннән соң, Бакуда Тагиевларның дүрт сыйныфлы кызлар мәктәбендә русча учительница булып берничә ел хезмәт итте. Урта дәрәҗә русча мәгълүматы булган кебек, нимесчәдән укый-яза алырык мәгълүматы бардыр.

Зәйнәб ханыма Бакуның һавасы килешеп йитмәдегеннән, Бакуны ташлап, торыр өчен Сәмәркандка килгән. Хәзер Сәмәркандта торадыр.

Зәйнәб туташ бик милләтпәрвәр, Сәмәркандта яшьләр түгәрәгендә ханымнардан иң эшлеклеседер. Яшьләр җыелышыннан бер дә калмый һәм калдырмый да. Любительский спектакльгә катнаша. Кыллы музыка оркестрына да күп ярдәм итә. Казаннан ноталар алдырып, пианинода көйләр өйрәнә. Татар һәм башкортларның иске һәм озын көйләрен бик яратадыр.

*«Сөембикә», 1914, №15, б.5.*

***Гайшә Чинаева***

**Троицкидан**

Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!

Ошбу тәшәккеремезне[53] гәзитәгезнең бер почмагында дәреҗ итүеңезне[54] үтенәмез.

Халкымызның уку юлында булган ихтыяҗларын игътибарга алып, мәрхүм Габделвәли әфәнде Яушевның әһлиясе[55] мөхтәрәмә Әшраф ханым Яушева 15 елдан бирле икенче мәхәлләдәге кызлар мәктәбенә ярдәм итә, һәр ел мәктәпнең хаҗәтләрен йитештереп, йөздән артык кыз балага бер төстән киемнәр биреп, гөл кебек тәрбияләп килде. Быел шул мәктәпне өр-яңадан салдырды. Хәзер бу мәктәпнең буе 30 аршин, иңе 20 аршин зурлыкта булып,

[52] Шаян – лаек, яраклы, тиешле дәрәҗәдә.
[53] Тәшәккер – рәхмәт әйтү.
[54] Дәреҗ итү – теркәү, арага кертү, урнаштыру.
[55] Әһлия – тормыш иптәше, хатыны.

биеклеге дә 5 аршин кадәрледер. Уртада коридор, ике якта сыйныф бүлмәләре. Бер башта баш мөгаллимә өчен аерым бүлмәләр ясалган. Парта, сыйныф тактасы вә башка әсбабы һәркаюсы, җитештерелгән кул эшләре өчен тегү машинасы куелган. Тегү-чигү, бәйләү, калфак ясау вә башка шундый йорт көтү өчен кирәкле һәртөрле эшләр үгрәтелә. Сентябрьнең береннән ачылып, уку башланды. 130 шәкерт укый, 8 мөгаллимә тарафыннан тәгълим бирелә. Русча өчен үзенә махсус учительница бар. Програмы гаять киң: уку, язу, игътикад[56] вә голүм диния дәресләреннән башлап, гарәбият, хисап, җәгърафия, татар әдәбияты, тарих, табигыять, хайванат[57], нәбатат[58], гаилә тәрбиясе дәресләренә кадәр укытыла. Соңгы ике елында ысул тәгълим вә тәрбия күрсәтелә. Мәктәпнең хифзыссыйхәт[59], нәзафәт[60] җәһәтләре мөхтәрәм вә могътәбәр[61] ханымнарымыздан Мәфтуха Яушева, Фатыйма Яушева, Өммегөлсем Яушева ханымнарның кулында булып, эчке идарәсе мөгаллимә Гайшә Чинаевага тапшырылмыштыр. Мөхтәрәмә Әшраф ханым Яушева җәнабләренә милләтенә иткән бу бөек вә даими ярдәме өчен мәктәптә укучы бөтен шәкертләр (130) вә мөгаллимәләр (9) исеменнән матбугат аша самими тәшәккер бәян итүне үземезнең бурычымыз дип беләбез. Чын мәгънәсе илә милләт аналарыннан саналырга лаеклы мөхтәрәмә Әшраф ханымның гомеренә бәрәкәт теләп, әмсаленәз[62] артуын самим калебтән[63] дога кылып телимез.

Троицкида икенче мәхәллә кызлар мәктәбендәге мөгаллимәләр вә шәкертләр исеменнән вәкилә – мәктәпнең баш мөгаллимәсе Гайшә Чинаева.

*«Вакыт», 1914, 31 декабрь.*

## Вафат

Эстәрлетамакның беренче мәхәлләсендә бер ел мөгаллимә булып торган Рабига туташ Кәримованың 27нче сентябрьдә вафат булуына Рәхилә ханым Габдуллина тәәссеф итеп[64] яза. Мәрхүмә аз гына вакыт эчендә зур иҗтимагы вә гыйлеме белән үзенә халыкның игътибарын җәлеп иткән иде, ди.

Рабига Кәримова да, башка мөгаллим вә мөгаллимәләремез кеби, күкрәк авыруы белән вафат булган.

*«Тормыш», 1915, 1 октябрь.*

---

[56] Игътикад – чын күңелдән ышану.
[57] Хайванат – зоология.
[58] Нәбатат – ботаника.
[59] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау турындагы фән.
[60] Нәзафәт – чисталык, арулык.
[61] Могътәбәр – абруйлы, хөрмәтле.
[62] Әмсал – үрнәк, мисал.
[63] Калеб – йөрәк.
[64] Тәәссеф итү – үкенү, кайгыру.

***Хәдичә Дунаева***[65]

**Мөхтәрәмә Фатыйма-Фәридә ханым хакында сабыйлык хатирәсе**

Кыйммәтле анамыз Фатыйма-Фәридә ханымның вафатына февраль 17сендә ике ел тулу мөнәсәбәте илә, аның илә кичерергә муафыйк[66] булындыгым бер кыш әснасендә[67] алдыгым тәэсиратны, мәрхүмәне искә төшерү нияте илә язмакчы булам.

1903нче сәнә иде. Мәскәүдә кызларга махсус тәртипле бер ысул җәдидә мәктәбе булырга түгел, мәктәп исемен алырлык бер ысул кадим мәктәбе дә юк иде. Бинаән галәйһи[68], мәрхүм атам үзе галим кеше булмаса да, аңлырак кешеләрнең тәүсыясы[69] илә мине тәртипле бер мәктәптә укытырга тели иде. Шуның өчен Мәскәүдән шактый гына ерак булса да, дахили[70] Русия мөселманнары арасында тәртипле вә низамлы уку-укытуы илә таныла башлаган Бубый мәдрәсәсенә укырга илтмәкче булды, һәм шул көз сентябрь ахырларында юлга чыктык. Казанга кадәр машина илә барып, аннан пароходка утырып, Бубыйга китәчәк идек. Ләкин Казанга барып җитүемез илә соңга калганымызны аңладык. Казаннан китәчәк соңгы пароход фәкать Чистайга кадәр генә барачак имеш. Инде нишләргә? Әгәр кире кайтсак, табигый, икемез өчен дә бик күңелсез булачак. Бинаән галәйһи, әтием мине соңгы пароход илә Чистайга илтеп, үзенең якын танышларыннан Мортаза әфәнде Ваһаповларда (Фатыйма-Фәридә ханымның атасы) урынлаштырып, Чистайның ибтидаи[71] мәктәбендә укырга калдырып китте. 8–9 яшьлек бер баланың беренче мәртәбә ата кочагыннан аерылып, чит бер шәһәрдә белмәгән халыклар арасында калуы, табигый, бала өчен бик авыр бер хәлдер.

Ләкин шулай булса да, Фатыйма-Фәридә ханымның җылы, йомшак сүзләре, шәфкатьле мөгамәләсе миңа ул авырлыкларны сиздермәде. Беренче көннән үк ул миңа татлы сүзләре илә мәктәп вә балаларны сөйләп, укырга кызыктыра башлады. Һәм шулай мин ул кышны Чистайның яңа гына ачылып, тәртипкә куелып өлгермәгән ысул җәдидә мәктәбендә укырга башладым. Мәктәптә укылмаган бәгъзе дәресләрне мәрхүмә мөхтәрәмә Фатыйма-Фәридә ханымнан укый идем. Бер генә кыш булса да сабыйлык хәятемнең иң мәсгуд[72] көннәрене Фатыйма-Фәридә ханым янында кичерүгә муафыйк булдым. Мәрхүмә гыйлемгә мәфтүн[73], гайрәтле бер кыз булдыгында, кызларга махсус мөкәммәл[74] гыйлем йортлары улмадыгы заманда бөйлә үзенең ты-

---

[65] Хәдичә Дунаева – мөгаллимә, Мәскәү сәүдәгәре Хаҗи Дунаев кызы.
[66] Муафыйк – кирәкле, яраклы.
[67] Әсна – вакыт, ара.
[68] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шул нигездә, шул сәбәпле.
[69] Тәүсыя – киңәш бирү, васыять итү.
[70] Дахили – эчке.
[71] Ибтидаи – башлангыч.
[72] Мәсгуд – бәхетле, игелекле.
[73] Мәфтүн – мөкиббән киткән, бик нык яраткан.
[74] Мөкәммәл – тәмамланган, камилләшкән.

рышлыгы саясендә[75] бик күп нәрсә үгрәтергә муафыйк булган иде. Фатыйма-Фәридә ханымның йөрәгендә яшьтән үк үз халкына булган самими мәхәббәте, тута вә сеңелләренә кулдан килгән кадәр ярдәм итү фикере бик нык урнашканга, миңа да аннан бик истифадә итәргә[76] тугры килде. Ул һәрвакыт минем фикеремне ачарга, миңа укуны сөйдерергә тырыша иде. Ул вакыт ысул җәдидә мәктәпләрендә дә тарих, җәгърафия фәне укытылмаганлыктан, мөхтәрәмә Фатыйма ханым мине үзенең теләве илә төрекчә бер әсәрдән җәгърафия, тарих дәресе укытты.

Фатыйма-Фәридә ханымның иң яратып укыган әсәрләре төрекчә әсәрләр иде. Ул төрекчә әсәрләрне шулкадәр яратып, чын күңелдән укый иде ки, аш һәм чәй янында бу илә аны сөекле китапларыннан аеру хәйле[77] авыр була иде. Хосусән[78] ул рамазан аенда бөтен кешене яткырып, үзе сөекле китаплары илә сәхәрне каршылый иде. Әлхасыйль[79], Фатыйма-Фәридә ханымның иң сохбәт[80] куйган ноктасы уку иде. Ул бай булса да, башка кызлар кеби кием вә модага, алтын-көмешкә һич исе китми. Мөхтәрәм атасы сәүдә эшләре илә чит шәһәргә баручы кеше булса да, Фатыйма-Фәридә ханым үзе өчен һичбер вакыт зиннәт-фәлән китерүне эстәми, бәлки: «Миңа шул китапларны ал», – дия, атасына төрле заказлар бирә иде.

Ул вакыт татар хатын-кызлары өйдә китапханә булдыруны бөйлә ни идекен белмәдекләре хәлендә, Фатыйма-Фәридә ханым бик мөкәммәл китапханәгә малик иде. Фатыйма-Фәридә ханымның китапханәсендә төрекчә, русча, гарәпчә бик күп әсәрләр бар иде. Ул Истанбулдан журнал, гәзитә ала иде. Фатыйма-Фәридә ханым илә кышны бик күңелле генә уздырып торган заманда, күп кешеләрне мәгънәви аналарыннан аера торган май ае да килеп җитте. Миңа да Фатыйма-Фәридә ханымнан аерылырга тугры килде. Ул мине актык минутка кадәр үз сеңеле кеби мәгънәви тәрбиясендә булындырды. Мине пароходка озаткан чагында шул сүзләрне сөйләде: «Һәмширәм![81] Сиңа бу уку илә генә калырга ярамыйдыр. Моннан соң тәхсилеңне[82] монтазам[83] сурәттә дәвам иттерергә тырыш. Сәгадәт[84] гыйлемдә генәдер. Хосусән татар дөньясының якты көнгә чыгуы, бәхетле хәяткә ия булулары хатын-кызларны тәрбия итүгә баглыдыр. Бер милләтнең тәрәккыйсе[85] тәртипле гаиләләр аркылы гына буладыр. Гаилә эчендә иң зур эш күрүче – хатындыр. Менә без шул вазыйфаны үтәргә

[75] Сая – күләгә, ышык.
[76] Истифадә итү – файдалану, тоту.
[77] Хәйле – байтак.
[78] Хосусән – бигрәк тә, аеруча.
[79] Әлхасыйль – озын сүзнең кыскасы, нәтиҗәдә.
[80] Сохбәт – иптәшлек, юлдашлык.
[81] Һәмширә – кыз кардәш, кыз туган.
[82] Тәхсил – гыйлем алу.
[83] Монтазам – тәртипкә салынган, тәртипле, рәтле.
[84] Сәгадәт – бәхет, рәхәтлек.
[85] Тәрәккый – алга китү, прогресс.

хәзерләнергә тиеш. Тәгътыйль[86] чагында да укырга тырыш. Мин сиңа һәрвакыт хат язармын», – диеп мине озатты. Табигый, мин дә күз яшьләремне агыза-агыза, кыш буе бергә торып, күп ярдәмнәрен күргән кыйммәтле анамнан аерылдым.

Җәйне Мәскәүдә, икенче көзне исә, иртәрәк юлга чыгып, Бубый мәдрәсәсенә таба юнәлдем. Бубыйда вакытта да Фатыйма-Фәридә ханымнан хатлар алып, укып кайтышлый һәр ел Чистайга кереп, күрешеп чыга идем. 1906 сәнәдә Фатыйма-Фәридә ханымнан алдыгым бер мәктүбтә[87]: атасы Бөгелмә өязе Кәрәкәшле[88] карьясендә йир алып, эш ачканлыгын вә җәй көне булу мөнәсәбәте илә Фатыйма-Фәридә ханым да шунда барып истирахәт кылачагын[89] бәян кыйлган иде.

Фатыйма-Фәридә ханым гомумән табигатьне бик ярата вә аның күренешләре илә рухлана иде. Кәрәкәшлегә барып тора башлагач та язган бер мәктүбендә: «Күккә йитәргә якын зөмред[90] кеби яшь-яшел таулары, башкорт сәхрәсе дия лотафәте[91] илә мәшһүр кырлары, очсыз-кырыйсыз урманнары, тау башыннан ап-ак күбекләрне сачеп аккан шәляләле[92] ермаклары, хисапсыз җиләк-җимешләре, берсеннән-берсе латыйф[93], берсеннән-берсе гүзәл чәчәкләре һич вә җәһлән тәгъриф[94] мөмкин булачак түгелдер. Шулкадәр гүзәл манзаралар арасында башына ак киез эшләпә киеп, зәңгәргә кызыл, сарыга яшел кушып теккән күлмәк кигән башкорт кызларының йөгерә-йөгерә җиләк җыюлары тугрысыны бик кыйммәтдар бер картина манзарасы тәшкил итәдер...», – диеп язулары Фатыйма ханымның табигатьне ни дәрәҗә ятратканлыгыны белдерсә кирәк. Ул елларда татар кызларына чын тәрбия бирердәй мәктәпләрнең юклыгы, татар хатын-кызларының һәркем тарафыннан изелеп, үз хокукларын үзләре химая кыла[95] алмаулары Фатыйма-Фәридә ханымны ачындыра вә ничек кенә булса да аларны шул әсарәтләреннән[96] куптарып, якты дөньяга чыгарырга тырыша иде. Шул ният илә Фатыйма-Фәридә ханым Кәрәкәшлегә җәй көне истирахәт өчен генә диеп барган булса да, андагы башкорт кызларының гыйлем-мәгърифәттән тәмам хәбәрсез булулары вә шул көнгә кадәр тәртипле бер мәктәп күрмәүләре Фатыйма-Фәридә ханымны шунда калырга мәҗбүр итә. Ул үзенең туып-үскән йирен, Чистай шәһәрен, русча укуын, вакытлы гына калдырып булса да, гыйлемгә сусаган тута вә сеңелләренә үз мәсърафы[97] илә беренче мәктәп ача, аларны

[86] Тәгътыйль – каникул, ял.
[87] Мәктүб – хат, язылган әйбер.
[88] Кәрәкәшле – Татарстанның хәзерге Ютазы районындагы авыл.
[89] Истирахәт кылу – ял итү, эштән бушап тору.
[90] Зөмред – зөбәрҗәт.
[91] Лотафәт – гүзәллек.
[92] Шәлялә – шарлавык.
[93] Латыйф – матур.
[94] Тәгъриф – таныту, сөйләп бирү, аңлату.
[95] Химая кылу – яклау, саклау.
[96] Әсарәт – әсирлек.
[97] Мәсъраф – тотылган акча, чыгым.

заманга муафыйк рәвештә тәрбия итәргә башлый. Бөтен көчен сарыф кылып, аларның фикерләрен ачарга тырыша. Берничә истигъдадлыракларын[98] аерым хәзерләп, мөгаллимә булыр өчен Бубый мәдрәсәсенә йибәрә.

Хәзерге көндә мөхтәрәмә Фатыйма-Фәридә ханымның исемен мәңгегә калдыру өчен салына башлаган «Мәдрәсәи Фатыйма»да (бу кыш өчен булган мәүкыйт[99] шөгъбәсендә[100]) Фатыйма-Фәридә ханымнан тәрбия алып, соңра Бубый мәдрәсәсен тәмам иткән Зәйтүнә ханым мөгаллимәлек итә. Ике йөзгә якын кыз укыйдыр.

Мөхтәрәмә Фатыйма-Фәридә ханымның матбугатка чыгып, моннан соңгы милләтенә булган җитди хезмәтләре татар дөньясына, вә бигрәк тә хатын-кыз галәменә, бик ачык мәгълүм булганлыктан, бу тугрыда артык язмыйча үземнең сабыйлык хатирәтемне шуның илә тәмам итәм.

И, кыйммәтле анамыз, Фатыйма-Фәридә ханым! Бүген синең гали[101] рухыңның тынычлыгы өчен бөтен татар дөньясы нечкә күңелләреннән сиңа догалар кылалар, мәктәпләрдә синең тәрҗемәи хәлләреңне сөйләп, мәгъзүм балалар да гөнаһсыз күңелләреннән чыккан пакъ догаларын гарешләргә[102] йибәрәләр.

Шат бул, әй кыйммәтле ана! Аллаһы синең гали рухыңны гали җәннәттә кыйлсын.

Мәскәү.

*«Сөембикә», 1916, №9, б.166–169.*

### Мәрхүмә Камилә ханым Мозаффария

Яшь һәм каләме белән матбугатка иштиракъ иткән[103] мөгаллимәләремездән Камилә ханым Мозаффариянең июнь ахырларында гына вафат хәбәрене тәәссеф[104] белә укыдык. Мәрхүмә дәртле истигъдадлымөгаллимәләремездән иде. Ул «Сөембикә» журналы чыга башлаган көннән алып, каләме белән «Сөембикә»гә иштиракъ итте. Аның «Сөембикә»гә язган мәкаләләре арасында «Әйдәңез бергә», «Аңгы-миңге вакытта бер тавыш», «Төркестанда», «Төркестанда татар хатыннары» дигән мәкаләләре бар. «Ил» гәзитәсендә дә байтак кына язгалады.

Камилә башлап Уфаның өченче мәхәллә кызлар мәктәбендә укыган, андан соң русча вә мөселманчаны хосусый сурәттә укып, мәгълүматене арттырган. Уфада бер биш ел кадәр мөгаллимәлек итеп тә торган.

Камилә ханым Уфаның Нигъмәтҗан мирза Моратов кызыдыр. 1909 елда Зариф әфәнде Мозаффарга кияүгә чыгып, гаилә хәятенә кергәннән соңында,

---

[98] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.
[99] Мәүкыйт – билгеләнгән вакыт, срок.
[100] Шөгъбә – бүлем, бүлек.
[101] Гали – бай.
[102] Гареш – күк.
[103] Иштиракь итү – уртак булу, катнашу.
[104] Тәәссеф – үкенү, кайгыру.

рәфыйкы[105] илә икесе берлектә мөгаллимлек итмәктә иделәр. Соңгы ике елда рәфыйкы илә берлектә Төркестанда булындылар. Камилә ханым уку яшенә йитү белән, барлык гомерен уку-укыту юлына сарыф кылган вә шул юлда корбан булган мөгаллимәләремездән бередер.

Мәрхүмә таза бәдәнле, матур чәһрәле[106], рухлы, сүзгә оста улдыкча тәрбияле вә назик[107] ханым иде.

Ун ел кадәр мөгаллимәлек итү, никадәр таза бәдәнле һәм рухлы булса да, Камилә ханымны йончыткан вә авырткан иде. Төркестанга баргач, үзендә авыру хис итә башлаган, вә шуның өстенә Төркестан һавасы да килешмәгән булырга кирәк, быел докторларның кушуы буенча дәвалану өчен Уфага кайткан иде. Ләкин авыруыннан дәвалана алмыйча, Уфага кайтканына ай ярым дигәндә, дөньядан күчте. Вафаты вакытында һәнүз[108] егерме алты яшендә генә булып, үзеннән соң биш яшьләрендә бер угылы калды. Каләме белән матбугатка иштиракъ иткән, мөкаддәс укыту юлында корбан булган бу яшь мөгаллимәнең Аллаһы Тәгалә каберен тыныч итеп, рәфыйкы илә сабый угылына сабыр җәмил[109] бирсен!

*«Сөембикә», 1916, № 18, б.316.*

***«Кайгыручы»***

**Мәрхүмә Сара Гыйсмәт**

Күкпикте[110] шәһәренең ахунды Давыд әфәнде Габдуллинның кәримәсе[111] Сара Гыйсмәт туташ август сигезендә дүшәмбе көн вафат итте. Мәрхүмә мөселманча «Бубый» кызлар мәдрәсәсен мөкәммәл[112] сурәттә тәмам итеп кайткач, хосусый рәвештә хәзерләнеп, кызлар гимназиясенең алтынчы классына кабул ителгән иде.

15–16 яшенә кадәр мөселманча укыган һәм татарлар арасында, татарлар белән укмашып үскән бер татар кызының гимназиянең алтынчы классына рус кызлары дәрәҗәсенә барып йитүе, ягъни үзен алтынчы класска кабул иттерүе өчен хосусый сурәттә никадәр тырышу лязем булгандыр.

Сара туташ гыйлемгә мәхәббәт мәсләгендә[113] алган, тоткан юлында сәбатлылык[114], шуның өстендә гаять дәрәҗәдә тырышчанлыгы белән башкалардан аерым торадыр иде.

Ул шул арада татар әдәбиятыннан аерылмады. Татар әдәбиятын сөйде, татар әдәбияты аңа бик якын иде. Аның каршында иң мөхтәрәм, иң кадерле

---

[105] Рәфыйк – иптәш, тормыш иптәше.
[106] Чәһрә – йөз, төс, кыяфәт.
[107] Назик – гүзәл, нәфис.
[108] Һәнүз – әле дә, һаман.
[109] Җәмил – матур, күркәм.
[110] Күкпикте – Казахстандагы Кокпекты шәһәре.
[111] Кәримә – кызы, кыз бала.
[112] Мөкәммәл – тәмамланган, камилләшкән.
[113] Мәсләк – дөньяга караш.
[114] Сәбат – чыдамлылык, ныклык, тотнаклылык.

нәрсә татары, татарының теле, татарының әдәбияты иде. «Сөембикә» журналына, «Вакыт», «Тормыш» гәзитәләренә һәрвакыт язып торды. Гимназияне тәмам иткәч, гали курсларга китеп, укуын дәвам иттерү ниятендә иде. Ләкин фәләк[115] аның бу теләкләрен бозды, җимерде. Аның артык дәрәҗә тырышуы сәбәпле, күкрәгенә чир алып, бу дөньяны куярга мәҗбүр булды. Ул чәчәк иде, вакытсыз шиңде.

Без аның өчен кайгырабыз, рухына тынычлык телибез, ата-ана вә туганнарына тәгъзия итәмез[116].

*«Сөембикә», 1916, №22, б.371–372.*

***Ш.Ә.***[117]

## Мәшһүр хатыннардан Суфия бикә һәм анасы

Безнең татар эчендә аз гына санлы морза дигән бер төркем халык яшәп киләдер. Табигый, морза булгач, аларның хокуклары башкалардан – сәүдәгәр, крестьяннардан өстенрәк һәм киңрәк; гади татарлар файдалана алмаган имтиязлар[118] белән алар файдаланалар.



Суфия Җантурина
*(«Сөембикә», 1916, №24)*

Морзаларның хокукта иркенрәк, сыйныф җәһәтендә дә өстәрәк булулары үзләрен түбәнге халыклардан аерырга сәбәп булган, һәм алар шулай иткәннәр дә, динен, милләтен нык саклап килә һәм үзенең гореф-гадәтенә ябышып торган татар, башкортларга кушылмаганнар, чөнки морзалар күбрәк рус тәрбиясенең тәэсиренә бирелеп киткәннәр, фәкыйрь татар дөньясыннан канәгатьләнерлек бернәрсә дә таба алмаганга, яисә табарга да тырышмаганга, барлык әйбер, барлык фазыйләт[119] рус галәменнән эзләнгән. Шулай итеп, морзаларда тик рәсми мөселманлык кына калган. Милли хис, милли тойгы, милли хәятнең әсәре дә калмаган, чөнки гореф-гадәт руска иярелгән; тәрбия рус мәктәпләрендә генә бирелгән; туган тел татарча урынына русча сөйләнгән. Халисән: морзалар төркеме башка татарлардан бап-башка булып яшәгәннәр; алар әле һаман да кыйшаймыйча шул эз белән баралар; ләкин аларның араларыннан татарны сөйгәннәре, татарны үз күргәннәре, шуның истикъбале[120]

[115] Фәләк – язмыш, тәкъдир.
[116] Тәгъзия итү – үлгән кешенең якыннарын юату, күңел юату.
[117] Шәһид Әхмәдиевнең тәхәллүсе.
[118] Имтияз – башкалардан аерылып тору, өстен булу, өстенлек.
[119] Фазыйләт – артыклык, яхшы холыклылык, яхшы сыйфатлылык.
[120] Истикъбаль – киләчәк, булачак.

өчен тырышып йөргәннәре дә күбәеп барадыр. Мәсәлән, морзалыкның мәркәзе булган Уфаны кулга алыйк. Монда мөкаддәс татар теле тәхкыйрь ителеп[121], фәрештә кеби татар балаларын «папа», «мама» белән авызландырган морза гаиләләре булган кебек, телен, җырын, моңын, милләтен сөйгән гаиләләр дә аз түгел. Менә боларның дөньяга килүләренә, икенче төрле әйткәндә, татарлык хисен калын катлаулар астында калдырган морзаларның яңа дөньяга чыгып эш күрә башлауларына сәбәп тә минем язачак сатыйрларымнан[122] күренер.

Мин бу урында иң кибари[123] гаиләдән һәм зур фамилиядән чыгып, үзенең татарына күп эшләр күрсәткән һәм ярдәмнәр иткән Суфия бикә һәм анасы Хәдичә бикә хакында берничә сүз әйтергә уйлыйм.

Хәдичә бикә Арслангали кызы Тәфкилева-Морадова; ул үзенең ир балаларын рус мәктәбендә, әмма кызларын анда йибәрмичә, өйдә генә тәрбия кыла; мөмкин кадәр балаларына дини, милли хис бирергә тырышкан. Суфия бикә Җантурина аның кызы. Суфия Җантурина[124] 1874нче елда дөньяга килеп, ул яшь чагында әтрафлы рәвештә өй тәрбиясе күргән. Ул Сәлимгәрәй әфәнде Җантуринга кияүгә чыгуы белән, үзенең татарына ничек карашын күрсәтә башлаган; һәм татар дөньясында татарның ихтыяҗатын[125] күз алдына китереп эшләргә тотынган. Менә аның эшләгән эшләреннән, әйткән сүзләреннән аңарда морзалыкның сүэ[126] истигъмаль[127] ителмәгәнен күрермез.

Суфия бикәгә Килем авылындагы бик зур бер имение мирас булып калган. Ул һәм шул имениесендә гомер иткән; бу вакыт Килем авылында бер мәктәп булса да, иске тәртип белән укытылганга һәм башында бер мулла гына торганга, укытуның рәте һәркайдагы шикелле бонда да булмаган.

Суфия бикә шушыны, шушы татарының рәтсез мәктәбене, рәтсез укытуларны, рәтсез укытып, балаларның гомерләре әрәм булуын күреп, шуны ислах кылу чарасына керешкән. Шушыларны тәртипкә салу, ысул җәдид кертеп, яхшы мөгаллимнәр кую өчен хосусый рәвештә үзе Бубый мәктәбенә барып, андагы әхвәлне, андагы укытуларны, андагы тәртипләрне карап тикшереп кайткан. Аларның мәктәпләреннән үрнәк алып, үз мәктәбенә дә әһлиятле[128] мөгаллимнәр китергән; мәктәпнең бөтен мәсарифын[129] үз өстенә алган; башта ул мәктәптә 40–50 генә кадәр шәкерт булса да, бара торгач, елдан-ел артып, елдан-ел аның сәмәрәсе[130] күбрәк күренеп, елдан-ел халык аның кадерен белеп, хәзерге көндә шул ирләр мәктәбендә 5 мөгаллим укыта; аларны сабак «Мәдрәсәи Галия» мөгаллиме идарә кыла.

---

[121] Тәхкыйрь ителү – хурлау, мыскыл итү.

[122] Сатыйр – юл.

[123] Кибари – аристократик, аксөяк.

[124] Ир ягыннан Җантурина, ата ягыннан Сәетгәрәй (Сәлимгәрәй мөфтинең агасы) кызы Тәфкилева (Астөшермә мәкалә авторы тарафыннан бирелгән).

[125] Ихтыяҗат – ихтыяҗлар.

[126] Сүэ – начарлык, явызлык.

[127] Истигъмаль – урынсыз куллану, явыз ният белән куллану.

[128] Әһлият – бер эшне белү, аны булдыра алу.

[129] Мәсариф – тотылган акчалар, чыгымнар.

[130] Сәмәрә – нәтиҗә.

Суфия бикә ирләр мәктәбе белән генә канәгатьләнмәгән; ул үзенең туганнары, балалары булган кызларны да исенә алган. Ул вакытта кызларны укыту модада булмаса да, ул кызларга махсус мәктәп ачкан. Хәзерге көндә ул мәктәптә 3 мөгаллимә укытып торалар; шул мәктәпләр өчен яхшы һәм төзек итеп биналар салдырып калдырган һәм шуларны яшәтер өчен үзе сәламәт вакытта 200 дисәтинә йир вакыф иткән.

(Хәзерге көндә ул йирләрнең вакыфы, корылган мәктәпләрне тәрбиягә йитмиләр; аның йитмәгән йиренә варислары ярдәм итеп, мәктәпләрне һаман төзек һәм тәртипле рәвештә дәвам иттерәләр.)

Суфия бикәнең авылын һәм әтрафын агарту юлында күрсәткән һиммәтләреннән[131] тагы да шушыларны санап күрсәтергә була:

Ул халыкта һөнәр тарату чараларына керешкән. Ләкин максатына гына ирешә алмаган. Ул сугуханә (ткацкая мастерская) ачкан; шул мастерскаяны ачар өчен иң әүвәл үзе Петроградка барып, шул эшне өйрәнү, белү нияте белән 2–3 ай кадәр курсларга йөргән. Аннан соң авылына кайтып, эшкә керешкән. Ләкин ул эш 2–3 ел гына дәвам итә алган. Чөнки Суфия бикә авыруга мөбталя булып[132], ул мастерскойның артыннан йөрүче булмау сәбәпле, сүнәргә-бетәргә мәҗбүр булган. Шулай итеп, Суфия бикәнең бу идеясе тик чәчелеп кенә, яфрак та ярмый, чәчәк тә атмыйча калган.

Суфия бикә авыл халкына да бик зур ярдәмнәрдә булган. Аның ярдәме ачлык елларда бигрәк тә сизелә. Ачлык елларында ул мохтаҗларга һәртөрле яктан җиңен сызганып, билен буып булышлыклар күрсәткән. Шуның өчен дә ул үз әтрафында онытылмаслык, бетмәслек сагынмалык калдырып киткән. Аны хәзерге көндә дә үз әтрафы, үз белгәннәре – һәркем сагына, һәркем яхшылык белән яд итәдер[133].

Суфия бикәнең иң зур хезмәтләреннән «Мәдрәсәи Галия»гә иштиракын[134] санарга кирәк: бервакыт, 1906–1907 елларда Мисырдан, Гарәбстаннан кайткан яхшы гына мәгълүматлы берничә мөгаллим Уфада начар фатирларда, мәсҗет астларында күп кенә шәкерт укытып торалар иде; алар тырышып, яхшы укытулары белән бик тиз вакыт эчендә йөзләрчә шәкертләрнең дикъкатен җәлеп иттеләр. Хәлфәләрнең иҗтиһадларын[135] һәм шәкертләрнең зур бинага ихтыяҗларын күреп, Суфия бикә башлап «Мәдрәсәи Галия»не салу фикеренә төшкән һәм аңа ярдәмгә Уфаның иң зур байларыннан Садретдин әфәнде Назыйров кул сузган. Шулай итеп, аларның икесе 40 меңлек 3 катлы таш бинаны мәйданга тудырдылар. Бонда вак-төяк ярдәмнәрдән 4–5 мең кадәресе генә булып, калган бөек сумма шушы Суфия бикә белән Садретдин әфәнденекедер. Хәзерге көндә алар салдырган «Мәдрәсәи Галия» Русия эчендәге мәдрәсәләрнең иң алдынгысы булып яши. Һәр елны әллә никадәр тирән генә мәгълүматлы һәм фикерле муллалар,

[131] Һиммәт – тырышлык.
[132] Мөбталя булу – дучар булып.
[133] Яд итү – хәтергә китерү, искә төшерү.
[134] Иштиракь – уртак булу, катнашу.
[135] Иҗтиһад – тырышлык, теләк.

мөгалимнәр йитештереп тора. Менә шушы октябрь эчендә аларның иштиракы белән бар булган шул «Мәдрәсәи Галия»нең ун еллык бәйрәмен, ун еллык юбилеен үтәргә хәзерләнәләр. Әлбәттә, бу юбилей вакытында Суфия бикәнең дә исеме яд ителми калмаячактыр.

Хәзерге көндә бөтен Русия татарларының дикъкатьләрен җәлеп иткән һәм яхшы гына эшләр дә эшләп торган Уфадагы «Ханымнар җәмгыяте»нең мәйданга килүенә дә беренче башлап йөрүчеләрдән Суфия бикә булмыштыр. Бу санаган хезмәтләре тик күзгә күренгәннәре генә; юкса Суфия бикәнең мәгънәви һәм матди ярдәм иткән йирләрен без әле алай гына, бу кыска гына мәкаләмездә санап бетерә алмыймыз.

Инде Суфия бикәнең балалар тәрбиясе хакындагы карашын да бераз гына булса да әйтеп китик. Ул кыз балаларын рус мәктәпләренә бирмәгән. Чөнки ул рус мәктәпләрендә кыз балаларга йитәрлек тәрбияне тапмаган. Ул: «Рус мәктәпләре безнең кызларга өмет иткән тәрбияне бирә алмыйлар», – ди икән. Шуның өчен дә балаларына бик яхшылап өй тәрбиясе бирергә тырышкан; үзе кайда барса да, балаларын яныннан калдырмаган. Аның милләтенә булган мәхәббәте искиткеч дәрәҗәдә икәнен шуның белән дә истидлял итәргә[136] була. Ул үзе мөкәммәл дәрәҗәдә русча сөйләшә белә торып, үз гаиләсендә башка телдә сөйләтмәгән. Үз гаиләләре арасында башка телдә сөйләшүче морза гаиләләренә һәрвакытта бик кәефе китә торган булган, ул һәрвакыт татарларның хәленнән, наданлыкларыннан зарланып сөйли икән.

Суфия бикәнең актык мәртәбә Истанбулга киткәндә, Уфа вокзалында озата төшкән угылының кулын тотып: «Балам! Син яшьсең әле, яшәрсең, мин бәлки сине күрә алмам. Минем сиңа иң актык сүзем, изге киңәшем шул: син татар угылы татар бул, татарыңны сөй, татарыңны онытма!» Менә аның актык мәртәбә күрешүендә угылына әйткән шушы сүзләре генә дә милләтен ничек сөйгәнен, ул милләте өчен ничек ачынганын бик ачык күрсәтә торган дәлилдер.

Суфия бикә яшьли генә авыруга мөбталя булып, шул авырудан котыла алмыйча, дөньядан китүе сәбәпле, аның бик күп башланган эшләре чын нигезгә коруда үз идеясенә ирешә алмады. Ул 1902нче елны кызамык (корь) авыруына мөбталя булып, иң элек Австриягә китте, андан соң берничә мәртәбә Кырымга барып кайтты; Кырымнан кайтып, үз илендә берничә кыш торып, янә Кавказга китте; анда баргач, авыруы тәмам көчәеп китте дә, табибларның мәслихәтләре белән Төркиянең Мәрмәрә диңгезендә Папасатага барып, анда бер кыш торып, җәен тагын иленә кайтты. Илендә бер җәй торгач, көз көне янә Төркиягә үзе алып калдырган һәм җәй буе эшләнгән Истанбулдагы йортына китте. Анда барып, озак та тормады, вафат булды һәм Бөек атауда[137] дәфен[138] кылынды.

*«Сөембикә», 1916, №23, б.377–381.*

---

[136] Истидлял итү – нәтиҗә чыгару.
[137] Атау – утрау, Төркия.
[138] Дәфен – күмелү.

# VIII БҮЛЕК

# «ИГАНӘ САХИБЛӘРЕНЕҢ ҺӘРКАЮСЫНА САМИМ КАЛЕБТӘН ТӘШӘККЕР КЫЛЫП, РӘХМӘТ УКЫЙБЫЗ»

Хатын-кыз мәгарифенә иганә күрсәткән шәхесләр, җәмгыятьләр эшчәнлеге

### Мөселман җәмгыяте

Оренбургта рәсми сурәттә ачылмыш мөселман җәмгыятенең 1 нче октябрьдә якшәмбе көн көндез сәгать 3 тә икенче гомуми җыелышы улды. Йөздән артыграк членнар бар иде. Совет (идарә) җәмәгатькә: 1) рәис могавине[1] – Капкаев, секретарьга могавине – Мишкин, казначыга могавине Баязидовның сайланганлыкларыны һәм 2) совет җәмгыятенең 23 сентябрь, 15 октябрь, 12 ноябрь, 1нче декабрьдә вә гомуми җыелышның 1нче октябрь, 29нчы октябрь, 26нчы ноябрь, 31 декабрьдә тәгаен ителгәнлегене игълан итте. [...] 3) Форштадта фәкыйрь кызларны укытыр өчен кызлар мәдрәсәсе ачу хакында вә шәһәрдә 20 фәкыйрь баланы укыту хакындагы докладлар җәмгыять тарафыннан кабул ителеп, Форштадт кызлар мәктәбенә Шакир Мөлеков попечитель сайланды.

Мәктәп эшләрене карау өчен советка могавин уларак алты кешедән гыйбарәт бер комиссия сайладылар. Мәктәп эшләрене карап идарә кылу шул комиссиягә тапшырылды.[…]

Габдулла әфәнде Ибраһимов Банный Озерода кызлар мәктәбе ачарга тәклиф итеп[2], һәр айда үзе 10 сум биреп торырга вәгъдә итте. Калганыны җәмгыять бирергә булды. Кызлар мәктәбе ачарга вә ир балалар укытырга үз тарафларыннан һиммәт итеп[3] иганә бирүчеләр һәм һәр айда биреп торырга вәгъдә бирүчеләр булды. Бонларның исемнәре тәфсилле киләчәк номерларымызда бәян улыныр.[…]

*«Вакыт», 1906, 3 октябрь.*

### Хисапнамә

1907нче елда март числосында Бишбалтада кыз балаларга махсус монтазам[4] ибтидаи[5] мәктәп ачу өчен бер җәмгыять тәэсис ителмеш[6] иде. Мәк-

---

[1] Могавин – ярдәмче, булышчы.

[2] Тәклиф итү – боеру, әмер итү.

[3] Һиммәт итү – теләк белдерү.

[4] Монтазам – тәртипле.

[5] Ибтидаи – башлангыч.

[6] Тәэсис ителү – төзелү, оештырылу.

тәптә голүм диниядән башка, ханымнарның мәгыйшәте өчен беренче мәртәбәдә зарур булган кисү-тегү, бәйләү һәм аш пешерү кеби һөнәрләр дә өйрәтеләчәк улдыгыннан, мондый мәктәпне дәвам кылдырмак өчен, әлбәттә, күбрәк акчага мохтаҗ улынадыр.

Безнең Бишбалтада, монаң мәсарифыны[7] тәэмин итәрлек байлар улмадыгыннан, мәктәпне иганә җыеп ачуга карар бирелгән иде. Шул карар буенча эшкә шөругъ ителеп[8], иганә җыеп ачу өчен талонлы дәфтәрләр басылып, түбәндәнге исемнәре язылачак кемсәләр[9] иганә җәмгъ кылдылар[10]:

1нче номер дәфтәр белән мин үзем (Сәгадәт Әмирхания) – 37 сум 95 тиен;

2нче – Шаһмулла Шаһҗиһанов – 13 сум 20 тиен;

3нче – мөгаллим Габдрахман Рафиков[11] – 17 сум;

4нче – Зиннәтулла Гатиятуллин – 10 сум;

5нче – Шакирҗан Усейнов – 8 сум 50 тиен;

6нчы – Ибнеәмин Морзин – 2 сум 5 тиен;

7нче – Габдулла Усейнов – 9 сум 20 тиен;

8нче –Закирҗан Усейнов – 5 сум;

9нчы – Габдрахман Исхаков – 5 сум 45 тиен.

Җәмгыятьнең мөәссисләре[12] тарафыннан иганә ителде – 55 сум.

Җәмгысе – 163 сум 35 тиен.

Бу акчадан иганә дәфтәрләре бастырыр кеби урыннарга 4 сум 50 тиен сарыф ителде. 158 сум 75 тиен акча быел 1нче гыйнварында җәмгыятьнең вакытлы хәзинәдары Габдрахман Исхаковка бирелде. Мәктәпнең сәрмаясен[13] арттырмак өчен, Габдрахман әфәнде бу акчаны үз суммасы белән бәрабәр сәүдәдә йөртеп, килгән файдасы илә ошбу ел беренче июньдә җәмгыять әгъзаларына кайтармак улды. Акча йитешмәгәнлек һәм дә башка бәгъзе мәванигъ[14] сәбәпле, үткән көн бу мәктәпне ачуга муафыйк булмадык, Ходай насыйп итсә, киләчәк көзгә ачмак булабыз. Бу ел 55 кыз бала мулла Габдулла Әмирханов[15] йортында аерым ханәдә, мөгаллимнәр җәмгыяте карар биргән «дәстүр әт-тәгълим» буенча Сәгадәт Әмирхания, Рабига Рафикова, Сорур Усейнова тарафыннан тәгълим итәләр.

Боның өчен мәктәпкә дип җыелган акчадан бер тиен дә сарыф ителмидер. Бу мәктәбемезне ачмак өчен дәхый[16] иганәгә ихтыяҗымызны игълан итеп,

---

[7] Мәсариф – чыгым.

[8] Шөругъ итү – керешү, башлап җибәрү.

[9] Кемсә – кеше, зат.

[10] Җәмгъ кылу – җыю.

[11] Габдрахман Рафиков (1873–1954) – Бишбалтада рус-татар мәктәбе директоры.

[12] Мөәссис – оештыручы.

[13] Сәрмая – акча.

[14] Мәванигъ – тоткарлаучы, эшнең үтәлүенә каршы килгән сәбәпләр.

[15] Габдулла Әмирханов (1871–1933) – Бишбалта мулласы, С. Әмирханиянең ире.

[16] Дәхый – янә, тагын да.

иганә итүче әфәнде вә ханымнарга, милләт аналары улачак кыз таләбәләр исеменнән рәхмәт вә афәриннәр укыймын.

*«Әл-Ислах», 1907, 2 март.*

## [Тоз-Түбә сәүдәгәреннән Галимҗан Хәбибулла угылы]

Тоз-Түбә сәүдәгәреннән Галимҗан Хәбибулла угылы вафат булмыш. Үзенең баласы булмаганлыктан, йортын кызлар мәктәбе файдасына улмак өчен, җәмгыять хәйрия исеменә васыять иткән имеш. Гүзәл эш.

*«Әл-Ислах», 1907, 9 март.*

## [22нче октябрьдә...]

22нче октябрьдә җәмгыяте хәйрия мәктәбендә Казан байларыннан Гайнетдин әфәнде Мөэминов барып, кыз балалар мәктәбендә укый торган фәкыйрь кыз балаларга күлмәклек вә ир балаларга 50 данә кәләпүш вә 8 данә бишмәт зәкяттән[17] бирде.

*«Әл-Ислах», 1907, 20 октябрь.*

## [1898нче елдан бирле...]

1898нче елдан бирле Чистайда дәвам итмәктә булган кызлар мәктәбендә быел 115 кыз бала укымакта икәне һәм бу мөкаддәс[18] эшкә бер тарафтан да иганәнең юклыгын, иганәгә бик мохтаҗ идекен һәм Чистай мещаннарының һәрвакыт мәктәп-мәдрәсә эшләренә каршы төшүләреннән зарланып, идарәмезгә язмакталар.

*«Әл-Ислах», 1907, 5 ноябрь.*

## Мөслимәләр җәмгыяте

Уфа шәһәрендә әһле ислам[19] хатыннары үз араларында бер җәмгыять хәйрия тәэсис итмәк[20] фикерендә улдыклары «Вакыт»та бер кач мәртәбәләр язылмыш иде. Уфада улан мохбиремезнең яздыгына күрә, мөслимәләр арасында улан ошбу фикер бу көннәрдә юлга салынмыштыр, шаять аз көннәр соңында тәмам булыр, вә башка мөслимәләргә дә күчергеч йола булыр. Мохбиремез бу тугрыда дияр:

«Кичен яз көне кызлар мәктәпләрендә улан имтиханнарда Уфада бикәләр (мөслимәләр) хазир улмышлар[21] иде. Шунда җыелмыш хатыннарны вә кызларның имтихан бирдекләрене күреп, гайрәткә килделәр вә хәмиять[22] исла-

---

[17] Зәкят – ислам буенча хәлле кешеләр, сәүдәгәрләр кеременең 40 тан бер өлеше күләмендә түләргә тиешле еллык налог.

[18] Мөкаддәс – изге, иң мөһим.

[19] Әһле ислам – мөселманнар.

[20] Тәэсис итү – төзү, оештыру.

[21] Хазир булу – катнашу.

[22] Хәмиять – башкаларның зарар китерүеннән саклау.

мияләре кузгалып, мөслимәләр җәмгыяте тәэсис итәргә карар биреп таралдылар. Бондан соң һәрвакыт мәҗлесләрдә ошбу җәмгыять мәсьәләсене мөзакәрә иттеләр[23] вә ниһаять бер низамнамә[24] ләйхасы[25] тәртип иттереп, губернаторга тапшырдылар. Шәмди[26] бу көннәрдә низамнамәне губернатор тасдыйк итте[27] вә җәмгыять ачарга рөхсәт бирде. Бераз көннәр соң җәмгыять ачылып, үзенең хезмәтенә керешәчәктер. Җәмгыятьнең мөәссәсләре[28] Маһипәрвазбикә Шаһгалиева, Мәрьямбикә Тимербулат кызы Солтанова, Суфиябикә Җантуринадыр. Низамнамә төземәк тугрысында бонларга Сәлимгәрәй солтан Җантурин, Искәндәр бәк Солтанов, Сабир хәзрәт Хәсәнов ярдәм иттеләр. Низамнамә төркичәгә тәрҗемә ителеп, ошбу көндә язылып таралачактыр.» […]

*«Вакыт», 1908, 5 гыйнвар.*

***Заһирә Байчурина***[29]

**[Мөхәррир әфәнде!]**

Мөхәррир әфәнде!

Гыйффәтле Мәрьямбикә Солтанова бу ел Башкирский приютта укучы мөселман кызларына дин дәресләре өчен кирәк китапларны алып бирде. Хәзерендә 48 кыз, дин вә әхлак исламиягә гаид нәрсәләрне бик шатланышып укыйлар вә игътибарга алып, бу илә иганә кылуы өчен Мәрьямбикәгә чын күңелләреннән рәхмәт вә дога итәләр.

Уфада Башкирский приютта дин мөгаллимәсе Заһирә Байчурина.

*«Вакыт», 1908, 7 февраль.*

**[Хвалын өязе Мастак карьясеннән язалар:...]**

Хвалын өязе Мастак карьясеннән[30] язалар:

«Өч мең җан кадәр халкы улан авылымызда кызлар укытыр өчен һичбер рәтле мәктәп юкка күрә, чәчәк кеби яшь балаларымызның гомерләре уку вә укыту эшеннән хәбәрсез абыстайлар вә карчыклар тирәсендә йөремәктә иде.

Хәмид[31] улсын, авылымызның сәүдәгәрләреннән Сөләйман Сүнчәләев бер мөгаллимә китертеп, ике сәнәдән бирле кызларымызны ысулы саутия вә тәртип илә укытмактадыр. Әлбәттә, һәр йирдә улдыгы кеби, бездә дә боңа каршы

[23] Мөзакәрә итү – фикер алышу.
[24] Низамнамә – кагыйдәләр җыентыгы.
[25] Ләйха – проект.
[26] Шәмди – хәзер, хәзер үк.
[27] Тасдыйк – раслау.
[28] Мөәссәс – башлап нигез салучы, коручы.
[29] Заһирә Гали кызы Байчурина (1890–1977) – мөгаллимә, шагыйрә, 1907–1908 елларда Уфа һәм Пермь шәһәрләре мәктәпләрендә укыта.
[30] Мастак – Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районына карый.
[31] Хәмид – мактаулы, мактарга яраклы.

килүчеләр күп булды. Ләкин хаклыкның ахырда өсткә чыгачагыны белеп, гайрәт ияләре бу сүзләргә колак бирмәенчә, үз эшләрендә дәвам иттеләр.

Инде, авылымызда 4 бүлмәдән гыйбарәт бер таш бина сатылачак улдыгыннан, Сөләйман әфәнде кызлар мәктәбе өчен шуны 800 сумга сатып алып, бер йөз сумын үзе вә 200 сумны бер ханым иганә иттеләр. Боны мәктәп формасында эшләтеп тәмам иттерергә дәхыйдә 1,500 сум кадәр акча хаҗәт улдыгыннан, кызлар тәрбиясенең әһәмиятене аңлаган хәйрат сахибләремез[32] иганәттә булышырлар дия өмет итәмез. Чөнки Сөләйман әфәнде 3–4 меңле бер авыл бае улдыгыннан, бу эшкә үзенең генә көче йитмәячәктер».

*«Вакыт», 1908, 9 февраль.*

## [Берничә елдан бирле...]

Берничә елдан бирле фәкыйрь кыз балалар укытып килмәктә улган мөгаллимә Мөслимә ханым мөселман җәмгыяте исеменнән укытырга теләп һәм шуннан үзенә мәгаиш[33] тәгаен итүене үтенеп, мәзкүр[34] җәмгыятькә мөрәҗәгать иткән.

*«Вакыт», 1909, 13 август.*

***Фатыйма Аблакова***

## Акмулла

Таибә ханымның ижтиһады[35] илә 4 елдан бирле дәвам итмәктә булган кызлар мәктәбе өчен махсус бина салырга керешелде. Бу эш артыннан Нурмөхәммәд бай Зәбиров бик тырышып йөридер. Кызлар мәдрәсәсенә иганә уларак, Баймөхәммәд Кошчыголов 100 сум, Хөсәен Бигишев 1000 сум, Шакир Бурнашев зәүҗәсе[36] 1000 вә башкалар хәленчә биргәннәр, мәдрәсә 7–8 меңнәргә төшеп, мәсарифының[37] бер кыйсемен[38] Нурмөхәммәд бай үзе күтәрәчәктер.

*«Вакыт», 1910, 22 май.*

## Кызлар мәктәбе

Тамбов губернасы Юнә[39] карьясендә[40] кызлар мәктәбе өчен Гомәр Агишев илә Латыйф Тинаевның бишәр меңнән ун мең сум сәдака кылдыгыны идарәмезгә хәбәр бирделәр. Мөгаллимәләрә тормак өчен дә Гомәр әфәнде

[32] Хәйрат сахибе – изге эшләр кылучы, химая кылучы.
[33] Мәгаиш – тормыш, яшәү өчен кирәкле нәрсәләр, акча.
[34] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.
[35] Ижтиһад – тырышлык, теләк.
[36] Зәүҗә – кәләш (ирнең хатыны).
[37] Мәсариф – тотылган акча, чыгым.
[38] Кыйсем – өлеш.
[39] Юнә авылы – Пенза өлкәсендә.
[40] Карья – авыл.

үзенең бер йортыны һибә иткән[41] икән. 2–3 сәнә мөкаддәмдә[42] Юнәдә шундаен бер эш эшләнәчәге гәзитәләрдә язылып кичкән иде. Бонысы шаять фәгалиятькә[43] чыгар иде.

*«Вакыт», 1910, 28 август.*

***Гобәйдулла Рәдүди***

**Тәшәккер[44]**

Мөгаллимә Багбостан ханым мәктәбендәге «Ханымнар кыйраәтханәсе»-нә[45] үз нәшриятләреннән берәр нөсхә[46] һәдия[47] иткән «Вакыт», «Кәримов, Хөсәенов вә ширкәсе», «Мәгариф китапханәсе» фирмаларына тәшәккер итәмез.

Мәктәп мөдире вә назыйры[48] Гобәйдулла Рәдүди.

*«Вакыт», 1910, 23 декабрь.*

***Фатыйма-Фәридә***

**Хатыннар һәм җәмгыятьләр**

Оренбургта гыйлемгә мәхәббәтле ханымнарның мохтаҗлыкта калган мөселман хатын-кызларына матди, мәгънәви ярдәм итү, кыз балаларга мәктәпләр ачу вә башка шундый эшләр илә мөселман хатыннарының тәрәккыйларына[49] хезмәт өчен «Оренбург мөселман хатыннарының җәмгыяте» исеме илә бер җәмгыять ачканнарыны могътәбәр «Вакыт» газетасының соңгы номерында укып бик шатландым. Әлхәмдүлилләһи, безнең хатын-кызларымыз да җәмгыятьнең әһәмиятене аңлап, үз туганнарына ярдәм касды[50] илә җәмгыятьләр ача башладылар. Оренбург мөселман хатын-кызларыны бу хәерле эшләре илә тәбрик итеп, изге максатларына ирешүләрене Аллаһы Тәгаләдән сорыйм. Башка йирдәге кардәшләренә дә күчергеч булсалар иде. Иң әүвәл җәмгыять ачып, хатыннарның да күлмәк, калфак гына сөйләүче булмаенча, ирләр кеби гомуми эшләрдә җәмгыять булып эш күрергә истигъдадлары[51] булганлыкларыны Уфа ханымнары үзләре җәмгыятьләр ачып эш илә исбат иткәннәр иде. Менә хәзер Оренбург ханымнары бу хәерле эшкә башладылар. Бөтен татарның мәркәзе саналган Казан ханымнары гына, ни эшләптер, бу вакытка кадәр йоклыйлар. Анда һәм зыялы, һәм бай хатыннар

---

[41] Һибә итү – бүләк (итеп бирү), буш бирү.
[42] Мөкаддәм – элек, әүвәл.
[43] Фәгалиять – эшчәнлек.
[44] Тәшәккер – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.
[45] Кыйраәтханә – уку залы, уку өе.
[46] Нөсхә – данә, экземпляр.
[47] Һәдия – бүләк.
[48] Назыйр – мөдир, караучы.
[49] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[50] Касд – ният, максат.
[51] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.

күп улса да, берләшеп эш күрерлек җәмгыятьләренең булмавы Казан хатыннарына бик зур кимчелектер. Өмет итәмез ки, Казан үзе картрак булса да, үзенең башка кардәшләреннән күчергеч алырга хурланмас. Тиз арада Казанда да шундый җәмгыять ачылганыны, Казан ханымнарының берләшеп эш күргәннәрен ишетеп, шатланырмыз диеп өмет итәм. Хөрмәтле пәйгамбәрнең «Йәд Аллаһ галә әл-җәмәгате»[52] дигән сүзенең әһәмиятене аңларга бик күптән вакыт йитте инде. Үз арамызда гына да һәрвакыт сөйләнә торган «Ил төкерсә, күл булыр» бабаларымызның мәкале дә безнең колакларымызга җәмгыятьнең кирәклегене тыгып торадыр. Бу заманда һәркем үз файдасыннан артык гомуми файдасыны кайгыртып, «беремез барымыз өчен, барымыз беремез өчен" кагыйдәсе мәйдан алмактадыр. Башка милләтнең хатыннары әллә никадәр җәмгыятьләр ачып эш күрәләр. Томскида да лютеран хатыннарының үзләренә махсус җәмгыять хәйрияләре бар. Ел саен ничек булса да җәмгыятьләрене тәрәккый иттерергә, күбрәк файдалы эшләр эшләргә тырышалар. Кирәк Томскида, кирәк башка шәһәрләрдә безнең мөселман хатыннары шул лютераннардан күбрәк булсалар да, һаман йоклыйлар. Әгәр безнең Томскида да хатыннар берләшеп, бер җәмгыять ясап, иттифак[53] илә эш күрергә теләсәләр, кулларыннан килмәс идемени? Үземез тырышмаенча, авызымызга китереп салганны көтсәк, байтак вакыт үтәргә тугры килер. Җәмгыять тәэсис итеп[54] иттифак илә эш күрүчеләр бәхетледерләр.

*«Сибирия», 1912, 27 май.*

***Габдулла Биги***[55]

## Мөгаллим вә мөгаллимәләргә ярдәм җәмгыяте

### I

Мөгаллим вә мөгаллимәләр тереклеге кебек төпсез вә ышанычсыз тереклек тагын булмас инде. Үзенең тереклегенә чынлап таянган вә чынлап ышанган мөгаллим бик аз табылыр. Мөгаллим вә мөгаллимәләр бер җирдә кышны уздырсалар, икенчесен кайда уздырачакларын бер дә белмиләр. Бу ел монда, икенче ел бәлки әллә кайда; бөтенләй уйламаган бер җирдә.

Ачы тузан, каты тавыш эчендә кыш буе арып вә хәлсезләнеп чыккач, җәйне бер төрле истирахәт[56] вә тәгътыйль[57] белән үткәрәсе урында, киләсе кыш өчен урын кайгыртырга, иң йончыган чакларда шуны уйлап каты хәсрәт чигәргә, шул урын тугрысында әллә кемнәргә мөрәҗәгать итәргә, ялынырга-

[52] «Аллаһ кулы (ярдәме) җәмәгать белән» мәгънәсендә.

[53] Иттифак – бер сүздә булу, берләшеп эшләү.

[54] Тәэсис итү – төзелү, оешу.

[55] Габдулла Хәсән улы Мостакаев (Габдулла Биги, 1890 – ?) – 1913 елда Ташкенттагы татар мәктәбе мөгаллиме, 1920 елдан – Ташкент төрек-татар мәгариф институты директоры.

[56] Истирахәт – ял.

[57] Тәгътыйль – каникул.

ялварырга, әллә кемнәр каршысында үзләренең хөрмәтләрен югалту, намусларын кимсетергә вә тагын белмим әллә нәрсәләр эшләргә мәҗбүр булалар. Аларның тавышларына колак салучы, ут йоткан көннәрендә ярдәм кулы сузучы, өсләренә шәфкать канатын ябучы һич бер җәмгыять вә һич бер мөәссәсә[58] юк. Алар беркемгә дә ышана алмыйлар вә бер нәрсәгә дә таяна алмыйлар. Булдыклы вә дәртле генә мөгаллимнәр әллә нинди хәйләләр, яшерен коткылар вә бозык фикерләр аркасында урыннарыннан мәхрүм ителәләр. Халык надан булганга, кайсыбер явыз, вөҗдансыз кешеләрнең коткыларына ияреп, фикерләренә алданып, яхшы гына мөгаллимәләргә зарар итәләр, рухларын сүндерәләр, бер төрле кырыштырып куйган кызганыч тереклеген пыр туздыралар.

Мәгълүматлы вә рәтле генә мөгаллимнәр үзләренең дәрәҗәләренә күрә урын таба алмыйча, начар төшләрдә изеләләр, йончыйлар. Ирекле-ирексез өметләре йомшара, дәртләре басыла, рухлары зәгыйфьләнә вә үз-үзләренә булган ышанычлары да бетә башлый. Күбесе гаилә сәгадәтеннән мәхрүм булып яши, төпсез вә ышанычсыз тереклек эчендә гаилә корырга батырчылык итмиләр. Көннәрнең бераз рәтләнгәнен, тормышның бераз рәтлерәк юлга салынганын, язмышның яктырак йөз күрсәткәнен көтеп, ярым өмет эчендә торалар. Көннәр үтә, гомерләр үтә, алар да, шулай итеп, урталыктан югалып китәләр.

## II

Көннән-көн заманнар үзгәрә, хәлләр башкара, мәдәният көчәя, халык арасында бер төрле уяну, һәр нәрсәгә җитди вә ачык күз белән карау арта; әдәбият дөньясы киткән саен байый вә яңа нәрсәләр белән чубарлана тора...

Безнең мөгаллимнәр вә мөгаллимәләр дә шул үзгәрешләр белән танышырга вә яңа нәрсәләрдән файдаланырга телиләр. Бигрәк тә рус әдәбиятына якынлашырга, андагы чиксез байлыктан өлеш алырга вә шулар аркасында тулмаган җирләрен тутырырга, мәгълүматларын киңәйтергә тырышалар, шуңа юллар эзлиләр. Фәкать моның өчен кайда мөрәҗәгать итәргә, рус телендәге китаплар хакында кемнәрдән киңәш сорарга белми аптырап калалар. Үз белемнәре буенча гына алдырсалар, күп вакытта алданалар. Теләкләренә муафыйк булганнарын таба алмыйлар. Соңыннан күңелләре кайта да, бөтенләй ташлыйлар.

## III

Тереклекне яхшырту вә төплерәк бер юлга салу уе берлән бик күп мөгаллим русча укып, рәсми шәһадәтнамә алырга омтылалар. Кыш көннәрендә күкрәк черетеп тапкан барлы-юклы акчалардан шул юлга борчып, ачлы-туклы торып булса да, шул теләкләренә җитәргә, мәгыйшәтләрен әсаслырак[59] рәвештә тәэмин итәргә тырышалар. Фәкать бу тугрыда да аларга юл күрсәтүчеләр булмаганга, бик күп кыенлыкларга очрыйлар, коры үзләре

[58] Мөәссәсә – оешма.
[59] Әсаслы – нигезле, төпле.

генә эшнең рәтен таба алмыйлар. Бер кечкенә генә рус каласында торып, ялгыз укыр өчен иң азында аена 25 сумнар акча кирәк була. Бу кадәр акчаны татар мөгаллимнәре кайдан алсыннар? Билгеле, шундый уңайсызлыкларны күреп, ярты юлда тукталып калалар.

Менә шундый күңелсез хәлләр безнең мөгаллим вә мөгаллимәләр арасында һәрвакыт булып тора, алар шундый авырлыклар вә өметсезлекләр эчендә бәргәләнәләр, кыйналалар. Ләкин берәү дә аларга ярдәм итәргә ашыкмый вә шул хәлләреннән коткару өчен юллар эзләп маташмый...

Минем белүемчә, хәзерге көндә иң әһәмиятле вә иң кирәкле мөәссәсәләремезнең берсе – «Мөгаллим вә мөгаллимәләргә ярдәм җәмгыяте» ачу булырга тиешле. Оренбургтагы «Укучыларга ярдәм җәмгыяте»нең[60] нинди зур эшләр эшләп торганлыгы вә уку юлындагы дәртле яшьләремезнең рухланулары илә сәбәп булганлыгы һәркемнең күз алдында. Мөгаллим вә мөгаллимәләр өчен дә менә шундый бер җәмгыять ачылса, бик күп файда китерәчәге шөбһәсездер. Тормышларын рәткә сала алмыйча аптырап йөргән мөгаллим вә мөгаллимәләргә ярдәм итәр, чын дәрт вә чын ихлас берлән хезмәт итүләренә сәбәп булыр иде. Һәрбер эшләрендә аларга тугры юл күрсәтер, сораган сөальләренә җаваплар бирер, алар өчен иң кирәкле вә иң файдалы рус китапларының исемнәрен белдерер, хакларын язар, русча укырга теләгән мөгаллимнәр өчен бер билгеле шәһәрдә җәйге курслар ачар, шуңа тәҗрибәле рус учительләре чакырыр, укырга килүчеләргә бер йирдә урын хәзерләр вә җиңеллек белән укылуына булышлык итәр иде...

Мондый бер җәмгыятьне ачып, безгә ярдәм күрсәтергә теләүчеләр табылмаса, без, мөгаллим вә мөгаллимәләр, үземез бу эшне башларга, шул хакта фикерләр йөртергә вә шуның чараларын эзләргә тиешлемез. Казан, Уфа, Оренбург шикелле шәһәрләрнең берсендә җәмгыять ачарга, шуңа әгъзалар җыярга, шул җәмгыятьтә даими хезмәт итеп торучы кешеләр сайларга, хокукларымызны саклар өчен юллар хәзерләргә, бер-беремезгә ярдәмнәр итәргә, кара көннәремезнең рәтләнүләренә сәбәпләр эзләргә вә шуңа керешергә кирәк иде.

Яңа Үргәнеч.

*«Тормыш», 1914, 9 март.*

***Зәйнәб Кормашева***

**Акмулладан**

Безем Акмулла шәһәрендә 1909нчы елда һиммәтле[61]байларымызның иганәсе илә бик яхшы, хифзыссыйхәткә[62] муафыйк[63] итеп, 8 меңнәргә төшере-

---

[60] Сүз Оренбугта 1912 елның май аенда төзелгән «Оренбург мөселман укучыларына ярдәм җәмгыяте» турында бара. Оештыручылары Закир Рәмиев, Фатыйх Кәрими, Габдрахман Фәхретдинов, Борхан Шәрәф һ.б.

[61] Һиммәт – теләккә омтылу, тырышлык.

[62] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау һәм аның юллары, гигиена.

[63] Муафыйк – яраклы, туры килгән.

леп, гүзәл кызлар мәктәбе бина кылынды[64]. Мәктәп дүрт бүлмәле, биш сыйныфлы улып, ике мөгаллимә тарафыннан идарә кылына, уку ике елдан бирле дәвам итәдер. Шул мәктәпкә, ярминкәгә сәүдәгә килгән троицкилы Хәсәнҗан әфәнде Габбасовның иҗтиһады саясендә[65], бәгъзе яшьләремезнең иганәсе илә, кызларга махсус кыйраәтханә[66] тәшкил ителгән иде. Үткән сәнәдә, Мәүлид бәйрәме мөнәсәбәте илә, бәйрәмгә җыелган ханымнардан китапханә файдасына 80 сумнарга якын акча җыелды. Вә шул акчага кызларга муафыйк китаплар алынып куелды. Ләкин бу сәнәдә китапханәмезгә бер тиенлек китап кушылмады, халкымыз китапханәне тәкъдир итә алмадыкларыннан, идарә тарафыннан да ярдәм ителми. Шулай итеп, китапханәмез артмый вә кимеми тора. Ләкин кызлар бер укыган китапларны кат-кат укудан туеп, китапханәдә яңа китап булмауга бик эчләре поша. Алдагы Мәүлид бәйрәмендә үткән сәнәдәге кеби дәхый дә хөрмәтле ханымнарның һиммәтен көтеп торалар. Инде Хода ни язгандыр.

Мәктәмебездә 100 дән артык кыз укый, ләкин йөздән артык балаларны укыту ике мөгаллимәгә агыррак улдыгыннан, һиммәтле байларымыз боны игътибарга алып, киләчәк сәнәгә тагы да яхшырак мөгаллимә алдырсалар, яхшы булыр иде. Ләкин мөгаллимә алдырган тәкъдирдә, Петропавелдагы Дәүләткилдиевлар мөгаллимәсе кеби, соңыннан куып йибәрерлек улмаенча, карабрак алдырсалар, гүзәл булыр иде.

Безем бу заманда яхшы мөгаллимәләр табуы бик читен, хосусән[67], хатын-кызларымыз өчен мәктәп юк. Соңгы заманнарда хатын-кызларымыз өчен Бубый мәктәпләре кеби тәртипле мәктәпләр улса да, ул да, безем бәхетсезлегемезгә каршы, күпкә бармады...

Ирләр өчен дарелмөгаллиминнәр улмаса да, яхшымы, яманмы, искедән дәвам итеп килгән зур-зур мәдрәсәләр бар. Аның өстенә, алар мәгълүматны мәктәптән чыккач та арттыралар: төрле шәһәрләргә йөреп, вә төрле фикерле, мәгълүматлы кешеләр берлән таныша, вә төрле җәмгыятьләргә йөреп, аннан да файда алалар. Бер йиргә җыелсалар, уку вә укыту хакында сөйләшәләр.

Ә безем хатын-кызлар хәленә килсәк, бичараларның хәлләре тәгъриф[68] мөмкин булмаган дәрәҗәдә кыенлыктадыр. Дөньяда торудан бар максатларымыз ашау, эчү вә кыйммәтле киемнәр киюдән генә гыйбарәт. Бер мәҗлескә җыелсак, арамызда укыту хакында телгә дә алмыймыз, милләткә файдалы сүзләр агызымызга да кереп чыкмый. Әгәр дә арамыздан берәремез мондый сүзләр сүләмәгә башласа, хатын-кызга андый мәсьәлә нигә кирәк, дип көлешәләр. Әмма күлмәк мәсьәләсенә килсәк, аның беренчелеген аламыз – тәәссеф[69] безем хәлемез!

---

[64] Бина кылыну – нигез салыну.

[65] Иҗтиһады саясендә – тырышлыгы күләгәсендә.

[66] Кыйраәтханә – китапханә, уку залы, уку өе.

[67] Хосусән – бигрәк тә, аеруча.

[68] Тәгъриф – белдерү, аңлату.

[69] Тәәссеф – үкенү, кайгыру; үкенечле.

Безем хатын-кызларга уйгану хисе кайчан керер икән! 57нче номер «Сибирия»дә Сания Гыйффәт ханымның Уфа ханымнары хакында язган мәкаләсене күреп, безнең дә хатын-кызларымызга уйгану фикере керә икән, дип мәэюс булган[70] калебемне[71] бераз юаттым. Ләкин Уфа шул безем шәһәрдән 2000 чакрым еракта!

Акмуллада мөгаллимә: Зәйнәб Кормашева.

*«Сибирия», 1913, 13 гыйнвар.*

## [Мөслимәләр җәмгыяте...]

Гыйнвар 13ндә Оренбург мөслимәләр җәмгыятенең гомуми җыелышы булып, рәисәлеккә янә бер елга Фатыйма ханым Адамова сайланмыштыр.

Бу җыелышның хәзердә әгъзалары йөздән арткан. Җәмгыять кассасына кергән әгъзалык вә иганә акчалары 1600 сумга йитәдер. Җәмгыятькә күбрәк биргән кешеләр ошбулар икән: Ширинбану ханым Хөсәенова – 150 сум биргән; Гәүһәр ханым Рәмиева, Фатыйма ханым Яушева (Троицк), Әшрәф ханым Яушева (Троицк), Хәдичә ханым Хөсәенова, Мәрьям ханым Хөсәенова, Рауза ханым Хөсәенова, Зәйнәб ханым Рәмиева, Әсма ханым Рәмиева, Диләфрүз туташ Рәмиева, Алмазкамал ханым Хөсәенова, Мәхфүзә ханым Хөсәенова – һәркаюсы 50 шәр сум биргәннәр. Акчадан башка, «Тегүкисү мәктәбе» өчен кирәк булган әсбап илә иганә итүчеләр дә күптер.

*«Вакыт», 1913, 16 гыйнвар.*

***Мөнәвәрә Нугаева***

## Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!

Минем түбәндә язылмыш берничә сәтыр[72] сүзләремне гәзитәңезнең бер почмагына дәреҗ итүеңезне[73] үтенәм.

Казан кебек мөселман мәркәзе булган бер шәһәрдә мөслимәләрнең җәмгыять ачып, эш күргәзә башлауларын күптән бирле дүрт күз берлә көтәдер идек, хәмед[74] улсын, бүген «Кояш» гәзитәсендә Казанда мөслимәләрнең җәмгыять ачарга теләп йөрдекләрене күрдек, бик мәмнүнә[75] булдык. Казан ханымнарының шундай эшкә башлаулары, энҗеле калфак, модалы күлмәк артыннан йөрүләрен ташлаулары берлә тәбрик итәмез. Җәнаб Хак башлаячак эшләрен вөҗүдкә чыгарып[76], һәрвакыт үзләренә файдалы эшләрне үзләре киңәшеп эшләүләрен дәвам иттерсә иде, дия дога да кылдык.

---

[70] Мәэюс булу– өметсезләнү, өмет өзелү.
[71] Калеб – йөрәк.
[72] Сәтыр – юл, язу юлы.
[73] Дәреҗ итү – теркәү, эченә салу, арага кертү.
[74] Хәмед – шөкер.
[75] Мәмнүн, мәмнүнә – шат.
[76] Вөҗүдкә чыгару – бар итү, барлыкка китерү.

Кырмыскалыда мөгаллимә: Мөнәвәрә Нугаева.

*«Сибирия», 1913, 20 гыйнвар.*

**Оренбург мөслимәләр җәмгыяте**

Җәмгыятьнең хәзердә 130 хакыйкый әгъзалары, 12 гомерлек әгъзалары бар икән. Бердән 50 сум биреп, ошбу ханымнар гомерлек әгъза язылганнар: Гәүһәр Рәмиева, Маһиәсма Рәмиева, Рауза Рәмиева, Мәхбүбҗамал Рәмиева, Әшраф Яушева, Фатыйма Яушева, Ширинбану Хөсәенова, Хәдичәбикә Хөсәенова, Хәдичә бинте Сабит Хөсәенова, Мәрьям Хөсәенова, Гайшә Хөсәенова (Казан), Камәрбану Яушева (Сүзүм).

Бу җәмгыятькә әгъзалык акчаларыннан башка иганә итүчеләр дә күп булган. Ошбу затлар иганә иткәннәр: Ибраһим Дибирдеев – 5 сум; Өммехани Хөсәенова – 10 сум; Габдрахман Хөсәенов – 10 сум; Диләфрүз Рәмиева – 100 сум; Исхак Баишев – 5 сум; Гайшә Акчурина – 100 сум; Камилә ханым – 5 сум; Мәхүбҗамал Рәмиева – 5 сум; Фатыйма Бинияминова – 3 сум; Сабирҗан Мөлеков – 3 сум, Зөбәйдә Мозаффарова – 3 сум; Нәфисә Мөлекова – 3 сум; Роза Арапова – 3 сум; Фәрданә һәм Нурдидә Салиховалар – 3 сум; Йосыф Дибирдеев – 5 сум; Камал Фәтхуллин – 10 сум; Зөләйха Еремеева – 1 сум; Гайнетдин Дибирдеев – 3 сум; Газизә Батракова – 10 сум; Фаизә Актуганова – 1 сум; Н.Рәмиева – 1 сум; Зәйнәб Рәмиева – 1 сум; Шәмсикамал Арапаева – 1 сум; Нәсимә Мостафина – 1 сум; Газизә Чанышева – 1 сум; Әсма Хәсәнова – 1 сум; Мәгъзизә Мозаффарова – 1 сум; Мәрвәр Арапова – 1 сум; Рәшид Рәмиев – 1 сум; Шәрифзадә Дашкина – 1 сум; Хөснижамал Курташева – 1 сум; Хәлимә Палванова – 1 сум; Һаҗәр Ниязбабаева – 1 сум; Касыйм Дәүликамов – 1 сум; Фатыйх Садыйков – 1 сум; Шакир хажи Мөлеков – 1 сум; Гайшә Девятова – 2 сум; Мәргубә Дибирдеева – 5 сум; Гайшә Ширбиева – 2 сум; Сәрби Аширова – 60 тиен; Гайшә Ш. – 3 сум; Фуад Рәмиев – 1 сум; Габдрахман Мусин – 50 тиен; Маһижиһан Дәүликамова – 50 тиен; Таһирә Дәүликамова – 50 тиен; Фатыйма Садыйкова – 50 тиен; Гөлчәһрә Чанышева – 50 тиен; Хәерниса Әхмәтҗанова – 50 тиен; Гайшә Корбангалиева – 50 тиен; намәгълүмә[77] – 50 тиен; Забидә Ситникова – 50 тиен; Таифә Әскәрова – 30 тиен; Өммегөлсем Гыймадетдинова – 30 тиен; Фатыйма Алибабаева – 30 тиен; Әшрәф Бикбулатова – 30 тиен; Мәймүнә Мозаффарова – 30 тиен; Мөхәммәтгали Дашкин – 20 тиен; Рубинштейн – 5 сум; Фатыйма Киникиева – 2 сум; Рабига Мөхәммәдъярова – 2 сум. [...].

«Оренбург мөслимәләр җәмгыяте»нең идарәсе иганә ияләренә һәркаюсына чын күңелдән рәхмәт укыйдыр.

*«Вакыт», 1913, 20 гыйнвар.*

---

[77] Намәгълүмә – билгесез хатын-кыз.

## Мөслимәләр җәмгыятенә иганә

30 гыйнварда шәһәр театрында булган спектакльнең саф файдасыннан любительләр үз кесәләренә төшкән 50 сум акчаны Оренбург мөслимәләр җәмгыятенең «Кисү-тегү мәктәбе»нә иганә итеп, «Вакыт» идарәсенә тапшырдылар.

*«Сибирия», 1913, 10 февраль.*

***Зәйнәб Кормашева***

## [Акмуллада...]

Акмуллада икенче мәхәллә хозурындагы кызлар мәктәбенең көтепханәсенә түбәндә исемнәре язылган ханым вә туташлардан шулкадәр иганә кылдылар:

Бурнашева бер еллык «Тормыш» газетасы,

Мәрьям Маматова бер еллык «Аң» журналы,

Мәрьям Солтанаева бер еллык «Ак юл» журналы,

Гөлсем Гайнетдинова бер еллык «Мәктәп» журналы,

Хәлимә Солтанаева, Зәйнәб Тәңребирдиева, Фатыйма Солтанова, Гөлсем Мирсәгыйдова, Сабира Хикмәтуллина, Сорур Фәхретдинова, Гайшә Рәхмәтуллина, Хәлимә Байбекова туташлар бер еллык «Сөембикә» журналын алып бирделәр.

Зөләйха Урманова 3 сум, Рабига Ишимбаева 1 сум, Хәнифә Исмәгыйлева 50 тиен, Тама иле казакъларыннан Ибҗан (Ибраһим) әфәнде Афаковның васыяте буенча, Хәмзә әфәнде Солтанаев 25 сум акчалата иганә кылдылар. Иганә сахибләренең[78] һәркаюсына самим калебтән[79] тәшәккер кылып, рәхмәт укыйбыз. Казакъның караңгы бер илендә булып та, гыйлемгә сусаган мөслимә кардәшләрен исенә алып, үлгән вакытта күпләргә үрнәк булырлык бер эш калдырган. Ибҗан әфәнденең һиммәтенә[80] аеруча тәшәккер кылынадыр[81]. Мәрхүмнең рухы шат булып, урыны җәннәттә булсын.

Акмулладан мөгаллимә Зәйнәб Кормашева.

*«Вакыт», 1914, 2 апрель.*

## Фатыйма-Фәридә ханым исеменә кызлар мәктәбе ачу мәсьәләсе

Бу ел Русия мөселманнары тәрәккыять дәверенең беренче карлыгачы Фатыйма-Фәридә ханымнан аерылдылар. Фатыйма-Фәридә ханым бик яшьтән җәмгыять хезмәтенә ихлас куйган вә шуның өчен Истанбулларга кадәр китеп, фидакарәнә сурәттә тәхсил күргән[82], иленә кайтып, берничә еллар мө-

---

[78] Сахиб – ия, хуҗа.

[79] Самим калебтән – чын йөрәктән.

[80] Һиммәт – тырышлык.

[81] Тәшәккер кылу – рәхмәт әйтү.

[82] Тәхсил күрү – уку, белем алу.

галлимлек иткәннән соң, гәзитәчелек эшенә керешкән, «Сибирия» вә «Тормыш» гәзитәләрендә даими мөхәррирлек итеп, татар дөньясында беренче җитди гәзитәче татар хатыны һәм дә иң самими вә дәртле бер җәмәгать хадимлеге исемен алган иде. Бик яшькәй вафат итте. Шулай да вафатына кадәр үзенең хезмәтен күрсәтеп китте. Шунлыктан, аның вафаты төрек-татар гәзитәләрендә язылу белән генә калмады, пайтәхет[83] матбугатында да мөһим бер урын алды.

Вафаты мөнәсәбәте илә наменә[84] бер хәерле эш ясап калдыру мәсьәләсе кузгатылды. Кызлар мәктәбе ачу мәсьәләсе мәйданга куелды. Петропавелда Кәримә ханым Ишмөхәммәдова тарафыннан язылган бер мәктүбтә Фатыйма-Фәридә ханымның наменә ачылуы фарыз ителгән бу мәктәп өчен Петропавел ханымнары арасында 95 сум 50 тиен иганә җыелганны белдерә. Тик бу хосуста гәзитәләр ачып бер фикер бәян ителмәдегеннән, бу акчаны кайда куярга белми торганлыклары аңлашыладыр. Төрле урыннарга хат язылып сорасалар да, нинди булса ышанычлы бер урын күрсәтелеп җавап бирелмәгән. Инде гәзитәмез аркылы мөрәҗәгать итеп, бу хакта ачык бер фикер сорый. «Фатыйма-Фәридә ханымның исеменә ачылачагы өмет ителгән мәктәп кайчан ачылачак? Аңа кайда фонд (сырмая) тәэсис ителмәдеме[85]? Ителсә, ул сырмая кайда саклана? Петропавел ханымнарыннан җыелган вә бу көнгә кадәр минем кулымда сакланган 95 сум 50 тиен акчаны кайда бирергә икән?» – диде.

Кәримә ханым Ишмөхәммәдованың иҗтиһад итеп[86], хезмәт вә каләм иясе бер иптәшләренең намен тәэйид итәргә[87] тырышуы вә шул юлда беренче тәшәббес күрсәтүе[88] шаян тәхсиндер[89]. Башкаларга да бондан үрнәк алырга ярый. Менә шул рәвеш һәр йирдә мәрхүмәнең мөхиб[90] вә мөхасләре[91] чыгып һиммәт[92] итсә, бу үз араларыннан бер микъдар акча җыйсалар, ханымнарның җәмәгать хезмәтен тәкъдир итә башлаганлыклары күренер вә бик яхшы бер кызлар мәктәбе мәйданга китерелер иде. Бу мәктәпнең кайда фонд тәэсис ителеп, я ителмәдеге хакында идарәмездә ачык мәгълүмат та юк. Ләкин һәрхәлдә бу эш бер мәйданга куелачагы шөбһәсез. Мәсьәлә кузгатылыр-кузгатылмастан, йөзәр сум иганәләр җыючы булып, ясалмый калса, оят булыр. Вафатына ел тулу мөнәсәбәте илә бу хакта ачык бер фикер бәян ителер. Кайда һәм нинди мәктәп ачу хакында шул вакыт мөнасиб бер карар ясалыр. Аңа кадәр боның өчен җыелган «Нәшре мәгариф» җәмгыятьләренең

---

[83] Пайтәхет – башкала.
[84] Нам – исем.
[85] Тәэсис итү – оештыру, булдыру.
[86] Иҗтиһад итү – тырышлык кую.
[87] Тәэйид итү – беркетү, раслау.
[88] Тәшәббес күрсәтү – инициатива күрсәтү.
[89] Тәхсин – мактаулы эш.
[90] Мөхиб – якын дусты.
[91] Мөхас – күркәм, гүзәл эшләр иясе.
[92] Һиммәт – тырышлык.

кассалары (аерым бер сумма сурәтендә) бирелеп, амәнәткә сакланырга ярыйдыр. Хәзергә бу иганәләрне саклар өчен шуннан башка мөнасиб[93] урын күрсәтә алмыйбыз.

Шуның белән бергә, Фатыйма-Фәридә ханымның якыннары вә яхуд җәмәгать хезмәтендә аркадашлык итүче иптәшләре тарафыннан бер һәйәт я фонд тәшкил ителгән булса, гәзитәләр аркылы белдерүләре матлубдыр[94].

Петропавелда Кәримә Ишмөхәммәдова иҗтиһады илә мәрхүмә Фатыйма-Фәридә ханым исеменә ачылачак кызлар мәктәбенә җыелган иганә сахибләре ошбу ханымнардыр:

Өммегөлсем Моратова, Өммегөлсем Янгуразова, Зарифа Яруллина ханымнар 10ар сум;

Фатыйма Тюменева, Хәдичә Моратова, Гайшә Тюменева, Хәдичә Симакова, Гайшә Максудова ханымнар 5әр сум;

Кәримә Ишмөхәммәдова, Зыяия Яушева, Газизә Бирушева, Сорур Бирушева, Зөһрә Тюменева, Хаҗәр Табиева, Фирүзә, Фатыйма Макрабовалар, Өммегөлсем Шәфиева ханымнар 3әр сум;

Сорур Тюменева, Сабира Ишимбаева, Фатыйма Ишимбаева ханымнар икешәр сум; Сорур Монасыйпова, К. Кәбирова, Әкрәмә Хәлиуллина, Нәгыймә Ермакова, Зөбәйдә Морадова, Фатыйха Акчурина, Гафифә Габделхаликова, Газизә Рахманкулова ханымнар берәр сум, Гафифә Ермакова – 50 тиен.

Барлыгы 95 сум 50 тиен.

*«Вакыт», 1914, 11 декабрь.*

### Багбостан ханым мәктәбенә иганә

Мөгаллимә Багбостан ханым 18 гыйнварда берничә бала аталарын вә могътәбәрләрдән берничә затларны мәктәпкә дәгъвәт итеп[95], мәктәп барышы матди җәһәттән авырлыкта икәнлеген аңлаткач, шул мәҗлестә хазир булган[96] кешеләр мәктәп файдасына үзара 373 сум иганә җыеп бирмешләрдер. Хөсәен хаҗи Хөсәенов 100 сум, бар зат 100 сум, Шәриф әфәнде Габидуллин 50 сум, калганнар төрлесе төрле микъдарда биргәннәр.

*«Вакыт», 1915, 20 гыйнвар.*

### Фатыйма ханым мәктәбе хакында сораучыларга

Мәрхүмә Фатыйма-Фәридә ханым исеменә салыначак мәктәпнең эше кайда барып тукталганын сорап идарәгә хатлар килә. Бу мәктәп файдасына иганә йибәрергә теләгән кешеләр аны кем исеменә йибәрергә кирәклеген

[93] Мөнасиб – яраклы.
[94] Матлуб – таләп ителгән.
[95] Дәгъвәт итү – чакыру, чакырып алу.
[96] Хазир булу – катнашу.

сорыйлар. Менә шул затларга җавап уларак, түбәндәге мәгълүматны бирә алабыз:

Фатыйма-Фәридә ханымның җеназасы укылгач, Кәрәкәшле авылында имам вә мөдәррис Гариф хәзрәт Батыршин өендә бер мәҗлес булган. Шунда «Мәдрәсәи Фатыймия» исемендә бер кызлар мәктәбе салырга карар биргәннәр. Шул мәҗлестә һәм соңыннан бу мәдрәсә файдасына барлыгы 40 сум акча җыелган. Вәгъдә кылынганнары дәхый[97] бер 20 сумлап булган.

Үткән җәй көне мәдрәсәнең планын ясатып алып, аның эшен вөҗүдкә чыгару[98] өчен 15 ләп попечитель сайланган. Ләкин земский начальник 3тән артык попечитель куярга ярамый дип, приговорны кире кайтарган. Халык икенче җыенда попечитель итеп шул авылның имамнарыннан Харрас, Гатиятулла вә Нуретдин хәзрәтләрне сайлаганнар (Эшне башлап йөргән эшлекле Гариф хәзрәт Батыршин бу сайлауда төшеп калган). Бу приговор тасдыйк кылынып[99] килгән. Ләкин эш шунда тукталып тора. Теге өч хәзрәтнең бу юлда һич тырышып күргәнлекләре ишетелми.

Фәкать шунысын да әйтеп узуны бурыч дип беләбез ки, мәдрәсә салырга рөхсәт алу белән генә ул мәдрәсә исеменә рәсми сурәттә иганә җыеп булмый. Аның өчен губернатордан аерым рөхсәт кирәк була. Бу мәктәп өчен башта җыелган акча Харрас хәзрәттә саклана икән. Иганә йибәрергә теләгән затлар Бөгелмәдәге Шакир әфәнде Хәкимов аркылы Харрас хәзрәткә йибәрсәләр ярый. Тик ул акчаның «Мәдрәсәи Фатыймия» файдасына икәнен белдереп язарга кирәк.

*«Тормыш», 1915, 22 гыйнвар.*

**Мөслимәләр җәмгыятенең еллык җыелышы**

26нчы январьда дүшәмбе көндез сәгать бердә Оренбурга мөслимәләр җәмгыятенең еллык гомуми җыелышы булачак.

Каралачак мәсьәләләр:

1) 1915 елга рәисә, секретарь, хәзинәдар, совет әгъзалары вә аларга кандидатлар, тәфтиш комиссиясенә[100] әгъзалар сайлау;

2) Җәмгыять исеменә килгән гаризаларны тикшерү.

Нинди дә сәбәп илә повестка тапшырылмаган әгъзаларның да мәҗлескә килүләре үтенелә. Җәмгыятькә катнашырга теләгән ханымнар булса, ошбу көнне килүләре һәм җәмгыятькә әгъза булып язылулары үтенелә.

Җыелыш Каргалы урамында, Адамова фатирында булачак.

*«Вакыт», 1915, 24 гыйнвар.*

---

[97] Дәхый – янә, тагы, тагын да.

[98] Вөҗүдкә чыгару – бар булу, тормышка ашу.

[99] Тасдыйк кылу – раслау.

[100] Тәфтиш комиссиясе – тикшерү комиссиясе.

## Мөслимәләр җәмгыятенең җыелышы

2нче февраль дүшәмбе көн көндез сәгать 3тә Оренбург мөслимәләр җәмгыятенең гомуми җыелышы булачак. 26нчы гыйнварда җыелышка килүчеләр Оренбургта булган әгъзаларның биштән беренә тулмаган сәбәпле, мәҗлес булмый калган иде. Инде бу җыелыш уставның 28нче маддәсенә бинаән, күпме әгъза килсә дә, рәсми булачактыр.

Ошбу мәҗлес идарә вә тәфтиш әгъзалары сайлау мәҗлесе булганга, әгъза ханымнарның һәркаюсыннан килми калмаулары риҗа кылына[101].

Берәр сәбәп белән повестка ирешмәгән ханымнардан да газетада күрүләре буенча килүләре үтенеләдер.

Җәмгыятьнең секретаре: Зәйнәб Адамова.

*«Вакыт», 1915, 30 гыйнвар.*

## Һиммәт ияләренең игътибарына

Мәфтүһа Габдуллина исемендә атасыз вә анасыз бер ятимә кыз бала идарәбезгә хат язып, һөнәр өйрәнергә ярдәм сорый. Мәктүбендә үзенең тегү эшләренә истигъдад[102] вә һәвәс барлыгын бәян итә. Оренбургтагы Маһирә ханым Гонних мәктәбенә кереп, һөнәр өйрәнерлек ярдәм итүче булса, шунда кереп укыр идем, ди.

Бу мәктәптә уку хакы (бөтен курсы) 40 сум икән. 20–30 сум ярдәм итүче булса, калганын Маһирә ханымның үз хисабыннан ярдәм сыйфаты илә гафу ителәчәге белдерелә.

Халкыбызның һөнәр вә мәгарифкә ихтыяҗының никадәр шиддәтле[103] булганлыгы бәянга мохтаҗ булмаса кирәк. Бу ихтыяҗның үтелүе юлында истигъдад вә һәвәс барлыгы беленгән вакытта, мөселманнарыбыз ярдәм ителеп торырга тиеш. Бу хәвәс хатын-кызлар тарафыннан күрсәтелгән вакытта бигрәк тә игътибарга алынырга тиештер. Югарыда язылган туташның мәктүбтә адресы күрсәтелмәгән. «Вакыт» идарәсенә җибәрелсә, тапшырылганлыгы газетабызда бастырылыр.

*«Вакыт», 1915, 10 февраль.*

***Габделмөхсин Рәшидов***

## Һиммәт ияләренең игътибарына

Ун елдан бирле кыз балалар укытып киләбез. Ләкин өебез бик кечкенә булганлыктан, 80 гә якын кыз баланы укытыр өчен гаять уңгайсызлык итә. Үзебез мәктәп бинасы салырга тырышып карасак та, булмады.

Ниһаять, 10 елдан бирле җыелып килгән көчебезгә 12 аршынлы бура алдык, акрынлап бәгъзе такталар һәм хәзерләдек. Инде шул бинаны яхшылап

---

[101] Риҗа кылыну – соралу, үтенү.

[102] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.

[103] Шиддәтле – көчле, куәтле.

утыртып бетерәсе калды. Һиммәт ияләре[104], игътибарына алып, шуны тәмамлашып бирсәләр яхшы булыр иде. Мәктәбебездә укыган балалар 4 сыйныф ибтидаи, бер сыйныф рөшдигә[105] бүленеп, тәртип илә укыйлар.

Уфа губернасы Бирск өязе Кызылъяр волосте Ямады авылында[106] мөэзин Габделмөхсин Рәшидов.

*«Вакыт», 1915, 11 февраль.*

***Ака***

**«Вазыйфа»чылар вазыйфалары башында булсыннар иде**

Инде аңа бер ел тулды: «Үткән ел Троицкида да могътәбәр[107] байбикәләр, тәрәккыйпәрвәр[108] мөгаллимәләр вә учительницалар арасында бер эшкә тәшәббес[109] хакында яхшы гына бер хәрәкәт барлыгы сизелә иде. Болар кышның озын кичләрендә һәркөн бер йиргә җыелышып, озак-озак киңәшәләр, ни дә булса бер зур эш башларга план иде. Үзләре серләрен чыгармау тугрысында бик сак маташканга, озын колаклар да әсаслы[110] бер хәбәр алып килә алмыйлар иде. Шулай да якында ясалачак Мәүлид кичәсендә Троицк ханымнарына гаять мөһим бер мәсьәлә гарыз итәчәкләре[111] тел төпләреннән аңлышыла иде. Менә бервакыт ни булыр икән дип дүрт күз илә көткән Мәүлид кичәсе килеп йитте. Кичәләре гаять тантаналы сурәттә ясалды. Хатибәләр[112] берсе артыннан икенчесе чыгып, ялкынлы-ялкынлы нотыклар сөйләделәр. Мәҗлеснең ахырына таба бер ханым каршыга чыгып, сөйләнеп үткән нотыкларның хөласаларын[113] җыйганнан соң, Троицкида гомуми мөселман хатыннарының махсус гыйльми, әхлакый «Вазыйфа» намендә[114] бер җәмгыять ачу мәсьәләсен уртага салды. Җәмгыятьнең әһәмиятен вә боны ачудан максат ни икәнен һәркем аңларлык рәвештә ачык итеп сөйләп биргәч, мәҗлес моны бер авыздан кабул итте. Кабул итте генә түгел, бик нык алкышлады. Хәтта моның артыннан йөрүчеләргә рәхмәт тә әйттеләр. Латыйф мәрхүм Яушев бикәсе Хәдичә ханым җәнабләре, әгәр җәмгыять ачылса, үзенең зур таш бинасын җәмгыятькә бирәчәген вәгъдә дә итте. Шулай итеп, рухлар күтәрелеп, хиссиятләр кабарып, җәмгыятьнең програмыны төзер өчен шул мәҗлестә үк бер комиссион дә сайланды. Мәҗлеснең артыннан үк комиссион эшкә дә кереште. Һәркөн кич җыелышып, тырышып эшләүнең

---

[104] Һиммәт ияләре – тырышлык куючылар, ярдәм итүчеләр.
[105] Рөшди – урта.
[106] Ямады авылы – хәзер Башкортстанның Яңавыл районына карый.
[107] Могътәбәр – хөрмәтле, игътибарлы.
[108] Тәрәккыйпәрвәр – алга китү, прогресс яклы кеше.
[109] Тәшәббес – керешү, эшкә тотыру.
[110] Әсас – нигез, база.
[111] Гарыз итү – бер эш яки хәл турында телдән сөйләп яки язып тиешле урынга аңлату, җиткерү.
[112] Хатибә – вәгазь сөйләүче хатын-кыз.
[113] Хөласа – нәтиҗә.
[114] Нам – исем.

нәтиҗәсе буларак, 85 маддәдән[115] гыйбарәт Оренбург губернаторына тәкъдим итеп, тасдыйк иттерер[116] өчен бер програм язарга да муафыйк[117] булдылар.

Төзелгән бу програмнары бервакыт иттифакый[118] гына кулыма төшеп, күздән дә кичергән идем. Програмнарына караганда, җәмгыятьне ачудан максатлары ислам хатыннарына үзләренә хас булган вазыйфаларын белдерү, хокукларын таныту, фикерләрен киңәйтү вә белемлекләрен арттыруга хезмәт итүдер. Бу максатларына ирешү өчен тотачак юлларына да програмнарында ачык язганнар. Ул юллар да шуннан гыйбәрәт: 1) җәмгыять айда бер мәртәбә гомуми Троицк ислам хатыннарына махсус бер мәҗлес ясап, бала тәрбиясе, йорт тота белү, шәригать ноктаи назарыннан[119] ир илә хатынның бер-беренә каршы булган вазыйфалары хакында лекция укытачак. Аш пешерү, тегеш, кул һөнәре хакында һәртөрле мәгълүмат белдерәчәк, дини вә әхлакый вәгазьләр сөйләнәчәк; 2) җәмгыять ислам хатыннарына махсус бер кыйраәтханә[120] ачачак; 3) җәмгыять вакытында укый алмый калган хатыннар өчен зурлар мәктәбе ачачак. Бу мәктәпнең өч шөгъбәсе[121] булып, берсе уку вә язу таныту, икенчесе дин вә әхлак өйрәтү, өченчесе тегү вә кул һөнәрләре белгезү шөгъбәләредер.

Җәмгыятьнең чыгымнары өчен каршылык итеп күргәзгән килерләре дә ошбулар иде: гади әгъзалык хакы, фәхри[122] әгъзаларның бүләкләре, хосусый сәдака вә иганәләр, хатын-кызларның алтын-көмеш зәкятләре, лекцияләрдән җыелган акчалар вә зурлар мәктәбе шәкертләреннән алыначак акчалар.

Програмнарында язылмасалар да, колактан-колакка ишетүемә караганда, җәмгыятьнең бюджеты куәтләнгәнгә кадәр җәмгыять әгъзасы булган мөгаллимәләр зурлар мәктәбендә акчасыз укытачак булганнар икән.

Мин бу програмны укып чыгып, мондагы җәдитне, мондагы гали максатларны күргәч, хәйран калган идем. Әле кичә генә тумачасының итәк сачәген тикшергән, туганкайның муен инҗәсеннең ваклыгын бик зур кимчелеккә санап килгән, аклы ситса күлмәге килендәшенеке кадәр матур тегелмәгәнгә дөньясы җимерелгән төсле булып кайгырган вә янып-көйгән байбикәләрнең төнге сәгать уникегә кадәр йокыларын калдырып, мондый гали задачалар артыннан утыруларына, тәкъдирнең кара язмышы сәбәпле вакытында уку-язу өйрәнә алмый калган туташ вә сеңелләрне кайгыртуларына соң дәрәҗә шатланган идем. Бәгъзе бер югары даирәдә рус дамалары бер җиргә җыелып, төн буена карта уйнап вакыт үткәргән вакытта, безнең байбикәләребезнең төн буена милли вә дини эшләр артыннан утыруларына чын-чынлап шатланган идем. Җанлы курчак дип мөнәсәбәтле-мөнәсәбәтсез кимсеткән, мыскыл

[115] Маддә – пункт, параграф.
[116] Тасдыйк итү – раслау.
[117] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[118] Иттифакый – очраклы, очраклы рәвештә.
[119] Ноктаи назар – караш.
[120] Кыйраәтханә – уку өе, китапханә.
[121] Шөгъбә – бүлем, бүлек.
[122] Фәхри – хөрмәтле, мактаулы.

иткән хатыннарымызга өметем фәүкылгадә[123] арткан иде. Програмнарын укып торырга биргән ханымга програмны кайтарганда бик зур рәхмәтләр укып, бу эшләре вөҗүдкә чыккан[124] тәкъдирдә, ирләрдән бик зур ярдәмнәр күрәчәкләрен сөйләгән идем. Менә моңар быел Мәүлид бәйрәмендә бер ел тулып үтте. Җәмгыять бу көнгә кадәр мәйданга чыкмаганга, минем былтыргы шатлыкларым, өметләрем хәзер төштә күргән хыял шикелле генә булып калды. Эшләнгән, язылган програм ни өчендер губернаторга тәкъдим ителмәде вә ни өчендер җәмгыять ачылмый калды, вә тәмам онытылды.

Үткән ел «Ил» гәзитәсендә бер адәм бу хакта мәгълүмат сораган иде. Ләкин аңа җавап та бирүче булмады. Соңра бу ел бер гәзитә бу җәмгыятьнең ачылмавына бер бай бикәсенең капризы сәбәп булды, дип язды. Ләкин моның бик үк әсаслы[125] бер сәбәп түгеллеге, тик аптыраганнан, үзеңдәге гаепне башкалар өстенә аударырга тырышканнан гына эзләп табылган бер сәбәп идеке әллә кайдан күренеп тора. Юкса мөкаддәс[126] бер эшкә чын иман вә камил мәтанәт[127] илә керешкән бер һәйәтнең батырчылыгы алай бер бай бикәсенең капризына гына түгел, бөтен дөнья аркылы килсә дә, кырылмаячагы табигыйдер. Бинаән галәйһи[128], фәлән байның бикәсе капризлык итте дә, шуңа күрә җәмгыять вөҗүдкә чыкмый калды, дип әйтү мәсьүлиятьне[129] үз өстеңнән төшереп, башка берәүгә йөкләтү өчен генә корылган тәдбирдән[130] башка бер нәрсә дә түгелдер.

Урынсызга баш ватып вакыт үткәрми, «Вазыйфа»чылар үзләренә кирәкле ярдәмчеләр алып, бөек вә мөкаддәс бер максат вә бер әмәл илә башлаган эшләренә тәкрар[131] керешсәләр икән. Әлбәттә, бу хакта ирләрдән теләгән кадәр ярдәм күрәчәкләре шөбһәсездер.

Троицк.

*«Тормыш», 1915, 1 март.*

***«Мохбир»***

**Мәрхүмә Фатыйма-Фәридә ханым исеменә мәктәп**

16нчы февральдә Фатыйма-Фәридә ханымның вафатына ел тулу мөнәсәбәте илә авыл мәктәпләрендә шәкертләргә бер көнгә тәгътыйль[132] бирелде. Шәкертләр Фатыйма-Фәридә ханымның рухына догалар кылдылар.

---

[123] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[124] Вөҗүдкә чыгу – бар булу, тормышка ашу.
[125] Әсаслы – нигезле.
[126] Мөкаддәс – изге, мөһим.
[127] Мәтанәт – ныклылык, чыдамлылык.
[128] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шул нигездә, шул сәбәпле.
[129] Мәсьүлият – җаваплылык.
[130] Тәдбир – эшне ахырын уйлап эшләү, алдан күрү.
[131] Тәкърар – кабат.
[132] Тәгътыйль – каникул.

Үткән ел Кәрәкәшле авылында өч мәхәллә бер көн, авылның урта бер йиренә Фатыйма-Фәридә ханымның исемене мәңгегә калдырмак өчен кызларга махсус мәктәп салырга карар биреп, бу хосуста приговор җыеп, земский начальниктан тасдыйк иттереп[133] алган иделәр. Кулларыннан килгән кадәрле акчалата һәм дә йир бирергә теләүче кешеләрнең барлыгы беленгән иде. Фәкать бу изге эш мөхарәбә[134] сәбәпле бераз тукталып торган иде.

16нчы февральдә Фатыйма-Фәридә ханымның үлүенә ел тулу мөнәсәбәте илә берничә зур мәҗлесләр ясалып, Коръән укылды, догалар кылынды, мәрхүмәнең үткән хезмәтләре хакында нотыклар сөйләнде. Шул ук мәҗлестә әлеге мәктәп эше мөзакәрәгә[135] куелды. Фатыйма-Фәридә ханымның исеменә салыначак кызлар мәктәбенең эше артыннан йөрергә, аның рәсми, гайре рәсми мөгамаләләрене кылырга, төрле тарафтан, төрле затлардан бирелгән вә биреләчәк хосусый иганәләрне кабул итәргә, хөласа[136] бу мәктәп эшене мәйданга чыгарырга шул авылның мәгарифпәрвәр Гариф, Гатиятулла, Нуретдин хәзрәтләрне, мәхәлләнең могътәбәреннән Хаҗиәхмәт, Кашафетдин, Шәйхетдин әфәнделәрне сайладылар. Бу затлар да шатлык белән кабул иттеләр. Кашафетдин әфәнде мәктәп салыр өчен бушлай үзенең йорт урынын вакыф итте. Аның күршесендә Гариф хәзрәт Батыршин да үзенең буш урынын бирергә вәгъдә кылды. Кәрәкәшле авылыннан 1 чакрым ераклыкта бер боярның үзе өчен эшләткән 10 бүлмәле агач бурасы бар иде. Шуны барып карадылар. Бояр мәктәп өчен булганда бик арзан хак илә сатачагыны белдергән. Хәзер шул 1500 сумга төшкән бураны 900 сумга алдылар. Бояр 900 сумның бер йөзен мәктәпкә иганә буларак бирде. Бура бик яхшы агачтан буралган. Мәктәп өчен бик шәп. Задатка итеп бер микъдар акча бирделәр. Калганын билгеле вакытта бирәчәк булдылар. Авыл халкы бик җитди сурәттә эшкә керештеләр. Фәкать бу эш авыл халкының гына хәленнән килмәячәк. Фатыйма-Фәридә ханымның исемен мәңгегә калдырырга теләгән мөхтәрәм әфәнде һәм ханымнарның хосусый сурәттә шул гыйлем йортын тәмам итәр өчен ярдәм итүләре үтенеләдер. Ярдәм итәргә теләүче затлар иганәләрне Бөгелмә каласының могътәбәр сәүдәгәрләребездән Шакир әфәнде Хәкимов җәнабләренә йибәрсәләр, тиешле урынына тапшырылыр иде. Бу эшнең башында торучы затлар халык каршында ышанычлы һәм эшлекле улдыкларыннан, мәктәп эшенең муаффәкыять[137] илә мәйданга килүен өмет итәбез.

Ышанабыз ки, хатын-кызларның хокукларын химая, алар арасына гыйлем, аң тарату хосусында үзен корбан иткән бу ханымның исеменә салыначак мәктәпкә бигрәк тә мөхтәрәмә ханымнар иганә итәргә ашыгырлар.

*«Тормыш», 1915, 8 март.*

---

[133] Тасдыйк итү – раслау.

[134] Мөхарәбә – сугыш.

[135] Мөзакәрә – җыелыш, фикер алышу.

[136] Хөласа – нәтиҗә.

[137] Муаффәкыять – уңыш.

### Ханымнар җәмгыяте

Инсаннар, вәхшиллектән чыгып утраклану өчен, гаилә тәртип итәргә вә, ниһаять, җыелып, бер йирдә яшәргә мәҗбүр булдылар. Аң туып, гыйлем вә мәгариф үсү белән, хәят мәшәкатьләре, хәят көрәшләре көннән-көн арта килеп, фәрдларның[138] берәм-берәм генә дөньяда яшәүләре читенләште, хәтта тора-бара мөмкин дә булмый башлады. Гыйльми вә иҗтимагый эшләрне генә түгел, сәүдә, һөнәр вә сәнаигъ[139] кебек хосусыйрак эшләрне алып барыр өчен дә җәмгыять вә ширкәтләргә ихтыяҗ сизелде. Шул ихтыяҗ нәтиҗәсе уларак, мәдәниятле мәмләкәтләр төрле җәмгыятьләр вә ширкәтләр белән тулды. Бу җәмгыятьләр вә ширкәтләр саясендә[140] мәдәният үсте.

Уяну дәвере башлану белән, без дә шул табигый канун буенча үзебезнең төрле җәмгыятьләргә булган ихтыяҗыбызны хис иттек. Хәят көчләве белән безнең арабызда да төрле җәмгыятьләр мәйданга чыга башлады. Мәдәниятебез үсү белән бу ихтыяҗ куәтләнеп, җәмгыятьләребезнең саны әллә ничә өлеш артачагы да шөбһәсездер.

Мәдәният бер йирдә дә хатын-кыз катнашыннан башка тумый. Хатын-кыз алгы сафтан урын алмаганда, мәдәният җәелеп, ул ныклы бер нигезгә бина ителми. Хатын-кыз уртаклашмаган берәр мәдәният булуын яки булачагын хәтергә дә китерергә ярамый. Иҗтимагый хәятебезгә хатын-кыз уртаклашмасалар, төрле җәмгыятьләр төзеп, милли вә гыйльми эшләребезгә алар ярдәм итешмәсәләр, хәят ярышында тапталып калачагыбызда бер дә шөбһә юк. Иҗтимагъның[141] әлифбасы булган шул хакыйкатьне күздә тотып, хатын-кызларыбызны иҗтимагый хәятебезгә уртаклаштырырга, җәмгыятьләр ачышып бирергә, ачылганнарына ярдәм итәргә һәрберебезгә милли вә дини бер бурычтыр.

Бездә укучы ханым вә туташлар һәм мөгаллимәләрнең саны елдан-ел күбәя бардыгы хәлдә, гомуми вә иҗтимагый, хәтта ханымнарның үзләренә хосусый булган эшләренә катнашучыларның саннары артмый. Без моңар һәм тәгаҗҗеб[142], һәм тәәссеф итәбез[143]. Моңарга мисал итеп «Уфа ханымнары җәмгыяте»н алып карасак, бу хәл бик ачык күренәчәк. Бу җәмгыятьнең 13нче елны 45 әгъзасы булып, 14нче елда бу сан 27гә төшкән.

Бу җәмгыять эшлексез булдыгыннан, әгъзалары кимегән дияргә дә юл юк. Чөнки ханымнар җәмгыяте елдан-ел эшен тәрәккый иттерә[144] бара, байтак ирләр җәмгыятен кызартырлык хәлдә дәвам итә. Бу 27 әгъзаның барысы да җәмгыятьнең эшләренә катнашып эшләшсә, мәсьүлият[145] беркадәр җиңеләер дә иде. Ләкин һәртөрле авырлыклар берничә ханым өстенә ташланган.

[138] Фәрд – аерым зат.
[139] Сәнаигъ – сәнәгать, промышленность.
[140] Саясендә – күләгәсендә.
[141] Иҗтимагъ – җыелу, туплану.
[142] Тәгаҗҗеб итү – гаҗәпләнү, хәйран калу
[143] Тәәссеф итү – үкенү, кайгыру.
[144] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.
[145] Мәсьүлият – җаваплылык.

Мөнәсәбәте чыкканда, берничә сүз әйтеп үтүне үзебезгә бер бурыч дип беләбез: Уфада 25 меңләп мөселман булса, бик аз хисаплаганда, шуның 10 меңе хатын-кызлар. Шөбһәсез, шул ханым вә туташларның 20%ы, икенче төрле әйткәндә ике меңе, укый вә яза белә. 10 мең ханым вә туташ һәм башка шәһәрләргә караганда гыйлем, мәгариф вә аң җәһәтеннән алда торган мөселман мәркәзе «Уфа ханымнар җәмгыяте»нең 27е генә әгъзасы булуы оят. Уфада яшәгән, аның мәктәп, мәдрәсә, Дим вә матур бакчаларыннан файдаланган туташ вә ханымнар, сез 20нче гасырның рухыннан аз да булса куркыгыз! Бергәләшеп-күмәкләшеп эшләргә өйрәнү өчен булса да, Ханымнар җәмгыятенә катнашыгыз! Мәдәният театрга бару, ачык йөрү, сөйләшүдән генә гыйбарәт түгел. Хакыйкый мәдәният иҗтимагый эшләргә катнашып, дин, милләт вә гомумән инсаннарга гыйлемегез, фикерегез, тәнегез яки акчагыз белән ярдәм итешеп, мәдәният агымын агызышуда икәнен исегездән чыгармагыз! Бу өстегезгә йөкләнгән бурыч, шуны үтәшү сезнең вазыйфагыз...

27 әгъзалы «Уфа ханымнар җәмгыяте»нең бер еллык гыйльми вә иҗтимагый эшләре үзенең куәтеннән бик күп дәрәҗәләр югары. Әгәр Уфаның ханымнары да күтәрешсә, бу җәмгыять дәхый[146] дә зур эшләр мәйданга чыгарыр, йитешмәгән күп эшләребезне йитештерер иде.

Бу ел бу җәмгыятьнең зуррак эшләре шулар: 1нче мәхәлләдәге ибтидаи[147] 4, рөшди[148] 4 сыйныфлы мәктәбендә 5 мөгаллимә идарәсендә 156; Вавиловский урамда 3нче мәхәлләдәге 4 ибтидаи, 4 рөшди сыйныфлы мәктәбендә 4 мөгаллимә вә бер учительница идарәсендә 165; Сафрун пристанендә бер мөгаллимә карамагында 43; Давинский урамында бер мөгаллимә тәрбиясендә 46; Казарминский урамда бер мөгаллимә вә бер учительница идарәсендә 45; Старый Уфада Посадский урамда бер мөгаллимә тәрбиясендә 36. Мәҗмугы 489 кыз укыткан. Үз йортындагы ятимханәсендә 14 ятим кыз тәрбияләнгән. Спасский урамындагы үз йортында гаскәри хастаханә ачкан. Хастаханә ачылу мөнәсәбәте белән, китапханәсе вакытлы ябылган. Җәмгыятьнең тышкы ягы эшләнеп беткән ике катлы таш мәдрәсәсенең эчке ягы эшләнеп бетмәгән көенчә тора. Шуны эшләтеп бетерү өчен 10 мең сумлап акча кирәк. Куәте азлыгыннан идарә әгъзалары ятимханәне ябарга да карар биргәнлекләрен язып үткән идек. Гомуми җыен мөнәсәбәте белән шуны әйтеп үтәргә тиешле күрәбез: мондый фәлякатьле[149] заманнарда ачылган ятимханәләрне ябу түгел, яңаларын ачарга бурычлымыз һәм ачмый да булдыра алмамыз. Шуңар күрә, без ятимханәне ябу тарафдары түгелмез, аны бер һөнәрханә сурәтенә куеп дәвам иттерешү бөтен Уфа халкына йөкләнгән бер фарыз[150] дип теләк әйтәмез.

[146] Дәхый – янә, тагы да, тагын да.
[147] Ибтидаи – башлангыч.
[148] Рөшди – урта.
[149] Фәлякать – бәла, бәхетсезлек.
[150] Фарыз – үтәлүе тиешле булган бурыч.



Уфада «Ханымнар җәмгыяте»нең кызлар мәктәбендә»
*(«Сөембикә», 1914, №1)*

Ханым вә туташларның мәдәниятемезгә булган тәэсирләрен игътибарга алып, һиммәт[151] ияләре ирләрнең дә матди вә мәгънәви ярдәмдә булынуларын, бетмәгән эшләрен бетерешүләрен, гомумән, ир вә аталардан ханым вә туташларын җәмгыятькә катнашырга дәлаләт итүләрен[152] өмет итеп каламыз.

*«Тормыш», 1915, 20 март.*

***Мәфтүха Яушева***

**«Вазыйфа»чыларга вә дусларыма ачык хат**

«Вакыт» гәзитәсенең 1664нче нөсхәсендә[153] «Троицкида ханымнар җәмгыяте»[154] сәрләүхәсе[155] астында мәкалә сыман бер нәрсә күргән идем. Бу мәкалә сыман нәрсә Троицкидан язылганлыктан, вә үзе дә хатын-кызларга тәгаллекъле[156] бернәрсә булганлыктан, вакытында беразрак дикъкатемне җәлеп иткән иде. Бигрәк тә Троицкиның ачык фикерле ханымнары тарафыннан ачылачак хатыннар җәмгыятенә бер бай хатынының каршы төшеп, эшне булдырмый калу җәһәте, «кем булыр бу бай хатын?» дип бераз уйланган идем.

Арадан бераз гына вакыт үтте. Бер мәҗлестә сүз иярә сүз чыгып, ачык фикерле ханымнарның берсеннән моның кем икәнен сорадым.

Ачык фикерле ханым мәгънәле итеп миңа туп-туры карады да, көлеп: «Белмим, ашыкма, бераздан соң белерсең», – диде.

---

[151] Һиммәт – тырышлык.
[152] Дәлаләт итү – юл күрсәтү, өйрәтеп күрсәтү.
[153] Нөсхә – сан.
[154] Троицкида ханымнар җәмгыяте // Вакыт. 1915. 25 декабрь.
[155] Сәрләүхә – исем, мәкалә исеме.
[156] Тәгаллекъ – бәйләнешле.

Моннан берничә көн генә соң дусларымнан берсе хатын-кыз арасында «каршы төшүче бай хатыны» дип мине сөйләгәннәрен килеп әйтте. Көлдем дә куйдым. Әлеге ачык фикерле ханымның мәгънәле көлешендәге мәгънәсен аңладым. Мәгәр ул халык арасында сөйләнгән сүзне ишеткән икән. Әһәмият бирмәдем. Чөнки безнең хатын-кыз арасында сөйләнгән мәгънәсез сүзләр әһәмият биреп бетерерлек дәрәҗәдә генә түгел. Аларның һәркаюсына әһәмият биреп, артыннан йөри башласак, бар вакытыңны шуның артыннан гына йөреп үткәрергә кирәк. Ни минем андый ук бар сүз артыннан йөрергә артык вакытым юк иде, чөнки Чөнки Троицкидагы мөселман ханымнары комитеты минем тәхет идарәмнән булып, бар вакытым шуның илә үтә иде.

Моннан берничә көннәр әүвәл «Тормыш» гәзитәсендә «Ака» имзасы илә язылган бер мәкалә[157] бу вазыйфачылар мәсьәләсен тагын яңартты. Ләкин «Ака» әфәнде җәмгыятьнең вөҗүдкә чыкмый[158] калуын бер бай хатынына сылтамаган, бәлки вазыйфачыларның үзләреннән, үзләренең эшкә камил иман вә мәтанәт[159] белән керешмәгәнлекләреннән күргән.

Менә бу тугры сүз кайберәүләрнең кәефенә ярамаган булса кирәк, бу арада исемемә имзасыз мәктүбләр[160] ява башлады. Тагын моның өстенә Казаннан, Ташкенттан да хатлар алгаладым. Анда да җәмгыятьнең вөҗүдкә чыкмый калуына мин сәбәп дип ишеттергәннәр. «Без боңа аптырыймыз, башка вакытта сине халык эшләре башында күрә идек. Бу ни хәл?», – дип, дусларым бераз шелтәлиләр. Бер кечкенә кыз баланың, кеше җилкетүенә карап, исемен гәзитә сәхифәләрендә күрү дәрте белән язган нәрсәсе әфкяр[161] гомумияне яхшы ук кына чуалтырга яраган. Мәсьәлә хәзер җитди хәлгә кергән. Дусларымның урынсыз пошынуларына сәбәп булган.

Инде мин дусларымнан шуны үтенәм: юк нәрсәгә эчләре пошмасын. Мин әле дә шул әүвәлге табигыятемдә. Мин әле дә шул әүвәлдәге шикелле үк, җәмәгать эшен яратам. Әгәр дә бездә андый башланган милли хәрәкәтләр булу түгел, хәтта мондый хәрәкәтләрне башларга миңа аз гына мәгънәви ярдәмчеләр генә булса да, мин аңа бөтен вөҗүдем илә бирeләм.

«Вакыт»ка ул мәкалә сыман нәрсәне кем вә ни сәбәптән язганын да бераз аңлатып китим. Моның комитетымызда юк-бар саф-саталар сатып, башкаларның эшенә манигъ[162] булганлыгы өчен бер-ике мәртәбә орыш итешкән бер хатынның кызы икәнен хәзер аңладык. Анасы комитетта сафсата сата алмый бизгәч, кызы комитет сүрелде дип белгән. Комитет сүрелгән юк һәм дә әкият, гайбәт, сөйләп утыручы бер-ике хатынның килми башлаулары илән генә сүрелерлек тә түгел. Чөнки бик әсаслы[163] суратта корылган. Бәлки көннән-көн

[157] Ака. «Вазыйфачылар» вазыйфалары башында булсыннар иде // Тормыш. 1915. 1 март.

[158] Вөҗүдкә чыгу – барлыкка килү, бар булу.

[159] Мәтанәт – ныклык, түземлелек.

[160] Мәктүб – хат, язылган әйбер.

[161] Әфкяр – фикерләр.

[162] Манигъ – тыючы, тоткарлаучы киртә.

[163] Әсас – нигез, база.

тәрәккый итмәктәдер[164]. Комитетның тәрәккыйда булганлыгына, башка эшләренә һич бер кимчелек китермичә борадәран[165] Яушевлар лазаретыннан ике кровать алганлыгы дәлил булса кирәк.

Мин «Вазыйфа» җәмгыятенең вөҗүдкә чыгуына чын күңелем илә телим. Әгәр «Вакыт»та язылган бай хатыныннан максудлары мин булсам, бу минем хакымда сарыф ифтирадыр[166]. Вазыйфачыларның җыелышачакларын ишетсәм, җыелышларына барырга карар кылып куйган идем. Ләкин ни өчендер (әллә «Ака» әфәнде әйтмешли, эшкә башта чын иман вә мәтанәт белән керешми, тик мода өчен генә җәмгыять ясыймыз дип йөргәнгәме), әле булса җыела алмыйлар, бу көнгә кадәр бай хатынын бәһанә[167] итеп тоталар икән, инде моннан соң бәһанәләр артына качарга урын юк. Чыксыннар мәйданга. Гомуми эшләр эшләнә торган йиргә бару ашка бару булмый. Анда бигрәк чакырмыйча барылачагын «Вакыт»ка язучы кечкенә сеңелем белмәсә дә, мин бик яхшы беләм. Җыелышлары булса, әлбәттә, чакырмыйча барам. Мөкаддәс[168] бер эшне башлаганнар икән, тизрәк җыелып вөҗүдкә чыгарсыннар. Әгәр бу хатым «Тормыш» гәзитәсендә басылып чыкканнан соң, унбиш көн эчендә җыелып эшләренә керешмәсәләр, «Вазыйфа» җәмгыятенең ачылмавындагы һәммә мәсъүлият[169] үз өсләрендә икәне бик яхшы аңлашылачак. Уңны-сулны аерырлык яшьтә булмаган бер яшь баланы җилкетеп, уртага юктан бар бай хатыны ясап чыгарудан төп максудлары «Нигә эшләмисез», «Нигә йоклыйсыз» дип һәрвакыт үзләренә әйтелеп торган шелтәдән котылу, «Без бик эшләр идек тә, менә «Вакыт» гәзитәсендә укыдык бит, бай хатыны манигъ була», дип әйтү өчен генә булып калачактыр.

*«Тормыш», 1915, 3 апрель.*

**Хисап**

Чиләбедә 18нче апрельдә кызлар мәдрәсәсендә укучы фәкыйрь шәкертләр файдасына ясалган театр-концерт кичәсенең хисабы.

*Килере:*
Билетлар сатудан – 419 с. 55 т.
Чәчәкләр, програм, конфетти, серпантин – 180 с. 68 т.
Буфеттан – 72 с. 25 т.
Буфеттан калган чәй, шикәрне сатудан – 4 с. 26 т.
Акчалата иганә – 18 с.

*Чыгымы:*
Барысы: 254 с. 22 т.
Саф файда: 440 с. 52 т.

---

[164] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.
[165] Борадәран – бертуган.
[166] Ифтира – яла, берәү өстенә ялган гаеп ташлау.
[167] Бәһанә – сылтау, сәбәп, ялган сәбәп.
[168] Мөкаддәс – изге, мөһим.
[169] Мәсъүлият – җаваплылык.

Бу акча кызлар мәдрәсәсендә укучы фәкыйрь балалар файдасына тотар өчен Чиләбе мәктәп вә мәдрәсәсенең хәзинәдарына беренче номерлы квитанция буенча тапшырылды.

Ошбу кичәнең гүзәл чыгуына тырышкан мөхтәрәмә ханымнар вә әфәнделәргә, кыллы оркестрда уйнаучыларга, акчалата һәм нәрсәләр илә иганә кылучыларга, билетлар сатуга булышлык кылганнарга, билетларга, башкача хезмәт итеп, кичәнең яхшы чыгуына ярдәмнәре тигән затларга һәм кичәгә килгән һәммә ханым, туташ вә әфәнделәргә чын күңелемездән рәхмәтләр укыйбыз.

Башкаручылар: Закир Тумашев, Шакир Сәлимов.

Тәсхыйх[170]: Чиләбедә ясалган театр хакында Габдулла әфәнде Галиев мәкаләсенә сбор бер мең сум чамасында булды дигән сүз ялгыш арттырылып басылган, дөресе менә шушы хисапта күрсәтелгәнчә.

*«Тормыш», 1915, 3 май.*

***«Мохбир»***

**[Кәримә ханым Ишмөхәммәдованың...]**

Кәримә ханым Ишмөхәммәдованың кузгатуы белән Петропавел ханымнары мөгаллимәләр курсына берничә туташ йибәрергә йөрсәләр дә, коры сөйләшү генә булып калды. Ялгыз Кәримә ханымның тырышуы белән генә хәзерләнгән акча белән бер мөгаллимә Уфа мөгаллимәләр курсына китте.

*«Тормыш», 1915, 17 июнь.*

**Мөслимәләр җәмгыяте идарәсеннән**

Җәмгыятьнең әгъзалары арасында еллык әгъзалык акчалары алынмаган кешеләр булганлыктан, үткән 1914нче ел хисабы тәмам булмый тора. Шул хәлне игътибарга алып, җәмгыять әгъзаларының үткән әгъзалык акчаларын җәмгыятьнең хәзинәдары табибә Разия ханым Сөләйманова җәнабләренә тапшырулары үтенеләдер.

Оренбург мөслимәләр җәмгыяте идарәсе.

*«Вакыт», 1915, 15 июль.*

**Тәшәккер[171]**

Бу ел җәй Оренбургта булган бер мөсафир[172] ханым иленә кайтырлык булмагач, җәмгыять хәйрия илә ханымнар җәмгыятенә мөрәҗәгать итеп, бурычка акча сораган икән. Ирләр җәмгыяте 10 сум 37 тиен, ханымнар җәмгыяте 10 сум иганә кылганнар. Мөсафир ханым идарәмезгә мәктүб язып, бу ике җәмгыятькә тәшәккер бәян итәдер.

*«Вакыт», 1915, 23 август.*

[170] Тәсхыйх – дөресләү.
[171] Тәшәккер – рәхмәт әйтү.
[172] Мөсафир – юлчы.

***Кәримә Ишмөхәммәд***

## Фатыйма ханым мәктәбенә

Милләтемезнең анасы мәрхүмә Фатыйма-Фәридә ханым исеменә Кәрәкәшле авылында салыначак мәктәп файдасына Петропавел ханымнарыннан җыелган 95 сум акча барлыгын һәм дә, хаҗәт булган вакытта, тиешле урынына алып бирү шарты илә Петропавелдагы Государственный Сберегательный кассага салдыгымны гәзитәләр аркылы игълан кылган идем.

Хәзердә шул мәктәпне сала башладыкларыны һәм дә акчага бик мохтаҗ булдыкларыны язып, Вәгыйзь әфәнде мәзкүр[173] акчаны йибәрүне үтенде. Мин һәм Вәгыйзь әфәнденең язуы буенча күрсәтелмеш 95 сум акчаны 450нче номер квитанция белән 4нче сентябрьдә Ютазы станциясенә Гариф мулла Бикташев исеменә йибәрдем.

Минем мәзкүр акчаны урынына тапшырдыкымны гәзитәңез аркылы игълан итмәкегезне үтенәмен. Гариф әфәнде һәм үз тарафыннан акчаны йолып алганлыгы тугрысында игълан итсә кирәк.

Петропавел.

*«Тормыш», 1915, 24 сентябрь.*

## Гыйффәт туташка[174]

Чиләбедә Гариф әфәнде Бурнаевны озату мәҗлесе ясалганын гәзитәмездә язып үткән идек. Шакир әфәнде Сәлимовның идарәмезгә хәбәр итүенә күрә, шул мәҗлеснең ахырында татлы шигырьләре белән танылган Заһидә Гыйффәт туташ файдасына 11 сум иганә җыелган вә бу акча гәзитәдә күрсәтелгән адрес буенча Гыйффәт туташка йибәрелгән.

*«Тормыш», 1915, 30 сентябрь.*

## 6нче октябрьдә!

Гыйлемгә сусау һәм гасырымызның укыган булучылыкны теләве бик күп аз акчалы кешеләрне, хәтта фәкыйрьләрне дә мәктәпкә таба тарта.

Фәкыйрь булганлыклары өчен генә шундый кешеләрне мәктәпкә кабул итмичә, кире кайтарырга һичкем кыючылык кыла алмый һәм бу хактагы мәсьүлиятьне[175] күтәреп калырга һичкемнең кулыннан килми. Мондый укучылар үзләренең чигә торган матди авырлыкларына ярдәм кулын сузучыларны җәмгыятьләр арасында табалар.

Менә шундый фәкыйрьләрнең бик күбесе, ихтимал иң күбеседер, Уфаның 2нче кызлар гимназиясендә укыйлар. Бу бичараларга башка җәмгыятьләр белән берлектә «Аталар комитеты» ярдәм итә. Ләкин болар өчен шул

---

[173] Мәзкүр – әйтеп үтелгән, югарыда әйтелгән.

[174] Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева (Гыйффәт туташ, 1895–1977) – шагыйрә, мәгърифәтче, Сәмәркандта «Михнәттәшләр тавышы» газетасы мөхәррире. Үзбәкстан дәүләт нәшрияты хезмәткәре.

[175] Мәсьүлият – җаваплылык.

чаклы күп акча кирәк ки, комитет әгъзаларының үзләреннән җыелган акчаны гына йиткерү мөмкин дә түгел. Шуның өчен комитет халыкның ярдәменә мөрәҗәгать итәргә карар бирде.

Менә шул аптырауларга ярдәм итү максаты белән, «Аталар комитеты» 6нчы октябрьдә Художественный театрда хәйрия сеансы ясарга карар бирде. Шунда оттырмый торган лоторея «Бәхет мичкә» дә булачак. Халыкның хитабнамәне[176] игътибарга алуына ышанамыз.

Ярдәм итегез укучы кыз шәкертләргә!

Аларның арасында уфалылар да, башка качак кызлары да бар. Аз гына иганә дә аларның байтак вакыт укуларын дәвам иттерүгә ярдәм итәчәк.

*«Тормыш», 1915, 4 октябрь.*

## Уфада

Ирләр җәмгыять хәйриясе урамда сәдака сорашып йөрүче мөселман кыз балаларын җыеп, төрле һөнәрханәләргә урнаштыру өчен биш кешелек бер комиссия сайлаган иде. Комиссия әгъзаларының сүзенә күрә, бу көнгә кадәр төрле сәбәпләр берлә комиссия бер баланы да урнаштыра алмаган. Фәкыйрь һәм тәрбиячесе булмаган балаларны белгән кешеләр шул комиссия әгъзаларыннан Бәдретдин әфәнде Назыйровка мөрәҗәгать итүләре үтенеләдер.

*«Тормыш», 1915, 21 октябрь.*

***Батыршин Гариф***

## Фатыйма-Фәридә ханым наменә[177] корылган мәктәпкә нигез кору мәрасиме[178]

Мәрхүм мөхәррирә вә мөгаллимә Фатыйма-Фәридә ханым исемене мәңгегә калдырыр өчен кыз вакытында иң әүвәл мөгаллимлек итдеке, үзе дәфен улындыгы[179] Кәрәкәшле авылында кызлар мәктәбе салынырга тәшәббес улындыгы[180] милли матбугатта берничә мәртәбә язылган иде. Бу хосуста татар милләтеннән ярдәм дә өстәлгән иде. Бик күп фидакарьлек иткәннән соң, бер мөселман хатыны исеменә салыначак гыйлем йорты хакында бер адым атланды.

Мәдәни милләт ир вә хатыннардан милләтләренә иткән хезмәтләре өчен төрле гыйльми вә хәйрат[181] мөәссәсәләре[182] коралар.

Урамнарына билә андый кадерле адәмнәренең исемнәре илә атыйлар. Русия мөселманнарын да мәдәнияткә аяк басканнан бирле, бөек мөрәбби[183],

---

[176] Хитаб – эндәшү, мөрәҗәгать итү.
[177] Нам – исем.
[178] Мәрасим – йола, церемония.
[179] Дәфен улыну – күмелү.
[180] Тәшәббес улыну – керешү, эшкә тотыру.
[181] Хәйрат – сәдака.
[182] Мөәссәсә – оешма, учреждение.
[183] Мөрәбби – тәрбияче.

мөхәррирләр вә шәгыйрьләренең, җәмәгать хадимнәренең[184] хезмәтләрене тәкъдир итә[185] башладылар. Мәрхүм Исмәгыйль бәк[186] үзе сәламәт вакытта билә аның исеменә мәктәп, кыйраәтханәләр[187] ачылды. Шиһаб хәзрәт[188] исеменә бер мөәссәсә корылмаса да, аның дөньяга килүенә йөз ел тулу мөнәсәбәте илә тәрҗемәи хәлене, гыйлеме, иҗтимагый хезмәтләрене күрсәтеп, зур бер китап басылды.

Фәкать бичара мәрхүм Каюм Насыйри[189] һәнүз[190] искә алынмый әле. Хәлбуки аның хезмәте шаян[191] тәкъдирдер. Милли шагыйремез Габдулла Тукайны сәламәт вакытта кадерли-тәрбияли алмасак та, үлгәч тәрбияләп күмгән идек. Тәгъзия[192] телеграмнары да яңгыр кеби яуган иде. Татар милләте сүздән эш дәверенә күчеп йитә алмаганмы? Яхуд башка сәбәпләрдәнме? Милли шагыйренең намен мәңгегә калдыру хосусында бер төрле җитди тәдбирләр[193] кылынганы юк әле. Шагыйрьнең каберенә билә таш куелмадыгы, каберенең тирәсе тотылмадыгы һәркемгә мәгълүмдер. Эшләнгән бер эш бар ләйсә[194] шагыйрьнең исеменә ачылган урта мәктәптә бер «стипендия»дер. Бу исә татар милләтенең мәдәни гөнаһысыдыр.

Русиядәге мөселман хатын-кызларына килсәк, алар әле яңа коллыктан чыга башладылар. Аларга гомуми, милли, иҗтимагый хезмәтләр дә булынудан бигрәк, иркенләп укырга ирек бирелмәде. Шулай да, алар арасында аз бервакытта гыйльми вә иҗтимагый хезмәтләре илә милләткә үзләрене таныттырып вафат булучылары да бар.

Фәкать Русия мөселманнары бер мөселман хатыны, яхуд кызы исеменә аларның хезмәтләрене тәкъдир итеп, исемнәрене мәңгегә калдырыр өчен бер нәрсә дә эшләгәннәре юк әле. Шул хатыннар арасында иң кадерле урынны тотып, милләтнең күңелендә тирән бер эз, самими бер мәхәббәт казанып вафат булучы Фатыйма-Фәридә ханымдыр. Фатыйма-Фәридә ханымның вафаты заманында меңгә якын телеграм, мең биш йөз кадәр тәгъзия мәктүбләре[195] килде. Телеграмнар матбугатта басылды. Мәктүбләрене басып бетерергә мөмкин булмады. Мәрхүмәнең вафатына тиздән ике ел булачак. Милләт аны да оныта башлады. Фәкать мәрхүмәне үзе дәфен улынган Кәрәкәшле авылы онытмады. Аның исемене мәңгегә калдыру өчен бик тырышты.

---

[184] Хадим – эшче, хезмәтче.
[185] Тәкъдир итү – бәя бирү.
[186] Исмәгыйль Гаспринский.
[187] Кыйраәтханә – уку өе, библиотека.
[188] Шиһабетдин Мәрҗани.
[189] Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров (Каюм Насыйри, 1825–1902) – татар мәгърифәтчесе, педагог, дәреслекләр авторы.
[190] Һәнүз – әле дә, һаман.
[191] Шаян – лаек, яраклы, тиешле дәрәҗәдә.
[192] Тәгъзия – үлгән кешенең якыннарын юату, күңел юату.
[193] Тәдбир – эшне ахырын уйлап эшләү, алдан күрү.
[194] Ләйсә – түгел, булмас, юк.
[195] Мәктүб – хат, язылган әйбер.

Ниһаять максатына да бер дәрәҗә ирешә башлады. Мөхтәрәм укучылар, гафу итеңез! Максаттан бераз читкә чыктык, ачы хакыйкать бу сәтырларны[196] язарга мәҗбүр иттеләр. Менә бу ел, мөселманнарның ел башы саналган мөхәррәм аенда, ноябрь числосының 11нче көнендә мәрхүмәнең наменә салыначак кызлар мәктәбенең нигез кору мәрасиме ясалды. Мәдәнияттән ерак, караңгы бер почмакта, тарихи ганганәсене[197] оныта башлаган, байлыгының күбесеннән аерылган, милләтене югалта язган бер башкорт авылында, аларның зәгыйфь булган гыйльми, мадди көчләре илә ясалачак мәрасимнең бик садә[198] (простой), фәкать бик самими улачагы табигыйдыр. Монда нәзар[199] дикъкатькә алыначак нокталар бар. Алар шулардыр: бер мөселман хатынының гыйльми, иҗтимагый хезмәтене, мәдәниятле кала халкыннан бигрәк авыл халкының тәкъдир итүе, бар көче илә Русия мөселманнары арасында иң шәрәфле булган бер эшне эшләргә авыл халкының омтылуы, бу хосуста аларның сәгый[200] вә гайрәтләредер. Мөселман хатын-кызларының тарихи гыйззәт[201] вә шәрәфләрене[202] мәңгегә сакламак нияте илә мөкаддәс[203] ядкәрнең бер авылга утыртылуыдыр. Русиядә фәүкылгадә[204] әхвәл хәйран итдеке вә дәһшәтле кайгылар улдыгы җәһәте илә, мәрасим көне билә милли матбугатта игълан ителмәде. Бәлки Бөгелмә өязендәге мәгарифпәрвәр руханилар илә бәгъзе гыйлем сөюче сәүдәгәрләргә мәрасим[205] көненең кай көн булачагы хосусый сурәттә генә белдерелде.

Шулай булса да, нигез кору мәрасимендә төрле авыллардан илледән артык голәма[206] вә сәүдәгәрләр бар иде. Мөсафирлар[207] арасында бик мөхтәрәм булган карт хәзрәтләр илә гыйльми вә иҗтимагый хезмәтләре илә халыкка танылган хөрмәтле затлар бар иде. Бу кунакларның күбесе 10нчы ноябрьдә кич килделәр. Билгеләнгән ханәләргә урнаштылар. Хөрмәтле кунакларны авыл халкы бик шатлык илә каршы алдылар.

11нче ноябрь көне бик тын һәм йылы, бөтен авыл халкының йөзендә шатлык әсәре күренеп тора иде. Хосусан хатын-кызлар шатлыкларына сыеша алмыйлар иде. Кызлар мәктәбендә мөгаллимә ханымнар, шәкертләрнең фәгалиятене[208] тәгъриф итеп[209] бетерү мөмкин түгел. Алар мәктәпне бизиләр,

[196] Сәтыр – юл, язу юлы.
[197] Ганганә – сүзнең кешедән кешегә күчүе; сүзне кешедән кешегә күчерүчеләр.
[198] Садә – гади.
[199] Нәзар – иътибар.
[200] Сәгый – тырышу.
[201] Гыйззәт – кадер, хөрмәт, мәртәбә.
[202] Шәрәф – кадер, хөрмәт.
[203] Мөкаддәс – изге, мөһим.
[204] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[205] Мәрасим – йола, церемония.
[206] Голәма – галимнәр, дин галимнәре.
[207] Мөсафир – юлчы.
[208] Фәгалиять – эшчәнлек.
[209] Тәгъриф итү – таныту, сөйләп бирү, аңлату.

җыештыралар. Чөнки кунакларга беренче зыяфәт[210] кызлар мәктәбендә биреләчәк иде. Нигез кору мәрасиме өйләдән соң сәгать бердә улдыгы җәһәте илә, өч мәхәлләнең халкы кунаклар илә мәхәллә мәсҗетләре тулы иде. Намаз тәмам улды. Мәрасимне идарә итүче әфәнделәр имам Харрас, имам Гариф, имам Гатиятулла, имам Нуретдин гаҗизләре мәхәллә тарафыннан сайлаган әфәнделәр көндез сәгать 2дә салыначак мәктәпнең урынына җыелдылар. Мәктәпнең урыны агачлык арасында, тау битендә, агым су буенда булганга, эчендәге халыкның күплеге, төрлелеге шагыйранә[211] бер манзара булып күренә иде. Һәркем билгеләнгән урыннарга урнашты. Бер-ике секундка дәкыйка[212] үтәлектә тынлык хөкем сөрде. Мәрасимне идарә итүче имамнардан имам Харрас кунакларны «Хуш килдеңез!» – дия алкышлады. Мәрасим хакында мәгълүмат бирде. Бәйрәкәдә ахун вә мөдәррис мөхтәрәм Мәсгуд Гобәйдуллин җәнабләре Коръән укыды. Беренче мәртәбә бер мөселман хатыны исеменә салыначак гыйлем йортының татар милләтенә бик файдалы хезмәтчеләр – аналар йитештерүене теләп, догалар кылды. Бөтен халык яшьләрене агызган хәлдә, «амин» тавышлары илә күкне яңгыраттылар. Патша хәзрәтләренең ханәдане галиләренең[213] сәламәтлеге, ватанның сәгадәте[214] өчен махсус дога иттеләр. Карт хәзрәтләр бергә-бер бүрәнәне күтәреп, олуг Ходаның исемене зикер[215] итеп, нигезгә куйдылар, янә бер кәррә Җәнабе Хакка ялварып, бу бинаның тизлек илә тәмам булуын теләп дога иттеләр. Мөхтәрәм Мәсгуд хәзрәт мәрасим мөнәсәбәте илә гыйлемнең файдасы, хатын-кызларны җитди сурәттә тәрбия итүнең әһәмияте хакында мөәссәр[216] хотбә[217] сөйләде. Мөселман хатын-кызларының тарихи хезмәтләрене берәм-берәм санап, мәрасимдәге халыкны мөтәәссир[218] итде. Мәсгуд хәзрәт шул җөмләләр илә сүзне тәмам итте: «Кәрәкәшле авылының тарихы, аларның һиммәтләре[219] искедән бирле безгә мәгълүмдер. Шул һиммәтеңезнең бөеклеге сезне шундый мөкаддәс гыйлем йорты салырга, ничә гасырлардан бирле хокукларыннан мәхрүм булган тута-сеңелләреңезне дини, милли рухта тәрбия итәргә өндәгән. Сезне бу көнге хезмәтеңез, тарихи көнеңез илә тәбрик итәм. Муаффәкыять[220] илә тәмам итүне Ходадан сорыйм. Бу йорт бер мөселман хатыны исеменә ядкәр уларак салыначагы җәһәте илә, бу изге мөәссәсәне тәмам итү истикъбалене[221] тәэмин кылу сез авыл халкы илә бөтен татар милләтенең бурычыдыр. Ышанам ки, милләт

---

[210] Зыяфәт – кунак итү.
[211] Шәгыйранә – шагыйрьләрчә.
[212] Дәкыйка – минут.
[213] Ханәдане гали – бөек династия.
[214] Сәгадәт – бәхет, рәхәтлек.
[215] Зикер – искә алу, искә төшерү.
[216] Мөәссәр – тәэсирле, йөрәгенә үткән.
[217] Хотбә – нотык сөйләү, чыгыш ясау.
[218] Мөтәәссир – йогынты алган.
[219] Һиммәт – тырышлык.
[220] Муаффәкыять – уңыш.
[221] Истикъбаль – киләчәк.

үзенең бурычыны үтәр. Ходай һәрвакыт ярдәмчегез булсын». Бөтен халык мөлдер-мөлдер күз яшьләрене агызып, хөрмәтле кунакларына тәшәккер[222] бәян иттеләр. Башка хәзрәтләр вә имамнар тарафыннан мәрасимгә муафыйк нотыклар сөйләнде. Мәҗлесне идарә итүче хәзрәтләр хөрмәтле кунакларыны кызлар мәктәбе бинасына зыяфәткә дәгъват иттеләр[223]. Кызлар мәктәбе иҗарәгә[224] алынган булса да, бик зур булганга, бөтен халыкны диярлек сыйдырды. Бу шатлыклы тарихи мәҗлестә урынына муафыйк хотбәләр сөйләнде. Читтән килгән тәбрик мәктүбләре укылды. Нигез мәрасиме, котлап бирелгән иганәләр кабул ителеп, догалар кылынды. Кәрәкәшле авылындагы кызлар мәктәбе мөгаллимәләренең тәбрик вә тәшәккерләре укылды. Нигез кору мәрасимене котлап, төрле авылдан килгән мосафирлар, руханилар, сәүдәгәрләр, авыл халкы иганәләр тәкъдим иттеләр. Ирләр вә хатын-кызлар мәҗлесендә җыелган бүләк, акчаның барлыгы ике йөз алтмыш алты сум сиксән сигез тиен булды. Авыл халкы мосафирларга тәшәккер бәян иттеләр. Шул ук мәҗлестә хөрмәтле мөсафирларның зыяфәткә дәгъват улынган спискалары игълан ителде.

Ирләрдән соң мөгаллимәләр, өстазбикәләр, авыл хатын-кызлары, хөрмәтле кунак ханымнарга кызлар мәктәбендә зыяфәт бирделәр. Нигез кору мәрасименә төрле авылдан хәзрәтләр илә рәфикалары[225] да килгәннәр иде. Хатын-кыз мәҗлесе бик рухлы, шатлыклы булды. Мәҗлестә муафыйк нотыклар сөйләнде. Хатын-кыз мәҗлесендә 30 сумга якын акча бүләк ителде, фәкать бу иганә гомуми булды. Бу иганәнең җәдвәле[226] тәртип кылынмады. Иганә бирүчеләр исемнәренең язылуын теләмәделәр. Бер мөселман хатыны исеменә ядкәр итеп салыначак гыйлем йортының нигезен кору мәрасимендә үзләре мәҗлестә була алмый иганә күндергән әфәнделәр вә ханымнарга үзләре мәҗлестә хазир улып[227], иганә итүчеләргә бөтен авыл халкы исеменнән самими калебемез[228] илә тәшәккер итәмез. Шушы шатлыгымызны мөхтәрәм халкымыз илә уртаклашмак нияте илә, «Нигез кору мәрасиме» хакында язылган шул мәкаләне мөхтәбәр «Сөембикә» журналы васитәсе[229] илә сөекле милләтемезгә тәкъдим итәмез.

Бу мәкалә илә бергә нигез кору мәрасиме котлап иганә биргән һәм дә үзләре мәрасимдә хазир булып, котлап акча бүләк иткән хөрмәтле ханым вә әфәнделәрнең исем вә фамилияләрене, иганәнең микъдарыны күрсәткән җәдвәлне күндерәмез. Могътәбәр «Сөембикә» идарәсе бу мәкаләбез илә иганә җәдвәлене басарга үзенең журналында урын бирер диеп өмет итәбез.

---

[222] Тәшәккер – рәхмәт белдерү.
[223] Дәгъват итү – чакыру, өндәү.
[224] Иҗарә – вакытлы файдалану, аренда.
[225] Рәфика – тормыш иптәше, хатыны.
[226] Җәдвәл – таблица.
[227] Хазир улу – катнашу.
[228] Калеб – йөрәк.
[229] Васита – арадаш, ике арада эш йөртүче.

Тиз көннән мәктәпнең програмы илә мөфассал[230] хисабы янә гәзитә вә журналлар васитасы илә хөрмәтле милләтемезә игълан ителәчәктер.

Иганә кылган әфәнде вә ханымнарның җәдвале:

1. Мәрхүмә Фатыйма-Фәридә ханымның әтисе Мортаза Ваһапов җәнабләре – 25 сум;
2. Кызлар мәдрәсәсендә чәй мәҗлесендә ханым әфәнделәрдән җыелган – 24 сум 13 тиен;
3. Бөгелмә шәһәрендә «Товарищество Баһаветдин, Галиев, Курамшин» әфәнделәрдән – 20 сум;
4. Бәйрәкә авылы[231] ахунд вә мөдәррис Мәсгуд Гобәйдуллин җәнабләреннән – 10 сум;
5. Бәйрәкә авылы Мөхсин хәзрәт Гобәйдуллин җәнабләреннән – 10 сум;
6. Каразирек авылы[232] шәех Бостам хәзрәттән (имам Гариф Батыршин бабасы) – 10 сум;
7. Туйкә авылы[233] Хәйретдин мулла Гатиятулланың бабасы – 10 сум;
8. Кәрәкәшле авылы Хәйретдин сатучы Хәйруллиннан – 10 сум;
9. Бәйрәкә авылы мулла Зәки әфәнде Мусиннан – 10 сум;
10. Бөгелмә шәһәрендә сәүдәгәр Сабирҗан Садыйковтан – 10 сум;
11. Кәрәкәшле авылы Габдулла Батыршиннан – 5 сум;
12. Кәрәкәшле авылы Шәйхетдин Садретдиновтан – 5 сум;
13. Әсәй авылы[234] Миңлеәхмәт сатучыдан – 5 сум;
14. Туйкә авылы Равил старшинадан – 5 сум;
15. Бәйрәкә авылы мулла Зәки Мусин җәмәгате Мәсрүрә ханымнан – 5 сум;
16. «Мәдрәсәи Фатыймаия»дә улган мөгаллимә ханым әфәнделәрдән – 4 сум 70 тиен;
17. Бәйрәкә авылы Мөҗаһид әфәнде Гобәйдуллин җәнабләреннән (Бәйрәкәдә вак бурыч банкысында рәис) – 3 сум;
18. Кәрәкәшле авылы имамы Харрас Фәхретдиновтан – 3 сум;
19. Әсәй авылы Әхмәдша хәзрәттән – 3 сум;
20. Каразирек авылы Әхмәдхәбиб хәзрәттән – 3 сум;
21. Якый авылы[235] Әхмәдзакир хәзрәттән – 3 сум;
22. Габдессәлам авылы мулла Сабит әфәндедән – 3 сум;
23. Кәрәкәшле авылы Нигъмәтулла Горфановтан – 3 сум;
24. Кәрәкәшле авылы Гази Хәбибрахмановтан – 3 сум;
25. Кәрәкәшле авылы Миңлевәли Әхмәтовтан – 3 сум;
26. Кәрәкәшле авылы Хөсәенов Батыршиннан – 3 сум;
27. Кәрәкәшле авылы хаҗи Әхмәд Гәрәевтән – 3 сум;

[230] Мөфассал – җентекле, тулы.
[231] Бәйрәкә авылы – хәзер Татарстанның Ютазы районына карый.
[232] Иске Каразирек – хәзер Татарстанның Ютазы районына карый.
[233] Туйкә авылы – хәзер Татарстанның Азнакай районына карый.
[234] Әсәй авылы – хәзер Татарстанның Азнакай районына карый.
[235] Якый авылы – хәзер Татарстанның Азнакай районына карый.

28. Кәрәкәшле авылы Сәлахетдин Фәрхетдиновтан – 3 сум;
29. Кәрәкәшле авылы Идрис Хәсәновтан – 3 сум;
30. Бәйрәкә авылы Зәкия ханым Искәндәр хаҗи җәмәгате – 3 сум;
31. Бәйрәкә авылы мулла Зәки әфәнденең анасы Шәмсинәһар ханымнан – 3 сум;
32. Кәрәкәшле авылы Әхмәтгалим Мөхәммәдвәли угылыннан – 3 сум;
33. Зәет авылы[236] Камалетдин хәзрәт Әхмәтовтан – 2 сум;
34. Эстәрле авылы[237] Мияссәр хәзрәттән – 2 сум;
35. Каразирек авылы Әхәдшәриф хәзрәттән – 2 сум;
36. Кәрәкәшле авылы Фатыйх Хәсәновтан – 2 сум;
37. Кәрәкәшле авылы шаигъ[238] Сәгъди Хәбибуллиннан – 2 сум;
38. Кәрәкәшле авылы имамы Нуретдин әфәндедән – 2 сум;
39. Кәрәкәшле авылы Гайсә Ибраһим угылыннан бер кәҗә сатылды – 2 сум 20 тиен;
40. Эстәрле авылы Солтангали хәзрәттән – 1 сум 50 тиен;
41. Каразирек авылы шәех Бостам хәзрәт чәчәк өчен иганә кылды – 1 сум 50 тиен;
42. Карамалы авылы[239] Хәсән хәзрәттән – 1 сум;
43. Мөтәви авылы Харис мулладан – 1 сум;
44. Әсәй авылы Шаһид мулладан – 1 сум;
45. Бәйрәкә авылы Ильяс мөәзиннән – 1 сум;
46. Бәйрәкә авылы Мирзаһид мөәзиннән – 1 сум;
47. Бәйрәкә авылы мулла Җәләл хәзрәттән – 1 сум;
48. Кәрәкәшле авылы Ибраһим Фәхретдиновтан – 1 сум;
49. Кәрәкәшле авылы Әхмәдхәбиб Шәрифовтан – 1 сум;
50. Кәрәкәшле авылы Габдулла Насыйрдан – 1 сум;
51. Кәрәкәшле авылы Локман Зарифовтан – 1 сум;
52. Кәрәкәшле авылы Әхмәтлатыйф Шәфиговтан – 1 сум;
53. Кәрәкәшле авылы Шәфигъ Шәрифовтан – 1 сум;
54. Кәрәкәшле авылы Давыд Ибраһимовтан – 1 сум;
55. Кәрәкәшле авылы Мирсәет Красиновтан – 1 сум;
56. Кәрәкәшле авылы Асылгәрәй Солтангәрәевтан – 1 сум;
57. Кәрәкәшле авылы Гыймадетдин Шәмсетдиновтан – 1 сум;
58. Кәрәкәшле авылы Шакир Зарифовтан – 1 сум;
59. Кәрәкәшле авылы Җамалетдин Фәрхетдиновтан – 1 сум;
60. Кәрәкәшле авылы Миңлешаһ Әхмәтҗан угылыннан – 1 сум;
61. Кәрәкәшле авылы Гариф Вәлиевтән – 1 сум;
62. Кәрәкәшле авылы Шәриф Хәсәновтан – 1 сум;
63. Рәссуй авылы Нәҗиб мөәзиннән – 1 сум;
64. Яңа Кәрәкәшле авылы Гали Мөхәммәд угылыннан – 70 тиен;
65. Габдессәлам авылы мөгаллим Мирсәлим әфәндедән – 50 тиен;

[236] Зәет авылы – хәзер Башкортстанның Шаран районындагы авыл.
[237] Югары Эстәрле авылы – хәзер Татарстанның Азнакай районына карый.
[238] Шаиг – билгеле.
[239] Карамалы авылы – хәзер Татарстанның Азнакай районына карый.

66. Кәрәкәшле авылы Сәләхетдин Гаясетдиновдан – 50 тиен;
67. Кәрәкәшле авылы Шәйхелислам Сиражетдиновдан – 50 тиен;
68. Кәрәкәшле авылы Габделбакый Мөхәммәдвәли угылыннан – 50 тиен;
69. Ютазы станциясендә сатучы Мәүлүдовтан – 50 тиен;
70. Ютазы станциясендә Мәүлүдов рәфикасы – 50 тиен;
71. Кәрәкәшле авылы Сахибгәрәй Сәфәргали угылы – 50 тиен;
72. Кәрәкәшле авылы Хәсәнулла Насыйбулла угылы – 50 тиен;
73. Кәрәкәшле авылында тимерче Хәйрулладан – 45 тиен;
74. Кәрәкәшле авылы Дәүләтша Гали угылыннан – 20 тиен;
75. Кәрәкәшле авылы Насыйбулла Сафиулла угылыннан – 20 тиен;
76. Кәрәкәшле авылы Сахибгәрәй Сәйфетдин угылыннан – 15 тиен;
77. Кәрәкәшле авылы Мөҗаһид Мөхетдин угылыннан – 15 тиен.

Мәҗмугы – 266 сум 88 тиен. Вә янә 5нче ноябрьдә Уфадан княгиня Гайнелхаят бинте Рөстәм хан Дәүләткилдиевадан алдык 10 сум.

Нигез кору мәрасимене идарә итүче әгъзаларыннан: мөдәррис, имам Гариф Батыршин, имам Гатиятулла Габдуллин, имам Нуретдин Фәрхетдинов.

Фатыйма-Фәридә ханым наменә салыначак кызлар мәктәбене тәмамларга ярдәм итәргә арзу итүче[240] ханымнар, әфәнделәр булса, түбәндә күрсәтелгән адрес илә иганә күндерергә мөмкин:

Ст.Ютаза. Волго-Бугульминской Ж.Д., дерев. Каракашли, мулле Гарифу Батыршину.

*«Сөембикә», 1915, №3, б.52–56.*

**Эстәрлетамактагы икенче кызлар мәктәбенә вакыф**

Гәзитәбезнең наширы Г.Госманов күптәннән бирле Эстәрлетамак өязендә берничә авылда һәм Эстәретамак шәһәренең үзендә кызлар мәктәбе тәрбия итеп килмәктә иде. Эстәрленең икенче мәхәлләсенә моннан берничә ел элек ибтидаи[241] вә рөшди[242] сыйныфлар берләштерерлек бер мөкәммәл[243] кызлар мәктәбе бина иткән[244] вә бу көнгә кадәрле шуның мәсарифын[245] үз кесәсеннән тотып килгән. Хәзер шул мәктәпне тәэмин итү максаты илә Эстәрле шәһәренә якын гына, байтак варидәт[246] китерә торган җиреннән 36 дисәтинә җирне һәм 5–6 мең тора торган мәктәп өчен салынган мәзкүр[247] бинаны кызлар мәктәбе итеп алып бару шарты илә икенче мәхәлләгә вакыф иткән. Вакыфын идарә итү өчен Эстәрле могътәбәрләреннән[248] Һади әфәнде Ибраһимов, Г.Айтуганов вә өченче бер кеше сайланган.

---

[240] Арзу итү – теләк, омтылыш белдерү.
[241] Ибтидаи – башлангыч.
[242] Рөшди – урта.
[243] Мөкәммәл – тәмамланган, камилләшкән.
[244] Бина итү – нигез салу.
[245] Мәсариф – чыгым.
[246] Вәридәт – керемнәр.
[247] Мәзкүр – югарыда әйтелгән.
[248] Могътәбәр – зыялы, хөрмәтле.

Бу вакыфны рәсмиләштерү хосусында да тәшәббескә тырышылып[249], мәзкүр вакыфны Гыйбадулла әфәндедән кабул итеп алырга Духовный Собраниегә рөхсәт ителгән. Гыйбадулла әфәнде үзе Уфада булмаганлык сәбәпле, кияве һәм вәкил Сәлях әфәнде Җәббаров нотариус хозурында Собрание вәкиленә бу вакыфны тапшырадыр. Собрание үзеннән вәкаләт вакыфны идарә итәр өчен ахун Сәлях хәзрәткә вәкаләтнамә бирәчәк.

*«Тормыш», 1916, 4 март.*

## Фәкыйрә кызлар мәктәбе

«Мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә караган фәкыйрь ирләр мәктәбе имтиханына җыелган халык, шул мәхәлләдә фәкыйрә кызлар мәктәбе дә булуын кирәксенеп, шуның өчен мең җиде йөз сум (1700) акча җыештылар. Бу мәктәп «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә караган вә аның түбәнге сыйныфы хисап ителергә тиеш күрелә. Шундый кызлар мәктәбенә урын билгеләүне ирләр фәкыйрә мәктәбенең мөтәвәллиләре[250] үз өстенә алдылар.

*«Тормыш», 1916, 20 апрель.*

***Сорур Сәлимова***

## Фатыйма-Фәридә мәктәбенә иганә

Мәүлид бәйрәмендә Фатыйма-Фәридә ханым исеменә салына торган мәктәп өчен 27 сум 88 тиен акча җыелган иде. Мин шул акчаны Кәрәкәшле имамы Батыршин җәнабләренә җибәрдем. Иганә итүче вә ярдәмләшүче ханымнарның һәркаюсына, хосусый рәвештә Шәрифҗамал ханым Алиевага тәшәккер итәм[251].

Чиләбе.

*«Тормыш», 1916, 20 апрель.*

***Вәгыйзә Әминова***

## Зур иганәләр вә имтихан

Казан өязе Казанбаш авылында[252] кызлар мәдрәсәсе салына. Бу илә мәдрәсәдә 38 кыз шәкерт укыды. Март 14ндә имтихан булды. Мәдрәсәнең бинасын салырга түбәндәге затлардан ярдәм бирелде:

Казанлы Садыйк Мусин[253] – 1180 сум;
Петропавелда җыелган – 290 сум;
Гариф Тюменов – 100 сум;
Бакый Шакиров вә Зиннәтулла – 50 сум;

---

[249] Тәшәббескә тырышылу – керешү, эшкә тотыну.
[250] Мөтәвәлли – вакыф эшләре белән шөгыльләнүче.
[251] Тәшәккер итү – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.
[252] Казанбаш авылы – хәзер Татарстанның Арча районына карый.
[253] Мөхәммәдсадыйк Гайсә улы Мусин (1862–...) – II гильдия Казан сәүдәгәре.

Галәх Рәҗәбов, Солтан Әлмөхәммәдов – 50 сум;
Ярулла Мостафа угылы – 50 сум;
Насыйбулла әфәнде – 30 сум;
Гыйсмәтулла әфәнде – 19 сум;
Исемнәрен әйтмәскә теләүчеләр – 274 сум.
Барлыгы – 2043 сум.
Зиннәтулла әфәнде 12 сумлык бер сәгать бирде.

*«Тормыш»тан:*

Халкыбыз арасында хәйрият вә иганә эшләре тәрәккый итүенә[254] бик шатланабыз.

*«Тормыш», 1916, 24 апрель.*

***Фатыйма Адамова***

**Бәян тәшшәкер[255]**

28нче декабрьдә Гарифҗан Халидов квартирында Сәгадәт ханым Сәйфетдинова илә Мөхәммәтгали әфәнде Фәтхетдиновның туйлары мөнәсәбәте илә булган мәҗлестә как-төшкә җыйналган 75 сум акчаны мөслимәләр җәмгыятенә иганә иткәннәре өчен самими тәшшәкеремезне гарыз итеп[256], Сәгадәт ханым илә Мөхәммәтгали әфәндегә бәхет вә сәгадәт[257] телим.

Җәмгыять рәисәсе: Фатыйма Адамова.

*«Вакыт», 1917, 4 гыйнвар.*

**Тәшәккер**

Шушы якын арада зур-зур иганәләр белән үзендә милли тойгылар күрсәткән яшь байларыбыздан Гариф әфәнде Камалов җәнабләре мәктәбем өчен бер шкаф белән йөз сумлык мәктәп әсбаплары вә уку кораллары алып һәдия итте[258]. Без бу нәрсәләргә һава белән суга булган ихтыяҗыбыз кадәр бер ихтыяҗ сизә идек. Шушы ихтыяҗыбызны сизеп, Гариф әфәнде һиммәт[259] кулын сузды. Киләчәктә милләт аналары булачак сөекле шәкертләремезнең дәресләрен тагы да әсаслы[260] сурәттә дәвам иттерүләренә зур сәбәпче булды.

Гариф әфәнденең шундый урынлы иганәсе өчен мәктәпнең һәйәт тәгълимиясе[261] исеменнән самими тәшәккер бәян итәм.

Оренбургта кызлар мәктәбенең мөдирәсе: Зәйнәб Камалетдинова.

*«Вакыт», 1917, 10 гыйнвар.*

---

[254] Тәрәккый итү – алга китү, прогресс.
[255] Бәян тәшәккер – язма рәвештә рәхмәт белдерү.
[256] Гарыз итү – белдерү.
[257] Сәгадәт – бәхет.
[258] Һәдия итү – бүләк итү.
[259] Һиммәт – ярдәм.
[260] Әсаслы – нигезле.
[261] Һәйәт тәгълимия – уку-укыту комиссиясе.

# IX БҮЛЕК

# «МӨСЕЛМАН КЫЗЛАРЫНЫҢ ХӘЛЕННӘН»

### [Рус хатыннары...]

Рус хатыннары тарафыннан ясалган «хатыннарны химая»[1] җәмгыяте киләчәк Думадан Русиядә фәхешне (кызлар илә сату итүне) бетерергә сәбәп була торган низамнар[2] ясауны үтенергә карар бирмешләр.

Рус хатыннарының бу яхшы эшенә мөселман хатыннары да кушылырга тиешле иде; чөнки Казан, Оренбург вә Уфа кеби йирләрдәге мөселманнарның бозыклыкларыннан мөселман хатыннары да күп йөдидерләр.

*«Вакыт», 1907, 20 гыйнвар.*

***«Нажҗия»***

### Хатыннар тарафыннан мөселман Дума әгъзаларына

Мөкаддәс[3] шәригатемез безнең хакымызда фәүкылгадә[4] бер гадаләт[5] вә хәкъканиять[6] изһар итеп[7], безне там[8] хокуклы хөр инсан[9] санаса да, ирләремезнең иң күп кыйсеме[10] улган надан вә залимнары[11] безне җамигъ хокукымыздан мәхрүм итәрәк, тәмам илә җәһаләт[12], әсарәт[13] вә хокуксызлык астына күмеп куймышлардыр. Шәригать буенча, хатыннарның мәсҗетләргә барып гыйбадәт итәргә, меңнәрчә чакрым сәфәрләргә чыгып, хаҗга барырга, базарларга чыгып, үзләре теләгәнчә сәүдә итәргә, һәртөрле сәнәдләр[14] вә вексельләр бирергә һәм алырга вә саир[15] һәртөрле хокукларга малик улдыгыны[16] һәм дә әүвәлге мөселман хатыннарының сестра милосердия булып ирләр илә

[1] Химая – яклау, саклау.
[2] Низам – канун.
[3] Мөкаддәс – хөрмәтле.
[4] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[5] Гадаләт – турылык, гаделлек.
[6] Хәкъканиять – чынлык, дөреслек, турылык.
[7] Изһар итү – күрсәтү.
[8] Там – тулы.
[9] Инсан – кеше, адәм.
[10] Кыйсем – өлеш.
[11] Залим – мәрхәмәтсез, каты күңелле.
[12] Җәһаләт – наданлык.
[13] Әсарәт – әсирлек, тоткынлык, коллык.
[14] Сәнәд – документ.
[15] Саир – башка.
[16] Малик улу (булу) – ия, хуҗа булу.

бергә сугышларга бардыкларыны, йөзләрчә ирләр вә хатыннарны каршыларына җыеп, мәдрәсәлек итдекләрене, шигырьләр, хикәяләр вә саир китаплар язып, мөхәррирәлек вә мөәллифәлек[17] иттекләрене вә пәйгамбәремезнең зәүҗә[18] мөхтәрәмәсенең гаскәр җыеп сугышка бардыгыны вә бүгенге көндә дә Истанбул вә Мисырдагы мөселман хатыннарының үзләре теләгәнчә урамнарда йөредегене, мәсҗетләргә барып намазлар укыдыгыны, вәгазьләр тыңладыгыны, мәктәпләргә йөреп төрле гыйлемнәр, һөнәрләр вә берничә төрле телләр үгрәндегене, гәзитәләр, журналлар чыгардыгыны күрә торып, белә торып, безнең ирләремез, хәтта шәригать белүче дәгъвасында булган муллаларымыз вә хосусый мөселманнар өчен йөз карасы улан кап-кара гөруһ[19] журналларымыз безләрне хәзергедән дә артыграк әсарәткә вә җәһаләткә чумдырмакчы булалар. Этләр дә ачык һавада йөреп, Ходайның якты кояшыны күреп, үзенең җан иясе икәнене белдерәдер. Безне ирләремез үзләренә уенчык итеп тотмакчы булалар, урлаган тавык шикелле безне капчыкларга тыгып, дүрт стена эченә ябып, айларча-елларча яшереп асрамакчы булалар. Кәефләре килгән саен бер хатын алып, безнең нәзек йөрәкләремездән кан агызалар, кәефләре киткән саен кыйнап, орышып, тиргәп, безне чахоткага сабтыралар. Һәр нәрсәнең бер чиге була. Безнең дә бу күрә торган хокуксызлык, золым вә җәберләремезнең бер чиге булырга тиеш. Шәригать хатыннарның хакына тими, анларны теләгәнчә йөрүдән тыймый. Бәлки ирләрне намәхрәмнәргә[20] иман күз илә карамасыннар ди. Караудан тыела алмый торган фасикъ[21] ирләр үзләре бөркәнеп, качып йөрсеннәр. Ирләремезнең төн буенча трактирларда, гостиницаларда йөрүләренә, квартирларда мәхбүбә[22] асрауларына безме гаепле? Бу соң заманда безләр дә укып, азрак дөньяны күрергә, шәригатьне танырга, үземезнең инсан улдыгымызны аңларга башладык. Думага барачак мөселман әгъзалары мөселман хатыннарының тәмам хокукларыны алып бирсеннәр, безне бу золымнардан, әсарәттән вә җәһаләттән коткарырлык низам[23] төзетергә тырышсыннар. Без – милләтнең аналарымыз, без – инсаннарның яртысымыз, милләтнең тәрәккъые[24] вә тәдәннисе[25] безгә табигыйдыр. Әгәр безне бу илә әсарәтдә тотачак әйсәләр, үзләренең дә бер көн әсир, мәхү[26] вә мөнкариз булачакларыны[27] ирләр хәтерләрендә тотсыннар да, Думага барачак мөсел-

---

[17] Мөәллиф – китап язучы, китап төзүче.

[18] Зәүҗә – хатын, кәләш.

[19] Гөруһ – төркем.

[20] Намәхрәм – ерак кардәш һәм бөтенләй кардәш булмаган кеше (шәригать буенча өйләнешергә ярый торганнар).

[21] Фасикъ – әхлагы бозык кеше, начар юлда йөрүче, азгын.

[22] Мәхбүбә – сөелгән, яратылган хатын, сөяркә.

[23] Низам – кагыйдә, устав.

[24] Тәрәккый – алга китү, прогресс.

[25] Тәдәнни – түбән төшү, артта калу.

[26] Мәхү булу – югалу, юкка чыгу, бетү.

[27] Мөнкариз булу – нәселе калмау, юкка чыгу.

ман әгъзаларына мөселман хатыннарының хокукларыны алмаенча кайтмаска кушсыннар. Без шуны таләп итәбез.

*«Вакыт», 1907, 15 февраль.*

***Сәхибҗамал***

**Мөселман кызларының хәлләреннән**

«Бән Уфа өязе «С...» авылының бер мөәзин кызы идем. Әткәм үзенчә бик суфи һәм мөриддер[28], мине яхшы гына төрки танырлык укытты. Мин дә хәл кадәремчә сабыя балаларны укытып гомер кичердем. Соңра үсеп буйга йиткәч, үземә муафыйк[29], күңелемә яраган бер мәгърифәтлерәк егеткә барып, шуның илә бергә укыту илә мәшгуль булырга, халыкка хезмәт итәргә хыял итә башлаган идем. 1908 ел башында яшем 18 гә йитте, төрле йирдән сората башладылар. Мин бичараның үтә бәхетсезлегенә каршы, авылыбыздагы Әхияр дип йөртелә торган мужик мишәрдән яучы килде. Мин боны сиздем вә аның кем икәнлеген яхшы белгәнлегемнән, туп-тугры риза булмаячагымны белдердем, чөнки ул мужик та, өстенә эчкәли дә...

Әткәм бирергә булды. Еглап каршы тордым, тыңламады, акчасына алданып, никах укыткан; никах алдында миннән ризалык сорамадылар да... Боны ишеткәч, аптырап нишләргә белмәдем, хәтта кулыма пычак алып, үз-үземә санчергә хәзерләндем, ләкин кател[30] нәфес хәрам улдыгыннан, кыючылык итә алмадым, артык сабырдан башка хәлем вә ярдәмчем калмады.

Укучылар! Ошбу көндә беләсеңезме минем хәлемне? Ни рәхәт бар инде миңа? Әгәр мин «ир» булса идем, берсен яратмасам, бу көндә икенчесен алырга иркем булыр иде. Ләкин безнең дин башлыклары үзләрен генә, ирләрне генә инсан[31] санап, без мескен кызларны мал урынына саталар, инде кая миңа рәхәт дөнья? Кайда калды гыйбадәтләр кылып, сабак балаларын укытып, моталәгаләр кылып [32] утырулар? Кая калды минем татлы хыялларым? Юк, һәммәсе бетте, йимерелде. Артык язарга кулым бармый... Артык мин бәхетсез, мискинәмен!

Хак мөселман кешеләр! Зинһар балаларыңыз булса, миндәй кылмаңыз, аннан артык янган утка салыңыз!

Бу күргән җәбер вә золымларым, бәхетсезлегем өчен ихтимал ки ахирәттә рәхәтен күрермен; ләкин хәзергесе бик кыйммәт, ахирәттә атамның якасына ябышып, хәзер күргән авырлыкларның интикамын[33] алырлык дия һәр көн ант итәргә мәҗбүрмен.

Язучы мәҗбүрә: Сәхибҗамал. Күз яшьләрем хакына бу хатыма языгыз! Аh!

---

[28] Мөрид – ишан шәкерте, иярчен.
[29] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[30] Кател – үтерү.
[31] Инсан – кеше, адәм.
[32] Моталәга кылу – уку, өйрәнү.
[33] Интикам – үч алу, ачу кайтару.

* * *

Хатын күчердек. Гомере бу әрәм ителгән бер мәзлумәнең[34] кар астына күмелеп куелган бер чәчәкнең зарлары бу илә дәреж ителеп[35] кенә бетәрме? Аның хәле аз гына булса да җиңеләерме? Бу бер мәсьәлә: бу кыз ялгызы гынамы? Юк, бөек Татарстан шундай ук йөзләр-меңнәрчә кызлар илә тулы. Меңнәрчә кызлар, меңнәрчә газиз балалар шулай сатылалар, шулай золым вә җәберләр күрәләр, меңнәрчә чәчәк-гөлләргә аңсыз ата, мәрхәмәтсез ана, инсафсыз рәис руханилар кыравы тиюгә корыйлар. Боларның моң вә зарлары беркемгә ишетелми, болар өчен кайгыручы юк, болар чирлиләр, чахотка булыр, болар йөзләрчә һәлак булалар. [...].

Хөр кызы булмаган милләт тә хөр булмас. Җария[36] аналардан да хөр милләт тумас, хөр гражданлык өчен хөр кыз, хөр аналар ляземдер[37].

Әйдәгез, галәм инсаниятнең иң гүзәл улан ярымының хокукыны мөдафәга[38] мәйданына, шунсыз без дә хөррият[39] рәхәтене күрергә мөстәхикъ[40] булмаячакмыз!

«Юлдаш угылы».

*«Вакыт», 1908, 8 март.*

**Хатын-кыз мәктәпләре**

Хатын-кызны укыту хакында фәйләсуфләр ике бөек фиркагә[41] аерылдылар. Бер фиркасе: «Хатыннар бала тәрбиясе вә йорт карау өчен яратылганнар. Аларның яратылмышлары ошбуның өчен генә улдыгы җәһәтле, аларга гаилә мәгыйшәте[42] вә бала тәрбиясе генә укытырга кирәк. Гали фәннәр илә башларын ватарга тиеш түгел», – диделәр. Бәгъзеләре исә фәннәр тәрбиясенә башка күздән карап, аларны да ирләр илә бер дәрәҗәдә укытуның ляземен[43] сөйли иделәр. Бонларның фикеренчә, бәни бәшәрнең[44] ярымыны тәшкил иткән хатыннар сыйныфы арасында, мәдәният вә хакның сәгадәте өчен иң бөек файдалар китерә алачак истигъдадлар[45] өйрәтергә, бонларны ялгыз ит турау илә бала чүпрәге юуга хәзерли белмәк бөек бер кабахәтлектер. Бу сыйныф: «Хатын-кызлар да ирләр кеби инсан[46]. Теләсәләр нинди хәләл кәсеп илә тамакларын туйдырырга хаклары бар. Бирелә икән аларга сәүдәгәр

---

[34] Мәзлумә – изелгән, җәберләнгән (хатын-кыз).
[35] Дәреж итү – теркәү.
[36] Җария – яшь кол хатын.
[37] Лязем – тиеш, кирәк.
[38] Мөдафәга – үзен саклау, каршылык күрсәтү.
[39] Хөррият – иреклелек, азатлык.
[40] Мөстәхикъ – лаеклы, хаклы.
[41] Фирка – төркем, партия.
[42] Мәгыйшәт – көндәлек тормыш, яшәеш.
[43] Лязем – тиеш, кирәк.
[44] Бәни бәшәр – адәм балалары.
[45] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.
[46] Инсан – кеше, адәм.

булырга, чиновник, мөхәррирә, мөһәндисә[47], табибә вә әмсале[48] булырга, ник юл ачмаска?» фикерен әсас тота[49] иделәр. Франция, Америка халкы ошбу соңгы фикергә иштиракъ итмәктә[50] икән. Немецлар гомумән диярлек беренче фирка тарафдары иделәр. Боңа кадәр немецларда кызларга һичбер чит телләр вә гали фәннәр укытылмый, дөрелфөнүннәргә [51] кызлар кабул ителми. Бонларга бары пакъ гүзәл мөрәббия[52] вә ашчы булырга үгрәтелә иде. Ләкин мәгыйшәт күрсәтдеге, тел дә муафыйк[53] күрелмеш, ялгыз «аналык вә гаилә хадимәсе[54]» ысулы мәдәни мәмләкәтләрдә уңайсыздыр. Мәдәни мәмләкәтләрдә ирләр кызлардан азрак. Кызлар 20гә кадәр кияүгә китәргә тиешле улдыгы хәлдә, ирләр 30–35кә кадәр уйланмыйлар. Күбесе аннан соң да уйланмый.

Боңа мәгыйшәт агырлыгы, кыйммәтчелек, гаскәрлек вә мәктәптә озак укырга мәҗбүр итү кеби эшләр сәбәптер.

Бу хәлнең нәтиҗәсе уларак, кызларга кияү җитми. Кызларның өчтән-бер өлеше үзләрен-үзләре тәрбиягә мәҗбүр булалар. Фәкыйрь егетләргә барган кызлар да, бераз яхшырак торыр өчен, һәркөн берәр җирдә 3–4 сәгать хезмәт итәргә мәҗбүр булалар. Монсыз рәтле тормак мөмкин түгелдер. Ирләр дәрәҗәсендә һөнәр вә гыйлем үгрәнмеш бер инглиз кызы бу вакытта хәләл юл илә кирәк кадәр акча таба ала. Хәлбуки, белеме я тәрбиясенә мөнхәсыйр улган[55] немец кызы аптырап кала. [...]

*«Шура», 1908, №19, б.614–615.*

### Кыйнаучы мөгаллимә[56]

Мөселман җәмгыятенең Банный Озеро кызлар мәктәбенең мөгаллимәсе укучы балаларны кыйный, диләр. Биш-алты баланың кулларын линейка илә шештереп чыгарган имеш.

Бер баланың кулы шешеп, сыдырылып, җәрәхәтләнеп калган диләр. Дөресме, түгелме, боны мөселман җәмгыяте тикшереп, тиешле тәдбирләр кылырга[57] лязем иде; мөгаллимә булса, укытсын да тәрбия бирсен. Кыйнау хулиганнар эшедер. Рус мәктәпләрендә балалар чыбыксыз да укыйлар.

*«Вакыт», 1908, 18 ноябрь.*

---

[47] Мөһәндисә – хатын-кыз инженер.
[48] Әмсал – мисаллар.
[49] Әсас тоту – нигез итеп алу.
[50] Иштиракъ – уртак булу.
[51] Дарелфөнүн – югары уку йорты.
[52] Мөрәббия – тәрбияче хатын-кыз.
[53] Муафыйк – кирәкле, яраклы.
[54] Хадимә – хезмәтче, ялчы.
[55] Мөнхәсыйр улу – ялгыз бер нәрсәгә генә өйрәнү.
[56] Мәкалә «Оренбург хәбәрләре» сәхифәсендә басылган.
[57] Тәдбир кылу – эшне ахырын уйлап эшләү, алдан күрү.

*Фәйзрахман Җиһандаров*

## Хатыннар мәгыйшәтеннән

Боннан мөкаддәм[58] язган бер-ике мәктүбемдә[59] Алма-Ата мөселманнарының бәгъзе хәлләрене бәян итмеш идем. Инде Алма-Ата мөслимәләре хакында да берничә юл язуны мөнасиб күрдем[60].

Алма-Ата хатыннары да башка Азия шәһәрләренең хатыннары кеби голүм, мәгариф вә үз кирәкләре кадәр һөнәр вә мәгълүматтан мәхрүмәләрдер. Бонда сартлык[61] рухы галибрәк[62] булганлыктан, хатыннарның качулары бигрәк ныклы; Алма-Ата хатыннары башка шәһәр хатыннары кеби урамнарга чыгып, буйларын аслан[63] кешегә күрсәтмиләр. Анларда ирләре илә бергә йөрү мотлакан[64] зур гаеп саналадыр. Алма-Ата хатыннары бакча вә урамнарга чыкмый өйдә генә гомер кичерсәләр дә, кием-салым тугрысында ифрат[65] дәрәҗә модага иярәләр. Татарларның аз гына хәллеләре хатыннарын марҗача киендерәләр (баш киеменнән башкасын). Бу модага ияру татар хатыннарыннан сарт вә башка таифә[66] хатыннарына да сираять итә[67] башлаган, алар да шулай аш саен бер формада күренә башлаганнар, диләр.

Алма-Атада кызлар укыту кичен сәнәгә кадәр бер дә юк хөкемендә булган. Кичен сәнә Исхак байның һиммәте[68] илә имам Хөсәен әфәнденең әһлиясе[69] йитмешләп кызны ысул җәдидә илә укыткан. Кызлар укыту өчен Исхак бай үзенең бик әгъла[70] бер өен биреп, мөгаллимәгә мул жалуния тәгаен иткән. Бу елда шулай итсә кирәк.

Алма-Ата мөселманнары кызларыны хөкүмәт мәктәпләренә аслан бирмиләр, анда укытуны яратып та йитмиләр икән. Бөтен Алма-Атада фәүкылгадә[71] уларак хөкүмәт мәктәбендә укып, кичен сәнә гимназия тәкмил иткән[72] ялгыз Фатыйма ханым Бичурова бар. Фатыйма ханым ятимә улдыгы хәлдә, анасы Әшрәфҗамал абыстайның бөек һиммәте[73] аркасында укыган, Әшрафҗамал абыстай киявеннән 3 бала илә тол калган. Үзенең балалар укытуы һәм тегүчигү илә тапкан бар нәрсәсен сарыф итеп, балаларын хөкүмәт мәктәпләренә

---

[58] Мөкаддәм – элек, әүвәл.
[59] Мәктүб – хат, язылган әйбер.
[60] Мөнасиб күрү – яраклы дип табу.
[61] Сарт – Урта Азиядә яшәгән күчмә халыкларның гомуми исеме, үзбәкләр.
[62] Галиб – җиңүче, өстен чыгучы.
[63] Аслан – беркайчан да, һичбер вакытта.
[64] Мотлакан – шиксез, ничек булса да.
[65] Ифрат – чамадан тыш, чиктән тыш.
[66] Таифә – төркем, җәмәгать.
[67] Сираять итү – йогу, бер нәрсәдән икенчесенә күчү.
[68] Һиммәт – тырышлык.
[69] Әһлия – тормыш иптәше, хатыны.
[70] Әгъла – бик яхшы.
[71] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[72] Тәкмил итү – тутыру, җитештерү.
[73] Һиммәт – тырышлык.

биреп тәрбия иткән. Хәзер дә 14 яшьлек бер угылы бу сәнә городской училище тәмам итеп, реальный училищега керү өчен Ташкентка китте. Кече угылы казачий мәктәбендә укый. 18 яшьлек Фатыйма ханым исә хәзердә айга 35 сум алып, Переселенческий управлениедә кятибәлек[74] хезмәтен итә. Әшрафҗамал абыстай балаларын бу хәлгә йиңел генә китермәгән. Ул бу тугрыда бөтен халыктан каргыш алган. Аңа, балаларыңны рус итәсең, диеп бөтен әһали[75] бәйләнгән. Шулай да булса, ул үзенең аңлавы буенча йөреп, һичкемнең каргышыннан курыкмый, һаман балаларын тәрбия иткән. Хәзердә дә бөтен һиммәтен бала тәрбиясенә сарыф кыла.

Хәзердә Алма-Ата кызлар гимназиясендә 3 казакъ кызы бар. Башка таифәдән юк.

Мөгаллим Фәйзрахман Җиһандаров.

*«Вакыт», 1910, 24 август.*

***Г.М.***

**Уку**

Университет тыйббия[76] шөгъбәсе[77] шәкертләреннән Кайбишев әфәнде Шәрык клубы залында[78] «Бездә хатын-кыз мәсьәләсе» хосусында[79] бер реферат (рисалә) укыды. Хөласәсе[80] шу илә:

Заманның үтә баруы илә яңадан-яңа мәсьәләләр чыга, бу мәсьәләләрдән безне иң күп мәшгуль иткәне[81] – хатын-кыз мәсьәләсе булып, инсаният[82] галәменең яртысы хатын-кызлар булганга, бу мәсьәләнең әһәмияте бик зурдыр.

Иң иске заманнарда хатыннар бөтен гаиләгә баш булганнар. Гаилә атасы урынына, гаилә анасы дигән сүз йөргән. «Фәлән кеше фәлән хатынның угылы» дип йөртелгән. Кире фикер тарала башлый. Будда, Конфуций, Гайсә бине Мәрьям, Әфләтүн кебек халык арасында олуг саналган кешеләрнең хатыннар хакында бик начар фикердә, аларны түбән күрүчән, аларның ирләргә кыяс кылынырга[83] да хаклары булмавы тиеш дигән фикердә булганнар вә бу фикерләрне муаффәкыятьле[84] рәвештә таратканнар. Хәзергә чаклы хатыннарның начар, хокуксыз, ирләрдән түбән хәлендә булулары шул вакытлардан бирле килгән. Соңрак хәким вә философлар да – Кант, Шопенгауэр, Ницшеләр вә башкалар хатыннарга ирләр берлән бер хокукта булыр-

---

[74] Кятиб – язучы, секретарь.

[75] Әһали – кешеләр.

[76] Тыйббия – медицина.

[77] Шөгъбә – бүлек.

[78] Шәрык клубы – 1907 елда Казанда оештырыла, татар яшьләренең аралашу клубы.

[79] Хосус – турында.

[80] Хөласа – нәтиҗә.

[81] Мәшгуль итү – эш белән шөгыльләнү.

[82] Инсаният – кешелек дөньясы.

[83] Кыяс кылу – чагыштыру, ошату.

[84] Муаффәкыять – уңыш.

дай булмаган җанварларга караган күз берлән караганнар. Хәтта хатыннарга хокук бирү, ирләр берлән тигез итү тиешлеген икъррар иткәннәре[85] дә (Бебель вә Энгельс кебиләр). Хәзерге хатыннарны балалар дәрәҗәсендә генә санаганнар. Шәрыклылар, хосусан[86] безнең татарлар, мәсьәләгә ноксанлык[87] җәһәтеннән карауда бөтен дөнья халкын уздырганнар ди. Шул фикерләрне исбат бабында Ф.Әмирханның «Татар кызы»ннан[88] берничә җөмләләр укый.

Татарларда хатын-кызга җансыз курчакка караган күз берлән карау фикере моңарчы мисле[89] күрелмәгән дәрәҗәдә түбән вә начар караш, ди. Бәхетсезлеккә каршы, мөхәррир әфәнде бу фикернең таралуына булган сәбәпләрне бер дә күрсәтми генә китә. Алай булса да, бик үк ачык әйтелеп бетмәгән булса да, фәнни бер мөляхәзә[90] тәгъбире[91] лаек булмаган «Кара көч» диеп кенә кителсә дә, ул «кара көч»нең нәрсә икәнен тыңлаучыларның бәгъзе берләре аңлаган сыман күренделәр. Рисаләнең теле бик йиңел вә матур.

*«Вакыт», 1911, 29 гыйнвар.*

***Биби Мәфтуха***

## Семи[92] ургашиларының[93] (хатыннарының) хәле

Яхшылап уйласак, безнең Семи ургашиларының (хатыннарының) хәле бик кызганычтыр. Без, туып-үсеп 17 яшькә йиткәнгә кадәр кызганучыларымыз булса, үземезгә кирәк булган вак-төяк эшләрне үгрәнә аламыз. Кайсыларымыз бу һөнәрләрдән дә мәхрүм булып, 17 яшькә йиткәч, яучы киләдер. Ата-аналарымыз вә башка кардәшләремез кияүнең яхшы иманлыгыны тикшерми, кызның ризалыгына карамый, үзләре сораган акчаны бирсә, һич көфү[94] булмаган кешегә дә тоталар да бирәләр. Кызның үзеннән ризалык алмыйдыр. Бары никах укыр алдыннан гына шаһитлар килеп кыз ризамы диеп сораган булалар. Бонда да башка бер хатынның чаршау артыннан риза диеп кычкыруны ишетеп, кыз риза диеп ялган шәһадәт[95] бирәләр. Хәлбуки[96] безнең шәригатемездә ике якның ризалыгы никахның шартларыннандыр. Шул сүз илә муллалар да никах укыйлар. Яучы килгәч үк, кызның ризалыгыны сорап, белеп куйсалар ниндәй яхшы булыр иде. Никах вакытында

[85] Икъррар итү – тану.
[86] Хосусән – бигрәк тә, аеруча.
[87] Ноксан – кимчелек, җитешсезлек.
[88] «Татар кызы» (1909) – Фатыйх Әмирханның шул исемдәге хикәясе.
[89] Мисле – ошаган, төсле, кебек.
[90] Мөляхәзә – фикер йөртү.
[91] Тәгъбир итү – телдән әйтү, аңлату.
[92] Семи – Казахстандагы Семипалатинск шәһәре турында сүз бара. 2007 елдан шәһәрнең исеме рәсми рәвештә Семей дип үзгәртелә.
[93] Ургаш – хатын.
[94] Көфү – тиң, пар.
[95] Шәһадәт – таныклык.
[96] Хәлбуки – ләкин.

гына сорагач, күп кызлар аталарыннан куркып та риза диярләр. Шуның өчен кызлар үзләренә яучы йөргәнне күп вакытта туй вакытына кадәр белми калып, үкенеч илә кияүгә китәләр. Әгәр кызның үзенең сөйгәне булып, качып чыкса, моны бик зур гаепкә саныйлар. Яхшылап гакылга салып караганда, монда гаеп итәрлек бер нәрсә дә юктыр. Беренче юл кыз аны ярatkanга качып чыккан була. Икенчедә егетнең кызны алырга хәле булмаса, туй кылып алганда әллә ничә йөз сум бурычка батып, фәкыйрь булып кала, бу вакытта ире түли алмаса, хатынына да кайгы була. Шундый бәлаләрдән котылыр өчен, качып чыгудан башка юл юк шул. Семидә туйның расходы зур булганга, бик күп егетләр өйләнә алмый йөриләр. Күрми алгач, күңеленә охшамаса, мөмкин булса аерылышалар. Юкса этле-мәчеле талашып гомер итәләр. Чөнки аерып йибәрсә, бурычы бетмәгән була. Я икенче хатын алыр өчен тагы әллә ничә еллар акча җыярга кирәк буладыр. Шуның өчен бичара егет елый-елый гомерене үткәрәдер. Кызлар барган йирләрендә пешерү-тегү кеби һәммә эшне башкарырга тиештер.

Әгәр әүвәлдән бу эшләрне өйрәнмәгән булса, бичараның хәле бик уңайсыз буладыр. Әгәр өйдә берәр кимпер[97], карчык та булса, ул яшь киленгә кара көн туадыр. Безнең Семи хатыннарының өйләрендә вакыт үткәрерлек һөнәрләре булмаганга, бер-беремезгә кунакка барышып, икемез җыелсак базар, өчәү булсак ярминкә ясыймыз. Әгәр гайбәт телеграмны буш таратучы берәр әби дә килеп керсә, төрле ялган хәбәрләр илә күңелләремезне ачып вакыт үткәрәмез. Туй кеби мәҗлесләрдә бер-беремезне сынап, гаеп итеп утырудан башка эшемез юктыр. Мәҗлестә сүз ачылса, бар хатын берьюлы кычкырганга, тыңлаучымыз булмыйдыр. Шуның өчен, сүзләрне чала ишетеп, соңында булганны булмаган, булмаганны булган диеп, төрле ялганнар таратамыз. Үземезнең бер тиен акча табарга һөнәремез булмаса да, ирләремезнең безне асрар өчен эссе-суык дими, ай йөреп, төрле мәшәкатьләр илә йөргәннәренә илтифат[98] итми, кайткан вакытларында да рәхәт күрсәтмимез. «Шуны ашыйм, моны ашыйм, фәлән хатыны шундай кием кигән, минем киемнең формасы беткән, аны кимим» кеби сүзләр илә колакларыны тондырамыз. Ирләремез сүземезне тыңламасалар, «ашатсак – ашат, ашатмасак – бушат», диюдән дә тартынмыймыз. Яшемез кырыктан узса, гайбәт сатып берәүне берәүгә дошман итәмез. Әби булам, дәва итәм диеп алдап, яшь киленнәрне имгәтеп бетерәмез. Безнең хатыннар өчен әбилек гыйлемене укыта торган урыннарымыз юктыр. Шул гыйлемне укыган башка халыктан булса да, белекле акушеркалар чакырмыйча, бернәрсә белмәгән кимпер, «карчык»ларның әби булуларына риза булып, бик күп мәзлүмәләрнең[99] дөньядан китүләренә сәбәп буламыз. Менә чытырдаган мөселман шәһәре булган Семи хатыннарының хәле. Аллаһы үзе ислах итсен[100].

---

[97] Кимпер (казах теленнән) – олы яшьтәге хатын-кыз, карчык.

[98] Илтифат – әһәмият бирү; игътибар.

[99] Мәзлүмә – изелгән, җәберләнгән, кыерсытылган.

[100] Ислах итү – реформа, үзгәреш кертү.

Биби Мәфтуха Габделкотдус зәүҗәсе[101].

*«Сибирия», 1912, 3 апрель.*

***Карамалы авылында***
***икенче сыйныфта укучы бер кыз***

**Безнең барыш**

Авыллар илә шәһәрләр арасында бик күп аерма булырга кирәк. Шәһәрләрдәге кешеләр иртә сәгать 6дан кич 8ләргә кадәр сатуда, эшче халык та эшләрендә дәвам итәдер. Безнең авылда булса, иртәдән кичкә кадәр урамнарда өелеп-өелеп гайбәт саталар. Шәһәр халкы кичнең яртысыны кыйраәтханәләрдә[102] үткәрдекләре хәлдә, авылларда бөтен төн буенча ун-унбиш егет җыелып, гармун уйнап йөриләр. Кибетчеләрнең яшереп тоткан хәмерләрене биш бәһасе илә эчләренә тутырып, очраган кешене кыйнап, сүгеп йөриләр. Һәр начарлык авыл халкының каннарына сеңгәнгә, күзләре яхшы эшне күрүдән пәрдәләнгәнгә, уку вә укыту эшләрене күрә алмыйлар.

Шулар арасыннан безнең Эстәрлетамак өязе Миркитлин волосте Яңа Карамалы авылында[103] мөхтәрәм Сабирҗан әфәнде Шәмгулов вә Мәхиян әфәнде Солтанбековларның ярдәме илә дүрт сәнәдән бирле ирләр вә кызлар мәктәбе дәвам итеп киләдер. Бу ел ачлык сәбәпле мәктәпләр ябылуга якынлашкан иде. Ирләр мәктәбенә Сабирҗан әфәнде Шәмгулов аерым ярдәм бирдеге кеби кызлар мәктәбедә мөхтәрәм Әхмәтҗан әфәнде Биктимиров, Мәхиян әфәнде Солтанбеков, Садыйк әфәнде Шәмгуловларның ярдәме илә дәвам итеп, март 28ндә имтихан булды. Мәзкүр[104] затларга бик рәхмәтләр укыймыз, мәктәбемез кечкенә булганга, килгән ханымнар сыя алмадылар. Соңра имтиханны мәсҗеткә күчердек. Килгән ханымнар илә мәсҗет тулды, энә ташласак, йиргә төшмәс хәлгә килде. Бу кызларның мәсҗеткә барып имтихан бирүләре надан халыкка бер дә ошамады. Хатын-кыз мәсҗеткә керә башлаган, маржа булганнар, диеп бөтен бозыклыкны безгә яба, игеннәр булмавын да бездән күрә башладылар. Безнең урамга чыгуымызны да бозыклык өчен, диеп, мәктәпкә баруымыздан көләләр. Урамда бүрәнә өстенә утырып «шәригать» төзиләр. Үзләре гомерләрендә бер мәртәбә намаз укымыйлар, язу белмиләр. Иман, исламнан хәбәрләре юк. Көне-төне хилаф[105] рәвештә йөриләр. Шулай да үзләрен [...][106] тәкауви[107] санап, безне укытырга Бубыйдан мөгаллимәләр китертеп, мәктәбемезнең алга китүенә тырышкан мөдиремез мөхтәрәм Кашшаф хәзрәт Ждановка һөҗүмнәр кылып, донос язып

---

[101] Зәүҗә – кәләш.
[102] Кыйраәтханә – уку залы, уку өе.
[103] Яңа Карамалы авылы – хәзер Башкортстанның Авыргазы районына карый.
[104] Мәзкүр – югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән.
[105] Хилаф – каршы, кире, тискәре.
[106] Газетада укылмый.
[107] Тәкауви – куәтләнү, куәт килү, көчәю.

йөриләр. Кашшаф хәзрәт үз мәсләкәтендә[108] сәбат[109] булганга, укуны таратыр өчен һәр авырлыкларга сабыр итәдер. Аның да тарафдарлары бар. Шуның өчен дошманнары каршы килеп, сүз әйтә алмыйлар. Бу көндә башка милләтләр корыда автомобиль, суда пароход, һавада аэропланнар илә йөргәндә, безнең агайлар урамнарда гайбәт сатып, тәмәке тартудан бушый алмыйлар. Шулай ук дөньяның яртысын тәшкил иткән хатын-кызларга Аллаһы йорты булган мәсҗетләргә керергә ярамый микәнни? Моны әрбаб[110] бәян кылса иде. Әгәр дөрес булса, ни өчен мәсҗеткә керүдән безне тыялар? Ирләр, хатын-кыз булса, мәсҗетне фәхешханә хисаплап, шул Аллаһы йортында да үзләрен тыя алмауларына ышанмыйлар микәнни? Үкенеч хәлемез! Бичара хәзрәтемне кызганам. Безне ничек булса да хайванлыктан коткарыр өчен нинди авырлыкларга түзеп, татлы йокыларыннан мәхрүм булып, безне укытырга йөргәне өчен күзләреннән яшь агызып рәхмәт әйтәсе урында, ләгънәтләр укып, донослар язарга йөриләр. Бу эшләр сезгә бит оят, әфәнделәрем!

*«Сибирия», 1912, 29 апрель.*

***Өммегөлсем Камалова,***
***Мәрьям Поташева***[111]

## Мөселман хатыннары хакында саташмагыз

(Идарәгә мәктүб)

Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!

Шушы мәкаләмезне гәзитәгезнең бер почмагына урнаштыруыңызны мөселман хатыннарының шәрәфенә[112] үтенәмез.

«Вакыт» гәзитәсенең соңгы номерларыннан берендә, 959нчы номерында, «Уфада дарелмөгаллимин[113] һәм дарелмөгаллимат[114] тәэсис кылу[115] хакында юбилей комитетына читтән килгән фикерләр»[116]язылган. Шунда хатын-кыз хакында язылган кабахәт сүзләр бик уңайсыз тәэсир итте һәм вөҗданымыз боларга каршы язмый калуны кабул итмәде.

---

[108] Мәсләкәт – дөньяга караш.

[109] Сәбат – фикердә, эштә нык торучанлык.

[110] Әрбаб – ия, хуҗа.

[111] Өммегөлсем Камалова (1889–1957) – Чистай шәһәрендә туып үсә, Петербургта хатын-кызлар өчен югары педагогия курсларында укый. Мәрьям Поташева – Ростов-Дон шәһәреннән, Петербургта медицина курслары студенткасы. Балкан сугышы вакытында икесе дә Төркиядә хәрби лазаретта шәфкать туташы булып эшлиләр.

[112] Шәрәф – хөрмәт, бәхет.

[113] Дарелмөгаллимин – ир-атлар өчен педагогик уку йорты.

[114] Дарелмөгаллимат – хатын-кызлар өчен педагогик уку йорты.

[115] Тәэсис кылу – төзү, оештыру.

[116] «Вакыт» газетасының 1912 елгы 22 апрель санында басылып чыккан «Уфада дарелмөгаллимин һәм дарелмөгаллимат тәэсис кылу хакында юбилей комитетына читтән килгән фикерләр» мәкаләсе турында сүз бара. Кара: 216–224 б.

Нигә ул хәзрәтләр һәрнәрсәне үз аршиннары берлә үлчиләр? Алар бәлки үзләре: «Хатын-кызларны күрсәң, һөҗүм ит», – дип карый торган хайваннардандыр (гафу үтенәмез «хайван» тәгъбирен кертүемезгә. Мондый фикердәге кешеләрне адәм дип булмыйдыр).

Нигә алар үзләренең шундый фикерләрен дөньяга чыгарып, бөтен инсафлы кешеләрнең йөзләрен кызарталар? Алар үзләре шул инсафсыз сүзләре берлә хатыннарның йөзенә кара якмакчы, гөнаһсыз кешеләрнең өстләренә былчырак атып, аларны буямакчы булалар. Без, хатыннар, һичбер вакытта сарыклар түгелмез. Гәрчә кайсыларымыз шул явыз хәзрәтләрнең һәм башка шундый фикердәге ирләрнең корбаннары булып, иң зәгыйфь хайван дәрәҗәсенә төшсәләр дә, бу да безнең гөнаһ түгел. Шул ук «гакыллы баш» хәзрәтләрнең хатыннары акчасыз хезмәтче, ирләр хозуры өчен яратылган курчаклар, дип караучылардан килгән бәлаләрдер. Шуларның ук гөнаһ шомлыклары өчен хатыннар мәшәкать чигәләр. Алар моның өчен аз гына да уңайсызланмыйлар, киресенчә, һаман үзләренең бозык уйлары белән хатын-кызны тәхкыйрь итәләр[117]. Хатын-кызның рухларындагы гыйzzәтне[118], яхшы тойгыларны аяклары берлә таптап, аларны «хайваннар», «куйлар» диләр. Гыйффәтне биткә ябылган берничә тиенлек пәрдәдә, тугрылыкны дүрт стена арасында ябылып торуда диеп күрсәтмәкче, шуңар бөтен галәмне ышандырмакчы булалар. Бу хәзрәтләрдә аз гына да әдәп вә вөҗдан дигән нәрсәләр юк микәнни?!

Хәзрәт, һәммәсеннән дә уздырыйм ди бугай: «Бу сүзем дарелмөгаллиматны нәфи[119] түгел, бәлки гараз[120] шөбһәдер», – ди. Кулыңыздан килсә, бик нәфи булыр иде дә, анысы сезгә тапшырылмаган. Сез хатын-кызны алга йибәрмәк өчен кул-аяк берлә каршы торасыз. Сез аларны курчаклык хәленнән чыгарасыңыз килми.

Инде җитәр, бик күп изелдек. Бик күп сезнең саташып сөйләгән сүзләреңезне тыңладык. Хәзер үземездә дә тел бар.

Бу тугрыда никадәр язсаң да, никадәр кычкырсаң да, йөрәкне тырнаган уңайсызлыклар аз гына да кимемәс. Хәзергә башка ханымнарга, туташларга каләмемезне биреп, шуның берлә тәмам кыламыз. Шаять башкалар да хәзрәтләрнең бу кабахәтлекләренә каршы авыз йомып калмаслар. Үз хөрмәтемезне саклау һәммәмезнең вазыйфамыздыр.

Петербург.

*«Вакыт», 1912, 6 май.*

---

[117] Тәхкыйрь итү – хурлау, мыскыл итү.
[118] Гыйззәт – кадер, хөрмәт, мәртәбә.
[119] Нәфи – кире кагылган.
[120] Гараз – вакытлы хәл.

***Асия Хәирова***

**Мөслимәләр хәленнән**

Әстерханда Шакир хаҗи Вильдановның кызы Сара ханымның Чистай байларыннан Ибраһим әфәнде илә гакыйд[121] никахлары булып үткән иде. Шуннан берничә һәфтәләр[122] узгач, Сара ханым шәрәфенә[123] кызлар чакырылды. Мин дә сәгать берләрдә чакырылсам да, Әстерхан халкының сәгать 12 дә чакырылса да, сәгать 2–3кә барганлыкларын белеп, 2 сәгать ярымда барып кердем. Кергәндә залда бик купшы киенгән 5–6 кыз утырып торалар иде. Мин килеп, кызлар берлә күрешеп чыкканнан соң, бер буш урын күреп, барып утырдым. Утырып ярты сәгать чамасы һичкем берлә сөйләшми алдыма гына карап тордым. Бәгъзән[124] күргәләгән кызларга карап аз-аз гына елмаеп кына ала идем. Тагын утырдык. Ике-өч гимназистка, дүрт-биш мөгаллимә һәм укучы кызлар җыелды.

Бу мәҗлестәге кызлар һәм мөгаллимәләрнең күбесе илә таныш булганлыгымнан, бик сөйләшәсем килми иде. Ләкин, бер яктан, мөгаллимәләр безнең кеби кечкенә укучылар илә, икенче яктан, шәрикләремнең[125] күбесе, бик бай булмасалар да, өстләрендә модный киемнәр, башларында әллә нинди, нугайча әйткәндә, «баҗаклы калфаклар» булганлыктан, күбесе минем берлә сөйләшергә теләмәдекләреннән, сүз дәшмәенчә тора идем.

Ниһаять, элеккедәге шәрикемнән туташ, «Кая да булса укыйсызмы, әллә башка бер-бер эш эшлисезме?», – дип соравыма каршы, горурланып кына: «Юк, беркайда укымыйм, – диеп, сүзне кыска гына кисте.

Мин аңардан да бер рәтле җавап ала алмавымнан бик кайгырып, эчемнән: «Кайчан гына, Ходаем, безнең татар кызлары да кеше берлә ачык кына сөйләшергә үгрәнерләр икән», – дидем. Ахырында, тик тору сәбәпле, тешләрем бер-берсенә ябышып камашты, яңакларым талды. Үземдә бер хәлсезлек сизә башладым.

Бераздан соң мөгаллимә Абруй ханым Гыйльманова килеп керде. Мөгаллимә һәм башкалар илә күрешкәннән соң, нәүбәт[126] миңа да җитте. Минем белән дә күреште: «Монда шәкертләр килгән икән, вә ни өчен бер дә сөйләшми болай тын утырасыз? – дип сорады. Ләкин аның бу сүзенең тәэсире күрелмәде. Тынычлык элеккечә дәвам итте.

Бераздан соң кулына нindидер ике гәзитә тотып керде вә: «Туташлар, мин үземезнең мондый мәҗлесемне тәнкыйть итеп гәзитәгә язмакчы идем, әмма миңа кадәр язып өлгергәннәр икән. Дөрес, безнең Әстерхандагы бу мәҗлесемезне язмаганнар, бәлки Хатимә имзалы бер ханым Мәскәүдәге бер

[121] Гакыйд – килешү.
[122] Һәфтә – атна.
[123] Шәрәф – хөрмәт.
[124] Бәгъзән – кайвакыт.
[125] Шәрик – бергә укыган кеше.
[126] Нәүбәт – чират.

туй мәҗлесен язган, ләкин безнекен атап язса да, башка төрле чыкмас иде, безнеке дә тәмам илә шуның илә бердер», – диде вә мәкаләнең мөндәриҗәсен[127] әйтте.

Соңра тагын сөкүт[128] дәвам итте. Бераздан «Баюлдым» дигән уен уйный башладык. Уен бетте. Чәйгә утырдык. Тагын сөкүт, тагын сөкүт. Ни гыйлем вә мәгарифкә даир вә ни дә азрак күңел ачарлык уен-көлкегә даир бер сүзләр булсын ла! Авызларымыз бары аш капканда, чәй эчкәндә генә ачылалар иде.

Кич сәгать 7 ләрдә өемезгә кайттым. Ифрат дәрәҗәдә кәеф бозылган, баш авырта, күңел болгана, эч поша. Биш сәгать вакыт зерә юкка әрәм булган, мондый мәҗлес әллә кайда бер генә булса, язып та тормас идем. Безнең Әстерханда кызлар мәҗлесе күп була; еш була. Ләкин, мәгаттәәссеф[129], барысы да шундый була. Барысыннан да кәеф бозылып, хәзсезләнеп кайтырга туры килә.

Әстерханда «Кара мәсҗет» мәктәбенең шәкертләреннән Асия Хәирова.

*«Вакыт», 1914, 3 апрель.*

## Казанда хатын-кыз галәме

Җурналымызның бу номерыннан башлап, «Казанда хатын-кыз галәме» дигән бер бүлек ачамыз. Анда һәр 15 көн эчендә Казан хатын-кызлары арасындагы әһәмиятле хәбәрләр, аларның милли һәм мәдәни эшләремез хакында хәрәкәтләре вә гайре хатыннарга гаид[130] Казан хәбәрләре язылып барыр.

Җурналымызны укучылардан: Казанда хатын-кыз галәмендә мөһим хәбәрләр булганда, идарәмезгә хәбәр бирүләрене үтенәмез.

*«Сөембикә», 1914, №1, б.19.*

***Сәлимә Ягъкубова***[131]***,***
***Мәхфузә Максудова***[132]

## Хатыннар тавышы

Петербургта укый торган курсисткалардан Сәлимә Якубова һәм Мәхфузә Максудова имзасы белә съездга ошбу мәфһүмдә[133] ике гариза тапшырылган:

---

[127] Мөндәриҗә – эчтәлек.

[128] Сөкүт – дәшми тору.

[129] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.

[130] Гаид – бәйләнешле.

[131] Сәлимә Ягъкубова – Петербургтагы Педагогия курсларында укый (1912 елдан), 1917 елда Казанда узган Бөтенроссия мөслимәләренең беренче съездында катнаша, Баку шәһәрендә мөгаллимәлек итә.

[132] Мәхфүзә Максудова – Петербургтагы Педагогия курсларында укый (1912 елдан).

[133] Мәфһүм – аңланган, төшенелгән нәрсә.

I. Никах турында.

1.Өйләнәчәк кыз белән егетнең кулларында сәламәтлекләренә, йогышлы авырулары юклыгына даир[134], никахтан 15 көн әүвәл доктордан алган шәһадәтнамәләре[135] булырга тиеш. Әгәр никях укучы имам бу хосуста шөбһәгә төшсә[136], никях укыячак кешеләрне табиб хозурында мөгайян иттерә[137] белү хакына малик булсын[138], шәһадәтнамәләре булмаган кыз белән егеткә имам никах укымасын.

2.Мәҗлестә кыз белән егет үзләре хәзер булып никахка риза булуларын үзләре сөйләгәч кенә никах укылсын.



Сәлимә Ягъкубова

3.Никах укый торган затларны кыз белән егетнең никахка гаид вазыйфаларын, бурычларын яхшы белә торган булуларын аңлагач кына аларга никах укырга мәҗбүр ителсен.

Никахка гаид вазыйфалар мәҗлесләрдә халыкка ана телендә имамнар вә әгъзалар тарафыннан сөйләнсен. Бу вазыйфалар кыз белән егеткә имам белән абыстай тарафыннан өйрәтелү мәҗбүри кылынсын. Никах көнне никахның шарт вә вазыйфалары тагы бер кат имамнар тарафыннан сөйләнү мәҗбүри булсын.

4. Әгәр никахның шарт вә вазыйфалары ир белән хатынның берсе тарафыннан йиренә йиткерелмәсә, икенчесенең тегенең ризалыгын алмыйча аерылырга хакы булсын.

5. Имамнар яше йитмәгән кызларга никах укымаска мәҗбүр ителсеннәр (мондый никахлар күбрәк башкортлар вә кавказлылар арасында була). Яше йитмәгән кызга никах укыган имам белән разый булган ата-ана мәсьүл[139] булсыннар.

II. Мөгаллимәлек мәсьәләсендә.

1. Мөгаллимәләрнең хаклары тәэмин ителеп, аларга шәһадәтнамә бирелсен.

Аз тәхсил күргән[140] мөгаллимәләремез тарафыннан сүэ истигъмаль[141] булмасын өчен, шәһадәтнамә мәсьәләсен бик игътибар белән хәл итәргә тиеш.

[134] Даир – караган.
[135] Шәһадәтнамә – таныклык язуы, диплом, аттестат, белешмә язуы.
[136] Шөбһәгә төшү – шикләнү.
[137] Мөгайян итү – билгеләү.
[138] Малик булу – ия булу.
[139] Мәсъүл – җаваплы, соралган.
[140] Тәхсил күрү – белем алу.
[141] Сүэ истигъмаль – урынсыз куллану, явыз ният белән куллану.

2. Мөгаллимәләр өчен җәйге курслар ачылсын.

3. Ысул тәгълимнән[142] яхшы хәбәрдар мөгаллимәләр йитештерү өчен дарелмөгаллимат[143] ачылсын.

Бик мөһим мәсьәләләрне хәл кылу өчен җыелган бу съездга муаффәкыять[144] теләп, мөселман хатын-кызлары хакында бу мәсьәләләрне дә игътибарга алуын үтенәмез.

***Идарә:***

Мәхфузә, Сәлимә туташларның бу тәшәббесләрене[145] тәбрик итми узып булмыйдыр. Съездда бу тавышларга күпме урын бирерләр – анысын хәзердән бернәрсә дә әйтеп булмый. Безнең белүемезчә, ир белән хатын арасында хәсән могашәрә[146], күркәм тормыш өчен мотлака[147] бу маддәләрнең кабул ителүе, шуларны канун тәхетенә кертү ляземдер. Әлегә кадәр хатыннарның җәбер-золым күрүләре араларында булган хокук-вазыйфалар чикләнгәнлектәндер.

Инде ханым вә туташларымыз тавышларыны ишетергә вакыт йитте. Съездга бу мәсьәләне әһәмиятсезгә санап калдырырга тиешле түгелдер.

*«Сөембикә», 1914, №17, б.15–16.*

**Аянычлы мөгаллимәләремез**

Татарның яңа хәяты үзенең кодрәтле тәэсире белән мөгаллимә аталган бер сыйныф – ханым вә туташларны да мөгаллимнәр белән бергә үк мәйданга чыгарды. Бу сыйныф эшкә тотынмаганда, безнең гыйльми һәм иҗтимагый хәятымыз ышанычсыз бер нигезгә бинаэн кылынып[148], истикъбалемездән[149] бер нәрсә дә өмет итә алмас, өмет итсәк тә, бушка чыгарыр иде. Шул табигый юл белән моннан 30 еллар элек сибирияле Хәнифә ханымнардан башлап, мәйданга атылган мөгаллимәләр сыйныфының татар мәдәниятенә, татар хәятенә тәэсире бик зур булды, мөгаллимәләребез Финляндияләргә, Хивә вә Бохараларга, хәтта Кытай эченә кадәрле кереп, мәктәпләр ачтылар, тырыштылар, укыттылар. Алар һаман да шул юлларында дәвам итеп киләләр, үзләренә каршы килгән тәгассыб[150] коймаларын җимерер өчен зур иҗтиһадларын[151] аямыйлар.

[142] Ысул тәгълим – укыту методлары.
[143] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар әзерли торган уку йорты.
[144] Муаффәкыять – уңыш.
[145] Тәшәббес – инициатива.
[146] Могашәрә – бергә булу, дуслыкта яшәү.
[147] Мотлак – шартсыз, шарт белән билгеләнмәгән.
[148] Бинаэн кылыну – нигезләнү, таяну.
[149] Истикъбаль – киләчәк, булачак.
[150] Тәгассыб – фанатизм.
[151] Иҗтиһад – тырышлык кую, тырышу.

Бәгъзе бер шәһәр вә байтак авылларда халкымыз, хәтта бәгъзе бер руханиларымыз тарафыннан күрсәтелгән гакыс[152] хәрәкәтләр, мәктәпләрнең хифзыссыйхәткә[153] муафыйк[154] булмавы, вазыйфаларының азлыгы химаясез[155] калган бу сыйныфны бик зур мәшәкатьләр йөкләргә вә шул нәтиҗәдә мөгаллимәлек юлында төрле хәстәлекләргә сабышып, шәһид булырга[156] яки өметсезләнеп, мөгаллимәлектән ваз кичәргә мәҗбүр итә.

Мөгаллимәләрдән идарәмезгә бик аянычлы мәктүбләр[157] килеп тора, хәлләреннән, халык вә руханиларның игътибарсызлыкларыннан шикаять итәләр[158]. Бу мәктүбләрнең берсе Бөгелмә өязе Сакы[159] авылында мөгаллимә Зәкия туташ Шакирия мәктүбе булып, ул: «Рөшди[160] сыйныфларда укыганнан соң, Бәләбәйдә ахунд Җамалетдин хәзрәт Хурамшин[161] идарәсендәге курста укып, шәһадәтнамә[162] алдым. Мөгаллимәлеккә һәвәсем зур булдыгыннан, укытыр өчен тирә-ягымыздагы авыллардан дәгъват[163] көтә башладым. Август вә сентябрьләр үтеп китте, берничә йиргә мөрәҗәгать тә итеп карадым, дәгъват ителмәдем, минем хезмәтеме кабул итүче табылмады. Ниһаять, Бөгелмә өязе Бакый[164] авылына барып, Мөхәммәдгали һәм Миңнегали Абушаминнәр дәляләте[165] буенча кышына 10 сум түләп фатир алдым. Яктырту, җылыту мәсарифе[166] дә, табигый, үз өстемнән булачак. Беренче октябрьдә 25 кызга дәрес укытырга тотындым. Кыз башына кышына 1 сум салсам да, моның яртысы да җыелмады. Хәзер ни эшлим инде? Чигеш, бәйләү эшен белсәм дә, матдәсене[167] алырга акчам юк. Минем кебек аптырап калган мөгаллимәләр байтак күренә, тәкрар әйтәм[168], мин ни эшлим инде?» – ди.

Уфа мөгаллимәләреннән Җиһан Йосыфия үзенең бер авылдагы иптәшеннән кызганычлы мәктүб алганнан соң, идарәмезгә бер мәкаләчек язып йибәргән һәм иптәшенең мәктүбенең бәгъзе бер урыннарын күчергән. Мәкаләдә авыл мөгаллимәләренең вазыйфалары аз булып, тормышлары авыр-

---

[152] Гакес – каршылы, капма-каршылык.
[153] Хифзыссыйхәт – сәламәтлек, гигиена.
[154] Муафыйк – яраклы, туры килгән.
[155] Химая – яклау, саклау.
[156] Шәһид булу – корбан булу.
[157] Мәктүб – хат, язылган әйбер.
[158] Шикаять итү – зарлану.
[159] Текстта шулай күрсәтелгән. Фаразлавыбызча, Якый авылы турында сүз бара.
[160] Рөшди – урта.
[161] Хурамшин Җамалетдин Хурамша улы (1877–1937) – мөгаллим, Бәләйбәй шәһәре ахуны, I Дәүләт Думасы депутаты.
[162] Шәһадәтнамә – таныклык, свидетельство.
[163] Дәгъват – чакыру, өндәү.
[164] Текстта шулай күрсәтелгән. Фаразлавыбызча, Якый авылы турында сүз бара.
[165] Дәляләт – юл күрсәтү, өйрәтеп күрсәтү.
[166] Мәсариф – тотылган акчалар, чыгымнар.
[167] Матдә – әйбер.
[168] Тәкрар әйтү – кабатлап әйтү.

лыгыннан, надан халык тарафыннан төрле ифтира[169] вә бөһтаннар[170] белән пычратылуларыннан иртән сәгать 7–8 дән башлап, көн батканчы укытырга мәҗбүр булуларыннан шикаять итәләр. Халык, бала никадәр күп укыса, шулкадәр гыйлем ала дип игътикад кылганлык[171] сәбәпле, алар тәрбия кануннарына мохаләфәт итәргә[172] мәҗбүрләр, ди.

Менә шундый кызганычлы мөгаллимә мәктүбләре идарәмезгә һәрвакыт килеп тора.

Без үз тарафымыздан шуны гына әйтә аламыз: милләтнең хатын-кызы, бигрәк тә мөгаллимәләре, лаек булган дәрәҗәсенә мендерелеп, ихтирам ителмәсә, ул милләт дөньяда яши алмый, бу көнме, иртәнме, ул үзенең милли мәүҗүдияте[173] белән исәпләшәчәк. Бу иҗтимагъ фәнендә исбат ителеп, тәҗрибә кылынган бер хакыйкать. Шәрыкның хәстәлеге, татарның артка калуының сәбәпләре менә шуннан эзләнергә тиеш. Шәһәр вә авыллардагы ил агалары, хосусан[174] руханиларымызга шул фәнни хакыйкатьне күздә тотып, хатын-кыз тәрбиясенә әһәмият бирүләрен, мөгаллимәләрне лаек булган дәрәҗәләренә күрә, ихтирам итүләрен үтенәмез.

Милләт хатын-кыз вә мөгаллимәләре белән генә тәрәккый итәчәк[175], алар адәм рәтле булмаганда, милли мәүҗүдиятемезне саклый ала алмаячакбыз.

Ил агалары, сез шуны хәтерегездән чыгармагыз!

*«Тормыш», 1915, 18 март.*

***Заһидә Бурнашева***

## Мәрхәмәт наменә[176] бер үтенеч

Бөтен татар дөньясын каплап алган аңсызлык, наданлыклардан хасыйл булган тәгассыб[177] вә кара көч белән тартышырга керешдегем вакытыннан игътибарән, мин бик авыр дәверләр кичерә килдем. Минем мәталибем[178] уку, мәгърифәт хасил кылу булганлыктан, бу мөкаддәс[179] вә фарыз[180] бер эшкә, бөек матлабка[181] каршы килүчеләр булмавы лязем[182] булса да, яшьтән тәрбия

[169] Ифтира – яла ягу, берәү өстенә ялган гаеп ташлау.
[170] Бөһтан – яла, кеше өстенә сөйләнгән ялган сүз.
[171] Игътикад кылу – чын күңелдән ышану, инану.
[172] Мохаләфәт итү – каршы килү.
[173] Мәүҗүдият – барлык, бар булу.
[174] Хосусан – бигрәк тә, аеруча.
[175] Тәрәккый итү – алга бару.
[176] Нам – исем.
[177] Тәгассыб – фанатизм.
[178] Мәталиб – теләкләр, максатлар.
[179] Мөкаддәс – изге, иң мөһим.
[180] Фарыз – ислам дине буенча, һәрбер мөселман эшләргә тиеш булган мәҗбүри гамәлләр.
[181] Матлаб – теләк, максат, омтылыш.
[182] Лязем – тиеш, кирәк.

күрмәгән анам вә иске фикерле атам тарафыннан минем юлыма ниһаясез киртәләр, калын-калын сәдләр[183] куелды.

Айлар, еллар буе аларга сүз аңлатырга тырышсам да, һичбер нәтиҗә чыкмады. Ниһаять минем яшерен имза илән матбугатка чыккан шигырь кисәкләрем аларга мәгълүм булгач, минем өстемә кыяматләр купты. Әллә нинди фаҗигалар чыкты. Әстерхан имамы Салих мулла Галимбековның шәригать исеменнән сөйләгән сафсаталары, әкиятләре аркасында ахырда мин анам тарафыннан тәмамән өйгә ябылдым. Минем бар нәрсәләрем анам тарафыннан гасбән[184] алынып бикләнде. Китапханәдәге китапларым яндырылды, язу әсбапларым кулымнан тартып алынды. Өйдән чыгуым, яхуд башкаларның миңа килүләре мөмкин булмады. Дусларым илән мохабәрәдән[185] киселдем. Шул зинданда ничә айлар буе хаксызга җәберләндем, тиргәлдем, сүгелдем. Әллә нинди газаплар арасында изелдем.

Аларның бу мөгамәләләреннән максатлары мине укуга булган һәвәсемнән кайтару иде. Ләкин шулай да күкрәгемдәге мөкаддәс[186] теләгемә аларның куллары йитешә вә андагы изге йолдызларны өзгәләп ташларга булдыра алмадылар. Ахырда, август 12сендә, бар нәрсәдән күз йомып, Җәнаб Аллаһы хәзрәтләренә өмет багладым да, аларның йортларын ташлап чыгарга мәҗбүр булдым. Чыкканым вакыт бер кабат кием һәм дә полиция рөхсәте белән чыктым. Минем йорттан һичбер нәрсә алып чыкмавымны шундагы кешеләрнең күрүе һәм дә анамның: «Ул минем акчамны урлап чыга торгандыр!» – дип полиция алдында мине тентеп тә миннән һичбер нәрсә таба алмавы минем вөҗданымның ни дәрәҗәдә пакъ икәнлеген белдерсә кирәк.

Ләкин шулай була торып та, иртәсе көн анам: «Кызым минем нәрсәләремне угырлаган», – дип, приставка заявление биреп, миңа караклык белән төһмәт итте[187]. Икенче көндә тагын, кызым фәхешханәгә бара, Төркиягә кача, дип волостной правлениегә заявление бирде. Һәркөн шундый бөһтан[188] ифтираларны[189] хави[190] заявленияләр бирә барды. Минем танышларымда һәм үз квартирамда тентү ясатты. Табигый, болар һәммәсе миңа чеп-чи ифтира булганлыктан, һичбер гаепле нәрсә табылмады. Бер тарафтан миңа шундый адәм чирканырлык, күңел болганырлык ифтираларны яудыруы илән бәрабәр, икенче тарафтан миңа кешеләр йибәреп, мине тагын да кире үз йортына чакырды. Һәм алар аркылы миңа: «Минем бу ифтираларым тик аны өйгә кире кайтару өчен, укырга бара алмавы өчен генә», – дип әйттерде.

Ләкин бондый җәберләүләр, рәнҗетүләр, ифтиралардан соң аңа кире кайтып керүне мин булдыра алмадым.

---

[183] Сәд – киртә, койма.
[184] Гасбән – талап, көчләп.
[185] Мохабәрә – хәбәрләшү.
[186] Мөкаддәс – изге, иң мөһим.
[187] Төһмәт итү – яла ягу, гаепләү.
[188] Бөһтан – яла, кеше өстенә сөйләнгән ялган сүз.
[189] Ифтира – яла ягу, берәү өстенә ялган гаеп ташлау.
[190] Хави – эченә алган, эченә алучы.

Ниһаять, аның миңа ифтиралары чиктән ашты. Аз гына миңа якынрак кешеләрне, һәм мине йортларына вә квартирга кабул итүчеләрне төрлечә тиргәде, сүкте. Ахырда шуның тәэсире белән миңа Әҗедә[191] квартир табылмады. Соңыннан Әҗедән 12 чакрым ераклыгында булган Багданова авылына[192] һиммәтле[193] вә тәрәккыйпәрвәр[194] сәүдәгәрләрдән Хөсәен әфәнде Ширинский[195] гаиләсе тарафыннан чакырылып, шунда үземә мәлҗаэ[196] таптым. Хәзер шул гаиләдә эшемнең ниһаятен көтеп торам. Көннән-көн анамның ифтиралары үсә бара. Читкә чыгарга (укырга барырга) волостной старшина паспорт бирми[197]. Әҗедә үзләрен тәрәккыйпәрвәр, халык хадиме[198] итеп танучы агай-энеләр; аңлырак сыйныфтан саналганнарымыз тарафыннан миңа һичбер ярдәм кулын сузучы, вөҗдан вә мәрхәмәт наменә хакыйкатьне сөйләр өчен авыз ачучы юк.

Минем гөнаһсызлыгымны, языксызга вә золыманә бер сурәттә түктерелгән күз яшьләремне күрә торып та, минем золымнар тырнагы арасында чытырдавымны ишетеп тә, миңа Әҗе тарафыннан бер мәрхәмәт иясе чыгып, үзенең шәхси мәнфәгатьләреннән, шкурасыннан вөҗдан вә инсаниятне артык күрүче табылмагач, үземнең рәнҗетелгән йөрәгемне, мәзлуманә[199] түгелгән яшьләремне матбугат аркылы милләткә аңлатып, үзенең хаксызга җәберләнгән вә уку юлында бу кадәр җәһәннәм газабы күргән бер кызын химаяга[200] милләтне чакырам.

Эссе кавем сәхрәләрендә сусызлыктан гали бөтен йиргә егылган, ерткычлар алдына ташланган бер химаясез, көчсез кошчык кебек җан көче белән соңгы талпынуларын талпынучы бер мәзлумәнең[201] рәнҗетелгән йөрәгеннән өзелеп чыккан: «Ярдәм! Ярдәм!» дигән соңгы сулышларына нинди булса да берәр мәрхәмәт иясе килеп ирешер өмете белән, бу мәкаләне милләт нәзарына[202] тәкъдим итәм. Йөрәкләрендә инсаният[203] хисе булган зат мөхтәрәмнәренең вә, хосусан[204], мөселман юристларымызның җитди ярдәм кулларын, химаяләрен көтәм.

---

[191] Әҗе – Рязань өлкәсендәге авыл. Заһидә Бурнашеваның туган авылы.
[192] Богданово авылы – Рязань өлкәсендәге авыл.
[193] Һиммәт – тырышлык.
[194] Тәрәккыйпәрвәр – алга китү, прогресс яклы кеше.
[195] Хөсәен бине Җәгъфәр Ширинский – Богданово авылы сәүдәгәре.
[196] Мәлҗаэ – сыена торган урын, котылу урыны.
[197] «Мин хәзер зам каршында совершеннолетний булып танылсам да, югарыдагы ифтираларга ригаэ миңа паспорт бирмиләр» (Астөшермә мәкалә авторы тарафыннан бирелгән).
[198] Хадим – хезмәтче, хезмәткәр.
[199] Мәзлуманә – рәнҗетелгән сыман, кыерсытылган төстә.
[200] Химая – яклау, саклау.
[201] Мәзлумә – изелгән, җәберләнгән, рәнҗетелгән хатын-кыз.
[202] Нәзар – караш, карау.
[203] Инсаният – кешелек дөньясы.
[204] Хосусан – бигрәк тә, аеруча.

Миңа мөрәҗәгать өчен адресым: Просяныя-Поляны Тамб.губ., село Багданова, дом Хусаина Ширинскаго, для Загиды-Гыффата Бурнашевой.

Милләттән ярдәм көтеп: Заһидә Бурнашева (Гыйффәт).

***«Тормыш»:***

Гыйффәт туташның бу мәктүбе безнең эчемездә 20нче гасырда шәригать наменә эшләнгән фаҗигаләрнең бер копияседер. Әҗе кебек мөселманы вә голәмасы[205] күп булган бер шәһәрдә күз алдында рәнҗетелгән шундый бер мәзлумәнең ярдәменә йитешмәү дин вә иҗтимагый нәзарендә[206] зур бер гөнаһтыр.

Без Гыйффәт туташның ай-вайларына чын күңелемездән иштиракь итеп[207], милләтемезнең аңлы сыйныфын бу мәзлумәгә ярдәмгә чакырамыз. Милләткә яңа йитешеп килмәктә булган үзенең бердәнбер шагыйрәсен тәрбия итеп үстерү – зур бер бурычтыр. Шагыйрәне тәрбияләп, аны укытып, чын шагыйрә итәр өчен, милләтнең аңлы вә мәрхәмәтле сыйныфына бу көннән ярдәм кулын сузу ляземдер[208]. Гыйффәт туташны укытуны үз өстенә алучы мәрхәмәтле бер һиммәт иясе булса, бигрәк тә мөнасиб[209] булыр иде. Әгәр андый һиммәт иясе табылмаса, матбугат васитәсе[210] илә иганә җыеп булса да, Гыйффәт туташны тәрбияләү ляземдер.

*«Тормыш», 1915, 10 сентябрь.*

***Заһидә Гыйффәт***

**Гыйффәт туташ мәктүбе**

Өстемә ыргытылган ифтира[211] вә бөһтаннардан[212] аруланып, паспорт алып, Мәскәүгә килүдер. Бөһтаннардан аклануыма вә авылымыздан берничә чакрым ераклыкта булган ике инсаниятле[213] зат ярдәм иттеләр. Шуларның химаяләре[214] аркасында хакыйкать хәл кем тарафында идеге ачык мәгълүм булды. Биш мең нөфүс[215] мөселманы булган Әҗедә хакыйкать вә шәфәгать наменә[216] бер сүз әйтүче булмавына тәгаҗҗеб[217] илә читтә торып кул сузган

[205] Голәма – галимнәр.
[206] Нәзар – иътибар.
[207] Иштиракь итү – уртак эшләү, катнашу.
[208] Лязем – тиеш.
[209] Мөнасиб – яраклы, яраклылык.
[210] Васита – арадаш, ике арада эш йөртүче.
[211] Ифтира – яла ягу, әләк.
[212] Бөһтан – яла, ялган сүз.
[213] Инсаниятле – кешелекле.
[214] Химая – матди ярдәм.
[215] Нөфүс – кешеләр, халык.
[216] Нам – исем.
[217] Тәгаҗҗеб – гаҗәпләнеп.

бу инсаниятпәрвәр[218] әфәнделәргә самим[219] калебтән[220] тәшәккер итәргә[221] бурычлымын.

*«Вакыт», 1915, 19 сентябрь.*

***Сабатзадә***

**Заһидә Гыйффәт туташ маҗаралары мөнәсәбәте илә**

«Тормыш» гәзитәсенең 318нче номерында[222] Заһидә Бурнаш (Гыйффәт) ханымның үтенечен укыдым. Үтенеч бик җитди һәм кызганыч – гәүдәле бер фаҗигадан гыйбәрәт. Шулай ислам галәмендә мөселманнар мөселман булулары сәбәпле түгел, бәлки исламнан йөз дүндергәнгә, бигрәк тә тугрысы, хәзер мөселманнар хәятене изгеч – халык кумирларына гына коллык итүчеләре булганга, хәзерге ислам галәмендә гомуми караганда ирләр дә бәхетсез, алар да золым вә золмәт[223] эчендә яшиләр, хатын-кыз галәме исә аннан да биш-битәр начар бер хәлдә.

Мөселманнарның хәзердә иң үзләшкән нәрсәләре – наданлык, пычраклык, ялкаулык, фәкыйрьлек, нифак[224], көйсезлек, исереклек, угрылык, курkaклык, тар фикерлелек, ә хатын-кыз галәмендә исә бу сыйфатларга башка да хәяткә киртә булган хәтсез[225] авырлык, мәсхәрәләр хөкем сөрәләр. Менә гәзитәдә Гыйффәт ханымның үтенече – ул Аллаһы тарафыннан яхшы талант бирелгән бер зат. Ул шул талантны эшләтергә тели, чын мөселманлыкка таба атлый, гыйлемнән, ә гаиләсе аңар «Борынгычалыкка гына кара, ямьсез көчкә генә баш и», – диләр. Аның мөселман вә адәм булырга тырышуына әллә нинди мәсхәрәләр – куркытулар белән көрәшкә каршы чыгалар. Сөекле йөрәк парәләренә гади генә бер хатын булып яшәп калып, нам-нишансыз[226] югалып китүенә генә хезмәт итәрлек планнарын булдырырга тырышалар. Аның хәзерге шәрәф[227] вә намусына, хөрмәтенә ни кадәрле ямьсез пычраклар ыргытканнар. Ләкин Гыйффәт ханым, шаять, мондый эшләр белән генә мәэюс булып[228], юлыннан тукталмас. Ул бар һәм бар булачагын өмет итәбез. Ул чәчәк аткан, милләт аның киң вә ак дөньяда йимешләре йитешкәнен Аллаһтан тели. Аның анасының хәрәкәтләреннән Гыйффәт ханымның кара көчкә генә гыйбадәт итеп, бер гади хатын булып калуына тырышуы бик ачык беленә. Әйе, кызлар бай хатыны да, мулла хатыны да, хасил нинди генә булса

---

[218] Инсаниятпәрвәр – кеше яратучы.
[219] Самим – чын, саф.
[220] Калеб – йөрәк, күңел.
[221] Тәшәккер итү – рәхмәт әйтү.
[222] *Заһидә Бурнашева.* Мәрхәмәт наменә бер үтенеч // Тормыш, 1915, 10 сентябрь.
[223] Золмәт – караңгылык.
[224] Нифак – икейөзлелек.
[225] Хәт – чик, үтмәскә тиешле нокта.
[226] Нам-нишан – исем-эз.
[227] Шәрәф – кадер, хөрмәт.
[228] Мәэюс булу – өметсез, өмет өзелгән булу.

да бер хатын була алалар. Дөрес, бу да тереклектә бер җай, мәҗбүри диярлек, ләкин гади җай; моны һәр кыз булдыра ала. Фәкать боларның артында берничә бала, бераз малдан башка ни кала? Болар «туды – үлде, үлде – бетте», вәссәләм. Ләкин Гыйффәт ханымның максаты исә, адәмлек маясе[229], мөселманлык нигезе булган гыйлем вә фазыйләт[230], бөтен мөселманлыкка шәрәф вә фәхер[231] булырдай бер гая[232] хыял; Аллаһы аның бу гая хыял вә фазыйләтенә юл ачсын да, иҗтиһадына[233] мөсагадә бирсен[234] иде. Максатының галилеге белән бергә, хәлнең үтә аянычлыгын игътибар итеп, тәкрар[235] булarak, аның үтенечен милләткә тагын гарыз итәргә[236] ярый. Аның ифтиралардан[237] котылуы, тоткан юлында дәвамы өчен юристлар һәм намуслы юмартларымыз кичекми, матди вә мәгънәви ярдәм кулларымызны сузарга тиешлемез. Мондый хәлләрдә Тукайның:

«Бар мени бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү,

Без аны кайдан белик, мескен, үлеп, аңлатмагач» шигыренең безгә тигән мәгънәсен бик аңларга вакыт.

***«Тормыш»:***

Заһидә Гыйффәт туташ маҗаларына даир[238], Әҗедән битараф каләм белән язылган бер мәкалә килде. Киләчәк номерларда басармыз.

*«Тормыш», 1915, 16 октябрь.*

***Ф.Сөләймания***

**Бөек фаҗига**

Мөхарәбә[239] мәйданыннан килгән дәһшәтле хәбәрләр өстенә Гыйффәт туташ фаҗигасе хәбәре күңелнең иң нечкә йирләренә кадәр тыкынып, йөрәкләрне тетрәтте. Ай фәләк[240]!.. Татар дөньясы өстеннән җәһаләт[241] караңгылыклары күтәрелеп, гыйлем таңы туган көннәр булырмы икән; әллә татар кызлары һаман да шул җаһил[242] ата-аналарның рәхимсез тырнаклары астында

---

229 Мая – нигез, төп элемент.

230 Фазыйләт – артыклык, яхшы холыклылык, яхшы сыйфатлылык.

231 Фәхер – горурлык, дан, намус.

232 Гая – төп теләк.

233 Иҗтиһад – тырышлык кую, тырышу.

234 Мөсагадә бирү – мөмкинлек бирү, булышу.

235 Тәкрар итү – кабатлау.

236 Гарыз итү – бер эш яки хәл турында телдән сөйләп яки язып тиешле урынга аңлату, җиткерү.

237 Ифтира – яла ягу, берәү өстенә ялган гаеп ташлау.

238 Даир – бәйләнешле.

239 Мөхарәбә – сугыш.

240 Фәләк – язмыш, тәкъдир.

241 Җәһаләт – наданлык, аң-белемсезлек.

242 Җаһил – надан, белемсез.

изелеп, җәһаләт корбаны булып бетәрләрме икән? Бу сөальнең[243] җавабы хәзер! Әгәр дә безнең кызларыбызга лязем булган[244] кадәр тәрбия бирелеп, мәгълүматлы, гыйлемгә мәхәббәт куйган аналар йитештерелмәсә, гыйлем вә һөнәргә истигъдадлы[245] кызларыбыз да, надан аналарның аяк чалуы сәбәпле, укудан мәхрүм булып, җәһаләт корбаны булып калачаклардыр. Шуның өчен дә, милләтебез югалмасын дисәк, безнең иң беренче вазыйфабыз кызларыбызны укытып, мәгълүматлы, гыйлем вә һөнәргә дошман булмаган аналар йитештерүдер. Без бу мәгълүматлы аналар сирәк, аларны йитештерү өчен икътидарлы[246] мөгаллимәләр кирәк дигән сүзне бер туктамый чәйнәп торсак та, матбугатыбызда бу тугрыда күп язсак та, без әле һаман да чын-чыннан эшкә керешеп, максудыбызга ирешә алганыбыз юк. «Элек кычкырган күкенең башы ярылыр» дигән кеби, без «Икътидарлы мөгаллимәләр йитештерү өчен дарелмөгаллимат[247] кирәк» дип кычкырып авызыбызны ачып калдык. Җәсарәтле[248], эшлекле Троицк ханымнары тавышсыз-тынсыз гына дарелмөгаллимат ачып, бу мөкаддәс[249] шәрәфене[250] алар казандылар. Хәзергә инде безгә шул хөрмәтле ханымнарга муафәккыять[251] теләп, икътидарлы милләт аналары йитештерә торган мөгаллимәләр көтәргә генә калды.

Әле мин максудтан бөтенләй читкә чыгып киткәнмен икән.

Мин дә үзем бер ана булганлыгымнан, һәм дә матбугат галәмендә аз гына булса да, бер хезмәтем булып, гаиләләр тәшкил итү, аларның төзеклеге хосусында фикер бәян итүне үземнең вазыйфам дип таныдыгымнан, бу ана берлә кыз арасына кысылып, үз фикеремне бәян итмәкче булам. Гыйффәт туташ фаҗигасен укыгач, өстән генә караганда, бөтен гаеп вә гөнаһ гыйлемгә дошман булган мәгълүматсыз анага гына иснад кылынса[252] да, дикъкать итеп тикшереп, әтрафлырак[253] мөхакәмә кылган[254] вакытта, Гыйффәт туташның анасы, кызын уку юлыннан туктатып, бик начар эш эшләгән булса да, ачу итеп, ата-анасын ташлап чыгуда Гыйффәт туташта да бераз ялгышлык бар дип әйтәсем килә. Гыйффәт туташны укудан туктату да, анасыннан бигрәк, безнең әби-бабаларымыз, сәләфләребез[255] гаепле. Әгәр алар аналарыбызны җәһаләттә калдырмаган булсалар, кызларга уку хәрам, шигырь сөйләү хәрам дигән кеби, игътикадларны[256] аналарыбызның күңеленә урнаштырган булма-

---

[243] Сөаль – сорау.
[244] Лязем булу – тиеш, кирәк булу.
[245] Истигъдад – булдыклылык, сәләтлелек.
[246] Икътидар – булдыра алу, көч җитү.
[247] Дарелмөгаллимат – хатын-кыз укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[248] Җәсарәт – йөрәкле, кыю, батырлыклы.
[249] Мөкаддәс – изге, иң мөһим.
[250] Шәрәф – кадер, хөрмәт.
[251] Муафәккыять – уңыш, уңайлык, булдыра алучанлык.
[252] Иснад кылу – сылтау, эшне кешегә аудару.
[253] Әтраф – тирә-юнь.
[254] Мөхакәмә кылу – хөкем чыгару.
[255] Сәләф – борынгы кешеләр, ата-бабалар.
[256] Игътикад – ышану, инану.

салар, бүгенге аналарыбыз укудан ул кадәр курыкмаслар иде. Сәләфләребез кыз баланың артык укуы, каләм тотып язу-язуы, көйле нәрсәләр укуы кыз баланың бозылуына сәбәп була дип, хатын-кызның тәмам йөрәгенә сеңдереп куйганнар.

Шуның өчен дә, һәрбер иске фикерле ана укыды исә, кызыны бозыла, харап була дип белә. Хәлбуки[257] ул үзенең кызын бик әдәпле, инсафлы булдырасы, бик бәхетле итәсе килә, кызына камил шәфкать вә мәхәббәтеннән наши[258] үзенең начар дип тапкан нәрсәләреннән аны тыя, кыса. Ул шуны бик тиешле дип белә, менә шуның өчен дә мин, үз фикеремчә, бичара, җаһил ананың яхшылык дип белеп эшләгән хаталыкларына каршы, мәгълүматлы, әдәпле туташларга бик тиз кабынып китмичә, бераз сабыр итеп, акрынлык берлә мәгълүматсыз ананың аңлашмаганлыктан килгән хаталыкларын төзәтергә тырышулары ляземдер дип беләм. Ана никадәр мәгълүматсыз да булсын, тупас та булсын, әхлаксыз да булсын, кирәк кем генә булса да булсын, ул һаман да ихтирамга лаек тәбрик ана. Аның һичбер вакытта балалары каршында кадер вә хөрмәте кимергә тиеш түгел. Бер әдәпле кызның ата-анасының бәгъзе бер кысынкылыкларына каршы гаилә учагында, ана кочагында качып, ятлар химаясенә[259] сыенып та матбугат галәменә чыгып, мөхтәрәм ананың гаепләрен энәсеннән җебенә кадәр галәмгә фаш итүен дә, шул ананың эшләгән кабахәтеннән ким дип әйтеп булмый. Гәрчә гаилә эчендә тәхәммел килә[260] алмаса, җәфа да күргән булсын, качып чыгып, милләтнең ярдәменә дә мохтаҗ булган булсын, ата-ананың гаебен әйтми дә милләтне ярдәмгә чакыру мөмкин булыр иде.

Безнең татар милләтендә бу кеби кысылган кыз вә ир балалар бер Гыйффәт туташ кына түгел, бәлки йөзләр, меңнәр илә санарлык кыз вә ир балаларның башында мондай кысынкылыклар, һөнәр вә мәгарифтән тыюлар бардыр. «Гыйффәт туташның ата-анасын ташлап чыгуын матбугат бик хуплап каршы алды» дип, кыз вә ир балаларыбыз ташлап чыгып китеп, болай да гаилә хәяте тәртипкә куелмаган зәгыйфь милләтебезнең бөтенләй таркау хәлгә килеп, тагы да зәгыйфьләнү ихтималы булганлыктан, Гыйффәт туташның бәгъзе кысынкылыкларга түзеп, анасы кочагында тәрбияләнүен мәслихәт[261] күрер идем. Укуга килсә, кыз вакытта мөмкин булмый икән, кияүгә чыккач та укырга мөмкин бит. Бу көндә гыйлем вә һөнәрләрен арттырырыга тырышып, тәхсил[262] берлә шөгыльләнгән ханымнарыбыз юк түгел ич. Гыйффәт туташ дәрәҗәсенә йитәрлек укыганнан соң, төрле китапларны моталәга кылу[263] берлә мәгълүматын арттырырга була. Шул ата-ана тәрбиясендә шагыйрәлек дәрәҗәсенә йиткән туташ, моннан соң да мәгълүматын

---

[257] Хәлбуки – ләкин.
[258] Наши – *-дән* барлыкка килгән, *-дән* барлыкка киләрәк.
[259] Химая – яклау, саклау.
[260] Тәхәммел килү – күтәрә алу, чыдау.
[261] Мәслихәт – уңыш,файда; киңәш.
[262] Тәхсил – гыйлем алу.
[263] Моталәга кылу – уку, өйрәнү.

арттыра алыр иде. Кувәи шигърияне[264] тәрәккый иттерә[265] торган иң беренче гыйлаҗ[266] шул – мәшәкать, зәхмәт, тарлык вә кысынкылык түгелме соң?

Тукай, мәрхүм, нинди генә мәшәкатьләр күрмәде, нинди генә тарлыкка төшмәде. Аңар карап кувәи шигъриясе кимемәде. Һаман арта гына барды ич. Аның иң җазибәле[267], иң тәэсирле шигырьләре дә шул тарлыкка төшкән вә изелгән вакытында сөйләгән шигырьләре, илһамы килгән вакытлары да шул күңеле сынык, күзе яшьле вакытларыдыр. Ана шәфкатенә, ата тәрбиясенә туймаган мескен, ятим Тукай үзенең шәфкатьле анасыны гүзәл, мөәссәр[268] шигырьләре берлә милләтенең күзе алдына бер мөкаддәс, очып китәргә торган нурани[269] фәрештә төсле итеп бастырып куя. Ник ул да анасын бер шәфкатьсез гыйфрит[270] кеби итеп күрсәтми? Чөнки ул анасының шәфкатьле, җылы кочагына туймаган, дөньяга килгәннән ахыр гомеренә кадәр бәгъре бирьян[271], күзе гирьян[272] булып, ач вә ялангач ятлар ишегендә сөйрәлеп, ятимлекнең ачысыны татыган.

Ай бичара ана... . Белсә иде балалар ана күңеленең никадәр йомшак вә шәфкатьле икәнен, аналарның балалары өчен никадәр мәшәкать вә зәхмәтләргә түзгәнен, татлы йокыларын, яшь гомерләрен фидаи[273] итеп, гүзәл йөзләрен саргайтып, шәфкатьле кочагында тирбәтеп үстергәнен! Дөньяда ана күңеле кадәр шәфкатьле, йомшак күңел, ананың баласына булган мәхәббәте кадәр саф вә мөкаддәс мәхәббәт тәсаувыр кылына[274] белерме? Фикер гаҗизанәмә күрә, әгәр дөньяда һич бервакытта араларына кер төшү кабил[275] булмаган ике күңел булса, ул ике күңелнең берсе ана күңеле, икенчесе дә кыз бала күңеле булырга тиеш. Һәм бу шулай да. Никадәр түбән дәрәҗәдәге гаилә эчендә булсын, ана берлә кыз арасы төзек була. Нинди генә әхлаксыз, надан кыз булсын, анасы әллә никадәр җәберләр дә кылсын. Бер авыз анасы ни хилаф[276] сүз сөйләгәнен ишетә алмассың. Шуның өчен дә нечкә вә хәссас[277] күңелле шагыйрәнең матбугат галәменә чыгып газизә анасыны яманлавына каршы бер-ике сүз язудан үземне тыя алмадым. Гаилә – иҗтимагый хәятнең нигезедер. Гаилә хәяте булмаган милләтнең көчле, куәтле, гаилә хәяте ислах кылынган иҗтимагый эшләрдә берләшкән милләтләр арасында яшәү ихти-

---

[264] Кувәи шигърия – шигырь язу көче, сәләтле.

[265] Тәрәккый иттерү – алга җибәрү, үстерү.

[266] Гыйлаҗ – әмәл, чара.

[267] Җазибә – үзенә тарта торган, үзенә карата торган.

[268] Мөәссәр – йогынтыланган.

[269] Нурани – нурлы, якты.

[270] Гыйфрит – каты күңелле, мәкерле, рәхимсез кеше.

[271] Бирьян – куырылган.

[272] Гирьян – елаучы, күз яше түгүче.

[273] Фидаи – үз-үзен аямыйча чын күңелдән эшләү; берәр максатка ирешү өчен үзен корбан итү.

[274] Тәсаувыр кылу – сурәтләп күз алдына китерү, гәүдәләндерү.

[275] Кабил – кабул итү.

[276] Хилаф – каршы, кире, тискәре.

[277] Хәссас – тиз сизә торган.

малы юктыр. Безгә ничек кенә булса да, гаилә хәяте тәшкил итәргә, гаилә әфрадын[278] бер-берсеннән аермый берләштерергә тырышырга кирәк.

*«Сөембикә», 1915, № 2, б.34–36.*

***С.Гыйсмәт***

**Гыйффәт туташ хакында**

Берничә айлар элек, июнь числосының иң матур көннәрендә, матбугат бакчасының гүзәл бер урынында истирахәт иткән [279] бер вакытларда «Гыйффәт туташның» елда язган бер шигырен укыгач, минем укыганны тыңлап утырган иптәшем: «Туган, билгеле инде, бу имза астында иң бәхетле вәһмәләрнең[280] җыры, нечкә вә хәссас калебле[281] йир фәрештәсе яши бит» дия, «Гыйффәт туташка» гыйбта иткәнен[282], егерменче гасыр тарихында сирәк-мирәк күренгәләгән шагыйрьләребез арасында «Гыйффәт» имзасы астында яшеренгән шагыйрәнең яшәве, Русия мөслимәләренең ирләр илә бәрабәр гыйлем, мәгърифәт берлә зиннәтләнүе вә ирләрдән артта калмаганлыкларын киләчәктәге һәмширәләремезгә[283] күрсәтергә зур дәлил булачагын аңлап, бигрәк тә шатланганын сөйләгән иде. Шул вакытта без икебез, Гыйффәт туташ кебек чын мәгънәсе илә улган шагыйрәне тудырган ананың вә тәрбияләп йиткезгән атаның исемнәрен алтын кара илә тарих сәхифәләренә язып калдыру безнең Русия мөслимәләренең, бурычыбыз дия, Гыйффәт туташ хакындагы фикеребезне берләштереп, сүзне өзгән идек. Шул көннән соң күп сулар акты. Гүзәл манзаралар арасында саткан төрле фәлсәфәләр арасында иптәшем илә «Гыйффәт туташ» хакындагы сөйләшкән фикер шул урында калды. Онытылды.

Менә бервакыт бик зур тәгаҗҗебне[284] ма важиб[285] уларак, күп калебләрне үзенә җәлеп иткән «Гыйффәт туташ» үзенең мөстәгар[286] имзасын ача. Бер дә көтмәгәндә гашыйкларына үзенең кем идекен ап-ачык иттереп аңлата. Бигрәк тә аның фаҗигале тормышы вә кичергән дәһшәтле дәверләре укучыларны гаҗәпләндерә.

Бердәнбер яшь шагыйрәбезнең башындагы кара болытлар калебләрне әрнетә. Ярдәмгә ашыгучылар да күренә. Гыйффәт туташ хәлен тасвирлаган хәбәрләрне укыган бер кеше, аның хакында сүз ача вә үзенчә фикер йөртә.

---

[278] Әфрад – бөртекләр.

[279] Истирахәт итү – ял итү, эштән бушап тору.

[280] Вәһми – хыялый.

[281] Калеб – йөрәк.

[282] Гыйбта итү – кызыгу, берәүдәге яхшы якларны күреп үзендә дә шуны булдырырга теләү.

[283] Һәмширә – кыз туган, кыз кардәш.

[284] Тәгаҗҗеб – гаҗәпләнү, ис китү, хәйран булу.

[285] Ма важиб – һичшиксез үтәлергә тиешле нәрсә.

[286] Мөстәгар – ялган исем.

«Гыйффәт туташның» гашыйклары җөмләсеннән улган мәзкүрә[287] иптәшем дә Гыйффәт туташның фаҗигасен китергән гәзитәне укыгач та, гәзитәне алып минем квартирга чапкан. Ишектән кереп тә йитмәде, шатлыклы йөзе илә: «Иптәш, Гыйффәтнең кем идекен белергә дә муаффәкъ булдым[288] бит, мә укы» дия кулындагы гәзитәсен миңа сузды. Мин ул хәбәрне үткән көнне үк укыган булсам да, иптәш хәтере өчен тагын бер кат укып чыктым. Минем укып бетергәнне сабырсызлык илә көтеп утырган иптәшем: «Син аны кызганасыңмы?» дия, «әйе» җавабын алачагына ышанып, миңа караса да, мин аңа җавап бирмәенчә: «Гыйффәт туташ шагыйрә. Шагыйрә булу өчен уку, гали тәрбия күрү лязем[289] улмасын, шагыйрәлек кувәсе[290] аңа Аллаһы тарафыннан бирелгән бер нигъмәт улсын, әмма шул куәтне вә калебнең хисен башкаларга аңлату өчен белем кирәкме? Түгелме?», – дия, үзенә бер сөаль илә иптәшемә карадым. Ул: «Әлбәттә, белем кирәк», – ди. «Гыйффәт туташ шигырьләрен» бер надан татар кызы авызыннан ишетә алмыйбыз, гәрчә иң оста җырчы улса да. Ә аның шигырьләре нәфислеге вә мәгънәләренең тирәнлеге илә аерылалар. Аның оста вә матур каләм илә язылалар. Бу Гыйффәт туташның яхшы ук укыганлыгын күрсәтә түгелме?» дия, мин үз фикеремне сөйли башласам да, иптәшем:

«Йә инде, бу фәлсәфәләрдән нәрсә чыгармакчы уласың, кыска гына әйт әле» дия, минем сүзне бүлә. Мин:

«Тукта, бераз тыңла әле», – дип, мин сөйләп бетергәнче тыңлавын үтенәм. Иптәш, менә нәрсә әйтергә телим: Гыйффәт туташның язуына бинаән[291], аның ата-анасы иң кара вә мөтәгассыйблар[292] булырга охшый. Шундый ата-ана кулында торып, шулкадәр белемне ничек вә кайдан алды икән? Гыйффәт туташ үз-үзен аңлый башлаган заманда аңа каршы килә алган ата-ана аның кечкенә вакытта укуына манигъ булырга[293] көчләре йитмәдеме икән? Гыйффәт туташның китапханәсе улган, китапханә дигәне гәрчә кечкенә генә китап шкафы улсын, кара вә каты йөрәкле атаның йортына ничек сыеп торды икән? Шагыйрь вә шагыйрәләрнең калебләре бик нәзек вә йомшак, шәфкать вә мәрхәмәт нуры илә туры булдыгы кебек, түгел ата-ананың хәтерләрен кыру, хәтта чит бер кешенең дә күңелен калдырырыга теләми торган рәвештә мөлаем була түгелме? Менә шул сөальләргә синнән җавап ишетәсе вә канәгать итәрлек җавап алгач, сиңа ияреп түгел, бәлки чын калебем илә кызганып мөмкин кадәр ярдәмгә ашыгасы килә дидем.

Минем шул сөальләргә җавап эзлисе урында иптәшем:

«Мин дә синең фикереңә кушылам, вә синең сөальләреңә җавап ишетәсем килә башлады», – дип, җавап бирү урынына, үзе җавапчы эзләргә

---

[287] Мәзкүр – әйтеп үтелгән, югарыда әйтелгән.
[288] Муаффәкъ булу – булдыра алу, көче җитү.
[289] Лязем – тиеш, кирәк.
[290] Кувә – көч, куәт.
[291] Бинаән – нигезләнеп, таянып.
[292] Мөтәгассыйб – фанатик.
[293] Манигъ булу – тыю, тоткарлау.

мәҗбүр улды. Без мәзкүр сөальләрне бер мәҗлестә уртага салдык. Ялгыз берәүнең: «Гыйлемгә ихлас кына улсын, башка бернәрсә кирәкми», – дип кыска гына җавабыннан башка бернәрсә ишетә алмадык. Шуңа күрә, мин бу сөальләрне язып, манзара[294] гаммәгә[295] йибәрмәкче булдым. Бәлки берәр зат тәнәззелән[296] мантыйклы[297] җавап язар дия өметләнәбез.

*«Сөембикә», 1915, №2, б. 36–38.*

***Шәһит Әхмәдиев***[298]

**Ун ел**

Гомуми тарихның агышында ун еллык хәят бик кечкенә дәвердер. Зур вакыйгалар килеп кысылмаса, ул дәвер бер эзсез, билгесез югала да китә.

Бер кавемнең ун еллык дәвере исә башкарактыр. Ун ел эчендә ул милләтнең күп нәрсәсе үзгәргән, яңарган була. Әлбәттә, болар да күп вакыт бер нәрсәнең тәэсире белән буладыр. Бу соңгы фикерне тәрәккыйгә[299] йөз тоткан, хәятка омтылган милләтләр тугрысында әйтергә мөмкин; юкса, татар милләте үзенең хорафатына[300] болганып, ничә-ничә гасырлар буена яшәп килгән, һич бер үзгәрешкә, яңалыкка очрамаган. Шуның өчен дә, 16 гасыр татары белән 17–18нче гасыр татары бер фикердә, бер калыпта булуында шик юк. 17нче октябрь хөррияте[301] татар милләтенең бер кыйсеменә[302] бик яхшы тәэсир итте. Хөрриятнең бирелүенә, татарга фикер ачылуга шаһит уларак, мәйданга татар матбугаты килеп чыкты. Әлбәттә, татар матбугатының беренче дәвере «фикер сугышы» белән үтте. Ул вакыт бездә гаять кызганыч хәл иде. Руханилар, сәүдәгәрләр, кара халык мәгарифкә, мәдәнияткә дин ноктаи назарыннан[303] карап, тәрәккыйпәрвәрләргә һөҗүм кылалар, матбугат әһеле[304] үзенең изге фикерен аңлатудан гаҗиз иде. Минем хәзерге максатым – ул дәвернең әхваленнән хисап бирү түгел, бинаән галәйһи[305] язарга уйлаган «Ун ел эчендә хатын-кыз галәмендәге мәгънәви үсү» дигән мәкаләмә киләмен. Матбугат дөньяга калку белән, «Хатыннар хөррияте» эчендә язу, көрәшү

---

[294] Манзара – күренеш.

[295] Гаммә – масса, гади халык.

[296] Тәнәззелән – түбәнчелек белән.

[297] Мантыйк – логика.

[298] Шәһит Гыймадетдин улы Әхмәдиев (1888–1930) – мәгърифәтче, мөгаллим, педагог, журналист. «Аваз», «Эшче», «Мәгариф» газета-журналларын оештыручыларның берсе, Казан губернасының мәгариф халык (1918), ТАССР мәгариф халык комиссары (1924–1926).

[299] Тәрәккый – прогресс.

[300] Хорафат – искелек калдыклары.

[301] 1905 елның 17 октябрь Манифесты турында сүз бара.

[302] Кыйсем – өлеш.

[303] Ноктаи назар – караш.

[304] Әһел – кеше.

[305] Бинаән галәйһи – шуның өчен.

беренче урынны әшгаль итте[306]. Әлбәттә, бу бик табигыйдыр. Һәрбер мөтәрәккый[307] татар хәят сорый, хәят эзли башлый. Әлбәттә, хәят матур тормыш, хатыннарның иштиракы[308] белән генә табыладыр.

Хатыннар исә үзләренең хуҗалары – ирләре кул астында изелә, кояш нурын да күрә алмыйча, чапан астында шиңеләләр, кибәләр иде. Кызларның хәле бигрәк тә аяныч иде. Яшь гомере дүрт стена эчендә үтә, үсеп йиткәч, ата-ана кәефе белән галибән[309] үзе теләмәгән кияүгә бирелә иде... Менә шуны күздә тотып, матбугат әһеле чынлап хатын-кыз хәрәкәте өчен көрәшергә тотынды. Мөхәррирләр, шагыйрьләр һәммәсе үзләренең әсәрләрендә, шигырьләрендә үзләренең апалары, сеңелләре хакында җыларга тотындылар. Нинди генә әсәргә, нинди генә шигырьгә карама, бар йирдә дә татар хатыны, татар кызы тормышыннан өзелә, коллыкта чери. «Кәләпүшче кыз», «Өч хатын белән тормыш», «Теләнче кызы»[310], «Татар кызы»[311] ... һәммәсе шул рухка корылганнар.

Бигрәк тә инде олуг әдибемез Гаяз Исхакый әүвәлгерәк әсәрләре белән, әдип Фатыйх Әмирханның «Татар кызы» ул вакыттагы хатын-кыз галәмен безгә көзге кебек күрсәтә алалар. Әлбәттә, бу хилафлар[312], бу сукыраюлар, бу көрәшләр юкка китмәделәр. Акрынлап кына хөррият көче апа-сеңелләренең дә өсләреннән чапанны ташлата башлады. Шулай итеп, безнең дөньябызда да хәят чаткылары оча башлады. Ул арада көрәшче мөхәррирләремез дә мәйданга килеп чыктылар. Мин әлегә мәрхүмә Фатыйма-Фәридә ханымны кулга аламын. Ул бичара бар рәхәтен, бар тормышын шул хатыннар хөрриятенә багышлады. Үзенең изге идеясенә бирелеп, чиктән тыш эшләве аның вакытсыз кабергә керүенә дә сәбәп булды. «Ул тик үзенең туганнары өчен корбан булды...» дигән сүзне чын иман белән әйтәмен. Ләкин ул үзе китсә дә, туганнарының хокуклары өчен көрәшергә бора-



Суфия Агиева
*(«Сөембикә». 1914. №16)*

[306] Әшгаль итү – шөгыльләнү.
[307] Мөтәрәккый – алга киткән.
[308] Иштиракъ итү – катнашу.
[309] Галибән – күбрәк вакытта.
[310] «Кәләпүшче кыз», «Өч хатын белән тормыш», «Теләнче кызы» – язучы Гаяз Исхакый әсәрләре.
[311] «Татар кызы» – Фатыйх Әмирханның шул исемдәге хикәясе.
[312] Хилаф – каршылык, кирелек.

дәрләрен[313], сеңелләрен калдырды. Әлбәттә, татар кызы үзенең каһарманы Фатыйма-Фәридәне онытмаска тиеш.

Яңалыкның, табигый уларак, кызларымызның укуларына да бик нык тәэсире булды. Ун ел мөкаддәм[314] остабикәләр кулында гына тәрбия кылына торган туташларымызга мәктәп, школа, гимназия, дарелфөнүн[315] ишекләре ачылып китте. Хәзерге көндә бу гыйлем йортларының һәрберсендә диярлек хәзерге көндә безнең туганнарымыз, башка мәдәни милләт кызлары кебек, тәрбия кылыналар, һәркаюсы чын милләт әгъзасы булырга тырыша. Алар арасында дарелфөнүн бетереп, бүгенге көндә зур эшләрнең башына менеп утыручылары да аз түгел. Мәсәлән, ун ел мөкаддәм гади татар кызы булган Хәдичә ханым Ямашева-Таначева[316] шул кыска дәвер эчендә үзенең иҗтиһады, сәбатлыгы[317] аркасында, укып теш докторы булды. Суфия бикә Агиева рәсми доктор булды.

Хәзерге көндә искиткеч күп мөгаллимәләремез аз-маз вазыйфа барәбәренә татар дөньясының бар йирендә үзләренең мөкаддәс[318] хезмәтләре белән милләт балаларына дин, туган тел өйрәтәләр. Болар да безнең өчен иң файдалы, иң мөкәммәл[319] милләт әгъзаларымыздыр.

Ун ел мөкаддәм фәкыйрь, зәгыйфь булган милли сәхнәмез дә татар кызларының тәэсирләре белән җанлана башлады. Хәзерге көндә ничә урында милли театрымызны тәрәккый иттерү[320] өчен корылган труппаларымыз бар. Һәммәсендә татар кызлары. Ун ел мөкаддәм башлап татар сәхнәсенә калыккан, сөекле артисткамыз Сәхибҗамал Гыйззәтуллина [321] һаман шул хезмәтендә дәвам итеп киләдер. Аннан соң да шактый артисткаларымыз мәйданга килде. Шул кыска вакыт эчендә милли көйләремезне җырлаучы ханым-туташларны да үз сәхнәмез күрә алды. Болар арасында үзенең хөр тавышы белән Фатыйма туташ Гомәрова[322] дикъкатьне җәлеп итә төште.

Хәзерге көндә безнең театрларымыз мәдәни чын хәят белән аңкыйдыр. Ничә еллар элек түбәтәйләр эчендә шәленә бөркәнеп утырган ханымнар сирәк кенә күренәләр иде.

---

[313] Борадәр – иптәш, туган, фикердәш.

[314] Мөкаддәм – элек, әүвәл.

[315] Дарелфөнүн – югары уку йорты, университет.

[316] Хәдичә ханым Ямашева-Таначева – Ямашева Хәдичә Зариф кызы (1883–1952), 1910 елларда медицина буенча югары белем ала.

[317] Сәбат – чыдамлылык, ныклык, тотнаклылык.

[318] Мөкаддәс – изге, мөһим.

[319] Мөкәммәл – камилләшкән, төгәлләнгән.

[320] Тәрәккый иттерү – алга җибәрү.

[321] Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская (1892–1974), беренче татар актрисасы, 1907 елдан «Сәйяр» труппасында чыгыш ясый, 1912 елда Уфада «Нур» труппасын оештыра.

[322] Фатыйма Гомәрова – татар хатын-кызларыннан тәүге җырчыларның берсе.

Хәзерге көндә билгакес[323] ханым вә туташлар театрның беренче әгъзаларыдыр. Елдан-ел хөр, аңлы татар кызлары арта бара, шул нисбәттә татар театрының кыйммәте дә күтәрелә, һәм матурлыгы да арта бара.

Менә шулай татарның һәр сыйныфында зыялылар, фикерлеләр, милләтнең яшь, аңлы әгъзаларының булуы әдәбиятымызга да бик нык тәэсир итә башлады. Иске, караңгы коллык тормышындагы изелүләр өчен, җылаулар урынына әдәбиятымызда чын татар кызлары да, чын татар хатыннары да күренә башлады. Бу үзгәреш тә шул ун еллык кыска дәвер эчендә килеп чыккандыр. Менә сез, минем хөрмәтле укучыларым, «Татар кызы» белән үткән ел гына мәйданга чыккан «Тигезсезләр»не һәм «Кәләпүшче кыз», «Теләнче кыз»лар белән «Мөгаллимә»не[324] тиңдәштереп караңыз. Шул вакыт нинди аерма табарсыз. Табигый, сезнең үткен зиһенегез хәзер үк мәсьәләне хәл кылыр.

Татар кызы бөтен уе, зиһене, идеясе өйнең түшәме, дүрт стенасы белән капланган. Аның бар теләге читлектәге кош, хайван кебек иркенлеккә чыгарга тырышу. Үзенең читлеге һәм һәркөн күз алдында булган нәрсәләре аны изәдер. Аның яшь, матур күңеле изелеп, бозылып бетә. Коллыкның кысынкылыгының тәэсире уларак, ул үтеп барган һәрбер егеткә сокланып каладыр. Көн буена, төн буена, җәй буена, кыш буена, дөресен әйткәндә, бар гомерен үз өендә бикләнеп яткан татар кызыннан нәрсә көтәргә мөмкин соң.

Инде хәзер мәдәни тәрбия күргән, хөрриятнең нигъмәте белән файдаланган «Тигезсезләр»дәге[325] Рокыя туташны алып карыйк. Аның фикере, идеясе бөтенләй башка. Аның хөр, гүзәл тәрбиясе һәрбер эшкә үлчәп карарга куша. Ул «Татар кызы» кебек һәрбер күзгә күренгән егеткә сокланмый. Аның бай рухына, нечкә йөрәгенә охшар өчен һәрбер егет кенә йитә алмый. Рокыя милләтен сөя, үзенең туган теле, әдәбияты хакында сөйли, мөхакәмә кыла[326].

Әлбәттә, татар кызының ун ел эчендә читлегеннән чыгып, үзенең милләте, әдәбияты хакында уйларлык гали идеягә барып йитүе гаять тә зур нәрсәдер. Инде Гаяз әфәнденең «Кәләпүшче кыз», «Теләнче кыз»ларын, һәммә башка хатын-кыз героинялары белән «Мөгаллимә»дәге Фатыйманы карыйк. Әүвәлгеләренең хәлләре һаман шул «Татар кызы» эзеннән, калыбыннан бара. Фатыйма исә бөтенләй яңа тормыш кызы. Ул милләтен, туган телен сөя, милләт, мәгариф хакында сөйли. Димәк, кыска гына гомерле татарның яңа тормышы Рокыяларны, Фатыймаларны йитештерә алган. Менә шушы хәл безне шатландыра һәм киләчәккә өмет, ышанычымызны арттырадыр.

Сүзнең ахыры уларак әйтәсе сүзем шул. Татар матбугаты хатын-кызлар хөрриятенә гаять тә әһәмият биргән һәм бар көчен аларны азатлыкка чыгарырга сарыф кылган.

---

[323] Билгакес – киресенчә.
[324] Гаяз Исхакыйның «Мөгаллимә» драмасы турында сүз бара.
[325] «Тигезсезләр» – Фатыйх Әмирханның шул исемдәге пьесасы.
[326] Мөхакәмә кылу – хөкем чыгару.

Хәзерге көндә яшәп килә торган «Сөембикә» журналы да шул тәэсир белән мәйданга чыккан һәм бар көче белән хатын-кыз галәменең мәнфәгатьләрен күзәтәдер. Бер милләтнең хәяте хатын-кызның югары менүе һәм ихтирам кылынуы нисбәтендәдер. Нинди милләттә хатынга ихтирам зур булса, ул милләтнең хәяте дә мәгънәле һәм бай буладыр. Мин татар хатыннарының кыска дәвер эчендә хәзерге хәлгә килүләренә һәм елдан-ел тәрәккый итеп торуларына чын күңелемнән шатмын.

Безнең матур истикъбалемез[327], хәятемез аларны ихтирамымыз аркасында гына булачак, дип тагын тәкърар итәмен[328].

*«Сөембикә», 1916, №6, б.113–114.*

***Кәбир Бәкер***[329]

## 1917нче елда милли хәятемез

Бу елда җәмгыять, мәктәп вә мәгариф эшләрендә хатын-кыз дөньясында гаид[330] ошбу эшләр эшләнде:

Уфада Зыяэтдин әл-Камали әфәнде һәм Тәкаевлар тарафыннан, Оренбургта Багбостан ханым тарафыннан кыска мөддәтле[331] тәгълим[332] вә тәрбия курслары ачылды. Зыя әфәнденең курсларында йөздән артык, Багбостан ханым курсларында 85 кадәр ханым вә туташлар җыелып укыдылар. Боннан берничә ел гына элек мөселман хатын-кызларының югары очтан түбән очка йөреп укырга җөрьәт итмәгәнлекләрен хәтердән чыгармаган вакытта, бу соңгы елларда мөселман хатын-кызларының әллә ничә йөз вә мең чакырымнардан килеп, гыйлем вә мәгариф алырга тырышулары бу юлда никадәр үзгәреш һәм дә күңелле бер үзгәреш булганлыгын күрсәтергә йитсә кирәк.

Уфада Гыйбадулла әфәнде Госманов тарафыннан «Кызлар мәдрәсәсе», Троицкида Габдрахман әфәнде Әхмәров вә иптәшләре тарафыннан «Сөембикә мәктәбе» исемнәрендә бишәр еллык монтазам[333] мәктәпләр тәэсис[334] ителде.

Казанда Фатыйха ханым Аитова тарафыннан Русия мөселманнары арасында беренче мәртәбә уларак «Кызлар гимназиясе» тәэсис ителде.

---

[327] Истикъбаль – киләчәк.
[328] Тәкърар итү – кабатлау.
[329] Бәкерев Кәбир Кәрим улы (1885–1944) – журналист, драматург, театр тәнкыйтьчесе.
[330] Гаид – бәйләнешле.
[331] Мөддәт – ара, вакыт.
[332] Тәгълим – өйрәтү, укыту.
[333] Монтазам – тәртипкә салынган, рәтле, тәртипле.
[334] Тәэсис – төзү, оештыру.

Чиләбедә Закир әфәнде Галиевнең тәшәббесе[335] илә кызлар мәдрәсәсе салырга 60 мең сум кадәр иганә җыелганлыгы хакында ошбу хисап язылганда гына хәбәр алынды.

Мөслимәләр җәмгыятендә әйтерлек бер хәрәкәт тә күрелмәде. Билгакес[336], һәркаюсында бертөсле сүнү вә торгынлык күренде. Ни Уфада, ни Мәскәүдә, ни Баку вә ни дә Оренбургта мөслимәләр җәмгыяте һич бер ис китәрлек эш күрсәтмәделәр. Шунлыктан булса кирәк, бу елда хатын-кызлар өчен аларның үзләреннән бигрәк хатыннарга шәригать вә низам [337] даирәсендә[338] ирек вә хокук бирелү тарафдары булган ирләр кайгырттылар. Бу хакта берничә урынны хөрмәтле Йосыф хаҗи Дибирдеев җәнабләренең «Вакыт»та язган мәкаләләре илә ел ахырында чыгарган «Җәмәгать намазларына йөрү хатыннарга рөхсәт!» нам[339] гыйльми рисаләсе[340] торса кирәк. Бондан берничә ел гына элек Русиядә «Хатыннарга җәмәгать намазына йөрү рөхсәт» дип китаплар чыгару түгел, ул хакта сүз сөйләү, вә хәтта уйлау да мөмкин түгел санала иде. [...]

*«Вакыт», 1917, 3 гыйнвар.*

***С.Аягузи***

**Авылларда мәктәпләр**

Курсадан ерак түгел Субаш-Аты авылының[341] кызлар мәктәбен кереп карадым. Бу авылның имамы Габделфатыйх хәзрәтнең үз кәримәсе[342] бөтен вөҗүде[343] белән бирелеп дүрт сыйныфлы кызлар мәктәбен тәрбия итеп бара икән. Бу яшь кенә мөгаллимә Марзия туташ Казанда Фатыйха Аитова ханым мәктәбендә укыган, аның тәрбиясе турында язып тору артыкка саныйм. Миңа Субаш Аты авылында берничә көн калырга тугры килгәнлектән, бу мөгаллимә туташ белән берничә мәртәбә утырдаш булып, аның эшләренә дикъкать итеп бардым. Ул һич нәрсәгә, һичбер манигъка[344] карамастан, яхшы гына програмлы, тәртипле дүрт сыйныф кызлар мәктәбен бик яхшы идарә итеп бара.

Марзия туташ кызларын сыйныфта укытканнан соң, аларга һәрвакыт үзе романнар, әдәби хикәяләр укый һәм үзләрен укыта. Аларны роман, хикәя китапларын укырга тәклиф итә[345]. Кызларның фикерләрен сорый, гәзитә,

[335] Тәшәббес – инициатива.
[336] Билгакес – киресенчә.
[337] Низам – канун.
[338] Даир – караган.
[339] Нам – исем, ат.
[340] Рисалә – брошюра, трактат.
[341] Субаш-Аты – Татарстанның Арча районындагы авыл.
[342] Кәримә – кыз, кыз бала.
[343] Вөҗүд – бар булу, тормышка ашу.
[344] Манигъ – тыючы, тоткарлаучы, киртә.
[345] Тәклиф итү – көчләп кушу, боеру.

журнал укыта, мөхәррир вә әдипләрнең тәрҗемәи хәлләре[346] илә укучы кызларын таныштыра. Үзе хосусый сурәттә русча укып, рус әдәбиятын да моталәгә итә[347] икән. Кызларына да рус әдәбиятыннан, рус әдәбиятының байлыгыннан бәхәс итә. Аларга шуны аңлатырга тырыша. Яхшы гына итеп кул һөнәрләре дә өйрәтә. Кызларын музыка белән таныштыра. Татар җыры, татар көенең әһәмиятен сөйли. Үзе гармун һәм мандолинада яхшы уйный. Авыл кызларына хөррият алуның чын-чыннан кирәклеген сөйләп, тәрбияле милләт аналары чыгарырга бөтен көче белән иҗтиһад итә[348].

Марзия туташның укытуына һәм шул система белән баруына бик зур манигълар чыкмаганда, ата-анасы кысмаганда, Субаш Аты авылы өчен киләчәктә бик зур бәхетләр көтәргә урын бар. Авыл кызларына аң, гыйлем, мәгърифәт бирергә бөтен вөҗүден, рәхәтен корбан итеп тырышучы яшь мөгаллимәләремездән Марзия туташны, төркестанлы сеңел вә апаларыма күрсәтмичә китә алмадым. Төркестанлы кардәшләремез дә, Эчке Русия татар кардәшләреннән гыйбрәт алырга тиешле иде. Андагы апа вә сеңелләремезгә дә уйганырга, укырга, укытырга вакыт йиткән булса кирәк.

Субаш Аты авылыннан тәкърибән[349] егерме-егерме биш чакрым йирдә Иске Тазлар[350] дигән авылда бер кызганыч хәл дикъкатемне җәлеп иткәнгә, берәр файдасы булыр әле дип, бу урында шуны да язып китим дим. Иске тазлар авылының имамы ишан Гатаулла хәзрәт. Бу хәзрәт үзенең искелеге һәм мөтәгассыйблыгы[351] белән мәшһүр икән. Нинди гөнаһ шомлыгы булгандыр, бу хәзрәт Марзия-Маһруй исемле кызын югарыда сөйләдекем мөгаллимә Марзия туташ белән берлектә Казанның Фатыйха ханым Аитова мәктәбендә укытып, шунда тәрбия иттергән. Марзия-Маһруй туташ укып кайтканнан соң, авылдагы тута, сеңелләренең хәлләрен кызганып, аларны укыта, аларга гыйлем-мәгърифәт, шуның белән бергә хөрриятнең дә кирәклеген сөйли башлаган. Ләкин кечкенә миле, тар даирәле ишан хәзрәтнең бозылган мигъдәсе[352], бу ләззәтле, татлы укытуны һазым итә[353] алмыйча, кызына кәефе китеп, мәктәбен яптырган. Кызын укытудан туктаткан: Казанга йибәреп укытуына үзенең бик тәәссеф иткәнлеген[354], кайгырганлыгын сөйлә

[346] Тәрҗемәи хәл – биография.

[347] Моталәгә итү – уку, өйрәнү.

[348] Иҗтиһад итү – тырышлык кую.

[349] Тәкърибән – чамалап әйткәндә.

[350] Иске Тазлар – Татарстанның Әтнә районындагы авыл, хәзерге исеме Ташчишмә.

[351] Мөтәгассыйб – фанатик.

[352] Мигъдә – ашказаны.

[353] Һазым итү – аш сеңдерү, аш үтү.

[354] Тәәссеф итү – үкенү, кайгыру.

гән. Бу турыда үз сүзе йөри торган даирәләрдә кызларын Казанга йибәреп укытуның аслан[355] ярамаганлыгы турысында катгый нәһиләр[356] биргәнлеген сөйлиләр.

Ләкин ишан хәзрәтләр алар һәр нәрсәнең чарасын табарга оста булалар бит. Бу хәзрәт тә, бер дә аптырамыйча гына, аңлы, заманча тәрбия кылынган кызын укытуыннан, шәкертләреннән аерып, Кышкар мәдрәсәсендә[357] черегән, сугыш, кычкырыш курсы тәмам иткән бер хәлфәгә биргән. Бер яктан атасы, икенче яткан аңсыз иренең газаплавы, кысуы астында изелгән бу туташ, үзенең азмы-күпме гыйлем вә тәрбиясе белән теләгәне кадәр авыл кызларын тәрбия кыла алмыйча, тар гына, сасы гына бер бүлмәдә изелгән, беткән кыяфәт белән биш-ун балаларга әллә нәрсәләр генә укытып ятканын күрдем. Аңлы, тәрбияле бер кыз, ишан әткәсенең тәгассыбы[358] астында изелеп, вакытсыз кабергә керергә хәзерлек күреп ята икән. Үз кызларын кызганмаучы аталар милләт кызларын ничек кызгансыннар. Инсафсыз аталарның булуыннан булмавы миллион мәртәбә артыктыр. Бу хәлне күргәч, мондый ата, мондый ирнең золымы астында изелеп, черегән ханым вә туташларның саны, безнең милләттә йөзләп түгел, миллионлаптыр дигән кара уй башымнан кичеп, тәәссеф иттем. [...]

*«Сөембикә», 1917, №5, б. 78–79.*

---

[355] Аслан – бөтенләй, һич.
[356] Нәһи – тыю.
[357] Кышкар мәдрәсәсе – Казан артындагы билгеле мәдрәсәләрнең берсе.
[358] Тәгассыб – фанатизм.

# ҖЫЕНТЫКТА ФАЙДАЛАНЫЛГАН ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР ТУРЫНДА КЫСКАЧА МӘГЪЛҮМАТ

**«ӘЛ-ИСЛАХ»**, атналык милли-демократик газета. 1907 елның 3 октябреннән 1909 елның 22 июленә кадәр Казан шәһәрендә нәшер ителә. Барлыгы 68 саны чыга. Рәсми нашире һәм мөхәррире Вафа Бәхтияров, фактик мөхәррире Фатыйх Әмирхан. Газетада Г.Тукай, К.Бәкер, Г.Ибраһимов, Й.Акчура, Г.Камал һ.б. авторларның мәкаләләре, әдәби әсәрләре басыла.

Газетада уку-укыту, тәрбия, әдәбият, мәдәният һәм мәдрәсәләргә реформа ясау һ.б. мәсьәләләр күтәрелә, бала тәрбиясе, хатын-кыз мәктәпләре турындагы язмалар тәкъдим ителә.

**«ВАКЫТ»,** иҗтимагый-сәяси газета. 1906 елның 21 февраленнән 1918 елның 26 гыйнварына кадәр Оренбург шәһәрендә чыккан. Барлыгы 2308 саны дөнья күргән. Наширләре – бертуган Закир һәм Шакир Рәмиевләр, мөхәррирләре Фатих Кәрими (1906–1917), Ярулла Вәли (1917–1918). Газетага иң күп язышкан авторлар арасында М.Бигиев, З.Бәшири, Х.Атласи, Җ.Вәлиди, Г.Гыйсмәти, Ш.Камал, Ф.Кәрими, Р.Фәхретдин, Б.Шәрәф, Б.Мөэминова, З.Бурнашева һ.б. бар. Басмада сәяси мәсьәләләргә зур игътибар бирелә, Дәүләт думасының мөселман фракциясе әгъзаларының эшчәнлеге яктыртыла, җир эшкәртү, сәүдә һәм сәнәгать, милли мәдәният, әдәбият, тел, театр, музыка үсешенә багышланган язмаларга зур урын бирелә. Иң күп яктыртылган мәсьәләләр арасында дин, мәгариф, татарлар арасында һөнәри, югары белем алу мәсьәләләре бар. Шулай ук чит илләрдә укыган татар студентлары тормышын, хатын-кызларның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге хәлен, мәгарифен, татарларның хәйриячелек эшчәнлеген һ.б. тасвирлаган мәкаләләр күп.

**«ТОРМЫШ»,** иҗтимагый-сәяси газета. 1913 елның 18 октябреннән 1918 елның 29 апреленә кадәр Уфа шәһәрендә чыга. Барлыгы 800гә якын саны дөнья күрә. «Сибирия» газетасының дәвамы. Мөхәррирләре – В.Нәүрүзов (1913–1914), З.Кадыйри (1914–1918), нашире – Г.Госманов. Мәгариф, дин, татар теле, иганәчелек, хатын-кызның җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге урынына багышланган мәкаләләр басыла. Татар әдәбияты, театры, вакытлы матбугатына зур игътибар бирелә. Аеруча күп басылган авторлар арасында С.Хәбиров, З.Ярмәки, Г.Ибраһимов, С.Кадыйрия, З.Бурнашева һ.б. бар.

**«СИБИРИЯ»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1912 елның 18 февраленнән алып 1913 елның 31 августына кадәр Томск шәһәрендә дөнья күрә. Барлыгы 145 саны чыгып кала. Себердә чыккан беренче татар газетасы. Наширләре һәм мөхәррирләре – В.Нәүрүзов, Фатыйма-Фәридә Нәүрүзова. Газетаның төп кыйбласы татар милләтенә хезмәт итүдән гыйбарәт. Иң күп язышкан авторлар арасында Г.Габдуллин, Ш.Әхмәтҗанов, Ф.Нәүрүзова, И.Биккулов, З.Кадыйри, М.Мозаффария, Ф.Сөләймания, Ф.Ибраһимова һ.б. бар. Сәяси

мәсьәләләр белән беррәттән, милли үзаңны күтәрү, татар мәдәнияте һәм әдәбияты, тел, театр, музыка, икътисад, сәүдә мәсьәләләре яктыртыла, татар мәгарифе, мәктәп-мәдрәсәләр тормышы, татар хатын-кыз мәктәпләре һәм мөгаллимәләре, хатын-кыз мәсьәләсенә багышланган язмалар урын ала. Аеруча зур игътибар Себердә яшәүче татарлар һәм аларның проблемаларын тасвирлауга бирелә.

1913 елдан редакция Уфа шәһәренә күчерелә, «Тормыш» газетасы буларак чыга башлый.

**«СӨЕМБИКӘ»,** хатын-кызлар өчен махсус журнал. Казан шәһәрендә 1913 елның 27 октябреннән 1918 елның 8 гыйнварына кадәр чыккан. Барлыгы 115 саны дөнья күргән. Нашире һәм мөхәррире – Якуб Хәлили. Иң актив авторлары арасында Ш.Әхмәдиев, Р.Атнабаев, Я.Хәлили, Б.Мөэминова, М.Акчурина, Ф.Бурнаш, Ф.Аитова, К.Мозаффария, М.Мозаффария, Ф.Сөләймания, З.Бурнашева һ.б. бар.

Журналның төп максаты – татар хатын-кызларын милли гореф-гадәтләр нигезендә тәрбияләү. Шуңа бәйле рәвештә төп игътибар хатын-кызлар хәрәкәте, аларның җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге урыны, хокуклары һәм вазыйфалары, аналар тәрбиясе, хатын-кызлар мәктәпләре, мөгаллимәләр тормышы, һөнәр үзләштерүнең әһәмияте, мөгаллимәләрне әзерләү һәм педагогик осталыкларын, белемнәрен арттыру, әхлак, бала тәрбиясенең эчтәлеге һәм үзенчәлекләрен билгеләүгә багышланган язмаларга бирелә. Шулай ук иҗтимагый һәм сәяси тормыш, мәдәният һәм сәнгать, сәламәтлек саклау, хуҗалык эшләре кебек темаларга багышланган мәкаләләр дә урын алган.

**«ШУРА»,** иҗтимагый-мәгърифәти һәм әдәби-публицистик журнал. 1908 елның 10 гыйнварыннан 1917 елның 31 декабренә кадәр «Вакыт» газетасының кушымтасы буларак Оренбург шәһәрендә чыга. Барлыгы 240 саны дөнья күрә. Каширләре – Шакир һәм Закир Рәмиевләр, мөхәррире – Риза Фәхретдин. Иң күп язган авторлар арасында Й.Акчура, Г.Сәгъди, Р.Атнабаев, Һ.Атласи, М.Акчурина, К.Бәкер, Җ.Абызгилдин, Г.Идриси, Р.Фәхретдин, Г.Баттал, Нәзифә-Хәтимә һ.б. бар.

Журналның төп максаты – Россия мөселманнары тормышын яктырту була. Дини, тарихи, иҗтимагый, әдәбият һәм мәдәният, мәгариф, хатын-кыз мәсьәләләренә багышланган язмалар урын ала. Чит илләр тарихын, төрки халыклар тарихын, татар тарихын, татар һәм башка төрки халыкларда һәм чит илләрдә мәктәп-мәгариф эшенең торышын тасвирлауга багышланган мәкаләләр күп басыла. Укучылар игътибарына шулай ук тәрбия, педагогика, мәктәп гигиенасы, укыту ысуллары, дәреслекләр, мөгаллимнәр һәм мөгаллимәләр, кыз балаларны укыту һәм тәрбияләүгә багышланган мәкаләләр тәкъдим ителә.

# АВТОРЛАР ҺӘМ ШӘХЕСЛӘР КҮРСӘТКЕЧЕ

«Бер кыз» – 33
«Вакыт мохбире» – 196
«Вәкил» – 14, 16, 17, 19, 21, 23
«Вәкилә» – 13, 15, 16, 17, 19, 22, 29, 30, 31, 32, 33, 209
«Кайгыручы» – 284
«Кардәш» – 187
«Мавия» – 100
«Мохбир» – 121, 129, 245, 308, 315
«Нәҗия» – 327
«Сөйкемсез» – 36
«Татар угылы» – 123, 126
«Таян» – 53
«Уфа кешесе» – 211
«Юлдаш угылы» – 330
А.Б. – 114
Абдуллин Я.Г. – 4
Аблакова Фатыйма – 293
Абруй ханым – 190
Абушаев – 125
Абушхамин Миңнегали – 343
Абушхамин Мөхәммәдгали – 343
Абызгилдина Гайшә (Гайшә ханым, Гайшәбәнат Абызгилдиния, Гайшә Абызгилдиния, Гайшә бинте ахунд Лотфулла Абызгилдиния) – 99, 103, 107, 117, 138, 139, 166, 183, 189, 191
Абызгилдина ханым – 188
Агафуровлар – 104
Агиев ахунд – 85
Агиева Суфия (Колахмәтова Суфия) – 274, 356, 357
Агишев Гомәр – 293
Адамова Зәйнәб – 305
Адамова Фатыйма (Фатыйма абыстай) – 42, 86, 101, 105, 170, 182, 299, 304, 326
Адирова С. – 131
Аитова Фатыйха (Аитова ханым, Фатыйха ханым) – 110, 112, 116, 124, 125, 127, 136, 137, 153, 159, 194, 198, 242, 359, 360
Айтуганов Гыймадетдин (Айтуганов Г.) – 255, 324
Ака – 306, 313
Акимбетов Искәндәр – 278
Акимбетова Зәйнәб – 278
Аксаков С.Т. – 52, 53
Актуганова Файзә – 300
Акчурин Ибраһим (Ибраһим әфәнде) – 125
Акчурин Тимербулат (Тимербулат хаҗи) – 173, 174
Акчурин Хәсән – 124, 174
Акчурин Ягъкуб – 128
Акчурина Бәдриҗамал – 124, 128, 129
Акчурина Гайшә – 300
Акчурина Зөһрә – 173
Акчурина Маһруй – 124, 127, 128, 129
Акчурина Мәргубә – 124, 128, 129
Акчурина Фатыйха – 303
Акчурина ханым – 155
Акчуриннар – 97, 123, 124, 125, 127, 129
Алибабаева Фатыйма – 300
Алиева Шәрифҗамал – 325
Алкин –120
Алкин И. – 55
Алмаев Нургали – 204
Апанаевлар – 106
Апашева Мәрьям – 39
Арапаева Шәмсикамал – 300
Арапова Мәрвәр – 300
Арапова Роза – 300
Арсланов Ибраһим – 92
Атнабаев Рәхимҗан – 49
Афаков Ибҗан (Ибраһим) – 301

Аширова Сәрби – 300
Аягузи С. – 174, 360
Әдибә Хәлидә – 74, 75
Әкрам хәзрәт – 111
Әл-Мөслими Габделхәмит – 168, 239
Әлмөхәммәдов Солтан – 326
Әмидова ханым – 188
Әминә ханым (Әгерже) – 103
Әминә ханым (Нижний) – 101
Әминова Вәгыйзә – 325
Әмирхан Фатыйх (Әмирхан Ф.) – 334, 356
Әмирхания Сәгадәт – 95, 290
Әмирханов Габдулла – 290
Әмирханов Р.Г. – 4
Әннисаи Әшраф – 101
Әсгать Мәхмүд – 75
Әскәрова Таифә – 300
Әсма ханым – 241
Әфләтүн – 333
Әхәдшәриф хәзрәт – 323
Әхияр – 329
Әхмәдзакир хәзрәт – 322
Әхмәди – 26
Әхмәдиев Шәһит (Ш.Ә.) – 285, 355
Әхмәдхәбиб хәзрәт – 322
Әхмәдша хәзрәт – 322
Әхмәров Габдрахман (Г.Әхмәров) – 109, 137, 153, 154, 359
Әхмәров Шаһбазгәрәй – 275
Әхмәрова Мәрьям – 117
Әхмәрова Сара (Сара ханым) – 74, 275, 276
Әхмәрова Хәдичә – 122, 123, 277
Әхмәтгалим Мөхәммәдвәли угылы – 323
Әхмәтҗанова Хәйрелниса – 300
Әхмәтов Камалетдин – 323
Әхмәтов Миңлевәли – 322
Әхтәмия Фатыйма – 242
Әшрәфҗамал абыстай (Әшрәфҗамал ханым) – 48, 332
Базаревская Мәрьям – 73
Байбекова Хәлимә – 301
Байбурова ханым – 188
Байчурин Лотфулла – 223
Байчурина Заһирә – 292
Баишев Исхак  – 300
Бакиров Хәнәфи – 170
Бакирова Сәкинә – 170
Басыйрия Фәрхинас – 64,65
Батракова Газизә – 300
Батыршин Габдулла – 322
Батыршин Гариф (имам Гариф, Гариф хәзрәт) – 304, 309, 320, 322, 324, 325
Батыршин Х. – 322
Батыршина Мәрхәбә – 173
Батыршинова Рәйхана бинте Габдулла – 50
Баязидов – 289
Баязидова Фатыйма – 39
Баязитов мөфти – 260
Бәдигый Тәкый (Бәдигъ әфәнде, Тәкый әфәнде) – 161, 162, 163, 243
Бәкер Кәбир (К.Б.) – 156, 359
Бәхтиев – 125
Бәхтизин Имаметдин – 204
Бәхтиярова ханым – 188
Бәшар Нәзиһә – 74
Бебель – 334
Биби Мәфтуха, Габделкотдус зәүҗәсе – 334, 336
Биги Габдулла – 295
Бигишев Хөсәен – 293
Бикбулатова Әшрәф – 300
Бикмәт Маһитап – 109
Бикмиева Маһисәрвәр (Маһисәрвәр) – 39, 43
Бикташев Гариф – 316
Биктимиров Әхмәтҗан – 28, 336

Биктимирова Т.Ә. – 5
Биниаминова Фатыйма – 300
Бирушева Газизә – 303
Бирушева Сорур – 303
Бичурова Фатыйма – 332, 333
Богданова ханым – 188
Бостам шәех – 322, 323
Браковский – 122
Бубый Мөнҗия – 138
Бубый Мөхлисә ханым (Мөхлисә ханым, Мухлиса Боби) – 137, 138, 151, 152, 153
Будда – 333
Бурнаев Гариф – 316
Бурнашев Шакир зәүҗәсе – 293
Бурнашева – 301
Бурнашева Заһидә (Гыйффәт туташ, Гыйффәт ханым, Заһидә Гыйффәт туташ, Заһидә Гыйффәт, Заһидә Бурнаш, Загида-Гыффат Бурнашева) – 11, 316, 344, 347, 348, 349, 350, 351, 353, 354
В.Н. – 226
Вафа әфәнде – 87
Вахидов Хәсән – 172
Ваһапов Мортаза – 280, 322
Ваһапов Н.Ә. – 4
Вәлиев Гариф – 323
Вәлиев Хаҗиәхмәт – 162, 163
Вәлиева Мәхфүзә – 136
Вәлиева ханым – 150
Вәлиуллина Әсма – 233, 234
Г.Г. – 114, 214
Г.М. – 115, 333
Г.С. – 151
Габбасов Хәсәнҗан – 298
Габделбакый Мөхәммәдвәли угылы – 324
Габделвәлиев Исхак – 178
Габделвәлиевләр – 177
Габделкотдус әфәнде – 103
Габделлатыйпова Бибигафифә – 46
Габделфатыйх хәзрәт – 360
Габделхак хәзрәт – 220
Габделхаликова Гафифә – 303
Габдерәшит Фәүзия (Фәүзия Истанбул) – 51, 225, 226
Габдерәшитов имам – 221
Габдеррәзаков Зәйнелгабидин – 275
Габиди Исмәгыйль – 260
Габдрахман имам – 92
Габдрахманова Әминә (Әминә ханым) – 9, 134, 135, 136
Габдулла әфәнде – 90
Габдуллин Гатиатулла (Гатиатулла хәзрәт, имам Гатиятулла) – 304, 309, 320, 324
Габдуллин Давыд – 284
Габдуллина Мәфтүһа – 305
Габдуллина Рәхилә – 279
Габдюшев Җиһанша – 260
Габидова Хәлимә – 103
Габидулла әфәнде – 197
Габидуллин Нәбиулла – 204
Габидуллин Шәриф – 303
Габидуллина ханым – 111
Газизә абыстай – 93, 94, 177
Газизә остазбикә – 100
Газизә ханым – 88
Газнәви – 228, 230
Гаибов Хөсәен – 216
Гайнанов ахун – 204
Гайнетдинова Гөлсем – 301
Гайнуллин Вильдан – 112
Гайнуллина Назыйрә – 158
Гайсә бине Мәрьям – 333
Гайсә Ибраһим угылы – 323
Гайшә бинте Сәлим – 122
Гайшә ханым – 103
Галиәкбәр Хаҗәр – 160, 161
Галиәкбәров Гариф – 176
Галиев Габдулла – 315
Галиев Закир – 359

Галиева Гафифә – 136
Галиева Сабира – 83
Галимбеков Салих – 345
Галимҗан Хәбибулла угылы – 291
Гали Мөхәммәд угылы – 323
Галимулла әфәнде – 205
Галия – 74
Гами – 206
Гариф хәзрәт – 175, 176
Гаспринский (Исмәгыйль бәк Гаспринский, бөек Исмәгыйль, И.Гаспринский, Исмәгыйль бәк) – 42, 43, 44, 79, 186, 318
Гатаулла хәзрәт – 361
Гатиятуллин Зиннәтулла – 290
Гафифә ханым – 48
Гафиятулла кызы Галимә – 50
Гафури Мәҗит – 183
Гаясетдинов Сәләхетдин – 324
Гәрәев Әхмәд – 322
Гыймадетдинова Өммегөлсем – 300
Гобәев Габделәүли – 35
Гобәева Гайнелхәят – 102
Гобәйдулла әфәнде – 90
Гобәйдуллин Мәсгуд – 320, 322
Гобәйдуллин Мөҗәһид – 322
Гобәйдуллин Мөхсин – 322
Гобәйдуллина Мәрьям – 185
Гомәрова Фатыйма – 357
Гомдә – 57
Гонних Маһирә – 171, 202, 305
Горохов – 265
Горфанов Нигъмәтулла – 322
Госмани Исмәгыйль (Исмәгыйль Госманов) – 116, 182
Госмани Хәйрулла – 107
Госмани Хәлим (Хәлим әфәнде) – 145, 146
Госманов Гыйбадулла – 84, 192, 243, 254, 255, 324, 325, 359
Госманов М. – 8
Госманов Миңлеислам – 89
Госманова Гайшә – 130, 182
Гөлсем ханым – 51
Гыйбадуллин Бәдретдин – 113
Гыйззәтуллина Сәхибҗамал – 357
Гыйззениса ханым – 178
Гыйлаҗетдинов Мөхәммәдзарим – 218
Гыйльманова Абруй – 339
Гыйниятулла казый – 97
Гыйсмәт Сара (С.Гыйсмәт) – 284, 353
Гыйсмәтулла әфәнде – 326
Дашкин Мөхәммәтгали – 300
Дашкина Шәрифзадә – 300
Дәүләткилдиева Гайнелхаят бинте Рөстәм хан – 324
Дәүләткилдиева Маһипәрвәр – 72
Дәүләткилдиевлар – 298
Дәүләтша Гали угылы – 324
Дәүликамов Касыйм – 300
Дәүликамова Гафифә – 177
Дәүликамова З. – 169
Дәүликамова Маһиҗиһан – 300
Дәүликамова Таһирә – 300
Девятова Гайшә – 300
Дибирдеев Гайнетдин – 300
Дибирдеев Ибраһим – 300
Дибирдеев Йосыф – 300, 360
Дибирдеева Мәргүбә – 300
Диваев – 188
Диваева ханым – 188
Диләфрүз туташ – 169
Дунаев Хаҗи – 85
Дунаева Хәдичә (Хәдичә ханым, хаҗи Дунаев кызы) – 85, 280
Екатерина ханым – 189
Елкыбаев Рәхмәтулла – 221
Еникиев Гайсә – 67, 68
Еникиева Мәрьям – 137
Еникиева ханым – 188
Еремеева Зөләйха – 300

Ермакова Гафифә – 303
Ермакова Нәгыймә – 303
Жданов Кашшаф – 336, 337
Җантурин Сәлимгәрәй (Сәлимгәрәй әфәнде) – 146, 274, 286, 292
Җантурина Суфия (Суфия ханым, Суфия бикә) – 145, 146, 274, 275, 285, 286, 287, 288, 292
Җантуриннар – 145, 150
Җәббаров Сәлях – 325
Җәләл хәзрәт – 323
Җәмилева Разыя – 117
Җиһангир – 86
Җиһангир дамелла – 99
Җиһандаров Фәйзрахман – 332
Җиһанша әфәнде – 224
З.И. – 134
З.С. – 202
Закирова Әсма – 136
Зарифов Локман – 323
Зарифов Шакир – 323
Заһидуллина Сара – 136
Заһирә ханым – 172
Заһирә ханым, Каюм хәзрәт әһеле – 88, 91
Зәбиров Нурмөхәммәд – 293
Зәйнәб туташ – 177
Зәйнәб туташ, Ризаэтдин хәзрәт мәхдүмәсе – 169
Зәйнуллин Шакир – 204
Зәйтүнә ханым – 283
Зәкия ханым, Искәндәр хаҗи җәмәгате – 323
Зиннәтулла – 248, 325, 326
Зыятдин әфәнде – 49
Зыятдин Әхмәд – 155
Ибраһим хаҗи – 104
Ибраһимов Габдулла – 289
Ибраһимов Гали – 40
Ибраһимов Галимҗан (Габди) – 234, 260
Ибраһимов Давыд – 323
Ибраһимов мулла – 197
Ибраһимов Һади – 255, 324
И.Г. – 104
Илькина ханым – 188
Ильминский – 180
Ильяс мөәзин – 323
Исәнбердин Мөсалим –172
Исмәгыйлев Мөхәммәтҗан – 117
Исмәгыйлева Хәнифә – 301
Исхак бай – 332
Исхаков Габдрахман – 290
Исхакый Гаяз (Гаяз әфәнде) – 68, 356, 358
Ишаева ханым – 188
Ишимбаева Рабига – 301
Ишимбаева Сабира – 303
Ишимбаева Фатыйма – 303
Ишморатова Рабига – 39
Ишмөхәммәдов Закир – 88
Ишмөхәммәдов Искәндәр – 275, 276
Ишмөхәммәдова Кәримә (Кәримә Ишмөхәммәд) – 302, 303, 315, 316
Йосыфов Нуретдин Хәсәнетдин угылы (Нуретдин Йосыфов, Нуртдин Хуснутдинович Юсупов) – 105, 106
Йосыфия Җиһан – 343
К. – 103
Кадыйрия Сания Гыйффәт (Сания Гыйффәт) – 61, 70, 267, 268, 299
Казакова Рабига – 39
Кайбишев әфәнде – 333
Калмаканов С. – 111
Камалетдинова Гайшә, Зыя хәзрәтнең әһлиясе – 242
Камалетдинова Зәйнәб (Зәйнәб Камалия) – 164, 169, 170, 182, 326
Камалетдинова Сәгадәт – 39
Камали Зыя (Зыяэтдин әл-Камали, Зыяэтдин Камали, Зыя хәзрәт, Зыятдин әфәнде) – 160, 161, 163, 242, 243, 248, 249, 256, 257, 258, 359

Камалов Гариф – 326
Камалова – 109
Камалова Өммегөлсем – 337
Камалова Рабига – 185
Камилә ханым – 300
Камилә ханым, Яхъя хәлфә тугмасы – 99
Кант – 333
Капкаев – 289
Карабаева Хөснизамал – 150
Касими Газыйм (Газыйм әфәнде) – 237, 241
Касыймбәк әфәнде – 249
Касыймова Камилә (Камилә Касыймия) – 161, 231
Кашафетдин әфәнде – 309
Кәбирова К. – 303
Кәримия Мәрьям – 236
Кәримов Фатыйх – 86
Кәримов Хәсән – 89
Кәримова Рабига – 279
Кәримова Шәмсезиһан – 133
Кәримовлар – 25
Киеков Гариф – 222
Кинзикеев Шәйхулла – 242
Киникиев Габбас – 100
Киникиева Фатыйма – 300
Козлова Нәгыймә – 39
Комарова – 169
Коннев – 208
Конфуций – 333
Корбангалиева Гайшә – 300
Кормашева Зәйнәб – 297, 299, 301
Коровин – 108
Котова – 106
Кошчыголов Мөхәммәд – 293
Красинов Мирсәет – 323
Краснова Евгения – 196
Крижановская ханым – 110
Крылов – 78
Кулаткый Каюм – 131
Курничкова Юстина – 196
Курташева Хөснизамал – 300
Кухтерин – 265
Латыйф Х. – 204
Ләбибә ханым, Мәсгудый хәзрәтләренең кәримәсе – 260
Ләйлә – 74
Ләйлә бинте Сабир – 19
Лермонтов – 183
Лотфи имам – 87
Лотфулла Шәрифҗан угылы – 50
Любимов – 109
М. – 104
М.Н. – 105
М.-Н. ханым – 105
Макрабова Фатыйма – 303
Макрабова Фирүзә – 303
Максуди Әхмәдһади (Максудов Һади) – 55, 120
Максудия Зәйнәб – 120
Максудова Гайшә – 303
Максудова Мәхфүзә (Мәхфүзә туташ) – 340, 342
Мамановлар – 49
Маматова Мәрьям – 300
Марзия Маһруй туташ – 361
Марзия туташ – 190, 191
Марзия туташ (Субаш Аты) – 360, 361
Маһруй ханым, Әхмәтҗан хаҗи Рәхмәтуллинның җәмәгате – 114
Мәҗидия Миңлеҗамал – 242
Мәмлиева Кәримә – 233, 234
Мәрҗани Шиһаб – 186, 318
Мәрьям туташ – 133
Мәрьям ханым, Миңлеислам Госманов әһлиясе – 89, 95
Мәсгуди ахунд – 260
Мәсрүрә ханым, Зәки Мусин җәмәгате – 322
Мәүлүдов рәфикасы – 324
Мәүлүдов (сатучы) – 324

Мәүлүдова Чистапули Зәйтүнә – 39
Мәхдүмә – 17
Мәхмүд әфәнде – 243
Мәхмүдов Хөҗҗәтелхәким – 221
Мәхмүтова А.Х – 5
Мәһдиева Нуркамал – 83
Миңлеәхмәт (сатучы) – 322
Миңлешаһ Әхмәтҗан угылы – 323
Мирсәлим әфәнде – 323
Мирза Салих – 125
Мирзаһид мөәзин – 323
Мирсәгыйдова Гөлсем – 300
Мишкин – 289
Мияссәр хәзрәт – 323
Мозаффар Зариф – 283
Мозаффария Камилә (Камилә ханым) – 7, 283, 284
Мозаффария Маһруй – 7, 39, 95, 95, 97, 116, 120, 123, 229, 246, 247, 250, 268, 276, 277, 278
Мозаффария Мәхмүдә – 39
Мозаффаров Мөхәммәткамал (Камал Мозаффаров) – 180, 201, 224
Мозаффарова Җәмилә – 39
Мозаффарова Зөбәйдә – 300
Мозаффарова Мәгъзизә – 300
Мозаффарова Мәймүнә – 300
Монасыйпова Сорур – 303
Морадова Зөбәйдә – 303
Моратов Нигъмәтҗан – 283
Моратова Өммегөлсем – 303
Моратова Хәдичә – 303
Морзин Ибнеәмин – 290
Мортазин Габделгазиз – 178
Мортазинәви Маһруй – 39
Мостафа Әхмәтҗан – 110
Мостафин Ярулла – 155
Мостафина Нәсимә – 300
Мөҗәһид Мөхетдин угылы – 324
Мөлеков Сабирҗан – 300
Мөлеков Шакир (Шакир хаҗи Мөлекев) – 86, 289, 300
Мөлекова Нәфисә – 300
Мөнәвәрә ханым (Газизә абыстай кызы) – 94, 100
Мөнир мөдәррис – 102
Мөслимә ханым – 293
Мөхәммәдҗанова Сафинә – 83
Мөхәммәдиева Фагыйлә – 233, 234
Мөхәммәдша хаҗи – 122
Мөхәммәдьярова Рабига – 300
Мөхәммәтгариф хәзрәт – 84
Мөхәррәмовлар – 158
Мөхетдинова Мәрьям – 137
Мөхсинов И. – 151
Мөэминов Гайнетдин – 291
Мөэминова Багбостан (мөгаллимә Багбостан, Багбостан, Багбостан ханым) – 7, 8, 101, 108, 109, 139, 145, 165, 167, 170, 182, 184, 260, 271, 294, 303, 359
Муллашәйхелсәләмова Хәдичә – 83
Мусин әфәнде – 102
Мусин Габдрахман – 300
Мусин Зәки – 322
Мусин Садыйк – 325
Н. ханым – 47
Назыйров Бәдретдин – 85, 204, 317
Назыйров Садретдин (Садрый Назыйров, Назыйров, Садретдин әфәнде Назыйри, Садретдин әфәнде) – 99, 117, 129, 130, 155, 161, 234, 287
Назыйрова Гайнелҗамал – 171
Назыйровлар – 246
Наразый – 252
Насыйбулла әфәнде – 326
Насыйбулла Сафиулла угылы – 324
Насыйр Габдулла – 323
Насыйри Каюм – 318
Нәгыймә ханым – 277

Нәҗиб мөәзин – 323
Нәҗметдинов Гыйбадулла – 173
Нәүрүзов (Вәгыйзь әфәнде) – 51, 316
Нәүрүзова Фатыйма-Фәридә (Фатыйма-Фәридә ханым, Фатыйма ханым) – 6, 51, 74, 115, 197, 261, 263, 265, 280, 281, 282, 283, 294, 301, 302, 303, 304, 308, 309, 316, 317, 318, 322, 324, 325, 356, 357
Нәфисә ханым, Хәйрулла хәзрәт кызы – 47
Нигъмәтулла Нурулла угылы – 177
Нигъмәтулла хәзрәт – 178
Нигяр – 74
Ницше – 333
Ниязбабаева Һаҗәр – 300
Нугаева Мөнәүвәрә – 299, 300
Нугай Гөлмөнәүвәр – 251
Нукайский – 216, 274, 275
Нурлыгата имам – 92
Нурмөхәммәд казый – 249
Нурмөхәммәдова Хәдичә (Хәдичә Нурмөхәммәдия) – 94, 95, 103, 231
Палванова Хәлимә – 300
Пәнбә ханым – 14
Поташева Мәрьям – 337
Пушкин – 183
Равил старшина – 322
Рафиков Габдрахман – 290
Рафикова Рабига – 290
Рахманколов Әхмәдхаҗи – 217
Рахманкулов Габдрахман – 155
Рахманкулов Гыйрфан – 219
Рахманкулов Мәгъсум – 156
Рахманкулова Газизә – 303
Рәдүди Гобәйдулла – 183, 294
Рәҗәбов Галях – 326
Рәмиев Закир – 7
Рәмиев Мөхәммәдгариф – 222
Рәмиев Рәшид – 300
Рәмиев Фуад – 300
Рәмиев Шакир – 7, 135, 136
Рәмиева Әсма – 299
Рәмиева Гәүһәр (Гәүһәр абыстай) – 9, 134, 135, 136, 193, 299, 300
Рәмиева Диләфрүз – 299, 300
Рәмиева Зәйнәб – 299, 300
Рәмиева Маһиәсма – 300
Рәмиева Мәхбүбҗамал – 300
Рәмиева Мәхибҗамал – 300
Рәмиева Н. – 300
Рәмиева Рауза – 300
Рәмиевләр – 8
Рәсүлев Габдрахман – 217
Рәсүлев Зәйнулла – 217
Рәхимова Гайшә бинте Хәбибрахман – 136
Рәхмәтуллин Әхмәтҗан – 114
Рәхмәтуллина Гайшә – 301
Рәшидов Габделмөхсин – 305, 306
Рәшит баба – 75
Рокыя ханым, Габделхәким хәлфәнең әһлиясе – 108
Романов – 53, 55
Романовлар – 55
Рубинштейн – 300
Руута ханым – 145
С.Г. – 153
Сабатзадә – 348
Сабирҗан хәзрәт – 104
Сабит мулла – 322
Сабитов Ногман – 85
Садретдинов Шәйхетдин – 322
Садыйк түрә – 156
Садыйков Сабирҗан – 322
Садыйков Фатых – 300
Садыйкова Фатыйма – 300
Саинов Ләбиб – 58, 61
Салихов Галиулла – 218
Салихов Мохтар – 224
Салихова М. – 121
Салихова Нурдидә – 300

Салихова Фәрданә – 300
Сара, мулла Мирза әһлиясе – 69, 70
Сара ханым, Шакир хаҗи Вильдановның кызы – 339
Саттаров әфәнде – 243
Сатыев Габдулла – 177
Сафуанова Тәгъзимә – 162, 163, 233, 234, 247, 250
Сахибгәрәй Сәйфетдин угылы – 324
Сахибгәрәй Сәфәргали угылы 324
Сәбатетдинов Әхмәтгали – 155
Сәбатетдинов Әхмәтҗан – 156
Сәбатетдинова Гөлсем – 155
Сәгыйдә ханым – 73
Сәгыйдевләр – 205
Сәгыйдов Йосыф – 222
Сәгыйдова Гайнекамал – 39
Сәгыйдова Миңлегаян – 39
Сәгыйрия Фатыйма – 177
Сәйдәшев Әхмәтҗан – 111
Сәйдәшев Мөхәммәтҗан – 55
Сәйфелмөлеков Садретдин – 159
Сәйфелмөлекова Маһидилбәр – 186, 187
Сәйфелмөлекова Фәгыйлә – 186, 187
Сәйфетдинова Сәгадәт – 326
Сәйфи Ф. – 241
Сәйфуллина Зөбәйдә Сафиулла кызы – 196
Сәлахетдинов Мирхәбиб – 159
Сәлахова – 182
Сәлимов Шакир – 315, 316
Сәлимова Сорур – 325
Сәмия Әминә – 74, 144
Сәүдә ханым – 103
Сәхибҗамал – 329, 330
Сәхибҗамал ханым – 101
Симакова Хәдичә – 303
Сираҗетдинов Шәйхелислам – 324
Ситникова Забидә – 300
Солтанаев Хәмзә – 301
Солтанаева Мәрьям – 301
Солтанаева Хәлимә – 301
Солтанбеков Махиян – 336
Солтангали хәзрәт – 329
Солтангалиев ахунд – 222
Солтангалиева Мәдинә – 131
Солтангәрәев Асылгәрәй – 323
Солтанов Искәндәр – 292
Солтанов Мөхәммәдъяр (мөфти Солтанов, мөфти хәзрәт, мөфти хәзрәт Солтанов) – 211, 212, 215, 216, 217, 225
Солтанова Мәрьямбикә бинте Тимербулат (Мәрьямбикә Солтанова, Солтанова ханым) – 99, 100, 125, 127, 190, 191, 266, 292
Солтанова Фатыйма – 300
Сөләймани Габдрахман – 223
Сөләйманов Ниязмөхәммәд – 219
Сөләйманова Разыя (Разыя ханым) – 85, 183, 206, 315
Сөләйманова Фәхрелбәнат (Фәхрелбәнат Сөләймания, Фәхрелбәнат ханым, Ф.Б.Сөләймания) – 7, 21, 22, 23, 159, 189, 242, 349
Сөнгатулла әфәнде – 178
Сөрут Салмә – 74
Спицын – 167
Субаева Фәхриҗиһан – 39
Суфия туташ – 133
Сүнчәләев Сөләйман (Сөләйман әфәнде) – 92, 102, 292, 293
Сүнчәләй Сәгыйть – 183
Сыртланова Әминә (Әминә ханым) – 73
Табиева Хаҗәр – 303
Тагиев Зәйнелгабидин хаҗи (Тагиев) – 20, 191, 193
Тагиевлар – 278
Таҗетдин Әхмәд – 76
Таҗетдинов Зәйнетдин – 177
Таибә ханым – 293

Такташев Хөсәен – 108
Таначиев Ибраһим – 133
Таначиева Мөбәйнә – 133
Таһири Һади – 239
Таһиров Хәсән – 219
Тәкаев Гофранулла (Гофран Тәкаев) – 247, 250
Тәкаев Фәтхелислам – 228, 230, 247, 250, 258
Тәкаева Газыймә (Газыймә ханым) – 155, 161, 164, 227, 228, 230, 231, 232, 233, 234, 236, 246, 247, 249, 250, 251, 255
Тәкаева Мәгъфуфә – 100
Тәкаевлар – 359
Тәлгать бәк – 75
Тәңребирдиева Зәйнәб – 300
Тәфкилевләр – 53
Тәфкилева-Морадова Хәдичә бикә Арслангали кызы – 286
Терегулов Ибраһим – 55
Терегулова Мәдинә – 110
Терешкавия Өммегөлсем – 65, 66, 269
Тимкиннар – 104
Тимошев Нигъмәтулла – 217
Тинаев Латыйф – 293
Толстой – 78
Төхфәтулла хәзрәт – 276
Төхфәтуллин Гарифулла – 111
Төхфәтуллин Ф. – 179, 180
Тукай Габдулла (Тукаев, Тукай, Габдулла әфәнде) – 10, 183, 189, 190, 191, 318, 349, 352
Тукай-Черкас Мәрьям – 109
Туктаров Сәет (Туктаров С.) – 155, 173
Тумашев Закир – 315
Тюменов Гариф – 325
Тюменева Гайшә – 303
Тюменева Зөһрә – 303
Тюменева Сорур – 303
Тюменева Фатыйма – 303
Уразаева Миңлевафа – 156
Урманов Салихҗан (Сәлихҗан казый, Сәлихҗан хәзрәт) – 161, 163, 247, 249
Урманова Зөләйха – 301
Усейнов Габдулла – 290
Усейнов Закирҗан – 290
Усейнов Шакирҗан – 290
Усейнова Сорур – 290
Усманов – 115
Үзбәкия Мәфтуха – 100
Ф.С. – 101
Фармаковский – 218
Фатыйма – 74
Фатыйма туташ (Әстерхан) – 204
Фатыйха туташ (Бәләбәй) – 172
Фәезханова – 110
Фәйзия Гайшә – 138
Фәйзуллина Кәримә – 176
Фәйзуллинәви Яфарбикә – 39
Фәйрүзә ханым – 108
Фәрхетдинов Җамалетдин – 323
Фәрхетдинов Сәлахетдин – 323
Фәттах мулла – 102
Фәттахетдинова Мөкәррәмә – 83
Фәтхетдинов Мөхәммәтгали – 326
Фәтхи бәк – 144
Фәтхуллин Камал – 300
Фәхретдинов – 108
Фәхретдинов Ибраһим – 323
Фәрхетдинов Нуретдин (Нуретдин хәзрәт, имам Нуретдин) – 304, 309, 320, 323, 324
Фәхретдинов Риза (Ризаэтдин хәзрәт, Фәхретдин Риза) – 4, 7, 169
Фәхретдинов Харрас (Харрас хәзрәт, имам Харрас) – 304, 320, 322
Фәхретдинова Мәрьям – 183
Фәхретдинова Сорур – 301
Фәхрия Зәйтүнә (Зәйтүнә ханым) – 30, 31, 32, 33
Федотова ханым – 150

Х.И. – 104
Х.Н. – 26
Хаҗәр туташ – 133
Хаҗиәхмәт әфәнде –309
Халидов Гарифҗан – 326
Халидов Мөшәрриф – 178
Хангильдин Вәли – 237
Хантимерия (Хантимерова) Гайшә – 183, 186
Харис мулла – 323
Харкә ханым – 145
Хатый Г. – 200
Хәбибрахманов Гази – 322
Хәбибулла әфәнде – 85, 151
Хәбибуллин Сәгъди – 323
Хәбиров Сәлях – 255
Хәдичә ханым – 145
Хәдичә ханым (Адамова кызы) – 42
Хәдичә ханым, Яхъя хәлфә әһлиясе – 99
Хәйдәрова Фәһимә (Фәһимә ханым) – 42
Хәйретдин мулла Гатиятулланың бабасы – 322
Хәирова Асия – 339, 340
Хәйрулла (тимерче) – 324
Хәйруллин Заһидулла – 85
Хәйруллин Хәйретдин – 322
Хәкимҗан әфәнде, Әхмәтҗан хаҗи Рәхмәтуллинның угылы – 114
Хәкимов Шакир – 104, 304, 309
Хәкимовлар – 118
Хәлил казый – 190
Хәлил хәзрәт – 220
Хәлиуллина Әкрәмә – 303
Хәмзә хәзрәт – 220
Хәмзин Нәҗметдин – 84
Хәмзинәви Мәрьям – 39
Хәмидов Нәбиулла – 111
Хәмидуллин Гыйззәтулла – 224
Хәнифә ханым (Баку) – 67
Хәнифә ханым (Себер) – 342
Хәсән хәзрәт – 323
Хәсәнов Галим – 204
Хәсәнов Идрис – 323
Хәсәнов Нургали – 223
Хәсәнов Сабир (әл-Хәсәни Сабир) – 98, 99, 292
Хәсәнов Фатых – 323
Хәсәнов Шәриф – 323
Хәсәнова Әсма – 300
Хәсәнова Маһипәрваз – 204
Хәсәнулла Насыйбулла угылы – 324
Хәтимә Нәзифә (Хәтимә) – 79, 81
Хәтимулла Мөхәммәтфазыл – 150
Хикмәтуллина Сабира – 301
Хөсәен әфәнденең әһлиясе – 332
Хөсәенов – 208
Хөсәенов Гани (Гани бай) – 42, 156, 186
Хөсәенов Габделхәмид – 182
Хөсәенов Габдрахман – 300
Хөсәенов Хөсәен – 303
Хөсәенова Алмазкамал – 299
Хөсәенова Гайшә – 300
Хөсәенова Мәрьям – 299, 300
Хөсәенова Мәхфүзә – 299
Хөсәенова Өммехани – 300
Хөсәенова Рауза – 299
Хөсәенова Хәдичә – 299
Хөсәенова Хәдичәбикә – 300
Хөсәенова Хәдичә бинте Сабит – 300
Хөсәенова Ширин Бану – 299, 300
Хөсәеновлар – 20
Хөснетдинов Зиннәтулла – 247, 250
Хуҗаәхмәт хәзрәт – 123, 276, 277
Хуҗаханов Әхмәдзәки – 131
Хурамшин ахун – 237
Хурамшин Җамалетдин – 343
Чанышева Газизә – 300
Чанышева Гөлчәһрә – 300
Чинаева Гайшә – 154, 278, 279

Ш. Гайшә – 300
Ш.Д. ханым –105
Шакир бәк – 142
Шакирия Зәкия – 343
Шакиров Бакый – 325
Шакирова Маһирә – 118, 119
Шаһгалиева Маһипәрвазбикә – 292
Шаһҗиһанов Шаһмулла – 290
Шаһид мулла – 323
Шәйхетдин әфәнде – 309
Шәмгулов Сабирҗан (Сабирҗан әфәнде) – 85, 173, 336
Шәмгулов Садыйк – 336
Шәмсетдинов Гыймадетдин – 323
Шәмсетдинова Нәйрә (Нәйрә ханым) – 238, 243
Шәмсинәһар ханым, Зәки әфәнденең анасы – 323
Шәмсия ханым – 130
Шәрәфетдинова Рабига – 183
Шәрәфиев Әхмәдхәбиб – 323
Шәриф Хәсәнов – 323
Шәрифов Шәфигъ – 323
Шәүкәт Бәлкыйс – 144, 145
Шәфигов Әхмәтлатыйф – 323
Шәфигова Мөслимә – 182
Шәфигуллин – 87
Шәфигуллина Нәфисә – 87
Шәфиева Өммегөлсем – 303
Ширбиева Гайшә – 300
Ширинский Хөсәен – 346, 347
Шнаси Габдулла – 170
Шопенгауэр – 333
Энгельс – 334
Юлдаш Кыям – 173
Юнысова Маһикамал – 208
Ягъкубова Зәйнәб – 136
Ягъкубова Мәрьям (Ягъкубова М.) – 199, 231, 233, 234
Ягъкубова Сәлимә (Сәлимә туташ) – 340, 341, 342
Ягъкубова ханым – 188
Ядкәрова Хәдичә – 150
Ямашева-Таначева Хәдичә ханым – 357
Янгуразова Өммегөлсем – 303
Ярулла Мостафа угылы – 326
Яруллина Зарифа – 303
Яушев Габделвәли (Габделвәли хәзрәт) – 278
Яушев Латыф (Л.Ш.Яушев) – 138, 152, 306
Яушев Шәриф – 153
Яушева Әшраф – 278, 279, 299, 300
Яушева Гайния (Гайния абыстай) – 151, 152, 153, 245, 252, 253
Яушева Зыяия – 303
Яушева Камәрбану – 300
Яушева Мәфтүха – 279, 312
Яушева Өммегөлсем – 279
Яушева Фатыйма – 279, 299, 300
Яушева ханым – 188
Яушева Хәдичә (Хәдичә ханым) – 151, 306
Яушевлар – 137, 314
Яһудиннар – 100, 118

# ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ

Аблай – 172
Австрия – 288
Ажурный – 156, 157
Акмулла – 221, 293, 297, 299, 301
Алабайтал – 178
Алабуга өязе – 131
Алма-Ата – 8, 48, 49, 177, 178, 332, 333
Америка – 180, 181, 331
Англия (Ингелтерә) – 75, 142
Атбасар – 91
Аурупа (Яурупа) – 10, 44, 75, 76, 139, 140, 141, 142, 180, 197, 198
Әгерҗе (Агрыз) – 88, 90, 91, 103, 138
Әҗе – 346, 347, 349
Әлмәт-мулла волосте – 119
Әсәй – 322
Әстерхан – 131, 132, 133, 224, 339, 340, 345
Багданова – 346, 347
Байбулат – 151
Баку – 20, 73, 148, 149, 192, 193, 278, 360
Балтика – 142
Бәйрәкә – 102, 211, 322, 323
Бәләбәй өязе – 129, 147, 151, 172, 241, 243, 343
Бешикташ – 145
Бишунгар волосте – 173
Богырыслан өязе – 112, 196
Бозаяз – 243
Бозаулык – 101
Борай – 117, 219
Бөгелмә – 104, 322
Бөгелмә өязе – 104, 322
Бөре (Бирск) өязе – 117, 219, 306
Буа – 222
Буа өязе – 69
Бубый (Иж-Бубый) – 50,89, 90, 109, 138, 280, 170, 173, 282, 283, 284, 336
Василий – 50
Верхнеурал өязе – 41, 82
Вятка губернасы – 89, 103, 175
Габделҗәлил – 82
Габдессәлам – 322, 323
Гарәбстан – 287
Германия – 142
Гомәр – 89, 95
Гурьевка – 123, 124
Дагыстан – 192, 193
Дуван Табын волосте – 131
Дүртөйле – 243
Екатеринбург – 219, 241
Зәет – 323
Зөя Башы (Зөя) – 123, 124, 126, 127, 128
Зөя өязе – 276
Зубачы – 156
Илек – 107
Индерка – 100
Иркутск – 52, 86, 87, 197, 221
Ирсай – 112
Иске Баграш (Елховой) – 105
Иске Килем – 150
Иске Котлумбәт – 196
Иске Мастак – 102
Иске Тазлар – 361
Иске Турай – 129
Истанбул – 76, 90, 139, 140, 143, 226, 274, 281, 288, 301, 328
Кабан – 260
Кавказ, Кавказия – 67, 175, 193, 216, 288
Казалы – 8, 10, 27, 159, 183, 186
Казачий – 156, 157

Казан – 8, 10, 12, 53, 54, 55, 56, 57, 77, 85, 92, 93, 106, 107, 108, 109, 110, 112, 116, 119, 120, 122, 131, 136, 150, 153, 161, 164, 165, 169, 173, 175, 191, 194, 198, 209, 229, 239, 240, 242, 246, 247, 250, 260, 269, 274, 275, 276, 277, 278, 280, 291, 294, 295, 299, 300, 313, 327, 340, 359, 360, 361
Казан өязе – 175, 325
Казанбаш – 325
Калмыш – 172
Капал – 48
Каразирек – 322, 323
Карамалы – 323, 336
Каргалы (Сәгыйдь бистәсе) – 46, 47, 73, 101, 134, 135, 136, 156, 158, 218, 256
Кармыш – 50
Каръяуды волосте – 151
Касыйм – 64, 65, 219
Кәрәкәшле – 282, 304, 309, 316, 317, 318, 321, 322, 323, 324, 325
Кече Кайбыч – 276
Килем – 145, 274, 275, 286
Кичуй – 106
Кузнецк өязе – 100
Курса – 175, 360
Күктәкә – 122
Күрдюм – 222
Күчәрбай – 172
Кызылъяр волосте – 306
Кырлай – 173
Кырмыскалы – 131, 300
Кырым – 73, 288
Кышкар – 361
Лепсы – 49
Малмыж – 131, 180, 200, 201, 202, 224
Манчыл – 222
Мәдинә – 192
Мәскәү – 95, 161, 203, 215, 252, 280, 282, 283, 339, 347, 360
Мастак – 92, 292
Минзәлә өязе – 105, 119, 155
Мөтәви – 323
Мерәс – 147
Миркитлин волосте – 336
Мисыр – 14, 30, 75, 192, 226, 287, 328
Морт – 131
Нижний (Түбән Новгород) – 24, 101, 203, 223
Нижңий губернасы – 49
Новая Казанка (Яңа кала) – 204
Нөркәй – 155
Одесса – 104
Олуг Күл – 155, 173
Олуг Мул – 114
Олуг Тигәнәле – 91
Олуг Тормы – 276
Омск – 88, 105, 219
Оренбург – 7, 8, 9, 12, 42, 43, 44, 72, 73, 85, 101, 109, 134, 150, 164, 168, 169, 170, 171, 172, 202, 203, 208, 211, 212, 217, 235, 238, 245, 260, 289, 294, 297, 299, 300, 301, 304, 305, 307, 315, 326, 327, 359,360
Оренбург губернасы – 193
Оренбург өязе – 130, 156, 178
Орск – 34, 88, 93, 100, 114, 160, 176, 218
Пенза – 8, 134, 203
Пермь – 104, 223, 235
Пермь өязе – 114
Петербург (Петроград) – 61, 67, 73, 74, 131, 203, 212, 213, 214, 215, 275, 276, 287, 338, 340
Петропавел – 64, 118, 298, 302, 315, 316, 325
Пишпәк – 49
Рәссуй – 323
Самара (Самар) – 8, 113
Сарапул өязе – 89, 91
Сарман – 119, 122
Сәмәрканд – 278

Сембер – 97, 123, 124, 125, 126, 127, 129, 264
Семи (Семипалат, Семипалатинск) – 8, 111, 220, 221, 334, 335
Семиречинский (Йидесу, Җидесу) – 48, 177, 178
Сергач – 50
Сергач өязе – 91
Себер (Сибирия) – 47, 51, 52, 198
Спас өязе – 91
Субаш-Аты – 360, 361
Суыксу – 70
Сүзүм – 300
Тамбов губернасы – 293
Тамьян волосте – 82
Ташкент – 115, 187, 188, 203, 313, 333
Ташлы Күл – 40
Тәтеш өязе – 276
Тоз-Түбә – 8, 34, 35, 36, 102, 291
Токмак – 49
Томск (Том) – 6, 12, 52, 198, 220, 268, 295
Төмән – 103
Төркия – 8, 30, 52, 180, 288, 345
Төркестан – 175, 284
Троицк – 73, 79, 105, 121, 137, 138, 151, 152, 153, 154, 155, 217, 245, 252, 253, 254, 278, 279, 299, 306, 307, 308, 312, 313, 350, 359
Туйкә – 322
Тукай – 130
Түбән Тигәнәле – 91
Түнтәр – 200
Уразай волосте – 49
Уральск – 100, 209
Урта Тигәнәле – 91
Уфа – 6, 8, 12, 56, 60, 66, 67, 72, 73, 84, 94, 97, 98, 100, 103, 106, 107, 117, 118, 121, 146, 147, 150, 155, 160, 161, 164, 166, 169, 189, 190, 191, 203, 212, 213, 216, 219, 221, 222, 223, 224, 227, 228, 229, 231, 232, 233, 235, 237, 242, 243, 246, 247, 249, 255, 260, 266, 275, 283, 284, 286, 287, 288, 291, 292, 297, 299, 310, 311, 312, 315, 316, 317, 324, 325, 327, 337, 343, 359
Уфа губернасы – 40, 89, 95, 155, 173, 329
Уфа өязе – 306
Финляндия – 342
Франция (Франсә) – 142, 263, 331
Хвалын өязе – 92, 102, 292
Хивә – 342
Һиндыстан – 75, 226
Чебенле – 101
Чеснакай – 156, 157
Чиләбе – 192, 314, 315, 316, 359
Чистай – 92, 280, 282, 291, 339
Чита – 222
Шәрекъ – 75
Шәрип волосте – 89, 95
Эдирне – 139
Эстәрле – 323, 324
Эстәрлетамак – 84, 113, 122, 254, 255, 279, 324
Юлык – 193
Юнә – 293
Ютазы – 316, 324
Якый (Бакый, Сакый) – 322, 343
Ямады – 306
Яңа Карамалы – 336
Яңа Кәрәкәшле – 323
Яңа Пар – 49
Яңа Үргәнеч – 297

*Муртазина Ляля Раисовна*
*Зиннатуллина Алсу Анваровна*
*(составители, авторы введения, примечаний, научно-справочного аппарата)*

**Вопросы женского образования в татарской периодической печати начала XX века (сборник документов)**

*на татарском языке*

*Научное издание*

Оригинал-макет – *А.Р. Тухватуллина*
Подписано в печать 18.12.2020 г. Формат 70×100 $^{1}/_{16}$
Усл. печ. л. 23,75 Тираж 100 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии ООО «Принт»
426035 г. Ижевск, ул. Тимирязева, 5

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
Татаровед.рф